АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ИНСТИТУТ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА
имени ГАЛИМДЖАНА ИБРАГИМОВА

Из сокровищницы научных экспедиций

# НАЦИОНАЛЬНО-КУЛЬТУРНОЕ НАСЛЕДИЕ

## *Татары Башкортостана. Стерлибаш*

Первая часть

КАЗАНЬ · 2021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән

# МИЛЛИ-МӘДӘНИ МИРАСЫБЫЗ

*Башкортстан татарлары. Стәрлебаш*

Беренче кисәк

КАЗАН · 2021

УДК 398+811.512.145
ББК 81.2=632.3+82.3(2=632.3)+85.12
М 48

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Гыйльми советы карарына нигезләнеп басыла*

**Редколлегия:**
***К.М. Миңнуллин*** *(рәис),* ***М.Р. Булатова, Ф.З. Яхин***

**Фәнни мөхәррир**
*филология фәннәре кандидаты* ***И.И. Ямалтдинов***

**Төзүче**
*филология фәннәре кандидаты* ***Н.Ш. Насыйбуллина***

**М48 Милли-мәдәни мирасыбыз: Башкортстан татарлары. Стәрлебаш.** 1 нче кисәк. – 2 нче басма. – Казан, 2021. – 440 б. – (Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән).
ISBN 978-5-93091-333-0

«Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» дигән сериядә дөнья күргән ике кисәктән торган чираттагы китап Башкортстан Республикасы Стәрлебаш районында яшәүче милләттәшләребез, аларның гореф-гадәтләре, тел-авыз иҗаты, сөйләш үзенчәлекләре, җыр-моңнары, җирле осталарның кул эшләре, шәҗәрәләр, археографик мирас турында бай мәгълүмат бирә.

Беренче кисәк татар халкының тарихына, теленә һәм мәдәни мирасына караган гомуми характердагы кереш сүз белән ачыла. Бу китапта Стәрлебаш мәдрәсәсе тарихын, урта диалектның минзәлә сөйләше бәләбәй урынчылыгына һәм көнбатыш диалектының стәрлетамак сөйләшенә караган тел үзенчәлекләрен, төбәк фольклорының бүгенге торышын тикшергән мәкаләләр урын алды.

Китап туган як тарихы һәм мәдәнияте белән кызыксынучыларга тәкъдим ителә.

**ISBN 978-5-93091-333-0**

© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты, 2019, 2021

*Тел – уйлауның коралы, уйның – калыбы...*
*Миллият бинасының нигез ташларыннан*
*иң ныклысы – тел... Телнең эчендә халыкның рухы,*
*моңы, уй һәм тойгысы яшеренгән.*

Галимҗан Ибраһимов

---

*Язык – это инструмент мышления,*
*форма мысли… Самый прочный камень*
*в фундаменте бытия нации – язык… В языке*
*сокрыты душа народа, его мысли и чувства.*

Галимджан Ибрагимов

# КЕРЕШ

Һәр төбәкнең табигать тә, анда яшәүче кешеләр дә, аларның ышанулары һәм дөньяга карашлары да йогынты ясый торган язмышы, йөзе, рухи үзәге-асылы бар. Шушы үзенчәлекне тою-аңлау өчен, әлеге төбәктә яшәү, һич булмаса, андагы тормышны өйрәнү һәм халык белән аралашу кирәк. Болар төбәкнең хәзерге хәл-халәтен күзалларга мөмкинлек бирә.

Үткән-тарих исә күпмедер күләмдә чыганакларда саклана; аларны археологик тикшеренүләр үткәреп тергезәләр; архив документларыннан һәм тарихи һәйкәлләрдән, ташъязмалардан эзлиләр. Археолог-галимнәр борынгы кешеләр турында мәгълүмат сакланган урыннарда разведка уздыра, казу эшләре оештыра һәм, табылдыкларга нигезләнеп, бик ерак тарих хакында төгәл мәгълүматлар китерә. Археологик тикшеренүләр вакытында эралар-чорлар да, шул заманнарда билгеле бер урында яшәгән кешеләрнең кайсы халыкка каравы, көнкүреше, һөнәрләре, нинди технологияләргә ия булуы, ышанулары да, күпмедер күләмдә зәвыгы, мәдәни казанышлары да ачыклана. Алар язма тарихи чыганаклар булмаган ерак заманнарны кабат күзалларга мөмкинлек тудыра, архив материаллары, документлар, эпиграфик һәйкәлләр һ.б. исә безгә якынрак чорлар хакында сөйли.

Алар да күрсәтә алмаган бик күп сәхифәләрне шәҗәрәләр һәм гаилә истәлекләре дә; төбәк кешеләре хәтерендә буыннан-буынга тапшырылып килгән мифлар һәм легендалар, җырлар һәм бәетләр дә; халыкның тел-сөйләм, әдәби фикерләү хасиятләре, көнкүреш һәм мәдәни үзенчәлекләре; матди һәм мәдәни кыйммәтләр дә

# ВВЕДЕНИЕ

У каждого региона есть свой неповторимый облик, своя судьба, особая духовная составляющая, которые формируются под влиянием местной природы, живущих там людей, их мировоззрения, привычек и верований. Чтобы понять и почувствовать это своеобразие, необходимо здесь пожить или хотя бы понаблюдать местное жизнеустройство и пообщаться с людьми. Только так можно получить представление о современном состоянии региона.

Страницы прошлого в какой-то степени раскрываются в исторических источниках, их восстанавливают посредством археологических исследований, находят в архивных документах и исторических памятниках. Ученые-археологи проводят исследования в местах, сохранивших следы пребывания древних людей, организуют раскопки и, опираясь на сделанные находки, способны представить точную информацию об очень далеких эпохах. Во время археологических изысканий выясняются возраст рассматриваемых объектов, принадлежность населения данной местности к тому или иному народу, особенности их повседневного быта, используемые технологии и ремесла, их верования, эстетические предпочтения и культурные достижения. Археологи дают возможность представить те далекие времена, о которых нет исторических источников.

Исторические источники (архивные материалы, документы, эпиграфические памятники и др.) рассказывают о ближайших к нам эпохах. Многие страницы истории, которые не получили отражение в источниках, сохранились в родословных, семейных преданиях; в передаваемых из поколения в поколение мифах и

үзендә саклый. Боларны күрә, аңлый, өйрәнә һәм аңлата белергә генә кирәк. Гаҗәеп күренеш: археологик һәм тарихи чыганакларда сакланмаган мәгълүматлар еш кына кешеләр хәтерендә, төбәкләрнең тормыш-көнкүрешендә яшәвен дәвам итә! Аларны төрле тармак галимнәре төбәкләргә экспедиция-сәфәрләр уздырып барлый, таба, өйрәнә... Аннары бу материаллар кабат халыкка кайта, шушы урынның, төбәкнең һәм бердәм татар милләтенең тарихи-мәдәни байлыгына әйләнеп яши бирә.

Татарстандагы академик фән, тарихи, археологик тикшеренүләр белән бергә, төбәкләргә чыгып, урыннарда халыкның яшәешен, көнкүрешен, матди һәм мәдәни хәл-халәтен өйрәнү белән һәрвакыт шөгыльләнә. Мондый тикшеренүләр XIX–XX гасыр чикләрендә үк аерым татар зыялылары инициативасы белән уздырыла башлый: бик күп татар җырларын, әкиятләрен, мәкальәйтемнәрен, миф-легендаларны язып алырга, татарларның телсөйләм үзенчәлекләрен ачыкларга ярдәм итә. Мәсәлән, К. Насыйри беренчеләрдән булып татар халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю, тарихи-этнографик тикшеренү эшен башлап җибәрә, 1871 елдан үзенең «Казан календаре»нда фольклор үрнәкләре бастыра. Бу эшкә Р.Ф. Фәхреддин, Г.Н. Әхмәрев, Х.Б. Бәдигый, Җ.Җ. Вәлиди һ.б. бик күп фикер ияләре кушыла.

XX гасырның аерым чорларында мондый тикшеренүләрне оештыруда активлык күзәтелә. 1920–1930 елларда – бигрәк тә Гыйльми үзәк эшчәнлеге белән бәйле махсус экспедицияләр фәнни нигездә уздырыла башлый. Н.И. Воробьев, А.С. Башкиров, Ф.И. Терегулов, М.С. Гобәйдуллина, К.С. Гобәйдуллин, С.Г. Вахиди һ.б. тарафыннан Арча, Әлки, Балык Бистәсе, Мамадыш, Минзәлә, Спас, Чаллы, Чистай төбәкләрендә шундый кыр тикшеренүләре үтә; аларда этнография, фольклор, сәнгать, тарихи-мәдәни мираска караган материаллар туплана.

Мондый эшчәнлек хәтта Бөек Ватан сугышы чорында да тукталмый. 1940–1980 елларда аерым тармак галимнәренең махсуслаштырылган экспедицияләргә чыгуы киң тарала. Бигрәк тә эпиграфик (Һ.В. Йосыпов), археографик һәйкәлләрне (С.Г. Вахиди, М.И. Әхмәтҗанов, М.Г. Госманов һ.б.), диалектларны

легендах, песнях и баитах, в специфике разговорной речи и литературного мышления; особенностях повседневной жизни и культуры; в материальных и культурных ценностях населения данного региона. Нужно только увидеть, понять, изучить и правильно интерпретировать эти явления. Удивительно то, что материалы, не сохранившиеся в археологических и исторических источниках, часто продолжают жить в памяти людей, в повседневном жизненном пространстве населения данной местности! Ученые и специалисты в различных областях знаний во время экспедиций в регионы находят, собирают, изучают эти особенности… А затем эти материалы, после комплексного изучения, возвращаются к народу и продолжают жить, став частью общего историко-культурного наследия татарского народа и данного региона.

Академическая наука Татарстана, наряду с историческими и археологическими изысканиями, всегда держала в центре своего внимания изучение жизни, быта, особенностей материального и культурного состояния татарского народа, проживающего в том или ином регионе. Подобные исследования проводились во время экспедиционных выездов по инициативе представителей татарской интеллигенции, на рубеже XIX–XX веков было записано много татарских песен, сказок, пословиц и поговорок, мифов и легенд; зафиксированы местные особенности татарского языка и речи. Например, К. Насыри одним из первых начал собирать материалы по устному творчеству татарского народа и по исторической этнографии; с 1871 года он регулярно публиковал образцы фольклора в своем «Казанском календаре». К этой работе присоединились Р.Ф. Фахретдинов, Г.Н. Ахмеров, Х.Б. Бадиги, Дж.Дж. Валиди и другие представители татарской интеллигенции.

В отдельные периоды XX века наблюдалась особая активность в организации подобных исследований. В 1920–1930-е годы начинают проводиться специальные научные экспедиции, что было связано с деятельностью созданного Академического центра. Подобные полевые исследования осуществляли Н.И. Воробьев, А.С. Баширов, Ф.И. Терегулов, М.С. Губайдуллина, К.С. Губайдуллин, С.Г. Вахиди и др. в Арском, Алькеевском, Рыбно-Слободском, Мамадышском, Мензелинском, Спасском, Челнинском, Чистопольском

(Л.Җ. Җәләй, Л.Т. Мәхмүтова, Н.Б. Борһанова, Д.Б. Рамазанова, Ф.С. Баязитова һ.б.), төрки-татар фольклорын (Х.Х. Ярмөхәммәтов, И.Н. Надиров, Х.Ш. Мәхмүтов, Л.Ш. Җамалетдинов һ.б.) җыю-барлау максатыннан, Татарстанда һәм аннан читтә яшәүче татар авыллары һәм шәһәрләрендә тикшеренүләр уздырыла. Экспедицияләрдә тупланган материал «Татар халык иҗаты» (1951, 1954), «Татар халык әкиятләре», 2 томда (1946, 1956), «Татар халык җырлары» (1965), «Татар халык иҗаты», 12 томда (1976–1988), «Татар халык сөйләшләре», 2 томда (2008), «Татар теленең диалектологик сүзлеге» (2009), «Татар халык сөйләшләренең атласы», «Татары Среднего Поволжья и Приуралья» (1967) кебек фундаменталь хезмәтләр, мәдәният-сәнгать тарихы, милли һөнәрчелек, кулъязма һәм басма китап тарихы һ.б. өлкәләр буенча күпсанлы китаплар нигезендә ята.

XXI гасыр башында, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең системалы эшчәнлеге нәтиҗәсендә, бу эш яңа баскычка күтәрелә: һәр елны милләттәшләребез яшәгән төбәкләргә комплекслы экспедицияләр оештырыла башлый. Комплекслы рәвештә өйрәнгәндә, тел, әдәбият, фольклор, сәнгать юнәлешенең төбәк хәзинәсендә булган барлык төр байлыгы – буыннан-буынга тапшырыла килгән авыз иҗаты үрнәкләре, бәйрәмнәре, йолагадәтләре, музыкасы, бәйләү-чигү кебек кул эшләре осталыгы, йорт-каралты бизәкләре, кием-салымы, тел үзенчәлекләре, эпиграфик һәм археографик мирасы – һәрберсе барлана-туплана һәм җентекләп анализлап бәяләнә. Татарстанда Актаныш (2009), Апас (2010), Кукмара (2011), Чүпрәле (2012), Мамадыш (2013), Арча, Әтнә (2016), Минзәлә, Мөслим (2017), Азнакай, Буа (2019) районнарындагы татар авыллары һәм поселокларында шундый кыр тикшеренүләре уза.

Татарстаннан читтә: Түбән Новгород, Курган, Оренбург өлкәләре (2010), Мари Илендәге Бәрәңге районы (2011), Удмуртия Республикасы (2012), Пермь краендагы Барда районы һәм Әстерхан өлкәсе (2013), Омск һәм Самара (2014), Оренбург һәм Томск (2015), Чиләбе өлкәләре, Казакъстан Республикасы (2016), Новосибирск өлкәсе, Башкортстан Республикасының

районах, собирая при этом материалы по этнографии, фольклору, искусству, историко-культурному наследию данных регионов.

Эта работа не прекращалась даже в годы Великой Отечественной войны. В 1940–1980-е годы широкое распространение получили специализированные экспедиции. В Татарстане и за его пределами, в местах компактного проживания татар, проводились исследования по сбору эпиграфических (Х.В. Юсупов), археографических (С.Г. Вахидов, М.И. Ахметзянов, М.Г. Усманов и др.) памятников, изучению диалектов (Л.Дж. Заляй, Л.Т. Махмутова, Н.Б. Бурганова, Д.Б. Рамазанова, Ф.С. Баязитова и др.), образцов тюрко-татарского фольклора (Х.Х. Ярмухаметов, И.Н. Надиров, Х.Ш. Махмутов, Л.Ш. Замалетдинов и др.). Собранные в экспедициях материалы легли в основу таких фундаментальных трудов, как «Татарское народное творчество» (1951, 1954), «Татарские народные сказки», в 2-х томах (1946, 1956), «Татарские народные песни» (1965), «Татарское народное творчество», в 12 томах (1976–1988), «Татарские народные говоры», в 2-х томах (2008), «Диалектологический словарь татарского языка» (2009), «Атлас говоров татарского народа», «Татары Среднего Поволжья и Приуралья» (1967) и многочисленных книг по истории культуры и искусства, народных ремесел, истории татарской рукописной и печатной книги и др.

В начале XXI века, благодаря системным усилиям Академии наук Республики Татарстан, эта работа вышла на новый уровень: началась организация комплексных экспедиций в регионы проживания представителей татарского народа. В ходе комплексного изучения собираются, тщательно оцениваются и анализируются все богатства духовной сокровищницы региона: язык, литература, фольклор, искусство, то есть все то, что передавалось из поколения в поколение – образцы устного творчества, праздничные традиции, обрядовая культура, музыка, искусство вышивки, убранство домов, одежда, особенности языка, эпиграфическое и археографическое наследие. В Татарстане подобного рода полевые исследования были проведены в деревнях и селах Актанышского (2009), Апастовского (2010), Кукморского (2011), Дрожжановского (2012), Мамадышского (2013), Арского, Атнинского (2016),

Стәрлебаш районы (2017), Ульяновск (2017, 2018), Иркутск, Киров (2018), Пенза, Төмән өлкәләре, Үзбәкстан Республикасы (2019) җирләрендә булып, анда яшәүче милләттәшләребезнең тел-сөйләш үзенчәлекләрен, тормыш-көнкүрешен, мәдәниятен, сәнгатен, кульязма һәм ташъязма мирасын барлау, аларны фәнни эшкәртү, тикшерү эше җайга-системага салына.

Экспедициядә җыйган материалларны тикшерү, өйрәнү, фәнни әйләнешкә кертү белән бергә, шушы вакыттан Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты архивында 1940–2000 елларда шул ук төбәкләргә, авылларга уздырылган экспедиция материалларын барлау, яңа кайткан мәгълүматлар белән чагыштыру башкарыла. Шул җирлектә фәнни хезмәтләр әзерләнә. Әйтик, бүген инде галимнәребез «Татар халык иҗаты»ның 25 томлыгын төгәлләү алдында.

Элегрәк җыелган һәм яңа гына алып кайтылган материалларны бергә туплау «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясендә «Милли-мәдәни мирасыбыз» гомуми исеме астында фәнни-популяр китаплар әзерләү эшен башлап җибәрергә этәргеч була. Бу эшнең максаты – халыкның рухи байлыгын үзенә кайтару, аны популярлаштыру, тарихка кертеп калдыру, шушы мәгълүматлар ярдәмендә татар халкының милли үзаңын ныгыту.

Бүген инде бу сериядән 20 китап дөнья күрде, яңаларын әзерләү дәвам итә. Китапларда экспедиция үткән һәр төбәкнең мәдәни тарихы, танылган нәселләр, авыллар-шәһәрләрнең үткәне, гореф-гадәтләре һәм тел үзенчәлекләре төрле яктан яктыртыла. Шулай ук шәҗәрәләр, җирле кул осталарының эш үрнәкләре, кызыклы экспонатлар турында бай мәгълүмат бирелә.

Татар халкының рухи асылын, тарихи-мәдәни сыйфатбилгеләрен бербөтен итеп күзаллау һәм тергезүнең иң нәтиҗәле һәм ышанычлы ысулы булып фәнни экспедицияләр, кыр тикшеренүләре тора. Чөнки бу яшәеш бик борынгыдан килә, татар халкы Евразиянең гаять киң территориясендә формалашкан! Төрле табигый, тарихи, конфессиональ шартларда, төрле этник тирәлектә (төрки халыкларның төрле төркемнәре, фин, угор,

Мензелинского, Муслюмовского (2017), Азнакаевского, Буинского (2019) районов.

За пределами Татарстана также налажена системная работа по сбору, научной обработке, изучению особенностей говоров, повседневного быта, культуры, искусства, рукописного и эпиграфического наследия татар, проживающих в Нижегородской, Курганской, Оренбургской областях (2010), Параньгинском районе Марий Эл (2011), Удмуртской республике (2012), Бардымском районе Пермского края и Астраханской области (2013), Омской и Самарской (2014), Оренбургской и Томской (2015), Челябинской областях и Республике Казахстан (2016), Новосибирской области и Стерлибашевском районе Республики Башкортостан (2017), Ульяновской (2017, 2018), Иркутской и Кировской областях (2018), Пензенской, Тюменской областях и Республике Узбекистан (2019).

Наряду с исследованием, изучением и введением в научный оборот материалов, найденных в экспедициях, ведется работа по сопоставлению новых сведений с материалами, которые были собраны в этих местах ранее – в 1940–2000-х годах и хранятся сейчас в архиве ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. На их основе готовятся серьезные научные труды. К слову, на сегодняшний день завершается работа над фундаментальным 25-томным сводом «Татарское народное творчество».

Проведенные исследования на основе объединения всего комплекса собранных материалов позволили начать работу по подготовке научно-популярных книг под общим названием «Национально-культурное наследие» из серии «Из сокровищницы научных экспедиций». Возвращение народу духовного наследия, популяризация и сохранение его в анналах истории способствует укреплению национального самосознания татарского народа.

На сегодняшний день увидели свет 20 книг из этой серии, продолжается подготовка новых. В книгах представлены обширные сведения по истории региона, прошлом известных татарских родов, деревень и городов, а также об обычаях, традициях и языковых особенностях татар. Вместе с тем в книгах дается богатая информация о родословных, работах местных умельцев и других интересных экспонатах.

славян этнослары янәшәсендә) татарларның этнотерриториаль (Идел-Урал буе, Себер, Әстерхан татарлары), субэтник (Казан, Касыйм татарлары, мишәрләр), субконфессиональ (керәшеннәр, иштәкләр, нагайбәкләр) төркемнәре барлыкка килгән. Бу төркемнәр кая гына яшәвенә карамастан, гомумтатар милли үзаңына ия. Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты уздыра торган экспедиция материаллары нәкъ шул хакта сөйли, һәр сәфәр шушы фикерне куәтли.

Әлбәттә, уртак милли үзаңның нигезен татар теле тәшкил итә. Төрки телләрнең кыпчак төркеменә караган татар теле иң борынгы телләрдән санала. Татар теленең төп лексик, фонетик, грамматик үзенчәлекләре борынгы төрки телдә үк формалаша. Шуңа күрә дә дөньяның төрле кыйтгаларында яшәүче татарларның, төрле сөйләш вәкилләре булсалар да, телсөйләмнәре уртак лексик, фонетик, грамматик калыпларга-кануннарга нигезләнә. Шуңа күрә без борынгы рун язулы истәлекләрне укып, эчтәлегенә төшенә алабыз, казакъ, үзбәк, азәрбайҗан һ.б. төрки телләрне дә аңлыйбыз, татар теленең төрле диалектларында да зур аермалар сизмибез.

Татар милли әдәби теле исә XIX–XX гасырлар чигендә Казанда, Уфада, Оренбургта, Троицкида, Әстерханда һ.б. шәһәрләрдә һәм алар тирәсендәге авылларда гомумхалык теле булып оешып җитә. Тукай теле, Туфан теле, Еники теле – барыбыз өчен дә уртак байлык. Татар әдәби теленең үсеше барышында кайбер традицион хасиятләр һәм формалар югала, әмма алар сөйләшләрдә сакланып кала. Димәк, төрле урыннарда компактлы яшәгән татарларның сөйләшләре борынгы уртак телебезнең үзенчәлекләрен югалтмавы белән дә кадерле. Экспедицияләр материалы безгә шул хакта да сөйли.

Татарларның мәҗүси заман ышанулары ислам дине белән бәйле күзаллаулары белән беррәттән бүген дә халык арасында яши. Бигрәк тә безнең халкыбыз тарихында мең еллык урыны булган ислам диненең һәм матди, һәм мәдәни тормышка йогынтысы халыктан җыелган материалларда аермачык күренә. Каберташ

Единственно надежным и достоверным способом составления общего представления о духовных основах и историко-культурных особенностях татарского народа является организация научных экспедиций и полевых исследований. Это связано с тем, что образ жизни татар формировался с древних времен и на очень обширной территории Евразии. Различные этнотерриториальные (татары Волго-Уральского региона, сибирские, астраханские татары), субэтнические (казанские, касимовские татары, мишары), субконфессиональные (кряшены, иштяки, нагайбаки) группы татар сформировались в разнообразных природных, исторических, конфессиональных условиях и в сложном этническом окружении (рядом с разными группами тюркских народов, финно-угорскими, славянскими этносами). Несмотря на то, что данные группы татар проживают на различных территориях, они все объединены общетатарским национальным самосознанием. Каждая экспедиция ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ и собранные материалы неуклонно подтверждают это.

Разумеется, фундаментом общего национального самосознания является язык. Татарский язык, относящийся к кипчакской группе, считается одним из самых древних языков. Основные лексические, фонетические, грамматические особенности татарского языка сформировались уже в древнетюркском языке. Именно поэтому татар, проживающих в разных местах и являющихся представителями разных говоров, объединяет единая основа – общие лексические, фонетические, грамматические закономерности. Благодаря этому мы можем понять самые древние рунические письмена, понимаем казахский, узбекский, азербайджанский и другие языки, не ощущаем большой разницы между диалектами татарского языка.

Становление татарского литературного языка в качестве общенародного происходит на рубеже XIX–XX веков в городах Казань, Уфа, Оренбург, Троицк, Астрахань и др., а также окружающих их селах. Язык Тукая, язык Туфана, язык Еники – это наше общее богатство. В ходе развития татарского литературного языка теряются некоторые его традиционные свойства и формы, но они сохраняются в говорах. Поэтому говоры татар, компактно про-

язмалары, борынгы китаплар һәм кульъязмалар, шәкерт дәфтәрләре, күчереп язылган текстлар, әдәп-әхлак кагыйдәләре, йола-гадәтләр, ышанулар һәм күзаллаулар, бәйрәмнәр һәм ырымнарда татар халкының барлык этник төркемнәре өчен уртак булган мәдәни мирас чагылыш таба. Ислам мәдәнияте гадәти көнкүреш һәм кеше тормышындагы иң мөһим вакыйгаларга (туу, исем кушу, өйләнү, гаилә, бакыйлыкка күчү) бәйле йолаларда этник мәдәнияткә үрелеп китә. Вакытны күрсәткән азан тавышы, намаз-догалар, җомга көнне бәйрәм дип карау белән бергә, татар халкының мәдәни хәтеренә бәетләр, мөнәҗәтләр, дини-суфичыл текстлар кереп урнаша. Традицион йолалар һәм бәйрәмнәр: Сабан туе, Җыен, Корбан гаете, Ураза гаете, өмәләр, Карга боткалары һәм Яңгыр боткалары – болар да уртак байлыгыбыз һәм татарлыгыбызның аерылгысыз билгеләре.

Комплекслы экспедицияләр вакытында төрле җирлекләрдә кием-салым, һөнәрләр, азык-төлек әзерләү рәвеше, архитектура, музыка сәнгате буенча да күзәтүләр ясала. Әйтик, төрле җирләрдә яшәүчеләрнең киемнәрендә үзгәлекләр булса да, татарларның традицион гомуммилли өс киеме Казан татарларыныкы йогынтысында формалашкан дигән фикер безнең материаллар белән дә тагын бер тапкыр раслана. Татарлар кайда гына төпләнмәсен – мәчет торгыза. Халкыбызның һәрчак белемгә омтылышы, балалар тәрбияләүгә зур әһәмият бирүе, олыларга аерым бер хөрмәт белән каравы, туган җир һәм нәсел-ыруның һәр кешене саклаучы-яклаучы көч дип санавы, шигърияткә-иҗатка тартылуы да кыр тикшеренү нәтиҗәләрендә чагылыш таба.

Республикабыздагы күтәрелеш татар дөньясының җанлануына, милли үзаң уянуга, татарларның үзләрен бердәм халык итеп тоя башлавына китерде. Хәтта элек-электән туган җирләре, ватаннары бик еракта – әйтик, Польшада яки Литвада, Әстерханда яки Иранда, Уралда яки Себердә, Кытайда яки Финляндиядә булса да, уртак тарих, уртак мәдәният һәм Казан, Татарстан татарларны берләштереп торган үзәк булып кала.

Һәр милләт булып җитешкән бердәмлек төрле мәдәниятләрнең хасиятләрен үзенә туплый. Бу – аксиома. Көчле мәдәният

живающих на разных территориях, ценны для нас сохранением особенностей нашего древнего общего языка. Материалы экспедиций говорят именно об этом.

В народе и сегодня продолжают сосуществовать древние домусульманские верования татар и представления, связанные с исламом. Материалы экспедиций особенно ярко демонстрируют влияние ислама на материальную и культурную жизнь нашего народа на протяжении его тысячелетней истории. Общее культурное наследие всех этнических групп татар ярко выражены в надгробных памятниках, древних книгах и рукописях, тетрадях шакирдов, списках литературных произведений, нравственно-этических нормах, обрядах и обычаях, представлениях и поверьях, праздниках и верованиях. В моменты самых важных событий человеческой жизни (рождение, имянаречение, свадьба, семейная жизнь, похороны) традиции исламской культуры тесно переплетаются с обрядами этнической культуры. Наряду со звуками азана, по которым определяли время, с молитвами, с обычаем считать пятницу праздничным днем и т. д. в культурную память татарского народа вошли баиты, мунаджаты, религиозно-суфийские тексты. Наши традиционные обряды и праздники: Сабантуй, Джиен, Курбан байрам, Ураза байрам, коллективные помочи (өмә), обряды вызывания дождя и встречи весны – все это тоже наше общее наследие и то, что делает нас татарами.

Во время комплексных экспедиций в различные места проживания татар изучаются одежда, ремесла, традиции приготовления пищи, архитектура, музыкальное искусство и т. д. Например, наши материалы ещё раз подтвердили мысль о том, что, несмотря на некоторые различия в одежде татар разных регионов, очевидно, что традиционная национальная татарская одежда сформировалась под влиянием казанских татар. Где бы ни селились татары, они воздвигали мечети. Стремление народа к знаниям и просвещению, большое внимание, которое они уделяют воспитанию детей, особое уважение к пожилым, почитание родной земли и своего рода – как оберегающих и защищающих сил, склонность к поэтическому творчеству – все это отражается в материалах полевых исследований.

үз тирәсенә башкаларны тарту сәләтенә ия. Алтын Урда чорында ук «татар казаны» күп кабиләләрне кайната, шул исәптән болгарларны да татар политонимына юнәлдерә.

Татар тарихы сикәлтәле, б.э.к. III гасырдан башлап язма истәлекләрдә эз калдыра. Шул ерак гасырлар чоңгылында Бөек кытай диварыннан төньяктарак төрки телле һуннарның империясе төзелә. II гасырда ул хәзерге Казакъстан далаларына күченә. Идел һәм Урал арасында угорлар белән укмаша, IV гасырда Европага юнәлә, халыкларның Бөек күчешен башлап җибәрә. Һуннарның нәсел тамгасы – казан – безнең башкалабыз Казанның да үзәгендә, Казансу буеннан милләттәшләребезне сәламли.

V гасырда Һун империясе таркала – Бөек кытай диварыннан Дунайга кадәр җирләрдә Бөек Төрки каганлык калкып чыга. Аның җимерелүеннән соң исә Болгар цивилизациясе чәчәк ата. Көнчыгышта куәтле татар халкы үзенең дан-шөһрәтен яңгырата. Алтын Урда таркалгач, аның варислары ханлыклар төзи. Бүген алар касыйм, әстерхан, себер татарлары, мишәрләр, керәшеннәр, нагайбәкләр һ.б. атамалар белән исемләндереп йөртелгән төркемнәр буларак билгеле. Аларны бер тел, бер югары мәдәният – Мәрҗани фәһеме, Тукай шигырьләре, Сәйдәш музыкасы, Урманче сурәтләре берләштерә.

Татар асылын, аның рухи үзәген, татарлыкның гомуми һәм үзенчәлекле сыйфатларын аңлау-төшенү өчен, һичшиксез, тарихи барышны гына түгел, бәлки халыкның хәтерендә яшәгән рухи кыйммәтләрне дә барларга, өйрәнергә кирәк. Татарстан Фәннәр академиясе, аның институтлары, шул исәптән Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре әлеге юнәлештә эшлиләр. Дөрес, татарлар элек-электән күпләп яшәгән барлык урынчылыклар да өйрәнелгән дияргә иртәрәк әле. Димәк, бу эш дәвам итәргә тиеш.

Фәнни күзлектән караганда, борынгы һәм бай тарихлы, үз әдәби теле, профессиональ әдәбияты һәм сәнгате булган бердәм татар милләте без. XX гасырда татар мәдәнияте, мәгариф һәм фән югары үсеш ала. Бу процесста төрле җирләрдә яшәгән, төрле

Разумеется, современная жизнь татар, где бы они ни жили, связана с Татарстаном. Общественный и духовный подъем в нашей республике способствовал оживлению татарского мира, пробуждению национального самосознания, осознанию татарами себя как единого народа. Даже для татар, чьей родиной давно является Польша или Литва, Астрахань или Иран, Урал или Сибирь, Китай или Финляндия, средоточием общей истории, общей культуры и единым связующим звеном остаются Казань и Татарстан.

Каждая общность, достигшая уровня нации, вбирает в себя свойства различных культур. Это – аксиома. Сильная культура обладает способностью консолидировать вокруг себя другие. В эпоху Золотой Орды в «татарском котле» перекипели многие племена, по той же причине название «булгары» стало татарским политонимом.

Перипетии татарской истории нашли отражение в письменных источниках, начиная с III века до нашей эры. В те далекие времена к северу от Великой китайской стены формируется тюркоязычная империя хуннов. Во II веке они переселяются в степи современного Казахстана. Сплотившись с уграми между Волгой и Уралом, они устремились в Европу, начав процесс Великого переселения народов. Не случайно родовая тамга рода хуннов – казан – сегодня приветствует наших соотечественников на берегу реки Казанки в центре Казани.

В V веке Хуннская империя распадается, и на землях от Великой китайской стены и до Дуная возникает Великий Тюркский каганат. После его распада получает расцвет Булгарская цивилизация. Могучий татарский народ во весь голос заявляет о себе на востоке. После распада Золотой Орды её наследники создают отдельные ханства. Сегодня их потомки живут как касимовские, астраханские, сибирские татары, мишари, кряшены, нагайбаки и другие группы. Их объединяют общий язык, общая высокая культура – интеллект и разум Марджани, поэзия Тукая, музыка Сайдашева, творения Урманче.

Для понимания сути народа, его духовной сущности, общих и специфических особенностей татарства, безусловно, надо изучать не только историю, но и сохранившиеся в памяти народа

этнографик төркемнәргә караган татарларның өлеше зур. Безнең көчебез – бердәмлектә!

* * *

Башкортстан Республикасы Стәрлебаш районы татарларының тарихын, телен, мәдәниятен тирәнтен өйрәнү максатыннан, татар галимнәре тарафыннан әлеге төбәккә берничә тапкыр махсус экспедицияләр оештырыла. Казан галиме, телче-диалектолог Д. Рамазанова тарафыннан Стәрлебаш районының Бузат, Яшерган (1969), Яңгырчы, Айдарәле, Турмай, Куганакбаш (1971), Хәлекәй, Карагыш (1974) авылларында шактый күп материал туплана. Әлеге мәгълүмат соңрак «Татар халык сөйләшләренең атласы»нда урын ала. Соңгы елларда Д. Рамазанова җитәкчелегендә яшь диалектологлар М. Булатова, Ә. Хөсәенова әлеге төбәктәге сөйләшләрне монографик планда өйрәнүне дәвам итә.

1971 елда Башкорт дәүләт университетының татар бүлеге укытучысы, әдәбият галиме Ф. Хатипов җитәкчелегендә Стәрлебаш, Яңгырчы, Хәлекәй, Бузат, Тәтер-Арслан, Кызыл-Яр, Айтуган, Өч-Әсән, Карамалы-Бузат, Гали-Бузат авылларында студентлар тарафыннан халык авыз иҗаты материаллары туплана. Әлеге экспедиция язмаларының бер өлеше Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан әзерләнгән татар халык иҗаты әсәрләренең 12 томлык җыелмасында (1976–1988) дөнья күрә.

Халык хәзинәсен бөртекләп җыю юнәлешендәге эшне дәвам итеп, 2010–2011 елларда Стәрлебаш районының татар авылларында институт хезмәткәрләре М. Әхмәтҗанов, Н. Насыйбуллина тарафыннан борынгы кулъязмалар туплана, ташъязмалар өйрәнелә. Экспедиция вакытында җыелган бай мирас бүгенге көндә институтыбызның Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана. Шул ук вакытта М. Әхмәтҗанов әзерләгән «Татар археографиясе» исемле җыентыклар сериясенең сигезенче китабында XIX гасырда иҗат иткән Стәрлебаш шагыйрьләренең әсәрләре тасвирлана.

духовные ценности. Академия наук Татарстана, её институты, в том числе ученые ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, работают в данном направлении. Естественно, ещё не все местности и регионы исторического проживания татар охвачены и изучены. Значит, эта работа должна продолжаться.

Если судить с научных позиций, то мы – единая татарская нация с древней и богатой историей, имеющая свой литературный язык, профессиональную литературу и искусство. В XX веке культура, просвещение и наука татарского народа достигли очень высокого уровня. В этом процессе незаменима роль татар, проживающих в разных регионах и представляющих различные этнографические группы. Ведь наша сила – в нашем единстве!

* * *

На протяжении десятилетий татарские ученые не раз организовывали специализированные экспедиции в Стерлибашевский район Республики Башкортостан с целью изучения истории, языка, культуры татар этого края. В селах Бузат, Яшерганово (1969), Янгурча, Айдарали, Турмаево, Куганакбаш (1971), Халикеево, Карагуш (1974) казанский ученый-диалектолог Д. Рамазанова собрала много материалов, которые впоследствии вошли в «Атлас татарских говоров». В последние годы молодые диалектологи М. Булатова, А. Хусаинова под руководством Д. Рамазановой исследовали говоры этого района в монографическом плане.

В 1971 году под руководством Ф. Хатипова – преподавателя татарского отделения Башкирского государственного университета – студентами был произведен сбор фольклора в селах Стерлибашево, Халикеево, Бузат, Тятер-Арасланово, Кызыл-Яр, Айтуган, Учуган-Асаново, Карамалы-Бузат, Галей-Бузат. Часть материалов этой экспедиции вошла в 12-томное собрание произведений татарского народного творчества (1976–1988), подготовленного Институтом языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова.

Продолжая пополнять по крупицам сокровищницу татарского народа, в 2010–2011 годах экспедиция в составе сотрудников ИЯЛИ М. Ахметзянова и Н. Насибуллиной обнаружила

Институтның берничә өлкәгә кагылышлы тикшеренүләрне максат итеп куйган комплекслы экспедициясе 2017 елда кабат Стәрлебаш якларына юл алды. Экспедиция составында фольклорчылар, телче-диалектологлар, археография, сәнгать һәм музыка белгечләре барлыгы 15 татар авылында (Айдарәле, Әмир, Бакча, Бакый, Бузат, Гөлем, Карагыш, Куганакбаш, Стәрлебаш, Турмай, Тәтер-Арслан, Өч-Әсән, Хәлекәй, Яңгырчы, Яшерган) булдылар.

Экспедиция җитәкчесе – филология фәннәре кандидаты, фольклорчы И. Ямалтдинов һәм фәнни хезмәткәр Г. Яхшисарова тарафыннан барлыгы 700 берәмлеккә якын халык авыз иҗаты үрнәкләре язып алынды. Эпиграфик һәм археографик мирасны өйрәнү юнәлешендә филология фәннәре докторы Ф. Яхин һәм филология фәннәре кандидаты Н. Насыйбуллина барлыгы 100 берәмлеккә якын материал туплады. Стәрлебаш авылы ташъязмаларын күп еллар дәвамында фәнни хезмәткәр В. Усманов өйрәнә, аның фәнни хезмәтләре даими дөнья күреп тора. Шул ук вакытта Н. Насыйбуллина Гали-Бузат, Карамалы-Бузат, Кече Бузат, Өч-Әсән авыл зиратларындагы гарәп язулы 107 ташны исәпкә алды. Филология фәннәре кандидаты М. Булатова җирле сөйләм үзенчәлекләрен этнолингвистик юнәлештә тикшерде. Этномузыкология өлкәсендә сәнгать фәннәре кандидаты Э. Галимова бу төбәктә яшәгән татарларның милли музыкаль үзенчәлекләрен барлады. Халкыбызның сәнгать үрнәкләре сәнгать фәннәре кандидаты Л. Шкляеваның тикшеренүләрендә игътибар үзәгенә куелды. Югарыда телгә алынган мәгълүматларның барысы да лексикология, этнография, этномузыкология, тарих һәм фольклористика өчен бик зур хәзинә булып тора.

Стәрлебаш районына төрле елларда оештырылган экспедицияләр нәтиҗәсендә табылган материалларга анализ ясаган фәнни һәм фәнни-популяр мәкаләләр һәм башка материаллар ике кисәктән торган «Милли-мәдәни мирасыбыз. Башкортстан татарлары. Стәрлебаш» китабында урын алды. Беренче кисәк татар халкының тарихына, теленә һәм мәдәни мирасына караган гомуми характердагы кереш сүз белән ачыла. Анда Стәрлебаш

в татарских селах Стерлибашевского района старинные рукописи и исследовала намогильные камни. Собранные во время экспедиции ценные материалы хранятся сегодня в Центре письменного и музыкального наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова. В 8-ой части серии сборников ученого-археографа М. Ахметзянова «Татарская археография» были представлены поэтические произведения XIX века, написанные авторами из Стерлибашевского района.

В 2017 году в Стерлибашевский район была организована экспедиция Института, поставившая себе целью провести исследования в нескольких направлениях. В составе группы ученых были фольклористы, диалектологи, археографы, искусствоведы, музыковеды; они побывали в 15 татарских селах и деревнях района (Айдарали, Амирово, Бахча, Бакеево, Бузат, Гулюм, Карагуш, Куганакбаш, Стерлибашево, Турмаево, Тятер-Арасланово, Учуган-Асаново, Халикеево, Янгурча, Яшерганово).

Фольклористы – руководитель экспедиции, кандидат филологических наук И. Ямалтдинов и научный сотрудник Г. Яхшисарова – записали около 700 единиц образцов фольклора, которые стали поистине драгоценной находкой. Доктор филологических наук Ф. Яхин и кандидат филологических наук Н. Насибуллина собрали около 100 единиц материалов эпиграфического и археографического характера. Намогильные камни села Стерлибашево уже на протяжении многих лет изучает научный сотрудник Института В. Усманов. Пополнив собранную им коллекцию материалов, Н. Насибуллина взяла на учет еще 107 татарских надгробных камней с надписями, сделанными арабским шрифтом, на кладбищах сел Карамалы-Бузат, Галей-Бузат, Малый Бузат, Учуган-Асаново. Особенности местного говора с этнолингвистической точки зрения исследовала кандидат филологических наук М. Булатова. Этномузыколог, кандидат искусствоведения Э. Галимова изучила специфические особенности татарской музыкальной культуры, а кандидат искусствоведения Л. Шкляева – образцы татарского народного прикладного искусства данного региона. Все упомянутые выше материалы стали бесценной находкой для лексикологии, этнографии, этномузыкологии, истории и фольклористики.

мәдрәсәсе тарихын, урта диалектның минзәлә сөйләше бәләбәй урынчылыгына һәм көнбатыш диалектның стәрлетамак сөйләшенә караган тел үзенчәлекләрен, төбәк фольклорының бүгенге торышын тикшергән мәкаләләр урнаштырылды. Икенче кисәк дәүләт, дин һәм җәмәгать эшлеклесе М. Тукаевның Стәрлебаш авылы һәм мәдрәсәсе тарихына караган хезмәтләре белән ачыла. Әлеге китапка Стәрлебашның затлы китапларыннан булган «Дөррел-Кәлам», Стәрлебаш шагыйрьләре әсәрләре, Стәрлебаш татарларының традицион музыка мәдәниятен, халык сәнгатен, бу төбәктә табылган гарәп телле кулъязма үзенчәлекләрен, элегрәк тупланган халык авыз иҗаты материалларын анализлаган мәкаләләр, кулъязмаларның тасвирламасы, кулъязма мирасны саклаучылар турында һәм Хәлекәй авылы тарихына кагылышлы мәгълүматлар кертелде. Кушымта рәвешендә академик В. Бартольдның Стәрлебашта тукталуы турында хәбәр бирелде.

Ике кисәктән торган «Милли-мәдәни мирасыбыз. Башкортстан татарлары. Стәрлебаш» китабында урын алган мәкаләләрнең барысы да халык теленең, авыз иҗатының, милли сәнгатьнең һәм гомумән традицион мәдәниятнең тере яшәешен үзе күргән белгеч күзлегеннән бәя биреп язылган. Бирегә тупланган ядкярләр татар халкы тарихын, аның мәдәни дөньясын өр-яңа мәгълүматлар белән баета, халкыбыз турында тагын да киңрәк күзаллау булдырырга ярдәм итә. Китаплар укучы күңеленә хуш килер дигән өметтә калабыз.

***Ким Миңнуллин,***
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институты директоры,*
*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*мөхбир әгъзасы*

В книгу «Национально-культурное наследие. Татары Башкортостана. Стерлибаш», состоящую из двух частей вошли научные и научно-популярные статьи, посвященные анализу материалов, обнаруженных во время экспедиций в Стерлибашевский район в разные года. Первая часть открывается предисловием общего характера, в котором идет речь об истории татарского народа, языке и культурном наследии. В нее вошли статьи об истории Стерлибашевского медресе; особенностях татарского языка данного региона, который представлен белебеевским подговором мензелинского говора среднего диалекта и стерлитамакским говором западного диалекта; современном состоянии фольклора. Вторая часть открывается трудами государственного, религиозного и общественного деятеля М. Тукаева, посвященными истории села Стерлибашево и его медресе. В нее вошли также статья об известной книге «Дөррел-Кәлам», созданной в Стерлибашево и тексты произведений поэтов Стерлибашево; статьи, анализирующие традиционную музыкальную культуру, народное искусство татар Стерлибашево, особенности арабографичных рукописей, найденных в данном крае, материалы по устному народному творчеству, собранные здесь ранее; описания рукописей, информация о тех, кто сохраняет рукописное наследие, и сведения, касающиеся истории села Халикеево. В качестве приложения в книгу вошла информация о пребывании академика В. Бартольда в Стерлибашево.

Статьи, вошедшие в обе части книги, представляют собой мнение специалистов, которые лично познакомились, увидели и исследовали живой процесс функционирования народного языка, устного народного творчества, народного искусства и традиционной культуры. Сведения, собранные в книгах, пополняют и обогащают новыми материалами историю татарского народа, сферу его культуры, помогая еще более расширить представления о нашем народе. Надеемся, эти книги придутся по душе нашим читателям.

***Ким Миннуллин,***
*директор Института языка, литературы*
*и искусства имени Г. Ибрагимова,*
*член-корреспондент Академии наук*
*Республики Татарстан*

# ТАТАР ТЕЛЕ УРТА ДИАЛЕКТЫНЫҢ МИНЗӘЛӘ СӨЙЛӘШЕ БӘЛӘБӘЙ УРЫНЧЫЛЫГЫ

*Миңнира Булатова*

Стәрлебаш районы, Башкортстан төбәгенә хас булганча, җиләк-җимешкә бай урманы, таулары, болыны, инеше, бигрәк тә салкын сулы чишмәләр чыгып торган мәһабәт калкулыклары булган гүзәл табигатьле җирдә урнашкан.

Айдарәле, Бакча, Бакый, Бузат, Гөлем, Әмир, Карагыш, Куганакбаш, Турмай, Хәлекәй, Өч-Әсән (Көчегән), Стәрлебаш, Тәтер-Арслан, Яңгырчы, Яшерган исемле татар авылларына экспедиция уздыру милләттәшләребезнең гореф-гадәтләрен, көндәлек һәм мәдәни тормышларын яктырткан материаллар тупларга, тел үзенчәлекләре җәһәтеннән фәнни нәтиҗәләр ясарга һәм төбәкнең тарихы, күренекле шәхесләре турында мәгълүмат тупларга мөмкинлек тудырды.

Октябрь инкыйлабына кадәр Стәрлебаш күпсанлы мәдрәсәләре, зур гыйлемле мөгаллимнәре белән дан тоткан. Шулар арасында бөтен Россия мөселманнарына яхшы таныш Мөхәммәтшакир Тукаев та (1867–1932) бар. Аны, атаклы Стәрлебаш мәдрәсәсе мөдәррисе, беренче һәм икенче Дәүләт Думасы депутаты буларак, хөрмәтләп искә алалар. 1899 елда чыккан «Тарихы Стәрлебаш» китабы авторы да ул. Бүгенге көндә әлеге мәдрәсәләрнең бер бинасы да калмаган, аның каравы Мөхәммәтшакир Тукаев йорты әле дә тора. Анда хәзер бай эчтәлекле музей эшләп килә икән.

Халкыбыз мәдәниятен һәм мәгърифәтен үстерүгә зур өлеш керткән Стәрлебаш авылы мәдрәсәләрендә танылган шагыйрьләр һәм җәмәгать хадимнәре дә укып чыкканнар: Шәмсетдин Зәки, Гали Чокрый, Мифтахетдин Акмулла, Гали Рәфикый һ.б. Шулардан, мәсәлән, Шәмсетдин Зәки (1825–1865) – суфичылык рухында лирик һәм фәлсәфи шигырьләр, газәлләр язу остасы; күренекле гыйлем иясе Стәрлебаш, аннан Оренбург Каргалысы мәдрәсәләрендә укыткан. Гали Чокрый (1826–1889) Стәрлебаш мәдрәсәсендә укыганнан соң, шул ук мәдрәсәдә хәлфәлек итә, бик күп тезмә һәм чәчмә әсәрләр яза. Татар, башкорт һәм казакъ халыкларының уртак шагыйре Мифтахетдин Акмулла (1831–1895) Стәрлебаш, Троицк мәдрәсәләрендә белем алгач, шул төбәкләрдә мөгаллимлек итә.

Башкортстанның Стәрлебаш районы Фәйзи Гомәров, Равил Шәммас, Әдхәт Синугыл, Зиннәт Галимов, Зәки Зәйнуллин, Мариус Максютов, Мәҗит Кәримов, Зөлфия Гыйззетдинова, Рәфгать Рысаев, Рәлиф Кинҗәбаев, Хисаметдин Исмәгыйлев һ.б. кебек туган як хозурлыгын әсәрләрендә сурәтләгән талантлы язучыларга да бай.

Мәсәлән, Әдхәт Синугыл (1935–2004) – Куганакбаш авылында туып үскән татар шагыйре. 1967–1970 елларда ул Татарстан китап нәшриятында мөхәррир, ә 1971–1977 елларда Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә әдәби бүлек мөдире вазифасын башкара.1992–1993 елларда «Шәһри Казан» газетасында әдәби хезмәткәр булып эшли. Әдхәт Синугыл-Куганаклы иҗатына шигъри форма, вәзен һәм ритм төрлелеге хас. Аның күп кенә әсәрләре гомумтөрки шигърияттә элек кулланылган «мөсәддәс», «тоюк», «кушма», «робагый», «фәрд» үлчәнешендә язылган. Синугыл төрки халыкларның уртак мәнфәгатьләренә, тел һәм дин берлегенә аеруча игътибар иткән.Үзбәкстан, Кырым якларында да яшәп иҗат иткән.

Хәзерге көндә дә бик актив иҗат итүче язучылардан Зәки Лотфулла улы Зәйнуллин (1933 елгы) киң билгеле. Ул – татар язучысы, галим һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе, техник фәннәр докторы. Зәки Зәйнуллинның балачак һәм үсмерлек

чоры хатирәләренә киң урын бирелеп, сугыш вакыты, сугыштан соңгы авылдагы кырыс тормыш күренешләрен киң яктырткан һәм фронттагы канлы сугыш эпизодларын да үз эченә алган «Галимулла бабай күгәрченнәре» (1990), «Сугыш алды малайлары» (1991), «Каршы таулар», «Урам» («Үрләр аша» повесте белән башланган трилогиянең икенче, өченче кисәкләре, 1993), «Ата нигезе» (1997), «Эстәрлебаш фетнәсе» (2002), «Арбалы үгез» (2003) повестьлары, маҗара жанрында язылган «Ат караклары» (1996) романы белән «Агыйделнең аръягында» (1998) исемле киң планлы тарихи роман-кыйссасы һәм дистәләгән хикәяләре безгә таныш.

З. Зәйнуллин татар тарихы, бигрәк тә туган авылы Стәрлебаш төбәгенең үткәне, аннан чыккан, анда яшәгән күренекле шәхесләр турындагы мәгълүматлар белән кызыксына. Тарихи материаллар әдипнең «Эстәрлебаш мәдрәсәсе» (2011) повестенда һәм «Агыйделнең аръягында» (1998) роман-кыйссасында үз урынын таба.

Стәрлебашның башка кешеләре дә туган як истәлекләрен, һәр кешегә, һәркемгә кадерле атамаларны тарихка кертеп калдырырга теләп, китаплар чыгарганнар. Мәсәлән, Тәтер-Арслан авылы турында Нәгыйм Ярмөхәмәтовның «Ага гомер», Рәфгать Рысаевның «Гомерләр» Айдарәле авылы тарихын яктыркан «Тормыш сынауларын җиңеп» (төзүче Ягъфәр Хисмәтуллин), Мәхмүт Мәхмүтовның Стәрлебаш тарихына багышланган «Стерлибаш, горжусь твоей судьбою», Фаткуллин Фәзит мөхәррирлегендә нәшер ителгән «Бакеево сквозь время», «Бакый чишмәләре», Нәсимә Әхмәтованың «Карагыш кичергән давыллар», Мәҗит Кәримов һәм башкаларның китаплары бу төбәкнең нинди вакыйгалар шаһиты булуын сөйли.

Стәрлебаш районыннан төрле өлкәдәге фән докторлары һәм кандидатлары, язучылар, дин әһелләре, артистлар, җырчылар чыккан. Атказанган һәм халык артистлары Хәй Фәхри, Шамил Рәхмәтуллин, Хәкимҗан Сәгыйтов, Гайсә Галимуллин, Наил Галиев, Әнисә Яхина, Флүрә Мозаһитова, Халидә Хәсәнова, Хәй Мушинский, бүгенге көндә дә моңлы тавышлары белән халык күңелен яулаган җырчылар Эльмир Газизуллин (Яңгырчы), Инсаф

Галимов (Бузат) – Стәрлебаш суын эчеп, шул җирлектән илһам алып үскән шәхесләр.

Татар эстрадасына беренче булып фокусчы һөнәрен кертүче Хәй Мушинский (Габделхәй Хафиз улы Мөхәммәтшин) (1908–1994) Тәтер-Арслан авылында туган. Ул – драма актеры, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында уйнаган (1936–1946). 1946 елда Татар дәүләт филармониясенә оригиналь жанр артисты (иллюзионист-манипулятор) булып күчкән. 1956 елда оешкан Казан циркының беренче төркеменә кабул ителгән.

Стәрлебаш районы милләтебезгә бихисап күренекле шәхесләр биргән. Биредә милли үзаң, милли рух та көчле. Бүген Стәрлебашта халкыбызның милли-мәдәни байлыгын саклау, үстерү өлкәсендә зур тырышлык куючы милли җанлы затлар Хисаметдин Исмәгыйлев (Турмай), Зәки Зәйнуллин (Стәрлебаш), Люция һәм Рифгат Дәүләтьяровлар (Тәтер-Арслан), Нәсимә Әхмәтова (Карагыш), Ягъфәр Хисмәтуллин яши. Тынгысыз милләттәшләребез тырышлыгы белән татар милли оешмалары нәтиҗәле эшләп килә. Мәсәлән, һөнәре буенча ветеринария табибы, ә бүгенге көндә лаеклы ялда булган Хисаметдин Исмәгыйлев татар милли хәрәкәтендә актив катнаша. Х. Исмәгыйлев, үзе әдәби мохиттән ерак торган һөнәр иясе булса да, каләмен кулдан төшерми. Газета-журналларга көнүзәк темаларга һәрдаим мәкаләләр яза, төрле басмаларда хикәяләре дә дөнья күрә.

**Тарихка килгәндә,** Башкортстан татарлары – шушы территориядә элек-электән көн күргән, гасырлар буена оешкан халык. Элек республиканың төньяк-көнбатыш өлеше Идел буе Болгар дәүләте йогынтысында булган. Алтын Урда чорында да бу җирләрнең болгар, татар кабиләләре тарафыннан үзләштерелүе дәвам иткән. 1550–1580 елларда бу җирләр Казан өязенә кергән.

XX гасыр башына кадәр мондагы татарлар төрле исемнәр белән аталып йөртелгән булсалар да («йомышлы татарлар», «татарлар», «дәүләт крестьяннары», «типтәрләр», «бобыльләр», «мешаннар», «ясачныйлар (ясаклылар)»), алар телләре, рухи мәдәниятләре, тормыш-көнкүрешләре ягыннан бер-берсеннән аерылмыйлар.

Башкортстан татарларын озак еллар дәвамында өйрәнгән зур галимә Д.Б. Рамазанова тикшеренүләреннән: «Башкортстан территориясендә элек-электән татарлар яшәгән. Уфа Пермь, Оренбуг һәм Мәскәү архивларында күпсанлы документларны, Урал тирәсенә караган тарихи әдәбиятны җентекләп өйрәнү XVI гасырда Идел буеннан татарларның киң масса төсендә күчеше дә булуын, Ык, Агыйдел елгаларының түбән агымы буйларында яшәгән җирбиләүчеләрнең биләмәләрендә 20, 30, хәтта 40 лап яңа авыллар барлыкка килүен күрсәтә. Килгән халык белән электән үк шушы территориядә яшәгән җирле халыкның (шул ук татарларның) телләре, мәдәниятләре бер үк булу күчеп килүчеләргә яңа җирләрдә урнашуны җиңеләйткән»[1]. Галимә шуны да билгеләп уза: «Көньяк-көнбатыш Башкортстандагы аз санлы чын башкорт авыллары, берничә йөз еллар татар авыллары чолганышында яшәп тә, татарлашмаганнар, халык буларак үзгәлекләрен саклап килгәннәр».

XVII гасырда Идел буе тирәләреннән күчеп килүчеләр дә башта бобыльләр дип йөртеләләр, бобыль ясагы түлиләр, хуҗалыклары ныгыгач, башкорт ясагына языла баралар, ягъни «башкорт» исеме белән атала башлыйлар[2]. Тарихчылар У.Х. Рәхмәтуллин, Р.Г. Кузеев раславынча, «башкорт» булып аталуга күчү крестьяннарга бик күп мәшәкатьле вазифа, йөкләмәбурычлардан котылу, биләмә хокукы (вотчинное право) алу юлы булып торган[3].

XVI гасыр азагыннан башлап XX гасыр башына кадәр башкорт сүзе башкорт халкын гына түгел, Уфа өязендәге өстенлекле җирбиләүчеләр катламын да белдерә; ягъни ике мәгънәдә кулланыла: 1) халык, этнос мәгънәсендә; 2) социаль төркем, сословие

[1] Татар халык сөйләшләре: Ике китапта. Казан: Мәгариф, 2008. I китап, Б. 177.

[2] Шунда ук.

[3] *Рахматуллин У.Х.* Заселение Башкирии (30–90-е годы XVIII в.): дис. ... канд. истор. наук. М., 1975.; *Кузеев Р.Г.* Происхождение башкирского народа. М.: Наука, 1974.

(вотчина хуҗалары) мәгънәсендә[1]. Бу турыда XVIII гасырга караган язма документларны һәм дәүләт эшлеклеләренең һәртөрле язмаларын, шулай ук галимнәрнең (Р.Г. Кузеев, Ф.Ф. Фәсиев, Д.Б. Рамазанова, Р.Г. Сибәгатов һ.б.) хезмәтләрен карарга мөмкин.

Шул күчеп килгән татарларның бер өлешен XVIII гасырның 30-40 нчы елларыннан башлап «типтәр» исеме астында аерып йөртә башлыйлар, шуннан типтәр (категориясе) катламы аерылып чыга. Гомумән, типтәрләр дип Башкортстан җирлегендә күчеп килгән һәм андагы түрәләр белән махсус шартнамәләр буенча кабалалы шартларда җир участоклары алган кешеләрне атаганнар. Бу шартнамәләр махсус дәфтәрләргә язылып, шартнамә төзегән кешеләр «типтәрләр» дип йөртелгәннәр (фарс. дәфтәр < тептяр). Типтәрләр арасында төрле милләт кешеләре булган, әмма күпчелеген татарлар тәшкил иткән.

Йомышлы мишәрләр 1570 елдан соң яңа җирләрдә (төгәлрәк әйткәндә Уфа өязендә) хезмәт итү өчен күчереп китерелгән. Аларга әле яңа гына Рус дәүләтенә кушылган башкорт җирләрендә тәртип саклау бурычы йөкләнгән. Йомышлы мишәрләрне Уфа тирәсендә хәзерге Чишмә, Кушнаренко һ.б. районнарны эченә алган җирләрдә (стәрлетамак сөйләшенең бер өлеше), Оса даругасында Байкыбаш (хәзер Караидел) һәм аның белән чиктәш районнарда (байкыбаш сөйләше) утырталар. XVIII гасырга алар арасында да башкорт, типтәр дигән катламнар барлыкка килә. XVII гасыр азагында, XVIII гасырда алар көнчыгышка (златоуст сөйләше), көньякка Стәрлетамак өязенә (стәрлетамак сөйләше) күчеп, яңа җирләр алып утыралар. Йомышлы татарларның бер өлеше Урта Уралга һәм Урал артына да күчерелгән һәм алар красноуфим, эчкен, учалы, сафакүл сөйләшләре формалашуда зур роль уйнаганнар. Бакалы крепостена караган йомышлы керәшеннәр 1842 елда Көньяк Урал аръ-

---

[1] *Рамазанова Д.Б.*Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии. Казань, 1984. 191 с.; *Сибәгатов Р.Г.* Башкортостан татарлары. Тел, тарих, мәдәният мәсьәләләре. Казань: Магариф, 2002. Б.18.

ягындагы хәрби сызыкларга күчерелгәннәр, нәтиҗәдә нагайбәк керәшеннәре сөйләше формалашкан[1].

XVIII гасыр урталарыннан хөкүмәт рөхсәте белән яки ирекле рәвештә казан татарлары, мишәрләр һ.б. килеп, яңа авылларга нигез салалар.

Күчеп килүчеләрнең зур күпчелеген казан татарлары тәшкил иткән. Бу исә Башкортстан шартларында да татар теленең ролен арттыра, татар халкының һәм аның мәдәниятенең борынгы генетик якынлыгын көчәйтә, Идел буе татарлары белән борынгы уртак тамырны тагын да тирәнәйтә, ныгыта барган. Инде XVI гасыр азагыннан ук күпмилләтле саналган Уфа өязендә дә татар теле аралашу теле булуын дәвам итә. Яңа күчеп килүчеләр белән җир биләүче вотчинниклар арасындагы килешүләр, төрле табигый байлыклардан файдалану турындагы шартнамәләр татар телендә төзелә.

Башкортстанда таралган татар сөйләшләре галимнәрне бик күптәннән кызыксындыра, аларны фәнни яктан өйрәнү XIX гасыр башларында ук башлана. Беренчеләрдән булып бу эшне Казан духовный академиясен тәмамлаган А.Г. Бессонов башлап җибәрә: Урал тирәсе татарлары сөйләшләренә күзәтү ясый. Ул аларны татар теленә якынлыклары ягыннан чагыштыра һәм типтәр (билгеле булганча, минзәлә сөйләшенең зур өлеше типтәр сөйләше дип йөртелгән) сөйләшләрен казан татарлары теленә иң якын торган сөйләш дип билгели[2].

Башкортстанның төньяк-көнбатыш районнарындагы сөйләшләр Л.Т. Мәхмүтова тарафыннан өйрәнелә. Ул күп кенә авылларда булып, әлеге төбәктә берничә сөйләш таралганлыгын ачыклый: урта диалектның минзәлә, Аскын төбәге сөйләшләре (соңрак бу төбәкнең златоуст сөйләшенә караганлыгы мәгълүм

[1] *Рамазанова Д.Б.* Урал төбәгендә формалашкан сөйләшләргә карата кыскача мәгълүмат // Татар халык сөйләшләре. I китап. Казан: Мәгариф, 2008. Б. 177–179.

[2] *Бессонов А.Г.* О говорах казанского татарского наречия и об отношении его к ближайшим к нему наречиям и языкам // Журнал Министерства Народного Просвещения. Ч. CCXVI. СПб., 1881.

була), көнбатыш диалектның байкыбаш сөйләшләре. Автор тел материалларын тикшергәндә, тарих, этнография һәм башка өлкәләр буенча да бай мәгълүматларны күздә тотып эш итә һәм татар диалектологиясендә шушындый комплекслы өйрәнү методын куллануны кертә, «типтәр», «башкорт» сүзләренең билгеле тарихи чорда, этноним гына түгел, сословиене дә белдерүләрен күрсәтә[1].

50 нче елларда Көнбатыш Башкортстанның көньяк-көнбатыш (Ә.Ш. Әфләтунов), Дүртөйле һәм Илеш (Җ.Алмаз) районнарына да экспедицияләр уздырыла. Һәр ике автор да әлеге төбәкләрдәге сөйләшләрнең татар теленә бик якын булуын ассызыклап үтәләр, сөйләш вәкилләренең бер өлеше башкорт дип аталу фактларына игътибар итәләр һәм, үз кулларында булган материалларга таянып, аларның бабаларның кайчандыр, җир алу өчен, башкорт булып язылганлыгын ачыклыйлар[2].

Башкортстан, гомумән, Урал төбәге татарлары һәм аларның тарихы турында тулырак мәгълүматны А.Г. Бессонов, Н.Ф. Катанов, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова, Ф.С. Баязитова, Ф.Ю. Йосыпов, И.С. Насипов, Ф.М. Хисамова, З.Р. Садыйкова, Р.Г. Кузеев, Р.Г. Сибәгатов, М.И. Әхмәтҗанов, М.Р. Булатова һ.б. хезмәтләрендә карый алабыз.

Билгеле, Башкортстан республикасында татар теленең ике диалект вәкилләре яши: 1) урта (казан-татар, болгар-татар) диалектның бөре, златоуст, кормантау, тепекәй, турбаслы, учалы сөйләшләре; минзәлә сөйләшенең бәләбәй, урта, яңавыл урынчылыклары; Түбән Кама керәшеннәре сөйләшенең бакалы урынчылыгы; 2) көнбатыш (мишәр-татар) диалектының стәрлетамак,

---

[1] *Махмутова Л.Т.* О татарских говорах северо-западных районов Башкирской АССР (по материалам экспедиций 1954-57) // Материалы по татарской диалектологии. Вып. 2. Казань, 1962. С. 57–85.

[2] *Әфләтунов Ә.Ш.* БАССРның көнбатыш, көньяк-көнбатыш өлешендә яшәүче татарлар сөйләшенең тел үзенчәлекләре: дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1960; *Алмаз Җ.* Башкортостанның Дүртиле һәм Илеш районнары татарларының сөйләшенә карата // Уч. зап. Казанского гос. ун-та. Т. 119. Кн. 6. Казан, 1959. Б. 145–165.

байкыбаш сөйләшләре. Без өйрәнгән Стәрлебаш җирлегенең татар авылларында урта диалектның минзәлә сөйләше бәләбәй урынчылыгы һәм көнбатыш диалектның стәрлетамак сөйләше таралган[1].

Бу мәкаләдә **урта диалектның минзәлә сөйләше бәләбәй урынчылыгы** турында мәгълүмат бирелә[2].

Минзәлә сөйләше Татарстанның көнчыгыш (Әгерҗе, Бөгелмә, Зәй, Азнакай, Сарман, Баулы, Минзәлә, Мөслим, Әлмәт, Актаныш, Ютазы, Бөгелмә), Удмуртиянең Малая Пурга, Алнаш, Башкортстанның көнбатыш (Бишбүләк, Благовар, Борай, Бәләбәй, Дүртөйле, Илеш, Кырмыскалы, Краснокама, Кушнаренко, Миякә, Мәләвез, Стәрлебаш, Стәрлетамак, Туймазы, Федоровка, Чакмагыш, Чишмә, Шаран, Яңавыл, Әлшәй) районнарында таралган[3]. Бу сөйләшкә төрле елларда галимнәр тарафыннан күзәтүләр ясала (А.Г. Бессонов, Н.Ф. Катанов, Л. Җәләй, А.А. Юлдашев, Л.Т. Мәхмүтова, Ә.Ш. Әфләтунов, Җ. Алмаз, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова, Ф.С. Баязитова, Ф.Ю. Йосыпов, И.С. Насипов, М.Р. Булатова һ.б.). Минзәлә сөйләшен өйрәнүнең 100 елдан артыкка сузылган бай тарихы бар.

Минзәлә сөйләше көнбатыштан чистай, мамадыш, балтач, төньяктан нократ, пермь, көнчыгыштан златоуст, турбаслы, кормантау, тепекәй, көньяктан стәрлетамак, богрыслан, камышлы сөйләшләре белән чиктәш.

Шулай да минзәлә сөйләше таралган территориянең аерым төбәкләрендә яшәүче төркемнәрнең сөйләшендә, төрле факторлар (тарихи, мәдәни, географик һ.б.) йогынтысы астында, үзләренә хас үзенчәлекләр барлыкка килгән. Бу исә, үз чиратында, минзәлә

[1] *Булатова М.Р.* Морфологические особенности татарских говоров ареала «Юг Башкортостана». Казань: ИЯЛИ. 2013. 240 с.

[2] Стәрлебаш районындагы татарларның икенче сөйләш (мишәр диалектының стәрлетамак сөйләше) үзенчәлекләре киләсе (алдагы) бүлектә тәкъдим ителә.

[3] Татар халык сөйләшләре: Ике китапта. Казан: Мәгариф, 2008. I китап, 463 б., II китап, 495 б.

сөйләшендә берничә урынчылыкны (әгерҗе, яңавыл, төп, бәләбәй урынчылыкларын) аерып чыгарырга мөмкинлек бирә.

Стәрлебаш районындагы Айдарәле, Бакый, Куганакбаш, Стәрлебаш, Тәтер-Арслан, Турмай, Яңгырчы, Яшерган авыллары минзәлә сөйләшенең бәләбәй урынчылыгына карый.

Гомумән, бәләбәй урынчылыгы Башкортстанның көньяк-көнбатыш районнарында таралган. Бу төбәккә татарлар төрле чорда һәм төрле төбәкләрдән дә күчеп утырганнар, аларның күпчелеген казан татарлары һәм мишәр диалектына караган татарлар тәшкил иткән. Җирле төрки халыкларның тыгыз аралашуы барышында минзәлә сөйләшенә хас төп үзенчәлекләрнең системалылыгы берникадәр дәрәҗәдә югалган. Мәсәлән, интердентальь, ягъни тел-теш [d] («сакау» [з]) авазын, *-ай/-әй* дифтонгын куллану пассивлаша төшкән. Ә без өйрәнгән Стәрлебаш авылларында сакау *d* авазы, *-ай/-әй* дифтонгы бүгенге көндә бөтенләй кулланылмый.

50 нче елларның азагында татар диалектологлары, төрки халыклар арасында беренчеләрдән булып, сөйләшләрне лингвистик география методы белән өйрәнүгә керешәләр. Башкортстан татарларының тепекәй, стәрлетамак, минзәлә сөйләшләре дә, шул исәптән аның бәләбәй урынчылыгы да, филология фәннәре докторы Д.Б. Рамазанова тарафыннан 1968–1975 елларда шушы ук метод белән нигезле тикшерелә. Галимә татарларның Урта Кама буе һәм Урал алды регионында Болгар дәүләте чорларыннан ук яшәүләрен, аларга соңгырак дәвердә тагын төрле объектив һәм субъектив сәбәпләр нәтиҗәсендә күченеп килүчеләрнең берничә дулкын булып өстәлүен билгели. Ык буенда этник процессларның бик катлаулы булуын ассызыклап, Идел буе компонентының өстенлек итүен, лингвистик материалның татар теле үзенчәлекләрен чагылдыруын нигезле дәлилли. Архив материалларына, тарихи чыганакларга таянып язылган, Башкортстан татарларының (шул исәптән, бәләбәй урынчылыгы вәкилләре) этник килеп чыгышына, тел үзенчәлекләренә багышланган монографиясе («Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии», 1984) һәм мәкаләләре басылып чыга. 1970 елда филология

фәннәре докторы Ф.С. Баязитова тарафыннан да бәләбәй урынчылыгы өлешчә өйрәнелә. Шулай ук диалектолог Ф.Ю. Йосыпов Чакмагыш, Илеш, Кушнаренко районнарын тикшерә.

Филология фәннәре докторы И.С. Насиповның «Древнетюркский пласт диалектной лексики мензелинского говора татарского языка» (1994) дигән темага якланган кандидатлык диссертациясендә дә бәләбәй урынчылыгында күзәтелгән лексик берәмлекләр тикшерелә.

Минзәлә сөйләшенең бәләбәй урынчылыгы 2010–2012 елларда М.Р. Булатова тарафыннан да өйрәнелә. Галимә Көньяк Урал татар сөйләшләренең морфологик үзенчәлекләрен өйрәнеп, кандидатлык диссертациясе яклый һәм аның төп нәтиҗәләрен үз эченә алган «Морфологические особенности татарских говоров ареала «Юг Башкортостана»» (Казань, 2013) исемле китабын бастырып чыгара. Хезмәттә Башкортостанның көньягында яшәгән татар халкы теле яңача – ареалогик аспектта яктыртыла, һәм автор, татар диалектологиясенең бүгенге үсеш казанышларына таянып, татар халык сөйләшләрен өйрәнүдә лингвогеографик тикшеренүләрнең нәтиҗәлелеген үстерүгә җитди өлеш кертә. «Башкортстанның көньяк» ареалында татар сөйләшләрен төркемләүгә һәм аларның таралу чикләрен билгеләүгә ачыклык кертә. Лингвистик география ысулы белән көнбатыш диалектның стәрлетамак, урта диалектның турбаслы, тепекәй, кормантау, учалы, һәм шул исәптән минзәлә (аның бәләбәй урынчылыгы) сөйләшләренең морфологик үзенчәлекләрен анализлый һәм фонетик, лексик күренешләр турында да мәгълүматлар китерә.

Әйтеп узуыбызча, эш барышында өйрәнгән Стәрлебаш районының Айдарәле, Бакый, Куганакбаш, Стәрлебаш, Тәтер-Арслан, Турмай, Яңгырчы, Яшерган авыллары вәкилләре татар теленең минзәлә сөйләше бәләбәй урынчылыгына карый. Минзәлә сөйләше – татар теленең төп диалектларыннан берсе булып торган урта диалект сөйләше. Белүебезчә, урта диалект сөйләшләренең зур күпчелеге әдәби телгә якын тора, ә минзәлә (шул исәптән Стәрлебаш татарларының да) сөйләше аеруча. Фонетик, грамматик яктан, һәр төбәккә хас булганча, урнашу

территориясенә карап кайбер үзенчәлекләр күзәтелсә дә, алар телдә зур роль уйнамый.

## Фонетик үзенчәлекләр

**Сузыклар.** Сузык авазларның составы һәм әйтелеше ягыннан татар теленең урта диалектына кергән минзәлә сөйләшенең бәләбәй урынчылыгы әдәби телдән аерылмый диярлек. Сөйләшкә хас үзенчәлекләр авазларның позицион үзгәрешләренә, төрле тәңгәллекләргә генә кайтып кала.

Бер төркем сүзләрдә [ы] авазы урынына [а] авазын куллану күзәтелә: *алҗадым* – әд. алҗыдым, *йасмақ* – йасмык (ясмык), *уңдару* – уңдыру; шулай ук [ә]~[э(е)]: *билдә* – билге, *билдәле* – билгеле һ.б.

[ы]~[а]: *апыра* – апара, *қатырқа* – катыргы, *йаңы* – йаңа (яңа).

Бәләбәй урынчылыгында *-ыр*/*-ер* кушымчалы фигыль формаларында шулай ук [ы]~[а] тәңгәллеге күзәтелә: *сатырға* / *сатарға* – әд. сатарга, *йағырбыз* / *йағарбыз* (ягарбыз), *оторға* / *отарға* һ.б.

Шул ук урынчылыкта [э(е)]~[ә] тәңгәллеген күрсәтеп үтәргә кирәк: *түгерләр* – әд. түгәрләр, *өзөр (өзер)* /*өзәр* – өзәр, *пәрәмеч* – пәрәмәч һ.б.

Минзәлә сөйләшенә хас булганча, бәләбәй урынчылыгында кайбер сүзләрдә [ә] авазы [и] авазына тәңгәл килә: *кәштә* – әд. киштә, *кәртә* – киртә, *кәбән* – кибән, *мәләш* – миләш, *кәмсетү* – кимсетү һ.б.

Түбәндәге сүзләрдә, киресенчә, [и]~[ә] теркәлгән: *дисбе* – әд. тәсбих, *инәй* – әни, *картинәй* – картәни (дәү әни), *пирәмәч* – пәрәмәч, *фирештә* – фәрештә, *тирәзә* – тәрәзә.

Бәләбәй урынчылыгында[о], [ө] һәм [у], [ү] сузыкларының мондый тәңгәллекләре бар.

[у]~[о]: *туқмач* – токмач; [о]~[у]: *йоқа* – йука (юка), *чобан* – чуwан (чуан), *җобату* – йуwату (юату), *чобалу* – чуwалу (чуалу), *мунча* / *монча* – мунча, *бола* – була һ.б.

[ы]~[у]: *ыңғай* – уңай, *была* – була, *быйау* – буйау (буяу), *быйақ* – бу йак (як), *мынча* – мунча, *ықлау* – уклау һ.б.

Тел уртасы [й] тартыгы алдындагы [у], [ы] авазлары [и] сузыгына да күчә. Бу күренеш минзәлә сөйләшенең барлык урынчылыкларында да күзәтелә, тик бәләбәй урынчылыгында әлеге күренешнең активрак булуы күзгә ташлана: *бийылгы* – быелгы, *бийау* – буйау (буяу), *бийаķ* – бу йак (як), *тийына* – туйына (туена), *бийына* – буйына (буена), *сийыр* – сыйыр (сыер), *тийаķ* – теге йак (як) һ.б. Сирәк [ы]~[и]/[е] тәңгәллеге дә күзәтелә: *Амырхан* – Әмирхан, *Тимырхан* – Тимерхан һ.б.

Кайбер сүзләрдә, аеруча [ч] авазы янәшәсендә, [ы], [е] сузыкларына [и] тәңгәл килә: *пичән* – әд. печән, *ич* – эч, *ичке (эчке)* – эчемлек һәм эчке (внутренний), *чир(е)гән* – чергән, *чиллә* – челлә, *чиршы/ чыршы* – чыршы, *ичķыну* – ычкыну, *пичķы* – пычкы һ.б.

Шулай ук: *җигерләү* / *җегерләү* – әд. эрләү, *инә* / *энә* – энә, *тиге* – теге, *тигермән* – тегермән, *кәлҗимә* – кәлҗемә һ.б.

Бәләбәй урынчылыгында [э(е)] авазын иренләштерү очраклары бар: *мөң* – мең, *дөбөт* – дебет – мамык һ.б.

Алгы һәм арткы рәт сузыкларының үзара тәңгәллекләре минзәлә сөйләше таралган бөтен территориядә күзәтелә: *йөн* – әд. йон, *мөрйә* – морҗа, *тәрих* – тарих; *чәк* – чак (көчкә), *йәбешү* – йабышу (ябышу), *әлсә* / *әләйсә* –алайса, *сәленү* – салыну; *чыған* – чегән, *тыш* – төш (урын, җир), *тубән* – түбән һ.б.

Нечкә авазларны кулланып сөйләү тенденциясе рус алынмаларында да актив: *әрмийә* – армия, *әктиф* – актив, *пәлтә* – пальто, *эшкәп* – шкаф, *кәнсә* / *кәнсәләр* – канцелярия, *сәмәлүт* – самолет, *сәwит* / *сәwет* – совет, *wәринҗә* – варенье, *әтү* – а то һ.б.

Иренләшү гармониясе буенча минзәлә сөйләше татар әдәби теленең орфоэпик нормаларына туры килә: *ķоро* – коры, *боролош* – борылыш, *тормош* – тормыш, *төлкө* – төлке, *төзөлөш* – төзелеш.

***Сузыклар өстәлү.*** Татар теленә хас, ләкин сүз башында кулланылмый торган авазларга (л, р, ч) башланган алынма сүзләрдә сүз башында сузык аваз барлыкка килә: *эрәт* – рәт, *эрәхмәт* – рәхмәт, *элинте* – лента һ.б. Шулай ук чагыштыр: *эчәй* – чәй, *өтөрмән* – төрмә, *эчерек* – черек һ.б.

Минзәлә сөйләшендә, татар теленең башка сөйләшләрендәге кебек үк, аваз өстәлүнең икенче бер төре дә билгеле бер төркем

сүзләрдә күзәтелә: *йөрөмә* – йөрмә, *күреше* – күрше, *ҡарышы* – каршы һ.б.

***Сузыклар төшү.*** Казан арты сөйләшләрендәге кебек үк, бу сөйләштә дә кайбер сүзләрдә сүз башындагы сузыклар төшә: *йәңке* / *өйәнке* – өянке, *йалды* / *өйалды* – өйалды, *ләгү* – эләгү, *шану* – ышану һ.б.

Сөйләштә шулай ук кыска сузыкларның, кыскарып, бөтенләй төшү очраклары күзәтелә: *ҡайсы* / *ҡайссы* / *ҡайсысы* – кайсысы, *олғайу* / *ол°ғайу* – олгаю, *шушылай* / *шушлай* – шушылай һ.б.

***Дифтонглар.*** Минзәлә сөйләшенең аеруча үзенчәлекле билгеләреннән берсе – әдәби телдәге ***-ый/-ий*** дифтонгларына ***-ай/-әй*** дифтонглары тәңгәл килү. Тик бу күренеш барлык урынчылыкларда да бер үк төрле чагылмый. Төп, әгерҗе, яңавыл урынчылыкларында -*ай*/ -*әй* кайбер очракларда системалы рәвештә кулланыла. Бәләбәй урынчылыгында -*ай*/-*әй* дифтонгының кулланылышы чикле. Даими рәвештә ул бары *үгәй, җизнәй, җиңгәй, тәпәй* сүзләрендә генә күзәтелә, калган очракларда әдәби вариант белән параллель кулланыла. Стәрлебаш районында -*ай*/-*әй*~-*ый*/-*ий* бары тик *әпәй, бәбәй, тәпәй, әтәй, биатай* сүзләрендә генә очрый.

***-өй*** дифтонгының әйтелешендә дә әдәби телдән тайпылышлар күзәтелә. Минзәлә сөйләшенең барлык урынчылыклары өчен дә *үрә* – өйрә, *күрәү*–көйрәү, *сүрәү* – сөйрәү сүзләрендәге -*өй* > -*ү* күчеше уртак күренеш булып тора. Бу дифтонгның монофтонглашуы әгерҗе урынчылыгында күбрәк күзәтелә (*түмә* – төймә, *сүwәк* – сөйәк (сөяк)). Минзәлә сөйләшенең калган урынчылыкларында, шул исәптән бәләбәй урынчылыгында *сүләү* / *сөйләү* / *сийләү, өй* / *ий, үрәнү* (өйрәнү) сүзләрендә очрый.

Киресенчә, бәләбәй урынчылыгында әдәби телдәге -*ай*/-*әй* дифтонгына -*ый*/-*ий* дифтонгы тәңгәл килә: туганлык терминнарына ялганган иркәләү-кечерәйтү кушымчаларында (*туткәй* / *туткий, инәкәй* / *инәкий, әткәй* / *әткий*); -*лай*/-*ләй* кушымчасында (*икенчелий* – диал. *икенчеләй, бутәнчәлий* – диал. бүтәнчәләй – бүтәнчә, башкача); чагыштыру кушымчасында (*айудый* – аюдай); аерым сүзләрдә (*бийәлий*/ *бийәләй* – бияләй) һ.б.

***Тартыклар.*** Тартык авазлар системасы белән минзәлә сөйләше әдәби телдән аерылмый.

Минзәлә сөйләшенең башка урынчылыкларыннан аермалы буларак, бәләбәй урынчылыгына караган Стәрлебаш татарларына [з] авазына урынына интерденталь, ягъни тел-теш [d] («сакау» [з]) авазын куллану хас түгел. Интерденталь [d] авазы төп һәм яңавыл урынчылыкларында гына системалы рәвештә диярлек сакланган: *dур* – зур, *қыdыл* – кызыл һ.б. Әгерҗе һәм бәләбәй урынчылыкларында бу күренеш үзенең системалылыгын югалткан. Бәләбәй урынчылыгының күпчелек авылларында әдәби [з] авазы активрак. Стәрлебаш, Федоровка районнарында [d] авазы бөтенләй юк. Чөнки бу төбәккә, нигездә, Сәет бистәсе (Оренбург өлкәсе) һәм нократ татарлары утырган. Архив документлары күрсәтүенчә, Оренбург шәһәренә Арча, Мамадыш һәм Зөя якларыннан килгән татарлар нигез салган.

Башка тартыклар ясалышлары буенча әдәби эквивалентларыннан аерылмыйлар. Сөйләшнең үзенчәлекләре, нигездә, аваз тәңгәллекләренә һәм башка фонетик күренешләргә кайтып кала.

***-ып/-еп*** кушымчалы хәл фигыльләр ясалганда, тамыр ахырында ***п > б >w***: *қаwып* – кабып, *йаwып* – йабып (ябып), *чаwып* – чабып һ.б.

Бу күренеш татар теленең орфоэпик нормаларына туры килә.

[н]~[л] мондый очракларда күзәтелә: билгеле бер төркем сүзләрдә: *нәзәтле* – әд. ләззәтле, *йондоз* / *йолдоз* – йолдыз, *Индус* – Илдус; ***-ла/-ла*** сүз ясагыч кушымчасында: *тешнәү* – тешләү, *қатнау* – катлау, *аннау* – аңлау, *тәкәрнәү* – диал. тәкәрләү – тәгәрәү һ.б.

[з]~[д]. Бу тәңгәллек ике сузык арасында күзәтелә: *Изел* – әд. Идел, *изан* – идән, *бозай* – бодай, *йозороқ* – йодрык, *мизал* – медаль, *узарник* – ударник һ.б.

Өрелмәле [ж] авазына сүз башында [й] сонанты тәңгәл килү күренеше сирәк кенә булса да очрый: *йен* – әд. җен, *йома* – җомга, *йетәкләшеп* – җитәкләшеп, *йебәрү* – җибәрү, *йайлап* – җайлап.

***Й-***ләштерү татар теленең мишәр, көнчыгыш диалектлары, урта диалектның нократ, златоуст, тепекәй, кормантау сөйләшләре

өчен дә хас. Иске татар теленең китаби теле традициясе итеп каралган *й*-лаштыру, мәсәлән, язучыларыбыз Г. Ибраһимов, М. Гафури әсәрләрендә еш очрый: *йир* – җир, *йиденче* – җиденче: *Вакыт үтә, вакыт үтә, төрле хәлләр инде* ***йитә*** (М. Гафури).

Урта диалект сөйләшләренә хас булганча, минзәлә сөйләшенә дә ***җ̧***-ләштерү характерлы, әмма Стәрлебаш татарларында ул бик сирәк очрый: *җ̧өнлө* – әд. йонлы, *җ̧он* – йон, *җ̧өз* – йөз, *җорт* – йорт һ.б.

Бәләбәй урынчылыгында еш кына [ж] һәм [й] параллель йөри: *йылау* / *җ̧ылау* – елау, *йаңгыр* / *җ̧аңгыр* – яңгыр, *йул* / *җ̧ул* – юл; *йан* / *җ̧ан* – җан, *йер* / *җ̧ир* – җир һ.б.

Билгеле бер төркем сүзләрдә [х]~[к] тәңгәллеге күзәтелә: *wахыт* – вакыт, *хәдәр* – кадәр, *хәләмпер* – канәфер, *хәрендәш* – карендәш, *хәтерләү*–кадерләү. Бу сүзләрнең, диалекталь вариантлары белән беррәттән, әдәби формалары да актив кулланыла.

[к]~[х]: *Қадичә* – Хәдичә, *қатын* / *хатын* – хатын, *эрәқмәт* – рәхмәт һ.б.

[*ғ*], [*г*] тартыкларының минзәлә сөйләшендә саңгыраулашу күренешләре бар: *көнҗ̧әлә* – әд. гөнҗәлә, *сулақай* – сулагай; *чикә* – чигә, *тәлкәш* – тәлгәш, *сискер* – сизгер, *қатырқа* – катыргы һ.б.

Түбәндәге сүзләрдә, киресенчә, [*ғ*],[*г*] тартыклары әдәби телдәге [*қ*], [*к*] авазларына тәңгәл килә, ягъни яңгыраулашу күренеше күзәтелә: *гөмбағыш* – көнбагыш, *нағыш* – нәкеш, *гөпшә* – көпшә, *гәрниз* – кәрниз һ.б.

Сөйләшкә, сирәк булса да әдәби форма белән параллель рәвештә, [ң] авазына тел очы [н] тартыгы тәңгәл килү очрагы хас: а) бер төркем сүзләрнең азагында (*ин* – иң, *аннамый* – аңламый, *тегенәргә* – тегеңә); б) иялек килеше кушымчасында (*безнен* – безнең, *анын* – аның, *басунын* – басуның һ.б); в) хәзерге заман хикәя фигыльнең, шарт фигыльнең 2 нче зат берлек сан кушымчасында (*киләсен* – киләсең, *суғасын* – сугасың һ.б.).

Минзәлә сөйләшенең бәләбәй урынчылыгында аерым сүзләрдә генә очрый торган тәңгәллекләр дә бар. Алар сөйләш таралган бөтен территориядә табыла. [ч]~[ш]: *ачаулық* – әд. ашъяулык,

*чәбен* / *шәбен* – күбә; [р]~[н]: *үткер* (Урал төбәге сөйләшләренең барысында да) – үткен; [н]~[м]: *ағым* / *ағын* – агым; [з]~[с]: *җиләз* – җиләс; [*м*]~[п], [б]: *ҷамшау* – капшау, *ләкәм исемнәр* – ләкапь, ләкабь; [м]~[н]: *чормау* – чорнау, *кәмбирт* – конверт; [й]~[л]: *ҷарайу* – каралу; [ф]~[п]: *фәҗе* – пәҗе, [*г*]~[*м*]: *элгәк* – элмәк; [л]~[н]: *фонтал* – фонтан; [*г*]~[*в*]: *йануғыч* – янавыч һ.б.

***Ассимиляция (охшашлану).*** Сүз башындагы [с], [ч] тартыклары билгеле бер төркем сүзләрдә үзләреннән соң килгән [ш] тартыгына тулысынча охшашланалар: *шишмә*– чишмә, *шаршау* – чаршау, *шишәмбе* – сишәмбе һ.б. Әдәби тел йогынтысында аларның әдәби вариантлары да кулланыла.

[л], [н] сонорлары үзләреннән соң килгән [к]–[ғ], [к]–[г] тартыкларына ясалу урыннары буенча өлешчә охшашланалар: *йаңғыз* – йалгыз (ялгыз), *йаңғылыш* – йалгыш (ялгыш); *урмаңға* – урманга, *килгәңгә күрә* – килгәнгә күрә һ.б.

Сүз азагындагы [н] тартыгы сорау (*-мы*/*-ме*) һәм 1 нче зат берлек сан (*-мын*) кушымчасындагы [м] авазына тулысынча охшашлана: *симме* – синме, *уммы* – унмы, *барғаммын* – барганмын һ.б.

[н]авазы үзеннән соң килгән ирен-ирен [б] авазына ясалу урыны буенча өлешчә охшашлана: *күргәмбез* – күргәнбез; шундый ук күренеш ике сүз арасында да булырга мөмкин: *гөмбағыш* – көнбагыш, *умбер* – унбер һ.б. Бу очраклар татар теленең орфоэпик нормаларына туры килә.

***Диссимиляция.*** Прогрессив диссимиляция: *чүкеш* – чүкеч. Регрессив диссмиляция: *чешү* – шешү, *чөшлө* – шөшле һ.б.

***Тартыклар төшү***. Ике бертөрле сузык арасындагы [ғ], [г] авазлары төшәргә мөмкин: *белмәәңгә* / *белмәңгә* – белмәгәңгә (белмәгәнгә); *чыып* / *чып* – чыгып; *тее*/*те* – теге һ.б. Ике бертөрле аваз озын сузыкка әйләнә.

Калган очракларда [ғ], [г] авазларына [w] яки [й] сонорлары тәңгәл килә: *нийә* – нигә, *түwел* – түгел һ.б.

[н] төшү: *асат* – әд. ансат, *нидәй* / *ниди* – нинди, *муча* / *мынча* – мунча, мучала – мунчала, *белә* / *была* – белән; [п] төшү: *җутару* – куптару; [л] төшү: *нишисен, нишәп,* [д] төшү: *бит ине* (инде) һ.б.

Ике бертөрле тартыкның берсе төшү, кыскару, *нн > н**:** Зинур* – Зиннур; *кигәнәр* – кигәннәр, *алганар* – алганнар, *шунан* – шуннан һ.б.; *кк >к*: *чықан* – чыккан; *тамақайым* – тамаккаем; *мм > м: қыймәт* – кыйммәт; *лл > л: әлә* – әллә һ.б.

Кайбер сүзләрдә иҗекләр төшү: *әлсә* – әд. алайса, *иләшү* – ийәләшү (ияләшү) һ.б.

***Тартыклар өстәлү.*** Бәйлекләр һәм *-ганчы*/*-гәнче* кушымчалы хәл фигыльләр ахырына [к] [қ] өстәлү: *чақлық* – чаклы, *тиклек* – тикле, *хәтлек* –хәтле, *киткәнчәк* / *киткәнчек* – киткәнче; [л]: *текәл* – текә; [р]: *қычыртқан*/*кечерткән* – кычыткан, *қысырық* – кысык; [б]: *эскәмбийә* – эскәмия һ.б.

[ғ], [г] өстәлү ике сузык арасындагы [ң] авазы белән янәшәлектә күзәтелә: *аңгарчы* – аңарчы, *шуңгынчы* – шуңынчы, *берыңгайдан* – бер уңайдан, *иңгелек* – иң элек һ.б.

***Метатеза (авазларның алмашынуы):*** *чәчкә* – чәчәк, *йалагай* – җалагай / нәҗәгай – аҗаган.

[б] авазына башланган саннар алдында килгәндә, *егерме* сүзенең соңгы авазлары урыннарын алмаштыралар: *йегерем бер* – йегерме бер (егерме бер), *йегерембиш* – йегерме биш (егерме биш).

## Морфологик үзенчәлекләр

Минзәлә сөйләшенең бәләбәй урынчылыгында сүз төркемнәре һәм аларга хас төп грамматик категорияләрнең (зат, сан, тартым һ.б.) зур күпчелеге әдәби телдәге кебек. Шуның белән бергә, бу сөйләштә дә кайбер диалекталь үзенчәлекләр табыла.

**Исемнәр.** Исемнәрне кыскарту: *Дәрес* – Дәрессәләм, *Хисамый* – Хисаметдин, *Сорур* – Миңсорур.

Исемнәрнең иркәләү-кечерәйтү формалары, әдәби телдәгечә, *-қай*/ *-кәй* кушымчалары белән ясала: *балақайым, гөлкәйем* һ.б.

Сөйләшнең үзенчәлеге шунда, ***-қай***/***-кәй*** иркәләү-кечерәйтү кушымчасы абстракт мәгънәле яки җансыз әйберләрне белдерә торган исемнәргә дә, сыйфатларга, ымлыкларга да ялганып килә. Мәсәлән: *Әпәкәй дигән басуыбызда иген бик уңа торғаныйы.*

*Бәләкәй чақта ақ йомороқай былғанмын. Бөтөнесе қарақай, чибәрләр. Эзмәкәй* (рус. змейка) *бу шәл. Анда бик йырақай.*

***-қай*/*-кәй*** иркәләү-кечерәйтү кушымчасы, кешене белдерә торган сүзләргә, ***нәрсә*** һәм ***нәстә*** (диалекталь вариант) алмашлыгына ялганып килгәндә, эмоциональ-экспрессив мәгънәсен югалтырга да мөмкин: *Тағын бер хатынқаймы* (әд. хатын), *қызқаймы* (кыз) *бар иде. Һәрберсесенә минем қызықай чиккән алйапқыч таратты. Миңкәй апаны қараңғы төшмәс борон барып, әнисе өйдә булмағанда, алып чығып киткәннәр. Нәстәкәй* (нәрсә) *эшлисен әле? Нәрсәкәй әйтергә? Урманнан бер нәрсәкәй дә алдыртмайлар.*

***-лар*/*-ләр*** кушымчасы төрле сүзләргә ялганып килергә һәм эмоциональ-экспрессив мәгънә белдерергә мөмкин: *Искәйләрем, ақылқайларым* (исем-акылым) *да бетте. Сибәләпләр* (сибәләп) *генә йаwа йаңғыр.*

Гомумән, *-қай*/*-кәй* кушымчасының мондый вазифаларны үтәве Башкортстанда яшәүче бөтен татарларга хас[1].

**Алмашлыклар.** Аларның составы, мәгънә үзенчәлекләре һәм кулланылышы белән дә минзәлә сөйләше әдәби телгә бик якын тора. Шул ук вакытта кайбер аерымлыкларны да күрсәтеп үтми мөмкин түгел.

Бәләбәй урынчылыгында ***мин*** зат алмашлыгының иялек килеше ике вариантта кулланыла: *минем* / *минең*. Мәсәлән: *Шуларға минем әнийем чигеп бирә торған ийе. Минең* (минем) *әбийем кендек әбисе булған. Әни иртәнчәк кантурға барған: минең игенемне алдылар, мин нәрсә эшлим дип.*

1 нче һәм 2 нче зат берлек сандагы алмашлыкларның юнәлеш килеше, әдәби телдәге кебек, ***миңа, сиңа*** һәм тагын ***миңә*** / ***мийә*** / ***мийа, сиңә*** / ***сийа*** вариантларында кулланыла: *Мийа уқырға туры килде, мин аулақ өйләргә бик эләгә алмыйдырыйым. Миңә күршегә кереп торoға қуштылар. Син давай өйлән шушы минем қызыма, мин сийа усад'ба бирәм, дигән. Сиңә картәнийем әйткән иде аны.*

---

[1] *Булатова М.Р.* Семантические функции аффикса *-кай*/*-кәй* в татарских говорах юга Башкортостана // Академик Э.Р. Тенишев и тюркский мир. Казань: Казан ун-ты нәшр., 2012. С. 207–210.

Алмашлыкларның *миңә, сиңә* вариантлары Башкортстанга гына түгел, гомумән, башка Урал буе татар сөйләшләренә дә хас.

*Мийә, сийә* алмашлыклары татар теленең урта диалектына караган норлат, дөбьяз, бөре, минзәлә, эчкен, златоуст, пермь, нагайбәк, сафакүл сөйләшләрендә дә күзәтелә, себер татарларында да очрый. Чагыштыр: дөбьяз (Казан арты) һәм керәшен татарлары сөйләшләрендә *мыйа, сыйа / сийә,* ягъни каты вариантлар хас.

Күрсәтү алмашлыклары: *бу / бы, шул, шушы, теге/тиге/тее/ те; ул, мондый / мондай, мынанда, шундый/шундай, андый/андай* һ.б. Мәсәлән: *Мынанда* (менә монда) *ақча салалар да матчаны қаплыйлар.*

***Анау, монау*** алмашлыклары тартым, зат, килеш кушымчалары алалар, тотрыклы сүзтезмәләрдә дә күзәтеләләр: *Монауның буйына шаршаулар эленә. Шул сулар менә монаннан ғынайы. Монандый стопка китаплары бар. Шуның башында монауың кебек тағын бер тайақ. Кешенең қош-қортларын қыра торған монауық хәтлек йәнлек бар, диләр. Килеп керәдерийе дә моналай вич клупны әйләндереп биидерийе. Монанда бер әби йәшийдерийе. Анаусы матур.*

Сорау алмашлыклары: *кем, ний, ни, нәрсә, нәстә, нәстәкәй, нәрсәкәй*; *ничә; ничек; қайсылай* – ничек, ничек итеп; *нихәлле* – ничек (каково); *ник, нигә, нийә, нәрсәкәйгә; күпме; қайа, қайан; қайчан/качан; қайсы/қайсысы; нинди/ниндәй/нидәй*. Мәсәлән: *Нәстә беләсең шуны уқыйсың. Нәстәкәй күрдең – сөйлә. Урнашына һәркем үзеннән берәр нәрсәкәй (маймы, бәрәңгеме) алып бара инде. Бу үләнне сәрби дип тә әйтәләр қайсы аwылларда. Нийә син халықтан алдан җимеш җиарға чығасың?*

Билгеләү (*бары, һәр, һәрбер/әрбер, барлық, бөтөн*), билгесезлек (*әллә кем, кемдер, әллә нәрсә, нәрсәдер* һ.б.), юклык (*беркем, бернәрсәкәй, һичкем, һичқайчан/ичқайчан* һ.б.) алмашлыкларының лексик составы, мәгънә үзенчәлекләре һәм грамматик күрсәткечләре буенча минзәлә сөйләшенең бәләбәй урынчылыгы татар әдәби теленнән аерылмый.

**Сыйфат.** Стәрлебаш татарларындагы бәләбәй урынчылыгында *начар, кечкенә* сыйфатларын куллану бик сирәк күренеш,

анда ***алама, бәләкәй*** вариантлары урын ала: *Берсе – йақшы, икенчесе – алама. Әти йөрөгән йегетен қуды да чығарды, қызымны алама йегеткә бирмим, дип. Безнең заман алама заман былды. Аның алама өйөнә барып йәшәде. Әниләр, без бәләкәй чақта, қапчық белән симинә ташыйлар ыйы. Бәләкәй бидыра белән суға барадырыйық.*

**Рәвешләр.** Ел фасылларын һәм тәүлекне белдерә торган сүзләрдән вакыт рәвешләре түбәндәге кушымчалар ярдәмендә ясала.

*-ын/-ен* (әдәби форма): *кышын, кичен* һ.б. Мәсәлән: *Әниләр ындыр табағында көндез, кичен шәл бәйлиләр.*

*-кы/-ке + -лық/-лек: Балтырған, башақ-мазар қышқылыққа запас инде әзерәк.*

Лексик чаралар ярдәмендә:

Стәрлебаш татарларында ел фасыллары, тәүлекне белдерү шулай да әдәби формага (*-ын/-ен* кушымчасы белән) караганда күбрәк ***көне*** / ***көнне*** сүзе өстәлү ярдәмендә барлыкка килә: *Қыш қыны* (әд. кышын) *төн озон. Күксағызның чәчкәсе кич көнө* (кичен) *йомола, иртәнге йаққа ачыла. Җәй көнө* (җәен) *йаланда эш күб буладырыйы.*

Алар алдыннан *-қы/-ке* нисбәтлек кушымчасы да килергә мөмкин: *Йазғы көннө* (язын) *қайын тузын қуптарып алалмыйбыз, ди.*

Дәвамлы вакыт белдерә торган рәвешләр әдәби телдәге чаралар белән ясала: *қыш буйы / қышның буйына, көннәр буйы, озон көн буйына* һ.б.

Минзәлә сөйләшендә катып калган килеш кушымчалары, фигыль формалары яки сүзтезмәләрдән ясалган һ.б. үзенчәлекле рәвешләр дә бар: *иртәнчәк* – иртән, *кичәгенәк* – кичә, *иртәгә соңға/иртәгәдән соңға* – берсекөнгә, *тәүдә / иң тәү / тәү башлап* – башта, *атна* – гел һ.б. Мисаллар: *Тәүдә* (башта) *өйгә нигез салалар оло абзыйлар. Атна* (гел) *балтырған белән йәшәдек суғыш wақытында.*

**Фигыль.** Бәләбәй урынчылыгында, минзәлә сөйләшенең башка урынчылыкларындагы кебек, фигыльнең аспектлары, юнәлешләре һәм наклонениеләре ясалышы һәм функцияләре әдәби

телдәгечә. Шуның белән бергә бәләбәй урынчылыгында кайбер аерымлыклар табыла.

Затланышлы формалар. Хикәя фигыль. 1 нче зат берлек сандагы хәзерге заман хикәя фигыль *-ыйым/-ийем* кушымчасы белән дә ясалу очрый: *Әл дә сүлийем* (< сүләйем – әд. сөйлим) *әле мин әбигә. Сезне җаратып җырлыйым* (< җырлайым – җырлыйм).

Гомумән, *-ай/-әй, -аем/-әем* формасы татар әдәби телендә XIX гасыр ахырына кадәр кулланылган. Мәсәлән, Г. Тукай әсәрләрендә дә *-ай/-әй* формасы очрап куя: *Селкенмәй дә чайкалмай...*; *...Хәер-фатихада булышаек*. Бигрәк тә М. Гафури шигырьләрендә еш күзәтелә: *Кил, милләтем, һөнәр-гыйльмә тырышаек, / Бил баглап, мәйданә чыгышаек.*

Хәзерге көндә *-ай/-әй, -аем/-әем* вариантларын кулланып сөйләү Башкортстандагы татар теленең урта диалектка караган бөре, кормантау, тепекәй, турбаслы, учалы сөйләшләре, һәм, өлешчә, златоуст, минзәлә сөйләшенең бәләбәй урынчылыгы сөйләше вәкилләре өчен хас күренеш. Башкортстаннан тыш, Себер, Удмуртия, Киров, Чиләбе, Курган, Оренбург өлкәләре татарларында да сакланган.

Хәзерге заман хикәя фигыль 1 нче зат берлек санда тулы (*барамын*) һәм кыска (*барам*) вариантларда була. Әмма бу урынчылыкка караган Стәрлебаш татарларында тулы вариант сирәк кулланыла: *Аулаҡ өйдә ашарларға пешергәнне белмимен мин. Әле генә уйлыймын да көләмен.*

Дәвамлы үткән заман, урта диалектның күпчелек сөйләшләрендәге кебек, түбәндәге формалар белән белдерелә.

*-а торған иде* (форма): *Киндер ыштыннарны абыйлар кийә торған иде.Саwыт-сабаны, күмәчне ашйаулыҡҡа төрөп алып ҡуйа торғаныйы.*

*-адыр иде: Пич арасында бәрәннәр тотадырыйыҡ. Аулаҡ өйләрдә йырлашып утырадырыйыҡ, йегетләр кәрт суғадырыйы.Ураза мин дә тотадырыйым.Үләнгә ҡуйадырыйык та алифбаны, унөчәр бала йатып, җир өстөндә хәреф өйрәнәдерейек.*

Бәләбәй урынчылыгының (шулай ук төп урынчылыкның да) көньяк өлешләрендә *-а иде* формасы да очрый: *Бәләкәй wақытта, кич утырғанда, палас суғыр өчөн иске чүпрәкләрне қартәни мәрхүмә йырттырайы* (ерттыра иде). *Шул бер суткада бер шәлне өлгөртәйек* (өлгертә идек).

**Теләк формалары**. Минзәлә сөйләшендә теләк фигыльнең 1 нче зат берлек саны *-айы*/*-әйе*/*-ыйы*/*-ийе* кушымчасы белән ясала: *Мин бөтөннәй апчығийым* (алып чыгыйм) *әле, үземә дә кирәгер. Мин синең белә барыйым* (барыйм).

Мондый форма бәләбәй урынчылыгында да күзәтелә. Бу исә әлеге урынчылыкка мишәр диалектының стәрлетамак сөйләше йогынтысы белән аңлатыла. Билгеле булганча, теләк фигыльне 1 нче зат берлек санда *-ийе* кушымчасы белән формалаштыру көнбатыш (мишәр) диалекты өчен характерлы.

Ниятне белдерү өчен, әдәби телдәге *-асы кил* (барасым килә) формасы белән беррәттән, *-ырга*/*-ергә + итү* (булу // исәпләү // уйлау // йөрү) конструкциясе дә кулланыла: *Песи қошларға ташланырға итә. Су килергәйтә, су беткән иде.*

Минзәлә сөйләшендә шартлы теләк, көчле теләк, үкенүле теләк, киңәш-теләк мәгънәләрен белдерә торган формалар да әдәби телдәгечә.

Сөйләштә фигыльнең юклык формасына борынгы *-ғай*/*-гәй* кушымчасы ялганып ясалган теләк формасы да күзәтелә. Урта диалект сөйләшләрендәге кебек, бу форма шикләнүне, алдан искәртүне белдерә: *Суға төшмәгәйләре, ди, чебиләрен чыбық белән қуwып йөри. Шамилләр булмағайы дип уйладым.*

Бәләбәй урынчылыгында бу форма ике мәгънәдә кулланыла: а) шикләнү, курку, хәвефләнү: *Қурқам әле берәр нәрсәкәй әйтмәгәйе дип*. Бу мәгънә казан арты сөйләшләрендә дә күзәтелә; ә) ис китмәү, битарафлык: *Ачуланыр бит – Ачуланмағайы*.

Фигыль дәрәҗәләре, әдәби телдәге кебек үк, *-ғала*/*-гәлә, -ыштыр*/*-ештер* кушымчалары белән ясала.

Сөйләштә тагын *-ыңқыра* / *-еңкерә* формасы да бар. Ул, әдәби тел белән чагыштырганда, шактый актив кулланыла: *Қоймақ ачыңқыраған* (ныграк ачыган).

**Юнәлешләр.** Минзәлә сөйләшенең бәләбәй урынчылыгында юнәлешләрнең ясалышында да кайбер аерымлыклар күзәтелә.

Түбәндәге фигыльләр, әдәби тел белән чагыштырганда, башка юнәлеш формасында кулланылалар. ***Бет*** (әд. бетер): *Унынчы классны беткәч* (бетергәч), *ике бухалтерийәдә уқыдым. Үзем медицинскины беттем* (бетердем) *Сверловскида.* ***Алдату*** (әд. алдау): *Шамси әбийем беренче апрел'да мине алдатты* (алдады). *Син мине алдатып* (алдап) *салқын мунчаға йебәрдең.* ***Язышу*** (язу): *Үзем дә хәзер йазышам* (язам) *әле.* ***Эссертү*** (эсселәтү) – *эсселәнү: Көн нық эссерде.* Искәрмә: *Эссе* сүзе, урта диалектның кормантау, тепекәй сөйләшләрендәге кебек, икенче мәгънәгә («кайнар») дә ия: *Чәй эссе* (әд. кайнар). Кайчакта: ***җийнашып*** (җыйнап): *Мансур абый һәрwақыт Бисмилла әйтеп, ашйаулықларны җийнашып* (әд. җыйнап), *саwыт-сабаны, күмәчне ашйаулыққа төрөп алып қуйа торған ийе.*

Бу күренеш Башкортстанның башка татар сөйләшләрендә дә таралган.

**Затланышсыз формалар. Инфинитив**. Минзәлә сөйләше өчен инфинитивның, әдәби телдәгечә, ***-ырға***/***-ергә*** формасы хас: *Уқырға кирәк. Күрергә килдем. Барырға тийеш.*

Бәләбәй урынчылыгында ***-ма***/***-мә*** формасы, минзәлә сөйләшенең башка урынчылыкларындагы кебек, бик сирәк очрый. Ул нигездә ***кирәк*** модаль сүзе белән бергә кулланыла: *Сигез бала белән, әти суғышта, нәрсәкәй ашап йәшәмә кирәк. Утын да булмаса,нишләмә кирәк****,*** *туңып үләсең инде.*

***-ма***/***-мә*** формасы периферияләге сөйләшләрдә (нократ, касыйм, бастан, керәшен, норлат) актив. Ул шулай ук мишәр сөйләшләрендә дә күзәтелә.

Сорау алмашлыклары һәм *кирәк* модаль сүзе белән булган конструкцияләрдә ***-мак*** / ***-мәк*** формасы да инфинитив ролендә килә: *Барысын да қайан белеп бетермәк кирәк.*

**Исем фигыль.** Минзәлә сөйләшендә исем фигыль, әдәби телдәге кебек, ***-у***/***-ү*** кушымчалары ярдәмендә ясала*: Киндерне бақчага чәчәдерейек тә, үсүе җиткәчтен, йолқып бәйлибез. Хәзер қорбан чалу қуб инде. Энекәш қайтуwына өй салынып бетә.*

Сөйләштә *-ыш/-еш* кушымчалы исем фигыль дә актив: *Соңғо өмөтнө өзөп китеп барыш. Безнең чығыш Қазан йақлары татарлары. Тычқан чалыштан уйныйық.*

**Сыйфат фигыль.** Киләчәк заман сыйфат фигыль, әдәби телдәге кебек үк, *-ыр/-ер/ -ар/-әр/-р, -асы/-әсе/-ийсы/-исе, -ачаң/-әчәк* кушымчалары белән ясала. Аларның кулланылышы һәм мәгънә үзенчәлекләре белән дә сөйләш әдәби телдән аерылмый. Бары тик бәләбәй урынчылыгында ***-р*** кушымчалы сыйфат фигыльләрнең активрак булуын гына күрсәтеп үтәргә кирәк, ул тиешлек, кирәклек мәгънәсен дә белдерергә, исемләшеп, тартым, килеш кушымчалары да алырга мөмкин: *Қайчан туй булырын* (буласын) *белеп китә. Анда нәстәкәй булырын* (буласын) *без қайан белик.*

Сөйләшнең характерлы үзенчәлекләреннән берсе – сыйфат фигыльләрнең *-малы/-мәле* формасы актив булу. Ул, гадәттә, даими билгене белдерә, хәбәр составында кулланыла һәм әдәби телдәге *-арлық* яки *-а торған* сыйфат фигыльләренә туры килә: *Суқа қул белән тотмалы* (тота торган). *Элек мылтықлар бит дары белә генә қормалы* (кора торган).

Сыйфат сүз төркемендәге *искиткеч* сүзендә дә *-мәле* үз урынын ала: *Стәрлебашның тарихы искитмәле*(искиткеч). *Урыста искитмәле* (искиткеч) *мәқәл бар: «Наглост' – второйы щаст'е», дигән.*

Хәл фигыль, *-ып* кушымчалы хәл фигыльләрнең юклыгы берничә вариантта кулланыла: *-мый/-май, -ми/-мәй, -мыйынчы/ -майынчы, -мийенче/-мәйенче, -мыйчы/-майчы, -миче/-мәйче, -мыйча/-мичә.* Шулардан киң вариантлар (*-май, -майынчы* һ.б.) минзәлә сөйләшенең характерлы үзенчәлеген тәшкил итә. Алар төп, яңавыл урынчылыкларында, әгерҗе урынчылыгының көньягында төп форма булып торалар, ә бәләбәй урынчылыгында бу вариантлар үзләренең системалылыгын шактый югалтканнар һәм биредә тар сузыклы вариантлар (*белмиче, белмийенче* һ.б.) күбрәк кулланыла. Шулардан *-мый/-мий, -мыйча/ -мичә, -мыйчы/-миче* вариантлары – әдәби формалар, алар мишәр, урта диалектның казан арты төркеме һәм башка сөйләшләрендә киң таралган. Кайбер мисаллар: *Қыз риза булмыйча йөрөсә, урлап апқайта. Чишмә суы ақмый* (акмыйча) *җийылып тора бит.*

Стәрлебаш татарларында -*мичәк, -мыйчаҡ* формасы да очрый: *Аны күрмичәк, ничек тапшырыйым инде. Безгә әйтмичәк китеп барған.*

Әдәби -*ғач*/-*гәч* кушымчасы белән беррәттән, бәләбәй урынчылыгында аның түбәндәге төрле вариантлары һәм синонимнары бар: -*ғачтын*/-*гәчтен, -ғачтан*/-*гәчтән* (сирәк). Бу форма, әдәби телдәге кебек үк, эш яки хәлләр арасындагы сәбәп һәм вакыт мөнәсәбәтләрен белдерә: *Мәктәптә уҡый башлағачтын* (әд. укый башлагач), *башаҡ җыйарға йөридерейек басуларға. Теге диwанаға салышҡачтын, моноң ҡайтасын белгәчтен, теге әйтә: Син бу ҡызны алып ҡайтып кит инде үзләренең йағына, ди.*

*-ган(нан) соң*: *Шунан бер ай торғаннан соң килен булып төшә тегендә. Күпме үскәннән соң ул үзе дә ҡойолып бетә. Кибән эшләгән соң, күп булса эскерт ҡойабыз.*

Хәл фигыльнең -*ганчы*/-*гәнче* (ягъни әдәби) формасы сөйләштә актив кулланыла: *Менә шулай җилкәдәге чәчме ҡойолғанчы бала йылый икән дип әйтәләр. Аwылға килеп кергәнче, аwыл күренми. Шуларны утый башладыҡ, пока мәктәп йәшенә кергәнче. Ҡызыл төскә кергәнче ҡайнатабыз эремчекне.*

*-мас борон* (сөйләшләрдә киң таралган форма): *Иртән ҡойолмас борон күксағызның чәчкәсен йыйабыз – кич көнө йомола, иртәңге йаҡҡа ачыла ул.*

**Ярдәмлек сүз төркемнәре.** Минзәлә сөйләшендә түбәндәге чагыштыру бәйлекләре кулланыла: *кебек*/*күwек*/*күк* – кебек, *төслө, шикелле, сыман.* Мәсәлән: *Ҡырлы ҡурай йомро гөпшә* (әд. көпшә) *кебек үсә. Матур алан кеwек җир. Ҡуйан тамыры үләненең тамыры тәмне, әрчеп ашыйсың, астында бәрәңге сыман була. Алма шикелле йоп-йомры.*

Стәрлебаш татарларында чикләүне белдерә торган түбәндәге бәйлекләр кулланыла: ***чаҡлы*** / ***чаҡлым; хәтле*** / ***хәтлем*** / ***хәтлек***.

Кайбер мисаллар: *Бер йәшкә чаҡлым баланы үзен генә ҡалдырып чығырға йарамый. Ҡырығына чаҡлы мәйет чыҡҡан өйнө берүзен ҡундырмыйсын. Әниләрне иртәдән кичкә хәтле көлтә бәйләтәләр. Суда монауыҡ хәтлек кешенең ҡош-ҡортларына*

*тийә торған бер төрлө йәнлек бар, диләр. Күрше қыз белән сәғәт 12 гә хәтлем өйдәге шәлне бәйлибез.*

Бәләбәй урынчылыгында ***тәңгәлдә, тәңгәлендә, тапқырда*** сүзләре әдәби телдәге ***турысында*** бәйлек сүзенә туры килә һәм урын-ара мәгънәсендә кулланыла: *Кылуп тәңгәлендә* (турысында) *генә тора. Суны үзебезнең тапқырдан алабыз.*

Стәрлебаш татарларында урын-араны һәм вакытны белдерә торган ***алата*** (әд. алып) бәйлек сүзе күзәтелә, ул чыгыш килешен башкара: *Тегеннән алата* (алып) *йөгөреп килде. Шуннан алата көтү көтә.*

***Әтү*** бәйлегенең кулланылышы: *Тақта қуйыла, әтү* (< рус. *а то*, тат. *алайса*) *бит йаз көнө йөрөп булмый, су керә.*

Минзәлә сөйләшендәге ***исә*** теркәгече, әдәби тел белән чагыштырганда, активрак (әгерҗе урынчылыгында аеруча актив) кулланыла. Ул билгеле үткән заман формасындагы хикәя фигыль белән килә, зат, сан кушымчалары төп фигыльгә ялгана*: -ды/-де исә.* Әмма Стәрлебаш татарларында бу күренеш беткән. Бик өлкән буын әбиләрендә генә сирәк очрый: *Шәһәргә китдисә* (китсә), *бер айдан қайтып керә иде.*

Бәләбәй урынчылыгында зат кушымчалары еш кына төп фигыльгә түгел, ***исә*** теркәгеченә ялгана: *Аңа бардисәң* (барсаң), *бу үлмәгән дип әйтерсез дип қаршы ала иде. Күрдисәләр* (күрү белән), *Шәмсеруй әби, исәнме, диләр.*

Хәзер дә кайбер сөйләшләрдә сакланган бу күренеш XX гасыр башына кадәр язучылар иҗатында актив кулланылып килгән. Бигрәк тә Урал төбәге татарлары теленә хас (мәсәлән: кормантау, тепекәй, учалы, златоуст һ.б. сөйләшләрдә), категорик үткән заман хикәя фигыль һәм исә теркәгеченнән торган конструкция ярдәмендә белдерелә һәм, нигездә, вакытны, шартны, еш кына икеләнүне аңлата[1].

---

[1] *Булатова М.Р.* Конструкция *-ды исә* в курмантауском говоре среднего диалекта татарского языка // Сохранение и развитие родных языков в условиях многонационального государства: проблемы и перспективы: материалы Международной научно-практ. конф. (Казань, 19–21 октября 2017 г.) / под ред. Р.Р. Замалетдинова. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2017. С. 39–40.

Урынчылыкта нык сүзе көчәйткеч кисәкчәсе ролендә кулланыла: *Айғыр таwы нық* (бик) *текәл* (текә). *Тәтер суwы да бик нық кәмеде.*

**Синтаксик үзенчәлекләр**

Хәбәрлек кушымчалары исем хәбәрләргә дә ялгана: *Алар эштә түгелләр. Син бәг усалсың икән әтү. Мин йылақмын үзем бик. Ничәүсез сез? Иптәшләр дүртәүләрийек без. Әнийебезләр Шарлық районына икмәк өчөн китәләр ийе.*

Галимнәр фикеренчә, борынгы төрки телдә дә гади җөмләгә шушындый ук төзелеш хас булган.

Минзәлә сөйләшендә дә сорау җөмләләр әдәби телдәгечә үк оештырыла: *Бүтән нәрсәләр кирәкмиме? Карточкага төшү қартайғачыннан нигә кирәк соң ул? Тәрәзәне ачмалы итәсезме? Нийә шул йулдан кереп китәбез мени?*

Сөйләштә сорау интонация ярдәмендә генә дә белдерелергә мөмкин: *Аwылға қайтмый* (кайтмыймы)? *Синнән зурлар, бәләкәйләр* (зурлармы, кечеләрме)? *Сез дә бардығыз* (бардыгызмы) *канциртқа?*

*Кайда... ни, кемне... ни* тибындагы аналитик төзелмәләр югарыда карап үткән ия – хәбәр – ия рәвешендәге конструкцияне хәтерләтә. Татар сөйләшләрендә хәзер дә күзәтелә торган мондый тип конструкцияләрнең борынгы уйгур язма истәлекләрендә дә кулланылганлыгы билгеле.

Бәләбәй урынчылыгында *шуннан ары соң* / *шуннан аннары соң, аннан соң* тезмәсе актив. Кайбер мисаллар: *Шуннан ары соң әни иртәнчәк кантурға барған.Шуннан аннары соң моның қайтыр срогы йеткән. Аннан утын урынына ғомбағыш тайағы йақтық. Аннан соң аwылға Мөнасыйп исемле кеше килеп утырған. Шуннан бер ай торғаннан соң килен булып төшә тегендә.*

**Лексик үзенчәлекләр**

Минзәлә сөйләшенең бәләбәй урынчылыгы гомуми сүзлек фонды, лексик-семантик системасы да аның урта диалектка һәм әдәби телгә бик якын торуын раслый.Тематик яктан түбәндәге төркемнәрне күрсәтеп үтик.

Туганлык-кардәшлекне белдерә торган һәм кешене тасвирлый торган сүзләр: *картәни/картинәй* – ***әд. дәү әни,*** *картәти/картәтәй* – ***дәү әти,*** *әби* – әти-әнинең олы кыз туганнары, *бабай* – әти-әнинең олы ир туганнары; *түтәй / түти* – апа, *бийана, бийем* – каенана, *бийатай* – каената, *әхи* – ахирәт, *ҡырлайчы* – кырыктартмачы; *чәмнәнү* – гарьләнү, *каңғыл* – чандыр, *сақбай* – чукрак; *ләкәт / ләкаш / ләкәм исемнәр* – кушамат.

Йолалар: *килен малы / бирнә* – кыз ягыннан егет ата-анасына һәм туганнарына бирелә торган бүләк; *бәбәй үстерү* – бәби туе; *урнаш пешерү* –аулак өйдә пешерелә торган ризык; *мыжык ҡуыру* – элеккеге йола: бала (аркасында) йонлы булып туса, «мыҗык курам» дип әйтеп, җылы мичкә тыгып алганнар.

Тормыш-көнкүреш белән бәйле яки төрле кирәк-яракны белдерә торган сүзләр: *мал өйө* – әд. аш йорты, *бүлмә* – чолан, *ихата* – койма, *мөйөш* – почмак, *күтәрмә* – өйалды баскычы, *кәмә* – көймә, *чәбен / шәбен* – күбә, *йөзек чите* – диван чите, *ҡыйчауғач* – кисәү агачы, *бидрә / бидыра* – чиләк, *йанұғыч* – янавыч, *суйыл* – озын таяк, *элмә* – келәм (стенага эленә), *ужҫау* – аш чүмече, *йәмкә* – кыскыч ‘шипцы для угля’, *тәрлинкә* – тәлинкә, *кәбәркә* – мич арасы, *пачтет / паштет / ләwәш* – юка бәлеш (пирог), *әпәй* – ак икмәк, *күмәч* – икмәк, *әчмуха чәйе* – бер пачка такта чәе, *шапа* – кәҗә мамыгын эшкәртү өчен махсус тарак (нишләү? – *Шапалау*); *түр йурганы* – мамыктан сырылган юрган, элегрәк кунаклар чакырганда аны түр башына идәнгә җәйгәннәр, кешеләр утырыр өчен; *шама / чәй чүбе* – чәй чүбе һ.б.

Кием-салым һәм бизәнү атамаларына кайбер мисаллар: *нағыш эшләү* – чигү, *пима* – киез итек, *көртә* – сырган, җиңсез камзул, *сүсинке* – галош белән кия торган киез итек < рус. чесанки, *башантай* – йон наски (әмма тапочки кебек кенә итеп бәйләнгән), *куфайкы* ‘фуфайка’, *дәwәт* – хәситә, *изү* – хатын-кызларның күлмәк өстеннән алга күкрәккә киелә торган бизәнү әйбере, *ука* – чачактан тегеп эшләнгән, маңгайга бәйләп куела торган бизәнү әйбере, *маңғайча* – яулык өстеннән башка киелә

торган, хатын-кыз бизәнү әйбере, сай түбәтәй рәвешендә тегелә һәм алды энҗе яки вак тәңкәләр белән бизәлгән була һ.б.

Хайваннар, үсемлекләр дөньясы һәм табигать күренешләре: *мамық кәжҗә* – зур куе йонлы кәҗә (йоны өчен асрыйлар), *ақ кәжҗә* – сөт кәҗәсе, *туқал* – мөгезсез сыер, *селәүчән* – суалчан, *сағызақ* / *сағадақ* – шөпшә, *киндераш* – киндер орлыгы, *күксағыз* ‘каучуковое растение’, *қымызлық* ‘кислица’, *қарағай* – нарат, *урләпә* / *гөрләпә* / *ғырлафа*/ *сәрби* – қақы, *күке башы* – күкбаш ‘медуница’, *қуйан тубығы* – йонлы бәрәңге ‘бутень клубненосный’, *сәрәнә* – лилия чәчәге ‘саранка, царские кудри’, *песәй үләне* – мәче борчагы, *песәй үләне мәмийе* – мәче борчагы җимеше, *қаз тәпийе* – казаяк, каз үләне; *йалағай* – аҗаган, *әтлек* – ат кузгалагы (чагыш.: башкортча *әтлек* ‘ҡыңғырау сәскә’, ‘бубенчик лилиелистный’), *қуйан қузғалағы* һ.б.

Түбәндә экспедиция вакытында минзәлә сөйләше бәләбәй урынчылыгы вәкилләреннән язып алынган, авыллар тарихын һәм халык традицияләрен чагылдырган материалларның кайберләре тәкъдим ителә. Стәрлебаш татарларының фонетик, грамматик, лексик үзенчәлекләре һәм аларга хас булган гореф-гадәт, йола һ.б.лар сөйләү үрнәкләрендә аеруча тәэсирле яңгырый. Текстларда сүзләрнең әйтелеше транскрипциядә бирелә. *Я, ю, е* хәрефләре урынына [йа], [йә], [йу], [йы], [йы], [йе] авазлары, өстәмә билгеләрдән [w] – ирен-ирен өрелмәле тартык аваз һәм [қ], [ғ] – тирән тел арты тартык авазлары кулланылды. Кыскартылмалар: әд. – әдәби, рус. – русча, һ.б. – һәм башкалар.

## СТӘРЛЕБАШКА ЭКСПЕДИЦИЯ ВАКЫТЫНДА МИНЗӘЛӘ СӨЙЛӘШЕ БӘЛӘБӘЙ УРЫНЧЫЛЫГЫ ВӘКИЛЛӘРЕННӘН ЯЗЫП АЛЫНГАН, ТЕЛ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕН ҺӘМ ХАЛЫК ТРАДИЦИЯЛӘРЕН ЧАГЫЛДЫРГАН МАТЕРИАЛЛАР (СӨЙЛӘҮ ҮРНӘКЛӘРЕ)

### Авыллар тарихыннан

**Айдарәле.** Безнең тарихыбыз буйынча, Саба йағыннан килгән дигән сүзләр былды. Қартәтәйебез (әд. *дәү әтиебез*) күчкән была

Қарғалыға, Қарғалыдан соң бийаққа алар китәләр. Аwылыбыз элек Нижний Ибрай һәм Верхний Ибрай дип йөрөтелгән. Бабайлар шушы җирне алырға булғаннар, килгәч ул йақтан. 1749 йылда аwылға нигез салынған, диләр. Бабайларыбыз безнең бу җирне алырға дип нийәтләгәч, бер Айдар дигәне башлап, Уфадан бирмәгәннәр җирне. Йөз йылдан соң безнең аwылға Айдарғали дип исем қуштырып, исемне мәңгеләштергән дигән риwәйәт бар. 1992 йылда салынған мәчетебез бар, шул йылдан бирле ул эшләп килә.

*Айдарәли авылында*
*Миңнехалит Саитгали улыннан (1937 елгы)*
*язып алынды*

**Бакый (*легенда*).** Бақый бабай килеп утырған монда. Ул болай була. Хә (*хәзер*) сүлим. Элек бит 25 йыл хезмәт иткәннәр. Шуннан аннары соң Бақыйның қайтыр срогы йеткән. Қабақуш аwылыннан бер қызны сатып апкиткәннәр булалар икән. Кәрткә отторғаннар. Шул қыз бу (Бакый) ыслужит' иткән йергә барып эләгә. Бу кеше шунда алып китә. Бу бит инде татарча йырлый, моңайып, қайғырып. Килә монођ йанына Бақый бабай. Танышалар, сүләшәләр. Йул ыңғайына (*юл уңаена*) туры килә. Ничек қайтырға моннан. «Син диwанаға салыш», – ди теге қызға. Бу қыз диwанаға салыша, килде-китте сүләп. Шуннан аннары соң, теге диwанаға салышқачтын (*салышкач*), моның қайтасын белгәчтен (*белгәч*), теге бу қызны алып киткән. «Син моны алып қайтып кит инде үзләренең йағына», – ди. Шуннан шуның белән алып қайтып, Қабықуш дигән аwыл бар менә монанда (шул Қабақуш аwылынықы була бу қыз), шуннан бу қыз қайтқачтын (элек бит инде 25 йыл хезмәт иткәч, бабайға әйләнгән бит инде, қартайған теге), «Син давай өйлән шушы минем қызыма. Мин сийа (*сиңа*) усад'ба бирәм», дигән Бақый бабайға инде. Шуннан соң Бақый бабай монда килеп утырған. Шуннан Бақый аwылы башланып киткән инде.

Үзем шушы аwылда тудым, үстем. 30 йыл тимерче булып эшләдем, тимер туқмадым. Монда элек көчлө мәчет булған. Анисы ағач ийе. Ул мәктәп булып та торды. Мәчетнең манарасын аударғаннар. Бу мәчетне үзебез төзөдек. Ташларын та-

шып. 1982 дә башладық, 1992 нче йылны бетте (*эшләнеп бетте, яки эшләп бетердек*). Мәчеткә йөрөйбез. Тәрәwих намазына Стәрлебашыннан да киләләр.

*Бакый авылында*
*Байтимеров Рәфкать Гафият улыннан (1928 елгы)*
*язып алынды*

**Карагыш.** Қарағышка да Қазан йағы кешеләре килеп урнашкан. Әнwәр Әсфәндийәров тикшеренүләре буйынча, Қарағышка 1756 йылда нигез салынған. Әммә аwылның килеп чығуы байтаққа иртәрәк булуына шик йуқ. 1965–68 йыллар тирәсеннән үк Фәйзрахман Фархшатов әкрен генә истәлекләр җыйудан башлаған. Ул җыйған истәлекләрнең берсе Қарағыш аwылына 800 йыллар элек нигез салынған дип дәлилли. Аwыл ақсақалы Ғомәр Туқтаров уқыған бер қәбер ташында 1247 нчы йыл дип йазылған булса, икенчесендә 1645 йыл дип йазылған. Ул һижри йыл белән исәпләнгән булырға кирәк. Тағын бер қәбер ташында 1405 дип күрсәтелә. Қәбер ташларының шул йылларны күрсәткән булуын бәлки Пугачев отр'адының бу тирәләрдән үтүе белән дә бәйләп буладыр.

1968 йылда Қарағыш обществысы булған. Җайлап-җайлап Қарағош волост' үзәге дә булған. Анда бер мәчетне йандырғаннар. Болайрақ күчкәннәр. Тау башына килеп утырғаннар.

Ул қара қошларның қанаты бер-берсе икешәр метр чамасы булған. Зур қара қош. Кешеләр сөйләшеп утырғандамы шул қош очоп киткән. Қарақош дип қуйыйық, дигәннәр. Қарағошка әйләнгән. Аwылның исеме шуңардан.

*Карагыш авылында*
*Әхмәтова Нәсимә Абдрахман кызыннан (1946 елгы,*
*тумышы белән Айдарәле авылыннан) язып алынды*

**Стәрлебаш.** Эстәрлебашның тарихы искитмәле (*искиткеч*). Эстәрлебашны урыс 1661 йылны салған дип йаза. Ә мин Ғабдерәхим Утыз Имәни әл-Болғаридән таптым датасын. 1583 нче йыл. Урыслар тар-мар иткәч, безнең бунтар бабайлар килеп Қарғалы аwылын салғаннар. Эстәрлебашның тәүге исеме Қарғалы. Менә бу крепост' исеме белән. 1583 йылдан алып 1661 йылға қәдәр

монда, Ағыйделнең сул йағында, бердәнбер татар аwылы, мосолман аwылы булған. Монда бер башқорт аwылы да булмаған. Безнең бабайлар монда ике йөз йыл буйына бер кешегә дә налуг түләмичә йәшәгәннәр. Киң күңелле қайсақлар (аларны бүгенге көндә «қазақлар» дип атыйлар) алмаған бездән бер тийен дә. Ходай биргән җир дип. 180 йыл буйына үз волена йәшәгәннәр. Налук түләмәгәннәр, сәүдә иткәннәр. Индустанға барып йеткәннәр безнең бабайлар. Бик бай булған аwыл. Урыс 1661 йылда салынған, ди. Ә урыс килгәндә биш мәдрәсә булған бит уже.

Аwылның иң тәүге урамына Шишмә урамы исеме қушыла. Урам бүген дә шул исемне йөрөтә. Ул урам башланған урында, Текә тау итәгендә, алты шишмә бәреп ағып йата.

Эстәрлебашта унлап гаилә – Туқайывлар. Алар – мөдәррисләр, ишаннар, хәлфәләр, сәүдәгәрләр, зур җирбиләүчеләр. Тархан Габделқадыйр Туқайывның Эстәрлетамақ белән Қуғанақбаш аwылы арасында ике мең дисәтинәдән артық җире булған, миллионер бай булған. Эстәрлебашта тәү имам Монасыйб мелла дигән кеше, икенче мәртәбә мөдәррис Ғаделшаһ хәзрәт бине Ғабдулла Боғданов булган дип йазған үзенең «Тарихул' Стәрлебаш» китабында Мөхәммәтшақир Туқайыв. М. Туқайыв үзе дә билдәле мәдрәсә мөдәррисе була.

18–19 ғасырда Эстәрлебаш татар шиғрийатының зур учағы да булған. Йазучы Дәрдмәнднең әтисе йағыннан қартәтисе Исмәғыйл' белән йазучы Ақмулланың әнисе йағыннан қартәтисе Сәлим ахун бертуғаннар. Исмәғыйл тармағы Дәрдмәндне биргән, Сәлим ахун тармағы Мифтахетдин Ақмулла белән Сәғыйт Рәмийевне биргән. Исмәғыйл дә, Сәлим дә – Рәмийевләр.

*Стәрлебаш авылында*
*Зәйнуллин Зәки Лотфулла улыннан (1933 елгы)*
*язып алынды*

**Стәрлебаш.** Монда Болғар крепосте булған. 1203–1209 йылларда салынған. Стәрлебашка иң тәү Монасыйп исемле кеше килгән. Қазан алынғанан соң килеп утырған. Күп чығанакларда халық Оренбурдан килгән дип баралар. Киресенчә, Қарғалы Стәрлебаштан килеп утырған дигән фараз да бар. Стәрлебашны

тәүдә (*башта*) Қарғалы ..., азақтан Стәрлебаш Қарғалысы дип йөрөткәннәр. Аннан Стәрлебаш қына тороп қалған. Теге Қарғалы тороп қалған Оренбур арқасында. Шундый фараз да бар. Байтақ қына ағым былған. Қазан ханлығы алынғаннан сон килгәннәр. Төп чығанағы билдәле (*билгеле*) түwел. Стәрлебашның теге қыры урман булған. Стәрлебашның урман эчендә, Тәтер-Арсланға (*авыл исеме*) киткәндә, җиде шишмә бар. Стәрле суwының башы. Бик матур йер ул. Уртаға қойалар безнең суларны. Бик матур йер ул урман эчендә. Шул Стәрлебаш дип шуңардан алынган исем. Революцийәдән күпкә элек түгел Қалқаш аwылында элек кәмә (*көймә*) белән йөзгәннәр. Шундағы бер хатын Стәрле суwындағы «Кәмәче» йырын йырлыйдырыйы. Тәтер суы да бик нық кәмеде. Тәтер суwы бик зур ыйы. Балық тоталар ыйы. Шишмәләр кәмей хәзер. Дим йылғасы безнең районда Березовка аwылында башлана. Стәрлетамақ шәһәрен пристан' итеп төзөгән. Зур йылға булған Стәрле йылғасы. Төшә дә йуғала ул, тағын килеп чыға.

Қартәтием 1921 йылда Тәтер-Арслан аwылында мулла булған. Стәрлетамақта бер кеше, қайтқанда, қул биреп исәнләшкән дә әйткән: «Стәрлетамақта ваба аwыруы көчәйгән бит, мулла абзый», – дип. – Кешеләр қырылып үлгәннәр». Шуннан әйткән теге: «Нийә килеп қул бирдең миңә?» –дигән. «Бар, кер өйөңә, чықма и кеше дә кертмә», – дигән. Икенче көнне үзе дә аwырып киткән. Таза кеше булған.Ул аwырып киткән көйө қартәнийебез (*дәү әниебез*) аwырып киткән дә иртәнге 9 ларда, көндөз сәғәт 12 дә үлгән. Бабайыбыз ақырып йатқан бер стакан суға өч тамчы дип. Йоды кирәк икән. Врач булған. «Шуны салып эчегез», – дип қычқырған. Әтинең абзасы да эчкән, әти дә эчкән. Әтинең абзасы исән қалған, үлмәгән. Әти керегә (*керергә*) қурққан инде. Бабай үлгән. Шуннан ишекне бикләгәннәр. Қадақлағаннар, чығып киткәннәр. Анда кеше кермәгән бүтән. 21 нче йылны, ачлық йылны, җимереп кергәннәр. Әти, 1938 йылны Стәрлебашқа күченеп килгәчтен, тузып йатқан медицина кыйтапларын (*китапларын*) җийып алған. Уқытучы булып эшләгән.

*Стәрлебаш авылында*
*Рәмиев Нил Әмирҗан улыннан (1937 елгы)*
*язып алынды*

**Тәтер-Арслан.** Шушы Тәтер йылғасы буйында бер участник Вайны мин (Гомәр) қалдым. 1942 йылда суғышка киттек. Киткәндә 18 тулмаған иде. 9 класстан киттек йегетләр.

«Шәкерт таwы». Федоровка районыннан, Эстәрлебаш данлықлы мәдрәсәләр бит инде анда, шунда уқып йөрөгән шәкертләр йаңғыр йаwыпмы теге чоқорға кереп утырғаннар да шунда басылып үлгәннәр. Шәкертләр үлгән дигән легенда бар.

Шуннан ары соң Хаҗи үлгән чоқоры бар. Хаҗи утынын алып қайтып килгәндә, аты дулап, йөк астында қалып үлгән. Шуңардан атамасы.

«Әҗәл таwы». Эстәрлебаш белән безнең арада Әҗәл таwы бар. Ул данлықлы, бийек тау. Асфал'т төзөгәчтен (*төзегәч*), аны кистертеп, текәлеген бетерделәр. Анда үлүчеләр күп булған, атлары дулап. Монауда (*менә монда*) безнең бер күрше малайы йырлый икән:

Эстәрлене су баса,
Әйдәрлене басар иде,
Әҗәл тауы булмаса, дип.

Монда базар бар ийе. Оло базар. Урыс аwылыннан марйалар киләйе. Қыйар, кәбестә китереп. Аwылда мәчет төзөлә әле. Элек ике мәчет иде: берсе мәктәп, берсе клуб былды.

«Әче урамы»нда сазлық былған. Күчеп беттеләр аннан, сазлық булғанға. Шунда кичке уйынға җийналышалар иде қызлар – йырлап йөрү, гармунға қушылып.

*Тәтер-Арслан авылында*
*Гомәр Мәсәлим улы (1926 елгы)*
*һәм Майтәп Бакир кызы (1928 елгы) Байморатовлардан*
*язып алынды*

**Тормай.** Бу татар аwылы. Бер урысмы, чуwашмы исем атаған. Аwыл тәүдә Қайрақлы булған. Печән чабучы чалғысын қайрақ (әле йанауғыч дибез бит инде, чалғы үткерли торғанны) белән үткерләп утырған да, теге су қырында, су эчәргә төшкәндә, су қырында қалдырған қайрағын. Шуннан Қайрақлы дип қалған. Бу Тормай – әле генә чыққан исем. Аны чуwаш қушқанмы инде Тормай дип. Қорманай да булган әле ул безнең аwыл. Бу аwылға

Қурманаев дигән фамилийалы кешеләр килеп утырған. Аннан алар ишәйгәннән ишәйгәннәр. Иң тәүдә Қайрақлы булған, аннан Қорманай атағаннар. Аннан бу Тормайқайдан килеп чыққандыр. Әниләр Қайрақлы дип аталған wақытта туғаннар. Өч километр бездән ары чуwаш аwылы Тәтербаш. Бездә чуwашлар йуқ. Безнең аwылда Қурманаевлар, Абдуллиннар күбрәк.

Безнең аwылны «бәрәңге аwылы» дип тә дигәннәр. Безнең аwылда бәрәңге үскән. Менә Стәрлебашны «қабақ» диләр ийе. Анда қабақ үстергәннәр. Бездә бәрәңге әйбәт үсә.

*Турмай авылында*
*Абдуллина Сәбилә Биктимер кызыннан (1937 елгы)*
*һәм М(н)оскова Суфия Миңнеәхмәт кызыннан (1939 елгы)*
*язып алынды*

**Яңгырчы.** Ирекле дигән бәләкәй аwыл булған. Монау йақта инде ул. Шунда Йаңғырчы дигән қарт килеп утырған, ди. Шуңардан аwылға шундый исем қушқаннар. Элек аwыл шунда булған, ди. Өршәк йылғасының монау йағында. Алар кийез басу белән шөғылләнгәннәр. Әнә шул кийез басучылар эзләп килеп чыққаннар дип сөйлидерийе. Йаңғырчы дигән сәүдәгәр килеп чыққан дип. Аның өч малайы булған. Бер малайына Ирекле дип қушқан. Анннан Гөлем дигән қызы булған. Қаранай дигән малайы булған. Шулай дип сүлиләр иде.

Қазахлар да йәшәгән дип сүлиләр ийе. Җир астын чоқоп кереп йәшәгәннәр. Земл'анкалар бар иде әле мин килгәндә дә. Монанда (*менә монда*) өстә. Күмелеп беткән инде хәзер. Киткәннәр инде.

Иң матур урын – Ирекле. Анда Йәшел күл дигән бар. Қарабүләк урманы.

*Яңгырчы авылында*
*Газизуллина Сания Хөснетдин кызыннан (1948 елгы)*
*язып алынды*

**Яшерган.** Бу чистый татар аwылы. Бузаттан (*авыл исеме*) килгән мишәр татарлары дә татарға әйләнеп беттеләр. 1770 йылларда Оренбур өлкәсенең Қарғалы дигән татар аwылыннан Исмәғыйл исемле дин әһеле килә үзенең Айдарғали, Арсланғали һәм

Ибраһим исемле уллар белән. Килеп урнашқан шушы матур табиғәтле җиргә. Айдарғали дигән улын хәзерге Айдарәли аwылы урнашқан җиргә, Арсланғалине хәзерге Арслан аwылы җиренә, Ибраһим дигән улын хәзерге Ибрай аwылы урнашқан җирләргә урынлаштыра. Алар шул җирләргә нигез қороп йәши башлыйлар.

Исмәғыйл бабай хөрмәтенә аwылыбызга Исмәғыйл дигән исем бирелә. Безнең аwылыбызның тәүге исеме – Исмәғыйл. Соңрақ аwылыбыз Йашырған дип йөртөлә башлый. Аwылға килеп кергәнче, аwыл күренми. Йәшерелгән. Шуңардан килеп чыққан дигән хәбәр дә бар. Безнең аwылда бик йақшы таш чығa торған урын бар. Ул бөтөн Башкирийаға бездә генә ул йақшы таш. Ағач кебек итеп тә эшкәртелә. Қарғалыдан армийа хезмәтенә китәрлек йәшләрне, армийа хезмәтеннән йәшереп, шушында шушы таш эшкәртүчене алып килгән йәшереп. Шундый вариант та бар. Шуларны йәшереп алып килгән йегетләргә исем хөрмәтенә Йәшерелгән / Йашырған аwылы булып киткән. Ул таш бар. Но ташлар эшкәртеw йуқ хәзер. Безнең мәчетләр бөтөнесе таш ихата (*койма*) була. Йақшы таш була. Қарғалы (Оренбургтагы) үзе бездән, шушыннан, зират ташларын, башқа ташларны – вич (*барысын*) шушыннан ташыған.

Бүгенге көндә аwылыбызда ике мәчет эшли. Бер мәчеттә ололарны, икенче мәчеттә балаларны уқыту ойошторылып тыра.

Исмәғыйл бабай килгән чорда монда өч-дүрт сем'йа чуwашлар булған. Алар йәши-йәши, ислам динен кабул итеп, татарлашып беткән алар. Аwылыбызның йаңы (*яңа*) ойошқан wақытта булған ул.

*Яшерган авылында*
*Әлмөхәммәтов Миңнегазыйм Саниәхмәт улыннан (1937 елгы)*
*язып алынды*

### Тормыш-көнкүреш турында

Безнең бит чығыш бер бабайдан булған. Аwыл бик бердәм булған. Әгәр дә берәрсе йалғылыш (*ялгыш*) җиләккә алдан чықса, җиләк җийарға, уже бабайға барып әйткәннәр: «Менә шул алдан чықты җиләккә шул». Һәм җийылып теге кешене әрләгәннәр:

«Нийә син халыктан алдан чығасың?!» Җиләк, шоморт или балан пешкәнне белер өчөн бер-ике бабай йөрөп чыккан җиләклекләрне, шомортлыкларны и әйткән халыкка: «Шоморт пешкән, иртәгә шоморт җийарға чығабыз». Алдан беркем дә йөрөмәгән.

Җирләр. Бақыр қазынтысы дип йөрөтәләр. Бақыр чоқоры булған. Бақыр ташы алған булғаннар. Завут асты йере. Анда көл заготовит' иткәннәр. Қайын көлө йандырып Францийаға озатқаннар. Селте йасар өчөн. Селтене қулланғаннар сабын йасарға.

*Турмай авылында*
*Исмәгыйлев Хисаметдин Шәрәфетдин улыннан (1953 елгы)*
*язып алынды*

Стәрлебашта мин үскәндә асалы палас суғучы берничә әби бар ийы. Станоклары бар ыйы. Чүпрәк паласны минем әни үзе суғадырыйы.

Стәрлебашта ташчылар бик шәп булған. Йашырған аwылында тау эчендә таш бар. Пычқы белә (*белән*) кисеп алалар. Анда тау қуышлығы бар. Ырымбурның Қарғалы дигән татар аwылы(на) моннан ташыдылар ташны шунда. Бүген дә Йашырғаннар таш белә сәүдә итәләр. Қәбер ташы белән.

1921 йылны урыс аwыллары берсе дә ачлықмады. Урыс аларны ашатты. 1921 йылны, ачлық йылны, татарлар алқаларны, бизәнү әйберләрне вич сатып беткәннәр. Урыс килеп җыйып йөрөгән. Хаситә дигән әйбер була иде күкрәккә тағалар хатыннар. Алтын, көмеш монетлар, бақыр. Монда Стәрлебаш бик қаты қырылды қырық өчөнче йылны. Кибет йағында, йуғары очта осталар, пич чығаручылар, мастерлар ийе. Мин үскәндә алтаужидәү бар ийе пич чығаручылар. Йарты аwыл пич чығарадырыйы. Йарты аwыл таш қойма қуйадырыйы. Мин үскәндә йуғары очноң бөтөн қоймалары таш ыйы.

*Стәрлебаш авылында*
*Зәйнуллин Зәки Лотфулла улыннан (1933 елгы)*
*язып алынды*

Қазан йақларыннан Оренбург Қарғалысына, аннан монда килгәннәр. Айдарғали исеменнән аwылның исеме. Аwыл башында Айдарғали бабайның зираты бар. Айғыр таwы – айғыр

таwыннан айғыр қолап (*егылып*) китеп үлгән. Шуңа күрә шулай атала. Ул тау нық текәл (*текә*). Колхозыбыз «Ключевые горы» дип атала иде. Шишмәләр бик күп булғанға.

*Айдарәле авылында*
*Хәкимов Юсуп Миңнегали улыннан (1932 елгы)*
*һәм Хәкимова Саира Саягфәр кызыннан (1935 елгы)*
*язып алынды*

Безнең чығыш – Қазан йақлары татарлары. Алты қойо аwыл эчендә йаңарттық. Қойоларны қазып төшкәннәр. Безнең йандағы қойоға йөз йылдан артық. Бағаутдиновлар һөнәрле булған, Ақсаттаровлар уқымышлырақ кешеләр булған. Ә Бағаутдиновларда һөнәрчелек зур булған аларда. Күп семйалар шушылар.

Қартәниләр сөйли: бу тауларда вич урман булған. Қара урман иде, ди.

Элек таш күперләр булған. Күбрәк бездә таш белә (*белән*) эшләгәннәр. Таш чыққан монда. Урман йырақ. Шуның өчөн таш чыққан. Бездә әле дә ташлар чыға. Ташлардан эшләгәннәр. Сарайлар да. Зират ихаталары вич таштан ийе. Мона монанда (*менә монда*) утыра иде таш өй. Қалынрағы чыға, төрлө формада чыға таш. Үзәк магазин вич таштан.

*Бакый авылында*
*Вәлишин Фәнүр Әмин улыннан (1965 елгы)*
*язып алынды*

Стәрлебаш мин. Район үзәгендә тудым. Унынчы классны беткәч (*бетергәч*), ике бухалтерийәдә уқыдым. Уфада. Кирәк икән – мин экономист, кирәк икән – уқытучы. Әтийебез мәдрәсәдә (Стәрлебаштагы) студентларның тәрбийәчесе булып эшләде. Мине йетәкләп апарадырыйы мәдрәсәгә. Бақыйға 53 нче йылны күчеп килдек.

Стәрлебашның мәдрәсәләре Российаның беренче урынын алып торған. Аны икенче Бохара дип йөрөткәннәр. Мөхәмәтшакир Туқайыв ике тапқыр дума члены булған. Стәрлебашта йәшәсә дә, Ленинградта да йорты булған. Безнең өйгә 30 гына метр ийе аларның өйләре. Минем әни аларға чигү чигәргә барадырыйы. Мине ийәртеп апарды. Бақчасы зур ыйы. Бассейны бар ыйы уртасында. Қарағай өй.

Безнең картәти укытучы булган мәдрәсәдә. Оренбург Карғалысында уқыған да направление белән Стәрлебашқа йебәргәннәр. Стәрлебашта математика белән географийадан уқытқан. Безнең Галиақберов фамлилийалары Стәрлебашта бар да уқымышлылар. Қартәтинең қәбер ташы әле Стәрлебашта сақлана. Қартәтинең (Биктимир Галиакберов) мәдрәсә йанында шәкертләргә сухана йасағаннар. Бәләкәй бидыра белән суға барадырыйық тегенәргә.

*Бакый авылында*
*Вилданова Ямал Газиз кызыннан (1921 елгы,*
*тумышы белән Стәрлебаш авылыннан) язып алынды*

Безнең аwылға Қарғалы йағыннан килеп утырғаннар.Тәтер йылғасы буйына. Тәтер-Арслан дип атағаннар. Әтием төп Арсланныққы. Әтийем хәлле кеше булған суғышқа хадәрле. 37 нче йылны колхозға керми торған өчөн (азақтан кергән ул), бөтөн безнең әйберләрне, игеннәрне – вич апчығып киткәннәр. Қулақ, хәлле кеше дип. Әти умарта тотқан булған. Перм'дә умартачылыққа уқып қайтқан булған. Сигез-туғыз йан булғанбыз. Келәтләрне бикләп, игеннәрне вич апчықтылар дип, әни жылый торғаныйы. пимаға (*киез итек*) хәтле алдылар дип. Эшләгән кешене элек күрәлмәгәннәр. Трудармийәдә әти үлеп қалды.

*Тәтер-Арслан авылында*
*Рысаева Зәйнәп Миңнегали кызыннан (1938 елгы)*
*язып алынды*

Мин бәләкәй wахыттан шушы аwылда Сәләхетдин бабай имам була, аңардан қала Хәйрулла бабай, аңардан тыш Әхмәтхәләф бабай, аңардан тыш Рәфкетдин бабай, аңардан тыш 1930 йылғы Миннибай бабай була. Хәзер дә мәчетләргә йөрибез, биш wақыт намаздан қалмыйбыз.

Аwылыбызның Ғайфуллин Зәйнулла бабай суғыштан сыңар қуллы булып қайтқан. Шушы бабайыбыз шушы мәчетне қараған йегерме биш йыл. Сыңар қул белә утын кисеп, мәчетне йылытып, биш кир азан әйткән. Мәчетнең манарасын кисәргә килгәчтен, шушы бабай кистермәгән. Бабайны бик нық усаллашып кисәргә көчләгәннәр. «Мине атыгыз, мин манара кисмим!» – дигән.

Кисүчеләр киткәннәр, бабай икенче көннө бөтөн документларын алған мәчетнең. Уфаға киткән. Уфадан мәчетне кисмәскә, мәчетне йапмасқа рөхсәт қыйағазы (*кәгазе*) апқайтып, шушы тәртиптә алып қалған. Йегерем биш йыл буйына мәчетне сақлап тәрбияләп алып қалған бабай. Ә намаз уқучылар өйдә қачып уқығаннар. Динне ташламаганнар безнең Йашырған аwылы. Урманнарда да қачып уқығаннар. Тәрәwих намазларын өйләрдә қачып уқыйларыйы. Бәләкәй wахытта, тәрәз төбөнә барып, тыштан тыңнап тора торғаныйық.

*Яшерган авылында*
*Галләмова Фәния Абдулла кызыннан (1936 елгы)*
*һәм Гобәйдуллина Флюрәдән (1944 елгы) язып алынды*

Бу аwылға Йаңғырчы дигән бабай килеп утырған. Қазақ бабайы булған ул. Элек монда күл, сазлық, урман булған бу җирләрдә. Шушы күл су астына киткән. Шуннан аннары сон, тау башында өй утыра бит, ана шунда төзөлгән булған. Су киткәннән соң, шушында урнаша башлағаннар.

Кич утырып шәл бәйлидерийек. Бер көндә бер шәл бетәдерейе. Дүрт қыз чит бәйлидерийе. Ике қыз урта бәйлидерийе. Әбит (<рус. *обед*) wақытында кереп утырадырыйық, таң атқачтын, кайтып китәдерейек. Аны сатадырыйық.

Суғыш йылында йазарға дәфтәр йуқ, уқырға ни йуқ. Үләнгә қуйадырыйық та алифбаны өйрәнәдерейек. Унөч кеше безнең очта. Бер қыйтап (*китап*) бирәләр безнең очқа (авылның), бер кыйтап бирәләр теге очқа. Уртаға тағы бер қыйтап бирәләр. Менә шулайттереп аwыл зур. Унөчәр бала йатып җир өстөндә хәреф өйрәнәдерейек. Туфраққа тайақ белән йазып. Беребез йазадырыйы, башқаларыбыз тыңлап утырадырыйық.

Қараға (рус. *чернила*) – имәннең йафрағы астында йәбешкән алмасы була (ул барысында да булмый), шуны алып, шуңа тутыққан қадақ саладырыйық (ржавчина, ржа получайытса иде) та шуннан ул бәскә (рус. *коричневый*) әйләнәдерейе. Шунарға манып йазадырыйық. Ул бетми. Имән қайырысын қайнатсан да әйбердән бетми бит. Шулай да йазасы булған инде. Қоромнан да йасыйдырыйық қараны. Қоромға әз генә май саладырыйық

та шуның белән. Қазан төбөнә йәбешәдерейе қором. Шуны аладырыйык та, шуның белән йазадырыйык.

*Яңгырчы авылында*
*Кәримова Кәримә Лотфрахман кызыннан (1938 елгы)*
*язып алынды*

**Мәзәк.** Бер бабай урманға барған. Утын төйәргә. Элек бит қоро ботақны да сындыртмыйларыйы. Бер нәрсәкәй дә алдыртмайлар. Балтасы да булған. Қоро ботақлар төйәгән. Төйәгән ботақларны Стәрлебаштан лесник килгән дә колхоз йортона бушаттырған. «Фамилийаңны әйт!» – дигән. Теге: «Кылғанов», – дигән. «Исемең?». «Шылған», дип йаwаплаған. «Шылған, иртәгә килерсең, ыштраф салабыз, балтаңны шуннан алырсың», – дигән. Шуннан чақырталар икән Қылғанов Шылғанны. Ә андый йуқ. Қылған бит шуып тора. Элеккеләр шулай шәп булған инде.

*Яңгырчы авылында*
*Кәримова Кәримә Лотфрахман кызыннан (1938 елгы)*
*язып алынды*

**Сагыз кайнату**. Йаз көннө (*язын*) қайын тузын қуптарып алалмыйбыз. Көз көнне (*көзен*) генә алалар икән қайын тузын. Аwылдағы бер хатын қайын тузын алып, әйбәтләп чистартып, wақ қына итеп бүлгәләп чыға, май салып қайната. Қара сағыз килеп чыға. Ул аны сата сабантуйларында.

*Яшерган авылында*
*Галләмова Фәния Абдулла кызыннан (1936 елгы)*
*язып алынды*

Чөгөндерне, бишәр гектарны, утап, тәпеп үстерделәр. Һәркемгә пай бүлеп бирелә. Машинаға төйәп озатасың. Писүк итеп бирәләр.

Печән эшләгәндә. Кечкенәсе шәбен дип атала. Шәбенне бишалтысын бергә өйөп чүмәлә дип атала. Шуннан ары соң чүмәләдән соң кәбән (бәләкәйрәге), эскерт (зуррак). Күбә шул чүмәлә дигән сүз инде. Элек без бәләкәй чақта көлтә итеп бәйлиләр ийе ашлықны. Ат белән чабалар. Көлтә-көлтә итеп кенә төшөрә. Шуны қатыннар бәйлиләр. Бәйләгәчтен (*бәйләгәч*) аны эскерткә

ташыйлар. Көлтәләрне қырларға өйөп қуйалар. Көлтәне ат чаба лабагрейка беләнме. Қатыннар бәйли. Бәйләгәчтен көлтәгә салалар. Утыртып қуйалар да. Кибә инде. Кипкәч, шуннан көлтә зур гына була инде ансы, өйөп қуйасың. Башларын эчкә салып. Башақларын. Шуннан ат белән ташыйлар кәбәнгә (*кибәнгә*). Кәбәннән молот'ба дигән нәрсә белән ашлық суқтыралар.

Элек чыбағач булған. Чыбағач белән суққаннар. Бер тайақ, сәнәк сабы кебек ул. Шуның башында монауың кебек тағын бер тайақ. Шуны бау белән, қайыш белән йалғаған. Буwыннанып әйләнеп тора. Шуның белән суғалар теге көлтәне. Ашлығы төшә, қойола. Шуннан сәнәк белән қағып алып, саламын алалар, ашлығын үзенә алалар. Аны көрәк белән җилгәрәләр. Чөйөп җибәрә көрәк белән. Элек шулайы без белгәндә.

*Бакый авылында*
*Байтимеров Рәфкать Гафият улыннан (1928 елгы)*
*язып алынды*

Киндерне бақчаға чәчәдерейек тә, үсүwе җиткәчтен, йолқоп бәйлибез. Аннан әни белән бәләкәй арбаға өстөрәп алып китәбез күлгә батырыға (*батырырга*). Ақмый торған күлгә. Ташлар белән бастырып қуйасың. Шуннан бер билдәле (*билгеле*) wақыт тырғачтын, ай торғандырмы, барып судан чығарып, бераз җилләгәнен көтөп торасың.

Талқы. Айақлы итеп эшләнә дә ике тотқа арасына қыстырыла итеп йасалған. Талқыйсың. Җон кебек җебе кала. Қабасы була, рачуска сыман. Қабада тарап, суwырып-суwырып эрли. Киндер суғадырыйы әни. Күлмәк-ыштан тегәдерейе.

*Тәтер-Арслан авылында*
*Шәрипова Разия Шаһвәли кызыннан (1937 елгы)*
*язып алынды*

Йылға буйы. Қурыс батырғаннар. Йүкә қайырысын батырғаннар. Мунчала йасағаннар. Ат өстөнә йабырға шыпта (*чыпта*, рус. *рогожа*) да эшләгәннәр. Шул урам Мунчала урамы дип аталган.

Шәл безнең йәшәү чығанағы булды. Эзмәкәй (< рус. *змейка*) бу шәл. Мамық өмәсе. Йахшы печән ашатқан, йылырақ абзар-

ларда тотқан кәҗәләрдән эшлибез. Феврал' айында мамық йылқылдап тора кәҗәләр өстөндә. Шуны тарыйлар. Тараганны тиз генә айалыйлар. Шапалауға хәтле айасы бар. Минем шапа бар иде. Айа йуқ. Миңнеғали шапа, айаларны эшләп сата иде.

*Карагыш авылында*
*Әхмәтова Нәсимә Абдрахман кызыннан(1946 елгы,*
*тумышы белән Айдарәле авылыннан) язып алынды*

**Йорт салу.** Бүген монанда (*менә монда*) өй йасыйлар икән, тәүдә нигез салалар оло абзыйлар. Шунда күрше тирә-йағы ботқа кертә, йәрдәм итеп. Бер күршесе кертә, ике-өч сәғәт' үтә икенче күршесе кертә. Шунда бала-чаға да җийылабыз. Үзеңнең тарелқақашығыңны аласың да йөгөрәсең. Алар безгә дә салып бирә инде шуны. Ботка дөгөдән дә. Абзыйларның җыйнаулашып эшләшү – ул йәрдәм, икенче йақтан йола.

Матчаға бура менә дә, болай йырыла матча қуйырға, монанда ақча салалар да матчаны қаплыйлар. Тимер ақча салалар.

Саман өйләрдә дә йәшәделәр. Балчық тутырасың да шуны киптерәсең. Салам қушасың. Шуны киптереп өй саласың. Элек ағачны алуwы бик қыйын булған.

*Бакый авылында*
*Вәлишин Фәнүр Әмин улыннан (1965 елгы)*
*һәм Байтимеров Рәфкать Гафият улыннан (1928 елгы)*
*язып алынды*

## Кием-салым, бизәнү әйберләре

Кәҗә күп иде элек. Ақ кәҗәләр – сөт кәҗәләре, мамығы йуқ, сөтө әйбәт диләр. Мамық кәҗәләр – йоно әйбәт. Қартәни нық булған: кәҗә йононнан бәйли, аны сата иде; умбиш киламитыр җийәү бара, онмы нәрсә күтәреп қайта. Иртән, қараңғыдан тороп, Йомағужа (*башкорт авылы*) аwылыннан йүкә апқайталар. Шуңардан чабата йасый. Чабаталарны Қарамал базарыннан итеп сата.

Бәләкәйдән челтәр бәйләп, нагыш эшләп. Чигү инде ул нағыш. Нағыш эшләү дип сөйлиләр.

Элек туйда қулйаулық бирәбез, бирнә дибез, қыз бирә. Тагы шуннан сөлгө башына и мендәр башына – простой товарның ике

башын эшлисең дә челтәр бәйләп чығасың. Мин аны күп кешегә бәйләдем. Шуны кидерәсең дә мендәрнең башына қызылны қуйасың. Шунан ақны кидерәсең, челтәрлене. Қызларның мендәре була инде. Қызның бүләге бирнә булып бара инде.

Чаршау сәкегә қордоқ, берсе караwатқа. Чыбылдық караwатқа. Тимер караwатның ике йағына қуйасың. Башына тағы қорасың.

Қартәниләрнең көмөш беләзеге бар ийе. Зур алқасы да.

Киндердән эшләгән әнинең ашйаулықлары, сөлгөләре бар иде. Күпертеп-күпертеп эшләнгән. Ике намазлық.

Өскә көртә (*сырган, җиңсез камзул*) кийәбез. Куфайкы да кийәбез. Айақта пима (*киез итек*). Пимаға эрзинкә кидерәсең дә сүсинкә була.

Уқырға барғанда кидек чабата. Чабатаны йасап бирә дә әни. Күтәртмә дидек – ике урнына ағачтан йасап бәйли. Шул күтәртмә белән йөрөйсең. Тақта қуйыла, этү (*алайса*) бит йаз көнө (*язын*) йөрөп булмый, су керә.

*Куганакбаш авылында*
*Галиева Масуфа Сиразетдин кызыннан (1939 елгы)*
*һәм Яхина Хәкимә Тимерхан кызыннан (1961 елгы)*
*язып алынды*

Без бит биш-алты йәштән шәл бәйләдек. Әнийебезләр Шарлық районына икмәк өчөн китәләр ийе. Безгә аулақ өй қала. Суқыр лампа. Үзебез йырлашабыз. Мансур абзый бар иде. Апалар чәй қуйалар. Мансур абый һәрwақыт Бисмилла әйтеп, ашйаулықларны җийнашып (*җыйнап*), саwыт-сабаны, күмәчне ашйаулыққа төрөп алып қуйа торған ийе. Апалар аwызға керосин қабып, эти-әниләрдән йәшереп, аулақ өйдәге лампаға аппарып салабыз дип сөйләде.

Күрше қыз белән сәғәт уникегә хәтлем өйдәге шәлне бәйлибез. Уникедән соң өчкә хәтлем пич башына менеп утырып, суқыр лампада, әниләр уйанмасын дип, әниләргә күрсәтмичә, шәл читен бәйләп, аны сатып, ақча алабыз да йә күлмәк, йә бер нәрсә сатып алабыз.

Элек стеналарга элмә (*стена өчен келәм сыман*) элү барийе. Шуларға минем әнийем чигә торған ийе. Орчоқ, тәрәзә қапқачы

йасаучылар бар. Сарық тиресеннән туннар тегүче Мәксүм бабай бар иде. Пима басучы Гафи бабай ийе. Пич чығаручылар, балта осталары Ғалл'амовлар бар ийе. Ихата осталары бар. Мәсәлән, Азаматов Таһир.

*Ашерган авылында*
*Галләмова Фәния Абдулла кызыннан (1936 елгы)*
*һәм Гобәйдуллина Флюрәдән (1944 елгы)*
*язып алынды*

Палас суғалар ийе. Мин әле бәләкәй wақытта, кич утырғанда, иске чүпрәкләрне қартәни мәрхүмә йырттырайы. Уннан палас суға. Үткәрә дә чық итеп қыса. Төрлө төстә. Без йыртып утырабыз чүпрәкләрне. Йомғаққа чорныйбыз да. Шулардан палас суға. Анарда барийе.

Хозяйство көчлө булғач, һөнәрчелек кәмегән (*кимегән*). Башқа аwыллар белән чағыштырғанда бездә һөнәрчелек әзерәк. Пима басу. Киләләр иде Ул'йановскидан, бер иске өйнө алар снимат' итә дә пима басалар. Читтән киләләр. Шунда халық йөн ыздават' итәләр ийе. Заказга. Басып бирәләр. Ашарға итәсең (*илтәсең*) аларга.

Хәзер кәҗәләр дә әз қалды, сарықлар да. Тапочка кебеге башантай диләр. Озоны – йон ойоқ. Элек кәҗә күп тоттолар. Шәл белән монда шөғыллләнделәр. Әниләр ындыр табағында көндөз эшлиләр, кичен шәл бәйлиләр. Былтыр шәл бәйләме бәйрәме үткәрделәр. Һәрбер аwылда. Аннан районда үткәрделәр. Халық бәйли.

*Бакый авылында*
*Вәлишин Фәнүр Әмин улыннан (1965 елгы)*
*язып алынды*

Ачлық йылында үлгән кешеләрне чыптаға төрөп күмгәннәр. Күп булғач үлүчеләр. Чыпта – йүкәдән шақмақлы итеп суққан зур итеп. Асқа җәйеп утырырға да, йабынып йатырға да йарый ул. Атлар өстөнә йабалар иде без үскәндә аны. Ат тирләп қайтса, шул чыптаны йабып қуйалар.

Чабата кийеп үстек. Киндер ыштаннарны абыйлар кийә торған иде. Без ул хәтле кимәдек. 31–33 нче йылғы абыйларым. Көртә, куфайкалар кидек. Башантай дип әйтәйек. Наски русча бит. Монда хадәрен җон ойоқ диләр ийе.

Сигез йәштән шәл чите бәйли идек сигез-ун сумға. Безнең йақта нағышны (<*нәкеш, чигү чигеп*) бик эшләмәделәр. Кәҗә асырадық бит. Шәл бәйләдек, шәл бәйләдек. Нағышларны үзебез өчөн, алйапкычлар чигә торғаныйык. Мендәр тышлары, сөлгө башлары чигәдерейек, караwат читләренә. Тормошқа чыққанда, шуларны сандық тутырып вич апкиләийек инде.

Дүрт читкә дүрт кеше, уртаға ике кеше. Шул бер суткада бер шәлне өлгертәйек. Йөрөп өй сайын. Қулалмаш дип атала инде ул.

Минем әнинең мәржен белән чиккән қалфағы бар ийе. Минем әниләр хәлле бай йәшәгәннәр бит.

*Тәтер-Арслан авылында*
*Рысаева Зәйнәп Миңнегали кызыннан (1938 елгы)*
*язып алынды*

Чабата йасап кидек. Кичке уйынға йаңарағын кийеп чығабыз. Искерәген – эшкә. Урманнан йүкә ағачы алып қайтып, шуның қабығын қутарасың (*куптарасың*). Төзләрен, йәшләрен алып. Аның қайырысын шудырасың. Аннан йүкәсе белән чабата йасыйсың инде.

Киндер суғалар ийе элек. Күлмәк-ыштан киндердән. Киндерне чәчеп үстек. Нәстә инде. Озон итәкле күлмәк йәш чақта.

*Бакый авылында*
*Байтимеров Рәфкать Гафият улыннан (1928 елгы)*
*язып алынды*

Күксағызны үстердек. Резинка, галош, машинаға тәгәрмәчләр эшлиләр анардан. Эрзинкә фурмалы була. Чәчкәсе ак аның. Чәчкәләрне җыйып қапчықлап, китереп сдават' итәбез бер стақан онға. Онно ашқа буталап эчә идек.

Қартәтийем чабата күп эшләгән. Эстәрлетамакқа апарып сатқан. Әмирдә (*авыл исеме*) су алама. Бәләкәй генә йылға. Йүкәләрне шунда батырып. Чабатаны Оренбургқа да сатқан. Қара урманнардан ат белән Оренбургқа йөрөгәннәр. Җиләк, қарлыған җийып сатқаннар шунда әбиләр.

*Стәрлебаш авылында*
*Гыйлманова Сәлимә Басыйр кызыннан (1937 елгы)*
*һәм Гыйбадуллина Зөлфирә Баян кызыннан (1950 елгы)*
*язып алынды*

## Аш-сулар

**Баwырсак** пешерергә йаратадырыййым. Таwық күкәйенә басып. Озақ қына итеп басып пешерәсең. Урап-урап инде. Пичақ белән кисеп, ғомбағыш майына салып қайнатып пешерегә (*пешерергә*) бит ине (*инде*). Қайнап торған майға салсаң да йарамый. Әзерәк бер стакан су салырға кирәк қайнап торған майға. Туйларға булса, зур саwытларға эшлисен. Баллап, тәмләп өстөнә витаминнар, кәнфитләр сибеп. Матурлап аппарасың.

Ләwәшләр дә саласың. Төчө қамырдан. Эченә салып, қамыр белән йабасың да, шул ләwәш дип атала. Қош теле дә пешерәбез.

*Яңгырчы авылында*
*Хисамова Зөбәрҗәт Сахау кызыннан (1938 елгы)*
*язып алынды*

**Қазылық.** Суйғаннан соң атның қабырғалыкны айырып алалар. Эч майы белә бергә қушып тозлап. Матур итеп ит озонча киселә дә, нығ итеп тозо чыққанчы шығырдатып ботап қуйабыз бер өч сәғәткә. Кем сарымсақ йарата – бер өлөшенә сарымсақ белә, бер өлөшенә сарымсақсыз. Эчәкне йуwып аны өрәбез. Эчәкне тутырыр алдыннан бик йахшылап өрөгә кирәк – алама җире йуқ микән.

*Яшерган авылында*
*Галимова Ләйсән Әхәт кызыннан (1976 елгы)*
*язып алынды*

**Кабартма, пәрәмәч, күмәч**. Арыш ононнан қабартма пешерә идек. Әпәй қамырын җәйәдерийек тә пешерә идек. Мичтә. Пәрәмәч қуйадырыййым. Күмәч тә. Салам йақтық. Аннан утын урынына ғомбағыш тайағы йақтық. Салам йағып шуның қызуwында пәрәмәч пешерәдерейек.

**Ләwәш/паштет**. Ләwәш тә бәләкәйрәк паштет дип әйтәдерейек. Әлеге пируг кебек. Қамыр эченә әйбер җәйеп. Элек әчедә түгел, төчөдә пешерәләр ийе. Эченә варенйылар салып. Төчө қамырдан, бездрожжевой камыр. Баланнан да. Шуны бездә паштет дип йөртәләр. Элеккеләр паштет диләр. Башка җирдә пирог диләр. Аны, ашқа барғанда, салып аппара идек.

Туйға барғанда ике каз, ике әпәй, ике паштет, баwырсақ тотоп барасың. Элек дүртәү булған, хәзер икешәргә қалған. Парлы булсын дип, икешәр иткәннәр хәзер.

*Куганакбаш авылында*
*Галиева Масуфа Сиразетдин кызыннан (1939 елгы)*
*һәм Яхина Хәкимә Тимерхан кызыннан (1961 елгы)*
*язып алынды*

**Әтлек.** Җәйгә чықсаң, балтырған, ат қолағы, әтлек, черек бәрәңгеләр. Шуларны ашап... Әтлек – аны тирмәндә тарттырып әпәй итеп пешереп ашыйдырыйиық. Урманда үсә ул. Қызыл чәчкә (*чәчәк*) ата, аның сабағы таплы, қаралы-йәшелле. Шуны чоқоп аладырыйиық та йылғада йуwадырыйиық та шуны киптереп, он тарта торған тартқычтан тартадырыйиық. Йә тирмәнгә барып тартадырыйиық. Шуны әпәй иттереп салып ашыйдырыйиық.

*Яңгырчы авылында*
*Кәримова Кәримә Лотфрахман кызыннан (1938 елгы)*
*язып алынды*

**Кәлҗимә.** Чабата кийеп туңған бәрәңгене җийадырыйиық. Шуны суда йуwып, алып қайдадырыйиық өйгә. Әниләр шунардан кәлҗимә пешерәдерейе. Шуны қорт кеwек әwәләп пешерәләр ийе.

**Бәрәңге буы.** Ачлықта, әче булса да, бәрәңге йафрағын да ашқа турап ашыйдырыйиық. Салқын тисә, қабықлы бәрәңгене пешерәдерейек тә, чүлмәктә шуның буwына утырадырыйиық. Без дару эчмәдек. Қабықлы бәрәңге пешеп чыға, таwықларға пешерәсең бит инде. Шуның суын сарқытасың да башыңнан алата (*алып*) шушылай әйбер йабынасың да чүлмәккә шуның буында утырасың. Салқын тигәннәрне вич бетерә.

*Турмай авылында*
*М(н)оскова Суфыя Миңнеәхмәт кызыннан (1939 елгы)*
*язып алынды*

Туйларны өчәр-бишәр көн йасый идек. Туйға баwырсақ, күмәч, ләwәш, қаз. Арақылар апаралар бит инде соңғы wақытта. Элек арақы апару йуғ иде. Үзебез пешерә идек барысын. Бәлеш сала торғаныйиық күп без. Ит бәлеше. Туйларға да өчәр бәлеш сала торғаныйиық. Бәлеш пешерәдерейек.

**Көлчәне** (рус. *лепешка*) ачлық заманда пешерәйек. Қамыр басасың да пич төбөнә саласың. Көлөн сыпырып, көлчә саласың. Ағач көрәк була торғаныйы. Күмәч сала торған. Кичауғач белән тартабыз, күмерләрне тарта торған белә инде. Таба күмәче дип әйтә идек. Көлчә дип боронғырақлар әйткән җәймәне. Аны әле дә җәйәбез. Йуқа ғына итеп қабарып пешә.

*Тәтер-Арслан авылында*
*Рысаева Зәйнәп Миңнегали кызыннан (1938 елгы)*
*язып алынды*

Сағыз эшләгәннәр туйызны эретеп, ақ май қушып. Файдалы ул, тәмне ул. Қайын ағачыннан. Қайырын суйырып апқайталар да.

Аулақ өйдә җәймә пешереп төчөгә. Пичтә пешерәләр таба тығып. Бәрәңге тәгәрәтәбез. Қыстыбый бәрәңгедән генә, тары йармасыз пешерәбез.

Туйларда баwырсақ, түгәрәк әпәйләр пешерәләр. Ләwәш (*пирог*) җиләктән дә, өстөнә қамырдан чәчкәләр дә йасап. Дөгө бәлешләре дә пешерәләр. Пар қазлар аппаралар.

**Как.** Җиләктән, алмадан, қарлығаннан қақ эшлиләр. Алманы турап, парда ғына пешерәсең дә, сетка белән сөзәсең дә сөзмәсе килеп чыға. Сөзмәгә әз генә писук қушасың. Ғомбағыш майы белән тақтаны майлыйсың, саласың. Қарлыған белән алманы қушсаң була. Чийәнеке, баланнықы дә тәмле була. Қызыл миләштән дә әчкелтемнән. Җилли ул җайлап, күгәртмәскә.

Ревен'нән пироглар пешерәдерейек. Хәзер үстермиләр. Әчмуха чәйе – бер пачка чәй, тақта чәй. Әбиләр «бер әчмуха чәй бирсәләр», дип әйтәләр.

*Стәрлебаш авылында*
*Гыйлманова Сәлимә Басыйр кызыннан (1937 елгы)*
*һәм Гыйбадуллина Зөлфирә Баян кызыннан (1950 елгы)*
*язып алынды*

Ләwәш пешерәләр. Эченә шоморт, балан салып. Күмәчләрне пичкә салып уңдыралар. Пирәмәч (*пәрәмәч*), қыстыбый. Иртүк балалар йоқыдан торуға әнинең өстәлендә өрөлеп пешкән қоймақ. Минем қартәнием бик оста булган аш-суға. Бер кийәwе төчө, икенчесе әче қоймақ йаратқан булған. Минем әнийем килен

булып төшкәчтен, шушы әбийем кийәүләрен атна сайын чәйгә чақыра торған булган хөрмәтләп. Шуннан әнийем бер табада әче қоймақ, бер табада төчөне пешерә торған булған.

*Яшерган авылында*
*Галләмова Фәния Абдулла кызыннан (1936 елгы)*
*һәм Гобәйдуллина Флюрәдән (1944 елгы)*
*язып алынды*

**Үләннәр**

Урманнан мәтрүшкәләр, йүкә чәчкәсе, балтырған, қымызлық, қузғалақ җийабыз. Ирен йарғычы су буйында туғайда үсә, аны моналай көлтә-көлтә җийсақ, шуның суwы беләккә тисә, пешкән кебек күперәдерийе. Қуйан тубығы – монауның озонлық булып үсә дә, аның төбөндә бәрәңгесе була. Сәрәнә бақчада да үсә ул. Сәрәнәне қазып аладырыйық. Ул сарымсақ кебек тырнақлы-тырнақлы. Ул түлке майлы. Әче түгел, төчө генә ул. Ачлықта бәрәңге йафрағын да ашқа турап ашыйдырыйық. Әче булса да. Бакчада қарлыған, шоморт үсә.

Бездә күксағыз үстерәләр ийе. Хәзер үстермиләр аны. 14–15 йәшлек чақта җийдық без аны. Аның чәчкәсе, ул бик җиңгел килә, тач менә шушы одуванчикның чәчкәсенә охшаган инде ул. Ап-ақ. Күксағыз көндөз генә чәчкә ата да, кичкә йомола да қуйа. Без күксағызны чәчкә атқанда ғына җийарға чығадырыйық. Анардан эрзинкә йасағаннар. Айаққа кийә торған. Бөтөн эрзинкәләр дә әwәл күксағыздан. Шул күксағызның чәчкәсен җийабыз да, үлчәп алалар, сдават' итәбез. Безгә бер учтаймы, йөз граммы кәнфит бирә. Одуванчикка охшаған чәчкәсе. Қойолмас борон шуның чәчкәсен җийабыз. Кич көнө йомола, иртәнге йаққа ачыла ул.

*Турмай авылында*
*М(н)оскова Суфыя Миңнеәхмәт кызыннан (1939 елгы)*
*язып алынды*

Қымызлық, урлапа, балтырған, кәз тәпийе (суык тигәндә әйбәт, сары чәчкә ата ул), күке башы (*күкбаш*), қузғалақ җыйадырыйык. Миләш, балан, қарлыған, гөлҗимеш, қарға бороны үсә.

Песи үләненең мәмийен (*мәче борчагы җимешен*) алып ашыйбыз. Қычытқан айақ астында үсә. Алар файдалылар.

Йазға чыққач, балтырған пешерелә. Балтырғанны бақчада үстерәбез. Балтырған ашында ите, қаймағы, йомырқасы да булса, тәмле була.

Қымызлық әчкелт тәмле. Урлапа дибез гөрләпәне (*какыны*). Аны сәрби дип тә әйтәләр қайсы аwылларда.

*Яшерган авылында*
*Мәүликәева Шәмсеруй Сәяхетдин кызыннан (1918 елгы)*
*язып алынды*

Балтырған җийып ашадық. Атна (*гел*) балтырған белән йәшәдек суғыш wақытында. Күтәрәлмәслек хәлдә апқайтасың инде. Күб итеп җийып. Җәй чықса, тамақ туйа. Қышқылыққа запас инде әзерәк. Башақ-мазар җийып. Балтырған, қымызлық, ғырлафа, кәккүк тәпәйе, қаз тәпәйе, кузғалақ үсә.

*Бакый авылында*
*Байтимеров Рәфкать Гафият улыннан (1928 елгы)*
*язып алынды*

Қырлы қурай (*ирен яргыч үлән*) безнең аwылда үсә. Йомро гөпшә (*көпшә*) кебек үсә. Балтырғанның гөпшәсе бармы? Шуның кебек үсә ул. Но қырлы. Гөпшә урыны сырлы-сырлы, балтырған шыма ғына, ә ул қырлы. Қурайны элек шуңардан йасағаннар.

*Айдарәле авылында*
*Сагетдинова Гөлнур Гарифулла кызыннан (1938 елгы)*
*язып алынды*

## Аулак өйләр, уеннар

Аулақ өйдә суқыр тәкә уйныйлар иде күзне бәйләп. Тота берсен берсе.

Уйнағанда тороп қалған кешенең йөзөген, алқасын җийалар. Шуннан сон бер кешене арты белән утырталар. Шунан соң икенче кеше тоже арты белә утыра. Монда қарап утыралар. Бу күтәрә дә бу фантикны «Бу кешегә ни наказ?» дип әйтә. Теге арты белән утырған әйтә инде: «Давай йырласын, бийесен» или қыз булса:

«Берәр йегетне тотсын». Йондоз санарға чығу. Менә йондоз санарға чығаралары́йы.

Аулақ ашы пешерә торғаннарыйы – урынаш. Һәркем үзеннән бернәрсәкәй алып бара инде. Май, бәрәңге. Шуңардан аш әзерлиләр.

Безнең әтиләр қудылы уйнадылар. Сарықларның қысқа сөйәкләреннән қузы уйыны уйныйдырыйық, ди. Аңа бәрәләр. Әтәйләр сөйли иде. Аның эченә тишеп қурғаш қойалар. Аwыр булсын өчөн.

*Кәримов Рифат (гармунчы, Яңгырчы авылыннан)*
*һәм Исмәгыйлев Хисаметдин Шәрәфетдин улыннан (1953 елгы,*
*Турмай авылыннан) язып алынды*

Аулак өйдә йегетләрне өйгә кертмиләр тәүдә (*башта*). Қызы булса, керергә тели йегет. Хәйлә таба керергә. Тәрәзәне ачып қарый. Эчтән кызлар тақмақлый:

Тәрәзәдән қарама,
Бүрек тышың алама.
Бар базарға, ал тегәр җип,
Бүрек тышың йамарға.

Тыштан малайлар әйтә:

Ақ алйапқыч кигәннәр,
Баwын салындырғаннар.
Өзөлеп сөйгәнне белмиләр,
Һаман йалындыралар.

Төртмә йырлар йырладык шулай. Гармонист йегетләрне қызлар итеп кийендереп тә утырталар.

*Бакый авылында*
*Вилданова Ямал Газиз кызыннан (1921 елгы)*
*язып алынды*

Бер кеше қунаққа китә дә аулақ өйгә қызлар килә. Йегетләр килә. Йегетләрне кертмиләр. Ишекне шақыртадып керә инде. Аулаққа барсақ, аулақ аш дийеп. Шунда урнашы пешерәләр. Таwықмы, қазмы – кем нәрсә апкилә шуны. Он күтәреп барабыз. Кем он, кем йарма йә тоз, май алып бара. Шуны пешереп.

Основной боламық пешердек. Суны қайнатабыз, тоз салабыз. Апкилгән май бар. Шуны салабыз да он сибеп кенә боталыйбыз. Арыш ононнан бу. Шул боламық була. Балтырған, қычытқан ашы. Тәрәзәгә йегетләр килә инде. Йөзөк салышлы, арқа суғышлы уйыннар уйныйдырыйық. Бийеw, йырлау.

Қыз wақытта чирталы уйный торғаныйық сикереп-сикереп. Қачышлы уйныйдырыйық. Күз бәйләшле уйныйдырыйық. Қызлар белән җийылып бер йергә, бәйлидерейек, йөн тетәләрийе. Шунда йырлыйдырыйық.

*Сагетдинова Гөлнур Гарифулла кызы (1938 елгы, Айдарәле авылыннан)*
*һәм Ягафарова Рәхилә Низаметдин кызыннан (1936 елгы, Куганакбаш авылыннан) язып алынды*

**Туйлар...**

Ун йыл элек қызларымны кийәүгә бирдем. Йаучыға килгәндә чиккән тастымал, сөлгө бирәләр. Әтисе әтисе қулына тапшыра. Тастымалны тотоп тора, өстөнә теге йақ акча сала. Ақча салғачтын (*салгач*), сөлгө тегеләргә була, ақча безгә. Бу ризалашу була инде.

Ниқахтан соң туйға қәдәр, кийәү булған кеше қыз йанында торорға тийеш. Ике атна.

Қызлар йабу дигән әйбер бар. Келәткә. Ә хәзер өйгә. Айырым өйгә йабасың да алар шунда төн йоқлыйлар. Иртән иртүк торалар да, аларга аwыл балалары бүләк алырға киләләр. Кем килә, кийәү бүләк әзерли. Малайларға пәке, қызларға нәрсә булса да йарый. Иртәнчәк (*иртән*) бирәләр аларға. Иртәнчәк, алар мунчаға киткәнче, бүләккә баралар.

Қодалар қунмадылар. Төннә қыз белән кийәүне йабып қайтып киттеләр. Қыз белән кийәү йоқодан торуға тегеләр кире килеп җиттеләр. Бездә мунчаға аппарғанда, қыш булса – чана белән, җәй булса арба белән аппаралар. Аппарып мунчада кертәләр.

Йоласы шулай: сандықны кийәү китерергә тийеш. Алдан китереп бирә дә, син тутырып итергә (*илтергә*) тийешсең. Элеккечә ашны қодалар бер көн алдан китереп қуйдылар. Ике әпәй, ике пирог, қазны алдан китереп қуйдылар да.

Хәзер мунча йаққан кеше түгел, кем мунча кергән, шул себерке астына ақча калдыра.

Теге йаққа төшкәчтен қыз, килен булып төшкәчтен, безнеңчә су йулына төштөләр. Су йулында без чиккән алйапкычлар әзерләгән ийек. Һәрберсесенә (*һәрберсенә*) минем қызықай чиққән алйапқыч таратты.

*Куганакбаш авылында*
*Яхина Хәкимә Тимерхан кызыннан (1961 елгы)*
*язып алынды*

Хәзер бит ниқахны әллә қайа аппарып уқыталар. Алай йарамый. Ниқахны уқытқанда урам аша чығарға түгел, су аша чығарға түгел. Үскән йортонда ул қыз Қөрән белән чығып китәргә тийеш. Үзенең түр башында уқытырга тийеш.

Туйда мунча йағасын. Килгән кийәү белән қызга бүләк салып чығасың. Ақча инде. Кем йаққан – ул бүләк қалдыра. Қыз белән кийәү барып керәләр. Шуннан қодалар керә мунчаны.

Қыз йегетенә кийәүгә чыгарга риза булмыйча йөрөсә, урлап апқайта инде. Атқа салып. Аннан соң башқодаға килгәннәр. Балағын салындырып. Туйда мылтық атулар да була. Берничә көн барған туй. Өйнөң мөйөшен төйәләр, қодалар қайтып китмәсә.

*Куганакбаш авылында*
*Ягафарова Рәхилә Низаметдин кызыннан (1936 елгы)*
*язып алынды*

Медсестра булып эшләдем. Йөрөдек тә урландым. Атқа салып алып китте. Сайлау көнө иде. Риза булып қалдым. Шул көнне үк ниқах уқытқаннарийы. Туйлар алтышар көн. Буран ыйы. Қайталмый интегеп. Бирнә әзерләнде. Алты пар киләләр. Алтысына да бирнә биреләдерейе. Ә үзебезгә қызға йастық, мендәр, матрас, йурған, адиал барысы да бар ыйы. Сандыққа салып китерелә. Сөлгө, мендәр тышлары чигәдерейек. Чаршаулар йасыйдырыйық, қороп йатырға.

*Яңгырчы авылында*
*Кәримова Кәримә Лотфрахман кызыннан (1938 елгы)*
*язып алынды*

1932 йылғы апамны торфқа җибәрделәр. Алты ай эшләп қайтты. Муса дигән абзый урлый. Миңкәй апаны қараңғы төшмәс борон барып, әнисе өйдә булмаған, алып чығып киткәннәр. Толопка урап. Йылый апа. Артыннан йөргән йегете килде. Әти тегеләрне қуды да чығарды. «Қызымны алама йегеткә бирмим», дип. Мөлдөрәп йылап қалды инде. Алар бик тату йәшәделәр. Ике көн барып урлый алмағаннар. Теге йегетләре сақлап торған. Аларда аулақ бит инде. Әнкәсе өйдә булмағачтын, қызлар-йегетләр булған. Урлый алмағаннар. Қараңғы төшкәнче, көндөз, күрше йаққа атны қуйғаннар да, тықрықта торалар ийе, сөйрәп апчыққаннар да, чанаға салғаннар да киткәннәр. Урлау бар иде элек.

Чигүле сөлгөне йома көннө бирәләр. Қызны сорап килгәч, аңа бер пар пирчаткы, йаулық қуйалар. Сөлгө күрергә киләләр туғаннар, өйөнә алып қайтып қуйғач. Керәбез, ақча бирәбез. «Сөлгө алып қайтқансыз икән менә. Алдағы тормошлары нықлы булсын», дип. Балдақ, күгәрчен чиккәннәр. Әле дә чигүчеләр бар. Чигүле алйапқыч, мендәр дә чигүле. Сөлгөдән соң туйға хәтле бер атна үтә. Башта қыз йағында, аннан йегет йағында туй булайы. Туйлар элек алтышар көн иде.

Йегет бирнәсе – перчатка, шарф, күлмәк, эчке кийемнән алып бер қат кием. Бирнә. Қыз сандық апкилә. Килен малы. Бу йегеткә бирелә. Ә йегет йағы апкилә қызға шушылай уқ. Палас, суққан ковер. Палас суғу остасы әле дә бар. Сандықны китергәндә сатып алырға тийешләр. Килен әйберләре, тәрәз фәрдәләре, сөлгөләре белән килергә тийеш. Киленгә җиңги тийешле кешеләр аларны эләләр. Алйапқыч тарату бар җиңгиләргә. Килен булып төшкәчтен, су йулына бару. Бау тотоп торғаннарға бутылка ташлыйлар. Килен төшкә қапқа төбөндә торучы ике бала була. Килен бүләге була инде, килен бүләк биргәч, қапқаны ачып керәләр.

Кичтән кийәү белән қызны айырым йортқа йабалар. Иртән кийәү бүләге алырға киләләр: тарақ, пәке. Қыз тарата йезнәгезнең бүләге дип.

Шундый йола да булған. Туйдан соң кийәү белән киленне йорт күрсәтергә чақырғаннар. Кунаққа йөрөткәннәр туғаннары. Йырақтан қунаққа қайтқан туғаннарны шулай итеп ашқа алу

бар ийе. Килен йегет йағына барғанда, йорт күрегә туғаннарына кергәндә, ишеккә сөлгө элү барийе.

*Яшерган авылында*
*Галләмова Фәния Абдулла кызыннан (1936 елгы),*
*Галимова Ләйсән Әхәт кызыннан (1976 елгы)*
*һәм Гобәйдуллина Флюрәдән (1944 елгы)*
*язып алынды*

Әти эшләгән сандықлар бу. Түл, элмәләр монауның буйына, матчалар буйына. Ишеккә шаршаулар, алйапқычлар – шуларны төйәп киләбез. Ирнең кече сеңелләренә бүләк алйапқыч бирәләр.

Сөлгөгә килү ғәдәт. Иң тәү безгә килеп сөлгө алалар да. Йегет йортона йорт күрегә баралар.

Бер ай кийәүләп йөриләр. Бер ай атна сайын йегет аwылларыннан монда қуна килә. Кийәүләү шушы була. Икене қуна. Берне генә қунарға йарамый. Атнасына ике көн қуна. Шунан, бер ай үткәннән соң, қыз килен булып төшә тегендә.

*Айдарәле авылында*
*Сагетдинова Гөлнур Гарифулла кызыннан (1938 елгы)*
*язып алынды*

Элек туй алтышар көн ийе. Бер йақта алты көн, икенче йаққа барып алты көн. Аннан ары соң дүртәр көнгә қалды. Элек сандық салып апкиләләр иде айырым. Қарамаллар, Стәрлебашлар саталар ийе сандықларны. Мендәр тышларына, сөлгөләргә нағыш эшләдек. Сандык белән апардык. Туйда қызыл эремчек йасыйлар ийе. Баwырсақ салалар. Үзем дә пешерә беләдерейем. Әл дә бар ул, пешерәбез. Қоймақ пешергәндә маныйдан. Әче қатыққа ғына бутап вич барысын да саласың. Май саласың, он саласың әзерәк. Ғомбағыш майы салып.

*Турмай авылында*
*Абдуллина Сәбилә Биктимер кызыннан (1937 елгы)*
*язып алынды*

## Ышанулар

Бала җөнлө туса, җилкәдәге чәчеме инде, шул қойолғанчы бала йылый икән дип әйтәләр. Күпмедән соң ул үзе дә қойолып бетә икән. Элек шушылайтеп туса бала, әпей көрәге, қалағы

булған. Шуның белән баланы пичкә тығып алғаннар, ди. Йаққан пичкә. Пичне булғачтын, пумала белән себерәбез, алабыз. Шуннан соң түгәрәк итеп арыш әпәйен әwәләп, пичкә көрәк белән төшөртәбез. Пичнең җиренә, табаға түгел. Шул әпәйне салғачтын, баланы урап төрөп, бите ачықтанмы, көрәк өстөнә қуйып пичкә тығып алдым, диде Миңнегөл. «Ни қурасың?» «Мыҗыққурам», – диләр. Мыҗық – йылақ булған инде.

Бала йыласа. Ишек тотқасын чайқатасын да, шунын белән баланың битен сөртәсең. Тәрәз тирен сөртәләр. Тәрәзә парлана да, ул дымлы была. Шуны сөртәләр.

*Куганакбаш авылында*
*Галиева Масуфа Сиразетдин кызыннан (1939 елгы)*
*һәм Яхина Хәкимә Тимерхан кызыннан (1961 елгы)*
*язып алынды*

Балан ағачыннан беләзек йасыйлар иде. Бала йыласа, күлмәгенә тегеп қуйалар. Баланны алдында үстерегә кирәк. Ағачтағы мәшкәкне төтәслиләр, (йандырам, ыслыйм – йөртеп чығам, төтөне оча), баланың башыннан уратам. Башын, маңғай чикләрен сөртәм, ишек-тәрәзләрне чайқатып сөртөп и бала тынычлана. Кеше сәленә дә төшә, күз тисә. Күз тимәскә «Собханалла машалла», дип әйтергә кирәк. Күз тидерew ғонаһ бит.

*Стәрлебаш авылында*
*Гыйлманова Сәлимә Басыйр кызыннан (1937 елгы),*
*Гыйбадуллина Зөлфирә Баян кызыннан (1950 елгы)*
*язып алынды*

Миңнегөлле Биби Саидә Әмелхәйрәт – мулла қушкан исеме, ә документта Хәйрәт кенә. Балалары үлеп тик торған. Йәтим баланы алып қалғач, туған балалары үлеп торудан туқтый. Бишенче балаға шул озон исемне қушалар. Шуннан үлми башлыйлар.

Бала йылый дип исем алыштыру булған бездә. Исемен йаратмый дип исемен алыштырғаннар. Қолағына ғына. Документал' түгел.

*Куганакбаш авылында*
*Галиева Масуфа Сиразетдин кызыннан (1939 елгы)*
*һәм Яхина Хәкимә Тимерхан кызыннан (1961 елгы)*
*язып алынды*

Таң суwына қойаш чыққанчы барыға кирәк. Барғанда да, қайтқанда да уқырға кирәк. Нәстә беләсең – шуны уқыйсың. Суны апқайтасың. Таң суwы бик әйбәт инде ул. Эчергә дә, йуынырға да йарый. Таң суwын қаплап апқайтырға кирәк. Атап апқайтмыйсың. Бөтөн кешегә дә җитә ул. Таң суwын ағымсудан алырга кирәк. Чишмә суwы түгел. Йылга суwы кирәк. Ағып тора бит. Чишмә суwы җийылып тора бит, ақмый. Суны үзебезнең тапқырдан алабыз. Таң суwы файдалы ул.

Қойаш байығач, себерке қузғатырға, себерергә йарамый. Себеркене өскә қаратып қуйарға йарамый. Пычақны өскә қаратырға йарамый, себерке, балта өскә қарап тормасын. Үткер (*үткен*) әйбер өскә карарға тийеш түгел.

Тәрәзәдән чығып йөрөгә йарамый – йәшен ата. Әгәр тәрәзә аша чыққансын, қабат керергә кирәк.

**Яңгыр яумаганда** ат башы салу. Анарға кеше ийәртеп бармыйсын. Үзең генә. Айақ тынған wақытта ғына барырға кирәк. Төннә түwел, көндөз. Су буйына төшәргә кирәк. Тәхәрәт алып, йуwынып, намаз уқып башны салырға кирәк. Ат башын. Суға саласың да бәйләп қуйасың. Белгәнеңне уқыйсың. Тал ботағына бәйләп қуйасың. Аны қузғатып торорға кирәк. Йаңгыр йаудырттырыға сорыйлар, колхоз сорый, килеп әйтә. Рәхмәт инде, әби, дип, арқадан сөйөп китәләр. Ат башын соңоннан өйөңә апқайтып қуйасың. Ағып китсә, йаwа да йаwа. Шул бер ат башы җитә. Йаңғыр туқтасын өчөн, башны аласың. Балық ашамый, сөйәк бит ул.

**Соңгы юлга озаткач...** Мәйетне апчыққач, утырғычны аударалар. Аумыйча қалырға тийеш түгел. Аумыйча қалса, ул мәйет тели. Мәйет чыққан өйнө берүзен қундырмыйсын. Қырығына чақлы. Үзең генә қунмыйсың, йаныңа кеше апкиләсең. Қырығына хәтлек ут сүнергә тийеш түгел. Утны сүндермәгез төннә, өйнө йалғыз қалдырмағыз. Мәйет суwын кеше басмый торған урынға салырға кирәк. Абзар бағанасы була. Баған төбөнә.

Мәйет булған йердә таwыш булырға тийеш түгел. Таwышланмасқа. Аның йаны үзе белән бергә бара. Йанында була. Лә илаһы ил Алланы уқырға кирәк.

*Куганакбаш авылында*
*Ягафарова Рәхилә Низаметдин кызыннан (1936 елгы)*
*язып алынды*

Мунчаны кереп чыққан wақытта «Абыстай белә мулла килә, әйбәт кенә торогыз, әйбәт кенә тотогыз мунчаны, таза булсын» дип әйт, дип өйрәткәнәрийе. Теге җеннәр мунчада пычратмасқа, йәнәсе абыстай белән мулла килгәч, уқымышлы дини кешеләр килгән дип, сүзләр әйтәләр ийе. Мунчадан чығып киткән wақытта.

Безнең аwылда ғәдәт бар. Өйдән чыққанда банкага су қуйу, тоз куйу. Қойаш байыған wақытта йоқларға йарамый. Баланы да йоқлатмағыз дип кенә торалар. Аwыру була дип әйтәләр.

Хайwанны қыйнарға түгел, нық гонаһасы күп.

*Айдарәле авылында*
*Сагетдинова Гөлнур Гарифулла кызыннан (1938 елгы)*
*язып алынды*

Зур йыланны Рәхимйан бабай күргән. Wәли абый мәрхүм күргән. Зур йуwан йылан. Қартинәй күрдем дип сөйлидерийе. Өч литр банкы йуwанлық. Урманда күргән. Ағачқа уралып торадырыйы дип. Сүлиләр ийе. Без урманға барырға шүрлидерейек. Үзебез генә түгел, берничә кеше барадырыйык.

Әгәрби қайынлығы – адаштыра торған урын.

*Турмай авылында*
*Исмәгыйлев Хисаметдин Шәрәфетдин улыннан (1953 елгы)*
*язып алынды*

Шулай итеп, Стәрлебаш районының татар авылларындагы апа-абыйлар, әби-бабайлардан үз җирләренә хас булган йолаларны, гореф-гадәтләрен, авыллар тарихын, яшәешләрен сораштырганда, аларның телләренә, сөйләшләренә дә игътибар ителде. Айдарәле, Бакый, Куганакбаш, Стәрлебаш, Тәтер-Арслан, Турмай, Яңгырчы, Яшерган авылларында көн күрүче татарлар минзәлә сөйләшенең бәләбәй урынчылыгына карый. Белүебезчә, минзәлә сөйләше – татар теленең төп диалектларыннан берсе булып торган урта диалект сөйләше. Урта диалект сөйләшләренең зур күпчелеге (минзәлә сөйләше аеруча) әдәби телгә якын тора. Фонетик, грамматик яктан, һәр төбәккә хас булганча, урнашу территориясенә карап кайбер үзенчәлекләр күзәтелсә дә, алар

телдә зур роль уйнамый. Бу үзенчәлекләрнең берсе – иске татар язма әдәби тел нормаларына туры килгән күренешләрнең саклануы. Мәсәлән, сөйләштә теләк фигыльнең *-ыем (ыйым)* < *-аем (-айым)* / *-әем (-әйем)* (*барыйым* < барайым – әд. барыйм) формасы күзәтелә. Урта диалектның бер күрсәткече булып торган бу *-ай*/*-әй, -аем* формасы татар язма әдәби телендә XIX гасыр ахырына кадәр кулланылган. Бу район татарларында, гомумән, Башкортстанның кайбер башка татар сөйләшләренә хас тагын бер үзенчәлек – *җ* авазы урынына *й* авазын куллану күзәтелә. Тарихка күз салсак, *й*-лаштыру күренеше иске татар теленең китаби тел традициясе итеп каралган, шул ук вакытта көнбатыш (мишәр) диалектының төп үзенчәлекләреннән берсе булып та тора. Мәсәлән, *й*-лаштыру күренеше Авыргазы, Гафури районнарында туып үскән язучыларыбыз Г. Ибраһимов, М. Гафури әсәрләрендә еш очрый (*йир* – җир, *йиденче* – җиденче, *йырлау* – җырлау). XIX гасырда һәм XX гасыр башында язылган әсәрләрдә сүз башы позициясендә *җ*-лаштыру һәм *й*-лаштыру параллель кулланылган. Бу факт әлеге күренешнең ул чорда нормалашып өлгермәгәнлеген раслый.

Гомумән, татар теленең урта диалект минзәлә сөйләше вәкилләре, шулай ук Башкортстанда таралган башка татар сөйләшләренең сузык һәм тартык авазлар системасы, аларның кулланылышындагы үзенчәлекләр, грамматик категорияләрне ясау һ.б. төп закончалыклар, гомуми сүзлек фонды, лексик-семантик системасы татар әдәби теле белән зур уртаклык күрсәтә. Бу уртаклык тарихи фактлар, архив чыганаклары, материаль һәм рухи мәдәният үзенчәлекләре белән дә раслана.

# ТАТАР ТЕЛЕ КӨНБАТЫШ ДИАЛЕКТЫНЫҢ СТӘРЛЕТАМАК СӨЙЛӘШЕ

*Миңнира Булатова*

2017 елгы экспедиция барышында Стәрлебаш районының Әмир, Бакча, Бузат, Гөлем, Карагыш, Көчегән (Өч-Әсән), Хәлекәй авыллары халкы белән дә аралашырга насыйп булды. Бу авыллардагы сөйләш татар теленең көнбатыш диалекты стәрлетамак сөйләшенә карый. Стәрлетамак сөйләше Башкортстанның көньяк-көнбатыш өлешенең башка районнарында да таралган.

Тарихка килгәндә, татар теленең көнбатыш (мишәр) диалекты вәкилләренең иң борынгы яшәгән җире булып Цна һәм Мокша елгалары бассейннары санала. XVI–XIX гасырларда Рус дәүләте тарафыннан аларны бу урыннардан башта көнчыгышка, аннан соң көньяк һәм көньяк-көнчыгыш юнәлешләрендә күчереп утырту барган. Тарихи чыганаклардан күренгәнчә, аларны күчерә башлау, Рус дәүләтенең чикләрен күрше күчмә халыкларның һөҗүменнән саклау өчен, хөкүмәт тарафыннан ныгытмалы саклану сызыклары, яңа крепостьләр төзү белән бәйле. Рус дәүләтенең чикләре киңәя барган саен, әлеге саклану сызыкларының урыннары да күчә барган[1]. Шул вакытларда ук (XVI гасыр), мишәр сөйләшләре инде ике типка – *ч*-лаштыручыларга һәм

[1] Татар халык сөйләшләре: Ике китапта / Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова һ.б. / Казан: Мәгариф, 2008. II китап. Б. 4.

*ц*-лаштыручыларга аерылган булган. Соңга таба төрле тарихи сәбәпләр аркасында, бер-берсенә якын тора торган яңа сөйләшләр барлыкка килә.

Көнбатыш (мишәр) диалектка караучы татарларның Урал тирәсенә күчүе (XVI–XIX гасырлар) 300 ел буена дәвам иткән. Яңа җирләрдә алар җирле халык һәм татар теленең урта диалект вәкилләре белән тыгыз мәдәни-икътисади һәм тел мөнәсәбәтләренә кергәннәр. Бу үзара тәэсир итешү процессында урта диалект төп һәм хәлиткеч рольне уйнаган. Көнбатыш диалект сөйләшләре, әйләнә-тирәдәге сөйләшләрнең йогынтысына дучар булу белән бергә, үзләренең специфик үзенчәлекләрен дә саклап калганнар. Татар теленең урта диалектына һәм көнбатыш диалектка хас үзенчәлекләренең активлык дәрәҗәсе төрле җирдә төрлечә. Бу исә әлеге ике диалект вәкилләренең саны, аларның бирегә күчеп килү, ягъни контактка керү вакыты белән турыдан-туры бәйләнгән.

Мишәрләр Башкортстанның түбәндәге өч өлешендә күпләп яшиләр:

1) төньяк-көнбатышта (Караидел, Мишкә, Балтач районнарында) *ц*-лаштыручы татарлар сөйләше, ягъни татар теленең көнбатыш диалект байкыбаш сөйләше таралган. Бу сөйләш вәкилләренең бабалары патша хөкүмәте тарафыннан, сөйләүләренә караганда, Сембер губернасыннан күчерелгән булган;

2) төньяк-көнчыгыш өлешендәге татарлар: XVIII гасырда байкыбаш сөйләше вәкилләренең бер төркеме көнчыгышка, Караидел аръягына да күчә (Салават, Кыйгы һ.б. районнар) һәм татар теленең урта диалекты златоуст сөйләше формалашуга зур өлеш кертә;

3) көнбатыш диалектка караучы татарларның шактый зур төркеме Башкортстанның көньяк-көнбатыш районнарында яши. Аларның бер өлеше – Уфа шәһәре төзелгәндә китереп утыртылган мишәр морзаларының дәвамчылары. Аларга Уфа тирәсендә, Урта Агыйдел буйларында җирләр бирелгән. Башкортстанның көньяк-көнбатыш районнары территориясендә XVII–XVIII гасырларда Пенза, Сембер, Тамбов губерналарыннан татарлар үзирекле

рәвештә яки хөкүмәт рөхсәте белән дә күчеп утыралар. Алар, авыллар булып, төркем-төркем урнашалар һәм көнбатыш (мишәр) диалектның специфик үзенчәлекләрен төрле дәрәҗәдә, кайбер төбәкләрдә исә шактый нык саклап киләләр, аларның сөйләше шул ук стәрлетамак сөйләшенең икенче бер тибы итеп карала[1].

Башкортстанда көнбатыш диалектның стәрлетамак һәм байкыбаш сөйләшләре өстенлек итә. Әйтеп узуыбызча, стәрлетамак сөйләше – республиканың көньяк-көнбатыш районнарында таралган. Бу сөйләш XX гасырның икенче яртысында Д.Б. Рамазанова тарафыннан татар теленең Урта Идел һәм Урал төбәге сөйләшләренең атласын төзү өчен материал җыю барышында ачыла. Аның үзенчәлекләре «Көньяк-көнбатыш Башкортстандагы татар сөйләшләре формалашу» исемле хезмәтендә[2] тасвирлана.

Д.Б. Рамазанова, көнбатыш (мишәр) диалект үзенчәлекләренең саклаdüыш дәрәҗәсенә карап, стәрлетамак сөйләшен шартлы рәвештә өч типка бүлеп карый[3].

I тип: кайбер авазларны көнбатыш (мишәр) диалектка хас булганча әйтү, ягъни әдәби тирән тел арты [қ], [ғ] авазлары урынына тел арты [к],[г] итеп, *-гынчы/-генче (-ганчы/-гәнче)* һ.б. очраклар күзәтелә, алар татар теленең урта диалектына карый торган авыллар чолганышында аерым урнашканнар яки шул авылларның бер өлешен тәшкил итәләр (мәсәлән, Туймазы районының Мәксет, Имән-Күпер, Кәлшәле авыллары, Ярмәкәй районының Сүлле, Әбделкәрим авыллары һ.б.).

II тип: XVIII–XIX гасырларда күчеп килгән, хәзер берничәшәр авылдан торган утрауларны тәшкил итә торган татар авыллары. Бу төбәкләрдә көнбатыш (мишәр) диалектка хас күренешләр шактый тулы һәм тотрыклылык саклыйлар (мәсәлән, Баулы районының Салих авылы, Әлшәй районының Слак авылы, Стәр-

[1] *Рамазанова Д.Б.* Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии. Казань, 1984. 191 с.

[2] *Рамазанова Д.Б.* Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии. Казань, 1984. С. 113–164.

[3] Шунда ук. Б. 114.

лебаш районының Бузат, Карамалы Бузат, Гали Бузат һ.б. авыллары, Благовар районының Каргалы авылы, Бүздәк районының Бүздәк, Шланлыкүл авыллары, Миякә районының Өршәкбаш-Карамалы авылы һ.б.).

III тип: XVI гасыр азагында йомышлы (служилые) татарлар катламы буларак күчерелгән мишәрләрнең дәвамчылары сөйләше (Чишмә, Авыргазы районнары). Бу тип сөйләш татар әдәби теленә якын, II тип төбәкләре белән чагыштырганда, стабильләшкән булу, бертөслелек белән аерыла.

2010–2012 елларда стәрлетамак сөйләше Башкортстанның көньяк өлешендә яшәүче татарларның тел үзенчәлекләрен ареалогик аспектта өйрәнү барышында, М.Р. Булатова тарафыннан да тикшерелә. Галимәнең татар теленең алты сөйләшендәге (шул исәптән стәрлетамак сөйләшендәге) фонетик, морфологик үзенчәлекләрен тасвирлаган «“Көньяк Башкортстан” ареалы татар сөйләшләрендә морфологик үзенчәлекләр» (2013) исемле китабы басылып чыга.

Стәрлетамак сөйләше көнбатыш (мишәр) диалектка хас күренешләрнең төрле дәрәҗәдә сакланып килүе, минзәлә сөйләше белән уртак үзенчәлекләр табылу һәм татар әдәби теленә якын булу белән характерлана.

Түбәндә стәрлетамак сөйләшенә хас булган фонетик, морфологик, лексик үзенчәлекләр һәм сөйләү үрнәкләре тәкъдим ителә.

## Фонетик үзенчәлекләр

**Сузыклар.** Сузык авазлар составы ягыннан сөйләш әдәби телдән аерылмый. Анда ун сузык аваз бар: *а, ә, ый, и, у, ү, о, ө, ы, е.* Стәрлетамак сөйләшенә хас үзенчәлекләр кайбер сузыкларның әйтелешендәге аерымлыкларга, тәңгәллекләргә һәм позицион үзгәрешләргә кайтып кала.

[а] авазының әйтелеше буенча мондый үзенчәлекләрне күрсәтеп үтәргә кирәк. I тип өчен ачык һәм иренләшкән вариантларның икесен дә куллану характерлы. II тип: [а] авазы көнбатыш (мишәр) диалекттагыча, кайбер авылларда (Бузат, Бүздәк, Хәлекәй, Карагыш һ.б.) көчле иренләшкән [а(о°)] әйтелә. III тип:

нигездә, иренләшкән [а]авазы әйтелә, ягъни [а] авазы әдәби телдәгечә.

[ә] авазын алдарак һәм нечкәртебрәк әйтү, ягъни аның көнбатыш (мишәр) диалектка хас варианты II тип авылларда сакланып килә.

[ү] авазын алгырак рәттә әйтү шулай ук II тип авылларда күзәтелә, Бузат, Көчегән, Каргалы, Бүздәк төбәкләрендә билгеле бер төркем сүзләрдә дифтонгоид [**үᵒ**] авазы кулланыла: *күᵒз* – әд. күз, *үᵒр* – үр, *күᵒпер* – күпер, *күᵒп* – күп (кайбер очракларда *көп*/*күп* вариантлары да әйтелә), *дүᵒрт* – дүрт һ.б.

Стәрлетамак сөйләшендә сузык авазларның түбәндәге тәңгәллекләре күзәтелә.

[ә]~[и]**:** сөйләш таралган территориянең көнбатышында: *бәк*/*бик* – әд. бик, *кәм*/*ким* – ким, *нәк* – ник, *мәләш*/*миләш* – миләш. Ә көнчыгышына таба бу күренеш киңрәк күләмдә күзәтелә: *кәртә* – әд. киртә, *кәбән* – кибән, *кәштә* – киштә. II тип авылларда тагын: *шәкәр*/*шикәр* – шикәр.

[ә]~[и] тәңгәллеге «Көньяк Башкортстан» ареалының башка татар сөйләшләрендә һәм, гомумән, урта диалектның Урал тирәсе сөйләшләрендә һәм шулай ук көнчыгыш (себер татарлары) һәм көнбатыш (мишәр) диалектларының башка сөйләшләрендә дә күзәтелә[1].

II тип авылларда рус алынмаларында да басымлы иҗек алдындагы [э(е)] (диал. [и]) урынына [ә] әйтелә: *ебрәй* – еврей, *Гәрмән* – диал. *Гирман* – Германия, *эстәна* – диал. *эстина* – стена, *бәдовый* – рус. бедовый һ.б.

[ү]~[и]: *күгәwен* (сөйләш таралган территориянең көнчыгышына таба *кәгәwен*) – әд. кигәвен сүзендә күзәтелә: көнбатыш (мишәр) диалектта – аеруча темников, сергач, кузнецк сөйләшләрендә бу күренеш күбрәк мисалларда чагыла; шулай ук

---

[1] *Булатова М.Р.* Морфологические особенности татарских говоров ареала «Юг Башкортостана». Казань: ИЯЛИ, 2013. 240 с.

бу вариант татар теле урта диалектының кормантау[1] сөйләшенә дә хас.

[и]~[ә]: *җийәү* – әд. җәйәү (җәяү), *әлбиттә* – әлбәттә, *җилбизәк* – җилбәзәк.

[э(е)]~[и] күренеше: *чеңгерткә* – әд. чикерткә, *энеч* – инеч. Бу күренеш [*җ*] авазына башланган бер төркем сүзләрдә дә күзәтелә: *йер* – әд. җир, *йетмеш* – җитмеш, *йеде* – җиде, *йемеш* / *җимеш* – җимеш, *җиңи* / *йеңгә* – җиңги, *йемерү* – җимерү һ.б.

Күрше минзәлә һәм, гомумән, Урал тирәсе сөйләшләрендәге кебек үк, билгеле бер төркем сүзләрдә һәм шулай ук [ч] авазы янәшәсендә дә [и]~[э(е)] тәңгәллеге күзәтелә: *җип* – әд. җеп, *Сибер* / *Себер* – Себер, *тиге* / *теге* – теге, *йигерме* / *йегерме* – йегерме, *печән*/*пичән* – печән, *кичерткән* / *кечерткән* – кычыткан, *чирегән* – чергән һ.б.

[у/ү]~[о/ө]. Билгеле бер төркем сүзләрдә әдәби телдәге [у] авазына [о] сузыгы тәңгәл килә: *корчак* – әд. курчак, *осак* – усак, *орлау* – урлау, *олым* / *ылым* – улым. Бу сүзләр көнбатыш (мишәр) диалектның башка сөйләшләрендә шулай ук әйтелә. Болардан тыш, сөйләштә минзәлә һәм Урал тирәсе сөйләшләре белән уртак мисалларда да [о]~[у] тәңгәллеге күзәтелә: *молла* – әд. мулла, *йобану* – йуwану (юану), *сом* – сум, *йока* / *җока* – йука (юка).

[ө]~[ү]: *бөгөн* – әд. бүген, *төгөл* – түгел, *мөк* – мүк (мишәр диалектындагыча); *төбән* – түбән, *бөкән* – бүкән (ягъни күрше минзәлә сөйләшендәге кебек).

[у]~[о]: *укшау* – әд. охшау, *умер* / *гумер* – гомер (мишәр диалектындагы башка сөйләшләрдә дә шулай ук).

Бер төркем сүзләрдә әдәби телдәге [у] сузыгына [ы] авазы тәңгәлләшә: *была* / *була* – әд. була, *мынча* – мунча, *сырыгу* – сурыгу, *шынсы* / *шунысы* – шунысы, *намыс* – намус. Бу күренешләр күрше минзәлә сөйләшенә һәм Урал төбәгендәге башка татар сөйләшләренә хас.

Күрше минзәлә сөйләшендәге кебек үк, тел уртасы [й] авазы алдында килгән [у] авазына [ы] яки [и] тәңгәл килә: *бийак* – әд.

[1] *Булатова М.Р.* Курмантауский говор среднего диалекта татарского языка в этнолингвистическом аспекте. Казань: Магариф – Вакыт, 2016. 384 с.

бу йак (як), *бийына* – буйына (буена), *тийына* / *туйына* – туйына (туена), *Тиймазы* – Туймазы.

Билгеле бер төркем сүзләрдә әдәби телдәге киң әйтелешле [а] авазына стәрлетамак сөйләшендә, көнбатыш диалектның башка сөйләшләрендәге кебек үк, тар әйтелешле [ы] сузыгы тәңгәл килә: *кагыз* – кәгазь, *йаңы* – йаңа (яңа) (чагышт.: борынгы төрки язма истәлекләрдә дә *йаңы*).

Стәрлетамак сөйләшендә кайбер сүзләрдә әдәби телдәге [ә] авазына аның тар варианты [э*(е)*] туры килә: *мәктеп* – әд. мәктәп, *мәрҗен* – мәрҗән (чагышт.: мишәр диал. – шулай ук).

Төрле фигыль кушымчаларында [ы]~[а], [ә]~[э(е)] тәңгәллеге дә күзәтелә: *укыгынчы* – әд. укыганчы, *кайткынчы* – кайтканчы, *баргынчы* – барганчы, *сүләгенче* – сөйләгәнче, *эшләгенче* – эшләгәнче, *белгенче* – белгәнче һ.б.; *түгергә* – әд. түгәргә, *кушырга* / *кушарга* – кушарга, *сатырга* – сатарга; *элер* / *эләр* – эләр, *өзәрбез* / *өзәрбез* – өзәрбез һ.б.

Стәрлетамак сөйләшендә [ы], [е] һәм [о], [ө] сузыкларының үзара тәңгәллеге турында түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин.

Билгеле булганча, көнбатыш (мишәр) диалектка, нигездә, иренсезләштерү, ягъни [о], [ө] авазларына [ы], [е] сузыклары тәңгәл килү хас. Стәрлетамак сөйләшендә исә бу күренеш зур үзгәреш кичергән. Әлеге үзенчәлек II тип авылларда бераз саклана, әмма анда да беренче иҗектәге [о], [ө] сузыклары иренләшү төсмере белән әйтелә: *те*$^{ө}$*сле* – әд. төсле, *ке*$^{ө}$*лке* – көлке, *ы*$^{о}$*зын* – озын, *ты*$^{о}$*ман* – томан, *се*$^{ө}$*лге* – сөлге, *ке*$^{ө}$*н* – көн, *ты*$^{о}$*рмыш* – тормыш, *ы*$^{о}$*рлау* / *орлау* – урлау һ.б.

Сөйләштә, аеруча I һәм III типларга караган авылларда, [о], [ө] сузыкларының кулланылышы, нигездә, татар әдәби теленең орфоэпик нормаларына туры килә, ягъни әлеге авазлар икенче иҗектә дә, хәтта өченче иҗектә дә әйтеләләр.

Сөйләш, нигездә, урта диалектка якын.

Бер төркем сүзләрдә, киресенчә, [ы], [е] авазлары, күрше минзәлә сөйләшендәге кебек, даими рәвештә иренләшәләр: *дөбөт* – әд. дебет, *мөң* – мең, *гөл* – гел, һаман; шулай ук: *тотош* – тоташ.

Калын әйтелешле сүзләрне алгы рәт сузыклары һәм, киресенчә, нечкә әйтелешле сүзләрне арткы рәт сузыклары белән әйтү минзәлә сөйләшенә хас мисалларда да (*йәбешү* – әд. йабышу (ябышу), *этлек* – атлык – ат кузгалагы, *теш* / *тыш* – (урын мәгънәсендә), көнбатыш (мишәр) диалектка хас мисалларда да (*йанаша* – йәнәшә (янәшә), *бәлчек* – балчык, *мый* – ми, *сыр* – сер, *хал* – хәл, *шыша* / *шишә* – шешә, *элсә* – алайса, *сәлену* – салыну, *чәйкәү*– чайкау, *чепчек* – чыпчык, *чебелдек* – чыбылдык; *кишыр* – кишер, *чаука* – чәүкә, *йогора* – йөгерә, *йурый* – юри, *кукай* – күкәй һ.б.) күзәтелә.

***Протеза күренеше.*** Янәшә ике тартыкка яки татар теле өчен чит булган авазларга башланган сүзләрдә: *эрәт* – әд. рәт, *эстәкер* – скатерть, *Ырай* < Ражетдин, *эрахат* – рәхәт һ.б.

***Аваз өстәлү.*** Бертөркем сүзләрдә сүз уртасында тар әйтелешле [ы], [е] авазлары өстәлә: *чүперәк* – әд. чүпрәк, *карышы* – каршы, *күреше* – күрше, *чирегән* – чергән, *шытыган* – шыткан, *йере* – йөр, *илетү* – илтү, *керетү* – кертү һ.б. Кайбер алынмаларда шул ук [ы], [е] сузык авазлары сүз азагында: *акты* – акт, *тылы* – тыл.

***Дифтонглар.*** Түбәндәге сүзләрдә, күрше бәләбәй урынчылыгындагы кебек үк, даими рәвештә ***-әй*** дифтонгы әйтелә: *үгәй* – әд. үги, *песәй* – песи, *тәпәй* – тәпи.

Әдәби телдәге *-ай*/*-әй* дифтонгына *-ый*/*-и(й)* кушыклары тәңгәл килү түбәндәге очракларда күзәтелә. Чагыштыру кушымчасында: *көрәктий* – әд. көрәктәй (сакал), *бердей* – бердәй, *айудый* – айудай (аюдай); рәвеш кушымчаларында: *тирәлий* – тирәли, *бушлый* – бушлай, *урталый* – урталай, *бүтәнчәлий* – диал. бүтәнчәләй – башкача, *терелий* – тереләй; шулай ук: *булмастый* – булмастай һ.б.

Күбесенчә [***к***] авазына башланган һәм киләсе иҗекләрдә арткы рәт сузыклары булган сүзләрдә [ый]~[и]: *кыйтап* – әд. китап, *кыйндыраш* – диал. киндераш – киндер орлыгы, *кишер* / *кыйшыр* – кишер, *кыйна* – кино, *килы* / *кыйлы* / *койло* – кило, *кисаугач* / *кыйсаугач* / *кычаугач* – кисәү агачы, *кыйсап* – диал. кисап – киле сабы, *хыйсап* – хисап һ.б.

Түбәндәге сүзләрдә исә [с], [ж], [к] авазларыннан соң килгән *-ый* кушыгына еш кына *-ий*/*-и* тәңгәл килә: *кыйбат* / *кийбат* – кыйммәт, *кыйаш* / *кийаш* – койаш (кояш), *кийу* – кыйу (кыю), *сийыр* – сыйыр (сыер), *җий* – җый һ.б.

Сүз яки иҗек азагындагы *-ый* кушыгы үзенең дифтонгоидлыгын югалтырга мөмкин: *Бары* / *Бари* – Барый, *кымылдау* – кыймылдау, *кынап* / *кийнап* – кыйнап, *кыбат* / *кийбат* – кыйммәт һ.б.

***-өй*** дифтонгын куллану үзенчәлекләре белән стәрлетамак сөйләше янәшәдәге минзәлә сөйләшенә якын тора.

*Өйләнү, сөйәм* сүзләрендә *-өй* дифтонгы даими саклана. Билгеле бер төркем сүзләрдә, минзәлә сөйләшендәге кебек, *-өй* дифтонгына [ү] сузыгы тәңгәл килә: *сүрәү* – сөйрәү, *күрәү* – көйрәү һ.б.

II тип авылларда **-***өй*/*-ү: сүwәк* / *сөйәк* – әд. сөйәк (сөяк), *төймә* / *түмә* – муенса, *чөй* / *чү* – чөй, *көйәнтә* / *күwәнтә* – көянтә һ.б.

III тип авылларда, *үрә, сүрәү, күрәү* һ.б. кайбер очракларны исәпкә алмаганда, *-өй* дифтонгы активрак кулланыла.

II тип авылларда *-өй* дифтонгы урынына, урта диалектның нократ, казан арты сөйләшләрендәге кебек, *-ий* дифтонгоиды куллану күзәтелә. Мәсәлән, Бузат авылында: *кий* – әд. көй, *сөйәк* / *сийәк* – сөйәк (сөяк), *чий* – чөй, *көйәнтә* / *күwәнтә* / *кийәнтә* – көйәнтә (көянтә).

Билгеле булганча, *-ай, -ай, -уй, -уй, -ой* дифтонгларының тел очы [л], [н], [д], [р], [с], [т], [ч] тартыклары алдындагы позициядә монофтонглашулары көнбатыш (мишәр) диалектның дифференциаль билгеләреннән берсе булып тора.

Стәрлетамак сөйләшендә бу күренеш тә әдәби тел нормаларына шактый якынайган, I, III тип авылларда ул бөтенләй беткән дияргә мөмкин.

II тип авылларда әлеге күренеш берникадәр саклана, еш кына дифтонг урынына дифтонгоидлар әйтелә. Мәсәлән: *мун'* / *муйн* / *муйын* / *мыйын* – муйын (муен); *ун'и* / *у[й]ни* / *уйный* – уйный; тагын: *кырлачы* – кырлайчы – кырыктартмачы, *Фатима* / *Фатыйма, бат'ак* / *ба[й]так* – байтак һ.б.

Ачык иҗектәге һәм сүз азагындагы [у], [ү] авазлары урынына *-ыw*/ *-еw* дифтонглары куллану очраклары бар: *бару*/*барыw* – бару, *су*/*сыw* – су, *тегү*/ *тегеw* – тегү, *сыwык*/*суwык* – суык, *йеwеш* – йүwеш (юеш), *йуwача*/ *йыwача* – йуwача (юача) һ.б.

**Тартыклар**. Стәрлетамак сөйләшендә тартык авазларның әйтелешендә түбәндәге үзенчәлекләр күзәтелә.

[*к*], [*г*], [*х*] тел арты тартыкларының әдәби тирән тел арты [*ҡ*], [*ғ*], [*х*] авазларына якынайган варианты кулланыла. Аны шартлы рәвештә [*к*$^{ҡ}$],[*г*$^{ғ}$] дип билгеләргә мөмкин. Мәсәлән: *к*$^{ҡ}$*ашык*$^{ҡ}$ – кашык, *к*$^{ҡ}$*арг*$^{ғ}$*а* – карга, *чык*$^{ҡ}$*к*$^{ҡ}$*ан* – чыккан, *Г*$^{ғ}$*айшә* – Гайшә һ.б.

Шушындый ук күренеш татар теленең ике диалект вәкилләре катнашлыгында формалашкан башка сөйләшләрендә дә күзәтелә (мәсәлән, чистай, волгоград, байкыбаш һ. б.)

Гарәп-фарсы алынмаларында, әдәби телдәге кебек үк, тирән тел арты авазлары үзләре дә әйтелә: *ҡәнәфер* / *канәфер* – канәфер, *сәгат* / *сәғәт* – сәгать, *ҡабер* / *кабер* – кабер, *Ғаптулла* / *Аптулла* – Габдулла һ.б.

Башка тартыкларның әйтелеше әдәби эквивалентларыннан, нигездә, аерылмый. Аерымлыклар төрле тәңгәллекләрдә һәм комбинатор үзгәрешләрдә табыла.

**Аваз тәңгәллекләре.**

[м]~[б] бер төркем сүзләрдә күзәтелә: *корман* – әд. корбан (балык), *мукча* – букча (сумка), *малан* (Гөлем, Хәлекәй, Бузат авылларында: *балан*/ *палан* / *малан*) – балан, *мәндә* – бәндә һ.б. Бу үзенчәлек регрессив ассимиляция күренеше булып тора. [м]~[б] башка кайбер сүзләрдә дә бар: *мышый* – әд. поши, *мөрө* – бөре, *мәке* – бәке; *мөтлөк* – бөтнек, *матис* – батист һ.б.

[в]~[w]. Көнбатыш (мишәр) диалектка хас ирен-теш [в] авазын куллану стәрлетамак сөйләшендә бик чикле. II тип авылларда мондый фактлар очрый: *ватан* – wатан (ватан), *Вәли* – Wәли (Вәли), *авыл* – аwыл (авыл), *вахыт* – wакыт (вакыт), *ватма* – wатма (ватма), *бырач* / *вырач* – врач һ. б.

[б]~[w]. Интервокаль позициядә шартлаулы [б] спирантлаша яки сонор [w] га күчә: *кебек* / *кеб*$^{w}$*ек* / *кеwек* – кебек, *таб*$^{w}$*а* – таба һ.б.

Бу күренеш тамырлары [п] тартыгына тәмамлана торган бер төркем фигыльләрдә дә күзәтелә: *табып* / *таб$^{w}$ып* / *ташып* – табып, *кабып* / *каб$^{w}$ып* / *каwып* – кабып һ. б.

[(ы,о)б]~[(у)w]: *чобан* / *чыбан* / *чубан* – чуwан (чуан), *чобар* / *чыбар* – чуwар (чуар); *җобану* / *йобану* – йуwану (юану), *чебәлу*/ *чобалу*/*чыбалу* – чуwалу (чуалу). Көнбатыш диалектта, Урал төбәге сөйләшләрендә дә шулай ук.

[з] авазы тел очы [с] (*зәләмә* – сәләмә ‘тузган, иске’) яки тел уртасы [җ] авазына тәңгәлләшә: *кәзә* – әд. кәҗә.

[ж] авазы кулланылышы ягыннан әдәби телдәгечә (*җизни, җәймә, әҗәл, җыр, җилкә, җәю*), шулай да бу авазга башлана торган сүзләрдә *й*-лаштыру да хас: *йәмәгәтем, йетмеш, йебәрү, йаwап*, *йер* / *җир, йетәргә* / *җитәргә, йыр* / *җир, йылыту* / *җылыту, йеп* / *җеп*, *йемерү* / *җимерү* һ.б. Билгеле, *й*-лаштыру – татар теленең көнбатыш (мишәр) диалектының төп сыйфатларыннан берсе.

Карагыш, Хәлекәй, Гөлем авылларында [$^{д}$ж]~[ж] тәңгәллеге дә очрады: *$^{д}$җибәрә, $^{д}$җир, $^{д}$җиде, $^{д}$җийабыз* һ.б.

[к]~[г] тәңгәллеге дә – ике яклы күренеш. Сүз яки иҗек башында һәм ике сузык арасындагы позицияләрдә даими рәвештә саңгыраулаштыру (*чикә* – әд. чигә, *кәрәбә* – гәрәбә, *бәрәңке* – бәрәңге, *закыс* – загс, *көнҗәлә* – гөнҗәлә) яки яңгыраулаштыру (*тугу* – әд. туку, *гөпшә* / *көпшә, гәрәз* – кәрәз) күренешләре күзәтелә; тагын: *тыгырык* – тыкрык, *чигерткә* – чикерткә (күпчелек авылларда) һ.б.

Стәрлетамак сөйләшенә [h]~ [х] тәңгәллеге хас: *һәтлек* – әд. хәтле, *һалык* – халык, *һәзер* – хәзер, *һәрби* – хәрби; шул ук вакытта: *хәм* – әд. һәм.

Түбәндәге очракларда әдәби телдәге [ң] урынына тел очы [н] авазы әйтелә, әмма сирәк күренеш: ([н]~[ң]): иялек килеше кушымчасында (*безнен* – әд. безнең, *анын* – аның, *дөгөнен* – дөгенең, *картларнын* – картларның һ.б.; мондый күренеш II тип авылларда актив, мишәр диалекты өчен характерлы күренешләрнең берсе); хикәя фигыльнең 2 нче зат берлек сан кушымчасында факультатив характерда (*барасын* – әд. барасың, *унисын* –

уйныйсың һ.б.), алмашлыкларда (*анарга* – аңа, *шунардан* – шуңардан) күзәтелә.

[к], [г] тартык авазлары урынына бугазда ясала торган [’] (хәмзә) авазы әйтелү очраклары теркәлгән: *бул’аннар* – әд. булганнар, *чапча’* – чапчак һ.б.

Аерым сүзләрдә генә күзәтелә торган тәңгәллекләр. *к~х: кәтле* – әд. хәтле, *н~д: алны* (миш. диал. – шулай ук) – алды, *ине* – иде (чагышт.: миш. диал. *иде*, урта диал. *ийе*); *з~с: җиләз* – әд. җиләс; *р~н: үткер* – әд. үткен; д~г: *билдәле* – әд. билгеле: алынмаларда *б~в: ебрәй* – еврей һ. б.

Стәрлетамак сөйләше бу тәңгәллекләрнең күбесе белән Урал төбәгендәге башка татар сөйләшләренә дә якын тора; [з]~[с], [н]~[д] тәңгәллекләре көнбатыш (мишәр) диалекты өчен характерлы.

***Тартык авазларның төшүе***. Фарингаль [һ] авазы даими рәвештә төшә: *уш* – әд. һуш, *өнәр* – һөнәр, *аман*– һаман, *Җәңгир* – Җиһангир һ.б.

Сүз уртасында [һ] авазы әйтелмәгән очракларда янәшәдәге сузык икеләтелергә (*Зөөрә* – әд. Зөһрә), ике бертөрле сузыклар урынына озын сузык әйтелергә (*шәр/шәәр*< шәһәр, *зәр/зәәр* < зәһәр) мөмкин.

Төрле күтәрелешле сузыклар арасындагы [һ] авазына [й] соноры тәңгәл килә*: аман* – әд. һаман, *зийен* – зиһен. Бу күренеш кеше исемнәрендә дә бик актив: *Майҗамал* – әд. Маһиҗамал, *Майрә* – Маһирә, *Майнур* – Маһинур, *Шаймуратов* – Шаһимуратов һ.б.

Тамырлары *-р* га беткән фигыльләрнең хәзерге һәм киләчәк заман, инфинитив формаларында *-р* авазларының берсе кыскара: *җибәрегә* – әд. җибәрергә, *керегә* – керергә, *карага* – карарга, *йандырыга* – яндырырга, *барыбыз* – барырбыз, *үстеремен* – үстерермен, *күресез* – күрерсез һ.б.

Геминат авазлар да кыскаралар: *Стәрлетамака* – әд. Стәрлетамакка, *күлмәкә* – күлмәккә, *анан* – аннан, *ашыкмасың* – ашыкмассың, *маный* – манный, *Зинур* – Зиннур, *читән* – читтән, *йыгылгамын* – йыгылганмын (егылганмын), *әлә* – әллә һ.б.

Кайбер сүзләрдә иҗекләр дә кыскара: *мәтәм* < мин әйтәм, *шунанары* – шуннан ары, *сунан* < *суннан* < *суңыннан* – соңыннан, *ишкәнем йук* – ишеткәнем юк, *иләшү* – ияләшү, *тасмал* – тастымал, *нишәтим* – ни эшләтим һ.б.

Сүз ахырында: *асал палас* – асалы палас һ.б.

***Аваз өстәлү.*** Стәрлетамак сөйләшендә сүз азагында тел арты [к] авазы өстәлү – шактый үзенчәлекле күренешләрнең берсе. Ул түбәндәге очракларда күзәтелә. Төрле сүзләрдә: *байагынак* – әд. бая, *лутчык* (лучше) – яхшырак, *ичмасак* – ичмаса һ.б. Алмашлыкларда: *монауык хәтлек* – әд. менә моның хәтле. Бәйлекләр азагында: *хәтлек* / *хәтлеге* – әд. хәтле, *кадәрлеге* – кадәрле, *чаклыгы* – чаклы, *тиклеге* – тикле һ.б.; ***-еп*** кушымчалы хәл фигыльнең юклык формасында: *белмичәк* – белмичә, *эчмичәк* – эчмичә, *килмичәк* – килмичә, *ашамийчак* – ашамыйча һ.б.; ***-ганчы*/*-гәнче*** кушымчалы хәл фигыльдә: *байыгынчык* – байыганчы (баеганчы), *белгенчек* – белгәнче һ.б.; сүз уртасында: *кунакча* – кунача.

Бу типтагы мисаллар татар теленең Урал төбәгендәге башка сөйләшләрендә дә билгеле.

## Грамматик үзенчәлекләр

Төп грамматик категорияләр, аларның ясалышы һәм семантик функцияләре белән стәрлетамак сөйләше татар әдәби теленнән аерылмый. Әмма шуның белән бергә кайбер үзенчәлекләр дә табыла. Алар аерым урыннарда әле һаман да сакланып килә торган татар теленең көнбатыш (мишәр) диалектына хас формаларга яки күрше минзәлә сөйләше белән уртак булган күренешләргә кайтып кала.

**Исемнәр.** Хәрәкәтне белдерә торган фигыльләр белән бәйле һәм юнәлеш пунктын белдерә торган исемнәр, бәләбәй урынчылыгы һәм Урал тирәсендә таралган башка кайбер сөйләшләрдәге кебек, баш килеш формасында да киләләр: *Уфа* (әд. Уфага) *китә бер апам. Салават* (Салаваткa) *барып кайткан ийе.*

Иркәләү-кечерәйтү *-кай*/*-кәй* кушымчалары белән белдерелә: *хатынкай, киленкәй, матуркай* һ.б. II тип авылларда палаталь

гармониянең бозылу очраклары бар. Кеше исемнәрен кыскарту аеруча II тип авылларда күзәтелә: *Шәмәт* – әд. Шәмсетдин, *Хисамый* – Хисаметдин, *Кәлук* – Кәлимулла, *Гилмуш* – Гыйльмулла, *Исмай* – Исмәгыйль, *Мөчти* – Мөхәммәдьяр һ.б.

**Алмашлыклар.** Аларның составы һәм төрләнеше буенча да стәрлетамак сөйләше бер яктан – көнбатыш (мишәр) диалект, икенче яктан, күрше минзәлә һәм Урал төбәгенең башка сөйләшләре белән уртаклык күрсәтә.

Зат алмашлыклары: *мин, син, ул, без, сез, алар.* 1 нче зат берлек сандагы *мин* алмашлыгының иялек килеше төрле вариантта ясала: *минен/минең/минем: Минен* (әд. минем) *дә такмакларым күᵒп була иде. Минең* (минем) *бер генә энем иде.*

1 нче һәм 2 нче зат алмашлыкларының юнәлеш килеше *миңа/ миңә, сиңа / сиңә* вариантларында кулланыла: *Синең улың тагы бар, берсен миңә* (әд. миңа) *бир, үзем кеше итәрмен – үстеремен* (үстерермен), *дигән ул. Күзе төшеп йеᵒрегән сиңә* (сиңа).

II тип авылларда *миңа, сиңа* вариантлары төп форма булып торалар.

3 нче зат алмашлыгының кыек килешләре, көнбатыш (мишәр) диалекттагы кебек, катлаулы кушымчалар белән ясала (*анарга* – әд. аңа, *анарда* – анда): *Шуннан хәзер анарга* (әд. аңа), *өй күтәрткән-салган кешегә, барып йетә чират. Анарга да укыйм әле.*

Күрсәтү алмашлыклары: *бу, шул, теге / тиге / тийе / тее, ул, анау /анаwу / анаwы; монау / монаwу / монаwы.*

Урын-ара килешләре, мишәр диалектындагы кебек үк, катлаулы кушымчалар *(-нарда/-нәрдә; -нарга/-нәргә, -нардан/-нәрдән)* белән ясала: *Төйәбез дә бәрәңге пешерәбез дә шунарга* (әд. шуңа) *салып, бутыйбыз. Монарга* (әд. моңа) *да сөйләрсен.*

*Монанда* (әд. менә монда), *онанда/оᵃнанда/ынанда* (әд. әнә анда) алмашлыгы еш кулланыла: *Монандагысын* (менә мондагысын) *«Урыс буасы» дигәннәр. Монанда алачык барийы. – Нәсимә, онанда* (әнә анда), *икенче бүлектә, писук бардыр, сөтсез эчкән кешегә мужет кирәгәдер. Оᵃнаннан* (әнә аннан) *урап бардым да оᵃнаннан кайтып киләмен.*

Күрше минзәлә һәм башка сөйләшләрдәге кебек үк, *анау, монау* алмашлыклары килеш белән төрләнәләр, башка төрле кушымчалар да кабул итәләр: *Анауда* (әд. анда) *казлар күле. Ул эссе* (әд. кайнар) *суда монауның* (әд. менә моның) *кебек саргылт төскә керә. Монау тугайга төшеп, без бәләкәйрәк чакларда, аркан тартышалар ийе. Утарлар йөри торган йулның монау* (бу) *йагында. Сеңлем монауык* (менә моның) *хәтлек кенә.*

Сорау алмашлыклары: *кем, ний (ни), нәрсә* / *нәстә, нәрсәкәй* / *нәстәкәй, ниндий* / *нинди* – нинди, *кайсы* / *касы* – кайсы, *качан* – кайчан, *ничә, ничек, нихәлле* – ничек, *кайсылай* – ничек (итеп), *ник, нийә* / *нигә* һ.б.

**Саннар.** Җыю саннарын микъдар саны ролендә куллану очраклары бар. Бу вакытта аларга тартым кушымчасы ялганган була: *Берәүсе* (берсе) *шәһәрдә. Өчәүсе* (өчесе) *авылда калган.*

Шушындый ук үзенчәлек янәшәдәге бәләбәй урынчылыгында, Урал төбәгендәге златоуст, кормантау, тепекәй сөйләшләрендә дә билгеләнеп үтелгән. Ул борынгы төрки язма истәлекләрдә дә теркәлгән: *Андан соң үчагүсү* (өчәүсе) *таң сарыга бардылар***.**

**Рәвешләр.** *Көйе* бәйлеге актив кулланыла һәм төрле формаларда килә: *көйө* / *көйгә* / *кийе* / *көйөнә* / *кейенә*. Мәсәлән: *Шул көйө которып йамгыр йауган. Шомортны пешкән көйөнә алып керәйек тә, җийып, мисарупкадан үткәреп, шуны чәй белә* (белән) *эчәйек.*

*-ча*/*-чә* кушымчасы рәвешләргә ялганып, бу кушымча ялганган сүзнең мәгънәсен көчәйтә: *Бүтәнчә итеп такмак белән биидерейек. Хатынкайы нәстә сүләсә дә анықынча.*

*-кылык*/*-келек* + юнәлеш, инструменталь килеш кушымчалары: *Кышлыкка да банкага тутырып куйайык. Җәйгелектә* (әд. җәен) *шунда тора бәрәңге.Үткәрәсең дә, писук бутыйсың да салып куйасың кышкылыкка. Көндез бер чабата, төнгелеккә бер чабата, бийергә.*

Диалекталь рәвешләрнең күпчелеге күрше минзәлә сөйләшендәге кебек үк: *тәү* / *тәүбаш* / *тәүрәк* / *тәүдәрәк* / *тәwендә* / *тәүдә* / *тәүге* – әд. башта. Мисаллар: *Тәү Бузат аwылына җиде кеше килеп утырган дип тә, кайсы биш кеше дип сүли. Кем*

*тәүрәк йасап бетер дип йарышып шәлләрне бәйли идек. Тәү бардык теге йакка, Әмиргә, аннан монда. Тәүге кат бүрәнәне салгачтын да мөйөшкә акча куйабыз. Тәүдәрәк Илсур сүли.*

**Фигыль.** ***Хикәя фигыль. Хәзерге заманның*** 1 нче зат берлек саны тулы һәм кыскарган вариантлардагы кушымчалар белән ясала: *барам* / *барамын.* Мондый үзенчәлек көнбатыш (мишәр), көнчыгыш (себер татарлары) диалектларына, Урал төбәге сөйләшләренә хас.

***Үткән заман. Тәмамланмаган үткән заман -а + иде*** конструкциясе ярдәмендә белдерелә, ***иде*** ярдәмче фигыле мишәр диалектындагыча да ***(иде),*** урта диалекттагыча да ***(ийе)*** әйтелә.

1 нче зат. *бара идем* / *барайым.*

2 нче зат. *бара + йдең* / *барайың.*

Мисаллар: *Боламык пешерәләр иде. Син дә аны күргән идең.* һ.б.

***-адыр***/***-әдер иде*** формасы да сөйләштә актив кулланыла: *Безгә киләдер иде. Элек пәҗине әниләр чәчәдер иде. Талкан дигән суга торган баридерийе. Моналай тарак буладырыйы, шунарга эрләп, әниләр сугадырыйы. Кендек әбиләрен чакырадырыйык.*

***Киләчәк заман***. 1 нче зат берлектә зат кушымчасы тулы һәм кыска вариантта күзәтелә: *барырмын* / *барымын* / *барым, китәрмен* / *китәрем.*

1 нче зат күплектә, 2 нче зат берлектә һәм күплектә дә икеләтелгән [*р*] кыскарырга мөмкин: *барырсың(н)* / *барысын(ң), барыбыз (барырбыз), барысыз (барырсыз)* һ.б.

***Инфинитив.*** Стәрлетамак сөйләшенә аның ***-ырга***/***-ергә*** (ягъни әдәби) формасы хас: *Барысы да тотондылар миннән пич чыгартырга. Лампага салырга кирасин йуг иде. Сеөлгегә ничә пар килергә инәй белән сөйләшкәннәр. Бидерәне абзарга илтеп, бер атналык таwыкларга ашарлык килен азык алып килергә тийеш. Мукайләп шуып барырга өйрәтәләр, окоп казырга өйрәткәндә.*

***Исем фигыль,*** *әдәби телдәге кебек,* ***-у***/***-ү*** кушымчасы белән ясала: *Кызны икенче күрше йортка качырып кийәү килүгә. Кийәү сатып ала бит инде, элек акча бирү түгел ийе, духилар, балаларга конфит-шиколатлар биреп.*

Сөйләштә ***-у/-ү*** урынына ***-ыш/-еш*** кушымчасын куллану очраклары да бар. Бу үзенчәлек, нигездә, билгеле бер төркем фигыльләрдә күзәтелә (*әйтү, курку* һ.б.): *Куркышыннан* (куркуыннан) *тәгәрәп китә. Җиде йөз йыллар диләр бу авылның утырышына* (утыруына).

***-ыр/-ер/-р*** формасының исем фигыль ролендә килү очраклары да теркәлгән: *Укырдан* (укудан) *кайткан.*Чагышт.: *керердән алда чыгарыңны уйла.*

Бу форма, ***бар*** сүзе белән килгәндә, шикләнүне, хәвефләнүне (рус. опасение) белдерә: *Хәтәр, бурадан йыгылып төшәрең* (төшүең) *бар. Мал чәйнәре* (чәйнәве) *бар, тегендәрәк эл.*

***Хәл фигыльләр.*** Төрле формаларның кулланылышында минзәлә сөйләшенә һәм әдәби телгә дә, көнбатыш (мишәр) диалектка да хас булган күренешләр табыла.

***-ып/-еп һәм -а/-ә, -ый/-и(й)*** кушымчалы хәл фигыльләрнең мәгънәләре әдәби телдәгечә. Мисаллар: *Кич кене йәшләр җийналып, атлар бизәп, мылтыклар атып кийәүне алып киләләр. Йаңгыр боткасы пешерәдерейек, йаңгыр теләп. Сөйли-сөйли эшләде.*

Шуның белән бергә, бу формаларны куллануда көнбатыш (мишәр) диалектка хас үзенчәлекләр дә табыла. Мәсәлән, хәрәкәтне белдерә торган фигыльләр белән килгәндә, әдәби телдәге ***-ып/-еп*** урынына ***-а/-ә*** формасы кулланыла: *Син сораша йер инде ату* (сорашып йөр алайса).

***-ып/-еп/-п*** кушымчалы хәл фигыльнең юклык формасы төрле вариантларда кулланыла: әдәби ***-мый/-ми, -мыйча/-мичә*** вариантлары төп форма булып тора. Мәсәлән: *Йаңгыр йаумыйча торса, чаукалыкка чыга торганыйык, ашарга пешереп ололар, әбиләр.*

Болар белән беррәттән, сөйләштә ***-мыйчы/-миче/-мыйнчы/-минче, -мыйчак/-мичәк, -мыйчан/-мичән, -мыйынчы, -мастан/-мәстән*** формалары да кулланыла: *1952 нчы йылны чыгып киттем, укырга бармастан* (әд. бармыйча) *качып, гербовой ителеп, 14 йәштә. Самаwырын утырткан ут салмыйынчы* (салмыйча). *Миңә әйтмичәк эшләгән. Ул килмичәк башламыйбыз.*

Мондый күренеш татар теленең күп кенә сөйләшләренә хас.

***-ганчы*/*-гәнче*** кушымчалы хәл фигыль мәгънә төсмерләре ягыннан әдәби телдән аерылмый. Ләкин кушымчаның берничә төрле варианты бар: *-гынчы/-генче* (төп вариант, иң киң кулланылышта), *-ганчыга/-гәнчегә/-кынчыга/-генчегә/гынчыга, -г(к)ынчык/-г(к) енчек, -г(к)ычак, -к(г)ынча/-к(г)енчә*, *-кынча/-гинча, -кинчы/-кинче/ -гинчы/-гинче* + бәйлек һ.б. Мәсәлән: *Бас, бас, бас, идәнен уй**ганчы** / Әкрен басып кил каршыма / Күрим күзем туй**ганчы**, дидерейек, малайлар бийегәндә. Тауга, йаланга чык**кынчы*** (әд. чыкканчы), *уйныйдырыйк шул уйыннарны өйдә дә. Таң ат**кынча*** (атканчы) *сүли ул. Эшкә бар**гынчы*** (барганчы), *эштән кайт**кынчы*** (кайтканчы) *эшлидерийем. Картәни-картәти үл**генчек*** (үлгәнче) *кийәүгә чыктым. Унынчы классны укы**гынчыга** хәтле шәлләр ты°тып эш белән җийналабыз. Мин бел**генчегә** хәтле Фатыймә әбинең алты почмаклы өйөндә йома укыдылар. Иң азактан пенсийәгә чык**кынчыга** хәтле механик по животоводству булып эшләдем.*

Әйтергә кирәк, *-кыйнча/-гыйнча* тибындагы вариантлар татар теленең көнбатыш (мишәр) диалектына хас күренеш.

***-гач*** кушымчалы хәл фигыль дә, нигездә, төрле вариантлары булу белән генә әдәби формадан аерыла: *-гач/-гәч, -гачтын/ -гәчтен, -гачтан/-гәчтән, -гачтин/-гәчтин, -гачын/-гәчен, -гачыннан/-гәченнән*. Мәсәлән: *Проватник дипломы алып, эшли эшли-эшли то**ргачтын*** (әд. торгач), *хәзер монда кунакка кайттым да урландым. Урлап алып килгә**чтен*** (килгәч), *мулла алып килеп никах укыттылар. Шунан күрше аwылга йөреп укырга суwык бул**гачын*** (булгач), *әни бер көнне тотты да әйтте инде: улым, болай итеп йөреп суwык тийәргә мужет, кийемеңне калынайтырга бүтән чама йук, быйылга укыма, диде.*

***-ган/-гән*** кушымчалы сыйфат фигыльнең чыгыш килеш формасы һәм ***соң*** бәйлеге белән дә килүе дә ихтимал: *Шапалаганнан соң* (әд. шапалагач), *йөнне* (йонны) *эрлибез. Әмәт кисентесен үткәннән соң* (үткәч) *Байар урманы.*

**Ярдәмлек сүз төркемнәре. *Бәйлекләр.*** *Белән* бәйлегенең *белә* вариантларында кулланылышы: *Сарык көтүwен абый белә* (белән) *дә көттек. Утарга хатле салам алырга килгән әнинең сеңелесе үгез белә. Өмә белә бит өй күтәрәбез бит инде.*

Чагыштыру бәйлекләре: *төслө, ише, шикелле, сыман/сымак, сынны* < сынлы (соңгысы мишәр диалекты өчен характерлы), *сыйфатлы, мисалында* (болары күрше минзәлә сөйләшендәге кебек), *кебек / кеwек / күк / күүк.* Мәсәлән: *Карагайлыктан соң чокыр сыман йер бар. Матур кызгылтырак те$^{ө}$сле була иде төскә мангач. Шул киндераш сабактан йеп кебек кенә нәрсә барлыкка килә.Ул йомшак, йитен сыйфатлыраг ул.*

*Ары* – соң: *Шуннан ары* (әд. шуннан соң) *талкышта киптереп талкыйлар. Шуннан ары соң матча астына акча салабыз.*

Стәрлетамак сөйләшендә *тәңгәле, тапкырында* сүзләре әдәби телдәге *турысында* бәйлек сүзенә туры килә һәм урын-ара мәгънәсендә кулланыла: *Мәмерҗәнең хикмәте – тау айырылды, ике чокор калды, аны фотога төшөреп булмай, wана агач тәңгәле* (әд. турысында). *Менә әле летний лагер – шуның тапкырында* (турысында).

Сөйләштә урын-араны һәм вакытны белдерә торган *ала* (әд. алып) бәйлек сүзе күзәтелә, ул чыгыш килешен башкара: *Шушы сызыктан ала* (алып) *теге растойанийегә таш куйыла.*

## Лексик үзенчәлекләр

Стәрлетамак сөйләшенең урта диалект (аеруча минзәлә) сөйләшләре йогынтысы астында формалашуы аның лексик үзенчәлекләрендә дә күренә. Бәләбәй урынчылыгы һәм стәрлетамак сөйләшенең төп сүзлек фонды үзара бик охшаш. Шуның белән бергә, тикшерелә торган сөйләштә көнбатыш (мишәр) диалект өчен специфик булган сүзләр дә саклана әле. Аларның кайберләре күрше минзәлә сөйләшенә хас эквивалентлары белән параллель кулланыла.

Туганлык белән бәйле сүзләр: *инәй/әни* – әд. әни, *әтәй/әти* – әти, *зур әтәй* – әтинең абыйсы; әдәби телдәге «әби, дәү әни», «бабай, дәү әти» төшенчәләре, көнбатыш (мишәр) диалекттан аермалы буларак, Урал тирәсе сөйләшләре өчен характерлы булган *картата/картатай, картәни* терминнары белән белдерелә. Көнбатыш (мишәр) диалекттагы кебек үк, никах туганлыгы, гомумән алганда, *каен* сүзе белән белдерелә.

Әмма III, кайбер II тип авылларда *бийата*/*кайната, биана*/*бийем*/*кайнана.*

Г а и л ә   й о л а л а р ы, нигездә, бәләбәй урынчылыгындагыча: *сөлгегә килү* / *сөлге сорау* – кыз йортына егетнең ата-анасы ризалык сорап килә, килешү билгесе итеп, кызның әтисеннән сөлге ала (җомга көнне), егет әтисе акча бирә; *ишеккә, түргә сөлге элү* / *сөлге күрергә килү* – туганнарының ризалык билгесе итеп алынган сөлгене, егет йортын күрергә килә; *бирнә* – кыз ягыннан егет ягына бирелә торган бүләкләр, *бирнә сандыгы* – кызның егет йортына алып бара торган кирәк-ярак әйберләре, *арчи* – кызның аны егет йортына озата баручы парлы туганнары.

К а р а л т ы - к у р а, х у җ а л ы к   э ш л ә р е   һ.б.   б е л ә н   б ә й л е   л е к с и к а: *кәзәнкә* – әд. бүлмә, чолан; *себән* – күбә, *мөйөш* – почмак, *алачык* – бәләкәй өй, *утын абзары* – утынлык, *ихата* – койма, *йолкыч* / *йолпыч* / *йулпыч* – җилпуч, *бәләкәй чәүген* – чәй чәйнеге ‘заварник’, *зур чәүген* – чәйнек (*Чәйгүннән салдым, чәйегез кызу* (әд. кайнар) *булдымы?)*, *мукча* – билгә тагып йөрү букчасы (сумкасы), *мунчала мунчаласы* – юкә мунчаласы.

А ш а м л ы к   и с е м н ә р е: *ләwәш* – юка бәлеш (пирог), *күмәч* – ипи, *питырас* – калган камырдан пешерелгән кечкенә икмәк, *әпәй* – кара икмәк, арыш онынннан, *күмәч* – ак икмәк, *йомшак* – бодай ипие, *күптермә* – борчак онынннан пешерелгән калынрак коймак, *җәймә* – яхшы он һәм күкәйдән генә әзерләнгән төче камырны, юка гына итеп җәеп, майда пешерелгән камыр ашы, *җәймә* / *кыстыбый җәймәсе* – кыстыбый тышы. Җәймә сүзенең 1 нче мәгънәдәге синонимнары да бар, алар кечкенә төбәкләрдә, аерым авылларда очрый: *йока* (Чуенчы, Нагадак), *чәлпәк* (Карагыш, Халикәй) һ.б. Алар күрше минзәлә сөйләше авылларында да табыла. һ.б.

Х а й в а н н а р,   ү с е м л е к л ә р   д ө н ь я с ы белән бәйле лексик- семантик төркемдә: *башмак* / *башмак-тана* – әд. бер-ике яшьлек тана, *чeләүсен* / *селәүсен* – суалчан, *кагау* – карчыга (миш. диал. – тилгән), *кормош* – шөпшә, *ак таракан* – кыргаяк, *абрахман* / *абдрахман* (минз. әрекмән) – әрекмән яфрагы, *кучан* – әрекмән (үсемлеге), *кырмаwык, кырмалау* – тигәнәк, *киндераш* –

киндер орлыгы; *пәҗи* (< мордв.) – киндер (үсемлек); *кара кура җиләге* – кара бөрлегән; *мәләш* – миләш, *малан* – балан, *әдәм теле* – кузгалак, *зелпе тамыры*; *кәккүк тәпәйе* / *тәпие* – каз үләне һ.б.

Стәрлетамак сөйләше гөлҗимеш атамаларының күптөрле булуы белән аерылып тора: *гөлҗимеш,* көньяк өлешендә: *этборон.* Болардан тыш, сөйләштә мондый атамалар теркәлгән: *айу камыры, камыр йеләге, нугыт чыбыгы, шипа, кәҗә сакалы* һ.б. Кайбер авылларда берничә атама кулланыла: *кәзә сакал, айу камыры, айу камыры, эт бороны, камыр җимеше, кәҗә камыры, гөлҗимеш, эт бороно* һ.б.

Стәрлетамак сөйләшендә башка бер сөйләштә дә билгеләнмәгән *котол* (борчак кузагы) сүзе бар.

Стәрлетамак сөйләшенең үзенчәлекле билгеләре гарәп-фарсы алынмаларын куллануда да табыла: *ушлы* – әд. башлы, хәтерле, *гиллә* – авыр хәл, сәер хәл, *хашәп* / *чабата хашәп* – башмак, *хыйтлык* – авырлык, *хыйтлану* – җәфалану, *һалак* / *һәләк* (шулай ук *зерә* сүзе дә очрый) – бик, искиткеч һ.б.

Шулай итеп, көнбатыш (мишәр) диалектның стәрлетамак сөйләше татар теленең урта диалект сөйләшләренең көчле йогынтысы астында формалашкан. Шулай булса да, анда көнбатыш диалектка хас үзенчәлекләр дә шактый тотрыклылык саклыйлар, күрше минзәлә сөйләше белән зур уртаклык күрсәтә.

Стәрлебаш җирлегендәге стәрлетамак сөйләшенә караган татарларның әйтеп узылган фонетик, грамматик, лексик үзенчәлекләрен һәм аларга хас булган гореф-гадәт, йола һ.б. сөйләү үрнәкләрендә дә күрербез. Текстларда сүзләрнең әйтелеше транскрипциядә биреләчәк. *Я, ю, е* хәрефләре урынына [йа], [йә], [йу], [йы], [йы], [йе] авазлары, өстәмә билгеләрдән [w] – ирен-ирен өрелмәле тартык аваз кулланылды.

# ЭКСПЕДИЦИЯ ВАКЫТЫНДА СТӘРЛЕТАМАК СӨЙЛӘШЕНӘ КАРАГАН СТӘРЛЕБАШ ТАТАРЛАРЫННАН ЯЗЫП АЛЫНГАН, ТЕЛ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕН ҺӘМ ХАЛЫК ТРАДИЦИЯЛӘРЕН ЧАГЫЛДЫРГАН МАТЕРИАЛЛАР (СӨЙЛӘҮ ҮРНӘКЛӘРЕ)

## Авыллар тарихыннан

**Әмир авылы.** Әмир дигән карт Шишмә районы Кашкалаша дигән аwылдан припущенник була. Шул килеп утыра. Кызлары и ике хатыны була. Берсе карт хатын, берсе йәш хатын. Безнең Күндрәк дигән йылганың Акйар дигән җиргә барып утырган былар. Шуннан соң күчеп монда килеп утыра. Шушында ул килгәләгәнче бу урында күлләр, кара урман була. Монда умбер кеше була. Семйа микән. Алар патша кешеләре булалар инде. Болар килгәнче. Аларны күчереп утырткан буламы Екатерина II, алар йасак түләп, күз-колак булып утыралар. Безнең конторының өскө йагын «Татар Очы» дип йөртәләр. Татарлар булганнар алар. Стәрлебаш, Аwыргазы – алар Рязан′ өлкәсенән килеп утырганнар дип йазган ул. Рәсәйдә иң зур Касыйм дигән аwыл бар бит. Татарлар булган. Алар рус патшасына хезмәт иткәнме инде. Шуннан күчеп утыртылган дип әйтәләр. Патша җирләрне алыр өчөн утырткан. Җиде йылдан соң, Әмир аwылына Казаннан Мортаза дигән карт килеп утыра. Мортазиннар. Аның гел малайлар була. Биш-алты малайы була. Әмир картның кызлар гына булгачтын (*булгач*), ызгыш китә. «Аwылга нинди исем кушабыз?» Мортазалар: «безнекен» дип. «Әмир карт иртә килде, аның исемен кушабыз», дигән халык. Зур аwыл булган. Ачлыкта, 1921 йылны, бишәр йөзләп кеше үлгән. Өйләр тыгыз утырганнар. Кеше күп булган, мең йарымнан да артык кеше булгандыр әле.

*Әмир авылында*
*Шиһабетдинов Нурислам Гәрәй улыннан (1941 елгы)*
*язып алынды*

**Бакча авылы**. Бакча аwылында 1997 йылда 41 өй була. Ызынкүл тамагында урнашкан. Аwылыбызга иң беренче нигез салучылардан Гашийә әби белән Галиәхмәт бабай Усмановлар, Бәдрисафа әби белән Хаҗиәхмәт бабай Хәсәновлар шушы шишмә

суына була 1927 йылда Әмир аwылыннан күченеп килгәннәр. Әмир аwылында ул wакытта шишмә-койолар бик булмый. Шул йылның җәйендә күченеп килүчеләр саны утызга җиткән. Бик матур табигәтле урын булганга Бакча дип атаганнар.

**Әмир, Карагыш, Хәлекәй** – Стәрлебаш районындагы өч мишәр аwылы матур табигәтле җирдә, Күндерәк суwы буйына бер-берсенә сийынып утырганнар. Йурматы башкортлары белән мишәр-татарлар арасында төзелгән җир сату килешүwенә нигезләнеп, 1754 нче йылны Хәлекәй аwылы, 1756 йылларда Карагыш, Әмир аwыллары барлыкка килә. 1960 йылларда алар бер колхоз булып тыралар.

*Бакча авылында*
*Рысаева Минзия Мөдәррис кызыннан*
*язып алынды*

**Бузатбаш, Бузат авыллары**. Мин тыумышым белән Бузатбаш аwылыннан, 1933 йылда тугаммын. Бузатбаш аwылы хәзер йук инде. Ул аwыл халкы хәзер Бузат аwылына күчеп утырганнар, чөнки анда басу җирләре булган. Бер өлеше хәзерге Бишкуйан, русча – Малый Бузат, аwылы җирләренә күчеп утырганнар. Бузатбаш аwылы кешеләре ике урынга төпләнәләр инде. Җир уңайлы була. Шулай итеп, ике аwыл барлыкка килә. Бишкуйан урман аша чыккач. Бузатбаш калкулыкта, Бузат аwылы астарак, түбәндәрәк. Бузат атамасын әйтеп үтәм. Бороңгы бабаларыбыз безнең шушы җирләрне карап китәләр. Үзләренең бүз – ак атлары – була. Бу атлары аларның аwырган була, айагымы. Аwыру атларын калдырып китәләр. Киләсе йылны йаңадан килә алар. Пенза йагыннан киләләр мишәрләр, алар аwылга нигез сала. Ошатып киткән булганнар: таулар, ышык, чокыр бит. Бихисап шишмәләр чыга таулардан. Тау битләрендә шишмәләр күп. Аwылга исем кирәк була. Нинди исем кушабыз дигәннәр дә, йулыбызга кем очрый, кешеме, хайwанмы – шуның исемен кушарбыз, дигәннәр. Карасалар, теге былтыр калган атлары килә икән, терелгән, исән, ди. Шуннан соң Бузат дип кушалар. Бүз ат исеменнән. Менә шулай аwыл барлыкка килә безнең.

*Бузат авылында туып үскән Сәхиуллина Фатыйма*
*Әбделгани кызыннан (1933 елгы) язып алынды*

Тәү Бузат аwылына җиде кеше килеп утырган дип тә, кайсы биш кеше дип сүли. Алар Акбузат дигән ат белән килгәннәр. Килгәчтен, су буйлары бит инде, атлары чирләп үлгән. Картәти (*дәү әти*) сүләгән иде. Кыскартып Бузат дип киткән. Аwылда күөп халык: татар, әзрәк урыслар и чуwашлар да бар. Күрше аwыллар безне мишәрләр дип йөртәләр. Бузат мишәрләре дигән атамабыз да бар инде. Күрше аwыллар сузыбрак сүли – без сөт, көрәк дибез, алар – сет, керәк. Аwылыбызда алты йөздән артык хуҗалык бар. Җитмешләп йорт буш. Без умбала үстек, мин җиденчесе.

*Бузат авылында*
*Нәзирова Миңнекәй Миңнебай кызыннан (1960 елгы)*
*язып алынды*

Бу аwылга Пенза кырыннан килгәннәр. Шулай дип бабай сүли иде. 1760 йылларда Стәрлетамакта (*шәһәр исеме*) беренче мәчет ачканнар. Шунда чакырганнар Татарийәдән. Мөхәммәтсәлим килгән. Шуннан соң ул шунда имам булган. Аның артыннан энесе Исмәгыйль килгән. Анысы сәүдәгәр булган. Мөхәммәтсәлимнең дүрт улы булган. Мин Мөхәммәтсәлим нәселеннән. Татарның бөйөк йазучылары Сәгыйть Рәмиев, Муса Җәлил – аның нәселе. Исмәгыйльнең токомнарынан миллионер Рәмиевлар. Аларның шәҗәрәсен Риза Фәхретдин төзөп калдырган. Мөхәммәтсәлимнең улы Әхмәтҗан. Анысы булган бөйек татар шагыйре Муса Җәлил авылыннан, Мостафадан. Әтисе моносын мулла булмаска, сәүдәгәр йасарга уйлаган. Но ул укырга теләгән. Шуннан соң Мисырга барып укыган. Дин буйынча ике факул′тет бетергән: дин и медицина. Кайтып Мостафада укыган. Аның биш кызы, өч улы булган. Безнең бабай Сәүбән – аның иң кече улы. Сәүбәннең тагын өч улы булган. Шуның иң олосы Ваффан – менә минем әнинең әтисе үзенеке. Аның кызы Гөлсем и мин, җиденче буын булам. Муса Җәлилнең картәнисе Сәүбән бабайның апасы булган инде.

*Бузат авылында*
*Шәрәфуллин Фәрит Фазулла улыннан (1947 елгы)*
*язып алынды*

**Гали-Бузат.** Мин Гали-Бузат аwылында туып үскәнмен. Аwылның исеме картәтийебезнең исемен йөрөтә. Бу аwылга нигез салучы ул. Сталыпин реформасы чоронда Бузат аwылыннан Солтанов Гали (Галиулла) Сафиулла улы – минем картәти Тәтер йылгасы буйына гаиләсе белән килеп урнаша. Урнашуwының сәбәбе җирләрне урыс байларыннан саклау була. Анда Тәтер йылгасының икенче йагында Зобова дигән урыс аwылы була. Үзләренең җирләрен бирмәс өчөн, бузатлылар сәнәкләр белән каршы чыкканнар, һәм бу тарткалашудан соң, Тәтер йылгасының арйагы урысларга кала, ә быw йак җирләр – Бузат халкына. Гали картәтинең тугыз улы была. Үз көчө белә дөнйа көтә, җир эшкәртә, тегермән сала. Үзе бик укымышлы була. Оренбур магометан духовный собранийыдә полковой мулла булуы турындагы таныклыгы әлеге көндә дә саклана. Җир эшкәрткән, мулла былган. Бик күп кулйазма һәм басма китаплары былган. Өч мәртәбә репрессийәгә эләгә, өчөсеннән дә йаңадан кайта. Гайебе йук, дип, кире кайтаралар. Кире кайтса да, йакшы көн күрми. Аwылның ата комунистлары өч тапкыр талап чыгалар. Фамилиясе Солтанов була. Ул wакытта Солтанов фамилийәле кешеләрне тикшереп тә тормаганнар, гайебе бармы-йукмы – озатканнар. Өлкән балаларын Солтанов фамилиясе урынына үзенең исемен Галиуллин фамилиясе йасап, Төрекмәныстанга Урта Азийа җирләренә йибәрә. Алар репрессиядән шулай котолалар. Бәләкәй өч баласы үз йанында кала. Безнең Рәшит – иң төпчөге, 1931 йылгы. Аңа әтисе үлгәндә өч йәш' булып кала.

*Бузат авылында*<br>*Фәйзуллина Нурия Рәшит кызыннан (1953 елгы)*<br>*язып алынды*

**Гөлем авылы**. Бу аwыл төп бабабызның исеменә бирелгән. Муллагөлем исемле булган төп бабабыз. Шуның дүрт улы булган. Дүрт улының берсеннән безнекеләр киткән. Динмехәммәт исемле. Шул Динмехәммәтнең балалары без: Динмехәммәтнең Шаймардан булган, Шаймарданның улы Шайморат, Шайморатның улы Хайбрахман, Хайбрахманның улы – мин.

Болай сүләү буйынча ни булган: Муллагөлем бабабыз үсеп килгән wакытта, Мурзаголга килеп йөрөгән булганнар, Исмәгил исемле әтисе белән. Мурзагол исемле кешенеке булган инде ул Мурзагол аwылы. Бик хәлле кеше булган. Шушы Муллагөлем бабайны сорап алган инде: «Синең улың тагы бар, миңә (әд. *миңа*) бир, үзем кеше итермен – үстеремен (*үстерермен*), җир биремен (*бирермен*), урын биремен». Шулай эшләнгән. Шушы йерне аңа бүлеп биргән була да. Шунда йәшәгәннәр инде. В основном, шуннан дүрт улыннан шушы Гөлем аwылыннан кеше таралган. Килгән кешеләр дә бар мында. Татарийадән килүчеләр булган. Берсе Хайрулла бабай Ахт'амовлар, Валиевлар. Бер өч семйа.

Иске аwыл дип йөртәләр ийе. Түбәнге Гөлем дип тә йөртәләр ийе. Аларны бетерделәр дә бу аwыл гына калды. Башта шунда гына булган. Семйа күмәгәйгәч, монда күченгәннәр. Әтиләрнең әтиләре күченгән булганнар монда. Картатайга (*дәү әтигә*) дүрт йәш булган монда төшкәндә, 1878 йылда. Безнең картатайның йере урман эчендә тороп калды. Шаймардан кайыны дип йөрөтәләр ийе. Карагайлыктан соң чокор сыман йер бар. Мин белгәндә әле wак кына агачлар иде. Пасаткы утырттылар.

*Гөлем авылында*
*Шәймәрданов Риф Хәйбрахман улыннан (1935 елгы)*
*язып алынды*

**Көчегән (Өч-Әсән) авылы.** Хәсән исемле эч (*өч*) бырат (*абыйлы-энеле*) мында килеп утырган, диләр. Шуннан Өч Әсән аwылы булып киткән, диләр. Аwыл башында салкын шишмә бар. Шифалы шишмә ихаталап алынган. Бу тау Актау. Үөрдән менгәндә Бузат таwы, дибез. Кыш кеннәрендә машиналар менәлмичә, буран басып шул җирдә, этләнеп (*җәфаланып, интегеп*).

*Көчегән (Өч-Әсән) авылында*
*Нурмөхәммәтова Тәнзилә Тимергали кызыннан (1947 елгы)*
*һәм Гафиятуллина Мөбарәк Муллагали кызыннан (1930 елгы)*
*язып алынды*

## Җир-су

**Мәгәзи таwы** (әлеге мәчет таwы), сүләү буйынча, анда магазин булган. Шунанары сон ачлык, уңдырышсыз йыллар туры килсә дип, халыктан күпмедер өлөш аванса җийганнар. Шунда келәт булган, магазин да булган. Шуны алама йылларда таратып йөргәннәр. Кемгә күпмедер өлөшләп. Анда җийылышып сүләшеп йөргәннәр инде.

**Урыс күпере**. Менә шушыннан киткәчтенә (*киткәч*), су бара бит, шушы суwының тее (*теге*) йагында урыс байары булган. «Урыс күпере», дип сүлиләр иде. Күᶱпере йуг иде.

Быйагыннан «**Зәһирә җире**» дигән урын бар иде. Шунанары сон быйакта «Гәрәй койосы». Монандагысын (*менә мондагысын*) «Урыс буасы», дигәннәр. Йуwан ике кайын утырадырыйы (*утыра иде*).

**Җәнгир кайыны**. Утарлар йөри торган йулның монау (*бу*) йагында. Менә әле летний лагер шуның тапкырында (*турысында*). Җәңгир (*Җиһангир*) исемле кешенең йере шунда булган.

**Хайрулла түбәсе.** Хәйрулла үтеп китсә, обизател'но өйөңдә бер әйберең йугала. Шундый шәп бабай. Мәрхүм инде. Ул йер шулай атала.

*Гөлем авылында*
*Шәймәрданов Риф Хәйбрахман улыннан (1935 елгы)*
*язып алынды*

**Әҗәл таwы**. Элекке ачлык йылында, йегерме беренче йыллардамы, бер әбей шунда адашып үлгән, әче буранда. Ачлык wакытта йөрөгән ине (*инде*) ул. Шуңа күрә Әҗәл таwы дип атаганнар. Аның кәберенең ташы бар ийе бер йердә. Хәзер кайда икәнен белүче йук. Әле тәбәшәгәйде (*тәбәнәгәйде*) ул.

**Кушкайын таwы.** Аwылдан кергәчтен (*кергәч*), Әҗәл таwын узып, Кушкайын дип атала. Кайыннар утыртканнар, уратып алынган. Кушкайынның таwы килә-килә, аналайга хәтле китә.

**Сәхи бабай чишмәсе**. Аларның өйләре шунда салынган. Шишмә суwы кырына. Шуңа күрә Сәхи бабай шишмәсе дип атала.

Анан ары соң **Насыйр бабай** койосы. Мәчет кырында. Улак куйдылар. Ул шишмәнең суwының тәмнелеге... Ансы аwыл уртасында.

**Мәмерҗә таwы**. Күренеп тора, бийек. Wана (*әнә*). Инде йәмсезләнде. Мәмерҗә сөзәк таудан аска таба килә. Метр йарым гына калды су читенә йетәргә тау. Менә хәзер туктады ул. Мәмерҗәнең хикмәте – тау айырылды, ике чокыр калды, агач тәңгәле (*турысында*). Ул чокырны фатага төшөреп алалмыйлар. Төшми фатага берничек тә. Анда бер хикмәт бар.

*Хәлекәй авылында*
*Мугаттарова Хәтимә Зәйнулла кызыннан (1935 елгы)*
*язып алынды*

**Хәлекәй (Уразай).** Бу йергә Хәлекәй исемле бабай килеп утырган, дип сөйлиләр. Башта Уразай исемле булган безнең аwыл. Башка аwыллар безне мишәрләр, диләр инде ул. Үзебез татар дип торсак та. Әмир аwылы белән бер үк сөйләш. Безнең сөйләм әдәбийәтнеке. Халык ике йөзләп бардыр.

**Мингали шишмәсе**. Минем кайнатай шишмәсе ул. Безнең кырда гына. **Гөлбахар шишмәсе**. Шундый әби булган. Кругом шишмә анда.

**Нурмый шишмәсе** бар. Анда туйда су йулына барайык. Хәзер су йулына Тугай урамына йөриләр.

*Хәлекәй авылында*
*В(Г)әлиева Гөлшат Мансаф кызыннан (1971 елгы)*
*язып алынды*

**Ак Чишмә. Байар урманы**. Ак Чишмә бар. Аның каршында ак йалан. Әти сөйлийдерийе. Шунда акташ булган, бик зур. Шул ак таштандыр инде дип. Гражданнар сугышыннан соң ул акташны алып киткәннәр. Чишмәсе дә Ак Чишмә дип атала. Ак чишмә урман эченнән килә. Шуны эчәбез. Ул колонкаларда. Бер урам да Ак шишмә дип атала. Моносы Карамалы дип йөрөтелә. Карама агачы үсә. Байар урманы. Әмәт кисентесен үткәннән соң (*үткәч*), Байар урманы. Анда байарлар хуҗа булган инде. Алар анда җиләк җиарга да кертмәгәннәр. Зәки дигән кешенең этисе бик төз бәрә

белгән. Элек шул Байар урманына барганда күсәкләрне йасап барган бик күбиттереп. Сакчыларга. Бу баргачтын теге сакчылар тотарга. Бу күсәк белән бәргән, йакын китермәгән тегеләрне. Күсәге беткәчтен, моно тотоп шунда үтергәннәр.

**Нәмәт бабай** чишмәсенә бара торганыйык. Түбән очта **Йосып бабай** чишмәсе. Теге йак **Хәдийә урамы**. Ташыwга төшөп үлде Хәдийә исемле кыз. Шишмәнең дә атамасы шунардан.

Безнен Әмир аwылында элек бурлар күб булган. Ат караклары. Болар Оренбурдан туры йулдан барып, атны урлаганнар инде. Бурлар йата торган зимл'анкалар бар иде. 1930 йылга хәтле урлаганнар.

*Әмир авылында*
*Шиһабетдинов Нурислам Гәрәй улыннан (1941 елгы)*
*һәм Ардуанова Сәлимә Бәхти кызыннан (1938 елгы)*
*язып алынды*

## Тормыш-көнкүреш турында

Әмир белә (*белән*) Хәлекәй (*авыл исемнәре*) икесе бер силсәwит. Мин Әмирдә туwып үскән. Калхуз персидәтеле килде дә миңә (*миңа*), җиденчене бетерәм йәнәдә (*янәсе*), Стәрлетамакка укырга йебәрәбез алты айга, ди. Укий белмибез, нәрсәкәй беләбез. 52 нче йылны чыгып киттем, укырга бармастан (*бармыйча*) качып, гербоwой ителеп, 14 йәштә. Уфага, Уфадан Черниковкага. «Сез кайа барсагыз, мин шунда барымын (*барырмын*)», дидем кызларга. Кызлар үткерерәк (*үткенрәк*), русча беләләр. Проватник дипломы алып, эшли башладык пойызда. Шулайтеп эшли-эшли торгачтын (*торгач*), хәзер мында кунакка кайттым. Кода мине клуптан урлап апкайтты. Белә иде мине. Күзе төшөп йөрөгән миңә. Урлап алып килгәчтен (*килгәч*), мулла алып килеп, никах укыттылар. Әти-әни белгән булган. Мин генә белмәгәммен, миңә әйтмәгәннәр. Туйны берәр айдан соң йасаганнардыр. Туй йасадык ике йакта да. Тәү бартык тее йакка Әмиргә, аннан монда. Бирнәсен әти-әни әзерли бит инде. Кызлар әзерләми бит. Мин әнидән йәш йарымда калганмын. Картәни-картәтине әти-әни дип үстем. Алар үлгенче (*үлгәнче*) кийәүгә чыктым. Аннан тороп киттек, калхузда эшләдек.

Шушында төшкәчтен (*төшкәч*), калхуз эшенә киттек. Калхузга күмәч (*икмәк*) тә салдым. Мин чыккачтын, пикарн'алар йасадылар. Миңә ул пикарн'алар эләкмәде. Өч кастрүлгә изәм икешәр бидырага (*чиләккә*) сыйышлыны. Өч кастрүлне басам. Бер пичен (*мичен*) пичкә салам. Монанда (*менә монда*) алачык барийы. Ике пичын газга салам. Шулайтеп күмәч салып.

*Хәлекәй авылында*
*Мугаттарова Хәтимә Зәйнулла кызыннан (1935 елгы)*
*язып алынды*

Аwылыбыз зур булган. Кырык йорт буш хәзер. Мукшыдан алып кайткан пәҗене эрләдек. Киндер инде. Палас ниләре эрләп. Әни Мукшыдан ташый. Шәлләр бәйлидерейек. Аулакта сукыр лампа белән генә кич утыра идек. Лампага салырга кирасин йуг иде. Әниләрдән урлап, Розаларга чыгадырыйыйк. Аwызга кабабыз да кирасинны, өйдәге лампадан урлап, йөгөреп барабыз да керәбез, тегене сукыр лампага бушатабыз. Шуның белән кич утырабыз кич көнне (*кичен*). Аны малайлар өрөп сүндерә. Бәйләгән әйберне дә эшләтмиләр. Бүтәнчә нәрсәкәй инде – такмак белән биидерейек. Аwылда ике гармун иде. Самат һәм Гайнетдин абзыйда гына.

*Бас, бас, бас, идәнен уйганчы,*
*Әкрен басып кил каршыма,*
*Күрим күзем туйганчы*, –

дидерейек, малайлар бийегәндә.

Ышкулда йыр дәресләре керәйе. Ленин, хөкумәт турында иде. Мин калхуз төзөгәндә туганмын.

*Ленин бабай wасийәт әйткән: укырга һәм укырга!*
*Йарыша-йарыша укыйбыз без,*
*Без алдынгы укуда,* –

дийәдереейек без.

*Ленин бабай үлгән, диләр,*
*Күрмәдем сөйәкләрен.*
*Күрмәсәм дә сөйәкләрен,*
*Тотам wәсийәтләрен,* –

дийәдерейек шайартып.

Мин алтынчы классны бетеп (*бетереп*) кыйтапларны (*китапларны*) каләм beлән йазып укыйдырыйык. Аларны куйдыртып, 1945 нче йылны мине плугарга утырттылар. Унөч йәштә булам ул wакытта. Үзем «нади» тракторында эшләдем, штурвалга алып китте абый, 6 йылга хәтле. Калган йылны сыйыр саудым.

Элек актык сыйыр-башмакларны алып чыгып китәләрийе. Хөкүмәткә налог түләмәгән өчөн. Икенче партия кереп акча давайлый.

Әрекмән тамырын казып, шуны пешереп, йомшак булып, әчкелт кенә тәмлейе. Кычытканны да ашыйдырыйык. Шуннан ары сон, бәрәңге йафрагы чыккачтын, йафрагын җийып пешереп ашыйдырыйык. Ну ашарга йук. 1943 нче йылны ангина дигән әйбер булды. Ике сеңелем үлде. Шушы Карагыш аwылыннан өч йөз дә ничә кеше үлде. Ангина белә йаз көнө башак ашап. Ачлык йылында кеше ашаганнар. Шундый гилләләр (*авыр хәлләр, сәерлекләр*) булган. Ул кешеләрне тотканнар. Мәчетнең теге йагында 21 нче йылны ачлыктан үлгән кешеләр тутырылган чокор бар. Кәртәләнгән ийе. Йемерелде, бетте ул. Үлгәннәрне вис шунда тутырганнар.

*Карагыш авылында*
*Туктарова Латыйфа Фазлыйәхмәт кызыннан (1930 елгы)*
*язып алынды*

### Аулак өйләр, уеннар

**Көлүкле** уйныйдырыйык (*уйный идек*). Ничә адымлап сүләшәсең дә сызык сызып куйасың. Көлүкле утырта торган җиргә тигез таш куйыла. Агачны тигез генә итеп кисеп утырталар да бәрәсең. Көтүче дийелә. Көтүче йегереп алып килеп утырта.

**Таш аударышлы** уйыны. Монда сызык сызылган, шушы сызыктан ала (*алып*) теге растайанийегә куйыла. Таш утыртылып куйыла. Туп тәгәрәтеп йебәрәсең дә ташны аударсың.

**Чебенлы уйыны**. Бәләкәй wакытларда йалан тәпәй (*тәпи*) чыгып китә идек. Мonанда гараж, тау башы бик зурыйы. Чебенлесе әпәт (< рус. опять) агачны – казыкны – кагып куйасың да моналай (*менә болай*) киртләп эстенә утыртып куйасың. Йырактан

барып бәрәләр дә шул чыгып очорга тийеш. Әпәт көтүче дигән кеше барып йегереп ала да китереп утыртканчыга хәтле «уууу» дип уларга тийеш.

**Чокыр туплы** уйныйдырыйык. Һәркемнең чокоры бар. Теге тупны тәгәрәтеп йебәрә дә. Кемнең чокырына туктый, ул алып кемгәдер бәрегә (*бәрергә*) тийеш.

**Лапталы уйыны**. Атның йененнән (*йоныннан*) туп йасап уйныйдырыйык.

**Йөзек салыш** уйыны. Берәүсенең учына йезек салына да, кемдә йезек йегереп чык, дип әйтәдерейек. Заданийы кушыла.

*Шәймәрданов Риф Хәйбрахман улыннан*
*(1935 елгы, Гөлем авылыннан),*
*Шиһабетдинов Нурислам Гәрәй улыннан*
*(1941 елгы, Әмир авылыннан)*
*язып алынды*

**Тычкан салу**. Тезелеп утырасың. Кулына берәү бер нәрсәкәй тота да сала учка. Тычкан салам, дип. Анан йаныңдагын үбеп чык, дип әйтә. Үбеп чыгарга өлгермәсәң, тагын кала.

**Кайыш сугыш** та уйныйдырыйык. Учка кайыш белә сугаларыйы. Сәкегә тезелеп утыралар. Кемгә азактан сугып туктый, ул чыга да икенчегә суга.

Аулак өйдә дә уйныйдырыйык. Аулак ашы пешереп ашыйдырыйык та. Кем нәрсә китерә, шуны пешереп ашыйдырыйык.

Тауга, йаланга чыккынчы, уйныйдырыйк шул уйыннарны өйдә дә. Тауда рәхәтләнеп уйныйсың. Кар эрегән wахытларында тауга чыга идек. Сулардан, ташулардан малайлар күтәреп алып чыгайде. Малайлар йакын-тирә аwыллардан киләләр ийе. Кызларны урлый башлагачтын, безнең аwыл малайлары тее малайлар белән сугыша башладылар. Кызларны бирмәскә.

*Хәлекәй авылында*
*Мугаттарова Хәтимә Зәйнулла кызыннан (1935 елгы)*
*язып алынды*

Айыры Тирәк дигән шишмәбез бар аwыл башында. Шунда каз сакларга бара идек. Без кызлар су кырындагы бәлчекләрдән

(*балчыклардан*) өйләр йасап, чәчкәләр (*чәчәкләр*) җыйнап, уйнап. Азык алып барып, күкәй, күмәчме ашыйдырыйык.

**Уртада йөрешле** уйыны. Уртада ике кеше. Уртадагы кешене бәреп чыгарырга кирәк.

Йаз кене **чебенле уйыны**. Тайак утыртып куйып. Берле формалы йасап агачны. Теше казыкка утыртып куйабыз. Чебенне төшөрергә тийешсең. Җиде мәрә сызабыз. Чебенне төшөрәлмәсәң, казык кырына килеп басасың. Икенче кеше бәрә дә, төшерсә, син мәрәгә барып басасың. Сызык сыза идек тә, шуның иң азаккысы, җиденчесе, мәрә дип атала. Булмаса, уйыннан чыгасың.

**Аулак өйгә** җийыла идек. Йегетләргә әйтми идек. Әниләр, хатыннар үзләре бер йортка җийналып кич утыралар ийе. Без үзебез аулак өйгә җийналабыз. Мамыкларны колга чала идек. Мамыкны колачлап куйа идек. Менә кулга урый идек тә сузып куйа идек. Барыбызныкын да бертигез йасыйбыз. Кем тәүрәк (*башта, алдан*) йасап бетә. Йарышып шәлләрне бәйләдек. Йегетләр килсә, пәрдәләрне йабып куйа идек. Йегетләр күрмәсен дип. Алар барыбер сизә бит инде. Аннан алар алдатып (*алдап*) өйгә керәләр.

*Бузат авылында*
*Нәзирова Миңнекәй Миңнебай кызыннан (1960 елгы)*
*язып алынды*

**Аулак өйгә** аwызга керосин каwып чыгасың, әтиләрдән урлап. Бишле лампаларны йандырыга. Боламык – онны бутап бирәләр ийе. Шуны пешерәләр ийе. Төчө коймак пешерәләр. Онны урлап апкилә идек. Анда матур чабата кийеп барадырыйык. Көндөз бер чабата, төнгелеккә бер чабата, бийергә. Йаз көне шакмаклы була. Йүкәсе белә (*белән*) бәйләп.

Кар чак кына ачыла, уже менәсең тауга. Дәрт бирә. Гармун уйныйлар.

*Бузат авылында*
*Булатов Хәкимҗан Гыйлемҗан улыннан (1936 елгы)*
*язып алынды*

Бәләкәй Карамалы Бузат аwылында тудым. Моннан сигез км. Монда килен булып төштем бу аwылга. Аулак өйдә сәкедә шәлләр

бәйли идек. Шайартып әйтәйем: «Мин эшләмим, эшләсәм – тирлим, тирләсәм – чирлим». Йегетләр килгәчтен, алышлы уйный идек. Төртмә йырлар да йырлашайык. Минем дә такмакларым күөп була иде:

*Казаннан килгән бер йегет,*
*Ойык-чабата кийеп.*
*Монда килеп читек кийеп,*
*Йөрөгән була бийеп.*

*Бузат авылында*
*Гобәйдуллина Миңсылу Нуртдин кызыннан (1934 елгы)*
*язып алынды*

Алама гына клубыбыз бар ыйы. Уйыннарга барадырыйык. Тауларда уйныйдырыйык. **Капка ачышлы** уйнадык. **Бүкәнле** уйныйдырыйык – менә икәү бергә баса да, бернәрсәкәйне, кулйаулыкны кемгә сала, шул кеше төшөп китә. Түгәрәк тәпәй басып.

**Капка ачыш** – ике кеше тотонасың да, арттан чыга да алга килеп баса. Җырлыйбыз инде. Уйнаган йердә ут йагалар.

Аулак өйдә җәймә пешерәйек. Камыр басасың да җәйәсең. Кисеп-кисеп. Нәзек кенә итеп. Йегетләрне кертмидерейек. Элек зерә (*бик*) күңелле иде.

Аулак өй такмакларын зерә күп йырлыйдырыйык.

*Агач башын сырлыйлар,*
*Йарың булса, матур булсын –*
*Кемнеке, дип сорыйлар.*

*Стәрлебаш бигерәк йәмле,*
*Сулары да бигерәк тәмле.*
*Халыклары саф күңелле,*
*Эштә дәртле үрнәкле.*

*Эх, матур Эстәрле,*
*Эстәрленең эшләре.*
*Эстәрленең өстәленә*
*Йаңа сыйлар өстәлде.*

*Әмир авылында*
*Ардуанова Сәлимә Бәхти кызыннан (1938 елгы)*
*һәм Шиһабетдинова Нәфисә Хәйбрахман кызыннан (1940 елгы)*
*язып алынды*

## Кием-салым

Сугыш wакытында киндераш дигән үсемлек үсә. Кәртә кырларында үсә (хәзер аны йолкыйбыз, чүпкә ташлыйбыз). Шунан ары соң шуны ᵈҗийабыз. Шунан киндерашын тукмап төшөрәбез. Аның wак кына теше була. Шуны киптерәбез дә кыздырабыз. Төйәбез дә бәрәңге пешерәбез дә шунарга салып, бутыйбыз. Инде тәмне була. Киндераш дигән нәрсә. Болай да ашыйбыз кыздырып. Шунан шуны суга батырабыз да сабагын, ул берничә көн йата. Суда чери тышкы сабагы. Шул сабактан йеп кебек кенә нәрсә барлыкка килә. Шул йеп кебек кенә нәрсәне тукмыйбыз. Йепкә әйләндерә торган сүс була. Шул сүсне киптерәбез дә, суда тотабыз да, йомшаргач, киптерәбез дә килегә салып куйабыз. Киледә кисап белән төйәсең. Или менә сирекмә – төйә торган була. Агачка куйалар да монда таш куйалар. Киледә төйәбез. Тарагы бар аның. Терешле диләр ийе. Шунардан болай иттерәбез дә эрлибез. Йеп кебек. Киндер сала торган сәке кебек нийе бар иде. Киндердән сузасың да ничә буй, сугасың. Кийемнәрне киндердән сугып кийәләр ийе.

Асал (*асалы*) палас суга идек. Иске чүперәкләрне йыртып, чүперәк палас суга идек. Чигүне эшләдем, челтәрне дә бәйләдем. Шәл дә бәйләдек. Кәзәләрне асырап, шәл бәйлидерейек. Стәрлетамакка барып сатабыз. Ун тәңкә, унбиш тәңкәгә. Сарык йонынннан пима бастырып, наски бәйләп.

Чабатаны үзем тугыдым. Картәти миңә калыпка кидереп бирә. Мин тугыйм. Шунан ары сон ике төрле ул. Берсе алтылы дип атала, берсе ᵈҗиделе. Алтылы дигәне тизерәк туза. ᵈҖиделе дигәне – йүкәне дә суга батырып аласың да, кызара. Шул кызаргачтын, кызыл чабата була. Анысы ᵈҗиделе чабата дип атала. Тегесе алты гына йептән, ә тегесе ᵈҗиде рәт. Чабатага күтәртмә тагасың. Тактаны беркетәсең, бәйләп куйасың.

*Хәлекәй авылында*
*Мугаттарова Хәтимә Зәйнулла кызыннан (1935 елгы)*
*язып алынды*

Гали Бузат аwылы бетте хәзер. Анда бер кеше генә калды. Карамалыда да әз калган. Карамалы Бузат аwылы (Карамалы дигән

тугай бар ийе. Шуның исемен кушканнар Карамалы Бузат дип) тугайында пәҗи орлогын чәчәләр. Чәнчә бармак калынлык булып үсә. Башлары зур-зур була. Орлогын киндераш диләр ийе. Аны чүплиләр берәмләп. Аны ыргыталар. Пәҗине йолкалар дә көлтә итеп бәйлиләр. Орлогын тукмыйлар. Бәрәңгегә кушып ашыйлар. Сабакларын суга батырып черетәләр дә. Шуннан ары талкышта киптереп талкыйлар. Аны эрләп терле-терле киндерләр йасыйлар. Киндер күлмәк йасап тегәләр. Тулалар сугалар, җеп итеп эрлиләр. Чикмән йасыйлар. Толып йасыйлар чикмән дигәннән. Туннар тегәләр (сарык тиресеннән дә). Йүкәләр эшлиләр. Чабаталар йасыйлар.

*Бузат авылында*
*Кәлимуллина Әминә Галлим кызыннан (1934 елгы)*
*һәм Галиуллина Рәхимә Баймөхәммәт кызыннан (1930 елгы)*
*язып алынды*

Пәҗи дигән барийе. Элек аны әниләр чәчеп, талкан дигән суга торган баридерийе. Моналай утырып торган тарак буладырыйы. Шунарга нитеп эрләп, әниләр сугадырыйы. Шуны ыштан итеп тегәләр ийе.

Тула басу. Йепне эрләп, шул йепне киндердә сугып. Тула итеп басмасаң, шул киндер буладырыйы. Тыгыз итеп эрләп сугалар ийе. Суга торган станогы буладыйрыйы. Анысы тыгыз булмый, тула түгел. Йокарак була. Тегеләрдән айак кийеме теккәннәр бит. Киндер буладырыйы.

Олы кешеләр нагыш дигән, без чигү чигәбез дибез. Мендәр каплары чиктек. Киез итек – сез суконный дисез. Ойыклар, башантай – сарык йөненнән бәйләдек. Мун’чак тактык. Чәчкә тага торган тәңкәләр дә барыйы.

*Әмир авылында*
*Ардуанова Сәлимә Бәхти кызыннан (1938 елгы)*
*һәм Шиһабетдинова Нәфисә Хәйбрахман кызыннан (1940 елгы)*
*язып алынды*

Кич утырайык. Шунда чигәргә өйрәндек. Бездә шәлне бәләкәйдән үк бәйли башлаганнар кызлар. Безнең йәшәү шәл белән булды. Шәлне зерә нык бәйләдек. Бер өмәдә өч шәл бәйли идек.

Шапалаганнан соң эрлибез. Кәләбә элек булмаган. Кәләбә йасарга сыздырып аласың шадра тастамаллардан. Элек булмаган чөнки. Буйалган ойокларны балалар сүтә. Мамык белән кату.

*Карагыш авылында*
*Туктарова Зөлфә Шәмсетдин кызыннан (1938 елгы )*
*язып алынды*

**Аш-су**

Аwылда ләүәш, пирүгләр, күмәч (*акикмәк*), әпәй (*арыш икмәге*) салайык. Баwырсаклар пешерәйек. Шулай әзерләп ашыйдырыйык. Тукмач элек йуг иде. Үзебез җәйәйек.

Сугыш йылында балтырганны ашадык. Безнең картәтийең эшчән кеше иде, уңган ийе. Балтырганны, урманга барып, капчыклап җийалар иде.

Мәләшләр (*миләшләр*), маланнар (*баланнар*) үсә бакчада. Кайнатып түгел, ул эссе (*кайнар*) суда монауның кебек саргылт төскә керә. Йарты стакан гына су саласың көймәскә. Шунан суwытасың да иләктән сөзәсең. Сөзмәсе чыга. Тешен (әд. *төшен*) ташлыйсың. Сөзмәгә берничә кашык кына писук бутыйсың. Шунан эссе утта әз генә йылытып аласың. Кайнатмыйсың. Берничә бутап аласың, йылытмыйча. Писук эреп бетә, шунан шишага тутырып куйасың.

Шомортны пешкән көйөнә алып керәйек тә, җийып, мисарупкадан үткәреп, шуны чәй белә эчәйек. Шунан ары соң аны ләүәшкә дә салайык. Кышлыкка да банкага тутырып куйайык. Кайнатмича гына, үткәрәсең дә, писук бутыйсың да салып куйасың кышкылыкка.

*Хәлекәй авылында*
*Мугаттарова Хәтимә Зәйнулла кызыннан (1935 елгы)*
*язып алынды*

Токмачлы аш өстөнлек итә монда. Мантый, җәймә, коймак, бәлеш, ләүәш. Җәймә тече (*төче*) камырга басыла. Сөткә май салып, күкәй салып басасың. Өзөп алып түгәрәкләп җәйәсең. Табада пешерәсең. Элек пич төбендә пешергәннәр тече күмәч.

*Көчегән (Өч-Әсән) авылында*
*Нурмөхәммәтова Тәнзилә Тимергали кызыннан (1947 елгы),*
*Гафиятуллина Мөбарәк Муллагали кызыннан (1930 елгы)*
*язып алынды*

**Сагыз кайнату**. Кайынның тузын алалар да сагыз кайнаталар. Кайынның тузы дибез. Йока (*юка*) гына итеп суйып. Шуны алып wак кына итеп ваклап. Су буйына төшөп. Тимер комган эченә туйызны салып, ак май саласың да озак итеп кайнатасың. Тәмне ул. Кара сагыз була. Май салгач, йомшара ул. Саталар да иде. Хәзер кайнатмыйлар.

Кыстыбый, пәрәмәч, чәкчәк, баwырсак пешерәбез, ләwәш. Күмәч салабыз. Тукмач җәйеп. Кычыткан ашы. Гомер буйы балтырган ашы ашадык.

*Әмир авылында*
*Шиһабетдинов Нәфисә Хәйбрахман кызыннан (1940 елгы)*
*язып алынды*

**Әдәм теле** (*кузгалак*) әче ул, тәмле. Шуның белән ләwәш салып була.

**Сәрәнә** дигән әйберләр ашыйдырыйыйк. Моналай суган кеwек була, үзе кат-кат. Катлы-катлы булып үсә ул.

Андыз бөтөн аwыруга шифалы. Турап кайнаган суга салып эчәргә.

**Күксагыз.** Элек йаланда чәчкәннәр. Ул галушлар, эрзинкәләр йасау өчен. Ашый торган әйбер түгел ул. Ыздават' иткәнәр.

**Зелпе.** Урманда зелпе дигән үсемлек үсәдерейе. Алып кайталар ийе дә кайырысын суйалар ийе. Суйып ыздават' итәләрйе. Зелпе тамыры нәрсәкәйгә нык кирәк булгандыр инде. Зелпене ыздават' итеп, әти миңә таwар алып, күлмәк тектергән ийе. Тунны иләп тегәләр ийе дә, шуны манарга кирәк ийе ул. Матур кызгылтырак төслө була иде.

**Кәкүк тәпәйе**, сары чәчкә ата, **каз айагы** зәңгәр чәчкә атайы. Гөрләпә, кымызлык үсәйе. **Адәм кузгалагын** болай да ашыйсың, **ат кузгалагын** пешереп ашыйсың. Балтырганны әл дә ашыйбыз. Кычытканны йаз көнө (*язын*).

*Абдуллина Сәбилә Биктимер кызыннан*
*(1937 елгы, Тормай авылыннан),*
*Шәңгәрәева Флюрә Бәхтегани кызыннан*
*(1938 елгы, Карагыш авылыннан)*
*язып алынды*

Этләшә-этләшә, әкрен-әкрен генә, дөнйа рәтләнә-рәтләнә, 1960 нчы йылларда граммлап иген бирә башладылар халыкка. Кычырткан (*кычыткан*), балтырган турап ашаганнар халык. Гөрләпәне тазартыптырып пешерә идек суда, тозлаптырып ашыйдырыйык. Гөрләпә, кымызлык – икесе дә әчкелтем. Кымызлык йаланда гына үсә, гөрләпә өй тирәләрендә дә үсә. Гөрләпә сары чәчкә ата, кымызлыкныкы аксыл гына була.

*Бузат авылында*
*Гарифуллина Флюрә Мансур кызыннан (1945 елгы)*
*язып алынды*

Кәккүк мәмәйләрен йаланнан җийадырыйык. Урманда кәккүк кычкыргач чыга ул. Шуны җийып пешерәләр. Куйан кузгалагы – йафрагы wак кына. Сәрби бар. Ул баса иде җирләрне – сары чәчкәлек. Какы айырым. Шоморт, малан, йуwага барабыз. Бакчада чыпчык тарысы да бар. Кузгылдык. Чеºлек себеркесе – бу идәнне йахшы себерә. Кәҗә сакалы бар. Ак чәчкәсе була. Беткәнче шулай сәленеп кенә. Баллы булайы.

*Бузат авылында*
*Арсланова Кәшифә Сәхиулла кызыннан (1944 елгы)*
*язып алынды*

## Йорт салу

Өйне өмә итеп башлап җибәрдем дә, калганын үзем эшләдем инде. Эшкә баргынчы (*барганчы*), эштән кайткынчы эшлидерийем. Тәүге кат бүрәнәне салгачтын (*салгач*) да, мөйөшкә (*почмакка*) акча куйабыз. Шуннан ары соң матча астына акча салабыз. Өйдә дөнйа йетеш, түгәрәк булсын дип куйабыз.

Матча күтәргәндә, ансы бер өмәчеләрнең күңелен күтәрү өчен буладыр инде (өмә беләә бит өй күтәрәбез бит инде), астан матчаны бирә берничә кеше өскә урынына мендереп салган wакытта, тота да берсе кычкыра: «Ооо, матча бит бу кыска булган. Килми бит бу», – дип кычкыра да берәү. Шуннан хәзер өй күтәрткән-салган кешегә барып йетә анарга. Алып чыга шишә белә. Өмәдәге кешеләрне барысын да эчереп чыга инде. Матча озайту шул была.

Пичник булып эшләргә туры килде. Аwылга кайткачтын, шушында иң тәү ни буладырыйы: үземә бер баш малны шушы өйне бетерү өчен асырарга кирәк ийе. Әти белә икәү бер семйада йәшибез бит инде. Өйләнгәнче, башмактананы (*бер-ике яшьлек тана*) асырарга кирәк. Аны саттым, и башка чыктым (*яңа йортка күчтем*), бер ташландык өйгә. Аның пиче (*миче*) беткән. Тоттом да пич чыгардым. Пич чыгара белгәнне белделәр дә барысы да тотондылар миннән пич чыгартырга. Йаңгырчыга да, Турмайга (*авыл исемнәре*) да барып пичләр чыгардым. Терле аwылларда пичник булып пичләр чыгардым. Хәзер пичнең кирәге дә йук. Шушы аwылда гына 54 пич чыгаргамын барлыгы. Тәрәзә рамнарны, утыргычлар эшләдем. Йараткан эшләрем булды миңә.

*Гөлем авылында*
*Шәймәрданов Риф Хәйбрахман улыннан (1935 елгы)*
*язып алынды*

**Яңа туган балага бәйле йола**

Кендек әбисе дип аталган әбиләр барийе. Бездә Гайшә абыстай бар ийе. Кендек әбигә әйбер бирәсең азактан.

Исемне бабай кешедән генә куштыралар. Баланың берәр җирендә миңе булса, исемен алыштыралар. Миңненур, Миңгәли дип һ.б.

Читтән килә иде сөннәт бабайы. Аwыл сайын йөриләр ийе. Сөннәтче бабайга бер әпәй бирәсең, күлмәк бирәсең, шуннан акча бирәсең. Азаккы йылларны безнең аwылга килмәделәр.

Балага баш очона һәрwакытта да сарымсак куйыгыз. Матрасның астына. Тотонмаган бер баш сарымсак. Сарымсак зәхмәттән саклый. Бала йыласа, сарымсак салып куй. Төшми торган йереннән.

Мин туганчы булган ул. Шәймәхәнә хәзерәт. Ул хәзрәтнең монда кабере бар. Фарыс йазуwы белән йазылган. Гарәпчәгә, татар теленә тәрҗемә иткән ул бабай. Бабай күрәзәлек иткән, әүлийәлек, әүлийә булган. Балага күз тигәнне бетергән.

*Хәлекәй авылында*
*Мугаттарова Хәтимә Зәйнулла кызыннан (1935 елгы)*
*язып алынды*

## Туй йолалары

**Сөлгегә (сорарга) килү / сөлге сорау**. Сөлге чигелгән була. Сөлгегә килгәч, бөтен нәрсә сүләшелә – кайсы көннө никах билгеләргә, кайсы көннө туй билгеләргә. Ничә пар бар. Башта кыз йагында. Аннан кийәү йагында. Сөлгө бирәсең икән, димәк, ризалык биргәнсең.

**Сөлге күрергә килү.** Кыздан алып кайткач, йегет өйөндә сөлгене түр башына элеп куйалар. Күрше-тирә, туган-тумача килеп, кем күчтәнәч алып килә, кем акча алып килә. Сөлге йанына. Ул йәшләрдә була. Сөлгене алып кайтучылар – йегетнең этиәниләре – туган-тумачасын җийнарга мөмкин. Сөлге күрегә дип. Мәсәлән, йегет йагына биш пар барса, кыз йагына бер пар артык булырга тийеш булган. Алты пар. Йә булмаса җиде пар икән, кыз йагында сигез пар. Ун пар да килгәннәр. Элек дүртәр көн туй иткәннәр. Кыз йагында кийәү мунчасы йагалар.

*Бузат авылында туып-үскән*
*Насыйбуллина Нуридә Шәйдулла кызыннан*
*(1975 елгы, Казанда яши) язып алынды*

Иртәгә риза булсаң, мин әниләрне сөлгегә җибәрәм, диде. Мөнәwәрә исемле зур апалары бар ийе – этисе белән бертуган. Бийатай белән бер туган апалары була. Иртән инәйгә (*әнигә*) әйттем: «Зәйнетдин сөлгегә җибәрәм» дип әйтте дип. «Без риза», – диде. Өйне җийыштырып бетеп, чәй эчәргә генә йөри идек, Мөнәwәрә апа килеп керде. Мин чыгып киттем. Инәй белән сүләшеп сөлгегә килергә ничә пар килергә сүләшкәннәр. Шуннан мине инәй чакыртып кертте. Шушы кенгә Зәйнетдиннең эти-әнисе килә, дип. Сөлгегә киләләр. Бийатайның бер йак чалбар балагы төшкән, бер йак чалбар балагын наскийына кыстырган. Мөнәwәрә апа, Зәйнетдиннең эти-әнисе керде. Алар сүләшеп. Мине кертмәделәр.

Сөлге – үзем чиккән сөлге ул. Зур сандык сатып алдык. Бирнә сандыгына: йастык (зур каз мамыгыннан), ике мендәр, йурган, комган, тас, тарилкалар. Ишеккә элә торган сөлгеләр әзерләдем. Эти-әнисенә күлмәклек. Бийем-бийатай йортында тордык. Өч йылдан соң үзебезгә өй бетереп чыктык. Башка чыктык.

Безнең март айында булды туйыбыз. Атлар бизәп. Җиде чана ат ийе. Кызны икенче күрше йортка качырып кийәү килүгә. Кийәү сатып ала бит инде. Элек акча бирү түгел ийе, «Красный Москва» дигән духилар, балаларга конфит, шиколатлар – балаларга шундыйларны биреп. Кийәү кызны эзләп таба. Шуннан соң кодалар төп йортта, кыз йак йорттан загска киттек. Загска кергәчтен, кайтып, төп йортка кайтмыйсын. Йегетне свидетел йегет алып кайтып китә. Кыз йанында свидетел кыз кала. Кич кене йәшләр җийналып, атлар бизәп, мылтыклар атып, кийәүне алып киләләр.

Иртән киләләр. Ололар килә мунчага җибәрегә дип йәшләрне. Иң беренче бийемем килде дә мунчага җибәрде безне. Барып кайткач, бийемем матур брошка бүләк итте миңә. Кийәү бүләге: кәләм, бетергечләр... Минем бер генә энем иде. Кайнешкә дип пәке. Ул җиде йәпле пәке дип атала иде. Җизни пәкесе дип куанды. Җизни пәкесе үткер (*үткен*), карларны кисеп-кисеп шатланды. Балдызына – сеңелемә – җизни бүләге итеп йаулык.

Килен булып төшкәчтен, капкадан кергәндә килен әйбер ыргыта. Мамык перчатка, йон наски и бер сөлге. Капкадан кертми торалар килен утырган атны. Әйбер ыргытмыйча кертмиләр. Килен ыргыта да капка аша, шуннан кертәләр. Бийем мендәр чыгарып куйды. Зәйнетдин күтәреп алып мине мендәргә бастырды. Бал-май каптырып, өйгә алып керделәр. Ак күлмәк өстеннән алйапкыч бәйләп, башка йаулык. Көйәнтә, бидырәне (*чиләкне*) үзең алып төшәсең, бодай тутырып. Кырыңа куйасың. Көйәнтәне тегендә йегет бизәп тора. Бидерәне абзарга илтеп, бер атналык таwыкларга ашарлык килен азык алып килергә тийеш. Таwыклар алдына салалар. Шул бидыраларны көйәнтәгә эләсең дә, аннан су йулына алып киттеләр. Шишмәгә килгәчтен дә, йаулык эләсең. Свидетел'ләр суны алып бирә. Җилкәңә куйасың да көйәнтәңне, күмәкләп җырлап кайтасың.

*Бузат авылында*
*Нәзирова Миңнекәй Миңнебай кызыннан (1960 елгы)*
*язып алынды*

**Ышанулар.** Мин кышкылыкка шәһәргә кызларга торорга китәм. Тоз белән он куйып китәм. Өй ийәсенә ризык дип. Йорт

ийәсенә абзар кыйыкларына күмәч куйарга диләр, май сөртеп дип әйтәләр.

Абзарга да, тышка да койаш байыган чорда тышка чыгарга түгел. Җеннәрнең самай которган чагы була. Бер йарты сәгәттән соң бисмиллаңны укып чыга аласың. Икенде һәм акшам намазы арасында йокларга йарамай.

*Гобәйдуллина Миңсылу Нуртдин кызыннан*
*(1934 елгы, Бузат авылыннан)*
*һәм Мугаттарова Хәтимә Зәйнулла кызыннан*
*(1935 елгы, Хәлекәй авылыннан)*
*язып алынды*

**Яңгыр яумаса**. Бездә бер ебрәй (< рус. *еврей*) булган. Үлгәч зиратка күмгәннәр. Йаңгыр йаумаган да йаумаган. Шуннан Сафийа апалар һ.б. шуны казып алып, өч километр моннан йырак Күндрәк дигән йылга ага, шул Күндрәкнең арйагына итеп күмгәннәр тегене. Шул көйө которып йамгыр йауган. Шуннан коро йыл булса, барып шунда су сибәләр ийе. Шул ебрей йаткан җиргә. И йаңгыр йаwa иде ди. Бу 46–47 нчы йылларда.

Йаңгыр теләп, йаңгыр боткасы пешерәдерейек. Кемнән йоморка, кемнән он, ак май. Су буйында балаларны күп итеп җийып, йаңгыр теләп, су сибешеп. Суны һәркемнең өйөнә кереп сибеп. Әпәй күп булсын, ризык күп булсын дип.

*Әмир авылында*
*Шиһабетдинов Нурислам Гәрәй улыннан (1941 елгы)*
*язып алынды*

Йамгыр йаумыйча торса, чаукалыкка чыга торганыйык, ашарга пешереп ы$^{о}$лылар, әбиләр. Балаларны ашатып, укып, йамгыр теләп. Монанда (*менә монда*) турыда гына койо бар иде. Шуннан су алып, үткән кешегә су сибеп, бидерә-бидерә.

Кыш озату була торганыйы. Монау тугайга те$^{ө}$шеп, без бәләкәйрәк чакларда инде аркан тартышалар ийе. Уйн'ийлар ийе мәктәп балалары. Кыш озатуда.

*Көчегән (Өч-Әсән) авылында*
*Нурмөхәммәтова Тәнзилә Тимергали кызыннан (1947 елгы) һәм*
*Гафиятуллина Мөбарәк Муллагали кызыннан (1930 елгы)*
*язып алынды*

Йомгаклап шуны әйтәсе килә, сөйләм үрнәкләрендә күренгәнчә, Башкортстан Республикасының Стәрлебаш районындагы татарлар әби-бабалары тапшырып калдырган йолаларны, гореф-гадәтләрне ихтирам итеп, туган телләрендә аралашып гомер кичерәләр.

Стәрлебаш районындагы Әмир, Бакча, Бузат, Гөлем, Карагыш, Көчегән (Өч-Әсән), Хәлекәй авыллары татарларының көнбатыш диалектның стәрлетамак сөйләшенә каравы дәлилләнде. Татар әдәби теленең үсешендә көнбатыш диалект мөһим урын алып тора. Әдәби тел үзенең фонетик һәм лексик төзелеше белән урта диалекта якын торса, аның морфологик төзелеше көнбатыш диалектка күбрәк нигезләнә.

Көнбатыш диалектның башка сөйләшләрендәге кебек, стәрлетамак сөйләшендә дә сүз төркемнәре һәм аларның төп грамматик категорияләре, нигездә, татар әдәби телендәгечә. Үзенчәлекле саналган морфологик билгеләрнең күпчелеге теге яки бу морфологик категориянең яки күренешнең төрле фонетик вариантлары булып тора. Биредәге сөйләшләрнең үзенчәлекле билгеләре күбрәк фигыльләр өлкәсендә күзәтелә.

Татар теленең мишәр сөйләшләре лексик һәм фонетик яктан бер-берсеннән бик аз аерыла. Әдәби телдә очрамаган, сөйләшләрнең спецификасын тәшкил итә торган сүзләр шактый гына булса да, көнбатыш диалектның төп лексик составын татар әдәби теле белән уртак сүзләр тәшкил итә. Фонетик һәм грамматик үзенчәлекләрендә дә шундый ук уртак күренешләр саклана.

# БАШКОРТСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СТӘРЛЕБАШ РАЙОНЫ ТАТАРЛАРЫНА СӘЯХӘТ

*Фәрит Яхин*

*Вакыйга 2017 елның 29 маеннан 9 июненә кадәр барды.*

Бөек, тарих өчен дә, мәгънә хикмәтләренә бәйле дә гаҗәеп кызыклы сәфәрләр була. Стәрлебашны татарлар «изгеләр иле» дип беләләр, «Милләтнең затлы төбәкләреннән берсе», дип атыйлар. Бу чыннан да хак сүз сыман тоелды. Күңелем ничә еллар шул якларга тартылды. Барасы иде, күрәсе килә иде шуларны!..

Әмма берничә көн эчендә ул тойгы-фикерләрем тәмам үзгәрергә мөмкиннәр иде түгелме?

Менә шунысы куркытты.

Күңелне төрлечә әзерләсәм дә, юлымны язмышым Стәрлебаш якларына һаман да салмады. Әгәр дә анда хәлләр мин көткәнчә булмаса? Өметтә алдануларым моңа кадәр азмы газапка салмадылар, эчтән яндырмадылар, бавырымны гүяки көйдермәделәр?..

*29 май.* Иртәнге сәгать дүрт. Сәяхәткә чыгучы бер төркем галимнәр Казанда, Карл Маркс урамының 12 нче йортында урнашкан Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты бинасына җыелдык. Җитәкчебез Ильмир әфәнде Ямалтдинов – коры сүзле, катгый галимнәребездән берсе, соңга калмаска

алдан ук кисәтеп куйды. Шоферыбыз Наил әфәнде автобусны 4 сәгать 35 минутта олы юлга алып чыгып та китте...

Көн – суык. Әмма кояшлы булды. Урал таулары артыннан искән Себер җиле Төньяк диңгезенең култыклары боздан арчылудан хәбәрне ил буйлап менә шулай тарата иде булса кирәк?

Стәрлебашка кичен генә килеп җиттек.

Юл безне шактый талкыган, талчыктырган. Стәрлебаш үзәгендәге ике катлы заманча кунакханәгә урнашуга, бераз капкалап алдык та, һәркем үз ятагында җылы урынга чумды. Төн салкын булып, иртәнге якта исә дөнья бозга каткан кебек тоелды.

*30 май.* Без Куганакбаш авылына килеп җиттек. Монда 299 йорт булып, 20–30 ихатаны тәмам буш, диделәр. Куганакбаш халкын казакълар дип сөйләгән иделәр, юк икән, чынында татарлар булып чыктылар. Шул хакта сүз кузгаткач, көлеп кенә җавап кайтардылар. Ул гына да түгел, арада, казакълардан тыш, саный китеп, кияүләргә һәм киленнәргә килгәндә, русларның да, башкортларның, үзбәк-сартларның һәм тагын башкаларның булуларын искәртеп сөйләделәр. Мин инде «куганакбаш» сүзенең халыкта «ат караклары» буларак аңлатылуын, «казакъ» сүзенең, дөресрәге – «казак»ның, борынгыда «карак» дигән мәгънәгә ия булуын, телебез тарихын өйрәнүче галимнәрнең хезмәтләрендәге «*р*- тел» һәм «*з*-тел» дип аңлатып язылганнарны кузгатып тормадым. Ярар, халык хәтерендәгечә булсын, дидем: имеш, Куганакбашта ат караклары яшәгәннәр дә, казакълар арасына китеп, аннан яхшы атларны көтүләре белән куып алып кайтканнар, аларны киң һәм төпсез Россиянең кайнар базарларына таратып, өлгерлек белән иркен сәүдә оештырып, үз бөек мәнфәгатьләреннән арыны күрмичә, дин тотып, бит сыпырып, шөкрана белән гомер сөргәннәр.

Болар онытылмас бер-бер риваять кенәме, әллә чыннан да тарихта шулай булганмы? Сөйләнелгән сүзләргә таянып кына, моны ачыклау мөмкин түгел, заманалар үзгәргән. Кызыклы хәбәрләр телдә төрлечә кала, чуклана һәм ямьләнә инде алар. Хәзер сөйләп кара, алай түгел, болай ул, көлкегә алырлар... Берәүләр бу авылда

бөек ишаннарның яшәгәнлеген әйтә, икенчеләре халыкның эшкә булдыклылыгын телдән төшерми.

Авыл җирле идарә башлыгы Вилданов Фуат Хәйдәрович белән сөйләшәм. Ул 1959 елда туган, Нури-Ивановка, Юмахуҗа авыллары өчен дә җаваплы кешеләрдән икән. Аның әйтүенә караганда, Куганакбашта мәчет 1726 елдан ук булган.

Минем йөз чалымнарымда гаҗәпләнү билгеләрен күрепме, кабер ташларын күрсәтергә дип зиратка алып барды. Монда аның бабалары җирләнгән, язулы ташлары да бар. Шуларның берсе Кәлән бәк исеменә куелган, икенчесе – Тәмур бәккә. Анысы 1877 елда вафат. Таштан төрбә итеп төзелгән зур каберлек икән. Әмма тарих барышында төрбәсенең диварлары җимерелгән, ташлары чәчелеп ята.

Бу ташлар каршында үз чорында, яшь вакытында, билгеле, тарихчы Риза Фәхретдин басып торган, дога укыган, ташлардагы язуларны өйрәнгән, һәм ахырда, данлыклы «Асар» хезмәтенең 135 битендә Кәлән бәкнең тормышын яктыртып язган. Аның язып калдырган мәгълүматлары белән Фуат әфәнде таныштыр, әлбәттә. Миңа да үз белемемне күрсәтеп алу кирәктер кебек тоелды.

Бераз яңгыр сибәләп алды. Фуат әфәнде мине мәчеткә алып килде. Тумышы белән шушы авылдан, 1952 елгы булса кирәк, газпромда эшләүче Ишнияров Марат Хафиз улы төзеткән икән аны. Мәскәүдә яши, ди. Әнисе – Саҗидә. «Хафиз мәчете»ндә мин намаз укыдым. Фуат әфәнде янәшәмдә иде.

Аннары, әңгәмәне дәвам итеп, Фуат әфәнде тагын хатирәләренә бирелде. Аның агасы, Вилданов Зәйнулла Гыйззәтулла улы, мәктәптә директор булып эшләгән, менә болар шуның сөйләп калдырганнарыннан: Тәмур бәк бине Гүлдән шушы Куганакбашка Пермь якларыннан күченеп килеп, туфрагын үз күреп, монда урнашып калган. Тора-бара мәгариф эшен киң җәелдергән, мәдрәсә оештырган, халыкны тәрбияләүгә күп өлеш керткән...

Минем юлым авылдагы китаплы саналган берничә йортка кереп чыгу максатында дәвам итте. Озатып йөрүче хуҗаны олы һәм кичектергесез эшләре белән чакыртып алдылар.

Максат иткән беренче йорт Иргашова Гүзәлнеке иде.

– Мансур ихатасы бу, – диде ул.

Бу китаплы саналган йортта Яһүдина Миңҗиһаннан калган Коръән аятьләре кисәкләре, «Бакырган китабы» битләре саклана икән. Аларны зур байлык мәртәбәсенә куеп күрсәттеләр. Китапка хөрмәтләре өчен рәхмәтемне әйттем.

Аларның киңәшен тотып, Миңсылу Бухармәтова һәм Сәрия абыстайлар йортына юл алырга тиеш идем. Зәлифә абыстайларга тукталдым. Ә ул яңа басмалардан гына укый икән.

Галимҗан бабайга кердем. Ул үзенең Курамшиннардан, Казан ягыннан булуын сөйләде.

– Безнекеләрне «казанлылар» дип әйтә иделәр. Моннан 12 чакрымнар булыр, Турмай авылы бар. Анда төп йортыбыз булган,– дип искәртеп алды ул. – 1928 елда монда килгәннәр дә, ошатып, торып калганнар инде, төп йортны ташламаска тырышып караганнар... Карт әтиебез Зариф улы Латыйп сәүдәгәр булган, Бәләбәйгә, «Раевка станцасы»на күкәй сатарга йөргән...

Алардан соң юлым Галләм улы Искәндәров Хәйдәргә (1929 елгы) килеп тукталды. Хатыны Шәрәфетдин кызы Гамбәрә Искәндәрова (кыз фамилиясе – Сиражетдинова, 1927 елгы) башлангыч сыйныфларда, аннан озак еллар буена татар теле һәм әдәбияты укыткан. Аның 36 ел хезмәт стажы бар икән. Нәкъ минеке кебек. Ә мин фән галәмендә 36 ел хезмәт куям бит инде...

– Мәктәбебез зур иде. Татар телен бер мин генә түгел, Гайсәрова Фәүзия, Ибраһимова Рәйсә укыттылар, – дип сөйләп алды ул. – Хәзер кызыбыз Корбангалиева Гөлдар Хәйдәр кызы, ул татар телен укыта. Безнең кыз!

Килгәч-килгәч, Габдрахманова Нәҗия Миргали кызына (1938 елгы) кагылып чыгарга киңәш иттеләр. Аны эзләп киттем.

Нәҗия ханым мәктәптә 34 ел укыткан. Кызы Гөлнара Стәрлетамакта яши, улы шунда заводта эшли.

– Әтием Миргали исемле иде, руста батрак булып эшләп үскән. Әнием – Фатыйма, Гөлем авылыннан, бик гыйлем кеше иде. Ә аның әнисе –Мәчтүрә абыстай булган. Тугыз бала үстергән, барысы да малайлар, бер генә кыз – минем әнием Фатыйма

гына. Яшьли ятим калып, аларны 1920 елда балалар йортына алып киткәннәр. Шулай да берсе качып кайткан... Әтием Миргали кырыс кеше иде. Әнием Фатыйма ак әби булды, Коръән, догалар укый иде.

Туганнары Фатыйманы бик яратканнар. Ул озын толымлы булган.

– Күзе белән генә тәрбияләп үстерде. Хәтта «әйбәт йөрегез» дип тә әйтми иде. Үзең дә беләсең дигән кебек иде,– дип сөйли иде абыйсын...

Башта гармунчы егеткә кияүгә чыккан. Әмма ирен үтереп киткәннәр. Аннары күрше авыл егетенә кияүгә бара. Анысы да ике елдан үлә. Тормыш авыр. Варановка авылына кирпеч сугу эшенә йөри. Яшьлек дусты Мәфтуха белән (ул да Гөлемнән) Яңгырчы авылында Закир байга тегермән эшенә керә.. Аңа он биреп җибәрә икән, байдан яшереп. Мишәрләр икән болар. Байның хатыны көнләшә башлаган...

Әтием сүзгә оста иде. Әниемне кияүгә болай дип сорап чакыра бу: «Атым бар иде, атым батып үлде. Карт әтием бар, улым – бишектә, кызым – дүрт яшендә, чәчкән игенем бар,– дип. – Үзенчә бәет ясап...»

Ризалашалар инде...

Аннары юлым Мөлекова Әнвәрә Шәкүр кызына (1945 елгы) илтте. Ул да укытучы булып эшләгән.

Кемгә генә кагылсам да, Тәтер-Арслан авылына барырга киңәш иттеләр. Аларда дин көчле, диләр. Яшерган авылы халкы турында да шулай әйтәләр. Борынгы китаплар бары тик аларда гына, имеш. Кызыктырып, күңелгә ут салып куйдылар. Бүген үк шунда китеп барырлык хәлдә идем.

*Кичке алтыда Турмай (Кайраклы) авылына килдек.* Безгә Бакый, Эстәрле, Куганакбаш авылларының ат караклары авыллары булулары хакында кат-кат сөйләп өлгергән иделәр инде.

Бәхетебезгә Стәрлебашта язучы Зәки ага Зәйнуллинны эзләп таптык. Ул да безнең белән бергә Турмай (Кайраклыга) килде. Мондагы халыкның тырыш, гыйлем, акыллы булуы хакында

мәгънәле риваятьләр һәм истәлекләр сөйләп шаккаттырды. Язучы Хисаметдинов Исмәгыйль (Исмәгыйль Хисами) шушы авылда ике катлы таш йортта яши икән. Аның гаҗәеп матур бакчалары булуын, техника-машиналар ясатуын Зәки ага зурлап искәртте...

Авыл буйлап киттем. Менә Вәгыйзь һәм Мәгъния Надершиннар (1957 елгылар) йорты, икесе дә борынгыча укырга өйрәнеп киләләр икән. Алар авылда укымышлы кешеләрнең күп булуын сөйләделәр, Сәвилә әбигә кереп чыгарга киңәш иттеләр.

Сәвилә әби Биктимерова (1937 елгы), кыз фамилиясе – Насыйрова, тормышта Абдуллина буларак яшәгән. Олылап Коръән китабын күрсәтте. Әнисе Гөлнаүһәрдән калган олы мирасы! Шундый да кадерләп, матурлап саклый, китапка карата шушындый җылы мөнәсәбәтекә сокланып туймассың.

Курманаев Данияр Биктимер улы (1931 елгы). Үз кулында «Тәгълимес-салават» («Дога уку»), «Шәригать», «Мөхәммәдия» китапларын саклый.

Сәмәрханов Сәббах (Сөббух). Аның хакында гыйбрәтле вакыйгалар ишетергә туры килгән иде инде. 85 яшендәге бу бабайны халыкта күрәзәче-әүлия буларак беләләр. Сөйләүләренә караганда, 50–60 еллар элек, мөгаен 30 яшьләрендә булыр, ул мәрткә киткән. Аны фәрештәләрме, гаиб әйраннар яки изге рухлармы укытканнар, ул алар белдергән гыйлемнәрне язып кына утырган, имеш...

Сәббах бабай үзенең фуражир булып эшләгәнлеген генә искәртте. Гомерен гади хезмәттә уздырган.

– Тауга китеп йөрим икән, – дип сөйләде ул. – Арттан бер әби күзәтеп бара. Мин бит йокылы хәлдә. «Лунатик». Менә шул әби харап итте. Кире борып кайтарып җибәрделәр рухлар. Уятып кына әрәм иттеләр...

Аны халыкта «натуральный Ванга» дип атап йөртәләр. Әмма күрәзәләреннән мисаллар сорап газапламадым. Халыкка андый кешеләр дә кирәк, ахрысы?

Садыйкова Минзифа Минрахман кызы (1943 елгы) Коръән китабын саклый. Карт әнисе Садыйкова Мөнәвәрәдән мирас буларак калган. Ул аны укый торган булган. Карт әтисе Германда

әсирлектә булган, аның язып калдырган дәфтәрләре сакланган, әмма аларны кызларына биргән.

– Карт әти Кашапов Сәббах исемле иде, Миякә районы Ышыкбаш-Карамалыдан, – диде.

Аннары Каранаева Лилия Рәшит кызы (1974 елгы) – балалар бакчасы мөдире, Абдуллина Мәрьям Гыйлемҗан кызы (1930 елгы) үзләрендә сакланган китап кисәкләрен күрсәттеләр. 1970 елгы Батырова Ильвира шигырьләр яза, район газетасында аларны бастыра икән. Авыл халкы хакында башкорт Әхәт Каранаев:

– Пермь ягыннан күченеп килгәннәр болар, – дип сөйләде. – белүемчә, Каранай Морат оныклары. Ул Каранай Морат – Каранай авылын башлаган.

Миңа бу көтүче башкорт агайның үзенең дә Каранаев фамилияле булуы кызыклы тоелды. Әмма сүзебез күбрәк башкорт халкының борынгы риваятьләре, озын җырларына бәйле тарихчалар, батырлар хакындагы дастаннар хакында барды. Ул алар турында шундый белеп сөйләде, миңа тыңлавы күңелле иде. Ә ахырда:

– Болары гәзитләрдә күп языла, шулардан укыганны гына әйтәм,– дип белдерүгә, колакларым шиңеп төштеләр.

*31 май.* Йөрер юллар Яңгырчы авылына алып килде. Безне гармуннар уйнап, олылап каршы алдылар. Ул да түгел, мәктәптә элмә тактадан сурәтләр күрсәтә-күрсәтә лекция башлап җибәрделәр. 48 укучы баланы 9 укытучы укыта икән. Батталов фамилияле физикадан укучы төрле күләмдәге ярышларда өченче урынны яулап алып икән.

Бу авыл элекләрдә Өршәкбаш дип аталган, чөнки Өршәк елгасы моннан баш алган. 1700 елгы документларда да авыл бар икән инде. Елга баш алып чыккан урында мул сулы олы чишмә булган. Болай суы мул булгач, көннәрнең берендә суын агызып бетерер дә, елга югалыр дип куркып, аның баш очына имән чөй какканнар.

«Өршәк» – ирани сүз, имеш...

Миңа бу хәбәрләр бик тә кызыклы иде, чөнки чыннан да Әршәк шаһ хакында тарихлардан укып белә идем. Ул безнең эрага кадәр 200 елларда яшәгән, парфяннарның кабилә башлыгы, аннары шаһы булган, тарихта «әршәкиләр токымы» буларак танылган шаһлар тәхетен торгызып калдырган. Әрмәннәр һәм мөселманнар арасында бүген дә киң таралган исемнәрнең берсе санала. Миңа ул исем «эречәк», ягъни «эре сөякле» мәгънәсенә иядер сыман тоела, чөнки бу сүз «баһадир» дигәнне дә аңлата, «матур», «күркәм» дигән мәгънәләргә дә ия...

Бу авылда яшәүче әбиләр, җәйге көннәр корыга китсә, тауга менәләр дә, шуннан вак ташлар җыеп, елга буена киләләр һәм, теләкләрен тели-тели, ягъни Аллаһыдан яңгыр сорап, шул ташларын суга сибәләр, ди. Шуннан яңгыр яуган. Авылның исемен, торатора, «Яңгырчы» («Яңгыр яудыручы») дип атый башлаганнар...

Авылда музейлары бар. Гармунны «Тула иләге» дип атыйлар икән. Матур итеп, дөньяларны күңелле ясап уйнап җибәрәләр, шаккатып сокланып карап торасың.

1951 елгы Мирхәйдәрова Роза Гыймади кызында иске китаплар саклана. Китапларының ул Турмайдан карт әтисе – Галимҗан Курманаевныкы икәнлеген сөйләде. Динле кешеләрдән булган. Роза ханымда сакланучы китаплар Коръән сәхифәләреннән, Таҗетдин Ялчыголның «Рисаләи-Газизә» китабыннан һәм берничә кульязма китап кисәкләреннән гыйбарәт булып чыкты. Кульязма китап сәхифәләре арасында әдәп-тәрбиягә, аң-белемгә чакыру шигырьләре дә бар иде.

Роза Гыймади кызы мәктәптә математика һәм татар теле укыткан, эш стажы 36 ел булып, шуларның 32 елын мәктәптә мөгаллимә буларак уздырган. Аңа кадәр почтада эшләгән.

Кәримов Рифат Миңлегәрәй улы (1951 елгы) хәзер лаеклы ялда, ферма мөдире, бригадир, клуб хезмәткәре булып та эшләгән. Шәхси китапханәсендә иске китаплар, Коръән сәхифәләре саклана. Бер кульязма китапчыкны институтка тапшырды.

Юлымда Батталов Рәис Зөфәр улы (1960 елгы) очрап, ул Мөнирә Миңнегали кызына барырга кушты, аларда борынгы китаплар булырга мөмкин икән.

Мөнирә Тимербәкова 1944 елгы булып чыкты. Гомере буе фермада колхоз терлекләрен караган. Шәхси китапханәсендә басма гарәп графикасындагы берничә китап бар. Аларны аңа Мөсәббихә Ходайбирде кызы һәм Тимербәкова Гобәйдә әби биреп калдырган.

Гобәйдуллина Тәгъзимә Әфтах кызының (1943 елгы) әтисе муллалык иткән. Шуның мирасы буларак, иске басма Коръән китабын саклый.

Фәхриев Фәрит Мидхәт улы (1973 елгы) үзләрендә иске басма Коръәннең өлешләрен, шәригать китапларын тота.

– Мөзәфә әбинеке болар, – ди. – Карт әниемнеке.

Фәрит электрик булып эшли икән...

*Кичке дүртләрдә Гөлем авылына килдек.* Бу авылның исеме элек «Миллагол» булган, «Гөлем» аталышы да шул сүзне кыскартудан ясалган.

Бу хакта ишеткәч, күңелгә «Муллагол бәете» килде.

«Тукай шигыре» дип сөйләү милләтебезнең гадәтендә булган кебек, «Муллагол бәете» дә әсәрне авторына нисбәттә атаудан ясалган сүз, ягъни «Муллагол шигыре» дигәнне белдерә («Зөлхәбирә бәете» дигән кебек түгел).

Чынлыкта бәетләр алар трагик вакыйганы тасвирлыйлар, шул трагедия корбаны булган әдәби каһарманның авызыннан сөйләнеләләр. Ә «Муллагол бәете» (дөресрәге, бәетләре) алар – шигъри әсәрләр, хәер, алар да Муллаголның (ягъни лирик геройны) уй-кичерешләрен чагылдыралар. Димәк, бәет тә, шигырь дә лирик герой исеменнән сөйләнелә һәм аларны сөйләүче автор лирик геройның үзе буларак кабул ителә.

Ул Муллаголны (Миллаголны) кайбер галимнәр XVII йөз ахыры татар шагыйре Мәүлә Колыйга нисбәт итәләр. Әмма бу фикергә тәнкыйди караучылар да бар. Мәсьәлә әлегәчә чишелмәгән.

Гөлем авылы бер нәселдән үрчегән. Әйтүләренә караганда, монда барысы да Шәмәрдановлар икән.

Муллаларын белештем. Аның Ганиев Хәян исемле икәнлеген әйттеләр. Диндә иң укымышлы кеше дип Шәмәрданова Хәлимә

Ханнан кызын (1933 елгы) атадылар. Гомере буе колхозчы булган, ә китаплары – хәзергеләр.

Турмай мәктәбе музеенда борынгы китап бар иде. Аның ахыргы битендә Аланчы авылыннан Шәмсетдин улы Шәмсетдин, Стәрлебашта Нигъмәтулла мулла улы ишан Мөхәммәд-Харис мәдрәсәсендә китапны язып тәмам итүен теркәп куйган, ә китапны музейга тапшыручылар «Әтәч авылыннан Шыяп хәлфәнең үзе язган кулъязмасы, Шәмсетдинов Бариның карт әтисе» дип өстәп язып куйганнар.

Китап сәхифәләрендә су билгеләре бар. Бу – кәгазь җитештерү фабрикасы мөһерләре. Аның берләрендә – «г. Козловск № 5 КозБД», икенчеләрендә – «Татаровский № 6 Простасьева Фабрики», диелгән.

Бу кулъязма китапны институт фондларына бүләк итеп бирәчәкләр, имеш.

*1 июнь. Хәлекәй авылына килдек.* Аның исеме авылга нигез салган Хәлиулла исемле кешедән икән. Вакыйга 1754 елда булган. Бу авыл шул заманнардан бирле рус патшасы документларында яшәп килә, диләр.

Безне авыл җирле идарә башлыгы Фәрит әфәнде каршы алды. Мине Хәйруллин Таһир исемле кешегә җибәрделәр. Ә ул:

– Бер китабым да юк! – дип, куып чыгарды.

Аннан соң Галиев Җәүдәт Галимулла улы (1955 елгы) һәм Галиева Миләүшә Гәрәй кызы (1957 елгы) йортына килдем. Әниләре яклап бабалары Шәехмөхәммәд улы Габдулла үлән белән савыктыручы табиб-мулла булган. 1885 еллар тирәсендә туган, 1974 елда, туксан яшьтән дә узып, шактый озын гомер кичереп дөнья куйган.

– Китаплары күп иде, Әмир авылыннан Шиһабетдинов Зиннур аларны җыеп алып китте, – диделәр.

Сөйләүләренә караганда, Габдулла мулла шашынган адәмнәрне дә бер тәүлек эчендә имгә кертә торган булган.

– Тәберсәк кенә бер агайны, исемдә, төрмәдән качкан кеше иде, савыктырды бит,– дип сөйләде Җәүдәт әфәнде, шушы бабасын искә алып.

Алардан соң Хатимә Мөгаттарова, Рәйсә Галиева, Зиннур Салихов һәм башкаларда булдым, әмма алар борынгы кулъязма китаплар күргән кешеләрдән түгелләр икән.

*Әмир авылына килдек.* Монда 1974 елгы Шиһабетдинов Галинур Зиннур улы имам икән. Энесе – Илдар. Иске китаплар арасыннан зәңгәр тышлы кулъязма табып бирде. Аны «Мәүҗүт кызы Хәлимә дәфтәре» дип атады. Китаплары арасында иске басма Коръән, шәригать басмалары бар, Җ. Руминың мәснәвиләреннән төрек теленә тәрҗемәләре һәм шәрехләре әсәрләре саклана. Карт әтисе Ярулла Шәйхелисламовныкылар икән, ул да шушы авыл кешесе булган.

Аннан соң Басыйрова Сәбилә Сәлахетдин кызында (1952 елгы), Сәлимә Бәхти кызы Ардуганова да (кыз фамилиясе Хөснетдинова, 1938 елгы), Мәрхабә Гыйззәтулла кызы Бурясова да (Мәгъсутова, 1937 елгы) һәм башкаларда булдым. Кайсында иске басма Коръән китабы, кайсында башка төрле иске басмалар саклана.

– Әнием сакларга кушты. «Йәсин» чыгарга кеше булмаса, шушы Коръәнне күкрәгеңә куй, диде, «Йәсин» чыккандай булыр, – дип сөйләде Мәрхабә әби. – Гомере буе колхозда эшләде, Шәмсебанат исемле иде, Гыйльметдин кызы. 1903–1977 елларда яшәде. Биатам уразага өйрәтте. Бүген дә уразадамын. 16 яшемдә кияүгә чыктым. Аталы йортка...

*2 июнь.* Карагош авылына килдек. Марис исемле агайларга кердем. Әтисе Габдулла исемле булган икән. Сугыш елларында дусты (латыш) Марис исемле булган. Исән-сау кайтса, улы туса, шушы исемне бирергә сүз куйган. Бәлки «Абдул» исемле латыш та бардыр бу дөнья йөзендә? Аларның командирлары монгол булган, ди.

Бу Марис (1952 елгы) кулында «Һәфтияк» сәхифәләре саклана.

Аннары 1959 елгы Рәис Батыршинда, ары китеп, Әминә, Нәсимә дә, Туктаров Кәбирдә, Мәгъсүтов Ильяста булдым, аларда иске басма Коръән китаплары саклана икән.

Авылдагы мулла Кәбир Хәйрулла улы Наримановка тукталдым (1941 елгы). Балта остасы да булган, авыл советында рәислек иткән, 24 ел буена колхозның баш бухгалтеры эшен алып барган, ахырда колхоз рәисе урынбасары йөген тарткан.

– Мәчетне 1996–2001 елларда эшләттек,– ди, төзетү-күтәрү вакыйгаларын искә алып.

Мәчет китапханәсендә «Алты бармак», иске кулъязма китап кисәкләре, төрле догалык күчермәләре саклана. Мулла агай аларны берәм-берәм күрсәтә барды, дин төсе итеп саклаячаклар икән. Рәхмәт әйттем.

Юлымны дәвам итеп, 1931 елгы Рысаева Флера Каюм кызына тукталдым.

– Биемем борынгы китапларын кызларына мирас итеп калдырды. Салаватта яши иделәр, – дип сөйләде ул. – Мин үзем хәзерге китаплардан гына укыйм.

Фельдшер булып эшләгән.

Юлым төшеп, 1952 елгы Исхакова Зилә Ягъфәр кызына тукталдым. Мәктәптә биология һәм немец теле укыткан. Иске басма китаплары да бар икән. Шәхси китапханәсеннән шуларны күрсәтте. Арадан кайберләре: «Әстеван тәрҗемәсе», Коръән, фикһе төпләнмәләре.

– Карт әни, карт әти, атам ягыннан, ак әби, ак баба иделәр,– дип сөйләп китте ул. – Габделхаликъ, Гөлзәйнәп... Әнкәйнеке – Бибиҗамал... Гомәр – әти ягыннан, Гомәрнең әтисе – Әбүбәкер, аңа кадәр – Исмәгыйль...

Ул җиде буын бабаларын исемләп белә иде.

*Бакча авылы.* Имеш, безне бу авылда мунча ягып көтәләр...

Рәссам, татар эпитафик ядкярләре белгече Венер Усмановта булдым. Күп эшләгән, бастырып чыгарган хезмәтләрен күрсәтеп, гыйлеме белән мине таң калдырды. Аны чын талант иясе дип бәяләдем. Ул хакта үзенә дә берничә кат әйттем. Иптәшләр дә бу сүзләремне ишетеп тордылар. Китапларыннан берничәсен бүләк итеп тә бирде. Аларны институтның «Мирасханә»сенә һичшиксез тапшырачагымны әйттем. Үзем дә авыл саен дүрт-биш китабым-

ны бүләк итеп калдырып йөрүче кеше буларак, Венер әфәндегә дә өлеш чыгардым.

Бу көнне бик тә каты итеп яшенләп, гүяки өскә басып яңгыр яуды. Мунча хакында шаяртканнар гына икән. Яңгыр яхшы җебетте.

*3 июнь. Бузат авылына килдек.* Музейлары бар. Клубта. Анда «Кыйссасел-әнбия», «Иман шарты» сәхифәләре, Коръән кисәкләре саклана. Галим Марсель Әхмәтҗанов аларда булып, бу китапларны ачыклап, ни-нәрсә булуларын аңлатып язып киткән икән инде.

*Өшегән авылына килдек.* Авылның исеме чынлыкта «Өч Хәсән» дигәннән алынган икән. Әмма «Хәсән»е – «Әсән» булып киткән кебек, «Өч Хәсән» дә «Өшегән»гә әверелеп калган. Телдәге еш әйтелә торган сүзләр шулай инде алар, шомарып бетәләр.

– Өшегән – ушкуйлар, ат караклары авылы булган,– дип сөйләп алды 1947 елгы Әсәдуллин Миннәхмәт Гыйниятулла улы, сүзенең дәвамында авыл тарихларына кереп китеп, шактый кызыклы итеп аңлатып, бөтенләй дә башка вакыйгаларны да кузгатты: – 1974 елда Альмира туган иде. Колак артында йодрык кадәрле миңе бар иде. Картлар барып, аңа «Миңнури» дигән исемне куштылар, миңе бетте дә китте. Менә бит хикмәт!.. Анда, тауда, өстәл ясап утырып, чәй эчәрлек төпсәләр бар иде, агач төпләре... Муллалар, совет чорында куыла башлагач, олы-олы китапханәләрен, сандык-сандык, башкорт авылларына илтеп, аларда әманәт итеп, сакларга калдырганнар. Китапларны башкача исән тота алмаганнар. Үзләре белән алып китәргә ярамаган. Ә башкортта китап бар дип советларда белүчеләр юк икән. Соңыннан, ул муллалар кайтып, шул башкортларны эзләп табып, китапларын дәгъвалап та йөргәләгәннәр икән... Татар муллаларыннан аталарымы, бабаларымы алып калган китапханә Рәҗәп Кунысбаевка (башкортка) килеп ирешкән. 1953 елгы. Ырыс бай авылында икән. Күн тышлы, кара, олы китаплар... «Кыйссасел-

әнбия», «Тәфсир», Коръән... Күп инде, күп... Безнең татар укымышлы булган, китап яраткан...

Мотыйгулла улы Гайнетдинов Сәхиулла (1965 елгы), әтисе Мотыйк аганың мулла булганлыгын сөйләде. Аларда иске басма фикһе, Коръән, «Мөхәммәдия», сәхабәләр турындагы китаплар булган. Шуларны күрсәтте. Бик күп укылып, алар тәмам таушалып беткәннәр, чын музей экспонатына әверелгәннәр. Бездә музейлар андыйларның кадерләре зур икәнлекне, халыкта укылуларын менә шушындый нөсхәләр белән күрсәтергә яраталар.

Сафиулла, Галимулла абзыйларда булдым, Камалова Назимә, Вәлиәхмәтова Хәдичә абыстайларга тукталып уздым. Аннары 1932 елгы Шәрифуллин Равил Хәбибулла улы һәм 1937 елгы Кәлимуллина Мәрьям Лотфулла кызында булдым. Алар:

– Бернинди китап та укымыйлар иде... Бездә Мәрфүга әби бары тик «Йосыф-Зөләйха»ны укый иде,– дип, кат-кат әйттеләр.

Түрләрендә – кунакка кайткан башкорт хатыны утыра. Ул:

– Бездә иске басма Коръән саклана. Ләсәем Газыймәдән калган китап иде, аны гарәпчә укый иде. Латаем Коръәне тузып беткән, – дип, кайнарланып сүзгә катнашып китте. Аның «ләсәем»е – «дәү әнием», «латаем»ы – «дәү әтием» икән.

Алардан соң Садретдинова Миннур Миннегали кызына кердем. Ул 1946 елгы икән.

– Әтием 1896 елгы иде, – ди. – Аның китаплары күп иде, намазларын укый иде. Миңнебаев Арыслан улы булган. 1945 елда сугыштан имгәнеп кайтты, каты яраланып. Колхозда эшләде барыбер. Үзем «доярка» булып эшләдем. Мин – Гали Бузаттан. Ул авыл бетте инде. Китапларны кендек әби Зәкия Гыйлемҗановага биргән идек. Көтү белән йөргәндә, зиратка керсәм, китапларыбыз – бер капчык, шуны кабер янына куеп киткәннәр. Күмгәннәр инде аннары. Карадым да киттем. Катышмадым. Малаена әйттем, анысы... Бездә Асия бар. Ул дин тота. Анда бардыр китаплар?. Аннары, Галимуллага бар, яшел капкалы йортта. Борынгы кеше. Булса – анда булыр...

Шуларга киттем.

Галимулла Сәмигуллин, Вәлиулла улы (1929 елгы). 35 ел буена фермада эшләгән, яланда сыерлар көткән.

– Инәйнең әтисе мулла булган – Габдеррахман. Инәй – Мәшрүфә, укый, әмма яза белми иде. Латин белән язып-укып йөри иде. Борынгы китаплары калмады, хәзергеләре генә бар... – диде ул. – Элек Җангир бабай бар иде. Бүзат, акбүзат калдырып киткән, бер хаҗга китешли. Адарынган булыр? Әти шулай сөйләде. Тимербулат бабай мулла булды. Эчә-сүгенә торган Сәетгәрәй дә, иманга килеп, мулла булды. Аннары, аңардан соң, мин йөрдем 20 еллар. Хәзер Назыйров Биктимер, укыган кеше, ул мулла булды...

Авылда тәмам арып-бетеп йөри торгач, кабат музейга килдем. Монда яшел, чигешле намазлык бар иде. Аның өч урынына матур итеп язып бәетләр чигелгән.

Урамда дөньяны агызып китәрлек итеп яңгыр койды. Минем өстем-башым энәдән-җепкәчә шыр су иде. Туңып та алдым... Ә иптәшләр юк та юк. Аларны эзләп йөри торгач, тагын да шабыр суга баттым. Алар, бәхетле җаннар, кешедә җитмешенче чокыр чәйләрен эчеп утыралар икән.

*4 июнь. Яшерган авылына килдек*. Боларның даны күрше-тирә якларга киң таралган. Авыл исеме телләрдә олы бер соклану авазларына кушылып әйтелә, халкын – бәхетле, туфрагын – изге, диләр.

1942 елгы Мохтаруллин Һидаятулла агайга барырга куштылар. Үзе дә кулъязма дәфтәрләр төзеп, догалар җыйный, мөнәҗәтләр, касыйдәләр туплый икән. Әнисенең дә дәфтәрләре аның кулында саклана, диләр. 1905 елгы Җәмилә Фәйзрахман кызы булган икән ул, 78 яшенә кадәр яшәгән.

Мине Хәсәнов Илдус Галинур улы (1980 елгы) үзе артыннан ияртте. Йон эрли торган орчыклар ясый белә икән. Бер-бер һөнәргә өйрәнермен дип, аңа кушылдым. Яңа һөнәр үзләштергәч, үз юлыма төштем. Илдус миңа Булатов Фәриттә борынгы китаплар барлыгы хакында искәртте.

Авылдагы иске мәчет 1946 елда салынган икән. Агачтан. Күрше авылларыннан бер русның йортын сатып алганнар да, сыерлар җигеп, шуны ниргәләп ташыганнар.

– Картам Сәяхов Фәсхетдин оештырып йөргән… Галиев Назыйм Вәлиулла улы имам булып торды, – дип сөйләде Галиева Наилә Вәлиша кызы (1931 елгы).

Мәчет китапханәсе белән таныштым. «Мөхәммәдия», «Алты бармак», Коръән, «Хәятел-хайванат» энциклопедиясенең икенче томы, «Ислам мәҗәлләсе» журналы төпләнмәсе (1925 елгы саннары), «1963 елда Рамазан аенда җыйнап, мулла Ибраһим Исмәгыйль бине Кәшәфетдин» дип язып куеп, иске басма Коръән китабы тапшырганнар. Тышлыгы эченә мондый шигырь дә күчерелгән:

Намаз укымый дөньяны куабыз,
Авыр эш кебек авырсынабыз.
Укысак намаз – тәнебез пакь булыр,
Аллаһ каршында йөзебез ак булыр.

Ходa кушканны һич тыңламыйбыз,
Газап кылырдин һич уйламыйбыз.
Аллаһ безләргә динне яраткан,
Иманлы итеп безне тараткан.

Бу дөнья безгә мәңгелек түгел,
Гыйбадәт кылу авыр эш түгел.

Назыйм мулла белән Наилә абыстай һәр китапны кем тапшырганлыгын исемләп атап әйтеп бардылар. Аларның китапларының барысын дә урыннарында калдырдым. Мәчет алардан башка ятим булыр сыман тоелды. Андый китапларны алып китәргә ярыймы соң?!

Юлымны дәвам итеп, 1932 елгы Булатов Фәрит Шәрифулла улында, 1937 елгы Булатова Разыя Сәетгәрәй кызында булдым. Алар 1905–2002 елларда яшәгән Булатова Мөнәвәрә Бәхтияр кызының кульязма дәфтәрләрен саклаганнар, шуларны институт «Мирасханә»сенә тәкъдим иттеләр.

*5 июнь. Тәтер-Арслан авылы.*

Монда безне ипи-тоз, җыр белән каршы алдылар. «Тәтер» – елга исеме икән. Халыкта ул сүзнең мәгънәсен «уңышлы

җир» дип аңлаталар. Атлас карта-хариталарны өйрәнеп утырганда, Кавказда шушы исемдәге елга барлыгына игътибар иткәнем бар иде, ул «татар» дигән сүздән үзгәртелгән икән иде, имеш…

Тәтер-Арсланда авыл тарихын шулай сөйлиләр: «Арыслан Бикмәтов исемле бер кеше булган, ул Оренбургта писарь хезмәтендә икән. Мондагы җирләрне ул сатып алган, диләр, башкортлардан».

«Башкорт җире» дигәнне ишеткәч, миндә һаман да сорау туа: «Әгәр дә элек-электән Идел-Урал буйлары татар җирләре саналган, монда татарлар бөек дәүләтләр төзеп яшәгәннәр икән, ничек соң бу җирләр башкортныкы булып атала башлаганнар? Бер дә мантыйкка сыешлы түгел!» Аннары үземне тынычландырам: «Аңа кадәр бу җирләр скифларныкы булган, аннары – һуннарныкы!.. Ә хәзер – Башкортстанныкы!»

Тәтер-Арслан исемле бөек бер каһарман булып, ул Ырсай батыр белән сугышып, аны аркасы белән салган икән, имеш. Башкортлар шундый риваять сөйлиләр, ди. Ә арысланнар бу әкиятне көлеп кенә искә алалар.

Татарстанда да Тәтер елгасы бар икән, Ә мин – белмим. Каргалы янында «Тәтер аланы» бар, диләр. «Бабаларыбыз шуннан»,– дип сөйли мондагылар һәм җыр сузып моңланалар:

Авыр чакта кайтып сыенырга
Туган ягы кирәк кешегә!..

– Сакмар елгасы буенда ул Тәтер яланы, Оренбургта!..

Безгә клубта концерт бирделәр, җырладылар-биеделәр, үзара котлаштылар. Тәтер-Арсланның 700 йортлы чаклары да булган, ул хәзер 450гә калган. Урта мәктәп эшләгән, анда тирә-юньнән килеп укыганнар. Авылда больница да булган.

– «Арыслан икмәге» дигән сүз бар иде искеләрдә,– дип, куанып сөйләделәр. – Аны алырга килә торганнар иде. Колмактан гына тәмле итеп пешергәннәр, чүпрә кушмыйча. Авыл укымышлы булды гомер-гомергә. Арысланнар булдыклы да, эшчән дә халык. Спортта да шулай булдылар, ярышларга барсак:

«Арысланнар килгән!» – дип, куркышып тора иделәр. Шундый бездә халык, шундый! – диделәр.

Авылда 1050 кеше яши икән, шуларның 360 ы – пенсионер, ди. Усманова Нәсимә Мәдәният йорты эшләрен алып бара; Мөхәммәтшина Гүзәлия – шагыйрә, композитор. Рифкать Шәмгун улы, Ришат Нәгый улы Татарстан Язучылар берлегендә. Нурия ханым – китапханәче, Рамил әфәнде – музей һәм мәктәп директоры.

Юлыбыз ике манаралы мәчеткә китерде. Аны шушы авылда туып үскән, Уфада ФСБда хезмәт итүче полковник Ибраһимов Рәшит Таһир улы 2011 елда төзетә башлаган.

Полковник белән күрештек. Ул үзе монда махсус, эш белән килгән иде, төзелешнең торышы белән кызыксынып кайткан.

– Тиздән – гает, мәчетне гаеткә зурлап ачабыз, – диде ул, гамәлләренә көчле горурлык хисләре кичереп.

Монда мәдрәсә дә буласы икән. Гарәп графикалы язма китапларны туплап, искесен дә, яңасын да, билгеле, китапханә һәм архив та оештырган, алар өчен шкаф-шкаф җиһазлар, ябулы киштәлекләр кайтарткан.

Сүзгә Ибраһимов Фәнис Шәрифулла улы кушылып китте:

– Иске, борынгы китаплар бар иде бездә дә,– диде.– Уфага җибәрдем. Тышлары бик таушалган иде. Яшерганнар – бик ипле, итагатьле халык, айдарәлеләр – ярпач… Без – арысланнар, базарлы халык, кәсеп-сәүдә кешесе, уку кешесе булган. Салаватов Гапсаттар, Тамирдаров Гарифулла – болар Стәрлебаш мәдрәсәсен бетергәннәр. Мостафин Габдрахман, совет вакытында, мулла булганы өчен алып киткәннәр, 1937 елда. Кайтармадылар. Югыйсә ул аклардан кызыл коммунистларны яклапйолып алып калган булган… Рысаев Бакый ага бар иде. Өен сүткәндә, кыек башыннан борынгы китаплары килеп чыккан. Салаватов Габсаттар ага вафат булгач, китапларын үзе белән күмделәр. Шулай кушкан. Җитмешенче елларда шулай итә иделәр шул...

Авыл буйлап Илсур Габделрәхим улы мине машинасында озата йөрде. Зур рәхмәт аңа!

Менә 1939 елгы Рысаев Рәфкать Шәмгун улы янына алып килде. Аның китапханәсендә 1903 елгы басма Коръән китабы саклана икән. Аны күрсәттеләр.

– Әнием Мәрьям Габделхәбир кызыннан мирас. 1906 елгы иде. Намаз укыды, ураза тотты. Колхозчы иде. Әтисе, Габделхәбир бабам, өенә җыеп, балалар укыткан, аларга дин гыйлеме биргән. Хәзрәт иде, мулла… – дип сөйләде ул.– Мәктәптә укыганда шигырьләр яза башладым, район газетасына язышa идем… Уфага китеп авыл хуҗалыгы институтына укырга кердем, ветврачлыкка. Әдәби түгәрәк бар иде. Анда йөрдем, ахырда мине шуның җитәкчесе иттеләр. Газеталарда әсәрләрем басыла иде. Бишенче курста укыган вакытымда «Кызыл таң» газетасына редакциягә эшкә алдылар. Ул вакытта баш редактор Таһир Ахунҗанов иде... Укуны бетергәч, авылга кайтып, өч ел ветврач булдым, аннары район газетасына эшкә күчтем. Монда да өч ел эшләгәч, авылга кабат иске эшемә кайттым. Ә сиксәненче елларда кабат яза башладым. «Кызыл таң»да еш басылам, «Өмет»тә, «Һәнәк»тә, «Чаян»да язышам. Башкортча да язам, басылам... 2013 елда «Казан утлары» безнең унлап кешенең әсәрләрен бастырды. 2010 елда Хисмәтуллин Исмәгыйль, язучы-шагыйрь, милли җитәкчебез, Татарстан Язучылар берлегеннән берничә әдипне алып килеп, мине Союзга алдылар...

Озатып йөрүче Рысаев Илсур Габдерәхим улы (1952 елгы), юл дәвамында мине авылның шактый кешеләренә алып керде. Аларның шәхси китапханәләрендә иске басма китаплар шактый иде. Илсур әфәнде үзе, 25 ел гына түгелдер, табигать, һава торышы күренешләрен, көн дә язып алып, анализлап бара икән. Ул шул күзәтүләре нигезендә унике еллык хайван ел календареның дөрес төзелгән булуына тәмам ышанып җиткән. Бүгенге көндә дә ул календарьны эшкә ярашлы дип аңлатып сөйләп алды.

– «Әтәч елы»на – «Әтәч елы» туры киләчәк! – дип белдерде ул.– Күреп торырсыз, мәсәлән, 2020 елның язы иртә киләчәк!

Бу – аның күзәтүләре. Хәер, халык акылының ышанычлы булуына тагын бер раслау сүзләре түгелме?

1949 елгы Шәрипова Фәүзия Муллахмәт кызына тукталдык.

– Әниемнән мирас буларак калган иске китапларым бар, – дип күрсәтте ул үз китапханәсен. – Унике баладан унысы үстек. Әтиебез бәхет эзләп чыгып киткән. Канал төзегән. Бистән авылыннан, Пензадан монда килеп йөргән. Чибәр булган... 1910 елгы иде, Фазыйлә Гарифулла кызының кулъязма дәфтәрләре дә миндә саклана, аларда төрле догалыклар, «Мәүлет касыйдәләре» күчермәләре генә, бәетләр...– диде ул.

*6 июнь. Солтанморат авылында булдык*. Күпме генә тырышып барласам да, бер кулъязма китап та табылмады.

*Аннары Айдарәле авылына килдек.* Аның 1749 елда нигезләнгәнен сөйләделәр. Мөгаен шул елдан патша документларына Россия кул астындагы авыл буларак теркәлгәндер? Аңа кадәр алар башка тәртипләр һәм бөтенләй бүтән төрле тарихлар белән яшәгәннәр, билгеле.

Авылларындагы мәчет 1992 елда төзетелгән, аны күтәрергә Согуд Гарәбстаныннан бер ханым акча биргән. Анда мәдрәсә һәм китапханә бар. Иске басма китаплардан Коръән, хәдис тупланмалары, «Мәүлидүн-нәби», «Рисаләи-Газизә» һәм тагын да ике киштә иске басма китаплар бар, арада берничә кулъязма да очрады. Фән өчен кызыклы тоелган иделәр. Институт «Мирасханә»сенә кулдан язылган сигез дәфтәр бирделәр, арадан берсе «Шәкерт дәфтәре» иде. «Галимнәр өчен, өйрәнсеннәр, белсеннәр өчен!» – диделәр, биргәндә сүз белән юллап. Мин елмаеп куйдым. Сорыйсы килде: «Ә сез галимнәрнең китапларын укып шушы кешеләр булгансыз түгелме соң?»

*7 июнь. Бакый авылында йөрибез.*

Халыкның сөйләвенә караганда, 1945 елда Яушев Фатих Таһир улы вафат иткән. Ул шушы Бакыйныкы икән. Репрессия корбаны булган. Әмма дә үз заманында бөек бер имам буларак танылган. Аның китапханәсе бай булган, әмма китапларын, совет кергәч, суга агызганнар. Әлбәттә, коммунистларның дәһшәтеннән куркып, бәласеннән башаяк котылырга теләп инде. Ул имамның

оныгы Шәүкәт шушы Бакыйда яшәгән. Совет чорында иске китапларны зиратка илтеп куя торган булганнар. Аннан аларны алырга кем дә шикләнгән, ул китаплар яңгырдан-җилдән, кардан-боздан харап булып череп беткәннәр.

Яушевлар нәселе Урта Азия якларына күченеп китеп беткәннәр икән инде, имеш. Шуларның берсе Шәрифулла исемле булган...

Юлым төшеп, 1938 елгы Байтимеров Юрис Сәйфетдин улы янына киттем. Аның укымышлы икәнлеген сөйләгән иделәр.

Ул уразада иде. Борынгы китапларны күргәне генә булганлыгын искәртте. Әмма кистереп:

– Китап юк! – диде. – Рәшиттә булыр, Шәүкәт абыйныкы, аннан сорагыз!..

Әмма, сөйләшә торгач, Шәмсетдин Мөхәммәд Кахстаниның «Җәмигуль-рамуз» («Символлар сүзлеге») кульъязма китабын күрсәтте. Тышлыгы алгалыгында мондый язуы да бар иде: «Ошбу китап иясе Мөхәммәд-Таиб вәлид Мөхәммәд Фатих Яушев дию мәгълүмдер». Китап Казанда Шәмсетдин Хөсәеновләр тарафыннан бастырылган, 404 сәхифәдән гыйбарәт. Битләрнең читләренә, өстәмә рәвештә, Таиб хәзрәт үзе дә сүз мәгънәләрен һәм фикри шәрехләр теркәп барган. Аның сугышка кадәр Әмир авылында укытучы булганлыгын сөйләделәр. Гаҗәеп укымышлы затлардан икән...

Аннары – кульъязма китап та чыкты. Олы, калын... Күчерүченең каләме матур, нечкә, затлы сыйфатта. Сәхифәләре – төзек һәм камил.

Аннары – иске басма Коръән китабын күрсәтте. 1915–2011 елларда яшәгән әнисе Байтимерова Шәргыя Закир кызының мирасы икән. Ә аңа указлы мулла Әхмәтшәрифтән калган.

– Әхмәтшәриф – карт атам, энесе Җиргәндә укыган. Ул шунда киткән. Полковой мулла булган. Габделнасыйр исемле икән. Әтиләре – Габделкәримнәр, Гафиевлар... Яушевлардан аерылганнар. 1829 елда безнең авылга күченеп килгәннәр. Мөхәммәдфатих Яушев монда бөек мулла булган... – дип сөйләде ул.

Аңлашылганча, Юрис аганың шактый бай китапханәсе булырга тиеш иде. Әмма ул берничә китап күрсәтү белән генә чикләнде. Хәер, халык байлыгы халыкта сакланырга тиеш. Мин шулай дип беләм. Китаплар һәммәсе иясе кулында калдылар.

Аннары мәчеткә киттем. 2002 елда халык аны өмә белән, 85 машина таш чыгарып күтәргән. Мисырдан да ярдәм иткәннәр.

– Зәликәев Илгиз (1967 елгы) Каһирәдә «Әл-Әзһәр университеты»нда укыды, шул тырышты, – диделәр. – Әхмәт исемле бер мөселманнан акча тапты...

Мәчеттә имам 1949 елгы Фәтхуллин Гаяз Нияз улы икән. Миңа мәдрәсәне, аның китапханәсен күрсәттеләр. Анда «Тәүзыйх», Коръән, гарәп теле дәреслеге кебек китаплар бар иде.

– Бу китапларны Байтимеров Рәфкать Гафият улы калдырган иде. Мәчетне ул торгызды, авылның мулласы иде. Тимерче булып эшләде. 1928 елгы идеме? – дип аңлаттылар.

Алга таба авылда, кемгә генә керсәм дә, бары тик бер генә төрле җавап ишеттем:

– Элек китаплар күп иде, аларны биреп бетердек инде!..

*8 июнь. Көнебезне Стәрлебашка багышладык.* Монда тарих һаман да тере иде.

Музейларында булдык. Кульъязма китапларны шактый туплаганнар. Әмма алар берсе дә тасвирланмаган. Мөмкин кадәр булышырга итеп, кайсы нәрсә икәнлеген язып чыктым. Арада дастаннар да бар иде.

Аннары Стәрлебашның тарихи урыннары белән җентекләп таныштырдылар. Монда данлыклы язучыбыз Зәки ага Зәйнуллин да яши. Мин инде бирегә килгәннән бирле аңарда көн дә була идем. Һәр кичне диярлек аңа барып, бу якларның данлыклы тарихларын сөйләттем, бай китапханәсе белән таныштым, аңа үземнең китапларымны да бүләк иттем. Зәки ага үз белгәннәрен язып, китап итеп бастырып чыгарып бара. Шунлыктан ул сөйләгәннәрдән язмалар алып бармадым. Ул аларны миңа караганда бермә-бер кызыклырак итеп сөйли һәм яза түгелме? Аның шәхси тормышы да гаҗәеп мавыктыргыч вакыйгалар белән тулы. Акыллы, туры

сүзле, катгый кеше, һәм дә шагыйрь җанлы. Аның бөеклегенә монда да сокландым. Халык та аны ярата, аңа соклана икән!

Стәрлебаш китапханәсендәге очрашуга чакырдылар. Анда чыгыш ясап, халыкка тугыз томда шигырьләремне, алты томда проза китапларымны бүләк иттем. Аларны китапханәнең уку залларына, фондына калдырдым.

Шулай итеп, бу сәфәремдә шактый затлы, хөрмәт иясе кешеләр белән таныштым, алар минем күңелемдә җылы хатирәләр калдырдылар. Әгәр дә аларның барысын да мәкаләмдә искә алмаганмын икән, гафу итсеннәр! Әле һаман да алар минем күңелемдә, бәлки киләчәктә язмаларыма әдәби каһарманнар буларак та кереп китәрләр.

# О КУЛЬТУРНОМ НАСЛЕДИИ И ИСТОРИИ СТЕРЛИБАШЕВСКОГО МЕДРЕСЕ

*Нурида Насибуллина*

На просторах России есть немало заповедных мест, ставших очагами культуры и просвещения. Стерлибашевское медресе (1720–1921 гг.) Стерлитамакского уезда Оренбургской (Уфимской) губернии получило известность дореволюционный период в России именно как центр татарской культуры и просвещения.

Исторические события, последовавшие после взятия Казани войсками Ивана IV: насильственная христианизация, колонизация края, невозможность получить образование, явились импульсом для развития просветительских идей. Позиции татарского духовенства, поддерживавшего просветительское движение, существенно окрепли после послаблений со стороны российского государства (указ Екатерины II о веротерпимости 1773 года, учреждение муфтиата в 1789 году, открытие учебных заведений в крае и возможность обучения там представителей татарского народа). Религиозный характер татарского просветительства стал отличительной чертой данного явления не только в начальный период, но и ещё на долгое время. Указанный историко-культурный феномен в судьбе татарского народа был неразрывно связан с борьбой за сохранение и развитие собственных культурных традиций, национальное самосохранение.

Главным событием в развитии образования в XVIII веке стало открытие в 1720 году медресе, которое впоследствии при-

обрело всемирную известность. Благодаря передовым философским и нравственно-этическим идеям просветителей, трудившихся в стенах духовно-образовательного учреждения, медресе на протяжении долгих лет сохраняло славу главного и, по сути, единственного центра общественной жизни татар этого региона. В стенах медресе получили образование Габдрахим Утыз-Имяни (1754–1836)[1], Абелманих Каргалы (1782–1833), Хибатулла Салихов (1794–1869), Шамсетдин Заки (1822–1865), Мифтахетдин Акмулла (1831–1895), Гали Чокрый (1826–1889), Габдулла бин Сает аль-Болгари (1836–1914), Гадельша Богданов, Хуснутдин Жданов, Гали Рафики (1890–1944), Тухват Янаби (1894–1938), Мухаммадшакир Тукаев, Абдулла Давлетшин, Мирсалих Бикчурин, Габдулла Сатыев, Абдулла Искандаров и мн. др.

Именно здесь вели активную просветительскую деятельность Тукаевы – самая знаменитая династия татарских педагогов XVIII – начала XX в. в Стерлитамакском уезде Оренбургской (Уфимской) губернии.

Мударрисам медресе приходилось самим разрабатывать график учебного процесса, подбирать и обрабатывать учебный материал, готовить планы и конспекты учебных занятий. Представитель татарского просветительства XVIII века – Габдерахим Утыз-Имяни аль-Булгари создал более 100 произведений. Он писал на старотатарском, арабском и персидском языках. Следуя традициям накшбандия-муджаддидия вначале своего творчества (в частности в работе над комментарием и словарем к трудам Суфи Аллахияра и Ахмада Сирхинди), Утыз-Имяни Булгари со временем стал более критичен к тарикату и его представителям (в частности, в поздних своих стихотворениях он достаточно смело обличал ишанов Бухары). В числе работ Утыз-Имяни аль-Булгари – труды по исламской философии, филологии, комментарии к книгам Гали, Атари, Джами, Руми. Великий поэт оставил нам 10 поэм – «Тохфэтел горабаэ ва лэтаифел газаэ» («Подарок

---

[1] https://studwood.ru/874751/kulturologiya/istoriya_prosvescheniya_tatarskogo_narod

обездоленным и притчи о терпении»), «Гаварифез заман» («Дары эпохи»), «Тэнзихел эфкяр фи нэсаихел эхъяр» («Добрые наставления для очищения мыслей») и др. Главные богословские труды Утыз-Имяни аль-Булгари того периода – «Ас Сайф ас сарим» («Острый меч»), «Джавахир ал байан» («Драгоценности разъяснения») и «Инказ ал-халикин мин ал-мутакаллимин» («Спасение погибающих от мутакаллимов»)[1]. Впоследствии отдельно изданные стихотворения и поэмы великого поэта вошли в сборник «Мохимматез заман» («Важнейшие проблемы эпохи») (1870 г.)[2].

Библиотека при медресе имела богатый книжный фонд, в котором насчитывалось более 65 тысяч книг. Было довольно много печатной продукции, выпущенной на татарском языке: большое количество газет и журналов, учебники, художественная литература, издаваемые в Уфе, Казани, Оренбурге. Библиотека пользовалась большой популярностью среди населения. По словам бывшего шакирда Стерлибашевского медресе Бария Ибрагимова, первая библиотека именовалась «Шәрык» («Восток»). Под таким названием существовала крупная библиотека и в г. Оренбурге.

В конце XIX века внимание к Стерлибашевскому медресе проявили и представители Петербургской академии наук. В частности, известный ученый-востоковед академик Василий Владимирович Бартольд, оставил свои впечатления от посещения башкирской земли: «Исследовав библиотеку Стерлибашевского медресе, внимательно и с наслаждением просмотрел рукописные книги, созданные 200–300, даже 500 лет назад»[3].

В рукописном сочинении «Болгар вә Казан төрекләре»[4] выдающегося религиозного и общественного деятеля Российского

---

[1] *Идиятуллина Г.* Глава 13. Духовно-религиозная атмосфера в Поволжье в XVII–XVIII вв. http://www.tataroved.ru/publication/jad/2/g13/

[2] https://nsportal.ru/shkola/kraevedenie/library/2018/01/23/referat-na-temu-pisateli-tatarskoy-literatury

[3] Вакыт. 9 июня 1913 г. С. 4.

[4] *Ризаэддин Фәхреддинев.* Болгар вә Казан төрекләре / китапны тәрҗемә итүче һәм төзүче Ә.Н. Хәйруллин. Казан, 1993. 287б.; Научный архив Уфимского научного центра РАН (НА УНЦ РАН). Ф. 7: Ризаэтдин бин Фахретдин. Оп. 1. Д. 13 (новый акт).

Востока, заседателя Оренбургского магометанского духовного собрания (1891–1906 гг.) Ризаэтдина бин Фахретдина содержатся сведения о более чем 100 мечетях Урало-Поволжского региона на рубеже XIX–XX столетий. В них охватываются культовые сооружения и персональные данные духовных руководителей 103 сельских и городских поселений, в том числе знаменитое на всю Россию мусульманский центр деревни Стерлибашево. Сведения ученого-востоковеда. служат отправной точкой для исследования.

В немалой степени расцвету Стерлибашевского медресе способствовала деятельность рода мурзы Богдановых, которые перебрались в Уфимское наместничество из Темниковского уезда. Выпускники медресе становились учителями, способствуя повышению образованности татарского народа. Особой порой расцвета медресе называют период начала XIX века. Гадельша хазрат (внук Умряка мурзы Богданова), будучи настоятелем медресе, был известен как ученый, автор немалого числа книг. Примечательно, что одна его рукописная книга, датированная 1779 годом, хранилась у ахуна Хуснутдина (прож. в деревне Балыклыкюль Аургазинского района Республики Башкортостан).

Гадельша хазрат умер в 1812 году, прожив 80 лет. После смерти Гадельши хазрата, указом от 22 августа 1813 года имамом медресе и мечети в Стерлибашево был назначен Нигъматулла бин Биктимер бин Тукай ас-Салаучи (1772–1844)[1] – родоначальник знаменитой династии ишанов Тукаевых. На этом посту он собрал богатейшую библиотеку. Кроме этого написал комментарии

---

[1] Нигъматулла аль-Эстерлибаши (Тукаев) (XIX), религиозный деятель. Был последователем и популяризатором идей А. Курсави. Мударрис медресе д. Стерлибашево Уфимской губернии (ТЭС, с. 381). Один из корифеев рода Тукаевых, который дал известных религиозных и общественных деятелей: сыновья Мухаммад-Харис и Мухаммад-Харрас – ишаны, внук Мухаммад-Шакир Тукаев – депутат 2-й и 3-й Государственной думы. Влияние рода, представители которого также были крупными землевладельцами, распространялись на Уфимскую и Оренбургскую губернии, Акмолинскую область, Букеевскую орду (Mozaffari, 1931. B. 66–67).

к богословским трудам, учебные пособия для курса медресе, лингвистические труды: персидско-тюркский словарь, сравнительно--сопоставительную грамматику арабского и тюркского языков (1794 г.)[1].

Первая половина XIX века ознаменована началом формирования татарского просветительства: помимо разработки проблем изучения истории, литературы, языка, устного народного творчества своего народа, ученые-просветители прилагали усилия по развитию светского образования.

Высокий уровень преподавания, демократический дух, царивший в медресе, привлекали тюрко-мусульманскую молодежь не только Волго-Уральского, но и других регионов. В Стерлибашевском медресе ежегодно в течение нескольких десятилетий обучались до 150 казахов[2]. При Нигъматулле Тукаеве Стерлибашевское медресе становится не только одним из крупных центров мусульманского образования, но и локальным центром братства муджаддидийа. Уроки, которые давал Нигматулла хазрат, вызывали большой интерес у слушателей. В тот период имя хазрата было на слуху у многих, и он являлся очень уважаемым человеком. Шигабутдин Марджани высказывался о нём следующим образом в своей книге «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар»: «Мулла Нигматулла Биктимир бин Тукай бин Урманай аль-Старли выходец из села Салауч Малмыжского уезда Казанской губернии имел много шакирдов. В своем крае пользуется огромным признанием. Он был одним из сторонников мировоззрения Абденасыра аль-Курсави и одним из его друзей»[3].

---

[1] *Умняков И.И., Туманович Н.Н.* Аннотированная библиография трудов В.В. Бартольда. Описание архива В.В. Бартольда. М. : Наука, 1976. С. 327–328.

[2] *Ямаева Л.* Суфизм на Южном Урале. https://posredi.ru/sufizm-na-yuzhnom-urale.html [дата обращения: 18.11.2020]

[3] *Шиһабетдин Мәрҗани.* Мөстафадел-әхбар фи Казан вә Болгар (Казан вә Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр) / китапны тәрҗемә итүче һәм төзүче Ә.Н. Хәйруллин. Казан, 1989 [1-е изд. в 2 т. Казань, 1883–1897 (араб. алф.)]. Б. 245–246.

Превращению в крупнейшее медресе и центр суфийского тариката накшбандийа-муджадидийа в Волго-Уральском регионе Стерлибаш обязан основателю рода Нигматулле Биктимер Тукай ас-Салаучи (1772–1844). Его предки переселились в Стерлибаш из деревни Салауч Малмыжского уезда Вятской губернии (ныне Балтасинского района Татарстана). Первоначально он обучался у мударриса Фазыла аль-Кизляви в медресе при мечети «Иске-Таш» Казани, Мухаммада Рахима Йусуфа аль-Ашити в Мачкаре и Габдуррахмана аль-Кирмани в Каргалах. Нигматулла и оба его сына Мухаммад-Харис и Мухаммад-Харрас Биктимеровы получили образование в Бухаре. Нигматулла в 1801 году выехал в Бухару, где проучился свыше 10 лет. Свои познания в учении и практике накшбандийа Нигматулла совершенствовал в общении с шейхом Абу Салихом Ниязкули ат-Туркмани. Там же он стал сторонником взглядов и другом великого татарского богослова Абденасыра Курсави.

Хазрат ввел преподавание основ богословия и права по книге «Новый комментарий к познанию веры Насафи» А. Курсави, что является первым примером изучения в медресе трудов этого выдающегося ученого-богослова. Тем самым уже тогда в Стерлибаше была принята доктрина о том, что человеческий разум не может обойтись без Божественного откровения.

Главными центрами суннитской идеологии для мусульман Стерлибашево были Бухара и Хорезм. Отсюда поступали все учебники и наставления по преподаванию. В Бухару и Хорезм направлялись те, кто стремился углубить свои познания в религиозных дисциплинах. Получив образование в крупных образовательных центрах, они возвращались на Родину и занимались преподавательско-наставнической деятельностью в качестве мударрисов и имамов мечетей.

Превращению Стерлибаша в один из главных религиозно-культурных центров в начале XIX века в немалой степени способствовали как внимание муфтиев Мухаммеджана Хусаинова и Габдессаляма Габдрахимова, влиятельных имамов и ахунов округа, многочисленных мюридов, улемов (например, Абдаррахима Утыз-Имяни) и даже казахских ханов Джихангира и Ширгазы,

так и подвижническая деятельность Нигматуллы Биктимера, превратившего, по словам Р.Фахретдина, Стерлибашевский медресе в настоящий «дом науки» [1]. Значима и реформаторская деятельность хазрата по превращению медресе в крупнейший суфийский центр региона: отменив местные обычаи (запрет джиены, празднования Навруза как Нового года, поминования усопших), ввел практику коллективных зикры, многодневных молений в мечетях.

Известный татарский религиозный деятель и историк Хусаин Амирханов (1814-1893) в своих «Булгарских хрониках»[2] представил такой портрет Нигматуллы-хазрата: «В Уфимском уезде, в деревне Стерлибашево, [жил] имам и мударрис Ниг‘матулла-ишан. Да ниспошлет Аллах ему Свою милость и прощение! Он был халифой Нияз Кулый (да простит его Аллах и воздаст Свою милость!). Медресе и ханака, созданные им, всегда были полны учеников, а сам он давал самые достоверные знания в области явных наук, да и других предметов. А сколько их, познавших [от него] [46] науку тариката[3] и ‘илмехаль, которые позже стали на путь наставничества! Со всей округи стекалось к нему множества людей. И, став его последователями, они. Словно звезды, освободились от темноты невежества! И это достопочтенное лицо, подхватив наследие Пророка Аллаха (мир ему приветствие!), всю свою жизнь было занято обучением как простого народа, так и знати различным шариатским наукам, ‘илме халя в тарикате. И тем самым вознес свою душу на самую вершину рая. Да наградит Аллах Всевышний его Своей защитой!» и посвящает марсию:

Он знал и шариат, и тарикат;
И как двукрылый ангел улетел.
Своим приверженцам он истину открыл;
А душу не жалел, как бабочка она взлетела.
Кто шел за ним – луне подобны!
Он в темноте невежества как солнце засиял;

---

[1] *Ризаэддин Фәхретдин*. Асар. 2 т., 9 җөзьә. Оренбург, 1904.

[2] *Амирханов Х.* Таварих-е Булгарийа (Булгарские хроники). М.: Изд. дом Марджани, 2010. 232 с.

[3] *Тарикат* – познания в области суфизма.

И путь прокладывал – итак всю жизнь!
Учил Исламу всех и старых, и заблудших.
Небесный трон, земля и небо – в горе!
Рыдают как сироты – не перенесть разлуки!
(Стих состоит из 34 строк.
Пер. со старотат. А. Ахунова) [1].

По стопам отца пошли и сыновья Нигматуллы-ишана – Мухаммад-Харис (1810–1870) и Мухаммад-Харрас (1814–1871). После Нигматуллы хазрата руководителем медресе становится Мухаммад-Харис[2]. Из Хаджа он привез и передал в дар библиотеке медресе рукописные книги, по которым потом обучались шакирды. Он был мюридом бухарского шейха Убайдуллы – сына Ниязкули ат-Туркмани, у которого получил иджаз-намэ – разрешение на воспитание мюридов. В это время значительно возрастает число прибывающих на учебу шакирдов, еще больше совершенствуется, расширяется объем знаний, даваемых воспитанникам. Примечательно, что Мухаммад-Харис обладал прекрасным педагогическим даром. Указом Александра II в 1869 году руководитель медресе Мухаммад-Харис удостоен звания тархана[3].

«Таварих-е Булгарийа» Хусаина Амирханова есть такие строки: «Совершивший хадж в два святых города, проживавший в Стерлибашево, Мухаммад-Харис б. Ни‘матулла-хазрат был очень образованным, трудолюбивым человеком. Считался совершенным муршидом. Обучался в Бухаре у Нияз Кулыя, был его халифой и [духовны] преемником, а также у совершеннейшего мюршида Махзума-хазрата. Идя по стопам своего отца, давал уроки по явным и скрытым наукам. В 1870 году он отправился на милость Аллаха Всевышнего!

---

[1] *Амирханов Х.* Таварих-е Булгарийа (Булгарские хроники). М.: Изд. дом Марджани, 2010. С. 67.

[2] Мухаметхарис Нигаметуллин (Тукаев), по архивному источнику, имам-хатыпом и мударрисом Стерлибашевской мечети стал по указу Оренбургского губернского правления за № 14816 от 20 октября 1845 г. См.: ЦГИА РБ. Ф. И-295. Оп. 10. Д. 66. Л. 106.

[3] http://kcobrb.ru/media/attaches/page/history

Мухаммад-Харис б. Ни‘матулла-хазрат был деятельным ученым. Он продолжил дело своего славного отца, подобно Пророку-солнцу, который стал наместником на земле Господа двух миров. Он обучал явным и скрытым наукам и покинул этот бренный мир в 1871 году. Он обучался у упомянутого выше Махзум-хазрата, был современником этого ничтожного [раба Божьего]. И не было равных ему щедрости!» и приводит марсию, посвященной Харрас-хазрату:

[47] Всевышний, Ты Прощающ – это правда;
Нас к смерти испрошающих числу не относи!
Добром он кончил, как и жил в добре;
Достиг всего во всем.
Давал огонь сердцам;
И пусть на ложе его гурии взойдут!
Прощающий – о, как прекрасно это имя!
Гафур – вот так прочтем мы дату смерти[1]
(По хиджре – 1287 г., по милади – 1871).

Также в книге дается информация об ученике Мухаммад-Хариса – Хибатулле б. ‘Абдулле: «Всю свою жизнь он провел в [деревне] Салавыч, служа имамом и мударисом. Был очень религиозным и набожным человеком, являлся халифой стерлибашевского Ни‘матуллы-хазрата. Автор многочисленных мунаджатов, а также стихотворного произведения, связанного с и‘тикадом»[2].

Прославил своего учителя и медресе и такой ученик Мухаммад-Хазрата, как суфий Гали Чокрый (1826–1889). Трижды бывший в хадже, Чокрый начинал свое обучение в различных медресе Уфимской губернии (Бирск, Белебей, Мензелинск). В 1849 году он отправился учиться в медресе шейха Мухаммад-Хариса аль-Стерлибаши. Ее основатель Нигматулла аль-Стерлибаши получил иджазу – свидетельство от шейха Нийазкули ат-Туркмани в Бухаре. Ему принадлежат Труды «Тәҗвид»

[1] *Гафур* (араб.) – «Прощающий», одно из «прекрасных» имен Аллаха. Буквенное обозначение числа 1287.

[2] *Амирханов Х.* Таварих-е Булгарийа (Булгарские хроники). М.: Изд. дом Марджани, 2010. С. 68.

(1860), сборники стихов: «Дәрри Гали» (1873), «Шәмг әз-зыя» (1883), поэма «Мәдхе Казан» (1889), книги религиозного содержания «Замме назыйр», «Тәрхибе рамазан», «Нәсим әс-саба» (1872), «Тәварихи Болгария, яки Тажриби Гари» (1879) и неизданные книги «Мәнзумате Гали», «Фосули әрбага».

Сын Мухаммад-Хариса Мухаммадшакир Тукаев (1862–1933) – известный общественный деятель, впоследствии депутат II и III Государственной Думы, автор нескольких исторических и публицистических работ. В рукописном фонде Государственной книжной палаты Республики Башкортостан хранится неопубликованная до сих пор рукопись сочинения Мухаммадшакира Тукаева под названием «Описание деревни Стерлибаш и Стерлибашевского медресе действительного члена Уфимского губернского статистического комитета, магзума Шакира Харисовича Тукаева». Эта рукопись детально проанализирована в работе Ш.Н. Исянгулова «Новые сведения по истории Стерлибашевских медресе и мечетей», опубликованной в книге «Из истории мечетей и медресе Башкортостана»[1].

В 1899 г. в Казани увидела свет книга М. Тукаева «Тарихуль Эстәрлебаш». Несмотря на то, что напечатана она была в арабской графике и для многих исследователей осталась малодоступной, среди узких специалистов (историков, литературоведов) данная книга по истории Стерлибашевского медресе пользовалась популярностью и авторитетным источником истории мусульманских учреждений края. Только в 2005 году благодаря переводу на современный татарский язык, сделанному В.М. Усмановым, рукопись стала доступной широкому кругу исследователей. Вследствие этого обнаружилось, что работа М. Тукаева «Описание», написанная им на русском языке, создана раньше – в 1890 году. Несмотря на то, что данное исследование опубликовано им не было, по объему превосходит «Тарихуль Эстәрлебаш» и также содержит немало ценных сведений по интересующему нас вопросу. Помимо истории знаменитого Стерлибашевского медре-

[1] Исянгулов Ш.Н. Из истории мечетей и медресе Башкортостана. Уфа, 2011. С. 71–100.

се, исследование М. Тукаева содержит ценные сведения этнографического характера: географическое положение деревни, каким образом осуществлялось землевладение, как организовывалось планирование улиц, домов, мечетей и другие. Сопоставляя два источника – «Историю Стерлибаша» и «Описание», современный исследователь обратит внимание и на такой любопытный момент: в «Описании», говоря о населении Стерлибаша, автор упоминает башкир, тептяр, но уже в «Истории» М. Тукаев прямо указывает, что стерлибашевский народ происходит из татар: «Стерлибашево было основано выходцами из Казанской губернии и Сеитовского посада на арендованных у башкир – вотчинников Тальтим-Юрматынской волости Ильчиктимировой тюбы землях»[1].

В отличие от «Истории Стерлибаша», раздел «Описания», посвященного истории медресе, является менее развернутым. Предвидя возможную цензуру, автор изъял из рукописи ряд сведений о том, что считает своими предками суфийских ишанов.

По архивным документам Центрального Государственного Исторического Архива Республики Башкортостан установлено, что на 1854 г. в Стерлибашево была зарегистрирована одна соборная мечеть. При ней числились два официальных священнослужителя: имам-хатип и мударрис Мухаметхарис Нигаметуллин (получил указ за № 14816 от 20 октября 1845 г.) и азанчей (муэдзин) Сагадитдин Биктимиров (получил указ 1 апреля 1837 г.)[2]. По Х ревизии 1859 г. в деревне было мужчин – 472, женщин – 454. В 1869 г. в медресе насчитывалось от 100 до 250 учащихся. Родной брат Хариса Харрас стал имамом и мударрисом указом Оренбургского губернского правления № 6808 от 31 августа 1856 г[3]. После смерти Хариса имамом стал его сын Габдулла (1844–1918), а после смерти Харраса – его сын Латыйфулла (1845–1878). По одним данным, Габдулла Тукаев (1844–1918)

---

[1] Исянгулов Ш.Н. Новые сведения по истории Стерлибашевских медресе и мечетей // Исянгулов Ш.Н. Из истории мечетей и медресе Башкортостана / отв. редактор Р.Н. Сулейманова. Уфа, 2011. С. 71–100.

[2] ЦГИА РБ. Ф. И-295. Оп. 10. Д. 66. Л. 106.

[3] ЦГИА РБ. Ф. И-295. Оп. 3. Д. 7205. Л. 56 об. –57.

стал имам-хатыпом и мударрисом 30 сентября 1871 г., по другим – 12 сентября 1872 г[1]. Латыйфулла Харрасов был назначен имамом и мударрисом указом Уфимского губернского правления от 16 марта 1873 г. за № 1193[2]. Губайдулла Харисович Тукаев был утвержден имамом и мударрисом указом от 19 сентября 1879 г. за № 3377. 31 мая 1887 г. стал ахуном. Второй сын Хариса Губайдулла (1850–1920) был утвержден имамом и мударрисом указом от 19 сентября 1879 г. за №3377. 31 мая 1887 г., стал ахуном.

2 и 3-я соборные мечети были построены в 1920 г. Резолюция о разрешении строительства принята 16 ноября 1920 г. Один из Тукаевых, Абдулгалим Хабибуллович (1892), стал имамом первой соборной мечети (по указу от 29 января 1921 г.). Муэдзином и мугаллимом первой соборной мечети указом от 30 сентября 1871 г. за № 3860 был утвержден Габдулла Галиев (1832). После него муэдзином предписанием Уфимского губернского правления от 25 февраля 1908 г. № 873 назначен Губайдулла Габдуллович Мухаметгалин. Имамом второй соборной мечети предписанием от 26 января 1921 г. утвержден Ахмедтагир Нуриманов (1869 г.р.). 13 февраля того же года муэдзином второй мечети стал Мухаметсафа Габдуллович Искандаров (1891 г.р.). Он в 1938 г. был арестован и осужден по ст. 58-10 УК РСФСР к лишению свободы на 10 лет[3].

История Стерлибашевского медресе довольно хорошо известна благодаря вышеуказанным работам М. Тукаева и Р. Фахретдинова[4]. В последующие годы историю Стерлибашевского медресе затра-

---

[1] ЦГИА РБ. Ф. И-295. Оп. 2. Д. 5. Л. 175; Оп. 3. Д. 7205. Л. 56 об–57.

[2] ЦГИА РБ. Ф. И-295. Оп. 2. Д. 6. Л. 204 об–205.

[3] Книга памяти жертв политических репрессий РБ. Уфа, 1999. Т. 2. С. 494; Реабилитирован в ноябре 1992 г.

[4] Ризаэтдин Фәхретдин: Фәнни-биографик җыентык [Ризаэтдин Фахретдин: научно-биографический сборник]. Казан, 1999; *Ризаэддин Фәхретдин.* Асар: 3 томда. Казан, 2006–2010; *Ризаэддин Фәхреддин.* Нәсел-ыруыбыз вә кыскача тарихыбыз. Казан, 2008; *Ризаитдин Фәхретдинов.* Һайланма әсәрзәр. Өфө, 2009; *Риза Фәхретдинов.* Йыуаныс. Өфө, 2011. 1 нсе китап; *Ризаэддин Фәхреддин.* Мәшһүр адәмнәр: «Шура» журналы сәхифәләреннән. Казан, 2012.

гивали в своих работах М.И. Ахметзянов[1], Ш.Н. Исянгулов[2], Н.Ш. Насибуллина[3] М.Н. Фархшатов[4], А.И. Харисов[5], Г.Б. Хусаинов, краеведы В.Л. Галеев[6], М.Г. Махмудов[7], Х. Гайсин, В.М. Усманов[8], Г.Г Басырова[9] и другие. Известный писатель и общественный

---

[1] *Әхмәтҗанов М.И.* Татар археографиясе (соңгы елларда археографик экспедицияләр вакытында тупланган кульязмаларның тасвирламалары). Сигезенче кисәк. Казан, 2011. 196 б.

[2] *Исянгулов Ш.Н.* Из истории мечетей и медресе Башкортстана. Уфа, 2010. 153 б.

[3] Насибуллина Н.Ш. История Стерлибашевского медресе сквозь призму рукописного наследия // Современная тюркология: язык, литература, история и культура тюркских народов: материалы VII Международ. тюрколог. конф., посв. Дню науки (7 февраля 2014 г.). Елабуга: Изд-во Елабужского института КФУ, 2014. С. 25; *Насыйбуллина Н.Ш.* Эстәрлебаш мәдрәсәсенең кульязмалар традициясе һәм мәдәнияте // Татарское рукописное наследие. Изучение и сохранение: материалы Всерос. конф., посв. 130-летию со дня рождения Саида Вахиди (19–20 октябрь 2017 г.). Казань: ИЯЛИ, 2017. С. 143; Тукаевларның дини һәм мәгърифәтчелек эшчәнлеге (Башкортстан Республикасы Стәрлебаш районының Стәрлебаш авылы мәдрәсәсе тарихыннан) // «II. Международный Саммит Невруз». III. Uluslararasi tatar tarihi-kültürü ve edebiyati sempozyumu. (Institute of Ekonomic Development and Social Researches). Turkey. Antalya (20–23 Mart 2019). С. 203; Тамырлардан танырлар // Мәдәни җомга. 2012. 3 август. № 31 (884). Б. 11–15; Тамырлар Эстәрлебашка илтә // Мәдәни җомга. 2012. 17 август. № 33 (886). Б. 14; 24 август. № 34 (887). Б. 14; 31 август. № 35 (888). Б. 15; Ерак еллар кайтавазы // Тулпар. 2013. № 5. Б. 60–65; Тамырлардан танырлар // Тулпар. 2013. № 6. Б. 36–38; Рухи ядкарьләрне барлап // Өмет. 2017. 26 май. № 21; Татар мөһаҗирияте матбугатында «Эстәрлебаш фаҗигасе» // Тулпар. 2018. № 3. С. 20; Башкортстан «Бохара»сы // Кызыл таң. 2018. 4 декабрь. № 140.

[4] *Фархшатов М.Н.* Народное образование в Башкирии в пореформенный период. 60–90-е годы XIX в. М., 1994.

[5] *Харисов Ә.И.* Башҡорт халҡының әҙәби мираҫы. Өфө: Китап, 2014. 464 б.

[6] *Галеев В.Л.* История народного образования села Стерлибашево. Уфа, Лето, 2009. 196 с.

[7] *Махмудов М.Г.* Стерлибаш, горжусь твоей судьбою! – Уфа: Белая Река, 2000. 310 с.

[8] *Усманов В.М.* Эстәрлебаш төбәгендә тарихи истәлекләр // Өмет. 2000. 7 июль; *Усманов В.М.* Тарихи ядкәрләр. Уфа: Дизайн Полиграф Сервис, 2005. Б. 58–128.

[9] *Басырова Г.Г.* Историческая судьба мусульманских женщин в деревне Стерлибашево. Казанский педагогический журнал . 2015. № 3. С. 152.

деятель З. Зайнуллин написал книги «Эстәрлебаш мәдрәсәсе»[1], «Эстәрлебаш дарелфөнүне»[2], «Тукаевлар»[3]. Все они опираются на известную работу «История Стерлибаша»[4] действительного члена Уфимского губернского статистического комитета, магзума Шакира Харисовича Тукаева.

Данная статья написана на основе изучения документов фонда Оренбургского Духовного Магометанского Собрания (ф. И-295), хранящегося в Центральном государственном историческом архиве Республики Башкортостан (ЦГИА РБ). В то же время в работе использовались ряд архивных документов. Это сочинение – Описание деревни Стерлибаша и Стерлибашевского медресе действительного члена Уфимского губернского статистического комитета, магзума Шакира Харисовича Тукаева, подлинник которого хранится в рукописном фонде Государственной книжной палаты РБ[5]. Оно намного полнее увидевшего в 1899 г. свет книги М. Тукаева «История Стерлибаша» и представляет несомненный интерес для историков, этнографов, религиоведов, краеведов.

Таким образом, деятельность просветителей, чьи имена были связаны со Стерлибашевским медресе, характеризуется многогранностью и разнообразием, их интеллектуальное наследие и на сегодняшний день сохраняет свою актуальность – в том числе и для исследования истории края. Выявление, описание, изучение и публикация рукописного наследия требует времени, концентрации усилий историков, филологов и других специалистов.

---

[1] *Зәйнуллин З.Л.* Эстәрлебаш мәдрәсәсе. Казан: нашире ШЭ Р.Х. Корбанов, 2011. 200 б.

[2] *Зәйнуллин З.Л.* Эстәрлебаш дәрелфәнүне. Казан: «Зур Казан» типографиясе, 2011. 296 б.

[3] *Зәйнуллин З.Л.* Тукаевлар. Стәрлетамак: Стәрлетамак шәһәр типографиясе, 2017. 288 б.

[4] *Тукаев Ш.Х.* Тарихи Эстәрлебаш. Казан, 1899.

[5] *Тукаев Ш.Х.* Описание деревни Стерлибаша и Стерлибашевского медресе действительного члена Уфимского губернского статистического комитета, магзума Шакира Харисовича Тукаева .1890 г. Государственная книжная палата РБ. Рукописный фонд. Папка № 6. Рукопись. Без пагинации.

# БАШКОРТСТАННЫҢ СТӘРЛЕБАШ РАЙОНЫ ТАТАРЛАРЫ ЗАМАН ФОЛЬКЛОРЫ

**(Халык иҗаты үрнәкләре)**

*Ильмир Ямалтдинов*

Башкортстан территориясе татарларның традицион яшәү урыны булып тора. Республиканың төньяк-көнбатыш өлеше тарихи рәвештә Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда һәм Казан ханлыгының йогынтысы астында, Казан өязе составында булган. 1708–1728 һәм 1731–1734 елларда республика территориясе (Уфа провинциясе) административ рәвештә Казан губернасына буйсынган. Идел һәм Урал буе территориясендә күп гасырлар дәвамында татарларның даими эчке миграциясе барган. Казан ханлыгы яулап алынганнан соң, татар халкының шактый өлеше үз яшәү урынныннан чыгып китәргә һәм дәүләтнең үзәк районнарыннан Урал алдына күченергә мәҗбүр булган. Татарлар үз авылларын булдырудан тыш, башкорт вотчинниклары авылларында да төпләнәләр. 1670 елдан Башкортстан территориясенә крепость һәм чик буе сызыкларында хезмәт итү өчен, Түбән Новгород һәм Касыйм районнарыннан йомышлы татарлар күчерелә. 1740–1750 елларда дәүләт салымы һәм христианлаштыру сәясәте көчәю сәбәпле, XVIII йөзнең икенче яртысында Урта Идел буендагы татарларның Урал алдына миграциясе яңадан көчәя[1].

[1] Республика Башкортостан // Регионы компактного проживания татар в Российской Федерации: справочник. АН РТ, Ин-т тат. энцикл. и регионоведения. Казань, 2016. С. 137–140.

Башкортстан төбәгендә яшәүче татарларның фольклоры белән кызыксыну ике йөз елдан артык элек башлана дияргә мөмкин.

Россия Фәннәр академиясе ачылганнан соң (1725), аның эшчәнлегенең аерылгысысз бер юнәлеше буларак, күпмилләтле илдә яшәүче халыкларның тарихын, этнографиясен өйрәнү максатыннан экспедияләр оештырыла. XIX гасырның беренче яртысында Казан университеты галимнәренең хезмәтләрендә дә татар халкының тарихына, рухи мирасына һәм фольклорына караган кыр тикшеренүләре нәтиҗәләре яисә башка чыганаклардан алынган материаллар бар[1]. Аннан соң да Башкортстан җирлегендә яшәүче милләттәшләребезнең авыз иҗатын өйрәнү эше татар галимнәре һәм әдипләре тарафыннан дәвам иттерелә.

XX гасыр уртасыннан Башкортстан татарларының сөйләшләрен өйрәнү өчен, телче-диалектологлар әлеге төбәкнең Яңавыл, Тәтешле, Аскын, Мәчетле, Бакалы, Балтач, Калтасы, Борай, Краснокама, Мишкә, Илеш, Дүртөйле, Бөре, Чакмагыш,Кушнаренко, Караидел, Дуван, Салават, Кыйгы, Туймазы, Бәләбәй, Шаран, Благовар, Бүздәк, Уфа, Чишмә, Кырмыскалы, Дәүләкән, Аургазы, Әлшәй, Бишбүләк, Миякә, Стәрлетамак, Стәрлебаш, Федоровка, Күмертау, Мәләүз һ.б. районнарына берничә тапкыр (1954–1957, 1965–1966, 1968–1975, 1977–1979, 1983–1984) экспедициягә чыга[2]. Галимнәр Ә. Әфләтунов, Җ. Алмаз, Л. Мәхмүтова, З. Садыйкова, Д. Рамазанова, Т. Хәйретдинова, Ф. Баязитова, тел материалы буларак, халык иҗаты үрнәкләрен дә туплыйлар.

Башкортстан татарларыннан халык авыз иҗатын системалы рәвештә җыю, туплау һәм аны фәнни өйрәнү өлкәсендә бәһасез эшне күренекле фольклорчы-галим, педагог һәм җәмәгать эшлеклесе Риф Мирхәбибулла улы Мөхәмммәтҗанов башкара. 1967 елдан алып ул республиканың татарлар күпләп яшәгән районнарына утызга якын фольклор экспедициясе оештыра, йөзләгән авылны

---

[1] *Ямалтдинов И.И.* Татарская фольклористика 20–60-х гг. XX века. Собирание, публикация и научное изучение фольклора. Казань: ИЯЛИ, 2016. С. 35–36.

[2] Атлас татарских народных говоров / отв. ред.: Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хайрутдинова. Изд. 2-е, доп. и перераб. Казань: ИЯЛИ, 2015. С. 28–36.

өйрәнә. Риф ага Мөхәммәтҗановның иң зур казанышларының берсе – БДУның татар филологиясе кафедрасы каршында фольклор фонды оештыру. Соңрак фондта тупланган материалларның икенче нөсхәсе хәзерге Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының фольклор фондына тапшырыла.

Башкортстан Республикасының Стәрлебаш районында яшәүче татарларның халык авыз иҗат үрнәкләрен туплау максаты белән 1971 елда галим Фәрит Миргалим улы Хатипов җитәкчелегендә фәнни экспедиция оештырыла. Башкорт дәүләт университетының татар бүлегенең беренче курс студентлары Стәрлебаш, Яңгырчы, Хәлекәй, Бузат, Тәтер-Арслан, Кызыл-Яр, Айтуган, Өч-Әсән, Карамалы-Бузат, Гали-Бузат авылларында кыска һәм озын җырлар, такмаклар, мәкаль һәм әйтемнәр, табышмаклар, мәзәкләр, юрамышлар, арбаулар, сыктаулар, легендалар, сынамышлар, бәетләр, мөнәҗәтләр, әкиятләр һ.б. фән өчен бик кыйммәтле халык иҗаты материалларын бөртекләп җыеп алып кайталар. Экспедициядә катнашкан студентлар өчен бу, беренче чиратта, һичнәрсә белән алыштыргысыз аралашу мәктәбе була.

1973 елда Стәрлебаш районында Башкорт дәүләт университетының татар бүлеге доценты Риф Мөхәммәтҗанов тарафыннан да халык җәүһәрләре үрнәкләре язып алына.

Стәрлебаш районында яшәүче милләттәшләребез дә күңелләрендә сакланган халык иҗаты үрнәкләрен Казанга – Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына язып җибәрәләр.

Әлеге материалларның бер өлеше Институт әзерләгән «Татар халык иҗаты»ның унике томлыгында (1976–1988) һәм соңрак нәшер ителгән «Балалар фольклоры» китабында (1993) басылган яисә искәрмәләрдә вариант буларак күрсәтелгән.

Алга таба да Башкорт дәүләт университетының, Башкорт дәүләт педагогия университетының татар бүлеге студентлары төрле елларда Башкортстан төбәгендә, шул исәптән Стәрлебаш районында да фольклор экспедицияләрендә була. Мәсәлән, 2010 елда Башкорт дәүләт педагогия университеты студенты Гөлнара Яхшисарова Стәрлебаш, Карагош, Яңгырчы һ.б. татар авылларында

җырлар, такмаклар, мәкаль һәм әйтемнәр, бәетләр, мөнәҗәтләр һ.б. жанрларга караган халык иҗаты үрнәкләрен язып ала.

Һәм, ниһаять, 2017 елда Стәрлебаш районына Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының комплекслы фәнни экспедициясе оештырылды. Ул берничә өлкәгә кагылышлы тикшеренүләр үткәрүне максат итте. Фольклорчылардан Ильмир Ямалтдинов (экспедиция җитәкчесе) һәм фәнни хезмәткәр Гөлнара Яхшисарова катнашты. Башкортстанның Стәрлебаш районына кергән 15 татар авылында (Айдарәле, Әмир, Бакча, Бакый, Бузат, Гөлем, Карагош, Куганакбаш, Стәрлебаш, Турмай, Тәтер-Арслан, Өч-Әсән, Хәлекәй, Янгырчы, Яшерган) булып, барлыгы 700 берәмлеккә якын халык авыз иҗаты үрнәкләре һәм татар халкының традицион мәдәниятенә караган материаллар язып алынды.

Стәрлебаш районында яшәүче татарлар арасында аеруча иң киң таралган авыз иҗаты жанрларыннан җырларны аерып чыгарырга була. Өч йөздән артык **җыр** язып алынды. Аларның күбесе – кыска җырлар һәм такмаклар. Алар арасында лирик, йола һәм уен-бию, бишек җырлары да бар.

Турмай авылында Курманаев Динияр (Минияр) Биктимер улы (1931 елгы), Әмир авылында Нәфыйкова Гөлсем Мулләхмәт кызы (1952 елгы), Карагош авылында Шәрипов Мөхәммәтзакир Мөхсин улы (1926 елгы), Бузат авылында Булатов Фәрит Гыйлемҗан улы (1955 елгы), Яшерган авылында Мөхтәруллин Һидиятулла Ибәтулла улы (1942 елгы), Гобәйдуллина Флүрә Ибәтулла кызы (1946 елгы), Тәтер-Арслан авылында Мөхәммәтшина Әнвәрә Хәмәтһади кызы (1941 елгы), Садретдинова Миннур Сәбәхетдин кызы (1938 елгы), Айдарәле авылында Йосыпова Сәгүрә Зәйнулла кызы (1929 елгы), Бакый авылында Баһаветдинова Әлфия Зәйни кызы (1952 елгы), Стәрлебаш авылында Шәмсетдинова Зөбәрҗәт Хаҗи кызы (1931 елгы) безгә бик күп татар халык җырларын җырлап күрсәттеләр.

Карагош авылында Табаева Әминә Мөхсин кызыннан (1930 елгы) берничә дистә татар халык җыры язып алынды. Алар арасында кыз елату җыры да бар:

Кизелкәй шаршау яшел читле,
Кор дисәң дә корма, әңкәем,
Бер вакытлар җиткәч,
Атлар җиккәч,
Тор, дисәң дә тормам, әңкәем.

Стәрлебаш районының Таллык авылында туып үскән Кәримова Фәрзәнә Гыйльметдин кызы (1926 елгы) Бөек Ватан сугышына озату мизгелләрен исенә төшереп, әтисе, абыйлары, авылдашлары җырлаган җырларны күңелендә яңартты:

«Таллыгымның буйларында
Унсигез ел үсте буйларым.
Монда яшәү миңа күңелле иде,
Шуңа күрә күреп туймадым, –

дип ерлады Фәрит абыем сугышка киткәндә.

Авылымның кыйбла тарафында
Күккә тиеп тора манара.
Хуш, иркәм, исән йөре,
Бәлки күрешә алмабыз тиз ара.

1941 елның 22 июненең иртәсе. Колхоз рәисе Заһидуллин Гаяз абзый бу ачы хәбәрне җыелган халыкка сөйләде.

Икенче көнне үк яшь ирләргә повесткалар килә башлады. Халык хәсрәт, куркуга чумды. Бәләкәй генә Таллык авылыннан көн дә бер атка төялеп 5–6 кеше Стәрлебашка китә. Шуннан ваенкомат озата. Атларга утырган солдатлар авылны яңгыратып җырлап китәләр.

Авылдашлар, сау-булыгыз,
Без китәбез иртәгә.
Без китмәс идек иртәгә,
Герман тия теңкәгә.

Тал бөгелә, тал бөгелә,
Тал яфрагы чайкала.
Үлү безгә берни түгел,
Туган илкәй җәл кала.

Әгәр үлеп калсак сугышларда,
Безгә истәлекләр куегыз.
Исән калсак, бер кайтырбыз,
Кайталмасак – бәхил булыгыз.

Гаяз абзый белән минем әтигә дә сугышка отправка хәбәре бер көнне килде, чөнки аларның яшьләре бер – 1898 елда туганнар. Сугышка китә торган кешеләр колхоз идарәсендә җыелдылар. Алар, ат арбаларына утыргач, озатырга җыелган туганнарын юатырга тырышып, шушы җырны җырладылар:

Матур була, ямьле була
Яз көннәрең, җәйләрең...
Исән булсам, бер кайтырмын
Язлар кебек әйләнеп...»

Озын көйләр Стәрлебаш районында гомер итүче татарларда саклана. «Олы юлның тузаны», «Рәйхан», «Сарман буйларында» һ.б. җырларны һәрбер авылда очратырга була.

Стәрлебаш районында яшәүче татарлар арасында «Йокла, балам, йом күзең», «Әлли-бәлли бәү итә» һәм «Аллаһу-Аллаһу» кебек бишек җырлары киң таралган. Аларның берничә вариантын теркәдек.

Автор җырлары да халык тарафыннан бик яратылып башкарыла. Алар арасында халыклашкан җырлар да бар. Тарихи җырлар, кызганыч ки, очрамады.

Ияләр, җеннәр турындагы **мифологик сөйләкләр, хикәятләр һәм әкиятләр** халыкта борынгыдан сөйләнеп килгән, кешеләр аларга ышанганнар, буыннан-буынга тапшырганнар. Татар халкында аеруча киң таралганнары – атның ялын үрә торган яисә яратмаганга шабыр тиргә батыручы абзар иясе; төрле кыяфәткә (песи, эт, бабай, матур кыз һ.б.) керә ала торган, яисә бала елаган тавышка ияртеп адаштыручы, яисә өсте капланмаган су-сөт белән баласын коендыручы, яисә ялгыз әбиләргә ияләшүче җен-пәри-шайтан; атны тугарып, дугасын (сбруен) кире якка җиккән очракта гына котылып була торган адаштыручы җенле урыннар; яратмаганга күрә күзенә күренүче яисә табак-савыт шалтыратучы,

яисә сыер (ат) бозаулаганда (колынлаганда) тәрәзә шакып уятучы өй иясе (йорт анасы), адашкан кешегә юл күрсәтүче Хозур Ильяс, кызыл ут булып тәгәрәп йөрүче Убыр, озын бармаклары белән кытыклап үтерүче Шүрәле, чәчен тарап утыручы Су анасы; Стәрлебаш төбәгендә генә була торган, аерым алганда, иртәгә гает дигән көнне бер җиргә дә чыгарга ярамаган килеш Гарәфә көнне игеннәрне карарга чыккан Ситдыйка картәнисеннән нишләп йөрүен сораучы Хозур бабай, матур кыз кыяфәтендә кич белән килеп, минем өстемнән кәләш алсаң, мин сине үтерәм, дигән җен кызы; Нәгыймә әбиләр йортында Морзаян бабай булып мал карап йөрүче Йорт иясе, бәхетле, бай булу өчен, җен күреп алганчы төнге уникедә аяк табаны астына салып алып кайтырга кирәк булган чикләвек чәчәге; ягылган мунчага бикләп кенә котылып була торган матур кыз кыяфәтендә килгән Юха[1]; Куганакбашта авыл советы бинасында күмәк сөйләшеп утыручы җеннәр[2]; Турмай авылында утлы шар булып йөргән сихерче – Убыр уты[3]; Җамал апалар бәләкәй чакта Рәфисләрнең өендә торган зур йөнтәс гәүдәле, 2 метрлы, җайлап кына зур адымнар белән йөрүче кар кешесе (снежный человек)[4]; ат арбаны тарталмагач, әнисе төягән утыннарны бушатып, бер-ике агач калгач кына арбадан төшеп калган урман хуҗасы һәм ураза вакытында сусап йокыга киткәч, салкын су бирүче ак түбәтәй кигән бәләкәй бабай[5]; бозауларга тиешле сыерны карамыйча кереп киткән хуҗаларга, бозау үлгәч, ачуланып, кәзәнкә ягыннан дөберт итеп китереп сугып, өй башына чоштырт-чоштырт менеп китүче Йорт иясе; Әҗәл тавыннан фермага кадәр Флүрәгә ияреп төшеп зәхмәте кагылган озын

---

[1] Куганакбаш авылында Ягафарова Рәхилә Низаметдин кызыннан (1936 елгы) язып алынды.

[2] Куганакбаш авылында Яхина Хәкимә Тимерхан кызыннан (1961 елгы) язып алынды.

[3] Турмай авылында Курманаев Динияр (Минияр) Биктимер улыннан (1931 елгы) язып алынды.

[4] Яңгырчы авылында Хисамов Мөнир Әхәт улыннан (1969 елгы) язып алынды.

[5] Яңгырчы авылында Абайдуллина Тәгъзимә Әфтәх кызыннан (1943 елгы) язып алынды.

аяклы биек җен; картәнисе элек мәчет булган клубның пичен ягарга баргач, мәчет тутырып намаз укып утырган фәрештәләр һәм шул клубны сүткәндә сәхнә астыннан борынгы китапларны өенә алып кайтып телсез-авызсыз калган картәнисе, өй тыныч булмаганда андызны базда яндырып кына тынычландырып булган һәм Флүрә апаның чәчен үргән өй ияләре[1]; төнлә трактор белән сабан сөргәндә Мәчет тавыннан тәгәрәп төшеп, авыл советы янында почмактагы абзыйларның морҗасына кереп киткән Убыр уты[2]; авырлы килеш берүзе кунган Миңсылуның җитлеккән баласын алган мәлгуньнәр-җеннәр һәм йомшак куллы, бармагында сөяге булмаган Нәкый булып килеп йөргән җен[3]; зираттан чәчелеп-чәчелеп китүче Убыр; мунча саласы урынга әллә күпме ел элек үк килеп утыручы яисә буш торган йортка ияләшүче яисә икенде-ахшам арасында иң котырган вакыты булган һәм ясин сүрәсен укысаң чыгып китүче җен-пәриләр[4]; ап-ак ялангач тәпиле, урта буйлы, кесәле шакмаклы күлмәкле, аяк-кулларын салындырган, дәшмичә карап торганнан соң юк булучы Өй иясе[5]; җен, алмаштырып, идән астына алып кереп киткәндә сыймыйча калганнан соң үсмәгән бала; намазга соңга калганда үзеннән-үзе кыйблага каратып җәелгән намазлык[6]; тынгылык бирмәгәндә андызны кайнатып, почмакларга сибеп кенә котылып булган Өй иясе[7]; бер әбине мунчага җибәреп аны үтерүче яисә Әсма әби

---

[1] Хәлекәй авылында Шәрипова Гадәния Низаметдин кызыннан (1937 елгы) язып алынды.

[2] Хәлекәй авылында Шәрипов Гали Шаһи улыннан (1931 елгы) язып алынды.

[3] Әмир авылында Мөрәсова Зөбәрҗәт Хөббрахман кызыннан (1934 елгы) язып алынды.

[4] Карагош авылында Табаева Әминә Мөхсим кызыннан (1930 елгы) язып алынды.

[5] Бакча авылында Тимербулатова Миңниса Минневәли кызыннан (1924 елгы) язып алынды.

[6] Бакча авылында Рысаева Минзия Мөдәррис кызыннан (1959 елгы) язып алынды.

[7] Өчегән Әсән авылында Гафиятуллина Мөбарәк Муллагали кызыннан (1930 елгы) язып алынды.

белән Гөлҗиһан әбине алып китеп укыткан җеннәр; җиләккә баргач адаштыручы җенле чокыр[1]; әниләре май сатарга барганда Федоровка белән Сухой Изәк арасында кызыл ут булып януучы Федр җене һәм өен сатып шәһәргә китмәскә кушкан Өй иясе[2]; Зөһрә әбигә ияләшкән җен һәм Ибрайдагы бер апаның кайгыларын алган Хозур Ильяс[3]; Арслан белән Айдарәле арасында Габсабир күперендә атларны тугаручы җен[4]; Куян очында кыңгырау тавышы булып арттан килүче, Габсабир күпере дигән җирдә апак киемнән күренүче җен[5]; иренең җаны күбәләк булып кайту могҗизасы[6]; ферманы чыккач, Сурлытау ягында күренгән Убыр уты, һәм сәнәк-көрәк очырып йөрсәң, сөяп-элеп куймасаң, абындырып егылдыручы Йорт иясе[7] турындагы мифологик сөйләкләр, хикәятләр һәм әкиятләр.

Тарихи һәм топонимик **риваятьләр** язып алынды, аларның авыл тарихларына (Турмай, Гөлем, Бузат, Өч-Әсән, Яңгырчы, Яшерган, Стәрлебаш, Ибрай, Карагош һ.б.) бәйлеләре – шул авылларда яшәүче милләттәшләребезнең үз тарихларына битараф булмаганлыкларының ачык мисалы. Өч-Әсән авылында Гафиятуллина Мөбарәк Муллагали кызыннан (1930 елгы) «Акылның атасы кем?» дигән һәм Сөләйман пәйгамбәрне балык йоту, Бакый авылында Вилданова Ямал Газиз кызыннан (1921 елгы) – кеше гомере, Яңгырчы авылында Кәримова Кәримә Лотфурахман кызын-

[1] Яшерган авылында Мөхтәруллин Һидиятулла Ибәтулла улыннан (1942 елгы) язып алынды.

[2] Тәтер-Арслан авылында Мөхәммәтшина Әнвәрә Хәмәтһади кызыннан (1941 елгы) язып алынды.

[3] Тәтер-Арслан авылында Мөхәммәтшина Гүзәлия Ягъфәр кызы (1960 елгы) язып алынды.

[4] Айдарәле авылында Мишарова Нурия Зариф кызыннан (1950 елгы) язып алынды.

[5] Айдарәле авылында Хәбибуллина Гөлшат Гыйбадрахман кызыннан (1962 елгы) язып алынды.

[6] Бакый авылында Байтимерова Наҗия Шаһиәхмәт кызыннан (1937 елгы) язып алынды.

[7] Бакый авылында Гафиев Зөфәр Габдрахман улыннан (1938 елгы) язып алынды.

нан (1938 елгы) – адәмнең гамәлләрен язып баручы фәрештәләр, Яшерган авылында Кашапов Габделхәбир Исмәгыйль улыннан (1932 елгы) Адәм белән Хәуваның җәннәттән җир йөзенә чыгарылуы турындагы дини риваятьләр язып алынды.

Стәрлебаш авылында Гыйзетдинова Зөлфия Зиннәт кызы (1961 елгы) беренче булып комсомолга кергән Әхсән исемле егетне һәм аның Гайфулла исемле дустын бертөркем ирләрнең килүе һәм алып чыгып кыйнаулары, аннары Әхсәнне, ат койрыгына тагып, Ибракай тауларына алып барулары, ике дистәгә якын хәнҗәр белән кадап аны үтерүләре һәм соңыннан халыкның Стәрлебашның бер урамына Әхсән исемен кушуы турында риваять сөйләде.

Стәрлебаш төбәгендә, нигездә, барлык татар халкы өчен хас **уеннар**ның тасвирламасы сакланган. «Түгәрәк» уеннан башлап, «Лапта», «Ак кирәк, күк кирәк» белән беррәттән, аулак өйләрдә, кичке уеннарда[1] традицион уйналып килгән «Наза», «Йөзек салыш» («Тычкан салыш»), «Йолдыз санашлар» да бар. Кышкы кич утыруларда, яз башында кич табигатькә чыгуларда, соңрак мәдәният йортларында «Чүпләм», «Читән үрү», «Кыз урлаш», «Тату», «Сукыр тәкә» һ.б. уеннар булган, ә балалар тарафыннан «Черталы» «Бастырышлы», «Чүрәкә», «Пограничник», «Триножка», «Чируклы», «Гузна» уеннары аеруча яратып уйналган. Турмай авылыннан Курманаев Динияр (Минияр) Биктимер улы (1931 елгы) берничә ел элек туксанынчы дистәләрен вакласалар да, малай вакытларында уйнаган уеннарны һәм Бакый авылында Гафиев Зөфәр Габдрахман улы (1938 елгы) бүген дә бик яхшы хәтерлиләр. Д. Курманаевтан «Такталы», «Чебенне», «Кыек баш», «Клюк», «Татулы», ә З. Гафиевтан «Кәшәкә», «Шәкшәкәр», «Кузырлы» уеннарының тасвирламалары язып алынды.

**Әкиятләр**гә килгәндә, Стәрлебаш районында Г. Тукай әкиятләре һәм берничә татар халык әкияте, яисә әкиятнең кыскача эчтәлеге, шул исәптән әкият-мәзәк язып алынды. Кайбер әкиятләрнең эчтәлеге яисә сюжеты халык әкиятләренә тәңгәл килә,

---

[1] Стәрлебаш районы татарлары кичке уеннарны *вечер* дип тә сөйли.

яисә берничә әкият сюжеты кушылып бер әкият итеп сөйләнә. Әкиятләргә ислам дине белән бәйле мотивлар килеп керү дә күзәтелә.

Бу төбәктә **мөнәҗәт** һәм **бәет** жанрларына караган үрнәкләр дә теркәлде. Стәрлебаш татарларында иң киң таралган халык иҗаты жанрларының икенчесе – **мөнәҗәтләр**. Алар һәр авылда очрый. Аллаһы Тәгаләгә, Пәйгамбәрләргә, Ислам диненә, Коръәнгә мәдхияләр, шигъри нәсыйхәтләр, бәйрәм, мәҗлес мөнәҗәтләре, яшәү һәм үлем фәлсәфәсе, ата-ана һәм бала турында мөнәҗәтләр киң таралган. Бу аңлашыла да, чөнки Стәрлебаш татарларында дин көчле. Бузат авылында Фәттахов Илдар Хәйдәр улыннан (1985 елгы) мөнәҗәт жанрына якын торган «Салаватулла» һәм «Ассубәһибәдә» әсәрләре икесе дә гарәп телендә язып алынды.

Сирәк булса да, **бәетләр** дә очрады. Куганакбаш авылында Ягафарова Рәхилә Низаметдин кызыннан (1936 елгы), Бакый авылында Вилданова Ямал Газиз кызыннан (1921 елгы) һ.б. информантлардан татар халкында киң таралган «Сак-сок» бәетләре язып алынды. Куганакбаш авылында Байморатова Рәшидәдән Әфганстан сугышында һәлак булган улы Азамат Байморатовка багышланган «Ана сагышы», Бөхәрмәтова Миңсылудан язып алынган «Мидхәт бәете», Вилданова Розалиядән бер-бер артлы фаҗигале рәвештә һәлак булган уллары Флорит һәм Спартак истәлегенә чыгарылган «Минем газиз улларым», Яңгырчы авылында язып алынган «Рәшит бәете», Стәрлебаш авылында Кәримова Фәрзәнә оныгына багышлаган «Рим бәете» бу төбәктә бәет чыгару традициясенең дәвам итүен күрсәтә.

Әлеге жанрларга караган үрнәкләр халыктан сирәк язылып алына. Алар, нигездә, кәгазьгә төшерелә. Шулай да, бу төбәктә халык мөнәҗәтләрне күңеленнән әйтә.

Балалар фольклорының «Багу поэзиясе» әсәрләреннән берничә бишек җыры, әйтеш, юаткыч, мавыктыргыч, сөйләм такмагы, шулай ук «Күңел ачу» һәм «Уен фольклоры» үрнәкләре язып алынды.

Табышмаклар һәм башка паремияләр дә өлкән буын вәкилләренең күңелендә генә саклана. Хәзерге вакытта дастаннар оч-

рамаса да, «Сәйфелмөлек» әсәренең эчтәлеге Өч-Әсән авылында Гафиятуллина Мөбарәк Муллагали кызыннан (1930 елгы) язып алынды.

Йола фольклорына килгәндә, йолалар, гореф-гадәтләр турындагы мәгълүматларны җырлары, уеннары, махсус әйтелә торган сүзләре белән бергә мөмкин кадәр бер күренеш буларак язып алырга тырыштык. Куганакбаш авылында Ишбулдина Мөзәлифә Корбангали кызыннан (1940 елгы) – өшкерү, 41 ясин чыгу, Куганакбаш авылында Ягафарова Рәхилә Низаметдин кызыннан (1936 елгы) – яңгыр яумаса – «Ат башы салу», мал зыянлаган җиргә «Пычак белән сызу», «Таң суы алу», күз тимәскә артыш агачы кую, бала тугач, башлыгына миләш агачын тегү, «Мәчетнең ыңгырашуы», бала йөрмәсә – май үләне, 41 аксыргак салу, курыккан кешегә «Кот салмасы» ашату, куркудан кургаш белән «Кот салу», «Күк кабагы (капусы) ачылу», Хәлекәй авылында Шәрипова Гәдәния Низаметдин кызыннан (1937 елгы) – «Тимрәү имләү», яңгыр яумаса – «Яңгыр теләү», кабергә су салу, бала курыкса, егылса, күз тисә – «Җиргә салу», Әмир авылында Мөрәсова Зөбәрҗәт Хөббрахман кызыннан (1934 елгы) – «Сугым сую», «Тула басу», Әмир авылында Басырова Фәһимә Гаяз кызыннан (1942 елгы) – «Кот кою», бала еласа, ботак тишеге, тары белән имләү, Әмир авылында Мөрәсова Мәрхәбә Гыйззәтулла кызыннан (1937 елгы) – Кот кою, сыерның җилене – шешсә ботак тишегеннән саву, Карагош авылында Табаева Әминә Мөхсин кызыннан (1930 елгы) – Кот кою, бала йөрмәсә – «Тышау кисү», тозлы суга утырту, яңгыр яумаса – «Яңгыр боткасы», кабердәге убылган урыннарга – чокырга, Салават әйтеп, 41 кашык су салу, Тәтер – Арслан авылында Мөхәммәтшина Гүзәлия Ягъфәр кызыннан (1960 елгы) – «Кот кайтару», «Җир тарту», Айдарәле авылында Мишарова Нурия Зариф кызыннан (1950 елгы), Яшерган авылында Мухтаруллин Һидиятулла Ибатулла улыннан (1942 елгы) «Туй», Бакый авылында Байтимерова Нажия Шаһиәхмәт кызыннан (1937 елгы) – «Бәби котлау (үстерү)», Стәрлебаш авылында Вилданова Ямал Газиз кызы (1921 елгы) язмаларыннан 1928–1930 елларда «Кәләш әйттерү», «Килен төшерү»,

«Тула өмәсе», «Каз өмәсе» кебек мәҗүсилек һәм борынгы чорлардан калган сүз үрнәкләре, ырымнар, келәүләр, имләүләр, ышанулар, йолалар, халык медицинасы һәм дини йолалар язып алынды.

Стәрлебаш районының татар авылларында гомер итүче милләттәшләребездән язып алынган, халкыбызның буыннан-буынга, телдән-телгә күчеп килгән кайбер фольклор үрнәкләрен (язылып алыну тәртибендә тематик бүлекчәләргә урнаштырып) тәкъдим итәбез.

## МИФОЛОГИК СӨЙЛӘКЛӘР, ХИКӘЯТЛӘР ҺӘМ ӘКИЯТЛӘР (ияләр, җеннәр турында)

Күзгә күренми торган әйбер кагыла. Алар кагылмаса, кеше авырмый. Әгүзе бисмилла итеп йөрергә кирәк.

Җен беләә(н) пәри бар да бер инде ул. Исеме генә аерым. Барысы да берләр. Шайтаны да бер аның, иблисе дә бер.

### Хозур Ильяс

Юлга чыксаң – хәерле сәгатьтә, хәерле юл булсын, Хозур Ильяс юлдаш булсын, йөзләрең ак булсын, сүзләрең пакь булсын дип, юлга чыкканда кешегә дога кыласың. Исән-имин бәла-каза күрмә. Ходай, бәла-казалардан, афәтләрдән үзең сакла. Берүк бәла-казалардан сакла инде, дип мин телим инде.

Хозур Ильясны төшемдә генә күрдем мин аны. Ул яшел таяклы була инде Хозур бабай, яшелдән киенә, ак сакалы була. Безнең картәнигә дә күренгән ул. Элек бит инде аерым хуҗалык, иген чәчкәннәр. Картәни яланга чыккан Гарәфә көнне. Иртәгә гает дигән көнне бер җиргә дә чыгарга түгел. Картәни игеннәрне карарга чыккан яланга. Хозур бабай сораган:

– Ситдыйка, нишләп болай йөрисең, дигән. Әйткән дә теге бабай юк булган. Шуннан картәни 3 көн авырыган, шуны күргәннән соң, ярамаган. Нинди гает булса да. Корбан гаете дә, Ураза гаете дә. Гарәфә көн.

### Җен кызы белән яшәде

Бабай сөйли иде. Кәркәледә берәү кәләш алмады, ди. Бер дә алмады, ди. Шайтан кызы белә(н) өйләнешкән дә. Шайтан кызы гел янына килеп йөргән матур кыз булып. Кич белә(н) килгән. Әгәр дә минем өстемнән кәләш алсаң, мин сине үтерәм дигән. Шуннан алмаган инде. Гомер буе җен кызы белә(н) яшәде, ди.

### Йорт иясе

Йорт иясе күренеп тә йөргән. Картым сөйлидерие. Нәгыймә әбиләр йортында Морзаян бабай мал карап йөри дип. Морзаян бабай булып йорт иясе йөри малларына ашарга салып дип. Көндез, төннә түгел.

* * *

Яратмаса атны ак күбеккә батыра. Яратса – ялын үреп куя. Йорт иясе. Бик сүгенергә дә түгел. Аны яратмый. Безнең атны яратадырие. Ялын гел үрә иде.

### Чикләвек чәчкәсе

Сәгать 12 дә чикләвек чәчкә ата. Шунда барып, чәчкә атканны көтеп утырасың. Шул чәкәне аласың, өзеп аласың да артыңа карамыйсың, сәгать 12 дә курыкмыйча шуны тотып апкайтасың. Әгәр дә артыңа карасаң, теге чәчкә югала. Төннә ата сәгать 12 дә. Шул чәчкәне алсаң, әй бәхетле буласың. Аның чәчкәсен яшен ала. Чикләвеге шуңа күрә аз була. 12 дә ата, аны җен урлый, җен күргәләгәнче чәчкәне алсаң бай буласың. Аны табан астына, аяк киеменә куясың.

### Юха

100 елдан соң аждаһа була. 100 елан 100 ел яшәсә аждаһа була. 1000 ел яшәсә Юха була.

Булган ул. Мунчага бер егеткә бер матур кыз килгән. Эй инде, матур ди шулхәтле. Хәзер моның кем икәнен сизеп калганнар да, мунча якканнар. Мунча якканнар да, хәзер мунчаны булдырып теге кызны мунчага керткәннәр. Мунчага керткәннәр дә, тыштан

бикләп куйганнар. Эй озын, ди теле, ди, тәрәзәне ялый, ди. Елан бит сусыз тормый. Тәрәзәне ялый, ди теге Юха. Шунда үлгән инде.

*Куганакбаш авылында*
*Ягафарова Рәхилә Низаметдин кызыннан (1936 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Безнең селсәвитнекендә дә бар ийе. Теге 2 этажлы зур зданиядә. Әле тындылар Коръән укыткач. Кеше булып та сөйләшәләр. Сөйләшкән тавыш ишетелә, күмәк. Синең белә мин сөйләшеп утырган кебек ишетелә. Кырына барып карасаң, булмаган була бер кеше дә. Җеннәр инде.

*Куганакбаш авылында*
*Яхина Хәкимә Тимерхан кызыннан (1961 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

**Йорт иясе** ялын үрә. Ялын әйбәтләп тарап куясың, үреләдерие. Яратканга күрә. Яратмаса, ат янып төшә, ди, ат тик тора алмый.

**Убыр уты.** Утлы шар. Сихырчылар әнә шулай йөрегән, утлы шар булып. Хәзер сихерчы юк та бит ул. Ә элек булган ул.

*Турмай авылында*
*Курманаев Динияр (Минияр) Биктимер улыннан (1931 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Алар икесе дә бердер, что пәри, что шайтан, миңа барыбер.

Ышанабыз **Йорт иясе** бар дигәнгә. Быел сыер бозаулар алдыннан, таңга таба минем иптәшем уянды. Рәфис, тор, сыер бозаулагандыр. Кемдер тәрәз шакыган моңа. И чыгып керде, сыер бозулап куйган. Өй хуҗасына ышанабыз. Коръән укытканда иң беренче өй хуҗасына башлап укыгыз дибез.

Йорт хуҗасы атның ялын үреп куйган дип әйтә торганнарие.

*Яңгырчы авылында*
*Назаров Рәфис Шәрифҗан улыннан (1968 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Абзарның да иясе бар, йортның да иясе бар. Килеп дәшә, сыер бозауласа тәрзәгә шакый.

**Өй иясе** ачулана, яратмый исерек кешене. Тегеләй дөбердәп йөри, болай дөбердәп йөри. Өй иясе бар ул, бөтен җирдә дә.

### Кар кешесе

Элек бездә снежный человек булган. Бер 40–50 ел элек, 60 булмаса. Ямал апалар бәләкәй чакта. Алар торганнар Рәфисләрнең өендә, теге баянис бар бит яшьрәк, шул йортта. Кич көне, төннә төшә ди теге снежный кеше, абзарда куна, ди, иртә таң белә торып китә, ди.

Аны күрәләр, төннә икешәрләп чыкканнар, и карт әниләре Салават абыйның әйткән: Сез аларны куркытмагыз. Бу кешегә тими.

Зур гәүдәле, йөнтәс, 2 метрлы, весы 1,82 центнер. Төннә чыгарга курыкканнар, шуңа икәүләп чыкканнар. Зур гәүдәле җайлап кына зур адымнар белән китә, ди.

* * *

Берәүләр Карамал базарыннан кайтканнармы, арт ниенә утырган. Алар карамаганнар инде. Ат кинәт кенә чак тарта башлаган. Ап-ак тиргә баткан. Авылга килеп җитәрәк теге (җен – *И.Я.*) төшеп калган. Арба сикереп киткән даже. Борылып карарга курыкканнар. Тегеләр җен дип аңлаганнар.

*Яңгырчы авылында*
*Хисамов Мөнир Әхәт улыннан (1969 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### Урман хуҗасымы, җенме

Урманга барган әни, әти өйдә юк вакытта. Шул коры-сарылар бит инде, агач кисәргә ярамый бит инде ул вакытта. Коры-сарылар гына төягән бит инде. Хәтсез агач салган. Хәзер кайтырга чыктык, ат туктады кинәт, ди, тартмай, ди. Шуннан хәзер, әни дә безнең укыйдырые ул. Нәрсә эшләргә дә белмим. Ташладым бер агач, ди, ташладым 2 агач, һаман тартмый, ди. Шуннан хәзер 1–2 агач калды арбада, ди. Шуннан ат тартып алып китте, ди. Теге утырган төшми, ди, бушаткач төшеп калган. Ул бит күренми урман хуҗасымы, җенме.

* * *

Берничә еллар элек, ураза тотам бит шулай. Эй сусадым бер көнне. Хәтсез вакыт бар, яттым. Оеп йокыга да киттем. Бер бәләкәй генә бабай, ак түбәтәй кигән, хәзер миңа су бирә. Мә монау суны, ди. Хәзер теге суны күтәреп алдым да, эчтем дә: әй, Аллакаем, мин уразаем бит, – дип уянып китеп сикереп торып утырдым. Карасам, бер кеше дә юк янымда. Ә тамак төбендә теге салкын су ураза беткәнче барды, тамак төбендә торды.

*Яңгырчы авылында*
*Абайдуллина Тәгъзимә Әфтәх кызыннан (1943 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## Убыр

**Убыр** бар икән, ди, су буйларында. Убыр – ут була инде. Кәбән кебек тәгәрәп-тәгәрәп йөри торган. Сулырак җирдә йөри ул.

Мына минем картәни Әмиргә барган, ат белә(н), мин бәләкәй чакта инде, картәни сүли инде. Картәти кайткан вакытта Сәхәп тирмәне дигән тирмән булган, ди. Шул тирмән яныннан, картәти әйтә, ди, килеп атка сыгылды, тәгәрәп килеп менде – ат өркеп, чапкан да чапкан. Зират янына җиткәч, картәти аңын югалткан да шул зират янында төшеп калган, аты ак күбеккә батып кайтып кергән. Убыр куып китергән. Элек булган ул. Нәстәдер булып күренә. Егет булып та күренә. Мына Гали бабайлар килеп утырганда тугайлык булган урыннары. Алардан ары өйләр булмаган. Тау буйлап шул убыр тәгәрәп төшәдерие, ди, төннә.

Убыр дип әйткәннәр. Ул теләсә нәстә булып күренгән бит инде. Ул мына шушы аулаграк урманнарда йөрегән.

## Йорт иясе

Йорт иясе бардыр ул, балам. Бер елны берәү китереп сукты монау кәзәнкә ягыннан, берничә ел, 6–7 ел бар. Коридорга сукты, дөберт итеп калды. Шуннан, бабай тор әле мин әйтәм, атыңны ябарга кирәк, япмадың мени әле. Әллә капка ачылды, чык димен. Чыгып атын гына ябып керде дә бу, бүтән ерне карамады. Хәзер сыерны да кара, дидем. Сыер басып тора, ди. Ул бозауларга

басып торган. Бозаулаган да бозавы үлгән, кыстырып үтергән бозауны. Хәзер бит инде сыерны басып тора дигәннән соң кереп барабыз икәү, монау коридордан бәрәкәтәй чоштырт-чоштырт хәзер өй башына менеп бара, ачуланды безгә бу. Действительно менә йорт иясе, менеп бара. Чыксак бозау үлгән. Әйтәм бит, безгә аңнаткан бу. Китереп сукты коридорга, анда әллә кем уяныр. Бар ул, белгертә ул, йөри барыбер. Куркырга түгел, абзар башына тоз белән әпәй куерга кирәк. Тегендә-монда еракка киткәндә: «Лә иләһе иллә Аллаһы», – дип бүрәнә ярыгына язу язып кыстырасың, кайткачтын: «Мөхәммәд рәсулуллаһ», – дип язасың, шуны кыстырасың, өй тынычлыгы өчен. Әйтеп китәсең: Без ерак юлга чыгабыз, тыныч кына тор, – дип. Бар ул бар, анысы бар. Йорт иясе аламалык китерсә бик алама була бит. Тозны күмәч өстенә сибәбез дә полителенга төреп кыстырасың. Абзарда һәрвакыт торырга тиеш ди ул.

* * *

Өянке төбенә дә тәгәрәп төшкән ул. Менә зур өянке бар бит. Шуның төбенә килеп тәгәрәгән, иясе булган инде аның. Шул агачның иясе булган.

### Зәхмәте кагылган озын аяклы җен

Бер елны Флюрага ияреп төшкән бит. Убырмы? Нәстәме? Хәзер шушы әҗәл тавы тып-тын булган. Нинди машиналар йөреп торган. Бу хатын төшкәндә бер әйбер дә очрамаган. Хәзер монарга капылт кына, Әҗәл тавының, олы юлдан безнең якка килеп төштегез бит әле сез, шуннан бер нәстә ияргән. Ике аягы да батинка кигән, ди. Берәр метрлап ди инде аягы, оозын, ди. Бу дәшәргә дә курыккан. Карарлык та түгел, ди, биек. Икәү бергә киләбез дип әйтә ди, яхшы итеп киенгән, ди ул, кешегә дә охшаган, охшамаган да, ди. Хәзер өстән үк аска – ферма янына төшеп җиткәннәр, шунда күпер янында югалган. Шуны нинди авылга алып барып өшкерткәннәре хәтеремдә юк. Җиде бабайдан өшкерткәннәр. Бу зәхмәт булган инде, зиярәтнең иясе булган ул. Шулай диләр. Җеннәр берничек тә аерылмый, ди. Мына

дигән кызлар булып та басарга может, егет булып та, әби булып та, ул төрле сүрәттә керә бит. Зәхмәт шулай итә. Ул ияргән ана шул зиярәтнең хуҗасы булган ул.

## Намаз укучы фәрештәләр

Картәни пич ягырга иртә бара бит инде. Шул клуб дип йөртәләрие. Артислар киләйе, рус артистлар да киләйе, бүтән артислар да. Мәчеткә килеп, ишекне ачтым, ди. Ябып өлгермәгән, ишекне ачкан көе генә күргән дә, ишекне әкрен генә ябып кайтты. Керсә алама да булырые, йә егылырые, кермәгән. Намаз укыйлар ие, ди. Муллалар, туп-тулы мәчет эче, ди. Анда бит гомер буена мәчет булган. Манарасын кисеп төшергән кешене дә каргыйларые. Барыбер игелек күрмәде. Әбинәгыйм дигән кеше кисте, ди. Нишләптер үтергәннәр инде аны, ул бабайны. Әйбәт үлем белә(н) үлмәгән. Чалмалы намаз укып утырган кешеләр болар фириштәләр булган. Ул мәчет урыны булгач, шулай булган.

* * *

Шуннан болай булды. Минем үсеп кенә килгән вакыт. Печәнгә ебәрделәр безне. Еракка – ерак авылга, куна ятып эшләргә. Хәзер бер мәлне, бер малай килә бер ат җиккән, бистарка кебек арба, улак кебек, картәниең начар, сине алырга килдем, ди. Ебәргәннәр бригадирлар. Ерак кына ара әллә көн буе, әбидкә хәтле кайттык инде, кайтсак, картәнине сузып салганнар, битенә тастымал япканнар, телсез-авызсыз, сүләшәлми.

Менә болай булган. Теге тәү бит инде мәчет ие, аннан клубка әйләнде бит ул клубны сүтеп, аска сельсоветлар белә(н) бер тирәгә күчереп салырга сүткәннәр. Сәхнә астында китаплар күп булган, Коръән китаплары. Шуларны җыеп алып кайткан булган картәни, кайткачтын да телсез-авызсыз булган. Сүләшәлми, шул көенә егылган ушсыз.

Җиде әбиме, җиде бабаймы Коръән чыктылар шунарга, картәни терелде, үлеп беткән ие.

Ул китаплар кая булгандыр, игътибар булмады.

## Йорт иясе

Йорт иясе тыныч булса тими бит.

Өй тыныч булмаса – чыга. Күзенә күренә, бала тынгысыз, бала елый бишектә. Шуннан соң, Гөлсинә бик ябык кеше ие, сүләп бармады. Сүләгәч, бик дини Миникамал дигән бер әби барые, бик дини, шунарга бардым. Ул нәстәләрдер язып бирде, бишегенә куйсын баланың дип. Шуннан Хамматхан дигән бабай, кода кеше инде әпәт. Киленебез Нәсимәгә сүләдем дә, Нәсимә әтисенә сүләгән, дини халыклар әтиләре. Баргачтан Хамматхан кода капчыгы белә(н) андыз биреп ебәргән. Чәчкәсе дә шунда, тамыры да шунда, менә шуларны базларына яндырсын, дигән. И тындылар мына. Йорт эчендә яшәгән кешеләрнең берсе булып күренергә мөмкин.

Флюра апа да сөйләгән ие. Килеп минем чәчемне үрде дип. Ул кеше кыяфәтенә керә. Ниндидер таныш кешенең белгән кешенең кыяфәтенә керә, кулы сизелеп тора, чәчеңне үргәндә сыйпаганы сизелеп тора.

* * *

Флюра апа күргән. Әле сервантның эчендә елап утыра, ди, үлгән ире, үзем карап утырам, ди, уяндым, ди, Флюра. Елап утыра, ди ире. Чүгәләп утырган, ди, бер мөешенә бу диваннан, карап утырамын, ди.

– Мин бит сиңа һәркөнне Коръәннәр укыйм нигә елыйсың? Нәрсәдән риза түгел? – дип әйтүгә югалды, ди.

*Хәлекәй авылында*
*Шәрипова Гәдәния Низаметдин кызыннан (1937 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Мәчет тавыннан тәгәрәп төшә иде ут. Сельсовет янындагы мөештәге абзыйлар бар ие, шул абзыйларныңморҗасына кереп китте, төннә ул, мин сабан сөргәндә, трактор белән ул тәгәрәп төшә, әнә – сәгатьтән зур. Анда бәләкәй генә өй ие, зыян итмәде.

*Хәлекәй авылында*
*Гали Шәһи улыннан (1931 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## Миңсылуның баласын алган мәлгуньнәр

Безнең апа 23, ул бала 22 елгы булган инде ул. Егерме бердә ачлык булган бик яман. Егерме икедә иген бик уңган. Хәзер безнең әткәй белән әңкәй, әңкәй йөкле булган, шул авылга (Стәрлетамак районында Кушкүл белән Түрешле дигән авыл бар) барганнар урак урырга. Әткәйнең апасы да булган, күрше апа булган безгә. Урганнар да, әңкәйнең вакыты да етә башлаган инде. Күчтәнәчләр алган шунда, әпәйләр күтәргән, 25 км ара бит инде чак торган кешегә, кайтканнар. Кайтканнар да күрше апаның әнисе Гөлҗан дигән әби:

– Балам, үзегезгә кереп кун инде, – дигән.

Рәдем торалар, мин булсам, өең ашалмас, дияр идем. Әңкәй үзенә кереп кунган, анда 21 елда үлекләр дә яткан булган, күмелмичә. Шуннан әйтә әңкәй хәзер, ди, арып кайткан бит инде, 25 км, авырлы кеше.

Хәзер яттым. Өч әби, ди, ап-ак күлмәк кигәннәр, юан 3 әби ди, гел эчемне аска сыпыралар. Җәйге төн бит инде, урак өсте кыска. Шуннан уянып китсәм, ди, эчемдә бернәрсә дә юк, ди. Тордым, карадым, хәзер якты бит инде, кан да юк, сүл дә юк, бернәрсә дә юк, корсак та юк. Шуңардан соң тордым да хәзер, шушы авылга килгән бертуган абыйлары, апасы бар инде:

– И, Сылугынам, әңкәйнең исеме Миңсылу, нәрсәң бар дигән. Бернәрсәм дә юк, балам югалды, дигән әңкәй. Әйдә, мин сине алып барам. Әллә кем карый да менә шушы югары очтамы. Шуннан кулымнан гына тотып карады теге бабай.

– И, балам, етлеккән balaңны теге мәлгуньнәр алган бит, дип әйтте, ди. Шулай итеп, минем җен абзыем да бар, ди. Абзыйдыр инде ул. Хатын-кызны җен алмас. Хатын-кыз болай да җен бит инде ул. Минем бертуган җен туганым да бар. Шулай итеп, безнең әңкәйнең бер баласын җен алган корсагыннан. Әнкәй шуның өчен көндез дә мунча кермәде, әңкәй курка иде.

Балта белә(н) пычак куйсаң бусага буш өйне саклый диләр инде. Без шушылай итеп ышанабыз инде.

## Нәкый булып килгән җен

Гел киләйе, кулымнан тартайе, кырыма килеп ята ийе. Мин матым. Сизелә, кочаклый, кеше кебек. Бервакыт шулай, инде йомшак, мин әйтәм, бу хәтле йомшак икән дип, монаулай итеп киләп теге әйбернең кулын тотып шулай итеп тоттым-тоттым да бармагын тешнәдем, сөяге юк. Бәтәч, бу бит син минәйтәм. Бу бит Нәкый түгел, җен дидем. Менә шулай итеп бармагын тешнәп карадым да сүгендем. Сөяге юк бармакта.

*Әмир авылында*
*Мөрәсова Зөбәрҗәт Хөббрахман кызыннан (1934 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## Убыр

Безнең зират кебек бер йердә дә юк. Убыр мына шуннан чәчелеп-чәчелеп китә бәләкәй генә булып, дип сөйлиләр инде. Ут таралып киткән. Бакчалар инде мында кинага киләләр бит инде клубка. Шуннан кайталар. Кешеләргә дә очыраштыргалаган. Шуның өчен бит кабер өстеннән тапап-тапап туфрагын вич салып бетәләр инде.

## Җен-пәриләр

Шайтан да бит гел кешегә зыян эшләп йөри. Шуның кебек җен-пәриләр дә шундый, ди. Менә мин бер китапның исемен белмим...

Өй саласы урынга, абзар булса элек, әәнә ул урынга өй салырга ярамый дигән. Ул әйбәт урын булмый, анда игелек күрми кеше, начар урын була, диләр инде.

Мына мунча саласы урынга әллә күпме ел элек үк җен-пәриләр килеп утыра ди шунда. Үзләре дә оя корырга. Иң начар урынга әнә шул җен-пәриләр нигез ясый, ди. Шулай дип сөйлиләр инде.

Икенде-ахшам арасы кояш баеп йетмәгән, шул вакытта янгыз хатын кызга мунча керергә ярамый, диләр. Самый җен-пәринең котырган вакыты була, ди. Аннан соң алар буш торган өйдә бик тиз иләшәләр, ди, җен-пәриләр инде. Буш торган өйләргә

кешеләр керә бит, ана шунда иң начар урын була инде. Аннан соң ана шул ясин сүрәсен укысаң, җен-пәриләр вич чыгып китеп бетә, ди. Мындый өйләрдә дә җен-пәриләр була, ди ул. Елына бер булса да Коръән укытырга өйгә. Җен-пәриләрне вич чыгарып ебәрергә. Алар тагы кабат керәләр, ди. Бер эт әрсезе кебек әшәке нәрсәләр инде.

*Карагош авылында*
*Табаева Әминә Мөхсим кызыннан (1930 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### Өй иясе

Телевизор карыйбыз бит инде. Бөтен кеше ятып карый. Мин бер дә ятып караганым юк. Гел утырып карыйм. Шуннан бер көнне утырдым да телевизор карарга, бөтен кеше ятып карый – мин дә ятып карыйм әле, дидем. Моналай башымны куеп ята идем. Шушы ук өйдә ул, урыны шушында инде өйнең, бу бит яңы салынды шушы урында, шушы ердә. Башны монда куеп йоклыйдырыем. Мынанда утырып телевизор карап утырдым да, телевизор шушында. Ярар, мин әйтәм, күчермим инде, шушында гына ятыйм да йоклыйм дип башымны шунда куеп яттым. Шуннан хәзер күпме йоклаганмындыр, белмим ансын. Бервакыт шыгырт итеп ишек ачылган тавыш ишетелде миңа, дерт итеп сикереп киттем дә уянып киттем. Күземне ачып карыйм, бернәрсә дә күренми. Шуннан хәзер уйланып ятам. Кем булыр икән, нишләп йөри икән? Әллә ишегемне бикләмәдем микән? Бикләдем. Шулай бикләдем, болай бикләдем, күңелемнән вич кичердем, бикләгәнмен ишекләрнең барын да. Кем ачала моны мәйтам, ничек ачып керергә кирәк? Кем булырга мөмкин? Шушы өйне эшләгән улым Радик Себердә эшлидерие, вахта белә(н) эшли. Минәйтәм, улыма әле кайтырга өч көн вакыты бар, ул түгел инде, мин әйтәм, әллә аны иртәрәк кайтардылар микән? Уйланып ятам. Шуннан хәзер йокламыйм инде, уйланып ятам. Кем булыр, нәстә булыр? Шушы ишекне ачып керде дә, хәзер ишекнең тавышы да ишетелмәде, әкрен генә шулай итеп кенә, ялан аяк, ап-ак ялангач аяк, кыскарак кына кара чалбар кигән, простой шакмаклы

күлмәк кигән, чалбар да кыстырмаган кармашкасы бар сул якта, кара чәчле озын түгел инде чәче, кыска гына, минем улларым да шулай кыска гына итеп йөртәләр, үстермиләр дә, кырккырып та алдырмыйлар, шулай чәче. Шуннан шулай әкрен генә итеп шушыннан килә бу, әй, Ходаем, дидем, ап-ак ялангач тәпәй, улым дип принимать итәм, шул Радигым дип, Себердән кайтып, мин әйтәм аягына наски да кимәгән, ялангач аяк, хәер, мин әйтәм, ярар, идән ялангач түгел әле, димен, аягы өшеми инде янәсе шушылай җәелгән, бу түгел инде ул чакта, шушылай җәелгән, ярый, уйлыйм инде уйлыйм, идән ялангач түгел әле, ярар мин шулай уйланып беткәнчә, мин шулай яткан, башым шушы якта шушылай итеп тегене карап ятам. Әкрен генә итеп килде дә, монанда еткәч туктады да миңа карап басты, сикереп кенә тордым да мин дә утырдым. Хәзер икәү карашып торабыз, китми дә, дәшми дә, мин шушылай утырганмын, ул шулай баскан менә шушында. Ул килеп баскач, мин торып утырдым бит инде. Хәзер шушылай утырабыз, хәзер тегене күз йөртеп кыймылдарга да куркам. Күз йөртеп карасам, чәчен дә абайладым бит инде, күлмәк – шакмаклы күлмәк, кармашкасы да бар, аяк-кулларын шулай салындырган, тора, дәшми дә, урта буйлы гына, шуннан хәзер тора хәзер нишләргә дә белмим. Нәрсә дияргә дә белмим. Күңелемнән генә: Әстәгыфирулла, Радигым булмады бит бу, дидем. Бу бер сүз дәшми дә ул, тик тора. Шулай Радигым түгел, булмады бит бу, дидем дә хәзер бу мине нишләтер икән дип уйладым. Шулай дип уйлаган ием, шушлай-шушлай итте дә, юк булды да куйды шушында. Бер нәстә дә булмады, ди. Бетте шунда. Сеңде шул ергә, баскан ерендә. Карыйм, юк. Болай итеп карыйм, юк. Бу мин әйтәм ния болай булды? Нәстәгә күренде? Бу тик томалга күренмәгән инде. Бер әйбергә күренгән, уйлыйм инде хәзер. Әләм, мин әйтәм, берәр зыяны тиде микән, бөтен әгъзаларымны кыймылдатып карыйм, бар да хәрәкәттә, бер ерем авыртмый да, шулай бетте дә куйды шунда, сеңде дә куйды.

Белмим нәстә булганын бер дә белмим. Шуннан тордым, бөтен организмнарны хәрәкәткә китерәм. Бастым, басалам да. Тәрәзәгә килдем, урамнарга карыйм, бөтенесе дә әйбәт, күренә,

хәрәкәтләнәм йөрим. Нәстә эшләргә, нәстә булды икән? Бүтән чакта мендәрем шунда куеп ятайем, шушы көнне генә теге телевизор карагач, башым шул яктайе. Әллә мин әйтәм, башымны шул якка куйганга күрә. Алай түгел бит, син шулай яттың, дип Алла Тәгалә шушылай эшләп куйды микән дип. Хәзер Аллага ябештем инде, кая барам, шулай дип уйладым. Шуннан бүтән бернәрсә уйлый алмыйм, йоклый да алмадым инде. Нәстә өчен белергә кирәк бит, бер зыяны да юк. Шулай итеп, беләлмәдем. Шул көе бетте, хәзер кешегә сөйләргә дә оялам, үзем курыкканга, тагы булмаса ярар ие бу хәл. Кешегә сөйләсәм мин әйтәм, шундый хәл бар бит инде, пәри ияләшкән ялгыз хатынга дип ишеткәнем бар. Шундый хәл дип уйларлар. Инде кешеләргә сөйләсәм, дип куркып йөрием сөйләргә. Шунан уллароыма сөйләдем инде. Шуннан уйлап йөредем-йөредем дә. Мин инде пенсияга чыкканнан бирле дини китаплар укып, динне өйрәнеп, абыстай булып йөрдем. Шуннан хәзер шуңа ябештем инде. Әллә, мин әйтәм, бу Ходай Тәгалә әллә дөрес, әллә түгел дип ышанмадык бит инде, гомерем буе ышанмадым. Мәктәпкә барам, балалар сорый бит инде. Бар ул, балалар, Алла бар дип булмый бит инде. Берүзем, активист юк иде авылда, берүзем, бөтен эшкә. Җыелышлар, берсеннән дә калмыйм, колхозныкымы, сильсәвитнекеме, мәктәпнекеме – вич йөрим, төннәрдә кайтам, берүзем яңгырларда-бураннарда. Чишмәне беләсезме? Шул чишмәнең, күпер өстеннән үтәбез инде, мин шул күпер төбендә йортта торадырыем инде элек, элек тормышка чыкмас борын. Шунда күпер өстенә басам да, төннә собраниядан кайтканда, Алла Тәгаләдән ялынып сорыйм:

– Алла Тәгалә, – димен. Барлыгың дөрес булса, – дидем. Су инәсе бар дип тә сөйлиләр бит инде, чишмә иясе бар дип тә сөйлиләр бит инде. Әгәр, мәйтәм, барлыгың дөрес булса, Алла Тәгаләгә ялынам күпер өстенә басып, миңа берәр могҗиза күрсәт, димен. Йә су инәсе күрсәт, йә тегеләй-болай берәр могҗиза күрсәт димен, ялынам, күрсәткәне юк, күрсәтмәде бер дә. Менә шуңа ябештем инде. Шулай дип үтенәдерием, шулай дип ялынадырыең, мына сиңа дип Алла Тәгалә шулай күрсәткәндер

дип, шулай дигән карарга килдем инде аннан соң. Менә шулай булгач, бар значит. Шундый нигә килдем. Тәү, кешеләргә сөйләргә курыктым, ялгыз хатынга пәри ияләшкән дигән сүзләр дә була бит инде. Кешегә сөйләсәң шулай дип уйларлар. Бөтен теләгем үтәлеп тора, Әлхәмдуллилләһи шөкер.

*Бакча авылында*
*Тимербулатова Миңниса Минневәли кызыннан (1924 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## Җен алмаштырган

Җен алмаштырган, җен ияләшкән дияләр ие. Мин ишеттем. Бер бала, үсми торган бер бала булган инде. Шушыны укыганда бер ахирәтем сөйләгән ие. Шушыны җен идән астына алып кереп киткән дә сыймаган шунда. Шул җен алмаштырганнан соң, үсмичә калган теге бала. Ул 15 яшькә хәтлеме, 18 яшькә хәтлеме шушы бәләкәй генә көенә бишектә генә яткан. Аңа шул манный, сөт эчереп кенә тотканнар инде.

Монауны җен алмаштырган дип әйтәләр. Шуңа күрә пычак, йә кайчы – острый әйбер куеп йөрергә бит инде, корал. Җен куркырга.

## Җен баласын коендыра

Су өсләрен, тоз өсләрен, ризыкларны һәрвакытта каплап йөртергә кирәк. Менә сөтне капламасаң, җен баласын коендыра икән.

Бер кендекче әби булган, миңа сөйләделәр әле, яңарак кына. Шуннан соң ул сөтен элеп киткән дә чөйгә, но капламаган өстен, сөтнең өстен капламаган. Бу кемгәдер барган бала таптырырга, бәбәйләтергә барган инде. Бу сөткә аның алтын йөзеге төшкән булган. Хәзер, бәбәйләткән дә бу сөт белән коендырганнар җен баласын, җен хатыны тапкан бит инде баланы. Караса мында аның теге йөзеген күргән. Бу бит минем сөт дигән, минем йөзек ие бит, дигән. Кайтып караса, йөзеге юк ди инде тегендә. Ризыкларны, суны капламыйча йөрмәгез, анда җен баласын коендыра диләр бит инде. Мына ул чын итеп күргән.

**Җәелеп куелган намазлык**

Мына миңа шулай намазга торганда, соңга калсам шушылай итеп тукылдаталар ишекне. Мин аны нәрсәкәй дип әйтәм? Ничек аңлатырга да белмимен. Шушы намаз вакытында бер-ике тапкыр ишекне тукылдаттылар. Мин ишетерлек тукылдаттылар. Нәрсә дип әйтеп була инде? Җендерме ул, фәрештәләрдерме, нәрсәкәйме?

Тиз генә тордым да, Стәрлетамакта идем, карасам, төне буе сөйләшеп яттык, соңга калганмын иртәнге намазга. Карасам, тордым да, тиз генә йөгердем юынырга. Хәзер килүемә намазлык җәелеп куелган. Мәйтәм, Нажия син җәйдеңме? Юк, ди. Мына бу могҗиза бит инде. Мин бит инде тордым да, намазлык җәеп тормадым, тәһарәт алырга йөгердем. Килүемә җәелгән кыйбла ягына каратып.

*Бакча авылында*
*Рысаева Минзия Мөдәррис кызыннан (1959 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Барын да ишеттек, күреп тә беттек без. Алар безне үтеп кенә китәләр. Без йә былай торабыз, тырма-сәнәк күтәреп. Төнге эштә ул күренә, ат менеп чабалар, җә үтеп китәләр. Мына шулай, мин күп күрдем. Битен корган, килә әкрен генә шундыйларын күп күрдек. Адәм сүрәтендә күрәм. Башы томалап килгәнен күрмим нәсә икәнен. Белсәң, яхшы догалар укырга да куарга җеннәрне исеме белә(н) әйтеп. 12 җеннең исеме бар. Алар үзләренчә сабраниялар ясый бит. Шулай, әтәч кычкыргач. Хәзер, балам, бигрәк тә күбәйде алар. Менә кеше караучы күбәйде, беләме-белмиме, күрәзәче, шунда баралар, ул нәсә белә Алладан узып? Ана шунда инде җеннәрнең оясы самый. Менә безнең, балам, дитсад, мына школ, мына клуб. Убшый магила анда. 1921 ачлык булган, халыкның үлгәннәрне күмәргә хәле булмаган, шунда җыйганнар да атлар канушнаена көзнеме январь, февраль, мартта шунда җыйганнар туңдырып. Мин 4 класста укыганда, балаларга су эчәргә кое казыдылар анда. Коедан кызыл балчык чыкмый, ак балчык чыга, сөякләр чыга башлады. Шуннан аны бикләп ябып куйдылар, теге убшый магила очраган диеп.

*Өч-Әсән авылында*
*Галәветдинова Бәлхия Гыйззәтулла кызыннан (1931 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## Йорт иясенә – андыз тамыры

Бар, бар. Ул йорт иясе мин килгәндә (мин бу өйне сатып алдым) зрә тынгылык бирмәде. Мин бабай белә(н) килгәнием. Бабай әйтә, сез беләсезме, бу өйдә бит без икәү генә түгел, тагын өченче кеше бар ди. Беләм дим.

– Куркасыңмы?

– Курыкмыйм, мәйтәм, син булгач.

Шап итеп ишекне яба да ишекне ачып керә дим.

Шуннан бу пенсиягә дип киткәние, Казахстанның әллә Теректанский каян килгән кеше ие ул. Минем фронтовик бабай үлгәч, куркам, дип йортка керткәнием. Шуннан хәзер мин бер бидра андызны кисеп кайнаттым да, бөтен почмакларга сиптем дә шуннан ул югалды, ул курка икән андыздан. Аны миңа өй саткан кеше, яшь кешейе 40 тагынамы. Әйдә, йорт хуҗасы, йорт анасы, мин кая китәм, син дә минем белән, мин китәм бит, әйдә минем белән, дип әйтмәгән. Әйтсә, ул анда булмый, ул аның белә китә. Мин өч рәт кереп әйттем, әйберне төягәч, өемә. Аны (андызны – *И.Я.*) сентябрьдә казырга була, тугайлыкта сазлыкта. Тамыры кирәк, чәчкәсе сары була, шуны 1–3 не өзеп мендәр астыңа куйсаң, бер дә саташмыйсың. Чәчкәсе дә аның хәсиятле. Андыз кирәк.

*Өч-Әсән авылында*
*Гафиатуллина Мөбарәк Муллагали кызыннан (1930 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## Җен-пәриләр

Җен-пәриләрне сөйлиләрие бит инде аны. Күрше бер әбигә килгәннәр дә:

– Әби, мунчага бар, дип әйтеп киткәннәр.

Әби мунчага барса, кайтмаган, иртән барсалар, әби үлгән, эчәкләрен киштәгә элеп куйганнар икән, теге җеннәр булган дип сөйлиләр.

## Җенне чокыр

Урман бит. Эчендә чокыр тирән генә, шунда җиләккә барган кешеләр адашкан, шуңа «Җенне чокыр» дип атала.

* * *

Монда бар иде Әсмә әби белән Гөлҗиһан әбине кыз бала җитәкләп алып киткән дигән риваятьләр. Алар халыкка күрәзәче булып, өшкереп йөрделәр. Аларны шул җеннәр апкитеп укыткан да, аларда сәләт барлыкка килгән.

– Кыз бала килеп җитәкләп алып китте, кая барганын да белмим, иңдерделәр дә китереп куйдылар, дип сөйләгәне генә Әсма апаның.

* * *

Абзар иясе дигәне атның йә ялларын үрә, йә ат иртән торуга шыбыр суга баткан була, яратмаса.

*Яшерган авылында*
*Мухтаруллин Һидиятулла Ибәтулла улыннан (1942 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## Федр җене

Хәзер әниләр май сатырга бара. Иртән иртүк караңгыдан чыгып китәләр. Хәзер майны тутыралар, бидрәләргә тутыралар. Хәзер тегендә ниндидер эчерек әйберләр ята икән, теге эчерек әйберләр яна икән ут булып, нишләп ул вакытта янгандыр инде ул. Безнең әни смелыйрак ие. Булса булыр, күренсә күренер, Ходай кушмаган эш булмас, мин чыгам да китәм бу тирәне дигән. Иптәшләре инде аның артыннан ияргән. Менә шулай итеп, Федр җене дип әйтәләрие. Безнең Сухой изәк монау турда инде ул. 18 км ул. Шунның арасында болар турыдан бара базарга Федорга (Федоровка. – *И.Я.*).

## Йорт иям бар

Хәзер Равил кайта, былтыр көз көне генә ул. Йорт иям бар.

Шуннан әйтә: Син ялгыз яшисең, без сине ныклап карый алмыйбыз, әллә сатып, Уфадан квартира алыйк микән? – дип әйтә. Бергә булырыек, бөтенебез дә Уфада, ди. Баланыкы да дөрес инде. Ярый, алай булгач, мин әйтәм, сатсагыз сатыгыз инде. Әтиең элек тә әйткән иде: Эй, балалар кайта мени инде, берүзең бит, ния кермисең, кайда йөрисең дип. Бәрәңге ята, берүзем

казыйм, берүзем чүплим. Нык итеп авырый, нигә кермисең, ния мине ташлыйсың, дип. Син сат та шәһәргә кит. Син шәһәрдә лучше яшисең, диде.

Әтиең дә шулай дип әйткәние инде. Барсам барырмын да куярмын дип әйттем бит инде.

Туктале, мин әйтәм, зрә ашыктырмагыз инде. Хәзер сөйләштек. Шуннан яттык та, диванда ятам инде. Яткан көйгә:

– Барма! дигән аваз минем колагыма яңгырады. Башка бер сүз дә юк.

*Тәтер-Арслан авылында*
*Мөхәммәтшина Әнвәрә Хәмәтһади кызыннан (1941 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Әтинең әтисенең (исеме) Камалтдин.

– Камалтдин, атың колыннады, дип йорт иясе әйтте, дип әниләр-әтиләр сөйлиләрие. Элек бит тәрәзәдән ишетелә иде. Хәзер ул тәрәзәдән ишетелми бер нәрсәкәй дә.

Йә сыерың бозаулады дип әйтә ди, йә тегеләй-болай.

* * *

Әйтәләр. Яшел таяклы, актан киенгән бабай Хозур Ильяс була.

Хозур Ильяс булсын юлдашың, диләр. Күзгә генә күренә дә аннан юк була ди ул.

* * *

Кешеләрдән ишеткәләгәнем бар инде. Безнең Яшерган ягыннан килгәндә, күпер янында ат туктап, шыбыр суга төшеп баралмый, дип сөйлиләрие. Йә төкеренергә, йә сүгенергә.

*Тәтер-Арслан авылында*
*Садретдинова Миннур Сәбәхетдин кызыннан (1938 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### Абзар иясе

Бер ат иртән торсак, ди, шыбыр тиргә баткан була, ди.

Әгәр ат шыбыр тиргә батса, абзар иясе яратмый малны. Яраткан атны ялыннан үрә.

## Җен ияләшкән

Менә кайвакытта бит әйтәләр җен ияләшкән дип, ялгыз әбиләргә, шундый очраклар булды. Зөһрә дигән әби барые, күптән мәрхүм булган әби инде. Җен ияләшкән дип әйтәләрие. Төннәр буе шушы әбине җен җафалый ди торганнарые. Шуннан соң ул әби кайларга баргандыр, ансын белмим.

Тоз белә(н) дә була, ишеткәнем бар минем.

Барыбер догалар белән чыгаралар. Алар бит догалардан куркалар дип әйтәләр инде.

## Хозур Ильяс

Минем ишетүемчә генә, Ибрайдагы бер апага очыраганын ишеттем. Хозур Ильяс дип әйтик микән, кеше кыяфәтендә булган. Аның башына зур кайгы төшкән булган апаның. Баласы үлгәнме. Шушы вакытта ул җиләк җыярга барган. Урманда йөргән вакытта (Хозур Ильяс булгандыр инде ул) ак сакаллы, ак киемдәге кеше килеп чыккан каршына. Шул киңәшләр биргән бит инде. Кайгыларын алган аның, үткәрергә өйрәткән.

*Тәтер-Арслан авылында*
*Мөхәммәтшина Гүзәлия Ягъфәр кызыннан (1960 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Менә сыер бозауларга тиеш.

Әнкәй: Нишләр инде, Аллаһым саклар инде, таза-исән котылса ярар иде, дип ятып йоклыйбыз, ди. Сәгать 4 тә тәрәзә шакадылар, ди. Чыксам сыер бозаулаган. Йорт иясе уяткан.

*Айдарәле авылында*
*Мишаров Гыйлемхан Сәлимхан улыннан (1951 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Бардыр инде ул. Тәрәз шакыйлар, уянам. Йорт иясе буладыр инде. Тәрәз шакып уяталар шулай.

## Сул кул башыңда пәри утыра

Картәниләр сөйлиләр иде аны, җен дип. Менә мин сулакаймын үзем. Ну бәләкәй чактан, күрәсең өйрәткәннәр инде, сул

кул белән ашарга ярамый, уң кул белән ашарга тиеш. Картәни мәрхүмә әйтәдерие:

– Балам, уң кулың белән аша. Уң кул башында фәрештә утыра, сул кул башында пәри утыра диеп. Шуңа күрә мин сул кул белән ашамаганмын.

## Габсабир күпере җене

Арслан белән безнең Айдарәле арасында Габсабир күпере бар. Анда постоянно авария. Элек Габсабир дигән кешенең тегермәне булган. Элекке борынгы бабай. Шунда су тегермәне булган, юл буенда. Күрәсең революция вакытында тегермәнен тартып алганнармы, җимергәннәрме, яндырганнармы, ансын инде әйтәлмибез. Шуның ияседерме, җендерме, халык сөйләве буенча, ат белән кайткан кешеләрне яратмаган – ат тугарыла икән үзеннән үзе. Габсабир күпере, үзенең яры бар аның, биек кенә кызыл балчык, бер 3–4 метр бар. Борылмалы гына урында шунда ясалган булган инде. Яратмаган атны тугара икән, кайсы шыбыр тиргә батып кайта атлар.

*Айдарәле авылында*
*Мишарова Нурия Зариф кызыннан (1950 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## Куян очында җеннәр бар диләр

Куян очыннан төшеп киләбез. Без апаның бер подругасына барып кич көне кайтып киләбез. Бу бит мине иптәшкә алды. Монда бер ердә ут юк. Хәзер киләбез, безнең артыбыздан колокольчик килә.

– Апа, минәйтәм, ишетәсеңме, дим. Кыңгырау чыңлый.

– Син дә ишетәсеңме. Мин синең кесәңдә берәр нәрсә шылтырый икән дип киләм.

Мәйтәм, юк, минем кесәмдә бер әйбер дә.

– Синең клуб ачкычларың түгелме?

– Миндә бер әйбер дә юк, дим.

Мин нык ышанам җен бар икән дип. Урман якын, зират якын. Хәзер шушы колокол тавышы әкренләп кенә килде-килде дә, шушы поворотка килеп җиткәндә, Асия апа әйтә миңа:

– Син, ди, Гөлшат сызгыр, ди. Мин дога укыйм, ди. Или беребез сүгенәбез, беребез дога укыйбыз, ди.

Хәзер тотындым мин сызгырырга. Асия апа дога укырга тотынды. Шул моментта, мин сызгырганга монанда ниндидер эт өрде, этләр өрә башлады да эт өргән тавышка менә шушы колокольчик артыбызда бетте дә куйды.

– Артыңа борылма ярамы(й), артыңа борылма ярамы(й), диде. Куян очында җеннәр бар диләр ие, элек булган ул.

## Габсабир күпере

Арсланга таба үткәндә, яшь вакыт, бардык аулакка. Кайтып килер сәгать 2 белән 3 арасы, шунда юл буенда шушы Габсабир күпере дигән ердә ап-ак киемдә бер кеше ята. Өчебез дә күрдек шуны. Ап-ак кием белән ята. Үлгән кеше кебек ята. Безнең арттан баручыларга:

– Күрдегезме?

– Юк, күрмәдек.

* * *

Мөнир белән Фәрит барганнар Арсланга, аулакка. Кайтканда, әнә шул күпер янында нәмә булгандыр инде, ди, мотоцикл белән тәгәрәдек инде, ди. Тик томалдан, ди, кайтып килгәндә.

*Айдарәле авылында*
*Хәбибуллина Гөлшат Гыйбадрахман кызыннан (1962 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## Иренең җаны күбәләк булып кайткан

1999 елны булды. Байтимеров Җәүдәт 1933 елгы иде. 66 яшендә китеп барды. Ул пенсиягә чыккачтын, колхозга эшкә чыкты, фермалар агартырга куштылар. Шунда эшкә киткәние. Йөрәгенә приступ булып вафат булды. 30 августта, икенче көнне туганнар җыелды, авылдашлар җыелды. Бик зурлап җирләдек, җиренә җиткереп, авыр туфрагы җиңел булсын. Без дә җирләп

кайтканнан соң, муллалар, үзебезнең агай-энеләр, балалар белән Коръән укытып әрвахларның рухына. Шуннан халык таралышканнан соң, аш эчәргә алып киттеләр монда килгән балаларны, туганнарны. Без ике сеңелем белән, Стәрлетамактагы, калдык өй саклап. Шул гадәт бар, йола бар. Ана шул алдагы якта өстәл тора бит, шунда без икәү утырабыз. Флүрә сеңлем белән. Әллә 3 көн дә, 7 көн дә диләр бит инде. Бер сеңлем басып торае, хәзер шулай сөйләшеп торган арада әнә шул өстәлнең аксыл, ап-ак, саргылт, үтә күренмәле матур күбәләк инде очып чыкты да ишеккә кунды. Күпме генә үтеп тә йөрибез, кузгалмады шул тәрзәдән ишекнең.

Икенче көнне алар да күрде, без сөләштек бит инде. Хәзер карап торабыз. Шуннан бу күбәләк фәрдәдә юк ие, хәзер карасак түшәмдә тора. Көн буе кузгалмады. Икенче көнне сеңелләрем кайтып китте. Килеп, Мансур улым, балалар куна килделәр. Мин шул күбәләкне күзәттем. Күз яздырмыйм бит инде, күбәләк тора, ул түлке төннә күчә. Икенче көнне икенче тактага күчте. Мына ул бит могҗиза. Төн саен алышынып торды, төннә генә күчә. Җиденче тактага күчте, җиденче тактага күчкәч, хәзер 7 се етте бабайның. Аш әзерләдек 7 сен үткәрергә. Мулла чакырдык, туганнар җыелды тагын. Шулай итеп аш үткәрәбез, күбәләкне күзәтәбез. Күбәләк түрдәге фәрдәдә, шул фәрдәгә кунды, күбәләк тора, бернәрсәгә дә кымшанмый. Коръән укып беттек, аш ашадык, халык таралашты чәйләр эчкәч, балалар калды әзрәге, ике сеңелләрем. Хәзер карасак күбәләк юк. Коръән укытып, кеше таралышкач, күбәләгебез юкка чыкты. Шулай итеп, шул могҗиза булды.

Бу Аллаһы Тәгаләнең могҗизасы, бу бик бәләкәй, миндә аның зурлары да булды.

*Бакый авылында*
*Байтимерова Нажҗия Шаһиәхмәт кызыннан (1937 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Сурлытау ягында, бит инде әйтәләрие, безнең ферманы чыккач, Сурлытау дип атала. Менә шунда убыр уты күргән, менә фәлән абзый күреп кайткан, фәлән кеше күреп кайткан дип.

* * *

Зәхмәтле урын дигәләштергәннәрне ишеткәнем булды.

* * *

Электән үк әйтәлирие йорт иясе бар менә, карап йөрегез. Сәнәк-көрәк очырып йөрмәгез, олылар әйтәдерие бит инде, сөяп куегыз, элеп куегыз. Йорт иясе үзегезне абындырып егылдыра бит.

* * *

Чуакай дигән ялан бар безнең. Әнә анда саташмыйча йоклап булмыйдырые. Анда бит инде берничә өй булган, зиратлары булмаган бит инде, әйтүләренә караганда. Бер кое барые инде. Ул кое хә күмелеп бетте инде. Саташтыра, бастырыла, ә бүтән яланнарда йоклыйм тыныч.

*Бакый авылында*
*Гафиев Зөфәр Габдрахман улыннан (1938)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Безнең бер вакытны, әни сөйли иде:

– Сыерың бозаулый бит, чык туңа бит, дип. Әллә ничә мәртәбә булган. «Чыгыгыз, сыерыгыз бозаулый бит» дигән тавыш. Шакыйлар.

Өй иясе әйткәннәрен ишеткәнем бар.

* * *

Җеннәр-пәриләр бар дип кешедән ишеткәнем бар.

Бәрелсәң:

Тьфү-тьфү,
Пәригә авырлык
Миңа җиңеллек, диләр ие.

* * *

Хозуры гел коры җирдә йөри бит инде. Ярдәм кирәккән кешеләргә ярдәм итә Хозур дигәне. Ильясы икенче кеше бит инде аның. Ильясы – диңгез буйлап кемгә ярдәм кирәк, шулай

итеп йөри. Олы кеше булып күренеп ярдәм итә, ди. Озын киемдә күренәләр кешегә. Ярдәм итәләр ди.

*Стәрлебаш авылында*
*Сәгыйтова Галия Төхвәтулла кызыннан (1941 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## ЫШАНУЛАР, ЫРЫМНАР, ЙОЛАЛАР, ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР

Тимрәүләрне догалар укып сызганнардыр. Өшкергәндә:
– Минем кулым түгел,
Гайшә Батман кулы.

Миннән өшкертәләр. Башларыннан тотынам да инде, колагын тотып, кыскалап өшкерәм дә (дога укып). Иң тәү «Әлхәм»не укыйм, аннан соң «Аятел-көрси»не укыйм, «Фәләк» белән «Нәс». Алар нык зур догалар, «зәхмәттән» саклыйлар. Шуларны укып өшкерәм. Сабыйларны өшкерәм. Аллага шөкер, тыным килешә.

* * *

41 ясин чыгабыз әрвахларга, кырыгына хәтле көн дә бер искә төшереп, 40 көн буена 41 ясин чыгабыз, шуны кырыгында ниятлибез, тыныч ятсын, җавапларын әйбәт бирсен, дип көн дә телибез. Әле менә 2 егет, кичә икесенең дә 7 се булды, шуларга 41 ясин чыгарга куштылар. Ясин чыгам, теләкләр теләп каберләре киң булсын, караңгы гүрләре якты булсын, урыннары җәннәттә булсын, бәхил булып ятсын, безгә риза булсын, арты хәерле булсын, дибез, безгә бәхет калдырып китсен, гомер калдырып китсен. Мәетне апчыгып киткәндә шуны теләп калабыз. Мәетне апчыгып киткәндә үзенә «Фәскурун» догасы бар, шуны укыганнан соң, җыештыра башлыйлар. Зияраттан кайтканчы җыештырып бетереләр инде. Зираттан кайткач, кереп укыйлар да мәеткә багышлап. Икенче җирдә ашын әзерләп өчесен, җидесен үткәрәләр бергә. Алдан үткәрергә ярамый диләр, хәзер муллалар яңача бит ул. Әле дә бар ул аерым-аерым үткәрү.

*Куганакбаш авылында*
*Ишбулдина Мөзәлифә Корбангали кызыннан (1940 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Әйбәт итеп, менә мәетне апчыкканда утыргычны аударалар. Ул аудару бик әйбәт. Мәет ята, яткан йереннән юарга кирәк, кузгатырга түгел. Югач, күтәреп апчыгып киткәч, башы белә чыгып китә, аягы белә ләхеткә китә. Чыгып киткәч, утыргычны аударалар. Аумыйча калырга тиеш түгел. Аумыйча калса, ул мәет тели.

**Ат башы салу**

Анарга кеше ияртеп барырга түгел. Үзең генә, аяк тынган вакытта гына барырга кирәк салырга. Су буена төшәргә кирәк. Су буенда тәһарәт алып, җуынып, әйбәтләп намаз укып, башны салырга кирәк, ат башын. Башны әйбәтләп тазартып, юып баш сөяген салырга кирәк. Аны суга саласың да бәйләп куясың. Суга салганда: Аллаһы Тәгалә, хәерле яңгырлар бир, шәфкатең белән бир, бәрәкәтең белән бир. Аллаһы Тәгаләкәем, безне ташлама, берүк яңгырларны бир, дисең. Башка бау тагасың да тал ботагына бәйләп куясың. Аны кузгатып торырга кирәк, әзрәк яумыйча торса. Яңгыр күп яуса, ат башын алып торасың. Аны апкайтып куясың. Кайда торса да ярый, ташларга ярамый. Ул әгәр агып китсә, әнә шул урында ява да ява, безгә булмый. Берәү гомер буе етә, югалмаса. Алай-болай агып китмәсә.

* * *

Өшкерү бар. Дога белә(н). Ярдәм сорыйсың. Безнең әни карыйдырые. Әллә кайлардан, ераклардан бер кеше авырый, ул әле монда да түгел, әллә кайда, Себердәме, Ташкенттамы, Мәскәүдә, әллә кайда еракта шунда. Әнигә әйтеп, моннан торып карыйдырые. Я мәет суына баскан, я кабер ташына бәрелгән дип, шулай әйтәрие. Күрмичә әйтә. Үзе монда утыра. Шулай белә, шундый гыйльме бар ийе аның.

Әйттеләр дә шуны карадым. Яткач, төшемә керде. Менә, бер бидрә су тотты да шул кеше, алып керде дә, зәңгәр сандык ул, сандыкка салды әзрәген. Калганын стинәгә бәрде. Әгәр дә шуны карамаган булсам, ул кеше киткән ийе. Сандык билдәле бит инде нәрсә икәне.

Суны әз генә салды – үлгәннән чак кына калды дигәнне аңлата.

## Пычак белән сызу

Мал зыяннаган җиргә пычак белә сызасың, мөешләрен сызасың, ишек башларын, тәрәзәләрен. Шуннан әйбәт була инде маллар зыяннаса. Сызганда укыйсың үзең белгәннәрне. Укымыйча түгел. Мөештән башлыйбыз. Кайсы булса да. Бөтен абзар беткәнче. Буеннан (өстән аска) сызып төшәсең. Нинди булса да ярый, түлке пычак булсын. Азакта аны юарга. Суда. Тышта, Пычакны хуҗаның үзенә бирәсең. Пычак белә(н) эшләргә кирәк, пычаксыз булмый.

* * *

Йортта шикле әйбер тапсаң, аны чокыр кебек җиргә, кеше басмый торган җиргә ташларга кирәк.

Алгач, төкереп-төкереп ташлыйсың, 5–6 мәртәбә төкерәсең инде. Ташлаганнан соң аның урынын тазартырга кирәк. Өшкергәч, тазаруга керә инде ул, дога белә(н) тазартасың. Искечә дога белә(н) укыйсың инде. Дога, үзең белгәнне укысаң, доганың бәләкәе юк, бөтен дога да зур ул.

## Таң суы

Таң суын алам да инде алуын, түлке моннан төшәргә урын юк, күзем күрми.

Э-эх, ул таң суы. Таң суына кояш чыкканчы барырга кирәк, таң алдыннан, таң чыккач ярамый. Аны укып барасың инде, укымыйча ярамый. Укырга кирәк, барганда да укырга кирәк, кайтканда да укырга кирәк. Үзеңнең белгән догаларың, нәстә беләсең укыйсың да, шул суны аласың да укып, шуннан алгачтын тагы укып алып кайтасың. Таң суы бик әйбәт инде ул. Бөтен авыруга да, күз тигәнгә дә әйбәт. Таң суы белә(н) юыну. Безнең әни күп кешегә алып бирәдер ийе. Әгүзе бисмилләңны әйтеп эчәсең инде. Нинди дога да ярый. Күңелең таза булырга кирәк. Күңелең таза булмаса, шифасы булмый алган суыңның. Таң суын каплап алып кайтырга кирәк, бидраның авызын бәйләп алып кайтасың, яулык белә(н). Таң суын атап алмыйсың инде ул. Бөтен кешегә дә җитә ул. Ул бит аерым гына түгел. Таң суын агым судан алырга кирәк. Аккан елга суы(н) алырга кирәк. Агымнан аласың инде. Аны

болгатып түгел, бер бәләкәй савыт белә(н) өстен генә. Ул файдалы таң суы.

* * *

Яшь баланы бер үзен генә калдырып китәргә ярамый, өстенә пычак куярга кирәк. Бер яшькә кадәр өстенә пычак куясың, чыгып киткәндә. Пычакны сузып куясың. Авырлы хатынны берүзен калдырырга ярамый. Кагыла инде, андый вакытта бигрәк тә.

* * *

Мәет чыккан өйне берүзен кундырырга түгел. Кырыгына хәтле берүзе кунырга түгел. Кырыгына хәтле ут сүнергә тиеш түгел. Утны сүндермәгез, өйне ялгыз кундырмагыз. Төннә утны сүндерергә түгел.

Мәет юган суны кеше басмый торган ергә салырга. Сарай баганасы була, абзар баганасы була. Багана төбенә салырга кирәк. Кеше басмый торган урынга. Ул суны чайкалып та апчыгырга түгел. Багана төбенә салырга. Мәет суына басарга ярамый. Мәет суына басса – карыйсың инде.

Кәфен теккән энәне һәр кешегә таратып бирәләр. Кәфеннәгән кешегә дә, шунда утырган кешегә дә, энәләре күп булса. Аны тотынасың (кулланасың). Озын җеп белә(н) кәфен тексә, ул кешенең гомере озын була.

* * *

Артыш агачы күз тимәскә әйбәт була инде

Бала тугачтын башлыгына мәләш агачын тегеп куясың, бәләкәй була инде, менә шундый озынлыкта (0,5–1 см). Зыян итми инде ул. 5–6 яшькә хәтле. Ишеккә, абзарга да дага кадакларга кирәк. Даганың ботаклы ягын кергән якка куярга кирәк. Үкчәсе даганың йортка карап торсын, ат дагасы.

* * *

Маллар исән булсын өчен, гошер бирәләр. Малларның гошере итеп нәрсә бирсәң дә ярый. Анда сөтен бирәме, каймагын бирәме.

Көтүгә чыгарганда да гошерен бирәләр. Малым исән-сау йөрсен, бүген көтү чыкты, малым исән-сау йөрсен, дип. Мескеннәргә бирәләр.

Көтүчегә өйдән ашату кирә. Күкәй дә биргәннәр, май да биргәннәр, чабатасын да биргәннәр.

### Мәчет ыңгырашты

Мәчеттән кайтып килгәндә, менә бәләкәй мәчет ыңгырашты. Кибет ягыннан килгәндә дөбердәде бертөрле. Шуннан кайтып барам бит инде, хәзер бу яктагысы ыңгырашты. Әҗәл авыруындагы үлер чиккә җиткәндәге кебек итеп, кызганыч итеп ыңгырашты ул. Әй, Илаһым, шул хәтле. Анда бит Харисның кызлары тора, шуны яратмады. Әй, кызганыч итеп ыңгырашты.

Манарасында бер кош сайрыйдырие, хәзер мин киткәч, кайтуыма юк инде шул. Мәчеттә торырга ярамый. Шуны яратмый. Нәрсәдер бер әйбер була шунда.

* * *

Бер елны яңгыр яумады. Әй хәзер, якында гына колын кешнәде. Ул яңгырның явасын белдереп шулай булды. Шуны күргәннән соң яңгыр яуды. Көндез инде. Аръяк зират яктан ишетелде. Колын кешнәгән кебек, еракта ийе, шуннан якынаеп-якынаеп, шуннан бетте, яңгыр яуды. Миңа Алланың мәгълүматы булып аңлашылды инде.

* * *

Манараны киссәң, икенең берсе була: йә шунда ук китеп бара, йә үлгәнче гарип булып кала. Бәдретдин абзый белән безнең арьяк Кәфи бабай мәчет манарасын кискәннәр. Ана үзләре үлгәнче гарип булдылар. Совет чорында манараны кискәннәр.

### Изге урыннар. Нарыс тавы

**Изге урыннар** бар инде ул. Шулар булмаган урын изге инде ул. **Нарыс тавына** бардым мин, эй анда рәхәтлек. Миякә районында Нарыс тавына барасың. Күңлеңне, изге уй белә(н) барасың, алама уйлар белә(н) бармыйсың. Баргач намаз укыйсың, белгәнеңне укыйсың, күңелең изгелектә булсын инде.

Әгәр күңелендә изгелек булмаса, анда тауга да менәлми. Аның тавы биек. Суга да керәлми. Аның су керә торган урыны бар. Сәламәтләнү өчен шул суга баралар инде. Аннан кайтасы килми, рәхәт. Тау башында әүлияләр-әмбияләр зираты. Аны 7 мәртәбә урап укыйсың. Берсендә ат күмелгән, диделәр. Әүлияләр-әмбияләр чуалышы булган да шул вакытта. Шунда үлгән атны да күмгәннәр. Ике тау. Әүлияләр-әмбияләр зираты аерым. Мәчет бар. (Таудан) төшкәндә әүлияләрнең әрвахы безне озата килде. Аңлата алмыйм мин аны. Килде дә ак күбәләк булды. Шул күбәләк безнең белән алдан барды-барды да шул күбәләк хәзер юк булды. Минем белән барган кешеләргә:

– Монда күбәләк бар иде, күрдегезме?

– Юк, диләр.

Әүлияләр иң яхшылар алар, әмбиялар. Гөнаһалы кеше тауга менәлми, җил-давыллар аптөшеп китә.

Ураза вакыт бит инде, башка су коябыз – башка су тимәй. Уразасы ачылмасын дип, суны тидермәгән, Аллага шөкер.

## Бала йөрмәсә

Бала йөрмәсә, менә май үләне җыеп, аны тимер белә(н) кисәргә түгел, җылы кул белә(н) өзеп, белгәнне укып, әйбәт итеп җыеп, менә шул май үләненә кертергә кирәк. Малаймы-кызмы кем булса да. Аңа нинди үлән дә ярый. Безнең әни җыяр иде: барганда бер яклап, кайтканда икенче яклап. Барганда суң яклап чыгып бара, кайтканда үң яклап җыеп кайта ие. Сәгаткә генә карап кертәсең, 10 минут җитә, йөрәге әйбәт булса, ярты сәгать кирәк. Корытага бөтен гәүдәсе белән яткырасың. Кайнаган суга саласың да, үлән пешә, өстен каплап куясың пешсен өчен. Май үләненең файдасы бик күп аның, зрә күп. Май үләненең файдасы бөтен дарулар файдасыннан да зур.

Май үләне бик кирәк. Аңа 41 аксыргак саладырие әни. Сазлык урында үсә ул аксыргак. Анысы да әйбәт.

Май аенда кечеткән, әрекмән. Икесен бергә кушып тыгып утырсаң – аяк яңа туган баланыкы кебек була. Май беткәнче ярый. Искечә. Хәзерге май уртасыннан алып июнь уртасына

кадәр. Үлән чыгу белән агулы була. Кыш буе ята бит инде ул. Май себеркесе тагы да әйбәт. Май себеркесе коелмый инде ул, әйбәт була. Ул каймак кебек була. Шифалы. Иснәп-иснәп чабынсаң, эх аның шифасы!

**Мунчадан чыкканда**

Сәгать 12 дә ярамый. Зәхмәтләрнең оҗмахы шунда, базарлары була. Мунчадан чыкканда: Әгүзе... бисмиллаһи рахмани рахим. Абыстай белә(н) мулла килә! – дип ишекне җабарга кирәк. Хәзер килә, дип. Шайтаннар килми.

**Кот салмасы**

4–5 күкәй алып, шуннан камыр басыла. Кот салмасын 40 мәртәбә укып саласың табага. Курккан кешегә ашатасың. Табада пешерәсең. Ул бит майсыз – яна, май белә(н) йомарлап-йомарлап – кот салмасы диләр инде аны.

**Кот салу**

Безнең әни курккан кешегә кот саладырые. Суга кургашны саладырые. Суга саласың да курккан әйбернең сүрәте төшә. Эттән курканмы ул, песидән курканмы. Нәрсәдән курккан – шуның сүрәте төшә. Атап саласың.

**Күк кабагы (капусы) ачылу**

Төнне сакласаң күк кабагы ачыла. Бик бәхетле кешегә генә ачыла инде ул. Безнең әти ел да күрә иде ул.

Күк капусы ачылганда теләк теләсәң, теләкләрең кабул була. Күк кабагы ачылу. Яп-якты була. Бер генә күрдем мин аны.

* * *

Туйда мунчаны ягасың, булдырасың. Бүләк салып чыгасың мунча кергән кияү белә кызга. Кияү белә кыз кергәннән соң, кодалар керә инде мунчаны. Тегеләр дә сала инде. Мин мунча яккач салдым инде. Анда акча саласың.

Элек урлау бар иде, хәзер урлау бетте бит ул. Әгәр кыз риза булмыйча йөресә, урлап алып кайта, атка салып. Йә кайтып китә, йә торып китәләр. Икенең берсе була инде.

* * *

Балагын салындырып баш кодалар килгәннәр. Баш кодага бүләк бирәләр инде.

Өйнең мөешен төяләр, кодалар кайтып китмәсә озак итеп.

* * *

Ашъяулык җәеп ашарга кирәк. Аңарга фәрештә куна. Сәкегә җәеп ашарга кирәк.

*Куганакбаш авылында*
*Ягафарова Рәхилә Низаметдин кызыннан (1936)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Карга боткасын ел да бер урамда үткәрәләр. Авыл зур бит. Ел да бер урам белән генә үткәрәләр

*Куганакбаш авылында*
*Яхина Хәкимә Тимерхан кызыннан (1961 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## Яңгыр теләү йоласы

Җәй көнне корылык булды бит инде. Аптырап әбиләр белән киңәшләшеп, яңгыр теләргә булдык. Элек безнең әбиләр шулай итә торган иде. Таудан менеп чуен ташлары җыеп алып төшәләр иде. Тауга мендек, бик матур итеп намазлар укыдык, теләкләр теләдек. Теге ташларны җыеп алып төштек тә укып суга салдык. Коръәннән аятьләр укыдык. Шуннан теләкләр теләдек. Шуннан су сибешүләр булды. Авылдагы барлык яше дә, карты да чыккан-нар иде. Шуннан мәктәп столовыйсыннан яңгыр боткасы пешереп алып төштеләр. Бу әйберләрне эшләгәннән соң, яңгырлар явып китте. Бу бик борынгыдан килә торган йола.

Хәзер яңгыр ява бит инде, туктамый гына. Ява да ява. Хәзер күрше әбисе кергән. Әйдәле, Мәгъфүрә җиңгәй, теге ташларны җыйыйк та, кире мендереп ташлыйк. Җебеп бетәбез бит монда дип. Аннан ташларны алып, тауга менеп салдык.

## Бала үссен өчен

Бала үссен өчен, кендек әбисе баланы икенче көнне үк мунча кертә башлыйдыр иде. Ул аны юындырып, эчләрен сыйпап, кадерләп, тәрбияләп. Шуннан соң бала савыгып үсә.

Мунча чапканда:

Әтәң төсле утын түгел,
Әниең яккан мунча түгел,
Шаканай[1] бул, шаканай бул,
Ят та йокла, тор да уйна,
Аю баласы, бүре баласы,
Берне генә биреп аласы, –

дип баланы мунчада чапкан.

*Яңгырчы авылында*
*Абайдуллина Тәкъзимә Әфтәх кызыннан (1943 елгы)*
*Г. Яхшисарова язып алды*

## Яңгыр теләү

Яңгырны берничә ел элек теләделәр. Балаларны апчыгып, без үскәндә дә шул барые ул. Чумара пешереп. Менә җәясең дә тукмачны или камырны басып кына өзеп саласың. Әбиләр бәрәңге турап, шуның белән генә коры аш пешерәләрие инде. Яланга чыгып пешерәсең, авылга кайтып сибешәсең (су). Аш бетә, ачлык, сугыш вакыты.

Әле нәрсә пешерәләрдер. Бер Хатимә дигән апа барые, безнең балаларны алып чыгаларые.

## Яңгыр булмаган вакытта

Үле. Шуның зиратын чокып су салганнары хәтеремдә минем. Каберенә салаларие, ну бер тирән чокыйлар. Бидралап китереп салганнары хәтердә.

* * *

Ат башымы, әллә башмак башынмы нык итеп тирәнгә күмеп куялар ди аны. Абзарның эченә, мөешкә инде. Алай без куйганыбыз юк. Әйтәләр инде ана шулай. Тунап сөяген күмәргә.

## Мәчет урынына утырырга ярамый

Мәчет урыннары кешегә зыян биргән бит инде, утырырга түгел. Мәчет урынында утырган кешеләр бар. Гел каза күрәләр.

---

[1] Шаканай бул – нык бул

Йорт та салырга түгел. Малларыннан или үзләреннән каза күрәләр. Әле менә бездә Яңавылда бар, тынычсыз диләр өйләрен. Өй салганнар ийе ике күршегә. Малларына да зыян килә, үзләренә дә. Мона бер Мансурлар бар иде. Ике хатыны да парализовать итеп үлде, аяксыз-кулсыз булып.

* * *

Кот коюлар, җиргә салулар, аның кебек йолалар бар ие. Халык күтәреп килгәннәр балаларын, шул куркса, егылса.

**Җиргә салу**

Тырнак, чәч – кирәк әйберләрен кисеп алып төн уртасында барып, җиде юл чатына тын гына урынга итеп салганнар инде. Догалары булган бит инде аның үзенең.

Җиргә салу әнә шул әйләндергән бөтен әйберләрен: тырнакларын чәчләрен. Шуннан нindидер күлмәк ишеләрен кисеп-кисеп сала.

Бер укытучының кызы күпердән төшкән ие Карагышта. Картәни шуннан җиргә салып йөрде.

Төннә картәни кайта да җиргә салып, инде саташа, котырып чыга инде картәни, менә зәхмәте кагылган була инде картәнигә. Ә теге кеше мына дигән булып кала. Үзе аша үткәрә, күрәсең. Шундый энергия була, күрәсең. Теге әйбәтләнә бара.

Артка карамаска бит инде. Мына бабай егылды, ат белән. Бер Сары елганыкы, Хәләкәйдә Сары елга авылыбыз бетте хәзер, бәләкәй генә бер авыл иде. Мин килгәндә 29 йорт ийе. Бер әби җиргә салган, Заригалар тавына. Тау, шунда уралыпмы, егылыпмы эштән кайтканда егылган да шул зәхмәте кагылган инде, кызын салган ул, шул егылган да. Артына карамаска бит инде. Бер әби әйткән артыңа карама, дигән. Ерак кына ергә барып салырга кирәк, таулар аша барып. Шул авылга кире кайткан. Кайткан да артына караган. Артына караса, сыер белә(н) бозаулар ашап йөри, ди. Җиде төн уртасында, шарт-шорт ашап йөри, ди. Кайтса, әбинең сыеры да бозаулары да үлгән, ди. Каза күргән, карарга ярамаган. Мына көчле булган, элеккеге йолаларны карале.

Төтәслисең, йә инде әйберен кисеп алып. Күлмәкнең бер кисәген алалар да, күз тиген кешенекең, догасын укыйсың. «Аятелкөрси» бар, «Фәләк»ләр бар.

**Тимрәү имләү**

Менә тимрәү чыгадырые, лычкылдап тора ие куллары, йә яңак-муиннар бозылае. Шуны картәни ниндидер догалары белән кыргаякны төядерие. Шул кыргаякка өшкереп, ул лычкылдап торган тимрәүгә ябадырые. Шул юып алган кебек буладырые.

*Хәлекәй авылында Шәрипова*
*Гәдәния Низаметдин кызыннан (1937 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Халык сугым суя. 3–4 катын эчәк юа, 3–4 ир мал суя. Хуҗабикә ашарга әзерләп утырта. Хатыннар эчәк юарга китә. Кайткач, иң тәү ирләрне ашатып чыгарабыз, аннан хатыннарны ашатып чыгарабыз. Шуннан кичкелеккә яңадан казанны юып, тутырып аш салабыз, аннан өй туп-тулы кеше җыябыз. Шуннан сугым суйган кешеләргә муйин сөякләрен бирәләр. Кунак чакыру булса 6 кич кунак сыйлыйбыз. Кайсы ере иң тәмле – кабыргамы, түш итеме. 4 ир, 4 хатын килә, аларның эти-эниләре, күрше-тирәсе була эшкә кермәгәннәре.

Һаваларда очкан ак кошлардан
Коела микән мамык тузаны.
Дус-иш белән бергә утырганда,
Сизелми дә гомер узганы.

* * *

Әткәй еры.

Нигә икән, нигә синең шаян күзләр
Күзләремә болай багалар.
Әйтче, нинди уйлар, нинди серләр
Керфек очларыңнан тамалар.

*Әмир авылында*
*Мөрәсова Зөбәрҗәт Хөббрахман кызыннан (1934 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

**Тула басу**

Ерлый-ерлый, гөрли-гөрли
Өмәләрдә тула басабыз.
Яшь йөрәктә (йөрәкләрдә) янган утны
Алып читкә атабыз.

Аңнамыйсыз күңел тәрәзәсен
Кемнәр килеп какканын.
Аңнамыйсыз яшь йөрәккә
Нинди утлар якканын.

Тула басып, чәйләр әзерләп, ашатып егетләрне-кызларны, тула бастырып.

Тула басу булды. Өйдә, өстәлдә. Йөнне түшиләр. 4 әр–3 әр кеше утыра, кара-каршы. Киез идәнгә түшәп эшләнә. Тулавы сугалар, 2 төрле йөнне эрлиләр дә, еп беләп, киндер суккан кебек сугалар да, шуннан тегәләр капчык кебек итеп, аннан басалар. 4 хатын, 6 хатын баса аны, күбрәк – зур булса 6 хатын, әз булса – 4 хатын. Чәстә куллы сәкегә салып уратып-уратып тегәләр дә, басалар, баскач сүтәләр, сүткәчтен тагын басалар, аннан су буена аббарып юалар, егетләр дә барып юыша. Басканда бүкәнгә куеп киерәләр, басканнан соң юарга апкиткәнче. Зур бүкән куясың да бүкәнгә басып-басып барасың. Басасың-басасың теге шомара, әйбәтләнә. Калын сукно була.

*Әмир авылында*
*Мөрәсова Зөбәрҗәт Хөббрахман кызыннан (1934 елгы),*
*Басырова Фәһимә Гаяз кызыннан (1942 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Бала салкын тигәннән дә йөри алмый. Таш өстенә утырта торган ием. Мунчадан 3 таш алып кайтасың, я урамнан 3 таш апкайтасың да, кыздырырга кирәк. Чирәм җирне чокып алырга кирәк тә бидрага салырга кирәк. Чирәмне, кайдан алганыңны белергә, ташны да кайдан алганыңны белергә. Ташны кыздырасың да чирәмгә саласың да. Баланы, әгәр тыңлатырмын дисәң инде, чишендереп ыштансыз гына тотарга кирәк. Әгәр дә балаң тискәрерәк булса, киендерәсең дә, триколы булса да ярый,

әкрен генә комган белән су алам да чүпрәкли покрывалны ябынып утырасың да бала пешмәслек итеп шунда тота торганием. Эче киткәнгә дә файда, тәпәй китүенә дә файда буладырые. Бала китәлмичә тора бит инде тәпәй. Аягына баса шул бала. Шуннан теге зәхмәтне, бер өч көн буена каен чирәме алсам, шунда илтеп салып, Салават укып, баланы шулай лечить иттем дә үз балаларымны, эче киткән баланы да и тәпәй йөри алмаганын да. Минем әнидән күреп эшләдем мин. Баланы хәзер беләмиләр бит.

## Кот кою

Бала куркты, **кот коярга** кирәк, диләр бит инде. Без баланы бервакытта да ычкындырмадык бит, баланы коендырам да, нык тота идем баланы, чтобы кулын күрмәскә кырыгына хәтле. Шуннан тимер аласың да, инде нинди дә булса. Баланы сискәндерергә кирәк, бу кот кою була (Салават әйтә) – 3 мәртәбә әйтеп, бала янына киләем дә тимерне бала тың гына торганда капылт кына нитәм, дерт иттерәм, баланың тавышын чыгарырга кирәк, калай табасыңмы анда, бер епкә тезәсең дә инде. Шуннан үзең карамыйча гына теләсәң, бер кеше йөрми торган ергә ташлыйсың инде илтеп, үзең борылып карамаска кирәк инде тимерен.

– Нишлисең болай? Нишлисең болай?

– Баланың коты очкан, кот коям.

Баланың коты очкан, кот коям. Минем баламда торма, чыгып кит. Җиргә сеңеп кит, дип чыгарып очыра торганыек.

## Таң суы

Менә таң сызылып атканда, таң беленгәндә генә кирәк шул суны алу. Иртәнге шәфәкъне күргән кешеләр бәхетле була, теләгең дә кабул була. Таң суын Аллаһумә гали… Салават әйтеп, таң суын алып куйсаң, балаңа сипсәң дә ярый өшкереп, эчерсәң дә ярый.

* * *

Агач ботагы кискәндә чыга бит түгәрәк кенә, күз кебек, баланы шуның белә имнисең.

* * *

Эче авырта бит баланың. Эчен ачасың да яңа туган баланың, нык итеп тә эче авыртып елый кайбер бала, түзәлми. Тарыны марляга төреп, бер унга кадәр саныйсың. Берәү – белеп кит, икәү – …, өчәү – очып кит шул унга хәтле саныйсың да кире күткә санарга кирәк инде уннан башлап. Суга алып кит, минем баламда торма.

*Әмир авылында*
*Басыйрова Фәһимә Гаяз кызыннан (1942 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

**Кот кою**

Хәзер баланы биләмиләр бит. Элек билиләр иде. Балаң курыкса, кот коярга кирәк. Без балаларны бер вакытта да ычкындырмадык. Баланы коендырганда да нык итеп тота идем, кырыгына хәтле. Шуннан тимер аласың да инде, баланы сискәндерергә кирәк. Бу кот кою була инде. 3 тапкыр дога әйтеп, бала янына килә идем дә теге тимерне, бала тик торганда, капыл гына тидерә идем. Тимер тавышы чыгара идем. Бала куркып китсен өчен. Шуннан теге тимерне үзең карамыйча гына, кеше йөреми торган җиргә ташларга кирәк. Үзең борылып карамаска кирәк тимерне ташлаган җиргә.

– Балага кот коям, балага кот коям.
– Нишлисең болай, нишлисең болай?
– Баланың коты очкан, кот коям.
Баланың коты очкан, кот коям.
Минем балаларымнан очып кит, җиргә сеңеп кит,

дип тимерне очыра идек.

* * *

Безнең әни алай итми иде.

Әни тимерне кыздыра да, итәгенә тас белән су куя. Шул тимергә су сала, яисә кургаш, или балавыз. Балавызны эретеп, теге тимер өстенә сала да, гжж итеп агып төшә. Шуңардан бала курка. Шунда нинди сурәт керә, этме, балыкмы, агачмы. Шуның суы белән су кертә иде әни. Ул балавызны 3 көн салып ясый иде.

Суын яңа суга алыштырып тора. Аннан 3 көндә нинди рәсемнәр чыккан карый иде.

* * *

Ботаклы агачны юынасың, шул коробкасы гына калырга тиеш. Эче буш булып кала. Сыерның имие (җилене) шешсә, аны ботак тишегеннән савырга кушалар иде. Шуннан сыерның башыннан алып сыртына кадәр сөртергә кушалар иде. Бисмилла әйтеп, 3 мәртәбә сөртергә кушалар иде. «Минем сыерымда калмасын, китсен. Тигән күз очсын, китсен. Минем сыерым авырмасын, терелсен», – дип әйтәләр иде. Шуннан ул ботакны кадакка элеп куя идек.

* * *

Бала курыкканда кот куярга кирәк. Әгәр салкын тигән булса, таш буына утырта торган булган әни. Мончадан 3 таш алып кайтасың, или урамнан алып төшәсең. Шуны кыздырырга кирәк. Шуннан чирәм җире чокып алырга кирәк һәм бидрәгә салырга кирәк. Чирәмне дә, ташны да кайдан алганын белергә. Ташны кыздырасың да чирәмгә саласың. Бала әгәр тыңлатырлык булса, чишендереп, ыштансыз гына тотарга кирәк. Әгәр дә балаң тискәрерәк булса, ыштан белән дә тотарга ярый. Шуннан комган белән су алып, покрывал белән ябынып утырасың. Бала пешмәслек итеп шунда утыртасың. Бу бала егылганнан зәхмәткә дә, суык тигәннән дә, эче киткәндә дә файдалы була.

Тәпәй киткәндә дә файдалы була иде.

*Әмир авылында*
*Басыйрова Фәһимә Гаяз кызыннан (1942 елгы)*
*Г. Яхшисарова язып алды*

## Кот кою

Безнең әни тимерне кыздыра да баланы шунда тота. Итәге алдына тас куеп, су куя. Шул тимергә су сала, я кургаш, я сумала – балавыз. Элек бит кургаш бик юк. Безнең күршедә бабайларның умартасы бар ие, Сәхи абзыйларның, алардан балавыз апчыга да, балавызны, эретеп, теге тимер өстенә сала да, теге выжж итеп агып төшә, шуңарга бала курка, Ә шушында нинди төс-форма

керә, сүрәт: этме, балыкмы, агачмы. Шуның суы белә(н) су кертә ийе әни, тастагы су белән. Әнә шул кот кою булайе. Ул балавызны 3 мәртәбә салып, 3 мәртәбә ясыйе. Көн дә, көн дә бер мәртәбә. 3 көн буена суын алыштырып тора, яңы суга сала. Әнә шул рәсемен алып куя да, шул 3 көндә ниндә рәсемнәр чыккан, шуны карыйлар.

### Сыерның җилене шешсә

Сыерның эмие шешсә, җилене, шушылай итеп ботак тишеганнән савырга кушалар инде. Эмиен кысып, сөт шушы тишектән агып төшсен. Шуннан сыртына сөртергә кушалар ие сыерның (шул сауган сөтне). Дүрт эмиеннән дә, башыннан алып, сыртына (койрыгына кадәр) сөртеп чыгарга кушалар ие, 3 мәртәбә бисмилла итеп.

– Минем сыерымда калмасын, тигән күз очсын, китсен, минем сыерым аруланлансын.

Үзенчә укып шулай итәләр ие. Аннан ул ботак тишеген кадакка элеп куя идек, абзарда (онытмаска, үзеңә).

Ботаклы агачны юынасың, тишегеннән үсеп чыкканы ботакның, төшә дә инде, коробкасы гына кала, шуны элеп куясың. Ат дагасын да.

*Әмир авылында*
*Мөрәсова Мәрхәбә Гыйззәтулла кызыннан (1937 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды.*

### Кот кою

Балаң курка бит инде, я чыррр итеп елап ебәрә. Шуңарга кот койдыралар. Аны теләсә кем белми. Кургашны да эретәләр. Су алып, шул суга манып, нәрсә булган дип тегене, фәлән кешедән курккан. Кот коям дип, котын качырам диеп инде. Шуннан соң алар нәрсәдән курка, ди, шуның сүрәте булып, теге кургашны эреткәч, кургашны суга салгач, теге курккан нәрсәсеннән шуның рәсеме төшә, ди. Ул суны эчәргә дип ишеткәнем юк. Мулладан бөти яздырып тагалар бит кайсы кеше, йә шулай янында йөретә инде төреп-салып кына.

**Тышау кисү**

Кайсыбер бала баса да атлап китәлми, абына да егыла, абына да егыла. Аның аягын мына шулай куеп, бер бау белән ат тышаулаган кебек тышаулыйлар да, балага йөрергә кушалар, инде теге бала йөресен дип шуны качы белән кисәләр. Әнә шул тышаулап киссәң дә, йөри диләр инде.

* * *

Кайсыберсе сәламәтлеге буенча йөри алмыйча тора. Анысына инде 10 л суга комовой тоз диләр бит инде. Теге казып чыгарган Оренбург тозлары инде. Таш тоз яхшы тоз инде ул, күл тозы түгел. Безнең авылда гомер буе базар булган, әле 51 нче елда базар булайе.

Бер бидра су алалар да, суны елыталар пешермәслек кенә итеп, шуннан анарга 1 кг тоз салалар, эретеп нитәләр дә баланы утырталар шул суга. Шунда утыра ул.

* * *

Әтиең кискән утын түгел,
Әниең яккан мунча түгел,
Аю баласы, бүре баласы,
Аю кебек көчле бул, –

шундый такмакларны әйтеп, кендек әбисе юындыра инде авылда туган баланы.

* * *

Мәетне алып чыгып киткәндә Салават әйтәләр (ул тәкъбир әйтә. – *И.Я.*). Әнә шулай әйтелә 7 рәт. Шәкертләр әйтеп йөргән, урам буйлап. Шуннан соң тәкъбир әйтеп йөргәннәр. 1944 елны ангина дигән авыру булды бит. Көлтә бәйләнмәгән, шул көйгә җыелмыйча калды, лабогрейка белән чабып ташлаган, шунда кар астында калып. Мына шушылай вич пәрәвез оя корып, септик ангина диделәр. Уфадан врачлар да килеп ятты безнең авылга. Шул агуланган да, шунда 300 кеше үлде диделәр инде.

Әсти Камәре шулай дип сөйли инде. Движок та кордылар. Движок белә(н) ГЭС строит иткәнче, мында шул движок белә(н)

эшләтеп, безнең авылның ярты ягында лампычка янды, багана башларына, сельсовет башларына шулай нитеп куялар иде, матурлап...

Көненә 20 шәр кеше үлде, ангина беләнн.

## Яңгыр боткасы

Яңгыр боткалары пешереп йөргәнебез бар. Аны җыялар, бала-чагалар да чыга олырак кешеләр дә чыга. Менә яңгыр боткасы пешерәбез. Су буенда пешерәләр инде, әйбәт урында, авылда ут якмыйлар. Шунда пешереп, бер-ике кешене пешерергә куеп, кемнең нәрсәсе бар, шуны бирә инде анда: күкәй бирәме, май бирәме, он бирәме, ярма бирәме. Җыялар-җыялар да. Он, теге йомыркалар күбәеп китсә, күкәй чумары пешерәләр, күкәйгә генә, бутап кашык белә(н), әзләп-әзләп кенә алып, теге шулпага салып, зур булып пешә кабарып. Бала-чагалар тыпырдап тора. Намазын укыйлар да барысы да яңгырны Алла Тәгаләдән сорап дога кылалар, ашыйлар да, шуннан су сибешәләр инде.

* * *

Зиратта йөргән кеше күрә бит инде. Анда менә шушылай умылып төшкән кайсы вакытта йодрык сыешлыгы чокыр. Убылган. Ана шунда менеп Салават әйтеп, 41 кашык су салалар икән шул тишеккә.

Салават әллә ничә төрле ул.

Аллаһы галәйһем
Вә галәйһи әҗмәгыйн.
Җөмләбезгә рәхмәт әйлә
Лә иләһә галәмин, –

дип тә әйтәләр.

* * *

Аллаһыма галә сәидинә
Мөхәммәдин вә һуа али Мөхәммәд,
Вә бәрик, вә сәлим галәйһи, –

дип тә әйтәләр.

Ана шунда 41 кашык су салалар да тегенең тишеген күмеп куялар.

*Карагош авылында*
*Табаева Әминә Мөхсин кызыннан (1930 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Йолаларның үзенчәлеге була. Бер үк дин, бер үк милләт бит инде. Авылына карап, урынына карап тәртипләр, йолалар үзгәрә.

Элек бит барган булганнар балакны сәлендереп. Кәләш алырга булса, яучы ебергәннәр бит инде.

Ике балакны чыгарсаң, бер төрле булса булмый. Яучы икәне күренү өчен, теге балакны чыгара. Сөлге биргәннәр бит инде. Сөлгене апкайтып эләләр ие дә бит инде, сөлге күргән кешеләр сөлгегә акчалар, әйберләр эләләр ие, котлап. Шуннан соң кыз ягына йорт күрергә баралар егет ягынан, туйны билгелиләр йортны күргән вакытта инде. Элек бит алтышар көн булайе туй. Башта туй кыз ягында буладырые... Кода алышып, 6 шар көн сыйлап. Ат белән кимәндә ястык-мендәрләрен алып килеп. Куналар ие, мунча кереп. Безнең әле, мин хәтерлием, зирекле Ибат агай дигән паровоз булып, «поооп» кычкырып, ат арбасын тартып мунчага аббарып, апкайтып, ат белән бер өйдән икенче өйгә аббарып. Шулай итеп күңелле итеп 6 шар көн нишләргә кирәк инде. Иртән өйрәгә чакыралар, күп вакытта өйрә – тары ярмасыннан, дөге булса, ярмадан сыек кына итеп, ботка кебек шурпа кебек ясыйлар, өйрә диләр инде. Егет ягына кызны апкитәләр. Теге якка төшкәнче кыз мында кала, атна саен килеп, мунча кереп китә кияү булган кеше. Төшкәч, үзләрендә кала.

*Яшерган авылында*
*Мухтаруллин Һидиятулла Ибәтулла улыннан (1942 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

**Җен ияләшмәсен өчен**

Балалар елый бит. Элек ата-ана, эштә булгачтын, бала йоклатканнар да йорт эшләренә чыгып киткәннәр. Шушы вакытта баланың өстенә пычак йә кайчы куйганнар, җен ияләшмәсен өчен. Җен ияләшкән бала елый һәрвакытта да.

Аны тәрәз тирләре белән сөртеп чыгара торганнарые, әлеге вакытта аерым догалары бар аның. Шул җеннәрдән саклана торган. Тәрәз парлана, шушы тир белән баланы битләреннән, тәннәреннән сыпырып. Әбиләр, ул вахытта белемле әбиләр барые бит инде ул. Сүзләрен әйтә белмим.

### Бала күзексә

Нык күзексә бала, кайбер кешенең күзе каты була бит инде, шушы кеше киткәннән соң, бала еласа нык итеп, барасың да теге кешенең берәр нәрсәен кисеп аласың: күлмәк итәгенме, өйгә кайтып, төтәтеп шушы баланы тагын да догалар белән күз тиюдән өшкерәсең.

### Кот кайтару

Курыккан вакытта да кот кайтару дигән әйбер. Аны аерым кешеләр кот койдыралар. Әлеге вакытта Миякә районының Кызыл чишмә авылында Тәнзилә дигән апа бар. Шушында кургаш белән кот коя. Коты китә бит кешеләрнең, кот койдырып кара, диләр. Суга кургашны коя да нәрсәдән коты киткәнен әйтә. Ул кургаш төшә берәр формаларда: йә кеше кыяфәтендә. Ризык апкилергә куша шул апа. Бал, варенье апкилергә мөмкин. Аббарып өшкереп ашап чыгаралар.

### Җир тарту

Кайбер кешеләр гел егыла. Җир тарта диләр бит анда. Егыла да йә аягын сындыра. Зәхмәтле урын дип әйтәләр. Гади генә итеп егылса да кеше имгәнә. Димәк, ангел хранителе юк, зәхмәтле урыннарны читләтеп үтәргә тырышалар. Зәхмәт тисә гыйлемле әбиләргә барырга кирәк. Безнең авылыбызда әби барые. Аларны бит инде укыткан, диләр. Мәрткә киткәннәр дә бәләкәй вакытларында, 7 көн буе мәрттә булып. Әчедә Сәрә әби иде. Мәрткә киткән булган, укытканнар аларны. Яшерганда бер әби барые, Әсмә әби барые. Алар бер вакытта мәрткә киткәннәр, ахры. Шулай мәрткә китеп, теге дөньяда булганнар алар.

Әбигә барасың, әби үзенең гыйлеме белән аларны өшкерә.

Балалар сөйләшмәгән вакытта да, кайбер балаларның теле озак ачыла бит.

Кемнәр бара аңарга, һәрберсенә файдасы тигән.

Авыру кешеләр, балаларның теле соңлап ачылса.

* * *

Өйдә зәхмәт дип әйтелә. Өйгә күчкәч, белгән кеше мөешләргә свеча куерга тиеш, өйдәге зәхмәтне куыр өчен.

*Тәтер-Арслан авылында*
*Мөхәммәтшина Гүзәлия Ягъфәр кызыннан (1960 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

* * *

Олы туйдан соң егет-кызны ябалар. Безнең теге очта әңкәйнең әнкәсенең барые сеңлесе Гайшә, без аны якын әби дип йөртә идек. Шул якын әбиләргә безне яптылар. Безнең Зөфаф кичәсе шунда булды. Иртән сәгать 5 иде микән, безне килеп уяттылар. Мунчага йөгерттеләр. Без мунчага бардык, акчаларны кыстырып калдырдык мунча яккан кешегә. 100 тәңкә – ул вакытта зур акча. Без кайтуга коймак пешкән, кияү беренче булып коймакны кабарга тиеш. Йә кырыннан тешли – кыз булса, кыз булмаса – уртасыннан, значит кызың тишек булган. Бу кырыннан гына тешләде дә тәрилкәгә куйды. Кияү чәе булды инде. Бездә кияү пилмәне юк – кияү коймагы пешерәләр. Туган тумачаны көн дә көннең буена берсеннән берсенә йөрттеләр.

Менә бәләкәй чакта шушы күршедә Флүрә апа барые, аның туе булды. Шул хәтердә калган. Ул Флүрә апаны күрше авылдан килеп атлар белән, мылтыклар белән. Менә бу өйгә яптылар, бу өй түгел инде бәләкәй өй иде, каршыдагы өй. Әй мылтыклардан аттылар, кечкене инде, мин кермәдем, бәләкәйем, җизни бүләгенә керә торганыек. Анда инде бөтен бала-чага җыела. Анда пудра бирәләр сиңа, крем бирәләр, тарак... Килен кешегә су юлы күрсәтәләр. Су юлы матур үтә.

2 туган энемнең кызы кияүгә чыкты. Мында сөлге алырга килделәр, бөтен шартына туры китереп. Шуннан соң никах туе булды, бөтен шартына туры китереп, шуннан тегендә барып

килен булып төшерделәр, мендәргә бастыралар, авызыңа бал каптыралар, май. Өйгә кергәч, биленҗә ни (алъяпкыч. – *И.Я.*) бәйләтеп, туй күлмәге өстенә көянтәләрен элеп, су юлына китәләр.

Ишек бавы – бер алтын,
Безнең апа – мең алтын.
Алтыныңны бирәсең,
Аннан гына керәсең, –

дип җизнине һәр ишек саен шулай кертәләр инде.

*Айдарәле авылында*
*Мишарова Нурия Зариф кызыннан (1950 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

**Бәби котлау (үстерү)**

Кеше бәби алып кайткач та, күрше тирә яклар, туганнар, әле мин әниләрнекен әйтәм әле, әниләрнең шулай үстергәнен. Күрше әбиләр бергә, алдан сөйләшеп, аш әзерлиләр, чәй әзерлиләр, кулдан килгәнчә, умач уып апкиләме, нәрсә апкилә бернинди дә гаеп юк, ул хөрмәт йөзеннән санала. Көянтәләп бөтенесе җыелып, көянтәнең ике башына 2 бидра элеп, алар бит 4–5 кеше, табын ясап, бәби котлап китәләрие.

Үзебезнең бәби туганнан соң, хәл белергә киләләр инде, аннан соң үзебез бәби үстерергә чакыраек бит инде, туганнарны. Шул бәби үстереп аладырыек инде.

* * *

Элек шаулап-гөрләп сугымнарны олы табын итеп үткәрәек. Хәзер өстәлең нинди генә сыгылып тормый ризыктан, кеше кешене белми, күрше күршене, кеше кешегә бик сирәк йөрешә.

*Бакый авылында*
*Байтимерова Нажия Шаһиәхмәт кызыннан (1937 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

* * *

Җеннәр-пәриләр бар дип кешедән ишеткәнем бар.
Бәрелсәң:

Тьфү-тьфү,
Пәригә авырлык,
Миңа җиңеллек, – диләр ие.

Шуннан догалар белән өшкерергә була төрле авыруларны. Аерым догалары бар бит инде.

Башта өшкерәләр бит. Дога укыйсың да, төкереп:

– Минем кулым түгел
Фатима Батман кулы, – дип әйтәләр.

Фатыйха сүрәсе.

*Стәрлебаш авылында*
*Сәгыйтова Галия Төхвәтулла кызыннан (1941 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## Кәләш әйттерү, килен төшерү (1928–1930 еллар)

Элек-электән Стәрлебаш авылы тәртипле, укымышлы-гыйлем кешеләр күп булуы һәм мәдрәсәләренең танылган булуы белән дан тоткан. Халыклары да тәртипле, хәлле яшәгәннәр. Кәләш әйттерү, кызны кияүгә бирү буенча, кодалар булачак кешеләрнең нәсел-нәсәпләрен алдан ук белешкәннәр. Тәртипле нәселле, укымышлы, хәлле кешеме, әти-әниләренең тормышлары, туганнарының дөнья көтүдәге хәлләре белән кызыксынганнар.

Кызга, килешү буенча, сөлге алу өчен алдан көн билгеләнә. Яңа туган ай башы, изге ай – Рамазан ае, йомга көн, йомгадан соң егетнең әтисе, кияү егете, һәм бер туган агасы яки энесес белән, кыз ягына сөлге алырга баралар. Кызның әти-әниләре һәм туганнары аш-су хәзерләп, кодаларны каршылыйлар. Аш-су табынында, күпме мал салу яки акча салу, кайчанга туйны билгеләү, һәр яктан ничәшәр пар кода алып бару турында сөйләшеп килешәләр.

Туй башлануга берәр ай калгач, егет ягы мал китерә. Мал китерү: зур сандык, аның эчендә кызга бүләк, постель, кием-салым, йорт әйберләре, табак-савытлар, аяк киемнәре, бүләкләре – кодаларга да бүләкләр була. Бу малны кияү егете китерә. Кыз ягыннан кияү егетенә мамык бияләй, түбәтәй, оекбаш, кулъяулык

бирелә. Кияү егете дә буш кул белән бармый, акча сала һәм ашсудан авыз итеп, яхшы атына утырып кайтып китә.

Кыз ягына мал килгәч, кызның әти-әниләре, мал күрсәтү өчен, барлык туганнарын аш-су хәзерләп ашка җыялар. Һәр килгән кеше, мал котлап бүләк – шәльяулык, чәмчәле читек, галош, күлмәклек товар, яхшы паласлар яки акча салалар. Бу бүләкләр кыз өчен бирелә.

**Кыз белән егетне ярәштерү**

Кыз ягында бер матур өйдә яки бүлмәдә урын-җир хәзерләнә. Бу эштә кызның якын дуслары, җиңгәләре күп көчне сала. Өйне бик матур итеп җыештыралар, кызны бик матур итеп киендерәләр. Һәркем бик тә нык шат, җырлар җырлыйлар, уен-көлке, шул ук вакытта кызны бик нык, игътибар белән саклыйлар. Чөнки төрле могҗизалар килеп чыгарга мөмкин. Яки уйламаган җирдән кыз югала, кызны урлыйлар, төрле үч алучылар булырга мөмкин. Капка төбендә сакчылар, егеттән бүләк алмыйча капканы ачмыйлар. Ә өйгә кергәндә – ишек төбендә чигүле сөлгеләр тоткан җиңгәләре. Бүләк алмыйча кертмиләр. Бүләкләре – хушбуй, одеколон, исле сабын, яулыклар бирелә.

Кияү бүлмәгә кергәндә, кызны җиңелчә генә яшерәләр. Кияү кызны эзли һәм кочаклап ала. Барлык дус-ишләре, иптәшләре таралыша, тышта җиңгәләре һәм кияү егете кала. Кыңгыраулы – егет килгән ат кайтып китә. Мылтык атыла.

Ә иртән кызның туганнары, күрше кызлары, үсмер егетләр бүләк алырга киләләр. Кияү бу үсмерләргә исле сабын, яулык, алъяпкычлар, ә малайларга пәке бирә. Һәркем канәгать.

Кыз белән кияү мунчага китәләр. Мунчадан соң – аш табыны, кода-кодагыйлар килен белән күрешә. Күрешеп, бүләкләр бирешәләр. Шулай ук кызның әти-әниләре, якын туганнары, кияү белән күрешеп, бүләк бирешәләр.

Туйдан соң, сөйләшү буенча, киленнең кайналарына төшүе билгеләнә. Төрле сәбәпләр, хәзерлекләр буенча килен кайна-кияү йортына төрле вакытларда төшәргә мөмкин. Элекке вакытта кыз – 3–5 ай буена ата йортында яшәгән. Һәр атна кичне кияү килеп кунып, яки кияүләп кенә йөрегән.

**Килен төшерү**

Кодалар белән сөйләшенгән көнгә килен төшерелә. Бер көн алдан кияү кыз янына килә. Аш мәҗлесе уздырыла. Кияү-килен, кода-кодагыйлар туйга бару өчен, атлар хәзерләнә. Килен төшкәндә, атлар бик нык хәзерләнә. Юлда туктау булмый. Кияү-килен утырып бару өчен яхшы күк айгыр бизәлә. Кыңгыраулы дуга, бик матур карандас (тарантас. – *И.Я.*), атта бик тәҗрибәле кучер. Кияү белән кыз артыннан матур итеп бизәлгән атта «мал» китә. Сандык белән бирнә әйберләре, урын-җир әйберләре, табак-савыт һәм тагы да дөнья көтү өчен кирәкле әйберләр. Бу атта да тәҗрибәле кучер утыра. Аннан 4 пар кода-кодагыйлар, һәрберсенең карандасына, артына асылы палас салындырып куелган, ак тышлы чигелгән мендәр кабы белән пар мендәр, юрган куелган, кодалар килешле итеп борынгыча киенгәннәр, һәрберсендә кучерга ат тотучылар утырган. Атлар бертигез юыртып баралар. Урамда туй карарга чыккан бала-чагаларга, олы яшьтәге кешеләргә конфет, акчалар сибәләр. Барлык атлар бертигез юыртып чабалар, атлар бер җирдә дә ялгыш кына да туктарга тиеш түгелләр. Әгәр ат тугарылса, арбадан тәгәрмәчнең чәкүшкәсе төшсә, чыбыркы төшеп ат туктаса – килен-кияү бәхетсез була, я аерылыша, яки балалары булмый, яки үлем-җитем була. Моның өчен килен төшерү бик катмарлы, четерекле мәсьәлә, һәрбер тәртибен тулы үтәргә кирәк.

Атлар килә, атлар килә, килен килә, диеп кычкырган тавышлар ишетелә. Капка ачылган, капка төбендә чигүле тастымал тоткан яшь егетләр, атларны кертмиләр һәм егет, кыз бүләк бирәләр. Капка ачыла, атлар йортка керә. Ишек төбенә ак мендәр куелган, килен аттан-крандастан күтәрелеп төшерелә һәм мендәргә ике аягы белән нәкь уртага баса. Котлы аягың белән килен, дөньяңны шушы мендәр кебек йомшак көтәргә язсын. Җиңгиләрнең кулында май-бал, килен авызына каптыралар. Килен, шушы май кебек йомшак күңелле бул, бал кебек татлы төкле бул. Йа Раббым, бәхетле, кешелекле, изгелекле бала булсын, диеп карт җиңгәсе дога – Аятел көрсине укый.

Килен тулы, зур гәүдәле, кара чәчле, кара кашлы, зур зәңгәр күзле, куллары зур – эш өчен генә яратылган, диярсең. Килен

биеме әзерләгән яулыкны ябына, һәм алъяпкыч бәйләп, аш хәзерләшү өчен почмакка юанәлә. Кунак өендә кодалар билгеләнгән урыннарны алалар. Бавырсак котлау.

Урнашып беткәч, Коръән-Кәримнән аятьләр укыла. Бәхетләр, изгелекле булу, тигезлектә яшәгән хәерле гомерләр, бәхетле, тәүфыйклы балалар үстерү, аларның изгелекләрен күрү турында теләкләр теләнә.

Киленгә су юлы күрсәтелә. Кодаларның ашы чыгарыла, кымыз, балдан коелган ачы бал куела, әкрен генә моңлы җыр агыла, аңа тальян гармун кушыла. Шул рәвешле тыйнак кына, әмма бик күңелле килен төшерү туе үткәрелә. Аш мәҗлесеннән соң кыз ягына туйга барган кода-кодагыйлар, кемдә кунак булып яткан булсалар, шул кодаларны үзләренә алып баралар. Ә алып барган күчтәнәчләр төп йортта кала. Иртән мунча ягыла, килен мунчасы, мунча керергә барган кодалар, мунча котлап, акча салалар. Мунчадан кайтуга аш-су әзерләнгән була, тик тәмле итеп тары коймагы пешерелә. Ә кич көн дә бер кодага аш мәҗлесенә баралар. 4 кич шул рәвешле сыйланып, үзләре җигеп килгән атлары белән, күп күчтәнәчләр алып кайтып китәләр. Кыз бик канәгать булып, төшкән йортында торып кала. Кодалар кайтып киткәч, килен җиңги кеше, туганнар белән таныша. Каенсеңелләренә бүләкләр бирә. Ә Әминәгә, мин әтиең ягыннан сиңа туган, ә Абдулла абыең әниең ягыннан туган, шуңа күрә миңа җиңги-апа диеп әйтерсең, диде.

Икенче көнне килен «сөю» мәҗлесенә барлык туганар чакырыла. Бу туганнар – Абдулланың туганнары. Килен «сөю» өчен киләләр. Аш мәҗлесе Коръән-Кәримнән аятьләр уку белән башлана, киленне күрергә килгән туганнар бар да бүләк алып килгәннәр.

Менә шулай килен төшерде Гыйзенас әби. Әгәр дә киленне тиң күргән бием булса, барлык йорт эшләрен бергә башкаралар. Олы кеше яшь киленне һәр эштә өйрәтә. Берлектә – терлек.

Соң булса да, уң булсын.

Су юлы күрсәтү килен төшкән көнне үткәрелә. Килен, биеме, яки кайнанасы биргән алъяпкыч киеп, ак яулык бәйли, көянтә-чиләк алып, су юлы күрергә бару өчен хәзерләнә. Янында

иптәш кызлары, каенсеңелләре, җиңгәләре, кияү, кияү егете, дус егетләре, туганнары була. Көянтә-чиләк күтәреп, килен урамга чыга һәм барлык туганнары бергә атлыйлар.

Иң тәүдә бисмилла әйтеп, уң аяк белән басып, урамның югары очына баралар. Әгәр дә анда чишмә яки кое булмаса, икенче якка борылалар, җырлар яңгырый, тальян моңы тарала. Киленне каршыларга яки күрергә чыгучыларга конфет сибәләр, вак акчалар сибәләр, кульъяулык тараталар. Һәркемдә шатлык, көлүшаяру, бәхетләр теләү һәм башкалар. Суны бисмилла әйтеп, уң кул белән чиләкне тутырып алалар. Ике чиләк тулгач, килен суны күтәргәнче, ияреп килүчеләр барысы да котлап суны эчәләр һәм көмеш тәңкәләр – акча салалар. Чиләк бушап кала, тагы тутырып су алып кайтырга чыгалар. Кайтырга чыккач, килен туктарга тиеш түгел. Шуның өчен, юл ерак булса, егет кызның кулбашыннан көятәне алып, суны үзе күтәрә. Юл буенча җырлап, биеп барулар – үзе бер матур күренеш. Йортка кайткач, килен суын эчү өчен, барлык кодалар чыгалар һәм акча салып су эчәләр. Бу туйның матур йолалары булып санала.

Хәдичә һәм Абдулла.

Алар гыйшык тотып кавышалар. Гыйшык тоту пәйгамбәрләрдән, Йосыф-Зөләйхадан калган, ди халык.

Матур, саф-инсафлы кызлар йорт яме, уңган егетләр ил күрке булып әверелгән. Мөхәббәт – күңел күрке, йөз матурлыгы, тәүге мәхәббәт – күңел гөле, егет – гөлнең былбылы, кызлар – былбылның гөле.

Менә шулай кавышуның нәтиҗәсендә, мин дөньяга килдем, диеп сөрән салып бала туа. Бала тугач, кендек әби, и рәхмәтле бала, изгелеге белән, хәерле гомерең белән, тәүфыйгың, ата-ана шәфкатьле булуың белән дөньяга кил диеп, кыз бала булса, колагына – Фатыйма, ир бала булса, Хөсәен диеп пышылдый һәм, юындырып, анасы янына яткыра. Элекке вакытта, бала өйдә туу сәбәпле, ананы бигрәк тә нык тәрбияләгәннәр. Җылы чәй эчерү, корт белән каймак кушып, шулпа эчерү, аякларын һәрвакыт җылы тотканнар. Икенче көнне мунчага алып барып, массаж ясап, себерке җиле җибәреп, күкрәкләрен юганнар. Мунчадан соң өйдә

тагы да тәрбия булган. Шул рәвешле 10 көн килен хәл алганчы тәрбияләнә. Атна-ун көн үткәч, күршеләре, туганнары бәби күрергә киләләр. Бары да бүләк белән киләләр. Ләкин бәбине күрсәтмиләр әле, күз тиюе ихтимал.

Аннан соң көн дә бәби чәе үткәрелә, бары да аш китерә. Коймак, тавык ашы, каз ашы – бу ашлар, әле зур түгел, бары тик киленне сыйлау, терелтү өчен генә.

– Килен аякка баскач, зур итеп бәби туе үткәрелә. Чакырылган кода-кодагыйлар, туганнар, күршеләр, зур бүләкләр зур ашлар белән киләләр. Кайбер бәби туйларында унар аш була торган иде. Уңган килен ул таба, изге килен кыз таба. Инсафлы, саф киленнән туган бала гомере буенча бәхетле була иде, диеп мулла Коръән-Кәримнән дога укып, балага исем куша. Шул ук вакытта намуслы, саф кыз булган анага бәхетле булса иде, диеп бәхет тели.

Бала үсә, бәхетле булып үсә.

Килен төшкәндә, аш мәҗлесендә бавырсак котлау була. Кыз ягыннан килгән бавырсакны, егетнең-кияүнең туганнарыннан бер абыйсы ача. Бавырсакны ача, өстенә ябылган бүләкне ала, чәкчәкне кисеп каба һәм бер мал әйтә. Сыер, сарык, кәҗә. Бу малларның берсе генә әйтелә һәм бирелә. Калган кунаклар бар да акча салып, чәкчәкне кабалар. Менә шулай, туйга бик нык әзерләнәләр. Һәм бик күп акча кирәк була.

### Тула өмәсе (1928–1930 еллар)

Стәрлебаш авылы Төньяктан тау тезмәләре белән уратылып алынган. Көньякта тигезлек – дала. Стәрлебашны урталай икегә бүлеп Стәрле елгасы ага, ә көнбатыш, төньяк-көнбатыш яклары тоташ урман белән капланган. Шушы урыннарда (халык) мал асраугa җайлашкан. Стәрлебаш халкы сыер, сарык, кәҗә маллары асраганнар.

Сарык – бик тиз үрчүчән хайван, тәмле сарык ите бирә, май, йон бирә. Сарык йонын елына ике тапкыр алалар. Язгы йон озын, йомшак була, аны май аеның 10–15 числоларында кайчы белән алалар. Ә көзге йон кыска була, аны 25–30 августта алалар. Язгы

йонны эрләп, кофта, шәл, оек, оекбашлар, бияләй һ.б. бәйлиләр. Ә көзге йон пима басу өчен китә. Шушы йоннарны тигез итеп, яхшы итеп тетәләр. Һәм язгы йонны агын гына эрлиләр. Көзге йонны да эрлиләр. Менә шушы йоннардан тула сугалар. Язгы йонны буйга озаталар, көзгә йонны аркауга куялар. Үзенә генә карата сугу станогы була, кәре, кылыч аша буйлыкны үткәреп сугалар. Суккан вакытта игътибар белән, җыермыйча сугарга кирәк. Сугып бетергәч, бу сугылган туланы, килештереп, эре-эре атлатып тегәләр. Бу йон һәм эрләгән, сугылган тулалар бер дә юылмаган, керле көенчә була. Бу материал 15–16 метр озынлыкта була. Хәзер шушы сугылган материалны эшкәртү яки сукно ясау өчен басарга кирәк. Басу өчен стан ясала. Станның ике як кыры юан сөяк агачыннан булып, уртасына өч урынга аркылыга шомырт агачыннан җепсә куела. Шул җепсәләргә юкә агачының кабыгы суерылып, шакарып чыгарыла.

Шул станны, сәке такталарын алып, сәке йөзлегенә бәйләп ныгыталар. Ул селкенмескә тиеш. Бу станның буе 2 метр, ике 1 метр була. Хәзер тула басу өчен өмә оештырыла. Бу туланы кызлар баса. Кызлар таза, тулы гәүдәле, таза йомры беләкле булу кирәк. 4 пар яки 3 пар кыз чакырыла. Тула бастыручы хуҗа өмәчеләр килүгә иртән коймак, җылы күмәч пешереп чәй эчерә. Өмәгә яки басып бетерүгә таба бәлеше, коймак хәзерләнә. Кич каз, үрдәк ашлары, каз шулпасына пешерелгән ботка, тагы затлы ашамлыклар әзерләнә. Чөнки тула басу эше авыр эшләрдән санала. Тула басу өчен кызлар кара-каршы утыралар. Материал җыелса, су белән юешләнгән була. Кызлар эшкә башлаганчы, җиңел аяклы диеп саналган кызны такмак әйтеп биетәләр. Кызлар эшка тотына. Гомумән тула басу көзге-кышкы айларга туры китерелә. Кызлар тула баса, билгеле инде кайда кызлар өмә дә – шунда егетләр. Һәм тальянга кызлар җырлап эшлиләр. Җырлыйҗырлый, гөрли-гөрли өмәләрдә тула басабыз.

Җырлый, җырлый, гөрли-гөрли
Өмәләрдә тула басабыз,
Яшь йөрәктә янган утны
Алып читкә атабыз.

*Кушымта.*
Ай-һай, дусларым,
Аңламыйсыз күңелем тәрәзәсен
Кемнәр килеп какканын?
Аңламыйсыз үксез яшь йөрәкнең
Кемнәр өчен янганын.

Ак тулалар тиз керешә,
Аркау буе тигез эрләнсә.
Үз ярың да чит була икән,
Читтә йөреп күңлең керләнсә.

*Кушымта:*

Тула басучы кызларның күзләре төшеп йөрегән дус егетләре дә килә. Алар кызларны алмаштырып, кызлар урынына утырып тула басалар. Шул ук вакытта кайбер кызларга үчле егетләр дә булырга мөмкин. Мондый очракта кызларга бигрәк тә сак булу күздә тотыла. Чөнки үчле егет кызлар алдына, тула өстенә тәмәке, махорка яки тоз сибәргә мөмкин. Шушы әйберләр кызларның беләкләрен уйдыра. Тула басканда, беләкләрне бер көйгә генә түгел, ә беләкләрне авыш итеп, боргалап басу таләп ителә. Шулай эшләгәндә, беләк уелмый.

Бераз баскач уен, көлке, бию башлана. Эшләүче кызлар да, килгән егетләр дә, тула басуны күрергә килгән иптәш кызлар да – бар да бииләр. Җырлыйлар, төрле уеннар кыза.

Шулвакыт бу өмәне ишетеп, уен-көлкене ишетеп, якынтирәдәге дин әһелләре килеп керә. Ай мәлгуньнәр, нинди шайтан уены оештырдыгыз, килешмәгәнне. Алладан куркыр идегез, Алла үзегезне күреп тора. Ә вәгазь сөйләгәндә яшьләр әллә кайларга качып бетәләр иде. Ә «әргәнче» кем ул, өй хуҗасы. Мин сиңа әйтәм, и абзый, бу кыз кеше Федор авылыннан килгән утырма кызы, шулай «шайтан» уены өйрәнгән икән. Ә ул егет булып, кызлар киемен киендереп, бөтенләй инде кыз «ясап» куйганнар. Кызлар эшләренә керешәләр, мулла абзый кайтып китә. Шул рәвешле тула 4–5 сәгать басыла.

Тула сукно булып, калын булып керешә. Сукноны теккән җиреннән, чит-читләреннән сүтәләр, стан өстенә шакмаклап өеп

куялар. Аннан кара-каршы басып, ике кеше (егетләр булу шарт) сугалар. Суккан вакытта да бик сак, оста сугу таләп ителә. Әгәр дә артта калсаң, каршыдагы кеше кулыңа сугып имгәтергә мөмкин.

Сугып бетергәч, туланы озын итеп, шома итеп ясалган уклауга урыйлар. Ике башыннан тотып, чишмәгә тула чайкарга баралар.

Тула чайкарга барганчы, станны чишеп алалар, сәке такталары куела, матур палас җәелә, кызлар эш киемнәрен салып, бәйрәм киемнәрен киенәләр. Бик матур аш табыны әзерләнә, самавыр кайнап утыра, табынга утырып, гөрләшеп-көлешеп, егетләр белән бергәләп чәй эчәләр. Чәйдән соң биешәләр, уйныйлар.

Тула чайкарга барганда, барлык яшьләр гөрләшеп, шаярып, шаян сүзләр сөйләп, дус кызларга, дус егетләргә сөйләшергә форсат табыла, вәгъдәләр куешалар, туй ясарга сөйләшәләр. Чишмәдә туланы туздырып тараталар. Чишмә улагында бәләкләп юалар. Ул ап-ак калын сукно була. Кайтканда уклауга урап, егетләр күтәреп кайта, чөнки тула сулы, авыр була. Туланы алып кайтып, читәнгә, киртәгә эләләр.

Кичке аш.

Һәртөрле каз, үрдәк, сарык итләре белән пешерелгән тәмле аш, ботка, чәй була. Бар да көлешә-көлешә ашыйлар. Уен-көлке җитәрлек, шаян сүзләр сөйләү һ.б. Кызлар өлешләр алып, өйләренә таралышалар. Шул ук вакытта кем эшкә бик оста, кемнең кулы уелмаган, аңарга да игътибар итәләр. Уен-көлке. Ләкин бер-берсенә хыянәт итү булмый.

Бу туладан, юлда ат белән йөргән чакта кию өчен, чикмән тегәләр. Аякка кию өчен ап-ак тула оек тегәләр. Бу оекның башына чолгау урап, чабата кияләр. Ул бик җылы була. Кулга кию өчен рукавица, бияләй тегәләр. Менә шулай элекке заманда өс киемнәре әзерләнгән.

**Каз өмәсе**
**(1930–1932 еллар)**

Каз канатларын санадым
Тезелеп кагынганда.
Бер-ике җыр языйм әле,
Җырларсың сагынганда.

Каз канаты кат-кат була,
Ир канаты ат була.
Чит илләрдә күп йөресәң,
Үз илең дә (ярың да) ят була.

Каз канатлары кавырсын,
Ай-һай, дустым, авырсың.
Бик авырсың, бик сабырсың,
Ахыры ятка калырсың.

Талгын гына моң агыла, аңа гармун моңы да кушыла, әйтерсең лә йөрәкләр өзелеп төшә яки күңелләрдә моң кабына. Бүген Гарифә каз өмәсе үткәрә. Кәримә, Нәсимә, Зәкия, Рәшидә, Зөләйха, Мәрьям каз йолкалар, 18 каз, һәркемгә өчәр каз, йолкып, тазартырга тиешләр. Каз өмәсе үткәрү өчен, хуҗа каз йолку өчен хәзерләнә, сәке такталарын алып, мамыкны салу өчен әрҗәләр куела. Каурый өчен – үзенә аерым әрҗә, каз коймагы пешерү өчен тары ярмасы оннатыла. Иртән тары коймагы, тәбикмәк пешерелә, ул һәрвакыттагыча каз мае белән майлана. Өйдә эш беткәч – бәлеш. Казны үстерүнең үзенә генә бер мәшәкатьләре бар. Элек-электән Стәрлебаш халкы мал асрау, каз үрчетү белән шөгыльләнгән.

Стәрлебаш авылы төньяктан тау тезмәләре белән уратып алынган, уртадан, Стәрлебашны ике өлешкә бүлеп, Стәрле тугайлык урыны казларны үстерү өчен бик уңайлы.

Көз казларны ашату алдыннан, икенче елга каз калдыру өчен, бик шәп ата каз сайлап алына, аны тавышы аша беләләр, ата каз сузып-сузып кычкыра. Ике яки өч ана каз калдырыла. Ана казлар кыйгак-кыйгак диеп кычкыра, аны ялгышмыйча калдырырга кирәк. Калдырылган казларны белеп кенә ашатырга кирәк, күп ашатсаң, артык нык симереп, йомырканы күп салалар, бәбкәсез була, казга февраль аенда сөткә җебетелгән икмәк ашаталар. Аларның яннарында ком, балчык, ат тизәге булу шарт. Март аенда казлар күкәй сала. Иң әйбәт каз 12–15 күкәй сала. Кайбер ана каз үз ата казын яратмый, андый очракта ана казны күрше ата казына кушарга кирәк.

Бу вакытта каз маҗаралары күп була. Казлар мартта йомыркакүкәй салып туктыйлар. Һәм мамык йоннарын үзләре утырып күкәй салган ояларына коялар.

Ул оялар талчыбыгыннан бик матур итеп, түгәрәкләп үрелгән була. Каз йомырка өстендә, һәр ояда бер генә каз утыра, бер атнадан соң каз күкәйләре карала. Әгәр бәбкәле булса, кара булып күренә. Менә шунда инде нәтиҗә ясала. Әгәр дә казлар белән уңышлы килеп чакмаса, күрше-тирәләр бер-берсенә ярдәмләшү буенча сөйләшәләр.

«Гарифә, минем казның ике генә йомыркасы аталы булды, синең казның йомыркалары аз бит, шул ике йомырканы алып чыгып каз астына куй әле. Мин үземнең казны чыгарып җибәрәм».

Миңзифа: «Син, Шәмсикамал, казыңны чыгарма, ул бит ихлас утыра, минем каз утырмый, йомыркалар искерә, синең казның астына йомыркаларны салыйк», – ди һ.б.

Күршеләр, ничек кенә булмасын, җаен табалар, йомры-йомры сары туп кебек йомшак бәбкәләр чыгалар.

Каз бәбкәләре, бик әрсез булалар, бер казның бәбкәсе икенче казның бәбкәсе белән кушылмый. Кайбер ата казлар, бәбкәләрне талыйлар, андый очракта ата казның борынына ашадан-аша кавырсын тыгалар. Каз бәбкәләрен бер ай сакларга кирәк. Бу эшне үсмер кызлар башкара. Озын юкә агачы алына, аның башын сырлап юнып иске чүпрәк, яки яулык бәйлиләр. Шушы колгалар ярдәмендә, әкрен генә казларны бәбкәләре белән тугайга куып алып баралар. Кызлар, бәбкәләрне ашату өчен, икмәк, йомырка пешереп алалар, шуларны җайлап ашаталар.

Бибиәсмә, Зәкия, Оркыя, Гатифә, Әминә, Миңлекамал тезелешеп казларны куып алып баралар. Казлар тугайга таралышалар.

Әнә бер бәбкә каз үләнен йолка – артка тәгәрәп китә, яки артына утыра. Тагы, урынынннан торып, үләнгә ябешә, карап торган кешегә бигрәк тә кызык инде. Кызлар бераз уйнап алырга булдылар. Биш таш уены.

Зәкия белән Бибиәсмә ташлы уйный. Оркыя казларын карый, Гатифә, Әминә черталы уйный һ.б. Ә җәүяле ала карга бәбкәләр-

не күзәтә. Ярый әле ата казлар бар. Алар каргаларны куркыта. Тилгән, тирә-якта әйләнеп, бәбкәләрне күзәтә.

Тилгән-тилгән, ике күзе тонган,
Бәбкә алырга килгән,
Көш-көш-көш-көш.

Шулай балалар куркытып җибәрәләр. Бу бәбкә саклау балаларны ялкыта, ә шулай да сакларга, эшләргә кирәк. Бер ай саклагач бәбкәләр үсә, үзләре аналары, аталары белән генә йөри башлыйлар.

Көз, сентябрь, октябрь айларында казларны ашатырга ябалар. Аерым каз абзары ясала, ул кысыграк була, казлар йөреп ашарга тиеш түгел, янәсе. Алларына улак белән азык, су салу өчен су савыты куела. Аслары көн дә тазартып торыла. Алар җайлап ашыйлар һәм бик нык итеп симерәләр. Аннан – каз өмәсе. Казларны кызлар йолкыйлар, кайнар суга тыгарга ярамый, кем шәп йолка, кем таза эшли, казның тиресе, кайрый белән чыгарга тиеш түгел. каз ап-ак шакмак-шакмак булып тора. Каз йолкыгында әбиләр, олы яшьтәге җиңгиләр, каз кавырыен суералар, ул мендәрләрне кабарту өчен кирәк.

Каз йолкыгында җыр-моң агыла. Кызлар җырлап эшлиләр. Ә йолкып бетергәч, өйләрне тазарткач, чәй эчәләр һәм йортта бииләр. Казларны көянтәләргә, як-ягына икешәр каз асып, чайкарга баралар. Чайкарга барганчы өйдә эчен-башын тазарталар. Бер кыз эчен ярып бирә. Икенчесе муен ала. Өченчесе эчке органнарын ала. Аннан юалар. Авылда үскән казлар зур гәүдәле, бик симез, авыр булалар, 4–6 кг. Чайкарга барганда, көянтә белән күтәрү авыр була, шунда инде кызларга күзләре төшеп йөргән егетләре ярдәм итә. Стәрлебашта, зират очында бик зур чишмә чыга, анда агач такталардан ясап улак куелган. Иң тәү кызлар улакны мунчала белән юалар. Аннан казларны бик таза итеп юалар.

Кайтканда да күтәреп кайтырга егетләр ярдәм итә, һәм әкрен генә моң агыла, гармун уйный, биеп тә алалар. Кайткач, бер ышык урынга казларны элеп куялар.

Каз ашы беткәч, өмәчеләр каз ашы ашыйлар, андый тәмле каз ашы бер җирдә дә юк.

Кызлар, егетләр биешеп, җырлашып таралышалар, бер-берсе белән танышалар һәм җәберләү, хыянәт итешү булмый.

*Стәрлебаш авылында*
*Вильданова Ямал Газиз кызы (1921 елгы) язмаларыннан*
*И. Ямалтдинов күчерде*

## РИВАЯТЬЛӘР-ЛЕГЕНДАЛАР, АВЫЛ ТАРИХЛАРЫ, СӨЙЛӘКЛӘР

### Турмай (Кайраклы)

Элек авыл Кайраклы булган. Менә Миякә ягына барсаң Тормай дигәнне белмиләр.

– Кайда ул Тормай?

– Менә, менә шул авылны үткәч...

– Ул бит Кайраклы авылы, диләр. Кайраклы елгасы буенда утыра. Корманай авылы дип аталган. Корманайдан Тормайга әйләнгән. Союз чыккач. Авылның утырышы 1740 елларда. Бер 16 йорт Куганактан төшеп утырган, ди, Әсфәндияровта. Кайсы бер нидә Ашкадар авылыннан килеп утырган, ди. Стәрлетамак юлында Ашкадар авылы бар. Аннан да булгандыр, моннан да булгандыр. Күпчелек Абдуллиннар, Курманаевлар. Иң тәү Абдуллиннар килеп утырган инде.

*Турмай авылында*
*Курманаев Динияр (Минияр) Биктимер улыннан (1931 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### Яңгырчы

Яңгырчы исемле карт килеп утырган менә шунда монау тауга. Ул вакытта монда авыл булмаган, шушы Яңгырчы исемле карт булган ул. Тауга килеп утырган, шуннан туган балалар – Яңгырчының основной халкы, шуның нәселе. Авылда 2 генә кеше безгә туганнар түгел икән ул. Безнең авыл читтән ала. Безгә килгән кызлар кайтып китми – авылда кала.

* * *

Пугач явы булган, балам, монда. Аны без белмибез. Әнигә ияреп бакчага барадырыек Кара бүләккә су сибәргә бала чакта.

– И, балам, монда яман сугыш булган. Менә шушы чокырлар – окоплар дип. Окопның нәрсә икәнен дә белмибез. Әни сөйли иде.

Ә картәни сөйли иде, Карамалы авылында, күрше Миякә районы, берсе, бер отряд чыгып китә, икенчесе килеп керә, ансы чыгып китә, бу кабат килеп керә. Картәнәйнең бала-чагы булган. Әниләр-әтиләр безне базга төшереп ябалар дия иде.

**Өршәк елгасы** – основной ага, безнең авылдан үтеп китә.

Тау исемнәре – **Чучак тавы, Ястык элгән.**

**Кара бүләк** – ялан исеме.

**Төлке ачкан** (берәрсенең төлкесе качкандыр инде, берәрсе охотага баргандыр), **Аскар буе**.

**Буклы куыш** – тау бите, аның күле бар, шул күлдән ферма маллары су эчә – **Буклы куыш күле**, тегендәрәк Аскар күле бар.

**Тимер каккан кое** – яланнарның исеме, ә тегендә түбәндә буаның ас ягында – **Әҗе тамагы**, диләр; ул ерак, сазлык булганга, адәм йөрмәслек сазлык – Әҗе тамагы дигәннәрдерме.

**Рәхмәй тигермәне**, 3 тигермән утырадырые шул буйда – элек су тегермәне булган бит инде. Ул хәзер аларның берсе дә юк. **Рәхмәй зираты** – теге сибирский язва белә(н) чирләгән дә Рәхмәй дигән, теге юриснең әтисе. Сугыштан кайткач, шунда тигермәне булган, шунда яшәгән дә, сибирский язва белән чирләп, шунда үлгән, аның зираты да шунда күмелгән.

*Яңгырчы авылында*
*Абайдуллина Тәгъзимә Әфтәх кызыннан (1943 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## Яңгырчы авылының килеп чыгышы

Урманның арьягында гына Ирекле дигән авыл бар иде. Шуның бу як битендә таулар бар. Шушы тауларга *Ямгырсы* дигән карт килеп утырган. Әнә шул тауның битендә каберлекләр дә бар

дип сөйлиләр. Яңгырчыда бөтенесе дә туган икән. Шуның берикесе генә туган түгел. Шуннан соң төрле якларга сибелгәннәр.

*Яңгырчы авылында*
*Абайдуллина Тәкъзимә Әфтәх кызынан (1943 елгы)*
*Г. Яхшисарова язып алды*

* * *

Ирекле дигән бер бәләкәй авыл булган. Матур урында торган. Шунда беренче булып *Яңгырчы* дигән карт килеп утырган, ди. Яңгырчы карт килеп утыргач, аның исемен биргәннәр. Элек авыл шунда булган, ди. Менә Өршәк елгасы бит инде, Өршәк елгасының, бу як чытырманында болото булган. Киез басу белән шөгыльләнгәннәр. Безгә сөйлиләр иде, киез басучылар эзләп чыкканнар, ди. Өч баласы булган – ике малае һәм бер кызы. Берсенә Өршәк, икенчесенә Карагай, өченче кызына Гөлем дип кушкан.

*Яңгырчы авылында*
*Газизуллина Сания Хөснетдин кызыннан (1948 елгы)*
*Г. Яхшисарова язып алды*

* * *

Безнең авылга *Яңгырчы* дигән бабай килеп утырган. Элек якын-тирәдә күл булган. Шушы күл су астына киткән дә, тау башында өйләр төзелгән. Казак бабае булган. Казакъстан ягыннан килгән. Шуңа күрә аның исемен биргәннәр.

*Яңгырчы авылында*
*Кәримова (Халикова) Кәримә Лотфрахман кызыннан (1938 елгы)*
*Г. Яхшисарова язып алды*

## Гөлем

Безнең картәтиебез төп Гөлемнеке. Картәнием Миякә районы Әнәч авылыннан. Әтием Гөлемнеке, әнием Гөлемнеке. Үзем дә шушында тудым, үстем, дөнья көтеп ятам.

Безнең Гөлем авылы бер кешедән таралган. Исмәгыйль дигән килгән, аңардан 4 малай булган, шуннан 4 малайдан киткән дә киткән. Муллагөлем исемлесе булган. Исмәгыйль улы

Муллагөлем. Шул салган нигезне. Арта-арта. Түбендә Утар дигән ниебез бар ие – Бәләкәй Гөлем диләр ие. Башка чыккан яшьләр шунда, тагын бер урам, бер авыл бар ие, ул таралып бетте инде. Авыллар таралды бит инде бер вакытны. Галимҗан бабай 400 ел дигән ие, хәзер аңа 430 лар тирәсе бардыр.

*Гөлем авылында*
*Сәхибгәрәева Әминә Миңнехан кызыннан (1940 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## Гөлем авылының тарихы

Гөлем исеме чит бабабызның исеменә бирелгән. Муллагөлем исемле булган төп бабабыз. Шуның дүрт улы булган. Шуның дүрт улыннан берсе безнең буын булган. Беренчесе Динмөхәммәт булган, аннан Шәймәрдан, аның улы Шәйморат булган, Шәйморатның улы – Хәйбрахман, аның улы мин – Риф. Алар сүләү буенча, Муллагөлем бабабыз үсеп килгән вакытта Морза авылына килеп йөргән булганнар, Исмәгыйль исемле кеше. Морза авылы Морзагыл исемле кешенеке булган. Ул бик хәлле кеше булган. Шушы Муллагөлем исемле бабайны сорап алган. Синең улларың тагын бар. Монысын миңа бир. Үзем кеше итәрмен, үстерермен, җир бирермен, урын бирермен. Шуннан шушы җирне бүлеп биргән дә монда яшәгәннәр инде. Шуннан Гөлем исеме авылда таралган. Бу авыл 788 елгы.

* * *

Шәймәрдан каены. Суның теге ягында Ужов күпере. Заһирә җире бар иде. Гәрәй коесы бар. Урыс буасы.

**Мөнәзи тавы**, сөйләү буенча. Тау башында магазин булган. Ачлык вакытта кешедән өлеш җыйганнар. Тау башында келәт булган. Өлешне җыйганнар да шунда саклаганнар. Ачлык вакытта шуны кешеләргә таратып биргәннәр.

Безнең авыл халкы бер нәселдән булгач, бердәм булган. Әгәр дә берәрсе ялгыш алдан чыкса җиләк җыярга, уже бабайга барып әйткәннәр, менә шушы кеше алдан чыкты җиләккә, һәм җыелып шул кешене әрләгәннәр, ния син халыктан алда чыгасың? Җиләк,

балан, шомыртның пешкәнен белер өчен, бер-ике бабай йөреп чыккан җиләклекләрне, шомыртлыкларны и халыкка әйткән: «Шомырт пешкән, иртәгә шомырт җыярга чыгабыз». Алдан беркем дә йөремәгән.

Элекке вакытта урманда аю яшәгән булган. Яз көнне чыккач, тауны тырный торган була иде. Шуннан **Аю тавы** дип атаганнар.

Зурәтәй сөйли торган иде. Элек безнең якта шүрәле булган икән. Аны күргән кешеләр булган.

Әгәрбинең өске ягында адаштыра торган урын бар. Анда водораздел бар. Елгалар бу якка гөҗләп ага, теге якка Тәтер елгасы ага, Көнбатышка Өязе елгасы ага, Көнчыгышка Стәрле елгасы. Ана шунда башланып китә **Әгерби каенлыгы** – адаштыра торган урын. Анда **Чаршау каен** дигән урын бар.

**Бакыр чокырлыгы** бар бит инде, бездә аны бакыр казынтысы дип тә йөртәләр. Бакыр чыгарган булганнар анда, безнеңчә шахта инде. Аның урыны әле дә бар, авызы гына калды инде. Бакыр ташы алган булганнар.

**Завод асты** дигән җир бар. Анда көл изготовит иткән булганнар. Каен көле, аны селте ясар өчен ясаганнар. Селтеләрен сабын ясар өчен сораган булганнар. Теге французларның бик сыйфатлы сабыннарын шушы яндырылган көлдән калган селте белән ясаганнар.

*Гөлем авылында*
*Шәймәрданов Риф Хәйбрахман улыннан (1935 елгы)*
*Г. Яхшисарова язып алды*

**Убырлы күл** дигән ялан безнең, гел әнә шунда тәгәрәп йөргән убырлар. Хәйдәрләр торамы. Шул ялан, бәрәңгеләр чәчеп йөрдек.

Янәшәсендә – **Баллы чишмә,** аның суы тәмне була торганые.

**Уразай** бар.

Бу ягы – **Баһау бабай кулкасы.** Сәхәй бабайның кулкасы.

**Әҗәл тавы** – үлгән кешеләр булган.

*Хәлекәй авылында*
*Шәрипов Гали Шаһи улыннан (1931 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Әҗәл тау башында зират бар. Хәер эстәп кайтып килгәндә, бер әбиме, бабаймы үлгән шунда. Хәзер ташы бар аның, каен арасында тора.

Искәндәр дигән, Карагышныкы, бабайның әнисе. Шуңа Әҗәл тау дигәннәр. Бу кешегә зәхмәт, теге нәстә сукты. Кайткан көйгә егылган. Бу 1921 елны ачлык булгачтан.

*Хәлекәй авылында*
*Шәрипова Гадәния Низаметдин кызыннан (1937 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

**Хәлекәй авылы**

Элек бу урынга Хәлиулла дигән бер бабай килгән булган. Шуннан Хәлекәй дип исем кушканнар.

*Хәлекәй авылында*
*Хәмзина Фәүзия Хәйретдин кызыннан (1941 елгы)*
*Г. Яхшисарова язып алды*

**Карагош авылының килеп чыгышы**

Элек тау битендә җыелышып утырганнар инде. Утырганнар да сөйләшәләр икән. Бу бик матур урын, чишмәләре дә (бар). Нинди исем бирербез икән дип уйлаганнар. Шуннан сөйләшеп утырган арада бер каракош килеп утырган. Шуннан соң Каракош дип исем биргәннәр.

*Карагош авылында*
*Туктарова Зөлфә Шәмсетдин кызыннан (1938 елгы)*
*Г. Яхшисарова язып алды*

**Карагош авылының килеп чыгышы**

Ул каракошларның канаты бер-берсе икешәр метр чамасы булган. Зур каракош. Әйтәләр иде, сарык төшкәсе хәтле бар дип. Кешеләр сөйләнеп утырганда, «каракош» дип куйыйк, дигәннәр. Ни өчен Карагыш дигәндә, чөнки татар теленең кагыйдәсе дә бар бит. Беренче иҗектә *о* булса, икенче иҗектә *ы* килә. Шуңа Карагыш дип калган инде.

*Карагош авылында*
*Әхмәтова Нәсимә Габдрахман кызыннан*
*Г. Яхшисарова язып алды*

## Бузат авылы легендасы

Безнең Бузат авылы халкы яшәгән ерләрдә элек, борын заманнарда урманнар каплаган булган инде. Халыклар яшәмәгән. Болгар халкын, татарларны, болгарларны урыс патшалары чукындыра башлагач, бу якларга килеп чыккан да, иң беренче урынлышкан дип әйтәргә була, уйларга була. Чөнки архив материаллары буенча, 1765 елда бу урында бәләкәй генә авыл булган, владения были дигән сүзләр бар, архивный материал Оренбург областной архивтан алынган инде.

Архив материалларыннан башка да, Каюмов Мостафа абый сөйләве буенча, ул риваять итеп сөйләде. Үзенең әтиләреннән ишеткән риваять:

XVII гасырда Пенза губернасында урыс патшасында хезмәт иткән Маминов фамилияле генерал-морза яшәгән. Хөкүмәткә яхшы хезмәт иткән өчен, патша аңа җир бүләк иткән. Әмма җирне Оренбург губернасыннан, буш яткан җирләрдән биргән. Мамин морза килеп җирне караган, ләкин бик еракта, төпкелдә булуын ошатмаган. Шуңа күрә генерал морза Мамин Пенза губернасында яшәгән үзенең крестьян-мишәрләре белән җирләрен алышырга уйлаган. Башта 3 кеше килеп җирләрне караганнар – күргәннәр урман арасында, чишмәләр буенда җәйрәп яткан акланнар булган. Бу җирләрне танышып йөреп ошатканнар инде. Җирләрне танышып йөрегендә боларның атлары чирләй, бер аты чирләй. Шуннан урман арасындагы акланда шул бер чишмә янында калдырып китәләр. Бу кешеләр яңадан Пенза ягына кайтып, генерал морзага үзләренең җирне охшатканын, яшәргә барырга ризалыкларын белдерәләр. Бер ел узгач, 7 гаилә бу якларга күченеп килә. Аларның килеп төпләнгән җирләре шул чирле атны калдырып киткән урман эчендә аклан булган. Бервакыт аклан янындагы чишмәгә хатын-кыз суга бара һәм чишмә янында бер ат очрата. Кайткач, ирләргә сөйлиләр. Барып карасалар, үткән җәй калдырып киткән теге чирле ат булып чыга. Ләкин ат исән-сау, терелгән, ул ат Акбүз була. Атның терелүенә, исән-сау кышлаганына куанган кешеләр авылларына Бузат дип

исем кушалар. Авылга беренче булып нигез салучыларга яшәп китүе бик авыр була. Аларга урман кисеп өй салырга, агачларны төпләп иген үстерү өчен җир эшкәртергә, өр-яңадан дөнья корырга кирәк булган. Урман эчендәге башта бәләкәй авылга, көн күрер өчен, төрле һөнәр ияләре кирәк. Шуңа күрә төрле авылдан тагы да берничә гаилә килеп кушылып яши башлыйлар. Авыл зураеп, үсеп ятканда урыслар да көченеп был якларга нигез сала башлыйлар. Оренбург өлкәсенә караган Зобово, Нистеп дип тә атыйлар, шул авыл урыслары монда килеп мишәрләрне кыерсытканнар. Мал-мөлкәтләрен алып киткәннәр. Җир эшкәртеп чәчкән игенлекләрен таптатканнар, малларын кертеп. Авыл картлары, киңәшләшеп, тагы теге генерал Маминга прошение белән кеше җибәрәләр. Маминга чит якларда үзләренең кыерсытылуларын һәм биләмәләренең, (бу яшәгән җирләре законлаштырылмаган бит инде) (үзләренеке) түгеллеген сөйләп аңлатканнар. Мамин морза берничә гвардеецын авылны сакларга (җибәргән), гаиләләре белән, семьялары белән алар бит инде мишәрләр, патшага хезмәт иткәннәр, алар үзләре бер урам булып утыралар. Әлеге вакытта да морза урамы дип атала ул. Мамин җибәргән (кешеләр) үзләре дә Мамин морза нәселеннән. Шулай итеп, Мамин авылга землимерлар да чакыртып китереп, җирләрен межалап законлаштырып бирә. Авылга землемер белән бергә генерал Мамин да килә. Бузатлылар генерал белән землемерны яхшы итеп каршы алалар, мул итеп сыйлыйлар. Җирне күбрәк бүлсеннәр өчен, бричкага җигелгән пар акбүз ат бүләк итәләр землемерга. Чыннан да землемер җирне бузатлыларга мул итеп бүлә. Оренбург өлкәсенең границасына кадәрлек Тәтер суына төшеп, суының бу як ярын кертеп, җирләрне бүләләр. Бу легенданы Бузат авылында яшәүче хезмәт һәм сугыш ветераны Каюмов Мостафа Әхмәтша улы сөйләгән иде, сугышта катнашкан 23 ме 25 ме, шул тирәйе.

*Бузат авылында*
*Гыйниятуллина Карлыгач Рәшит кызыннан (1959 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## Бузат авылының килеп чыгышы турында легенда

Безнең ата-бабаларыбыз килеп төпләнгәнче бу җирләр калын урманнар белән капланган. Салкын, шифалы сулы чишмәләре челтерәп аккан, төрле кош-корт, җәнлекләр төбәк иткән бик гүзәл табигать почмагы булган. Бу якларда авыллар да сирәк булган әле.

XVII гасырда патшага хезмәт иткән Мамин фамилияле генерал – морза яшәгән. Тик патша Маминга яхшы хезмәте өчен буш яткан башкорт җирләрен бүләк иткән. Мамин килеп җирен караган, ошаткан, әмма бик төпкелдә булуын яратмаган. Шуның өчен Пенза округында яшәгән татарлар белән җирләрен алмашырга уйлаган. Башта өч хуҗа килеп, бу җирләрне күргән һәм ошаткан. Шул вакытта аларның бер аты чирләгән, атны бер акландагы чишмә янында калдырып киткәннәр. Бу өч кеше кайтып, Маминга җирләрен алышырга ризалыкларын белдерәләр. Бер ел үткәч, 7 гаилә бу якларга күчеп килә. Аларның килеп утырган җирләре шул чишмәле аклан була. Бузат авылының Актүбә урамы – шул аклан. Безнең бабайларга яшәп китүе бик авыр була. Урман кисеп өй салырга, иген үстерү өчен агач кисеп, җир эшкәртергә, өрҗәнадан дөнья корырга кирәк.

Бер көнне суга барган хатын-кызлар чишмә янында бер ат очраталар. Кайтып ирләргә сөйлиләр. Карасалар, бу үткән кимәндә үзләре калдырып киткән чирле ат булып чыга. Бу ат – акбүз ат була. Атның терелүенә һәм исән-сау кышлавына куанган халык авылларына Бузат дип исем кушарга булалар.

Урман эчендәге бәләкәй генә авылга әйбәтләп көн күрер өчен төрле һөнәргә ия булган кешеләр кирәк булган. Төрле авыллардан гаиләләре белән тагын берничә кеше килеп кушыла. Шулай, халык үрчеп, авыл киңәеп яшәп ятканда, тирә-яктагы урыс авылларыннан килеп, малларын куып алып киткәннәр, мал-мөлкәтләрен тартып алганнар, төрлечә кыерсытканнар. Авыл картлары киңәшләшеп, теге генерал Маминга прошение белән кеше җибәрәләр. Аңа чит җирдә кыерсытуларын һәм биләмәләренең законлы түгеллеген сөйләп бирәләр. Мамин берничә гвардеецын авылны сакларга җибәрә. Шулай итеп, бу гвардеецлар бер урам булып төпләнәләр һәм Морза урамы дип атала башлыйлар. Генерал

Мамин авылга землемерлар җибәреп җирләрен межалап, ягъни законлаштырып бирергә була. 1803 елның октябрь аенда авылга землемерлар килеп төшә. Землемер Ефим Степанов һәм генерал Мамин дә килә. Бузат халкы аларны яхшы итеп каршы алалар, мул итеп сыйлыйлар. Җирне күбрәк, күбрәк бүлсеннәр өчен, җигелгән пар ат бүләк итәләр. Чыннан да җир бүлгәндә межаны киңәйтеп җибәрәләр, Тәтер тугайларын кертеп бүләләр. Землемерга бүләк ителгән ат – акбүз пар ат була.

Башта авылның урынына 12 бабай килә, авылның урыны урман була. Авылга алар урнашалар, чөнки җире дә әйбәт, чишмәләре дә бик шәп аккан була. Авылга исем бирүнең сәбәбе түбәндәгечә: бабайларның хатыннары чишмәгә суга дип киләләр, шул вакыт су эчәргә бер ат та килә. Ат иярле, җөгәнле, авызлыклы була. Бу ат турында кайтып бабайларга сөйлиләр. Алар атны чишмәдән тотып алалар. Бу акбүз ат була. Авыл исемен Акбүзат дип, соңрак Бузат дип йөртә башлыйлар.

Авылның картасы һәм тарихы язылган «Шазәрҗә» исемле китап та була. Бу китапта авылның тәү утырган чорыннан алып 1933 елларга кадәр язылган була. Китап һәм авылның картасы Галләм бабай үлгәннән соң югала. Безнең торган җирләр Азнай башкортларыныкы була. Бабайлар шушы башкортлардан җирне сатып алалар. Бузат җире су, ягъни чишмәләр белән уратып алынган була. Морза очлары авылга соң киләләр. Бузат халкының төп чыгышы Пенза мишәрләре, шуның өчен без үзебезне пензалылар дип йөретсәк тә була. Элек землемерлар җирне каян ярган, шул дөрес булган һәм ул вакытта документлар да дөрес итеп ясалганнар, шуның өчен дә нестриар безнең җирне ала алмаган. Куштан һәм хәллерәк кешеләр җирне күбрәк алганнар да сатканнар, ә кайбер кешеләр бик аз гына җир белән дә торып калганнар. Барлык биләгән җирләре 12 мең десятина булган. Безнең Бузат урамнары яман чокырлы, сулык ягъни саз була, еллар үтү белән бу үзгәрә. Тормыш бик начар, җирне сука белән эшкәрткәннәр, игеннәр уңмый, чүп баса.

Шулай итеп, хәтсез еллар үтә һәм авылның күренеше дә үзгәрә. Ашау-эчү начар, икмәк булмый, өс киемнәре киндердән

тегелгән, җитен чәчеп аны киптерәләр, суга батырып талкыганнан соң эрлиләр. Өйләр читән, кирпеч һәм агач була. 1910 елларда Столыпин реакциясе була. Бу реакциядә авылларны ваклау карала. Бузаттан да Бузат Башы һәм Кече Бузат авылларына халык аерылып чыга. Ә Үч-Әсән авылында яшәүчеләрне Бузаттан да элек килгәннәр дип сөйлиләр. Кече Бузат халкы белән Гәләветдин дигән кеше, ягъни Баязитов Салихның әтисе күп эш алып бара. Ә Бузат халкы Кече Бузат халкына җирен бирмәскә тырыша. Гали-Бузатлар да Бузаттан аерылып чыгалар. Халыкны «отрубка» чыгарга Галиулла һәм Мөхәммәдияр Касыймовлар өндәп йөриләр, аларга ияреп, халык та языла башлый. Шуннан соң Гали-Бузатка һәм Карамалы-Бузатка күпме җир бирергә землемер алып килеп бүлеп бирәләр. Нестрлар безнең җирне алмасын дип, тизрәк бүленәләр. Нестрлар безнең җирне шулкадәр алырга телиләр, ләкин бузатлылар каршы торалар һәм бирмиләр. Бузаттан 50–60 лап йортлы шушы ике авылга күчеп утыра. Авылның исеме Гали-Бузат була, чөнки Сәхиуллин Галиулла күп эш башкара һәм аның исеме белән йөртәләр. Карамалы Бузатлыларны отрубка чыгарга Мөхәммәдияр Касыймов өндәп йөри. Тәүдә авылны Черки-Карамалы, соңыннан Карамалы-Бузат дип йөртәләр, чөнки тау буенда куе итеп карама агачлары үскән, шуның өчен Карамалы-Бузат дип йөртәләр. Алар үзләренә җир алып, иген чәчеп, мал асрап яши башлыйлар. 1932 елда Карамалы-Бузат, 1935 елда Гали-Бузат халкы колхозга керә. Бу авыллар аерым колхоз була һәм соңыннан бер колхоз булып берләшәләр.

Бу елларда авылда укый-яза белүчеләр бик аз кеше исәпләнә, чөнки мәктәп булмый. 1906 елда түбән очтагы мәчеткә, 1902 елда янганнан соң югары очтагы мәчетне зурайтып салалар. 1914 елда Беренче бөтендөнья сугышы башлана. Хәбәр килгәч тә, халыкны җыеп алып китәләр, авылда да халык хәтсез генә кала. Бу сугышта хәтсез кеше үлеп кала. Бу сугышка яшьләрне 20–21 яшьтән алганнар. Гражданнар сугышы 1926 елга кадәр тартыла, чөнки аклар бандасы Ташкент тау арасында (соңгылары бер кышлакта) безнекеләргә каршы тора. Боларны бетергәнче, коралларын ташлатып үзләрен исән көйгә алу өчен, безнекеләр 6 коммунистны

җибәрәләр. Бу бандитлар коммунистларны үтерәләр. Бандитлар коралларын ташламагач, безнекеләр аларны кышлыктан чыгармыйча юк итәләр. Бу кышлыкта теге туган ил өчен һәлак булган алты коммунист өчен 800 коммунист җыйнап, «Имени мести коммунистов» дигән мәктәп ачып, аларны укыталар. Безнең авылдан да Фәттахов Закир Әттах улы була. Ул аннан кайтканнан соң, колхоз председателе булып эшли.

Колхоз оештырылганга кадәр, 1925–1926 елларда, «Касса взаимопомощи» оештырыла, аның җитәкчесе (булып) Яруллин Гыйниятулла белән Галимуллин Җангир эшли. Ә 1929–1930 елларда «Инициативная группа» оештырылып, җитәкчеләре Зарипов Гәрәй, Заһидуллин Хәбибулла була.

1917 елда Бөек Октябрь революциясе була. 1918 нең язында большевиклар – кызыллар безнең авылга да килә, алар артыннан казаклар һәм аклар килә.

Бузат авылына төрле яклардан, төрле авыллардан күчеп килгән кешеләр нигез салган. Бу хәлләр 1780–1790 еллар арасында булган.

1795 елны үткәргән V ревизиядән иртәрәк документларны очрата алмадык.

Башкортстан Үзәк архивында сакланган 1795 елгы «Ревизская сказка»дан күренүенчә (ф. 138, оп. 2, д. 53), Бузатка түбәндәге авыллардан күчеп килгәннәр:

Яфар авылыннан – 24 кеше.

Якуптан – 11 кеше.

Абдразәктән – 29 кеше.

Мәсәгуттән – 31 кеше.

Мәтәй авылыннан – 23 кеше.

Богдан авылыннан – 48 кеше.

Касимнан – 8 кеше.

Хисаметдиннан – 7 кеше.

Якуп һәм Богдан авылларына халык Богорослан .... Матюшкина авылыннан күчкән булганнар.

*Бузат авылында*
*Каюмов Мостафа Әхмәтша улыннан*
*Г. Яхшисарова язып алды*

## Бузат авылының чишмәләре

**Шифалы чишмә.** Актау урманы астындагы тау башыннан кыйблага карап ага. Борынгы вакытларда моннан ниндидер үткенчеләр үтеп барганда, бер Мосафир ишан үлгән. Бу мәрхүм булган ишанны иптәшләре шул үзләре туктаган чишмә кырына җирләп киткәннәр. Хәзер бу урынны Шифалы чишмә дип йөретәләр.

**Кәрим кизләве чишмәсе**нең исеменең тарихы болай. Кәрим исемле бер кеше күрше хохол авылыннан нәрсәдер урлап кайтып килгәндә, артыннан хохоллар куып җитеп үтереп киткәннәр. Кәрим кизләве яланының ас ягында, беренче бригада җирендә, Арбихан урманы астыннан чыккан бу чишмә суы зур җырын булып Көчегән елгасына агып төшә.

**Коры күл** исеменең тарихы болай. Ырымбур өлкәсенә кергән Кузылы авылының бай мукшылары Көчегән авылының ярлылары, куштаннарын алдап, юк кына хакка күп кенә җирләрен алганнар. Шулар арасында Сафрон исемле бай да булган. Шулай итеп, күп кенә көтүлекләр, сабынлыклар буш кына хакка сатыла. Шуңа күрә исеме дә Каракүл – буш, калдык дигәнне аңлата. Ул инеш хәзер чынлап та сусыз, корыган чокыр, «Каракүл»гә әйләнгән.

Сафрон байның утарын (Синатурдан аста) халык **Нахаловка** дип атый, әрсезләнеп, оятсызланып кешеләрнең җирен алган өчен. Аның янындагы чишмәне Сафрон чишмәсе дип йөртәләр.

Каракүлгә агып төшүче чишмәләр: Каракүл, Золып, Синатур, Сафрон.

**Синатур** электән үк Аксён ягында кымыз белән давалый торган санаторий булган. Санаторийның кымыз бияләрен бу җирдә көтеп йөрегәннәр. Санаторийдан Синатурга әйләнгән сүз ул. Ә аңа кадәр Каракүл тамагы дип тә йөрткәннәр.

**Золып чишмәсе** – өзелеп дигән сүздән кыскарып калган.

Көчегән урманының артында **Зөләйха чишмәсе** бар. Урман кырындагы акланда Зөләйха исемле әби җиләк җыеп йөргәндә, сусап, сазлыкта чишмә казый, ургылып шул җирдә су чыга.

Кече Бузат авылы халык телендә Бишкуян исемендә йөри. Бу авыл бик матур кечкенә инеш буенда урынлашкан. Кече Бузат

инеше чишмә суларыннан хасил. Сәүбән, Гата, Кәкән һәм башка исемсез чишмәләр инешкә кушыла. Карталарда бу инешне Бузочка дип язалар. Бу инеш тә Бузат елгасына ага.

**Карамалы инеше** тугаенда урынлашкан Карамалы-Бузат авылы 1925 елда барлыкка килгән. Шул ук вакытта Гали-Бузат авылы да Бузат елгасы буенда төзелә. Бу авылларга Бузат авылы кешеләре нигез сала. Моның сәбәбе Бузат җирләрен Ырымбур урысларыннан саклау булган. Тәтер буенда Зобово (Нестер) авылы барлыкка килү белән Бузат җирләрен үзләштерү башланган. Тәтер аша чыгып, печәнлекләрен чапканнар, иген чәчкәннәр, малларын йөреткәннәр. Бузатлыларның урманнарын, чишмәләрен, матур тугайларын үзләренеке ясыйсы килгән. Озак елларга сузыла бу җир өчен бәхәс. Гали-Бузат белән Карамалы-Бузат авылларына нигез салгач кына туктый бу җир өчен бәхәс.

Карамалы-Бузат авылын үтеп, **Черекәй урманы, Черекәй өсте яланнарыннан** соң **Пятка тавы** башлана. Тәтер буенда **Пятка тугае** ята, Пятка чишмәсе дә бар. Пятка исемле борынгыдан калаган. Землемер Бузат җирен бүлгәндә була ул.

Көчегән елгасы буйлап межа бүлгәндә, бер бүз атлы яңгылыш землемерның бавына баса. Межаны бау тартып, бүлеп – билдәләп, артыннан сабан белән сөреп барганнар. Землемерның ачуы килеп, җирне кисә, ягъни киметә башлый. Пьяный хутор дигән җирдә бузатлылар землемерны туктатып эшеннән, аны көйли, сыйлый башлаганнар. Шунда ук землемерга бричкага җигелгән пар бүз ат бүләк иткәннәр. Шуңа күрә дә землемер бузатлыларга, Тәтер елгасының ярты суын кертеп, җирне мул итеп бүлә. Бу киңәеп киткән җирләр: Пятка тау өсте, Пятка тау бите, Пятка тугае исеме белән йөртеләләр. Татарча пятка үкчә дигәнне аңлата, чынлап та бу җирләр картага карагач, үкчәгә ошап тора.

Бузат урманнарының исемнәре: Баймый, Сулы чокыр, Тирән чокыр, Комтау, Иске посадка, Сирәк имәнлек, Серекәй, Алексей, Мәчет, Кәкән (Сатра), Әрбихан, Аргы Бишкуян, Бирге Бишкуян, Актау, Чытыр һәм бәләкәй урманнар: Алаша киләге, Шалкан киләк, Озын киләк, Бурлык киләге, Мукшы чокыры, Кынак.

Киләк сүзе вак агачлык, куаклык мәгънәсендә.

Кынак – элек кәзәгә ошаган «кулак» дигән хайван бу урманда бик күп булган.

Әрбихан – армия һәм хан дигән сүзләрдән ясалган. Моннан күп еллар элек, ханнар белән урыслар сугышкан вакытта, ханның армиясе бу җирдә туктап торган.

Бузат авылына карт бабайларыбыз нигез салганда, тирә-як куе урман булган. Иң беренче Актүбә чишмәсе акланында нигез корганнар. Бу аклан урман эчендә булган. Карт бабайларыбыз урман кисеп, агач төпләп, йорт салганнар, бакча ясаганнар, иген чәчкәннәр. Еллар үтү белән авыл зурайган, мал артып үрчегән. Урманнарны кешеләр кисеп, маллар таптап бетергән. Күп урман юкка чыккан.

*Бузат авылында*
*Гыйниятуллина Карлыгач Рәшит кызыннан (1959 елгы)*
*Г. Яхшисарова язып алды*

**Уч-Әсән**

Исемен бозып беткәннәр язуда. Учуган дип язганнар. Бу авылның исеме Уч-Асанова. Монда, балам, кара урманнар булган элек. Дикий янлекләр яшәгән. Бер Әсән дигән бабай килә Стәрлетамак ягыннанмы, юк, бу яктан килә, без – Казан нәселе. Бузатлар безгә бер родня да түгел. Ялгыз каен дигән авылдан килгән аларның беренче кешесе. Безгә якын килгән кешеләр түгел, телләре дә бүтән аларның. Шуннан бу бабай килә дә, Әсән дигән бабай, агач төпли дә өй сала. Кайтып 2 малаен алып килә, кешеләр җыела, шуннан яшәп киткәннәр инде. Бу үзе олы, күптәнге авыл, карт авыл. Уч кебек кенә урынга килеп урнашкан. Әсән (бабай) исемле кеше. Монда беләкәй генә алан булган, уч кебек кенә, шунда урнашкан. Шуңа күрә Уч-Әсән.

**Бузат**

Бузат безнеке түгел. Бузатка ул Ялгыз каен авылыннан килгәннәр. Акбүзатка менеп бер бабай килгән. Бузат берәү калды инде ул. Таралып бетте алар. Алары Бузатның үзеннән аерылып чыкканнар, алары килмәгән. Шуннан курыкмыйча берүзе

урнашып, шуннан авыл булып яшәп киткәннәр. Бүтәннәре аның биш йортлы. Ерүзәнгә киттеләр. Мәктәпләре дә юк, бетте, таралды бит инде.

*Өч-Әсән авылында*
*Галәветдинова Бәлхия Гыйззәтулла кызыннан (1931 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

**Акылның атасы кем?**

Бер җегет укырга бара. Ул заманда 25 ел укыйлар Бохарада. Укырга бара, 25 ел укый, ике аяклы арбага китапларын төеп, экзамен бирә дә, кайтырга чыга. Кайтырга чыкса, бер Сакмар күпере кебек озын күпер, шунда бер бабай тора. Бабаймы? Урта яшьләрдә. Туктата.

– Балам, син укып кайтып киләсеңме?

– Әйе.

– Китапларың да күп икән.

– Күп. Менә алып кайтам барсын да.

– Менә син миңа шуны әйт әле. Ул бабай булып күренә фирештә икән. – Син әйт әле, мына шул, бер сорау бирәм, шул сорауга явап бирсәң, үтәсең күперне, бирмәсәң – үтәлмисең. Шуннан:

– Акылның атасы кем? – ди.

Ват, Ходай Тәгалә, белә иде бу, оныттырды. Ык-мык итә, белми бу.

– Вакыт узды, балам, бар остазыңа әле ерак китмәгәнсең икән. Бохарадан сорап кил сине укыткан кешедән. Бу белә иде аны. Барды да, И-и, укытучысы әйтә, син аны беләең, нишләп әйтмәдең, ди.

– Оныттым, ди.

– Акылның атасы, балам, сабырлык.

Бу шуны әйтәлмәде. Кире барып сорагач, әйтте.

* * *

Өч егет монда, безнең арада бер явыз кеше бар, су керә көймәгә, ди. Ә, давай, ди, шобага тотабыз, кем явыз була, шул

башка чыга. Көймәгә су керә, мына дигән көймә барган. Шуннан бу Сөләйман пәйгамбәр дә була анда. Шул башка чыга. Алар да диңгезгә ыргыталар моны. Ыргыткан көйгә балык авызына эләгә. Кит балыгыдырмы, акуламы. Эләгә, шул күпмеләр йөретә, утырып тик тора, бер дә питаться итми ул балык аның белән. Шуннан беркөнне Җәбраил фирештәгә Аллаһы Тәгалә әйтә:

– Бар шул диңгезгә, бөтен халык җыелыгыз, яр башына утырыгыз бүген, ди, шул балык авызыннан нык өермәле давыл чыгара да, ди, ярга 2 м килеп ярга су чыга, ди, 2 м биеклектәге ярга, шуннан балык коса, ди, ә пәйгамбәр исән-сау чыга, ди, сәдәф кебек кенә калган.

Шунда тагы әйтәләрие:

Балык карынында
Бер сәхип кирәмәт
Чиләү утыр ди
Ачык ти ул, сәламәт.

Аңа 1 ел калак белә(н) ашатып, өйдә тоталар. Ул бит беткән инде анда ничә көннәр буе. Шуларга да бик күп мөнәҗәтләр ие.

*Өч-Әсән авылында*
*Гафиятуллина Мөбарәк Муллагали кызыннан (1930 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### Өч-Әсән авылының риваяте

Үч-Әсән авылы Башкортстанның иң матур табигать кочагында урнашкан. Каен урманнары, чәчкәле үзәнлекләр, биек булмаган калкулыклар арасында утыра ул.

Безнең Әсән авылы турында шушындый риваять яши. Зур авыл Алагуаттан берәү ауга чыга. Киек кошлар эзләп, ул озак йөри. Ниһаять, бик матур урынга килеп чыга: куе урманнар эчендә зур гына аланлык ачыла. Янәшәдә генә кечкенә елга агып ята. Аңарда балыклар йөзеп йөри. Елга аръягында ябалдашлы агачлар белән капланган калкулык була.

Әсән, әсәрләнгәндәй, шушы аланда тукталып, тирә-яктагы хозурлыкка сокланып тора. Бу урын аңа шулкадәрле ошый, ул

шушында төпләнергә карар итә. Тиздән туганнарының ярдәме белән өй сала, гаиләсен күчереп алып килә. Соңрак аның биредә ике улы дөньяга килә.

Әсән артыннан аларның туганнары, якыннары, дуслары күченеп килә башлый. Әлеге авылга нигез салучы Әсән һәм аның ике улы хөрмәтенә Үч-Әсән яки Өч-Әсән дип йөртә башлаганнар.

Авылның икенче исеме Көчегән – кече авыл мәгънәсендә алынган.

*Өч-Әсән авылында*
*Нәҗметдинова Әлфиядән (1998 елгы)*
*Г. Яхшисарова язып алды*

**Яшерган (Исмәгыйль)**

Яшерган авылы 1706–1710 елларда җыела башлаган. Монда әле кара урман булган. Түбәдә алан булган. Түбә дигән авылда. Тәүге йортлар салынып, авыл шуннан үсә башлаган инде. 1751 елны Елизавета императрица, татар халкының Урта Азияне яулап алудагы керткән хезмәтләре өчен, татар зыялыларына (служилый татарлар) Оренбург крепостеннән Уфа крепостенә хәтле юл буйларына татар авыллары төзергә рөхсәт иткән. Шул вакытта Татар Каргалысы, Юзеево, Мостафа (М. Җәлилнең туган авылы), Шарлык, Сарманай, Нәүрез Ибрай, Яшерган, Айдарәле һ.б. татар авыллары тезелеп киткән. Авыллар үскән.

Авылның исеме килеп чыккан шуннан: 1773–1775 елларны була Пугачёв восстаниясы. Каранай авылыннан Каранай Моратов, Салават Юлаевлар катышкан булган. Александр Суворов – безнең генералиссимус килеп бастыра восстанияны. Шул вакытта участникларны эзерлекләү башлана бит инде, шулар качып килеп, Тишекле тау дигән тауга чокып кереп, землянка ясап, шунда качып ятканнар инде (Пугачёв явында катнашканнар). Шул качакларны яшереп яткан өчен, халык арасында качакларны яшергән авыл дип йөрткәннәр. Шул яшергән дигән сүз, качакларны яшергән авылга шул яшергән дигән сүз ябешеп калган. Аңа хәтле 1770 елны Каргалы авылыннан чыккан Нократ утарыннан Исмәгыйль дигән старшина килеп, бу җирләрне Дистән карттан

сатып ала, үзенең кешеләре белән килеп урнаша. Монда Ибрайга Ибрай дигән кеше, Яшерганга – шул Исмәгыйль, Арсланга – Арыслан, Айдарәлегә – Айдаргали дигән кеше.

Авыл башта Исмәгыйль исемен йөртә, качаклардан соң Яшерганга әйләнә. Авыл шулай үсә, халыклар яши. Шөгыльләре – җәнлекләр аулау, елгадан балык тоталар бит инде, кем умарта, сыер, кәҗә, сарык асраганнар, кайсылары каен тузыннан дегет кайнатканнар – арбаны майлау өчен, күчәр майлаганнар, күмер иләгәннәр, арба ясаганнар, чана ясаганнар һ.б. эшләгәннәр. Әйберләрен Оренбур базарына алып барып тозга икмәккә алмаштырып кайтып көн күргәннәр. Яшерган авылының ташы авылның тарихында зур урын алып тора. Яшерган авылының ташы единственный бер урында чыга ул. Оренбур ягыннан Стәрлетамакка хәтле бөтен мөселман зияратларының кабер ташлары күбесе Яшерган ташыннан эшләнгән. Пычкы белә(н) кисеп, балта белән(н) юынып, ышкы белә(н) ышкып. Әле дә чыга, ясаган кеше бар. Хәзер бит инде мәрмәр-гранит эшләгәч, шуңа күрә спрос әзәйде инде. Элек бит инде специально ташчылар барые. Элек мәчетләрнең ихаталары да, стеналары, фундаментлары да вич шул таш белән уратып алынган иде.

Моңардан тыш халык сарык йонынннан киез басканнар, тула, пима басканнар, свитерлар бәйләгәннәр. Моңардан тыш кәҗә мамыгыннан бәйләгәннәр мамык шәл, шарыф, мамык пирчәтке – кияүгә бирә торган кызның бирнәсенә обязательно атрибут иде инде ул вакытта. Әл(е) дә бирәләр, элекке кебек биргәннәр. Мамык шәлне кем кайда сата, күбрәк Ташкент базарына китеп, шунда сатып кайталар. Шуның белә(н) халык яшәде, шәлләр белән, төп кәсеп булды. Оренбур пуховый платок дип ерласалар да, төп кайнады инде мында. Укучы балалар(ның) күтенә утырганы тотына иде бәйләргә. Әл(е) дә бәйлиләр, менә иптәшем дә бәйли. Бер 10 лап шәл бар әле. Киленнәргә әзерләп салып куя. Шунсыз, шуның белә күңелемне тынычландырам, ди, алар бит шуңа өйрәнгән. 1861 елгы крепостной праваны отменять итү авыл халкына бернинди үзгәреш тә кертмәде. 1909 елгы Столыпин реформасы авылга үзгәреш кертте, чөнки Айтуган авылыннан Кызыл

юл авылы чыкты, Ибрай авылыннан чыкты Кызылъяр, бездән Акчишмә авылы чыкты. 12 семья башта. Хрущев перспективные деревни дигәннән соң таралдылар инде. Кызылъяр бар әле.

Революция, гражданнар сугышы, аклар белән кызыллар үткән. Әни сөйлидерие әле. Килеп үтәләр, туплар такканнар. Аклар килеп керде, алар алама гына киенгән. Ашык-пошык кына мунча керәләр дә, тегеннән кызыллар килә башлагач, чыгып чабалар качып. Кызыллар әйбәт кожанный курткалар кигәннәр ие. 1921 елны авыл советы оешкан, 1931 елны берләшеп колхозларга кергәннәр, колхозлар оештырганнар. Сугыш чорында безнең авыл советыннан 550 кеше яу кырына китә, шуның 347 се яу кырында ятып калалар инде. Бу бик зур, күп югалту инде. Аннан соң инде сугыш чорындагы өзеклекне, җимерекне тергезү башлана бит инде. Авылга 1961 елны башлап свет керде. Радио тыңный башладык. 1982 елны авылга су керде. Чишмәдән китердек самотек белән таудан. 1997 елга авылга газ керде. Менә 20 ел булды инде авылга газ кергәнгә. Болай авыллар яшәргә тиеш иде. Авылларның иң үсешкән вакыты 1960–1990 елларга хәтле булды. Ул вакытта 747 йорт барые, 3500 артык кеше барые. Монда мәктәптә генә 1200 бала укыйдырые. Елына 180–200 бала туадырые. Районда сыйдыралмагач, үзебезнең авылда роддом ачылды.

Дәүләт думасы депутаты Стәрлебашныкы, Мөхәммәтшакир Тукаев бит инде. Аның малае Габделхәй белән бергә хезмәт иттек без. Энесе Марс главный редактор газеты булды. Алар мәрхүм булды инде икесе дә.

Данлыклы мәдрәсә. Чокрыйлар, Мифтахетдин Акмуллалар бөтенесе күренекле, элек(ке) Стәрлебаш мәдрәсәсе бик данлыклы. Элек авылда 3 мәчет булган. Закон булган халыклар өчен. Бөтен нәрсәне алар хәл иткән. Совет власте чорында да Башкортстанда 3 указной мәчет кала, берсе Яшерганда, бервакытта да ябылмады. Әле 2 мәчет бар. 25 кеше булырга тиеш иде. Списокта торырга тиеш иде совет чорында.

*Яшерган авылында*
*Мухтаруллин Һидиятулла Ибәтулла улыннан (1942 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## Яшерган

Яшерган авылы башланганчы монда башта чувашлар яшәгән. Мин(нем) ишетүем буенча, Нукрат исемле карт килгән беренче. Утырган монда. Чуваш авылы булган. Шуннан соң чувашлар күчеп киткән. Чувашлар чыгып киткәч, татарлар килеп утырган. Каргалы дигән авылдан казак булып хезмәттә йөргәч, аңа җир биргәннәр. Ул туганнарын вич ияртеп апкилгән шул Каргалы дигән Оренбургский областьның авылыннан. Монда Яшерганга килеп утырганнар. Монда куе урман булгач, эзләп табучылар чак тапканнан соң:

– Ну яшеренгәнсең, дигәннәр. Шуңардан Яшерган авылы булып киткән.

* * *

Икенче версиясе:

Монда Салават Юлаев гаскәре белән үткәндә, кешеләр җыйнаганнар авылга кергән саен. Бу авылга килеп керсәләр, авыл буп-буш. Болар яшеренгәннәр дип киткәннәр.

Шуннан:

Кайсы авылдан син.

– Әнә шул тирәдәге, – дисәләр...

– Ә, Яшеренгән авылыннан мени. Шуңа күрә Яшерган булып киткән.

*Яшерган авылында*
*Хәсәнов Илдус Галинур улыннан (1980 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## Ибрай авылының килеп чыгышы һәм тарихы

Авылыбызның исеме дә вакытлар үтү белән бераз үзгәрә торган. Таш асты Ибрай, Ибрай, Түбән Ибрай. Башкортстандагы татар авылларының күп өлеше кебек үк, Стәрлебаш районы Түбән Ибрай авылының тарихы да XVIII гасыр уртасына килеп тоташа.

Явыз Иван Казанны тар-мар итеп, әлеге халыкны яңадан беркайчан да аягына баса алмаслык итеп тулысынча хәлсезлеккә китерергә карар итә. Ул авыл һәм шәһәрләрне яндыра, ирегетләрне үтерә, татарларны коллыкка сата һәм аларны көчләп

чукындыра. Шуңа күрә татарлар күпләп Себергә, Урта Азиягә китә башлый, ә 800 меңе хәзерге Башкортстан җирендә төпләнеп кала.

1745 елда Вятка (борынгы исеме Нохрат) елгасы буендагы Саба авылыннан 200 гаиләдән торган татарлар төркеме, Сәет исемле кеше җитәкчелегендә, Оренбург губернасының Каргалы авылына күченеп утыра. Җайлап алар аннан бәләкәй төркемнәргә бүленеп күченә башлыйлар. Шул рәвешле 1751 елда Тәтер елгасы буенда да татарлар пәйда була. Аларның агымы аеруча Пугачев восстаниясен бастырганнан соң көчәя.

1751 елны Оренбург шәһәре янындагы Каргалы авылыннан (Сәет бистәсеннән) килгән татар сәүдәгәрләре мең башкортлары белән килешү төзиләр һәм җир сатып алалар.

Башта ташлы тау турындагы Тәтер елгасы буена Каргалыдан Рәхмәтулла дигән кеше җитәкчелегендә 7 гаилә килеп урнашкан. Рәхмәтулла җир хуҗасы була. Алар арасында аларның малларын куып килүче 1 казах егете һәм 1 казах кызы була. Алар өйләнешеп, бер гаилә булып яшәп китә. Рәхмәтулланың 4 улы була: Шәрип, Кәшәп-Кәшиповлар нәселе (Муллабай абый), Әхмәтвәли-Рәхимовлар (Нәүрүз абыйлар нәселе), Зариф-Саббах бабай или Зарипов Сабитлар нәселе.

Бераздан, таудан ташлар тәгәрәп төшә башлагач, авыл хәзерге урынына күченә – Тасай һәм Пешкәрдәк сулары кушылган җиргә. Тасай һәм Пешкәрдәк исемле кешеләр авылга күченер өчен урын эзләгәннәр. Суларга аларның исеме бирелгән. Чияле тау ягыннан килгән инешкә Тасай диелә. Бүгенге бәйрәм дә Тасай буенда үтә. Елга башыннан килгән елгага Пешкәрдәк дип исем кушыла. Рәсми документларда авыл 1781 елда барлыкка килә дип языла. Шулай булса, быел авылга 235 ел була, ә Таштауга килеп утыруларына, чыннан да, 1751 ел булса, 265 ел була.

Биләмәләре Зирекле, Кызылъяр, Ибрай, Гали-Бузат, Старое Любино, Новое Любино, «Әгелчән утары», Спасск авылларының җирләре һәм Изәк-Никитина, Кәлдәй, Айтуган сыртларыннан Тәтер-Арслан межасына, аннан Яшерган каенлыгына кадәрге җирләр була.

Авыл яңа урында төзелә башлый. Аларга Казан һәм Стәрлетамак шәһәрләреннән мещаннар килеп кушыла. Тимерчеләр, буяучылар, тегүчеләр (бертуган Халиковлар) булалар. Припущенниклар урындагы халыктан рөхсәт алып, батрак булып эшлиләр. Авыл дүрткә бүленеп йөргән: «хәҗәен», «ясаклы», «мещан» һәм «припущенник»ларга.

«Хәҗәен»нәр – җир хуҗалары булган. Мещаннар Түбән Очта яшәгәннәр. Җирсез, урмансыз, читән өйле булганнар. «Ясаклы»-лар – җир хуҗаларына хак түләп, җирне файдаланучылар. Припущенниклар Югары очта яшәгәннәр. Күбрәк солдат хезмәтендә булган кешеләр. Алар урман, җирләрне саклаганнар. Угрылык һәм авылдагы тәртипсезлек белән көрәшкәннәр. Халык мал-туар асраган, игенчелек, урманчылык белән шөгыльләнгән, сәүдә белән көн иткән. Сөренте җирләр аз булу сәбәпле, өстәмә хәзерләү, күмер яндыру, курыс кисү һәм башка эшләр булган. Урманны Айтуган сыртыннан һәм Стрельцовка урманнарыннан алганнар, чөнки аннан Шарлык базары якын була. Урман әзерләүчеләр кыш буе землянкаларда яшәгәннәр. Ул вакытта чәй кайнатырга самавырга салырга, үтүк кыздырырга һәм тимерчеләргә күмер кирәк булган.

Авылда ике мәхәллә булган (мәхәлләне кеше саны буенча ачарга рөхсәт иткәннәр).

Кызлар да надан булмаган. Гарәпчә укырга өйрәнгәннәр. Авылдашлар тырышып дөнья көткән. Илдә булган хәлләрнең берсе дә авылыбызны читләп үтми. Бик күп авылдашларыбыз Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. Аннары Гражданнар сугышы башлана. Аклар һәм кызылларның бәрелешләре авылдан читтә, Ташлы тау янында була. Авыл халкына зыяннары тими, бары тик ике як та күченү өчен олаулар гына алганнар. Бу хәлләр 1919 елны була.

1921 ел житә. Бу елны тоташ ил буенча корылык була. Авыл яна. Янгыннан соң авылда унлап кына йорт калган. Шушы сәбәпләр аркасында бик күп кешеләр читкә китә. Оренбург, Урта Азия, Казахстан һәм башка якларга.

Авылның (беразы, 7 гаилә халкы) әлеге Кызылъяр авылы урынына күчә. Калган халкы Елга башы янында землянкаларда яши

башлаган. Бердән авылга кайтырга кирәк, дигән фикергә киләләр. Кайтып йорт урыннарын көлдән тазарталар. Авыл халкы бик авырлык белән йорт-илне аякка бастыра башлый. Әлбәттә, 1921 елга (кадәрге) кебек төзелгән карагай йортлар аз була. Мәчет урыны – Исмәгыйлев Шамил абыйның бәрәңге бакчасы урыны.

Авылда төзелеш эшләре барганда, халыкның канау төзергә вакыты да булмый, 1928 елларда канау төзү эше башлана. Канау башында һәм Мунчала күле чокырында 2 зур буа төзелә.

1970–1971 елларда авылга суүткәргеч сузалар. Халык тырышып эшли, тормыш матурая бара. Ләкин шул вакытта, 1941 елны сугыш башлана. Безнең Ибрай авылыннан 149 кеше сугышка китә. Ләкин кире әйләнеп кайту барысына да насыйп булмый. Авылыбызның 80 ир-егете яу кырында башын сала.

*Яшерган авылында*
*Локманова Рәйсә Равил кызыннан (1955 елгы)*
*Г. Яхшисарова язып алды*

## Тишекле тау

Кызыллар акларны куып килгәннәр дә, аклар кереп качкан. Шуннан анда пәрәвез оясы бар иде. Күгәрчен килеп күкәй салган. Шуннан аларны ничә еллар якканнар шунда. Вакытлар шактый үткән. Сакаллары, чәчләре үскән. Әйтәләр икән: «Без күпме вакыт монда тордык икән?» – дип. Шуннан чыксалар, дөнья үзгәргән икән.

*Яшерган авылында*
*Кашапова Гөлфани Сафиулла кызыннан (1937 елгы)*
*Г. Яхшисарова язып алды*

## Айдарәле

**Урта тау.** Бу якта торган тау **Айгыр тавы** дип атала, урталыгында **Чишмәле тау**, бу яктагысы **Мәчет тавы** – шуннан кисеп мәчет салганнар. Аска төшкәндә мәчет урыны бар иде, шуннан мәктәп булды. Усаклык, шуннан китә **Зират тавы** – авылның башында. Анда Айдар бабайның зираты бар, аны уратып алынган. Шушы очтан башланган авыл. Бабайның исеме Айдаргали булган. Авылның исеме Айдарәле булып киткән. Бабайның ташы

шул үлгәч куелган таштыр инде ул. Соңгы председателебез куйдырткан таш.

*Айдарәле авылында*
*Мишарова Нурия Зариф кызыннан (1950 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Аллаһы Тәгалә, фәрештәләргә гомер сорап киләләр.

Иң тәү кешенең дусты, хезмәттәше – Ат килә.

– Миңа күпме гомер бирәсез, ди ул.

– Сиңа 60 яшь, гомер – бәйрәм, гомер буе кешегә хезмәт итәрсең, йөк ташырсың, арырсың, ашарга да бирмәгән вакытлары булыр, суеп та ашарлар, – дигән. Ат әйтә:

– Бик авыр яшәгәч, 20 ел җитәр, – дигән.

Шулай итеп 40 запаста кала.

Эт бара.

– Сиңа 20 ел гомер. Кешегә хезмәт итәрсең, урының тышта булыр. Бур анда да, яңгырда да, тышта ятарсың, ач чакларың да булыр, – дигән.

– Ай-һай яшәве бик авыр булгач 10 ел гомер җитәр, – дигән.

Кеше бара.

Аллаһы Тәгалә кешегә әйтә:

– 20 ел гомер бирәм, – ди. Бик рәхәт яшәрсең, кайгы хәсрәт күрмәссең.

Кеше:

– Болай бир рәхәт яшәгәч 20 ел гомер бик аз була, – дигән.

– Алай булгач, үз гомерең – 20 ел, аттан калган – 40 ел, эттән калган – 10 ел.

Кешегә 70 ел гомер бирик, – ди.

Кешенең 20 ел гомере рәхәттә үтә, үсмер чагы. 40 ел гомере аттай эшләп үтә. Ә 10 ел – эт гомере, диләр. Картайгач төрле кеше төрлечә гомер кичерә. И Аллам, картайгач эт гомере генә булмасын!

## Ит изгелек, көт явызлык!

Карт бабай урманнан китеп бара. Бер биек агач яна, агач башында елан утыра, ут еланга менә-менә килеп җитәргә тиеш.

Елан бабайга нык итеп сызгыра. Коткар мине диеп ялына, ялвара. Бабай озын колга алып килеп, агач башына тери. Елан шуышып җиргә төшә башлый. Җиргә төшкәч, бабайны елан буа башлый. Бабай ялына: «Үтермә мине, мин сине үлемнән алып калдым», – ди. Шуннан бабайны җибәрә. Икәү юлга чыгалар... Каршыларында инжир агачы үсеп утыра. Туктыйлар, сөйләшәләр: «Кешеләргә җимеш бирәм, ашыйлар, туеналар, күләгәмдә ял итәләр, ә соңыннан сындыралар ботакларымны, җимешләремне җиргә өзеп ташлыйлар, яфракларымны өзгәлиләр, ярты янып өзгәләнеп җирдә ята, – ди. – Изгелегем явызлык булып кайта», – ди инжир агачы.

Болар алга таба юл алалар.

Алда бер үгез җир сөрә. Сөйләшәләр, хәлләрне сорашалар. Үгез: «Кешеләргә җир сөрәм, ашлык чәчәләр, туенып яшиләр. Шулай картайганчы эшлим, аннан сугып үтерәләр. Изгелегем явызлык булып кайта», – ди үгез.

Елан белән бабай һаман юлда. Каршыларына төлке килеп чыга. Бабай: «Менә әйбәт булды әле. Тиресе әбиемә тапочка тегәргә кирәк иде», – ди. Хәйләкәр: «Юк, мин тиремне сиңа бирмим, – ди. – Картлач, нигә елан белән дуслашып китеп барасың, ул сине буып үтерәчәк, – ди. – Хәзер үк үтер еланны, – ди.

Бабай таяк алып еланны сугып үтерә. Ит изгелек – көт явызлык.

Шулай итеп, бу хәйләсез дөньяда хәйләкәрләр, шайтаннар арага керү нәтиҗәсендә изгелек явызлык булып кайта икән.

*Бакый авылында*
*Вилданова Ямал Газиз кызыннан (1921 елгы)*
*Г. Яхшисарова язып алды*

**Әхсән**

Аклар-кызыллар сугышы вакытында. Шушы Стәрлебаш авылында, революция елларында, гражданнар сугышы башлана башлагачтын. Комсомоллар оешмасы төзиләр бит инде. Балаларны, яшьләрне яшүсмерләрне җыйнап утырталар да бинага. «Егетләр-кызлар кайсыгыз(ның) комсомолга керәсе килә?»

Берсе дә эндәшми, куркалар. Дини яктан көчле булган чак була бит инде. Беренче комсомолец булып Әхсән исемле егет кул күтәрә. Комсомол булып кереп китә бит. Шуннан соң аклар-кызыллар сугышы китте. Безнең мәчетебезнең бер бинасын клуб ясыйлар. Хәзер шунда Бизгин дигән авыл бар, шунда алпавытның фортепианосын алып төшәләр. Анысы рус авылы. Теге баланың музыкальный сәләте булды микән инде. Гайфулла исемле дусты белән чыңгырдатып утырганда, бертөркем ирләр килеп керә, атларга атланган, киемнәре буенча билдәле булмый, аклар микән, кызыллар микән?

– Егетләр, сез кемнәр?

– Без комсомоллар абый.

– Комсомоллар булгач, әйдәгез, чыгыгыз әле.

Апчыгалар да, чыгу белән бәреп егалар балаларны, икесен дә. Ат койрыгына тагалар. Шуннан бөтен Стәрлебаш буйлап йөртеп, күрше генә бер авыл бар безнең – Ибракай, шул Ибракай тауларына алып баралар. Ике дистәгә якын хәнҗәр белән казап, теге баланы үтерәләр. Гайфулласы беренче сугу белән ук егыла, үлгәнгә салышып ята. Ансы исән кала азакта, көч хәлләр белән. Монысы бит инде үлә бу бала. Хәзер моны берсе бер кулы белән сугып очыралар, аннан икенче кул. Әхсән исемле. Апкайталар, әтисе-әнисе булмый бу баланың, картәтисе үстергән була. Картәтисе кич көне кояш төшә бит инде.

– Улым, Әхсән, ди. Күз күрми. Таяк белән ихатага суга-суга эзләп йөри. Юк. Капчыкларга тутырып апкайталар бу баланың гәүдәсен. Халык шул тиклем яраткан була бу баланы. Һәм безнең Стәрлебашыбызның бер урамына Әхсән исеме кушалар бит инде.

*Стәрлебаш авылында*
*Гыйзетдинова Зөлфия Зиннәт кызыннан (1961 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## Стәрлебаш авылының тарихы

Стәрлебашны элек-электән элеке Бохара дип йөреткәннәр. Мәдрәсәләре белән бик данлыклы булган. Төрле регионнардан, төрле җирләрдән килеп укыганнар. Бу мәдрәсәдә дини белем

генә бирмәгәннәр, ә точный наукаларны өйрәткәннәр (математика, география, естествознание, астрономия). Мәдрәсәне укып чыккан кешеләр мөгаллим, мөгаллимә булганнар. Мәдрәсәдә яшәгәннәр, столовые булган. Бөтен расходларын Тукаевлар каплаган. Ә менә Мифтахетдин Акмулланың әнисе татар хатыны булган. Өммегөлсем исемле. Ә әтисе казакъ булган. Өммегөлсем апа Тукаевларда яшәгән булган. Акмуллага 5 яшь тулгач, Өммегөлсем апаның ире үлгән. Шуннан Өммегөлсем апаны Миякә районы Туксанбай авылына бер башкорт иренә кияүгә биргәннәр. Үзе белән Акмулланы да алып киткән. Ана шунда ничәдер яшькә кадәр тәрбияләнгән. Шуннан кимсетүләргә түзәлмичә, Акмулла өеннән чыгып киткән.

Мин белгән чакта 3 фонтан бар иде, аны фантал дип йөртә иделәр. Аларның башы куполообразный тимер белән ябылган иде. Тимер ручка буладыр иде. Без элек гел шунда су алырга килә идек. Ул суның чисталыгы. Шуннан әби-бабалар әйтә торган иделәр: «Стәрлебашның суын эчкән кеше, обязательно икенчегә әйләнеп кайта». Тау янында чишмә бар. Аны чишмә башы дип йөртәләр. Минем бабай әйтә торган иде: «Шушы фонтаннарга агач трубалар эшләп үткәргәннәр. Бер грамм черемичә ул трубалар җир астыннан чыкмый». Менә нинди агачтан эшләткәннәр аны, ничек эшләгәннәр? Менә шушы Тукаевлар заманында әтием сөйлидер иде.

Минем әнием сөйли иде. Граждан(нар) сугышлары вакытын сөйли иде. То килеп керәләр иде аклар, то кызыллар. Аклар килеп керсәләр, кыз балаларны базга яшерәләр иде, ди. Утыра идек базда, күренмичә, куркып. Стәрлебаштан чыгып китсәләр, баздан чыгадыр идек, ди. Бигрәк тә комсомолец исемен йөреткәннәрне әзерлекләгәннәр. Блюхер отрядлары да моннан үткән, тау башларыннан үткән. Окоплары әле дә сакланып калган. Өй нигезләре ясаганда, шуннан ком алырга йөргәннәр. Кайбер вакыт аннан оружиялар да чыккан, ди.

*Стәрлебаш авылында*
*Галиева Зәйтүнә Рәхмәтулла кызыннан (1945 елгы)*
*Г. Яхшисарова язып алды*

## УЕННАР, АУЛАК ӨЙЛӘР

Клубка барганда, кайтканда гармуннар белән ерлап кайта идек. Атна саен вечер, шунда **«Чүпләлә»**не уйнау. Ике кеше капма-каршы басалар да, моннан тагы икесе шунда чыгып әйләнә. Тагы икенчесе (чыгып) тотынышып җитәкләшәр дә монда ике кеше басып тора, уртадан чыгалар да әйләнәләр, тагы басалар, хәзер монда икенчеләре шулай тотынышып чыгалар да (гармун уйнап тора) шуннан әйләнеп тагы басалар. Бию көенә, гармунга.

* * *

Аулак өйләрдә **«Тычкан салышлы»** уйнайдырыек. Тычкан салып чыгалар ие дә:

– Тычкан кемдә? – дип әйтәләрие.

Бер егет белән бер кыз дуслашып йөргән чыгып китәләр ие, сөйләшеп керәләр ие.

**Урнашлар** пешерә торганыек сугыштан соңгы елларда. Һәркайсыбыз берәр әйбер алып килә дә, шунда пешереп кызык итеп ашый торганыек. Эчү фәлән юк инде анда. 14–15 яшьлек вакытларыбыз. Урнаш пешерә торганыек бәйрәмнәрдә җыелышып. Кайсыбыз ит алып, кайсыбыз бәрәңге, аулак өй булса шунда. Бергәләп егетләр-кызлар тәмне ашлар пешереп ашый торганыек – ул урнаш дип атала торганые. Ул борынгыдан калган. Без кул эше эшли идек. Без бәләкәйдән кул эше эшләдек, авыл кызлары. Шәлләргә өйрәндек бәләкәйдән, наскилар бәйләргә.

*Куганакбаш авылында*
*Ишбулдина Мөзәлифә Корбангали кызыннан (1940 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### «Черталы»

«Черталы» уйный тораныек сикереп. Сызасың – өй саласың. Шакмаклап. Таш кая төшә. Таш туры төшсә, әйбәт була инде. Кыек төшсә, дурак буласың.

### «Бастырышлы»

Бастырыша идек. Син йөгерәсең, ул килеп тота. Сугасың да – йөгерәсең.

## «Туплы»

Бәләкәй туп бар иде. Шуның белән уйный идек. Туп белән бәрә-бәрә уйныйдырыек, кара-каршы торып.

Ак тирәк, күк тирәк!
Сездән безгә кем кирәк?

Тотынасың да. Теге якта да тотынып торалар. Егетләр дә кызлар да бар анда.

Ак тирәк, күк тирәк!
Сездән безгә кем кирәк?

Шуннан исеме белән чакырасың. Ул кеше йөгереп бара.

## Аулагый

Берсе кунакка китә дә шунда егетләр килә, кызлар килә аулак өйгә. Башта кызлар килә. Шуннан бераз торгач, егетләр килә, егетләрне кертмиләр.

Бер өйгә кызлар җыела. Шунда урын ашы пешерәләр. Кем нәрсә апкилә. Егетләр килә, шуннан керәләр. Кызлар бәйләм бәйлиләр, оеклар бәйлиләр, җон (йон) тетәләр.

Бас-бас эзенә, энә күзенә,
Бер стакан кирәк була
Аның үзенә генә.

*Куганакбаш авылында*
*Ягафарова Рәхилә Низаметдин кызыннан (1936 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## «Такталы»

Бер дистә чыбыкны нитәсең дә Такта астында ние бар. Бер дистә чыбык тора инде. Сикереп тактаны нитә дә, кача. Тегене җыеп ниткәнче, качып бетәләр бит инде. Хәзер табарга тиеш качканны. Качкан кешеләрне бу эзли бит инде. Берәү тегендә качып кына килә дә баса, теге тагы җыя.

## «Чебенне»

Таяк җирдә, казап куелган. Чыбыкны киртләп китәсең дә, башына эленеп тора. Аннары таяк белә бәрәсең, теге оча бит инде

5–6 метрдан (бәрәсең. – *И.Я.*) Теге оча бит инде, тегене йөгереп барып бәреп очырган кеше таякның кырына килеп баса. Чебеннең кырына килеп баса. Теге алып килеп өлгерсә өлгерә инде. Өлгермәсә тагы бер бәрә. Бәргән кеше урап килеп баса. Башта бергә торалар (берсе круг ясый, тегесе чебенне алып килеп куярга тиеш. – *И.Я.*). Чебенне алып килә торганы постоянный дежурный була инде. Шуннан алай-болай соңга калып таягын алып-килеп ниткәнче, монда килеп басып өлгермәсә, «Чебен» дип тегене нитеп куя икән,теге кеше көтүче булып кала.

### «Кыек баш»

«Кыек баш» дидер идек бит инде. Бер 25–30 см таяк, күбесенчә юкәдән була инде ул, җиңгел. Шуның ике башы да монайлай кыелган. Аның чертасы бар, шунда гына тора, җирдә. Шакмак эчендә тора ул. Чыгып торган кыек башына сугып очырасың. Бу башы да – юынган кыя, бу башы да – юынган кыя. Оста кеше суга да суккан көенә күтәрелеп китә – бәреп җибәрә. Күпмегә ерак китә инде. Ерак китсә, алып килүчегә кыенрак була. Аның границасы бар. Суккан кеше йөгерә дә әйләнеп (круг ясап) йөгереп килә кайда төшкән шул кыекбашы. Кем беренче килеп өлгерә (берсе – таяк артыннан йөгерә, берсе – әйләнеп килә. – *И.Я.*).

### «Клюк»

Примерно бер 20 см, ике башы да тигез. Утыра, үзенә күрә площадкасы була. Клюклар 5–7 була. Монаулай нитәләр колодец, ул шулай утыра колодец итеп ясап куйган. Әнә шул колодецны нитеп вич очырсаң – оча, нитмәсәң, – площадкада таралып кына ята. Таралып ятканын сугып бәреп очырырга кирәк. Шул черта эченнән чыгарырга кирәк, бик зур түгел инде ул, зур түгел, 50×50 яисә 40×40. Башка фигуралары да була.

«Пушка»сы – әнә шул клюк инде ул.

### Аулак өй

Сугыш вакытында барыр урын юк. Кызлар бер йортка эш белән җыелып утыра. Элек шәл бәйлиләр ие. Кәҗә үстерәләр,

мамык була. Элек кенә ул бәйләп – китеп саталар ие. Себер ягына китеп тимер юл белән, салкынгарак китеп тегеләр сата инде.

### «Тату»лы уены

Бер пар була. Монда көтүче йөри:

– Сез татумы? – дип сорый, килә дә пардан.

Я кыз, я егет әйтергә может, тату түгел.

– Кемне сорыйсың?

– Мин шуны сорыйм, ди.

Шуннан теге көтүче барып китә инде. Егет кызны бирсә, китә. Бирмим дисә, егеткә штраф.

– Ничәне?

Аннан каеш белә(н) кулга сугалар. Анда безнең берәү бар ие. Каешның плашмясын түгел, кабыргасы белә(н) китерергә тырышадырые, теге авырттыра бит инде. Аулагыйда «наказ» бирелә инде. Теге пар тышка чыгып китәләр. Тышка чыгып икәү сөйләшергә әйбәт була инде.

*Турмай авылында*
*Курманаев Динияр (Минияр) Биктимер улыннан (1931 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### «Читән үрү»

«Таң атканда»ны матур итеп ерлап «читән» үрәдериек.

Таң, таң ата, Чулпан калка,
Чулпан таңны уята.
Чулпан таңнарны уята,
Күңлем сезне уйлата.

Кулъяулыгым төшеп калды
Кесәмнән яулык белән.
Гомер үтә димәс ием,
Яшәсәм сезнең белән.

Таң атканны шуннан беләм –
Таңдагы аклык белән.
Гомрем үтә димәс ием,
Яшәсәм сезнең белән.

Пар аккошлар күл эчендә
Баласын коендыра.
Киләчәкләр берни түгел,
Үткәннәр сагындыра.

Китәм инде, китәм инде,
Китәм инде, каласың.
Мин киткәчтен кемнәр сөяр
Син сандугач баласын.

Бер уннап кыз чыгабыз да егетләр белән ерлыйбыз да читәнне үрәбез: бер кешенең яланбашына кулны сала торабыз, икенчесе килә, сала. Бер 10 кеше шулай култыклашыбыз. Читән үрелеп беткәч, һәр кеше үз пары белән бии.

### «Кыз урлаш»

«Кыз урлаш» буладырые инде. Утларны сүндерәләр дә кызлар яшеренәләр, егетләр кызларны урлыйлар, табалар да алып чыгып китәләр инде. Күтәреп апчыгып китәләр. Күңел ачу уены, аулакта. Кем нинди кызны таба – алып чыгып китә инде, шул. Кызык итеп.

*Яңгырчы авылында*
*Тимербакова Мөнирә Миңнегали кызыннан (1944 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### «Клюк»

Утыртып куясың да берәү көтүче була бит инде. Таяк белән бәрәсең дә оча. Теге көтүче дигәнебез йөгереп барып китереп утырта, син шул урында торып каласың. Ә таягың тимәсә, ул таякны ала да шул нигә ыргыта, пружинага. Синең таяк тиде икән, көтүче булып мин уйныйм бит инде. Тегеләр суга, мин пружина артыннан йөгерәм.

*Яңгырчы авылында*
*Назаров Рәфис Шәрифҗан улыннан (1968 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### «Сукыр тәкә» уены

Аулак өйдә кызлар, егетләр җыела идек.
Сукыр тәкәле уйный идек.

Арадан берәүнең күзен сөлге яки яулык белән томалап бәйлиләр дә, аны икенче берәү җитәкләп, ишек бавын тоттырып:

Сукыр агай, көтеп тор,
Ишек бавын тотып тор.
Ишек бавын нык тот,
Солдатларың кырып тот! –

дип, аркасына сугып китә. «Сукыр тәкә» аларны кулы белән кармап эзләргә тотына. Аны адаштыру өчен, төрле яктан аркасына суккалап әйтәләр:

Әби коймак пешерә,
Бабай кабык төшерә,
Сыерлары бакыра,
Бозаукаен чакыра.
Үгезләре үкерә,
Кәҗәләре сикерә,
Дөбер-дөбер, дөп тә дөп,
Тиир, тиир, ти дә тип!

Төрле яктан төрле хайван тавышлары белән кычкырып яки аяк тибеп, аны адаштырырга тырышалар. «Сукыр тәкә» аларны тотарга тырыша. Ул билгеләнгән чиктән чыга башласа, «Суга төшәсең!» – дип кычкыралар. Ул кемне тотып алса, шуның күзен бәйләп «сукыр тәкә» ясыйлар.

### «Клюк» уены

Уенчылар белән сөйләшәсең дә, адымнар санап, сызык сызып куясың. Сул якка клюкны утырта торган җирдә бер тигез таш куела да, шунда примерно бер 15 сантиметр озынлыктагы, 4 сантиметр юанлыктагы. Тигез генә утыртыла бу агач. Көтүче була. Шул бәрә иде теге агачка. Командадагы кеше йөгереп барып ала да утыртырга тиеш моны таш өстенә. Утыртып өлгерсә, җиңә, өлгермәсә, шул көтүче булып кала или уеннан чыга.

### Чебенле уйнау

Чебенле уенында, җирне казып агачны кагып куясың да, киртәләп, тегенең өстенә таш куясың. Сызык артында торып

бәрергә кирәк теге ташны. Көтүче кеше, барып йөгереп алып, ууу, дип, алып килергә тиеш

*Гөлем авылында*
*Шәймәрданов Риф Хәйбрахман улыннан (1935 елгы)*
*Г. Яхшисарова язып алды*

**«Клюк»**

Шакмак монауның озынныгы, түгәрәк агачны утырталар бит берничә метрга бер, 10 м арага. Мин тотып торам, миннән ары теге клюк дигән агач утыртып куялар да шуннан кем шуны таяк белән ега бәреп ега – шул җиңә. Аны бәк сирәк кеше ега ул аны – шакмакны. Клёка диләр инде аны.

*Хәлекәй авылында*
*Шәрипов Гали Шаһи улыннан (1931 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

**«Тату»**

Безнең бэк шәп «Тату» дигән уен барые. Парлап утырасың. Менә шушылай – бер кыз, бер малай. Бер көтүче була. Аның кулында кашык. Агач кашык була бит инде. Утны сүндерәсең, теге йөри бит инде:

– Татумы?

– Тату.

– Татумы?

– Түгел.

Егеттән сорый инде:

– Кем кирәк?

Кызга исеме белән әйтә инде. Икенче кеше белән утыра бит. Шул кыз кирәк. Бара да:

– Ризамы?

– Юк.

– Ничәне бирергә?

Кашык белән, кулын тотасың да инде. Кашык белән шушында сугасың. Егеттән генә сорый. Анарга риза булмаса.

– Ризамы?

– Юк.

Бирмәгәч тагы сугасың.

Риза булса, бирә бит.

Ул дәрәҗәгә барып җитсә, берәү бит, теге кызга ушы китә тегенең. Монарга бирмиләр. Шуннан теге кашык белән генә сукмый, кружка белән шулай иттереп. Шуның учына кан сава.

*Карагош авылында*
*Шәрипов Мөхәммәтзакир Мөхсин улыннан (1926 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Яшь чакта безгә гел аулак өйләр була иде. Әниләр Мукшыдан кайтмады, эшләде. Безнең үзебездә гел аулак өй булды. Сеңелләремне карадым. Аулак өйдә әниләр Мукшыдан алып кайткан пәгиләрне[1] эрләдек. Шәлләр бәйли идек. Ул вакытта лампа юк иде. Сукыр лампа белән генә кич утыра идек. Ул лампага салырга крачин[2] юк иде. Әниләрдән урлап, авызга кабабыз да крачинны, үзебезнең лампага –пххх, дип сукыр лампага бушата идек.

*Карагош авылында*
*Туктарова Латыйфа Фазлыйәхмәт кызыннан (1930 елгы)*
*Г. Яхшисарова язып алды*

«Чүрәкә», «Пограничник», «Чебенне», «Лапты», «Триножка». Уеннар күп ие. Мин гармунны булгач, олыраклар кич апчыга. Анда «Наза»лы, тауга менеп уеннар бар ие.

### «Чебенне»

Бер багана кадап куясың да инде, шуңа киртләп чебен куела. Инде, агачтан ясап куясың. Сага белә бәрәсең. Чебен оча бит инде агач тигәч. Шул чебен төбендә торган кеше барып алып, син йөгереп барып сагаларга тиеш, шул вакытта чертада син эләксәң, син каласың төптә.

### «Тринажка»

**«Лапта»** кебек. Лаптада йөгереп, урап килергә кирәк шул вахытта, туп белә бәреп бит инде, кул алышына анда, ә

[1] Пәги – киндер

[2] Крачин – керосин

«Тринажка»да берәү подавать итә, берәү суга инде. Тегендәге тоткан кеше, тупны тотса, үзе килә сугарга. Теге китә тегендә. Ыргыткан кеше килә подавать итәргә. Таякның озынлыгы 50–70 см буладырые.

*Яшерган авылында*
*Мухтаруллин Һидиятулла Ибәтулла улыннан (1942 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Аулак өйләрдә йөрдек. Каешка суктыралар бит кулны. Монаулай утырабыз. Тауларга чыгадырыек, матур итеп шушындый.

«Наза»лы уйныйдырыек, сөйләшәбез, хәзер җегетләр килмәсә, нигә килмиләр икән, дип тәрәз төпләренә тоз салабыз, килсәләр үзләрен ишектән кертмәгән булабыз бит инде. Шәл бәйлибез.

*Тәтер-Арслан авылында*
*Мөхәммәтшина Әнвәрә Хәмәтһади кызыннан (1941 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### «Черта»лы

4 шакмаклап эшләп, 6 шакмаклап эшләп, шунда «Черта»лы уйный торганыек. Ул әйберне ыргытадырыек та, артыннан үзебез сыңар аяк белән барабыз бит инде, сикереп. Шуңа хәтле барып алабыз сыңар аяк белән.

*Тәтер-Арслан авылында*
*Тәминдарова Фатыйма Бакыйр кызыннан (1931)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Малай вакытта **«Лапта»** уйныйдырыек инде. Аннан соң таяклар утыртып, палка белән бәреп – исемнәрен дә белмим хәзер.

**«Кәшәкә»** – хоккей була бит инде ул.

### «Шәкшәкәр»

Бүрекләрне өеп куядырыек та инде, кем ничек, күпме сикерәлә, бүрекне эләктермичә сикерергә кирәк. Берәүне утыртабыз яланда, тышта, җир кипкәч. Чүгәләп утыра да, башына кемнең фуражка, кемнең бүрек өябез дә шуннан сикерәбез. Кем бүрекне эләктермичә сикерә, отты дигән сүз бит инде.

* * *

Монауның кебек йомры кругларны утыртып куябыз да, палочка инде куябыз да бәрәбез бит инде. Шуннан туп белән дә тәгәрәтеп тегеләрне егабыз бит инде.

### «Кузыр»лы

Олы мал тоягыннан чыга бит берсе бәләкәй, берсе зур шарнирлар – кузыр дип йөрибез аны. Шуның белән уйныйдырыек. Анда була бит инде берсе бәләкәй, берсе зур. Шуның бәләкәен куялар да күмә биреп, чак кына күрсәтеп калып, теге зурысы белә(н) бәреп чыгарырга кирәк инде. Ничәдер адымнан арырак җирдә тезелеп тора. Уйныйбыз бит инде кар сулары эри башлагачтан, шул вакытта, җәй көне уйналмый инде ул. Эре малныкы, сарыкныкы ярамый, бәләкәй ул. Кузырлы дияләрие инде. Кузырлы уйныйбыз дип уйныйдырыек. Зурысы белән бәрәбез. Бәләкәе – «бәбер» дип атала, зурысы – «сага» дип, шул тоякның шарниреының. Аның бар «юкә», «имән» дигәне. Основном зурысы инде. Үгезнеке – «юкә» була, тананыкы – «имән» була. Аерыла, төбендә бер бунак бар, тана малныкы кубып төшә, кубып төшмәсен өчен, кадак тапсак, кадак белән кагабыз да уртасыннан бу якка кәкрәйтеп куябыз. Шуннан кургаш тапсак, эчен чокып кургаш куябыз, тегене бәреп чыгарырга авырырак булсын. Ансын инде урлап кына куябыз, кем ничек куяла, чтобы күренмәсен. Хәзер бәрәбез, чыгып оча теге кургашлы булса, шуннан шикләнгәнне сизсәләр, алып карыйлар бит инде. Ә тишек булса – күренә. Тишекне бәләкәй генә тишеп, нәзек кенә итеп куярга тырышабыз. Шуннан сылап та карыйсың инде аны, куба.

Кургашны табарга кирәк бит, юк бит. Әгәр дә теге хәзер синең шул кургашлы белә(н) чыгарып отканыңны сизсәләр, исәпләмиләр. Чиратлап инде.

* * *

Акча тапсак, **«Акчалы»** уйныйдырыек инде. Стинәгә бәрәбез дә. Орел ягы белә(н) төшсә – аласың, реш ягы белә(н) төшсә – отыласың, акчаның цифрлы ягы белә(н). Арюл ягы белә(н) – отасың.

* * *

Туп белән бәреп. Круглый палкадан кисеп, шундый палочкалар була инде. Озынлыгы булса бер 10–12 см, 15 см. Аның стандарт размеры булмагандыр да ул. Ничәне тезәсең – аны санап тормыйсың инде, ничәне бар. Бишәүме, унаумы була. Туп – теге яз көне коела бит малның йоннары, шуларны әвәләп алабыз, яисә эченә чүпрәк тегәбез дә инде. Җирдән тәгәрәтеп җибәрәсең тезелгән таякларга. Эрзинкә туп юк бит инде, сирәк эләгә.

* * *

«Качкалаклы» уйныйбыз.

**Чана. Чаңгы. Кәңки**

Монанда су аша гына ат сарае. Шуннан чананы алып, тегендей бәләкәй чана һәркемдә юк. Авылда санаулы гына ие бит бәләкәй чаналар.

Чаңгы урынына кабыктан ясап шуайек инде, кабык тапсак. Юкәнең кабыгы калынрак, картрак юкәнең кабыгын куптарабыз да, шуннан теге чабата ясый торган ягы йомшак була бит инде, өске ягы каты була. Шуны пычак белән генә ярабыз да, шуның быяктагы юкәсен чаңгы бавы кебек иттереп ныгытабыз да шуңа киеп шуабыз.

Агач тапсак, чаңгыны ясыйдырыек инде, башын былай юынабыз, юкартабыз шунда әтмәләп, шугалыйдырыек инде.

Агачтан бүкәнне юынабыз да, шуннан тимерчыбык тапсак, уртасына тимерчыбыкны менә бу көйгә, теге агачны бит инде юнабыз, тимерчыбыкны табанына китерәбез дә, тимерчыбык белән кагып куеп, шуның белә шуайек, кәңки дип атыйдырыек. Чабата астына куядырыек – күтәртмә бит инде.

*Бакый авылында*
*Гафиев Зөфәр Габдрахман улыннан (1938 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

«Тычкан салышлы», «Фантиклы» – шул уеннар бит инде.
– Кемдә тычкан сикереп чык,
Яңындагын үбеп чык.

Фантик алсалар – нинди наказание бирергә монарга. Үпсен, ерласын, биесен.

*Стәрлебаш авылында*
*Шәмсетдинова Зөбәрҗәт Хаҗи кызыннан (1931 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

**«Чируклы»**. Багана утырта, баганага бәрә.

**«Городки»** уйныйдырыек. Йолдыз ясап бәрәдерие, пушка ясап.

*Стәрлебаш авылында*
*Дәүләтшин Альберт Рәхми улыннан (1944 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

**«Чебенне».** Чебен төшеп китә бит инде.

**«Гузна».** Малның сөяк, тояк янында була сөяк шундый.

**«Акчалы»**.

*Стәрлебаш авылында Шәмсетдинов*
*Мөхәммәтфарих Мөхәммәтгариф улыннан (1932 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## ӘКИЯТЛӘР

Борын-борын заманда әби белән бабай булган, ди. Алар бер ятим кыз алып үстергәннәр, үзләренең кызлары да булган. Үзләренең кызлары бик иркә булган, бер дә тыңламаган. Шуннан хәзер ул ике баланы җиләккә җибәргәннәр. Хәзер җиләккә баргач, болар адашканнар, җиләк җыйганда берсе-берсеннән аерылышып. Шуннан хәзер бу бала янына хайван кебек, төлке кебек бер әйбер килеп чыккан, бу ятим балага. Шуннан нәрсәдер ишарәләгән кебек, бу ятим бала кайта белми бит инде, адашканнар урман эченә кереп. Шуннан шушы төлке кебек бер җәнлек моны килә дә икән, ялап, әйдә дигән кебек, юл күрсәтеп алып барган. Шуннан хәзер бу юл күрсәтеп алып барган да үзләренең килгән юлына алып чыккан. Шушы балага әти-әниләрен тыңлаган өчен менә шушы хайванкай аны юлына төшереп кайтарып җибәргән. Ә теге үзләренең бик капризный кызлары бик иттеккән. Адашып кайталмаган. Кешене тыңламагач, менә Аллаһы Тәгалә юл да күрсәтмәгән, адаштырган. Шуннан хәзер

берне урманда кунган. Шуннан әти-әниләре эзләргә чыккан. Икенче көнне генә... Теге бала арыган-сусаган, аптыраган. Шуннан икенче көнне генә табып авылга алып кайтканнар. Шуннан икесен дә бергә утыртып, теге тыңламаган кызга әйтткәннәр:

– Менә хәзер, син кешеләрне тыңла. Менә иптәшең тыңлагач, аны, фирештә төлке булып күренеп, фирештә апкайтып җиткерде. Менә сине дә шулай итәр ие. Син тыңламаганга Аллаһы Тәгалә сиңа шушы җәзаны күрсәтте. Шуннан теге бала акылга утырып, әйбәтләнеп киткән. Менә шул.

*Куганакбаш авылында Ишбулдина*
*Мөзәлифә Корбангали кызыннан (1940 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Бармагын Шүрәле кыстырган шул. Бер малай урман кисәргә барган да, Шүрәле моны кытыкларга килә икән. Шуннан агачны ярган да инде, юан агачны, монанда бармагыңны куеп кына тор әле, дигән. Шүрәле бармагын кыстырган да Шүрәле кычкыра, ди. «Былтыр кысты» кычкыра, ди. Шуннан икенче кеше килгән дә: «Бармагыңны кем кысты?» – дип сораган. «Былтыр кысты», – дигән. «Минем исемем Былтыр булыр», – дигән егет.

*Куганакбаш авылында*
*Ягафарова Рәхилә Низаметдин кызыннан (1936 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

**Шүрәле**

Бик матур бер айлы кичтә
Бу авылның бер егет
Киткән урманга утынга,
Ялгызы бер ат җигеп.
Тиз барып еткән егет,
Эшкә тотынган баргач ук,
Кисә башлаган утынны
Балта белә(н) тук та тук!

Теге ниткән инде, хәл җыярга туктаган.

Каранып торса тирә-ягына,
Ниндидер ят күрә инде егет.

Борыны кәп-кәкре – бөгелгәндер
Тәмам кармак кеби;
Төз түгел куллар-аяклар –
Ботак тармагы кеби.
Бик озак торгач карашып,
Күзгә күзне нык терәп,
Эндәшә батыр утынчы
«Сезгә миннән ни кирәк?»
Ялгыз кешеләр күрсәм
«Гадәтем – кытыклап үтерәм.
Мин әле сине күргәч,
Шатлыгымнан үкерәм», –

дип, шуннан тегенең хәйләсен табып, ана ярык башыннан суккалыйдыр ул.

Ярар үтерерсең, ди егет тә,
Бер пыжганмый егет булмый.
Менә бүрәнәнең бер очында
Бер ачылган ярыгы,
Шул җиреннән нык кына син
Тот, эй урман сарыгы!
Яп-ялангач, нәп-нәзек,
Ләкин кеше төсле үзе;
Урта бармак буйлыгы бар
Маңгаенда мөгезе.

Тегене күндерә тотарга. Теге хәзер суккалый. Монда чөй кагып куйган. Балта белән суккалыйдыр, чөйне әле бер якка, әле икенче якка – очырырга инде.

Суга торгач, очты-китте чөе шалт итеп,
Шүрәленең бармагы калды-кысылды шап итеп.

Теге чөе чыгып киткәч, моның кулы кысылып кала. Эй бу кычкыра:

– Ычкындырчы, егет, нәселеңә түгел ыруыңа тимәм, – дип ялына, тибрәнә дә йолкына.

Бичара акылыннан шаша.

Шул вакытта яшь егет өйгә китәргә маташа. Иртәгәсен Шүрәлеләр килгәч әйтермен «Былтыр кысты», диеп. «Бу егет абзаң булыр бик белеп тор син». Иртәгәсен һаман акыра. Шүрәлеләр бу фәкыйрьне тиргиләр: син җүләрсең, син котырган, син тилергәнсең, диләр.

Әй җүләр! кысканга – былтыр
Кычкыралар мени бу ел?

*Карагош авылында*
*Табаева Әминә Мөхсин кызыннан (1930 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

* * *

Бер егет белән кыз булган. Алар өйләнешергә тырышканнар. Өйләнешә алмыйча, берсен-берсе яратышып йөрегәннәр. Шуннан теге кыз сарайга кергән. Ул сарайга егетне кертмиләр. Егет кыз янына энә булып очып кергән. Шуннан икәү очып чыгып киткәннәр. Теге кызны атасы куа килгән. Кыз чәчкәгә әйләнеп качып кала. Шуннан тагын куып җиткәннәр. Аннары егет суга әйләнә, кыз балыкка. Шулай итеп, аталарыннан качып калалар.

* * *

Борын-борын заманда, яшәгән ди әби белән бабай. Булган ди бер сандык. Сандык эчендә тагын сандык. Аның эчендә тагын сандык.

*Карагош авылында*
*Туктарова Зөлфә Шәмсетдин кызынан (1938 елгы)*
*Г. Яхшисарова язып алды*

* * *

Безнең яттан әйтә иде. Сәйфелмөлек дигән китап. Шушы калынныгы китап. Шуны үз башы белә әйтә.

Сәйфелмөлек төш күрә. Төшендә күргән кызга гашыйк булып эзләп чыга, патша малае була. Эзләп чыга, әллә 3000 әллә 4000 кеше белә. Азакы вакытны бер иптәше генә кала, вич кырылып бетәләр. Диңгездә йөри торган корабльләр юк, агачтанмы, нидәнме камыштан көймә ясыйлар, чыгалар анда каргалар ул вакытны кибән зурлыгы икән. Шулай йөри-йөри мының бер иптше кала. Аны да аждаһалар йоталар икән, кулында ни була –

йөзек, оҗмахтан чыккан Сөләйман пәйгамбәрнең оҗмахтан чыккан йөзеге була, аны бернәрсә дә эшләтә алмый бер кеше дә, бер хайван да икән. Шулай итеп, ул вакыт дию пәриләре кызлар урлаганнар бит. Моның Бәдигылҗамал дигән кыз. Аны син тапкан, ул сиңа бармый, ди. Төштә күргәнне эзләве рәхәт мени. Ул уттан яралган, ди. Ә бу бит Сөләйман пәйгамбәр, Сәйфелмөлек бит ул җирдән яралган, безнең кебек җир кешесе.

(Ул озын инде.)

Бәдигылҗамал белән күрше иптәше тышка чыгарга чыгалар, комганнары да була.Тышка чыгып торган ердән Бәдигылҗамалны урлар иде уттан яралган, дию пәрие ала да китә иптәшен. Алып бара да мендәр астына бер китап куя да тегеләр кайтканчы йоклый икән. Йоклата торган китап. Шунда барып чыгып Сәйфелмөлек: «И, хәзер дию пәрие кайта, ул кеше исеннән белә, монда ничек килеп чыктың?» – ди. Йөзеген күрсәтә, йөзек бар кулында, оҗмахтан чыккан, бу Бәдигыҗамалның иптәше. Шуннан согыдан ул аны таба. Барыбер Сәйфелмөлекне күпмедер торгач урлыйлар теге дию пәриләре, урман, бер почмактагы диңгез янында бер түгәрәк кое кебек су, үзе нык тирән, әйләнеп кенә тора, акмый, шунда сандык бар, шул сандык эчендә бу дию пәриләренең күгәрчен … җаны. Шуны Сөләйман пәйгамбәрнең, оҗмахның йөзеге белә, болай сызса, сандык килә дә чыга, ди. Эчен ачсалар, күгәрчен. Күгәрченне бу суя да, шул сандыкка сала да, почмактагы суга ебәрә. Шуннан ары берничә ел үткәч, Сәйфелмөлекне табып, шул сандыкка салып җибәрәләр. Аннан аны пәйгамбәр көчләре белә(н) алар алгачтын, ул инде күпме торадыр, ул анда бик беткән була бит, яны гына була. Мына дию пәриләре гөжләп шунда, 12 башлылары гөжләп килеп төшәләр икән. Сандыкта яннары икән, шунда икән, үзләре белә түгел, аерылып икән аларның яннары.

Сәйфелмөлеккә шул хәтле гаскәр бирәмени. Әтисе патша булганга биреп чыгара бит аны.

*Өч-Әсән авылында*
*Гафиятуллина Мөбарәк Муллагали кызыннан (1930 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

* * *

Әни сөйләгәнне сөйлим:

Борын-борын заманда булган ди әби белән бабай, аларның булган бит инде уллары, алар бик чибәр булган. Бай патша кызына гашыйк булып, аңа өйләнгән инде. Аның белән яшиләр икән инде. Теге кызга күз тотып йөргән кешеләр мыны үтергәннәр. Үтергәч салып агызып ебәрәләр. Шаманнар табып алып тегеңә тере су салып терелткәннәр, дүрткә бүленгән булган ул. Шуннан соң ул бер байга эшкә урнашкан. Шунда яхшы хезмәт иткән. Бай:

– Мин сиңа яхшы хезмәтең өчен бер кылыч бирермен, бер ат бирермен, ди. Теге әби алдан әйткән булган тегенә: «Менә ул сиңа ат тәкъдим итәр, иң аламасын ал, кылыч арасыннан тутыгып беткәнен, читтә торганын ал».

Эх, тегендә таза-таза, матур атлар бар икән, бу читтә торган бер атны алган, монауны бир миңа, дип.

– Нишләп, яхшы атлар бар, моның белән ярты юлга да җитәлмисең. Яра(р), яхшы хезмәт иттең, ал, ди.

Кылычка җиткәч, тегендә ялтырап (яткан) алтын кылычлар бар. Бу тутыгып беткән кырыйда яткан кылычны ала. Яхшы хезмәт иттең, дип бирә. Кайтырга чыкса, дөл-дөл оча торган ат булган – очып кайтып киткән.

Тегеңә әйткән киткәндә: «Кылыч белән селтәсәң, 40 метрдан кисә.

Бу кайткач, моның кайтканын ишеткәч, тегеләр уже, патша кияве булгач, гаскәр ебәрә моңа каршы. Бу аркылы-торкылы гына кылычны болгагач, тегеләр вич киселеп, бу җиңә. Хатынын ала бит яңадан. Яши башлагач, качып калган була, үтермәгән кияү. Бу хатынга аңнатырга, син аның кылычын урлап бир, дип. Теге иргә кылычын урлап бирә дә, моны үтерәләр тагы. Теге әби моны тере су белән терелтә тагын. Терелткәч, кайта, тегеләр күл буенда йөри. Ире белән йөргәндә, бу агач булып үсә, биек агач булып үсә. Тегенең алмалары кызыл, теге ир алып ашарга әйтә дә. Теге кызда сихер ние булган күрәсең: «Ашама, бу алмагач – элекке ире, үләсең. Теге агачны кистереп ягалар. Агачның

бер йомычкасы күлгә төшкән була, бу үрдәк булып китеп, теге үрдәкне, охотага чыккач, теге ир ата да, бу чалкан ятып, тыпырчынып ята инде. Бу төшеп алыйм дисә, теге яңадан егеткә әйләнеп, тегене батырып үтереп, бу хатыны янына кайткан икән, дип сөйлидерие.

*Яшерган авылында*
*Мухтаруллин Һидиятулла Ибәтулла улыннан (1942 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

**Үгәй кыз**

Яшәгәннәр бабай, әби. Бабайның үз кызы булган, әбинең үз кызы булган. Обижать ителгән бабайның кызы. Бу кыз бик оста булган, бөтенесен дә эшләгән. Ике кыз берсенәберсе көннәшкәннәр бит инде. Шуннан соң бу үгәй әни бабайга әйткән:

– Үз кызың миңа кирәкми, урманга илтеп ташла. Бабай кая барсын, тыңнаган, урманга илткән.

– Кызым, балам, син җиләк җыя тор. Килеп җитеп, сине апкитәрмен.

Шуннан кыз чиләген тутырган.

Бабай:

– Мин утын кисәм, шуны тыңна, утын таягы шакылдар, шул тавыш беткәч, мин сине килеп алырмын.

Кыз тыңнап карый, утын тавышы чыкмый. Шуннан ары сугыла, бире сугыла, елый башлый. Шуннан йөри торгач, бер өйгә барып керә бу. Анда убырлы карчык яшәгән булган. Бу убырлы карчык кызны сынап, төрле эш эшләргә кушып караган. Кыз эшләгән, тыңнаган, бөтенесен дә әйбәт итеп эшләп күрсәткән. Шуннан бу кызга теге убырлы карчык: «Мине мунча керт!» – дигән. «Ничек итеп кертим, әби, ничек итеп юындырыйм?» – дигәч. «Себеркенең сабы белән чап мине», – дигән. Кыз алай итмәгән, яфраклы ягы белән әйбәтләп юындырып, чабып апчыккан. Кызга күп бүләкләр китереп, кайтарып җибәргән. Чәчен карарга кушкан бит инде. Чәче тулы алтын, көмеш, ди. Бу караган да биергә кушкан азактан. Биесә, моннан бернинди

алтын да, бернәрсә дә төшмәгән. Бу саф йөрәкле намуслы кыз икән дип.

Үгәй кызы кайтканда өйдәге эт:

– Үлергә киткән түтекәй баеп килә лең-лең.

– Үлергә киткән түтекәй баеп килә лең-лең.

– Кит моннан, нәрсә сөйлисең, үлергә киткән үлеп кайтып килә, диң.

Сандыкны ачсалар, эче тулы алтын-көмеш.

Шуннан өенә кайткан күп бүләкләр белән. Шуннан теге үгәй әни үз кызын җибәргән.

Шуннан бабай хатынның кызын да апкиткән. Урманга барган. Бу, тыңнаусыз кыз булган инде. Теге йөри-йөри убырлы карчыкка барып кереп, убырлы карчык моңа эшләр кушкач, тегенәргә каршы эндәшеп, тыңнамыйча. Әби нәрсә кушса, тукмап аббарган. Себеркенең сабы белән чапкан, чәчендәге алтын-көмешләрне үзенә тутырган, биесә шылтыр-шылтыр коелган.

Үгәй әни кызыгып, үзенең кызын да җибәргән. Адаштырган, теге убырлы карчыкка барып ирешкән. Шулай иттереп, ярый, балам, сиңа да сандык.

Эт:

– Кайтып килә ләң-ләң, ди.

– Баеп кайтып килә дип әйт, дип этне тукмый икән әби.

Кайткачтын, и куанып, әнисе белән кызы байлык апкайтты дип ачып карасалар, эчендә елан чыккан да боларны чаккан, чагып үтергән. Шуннан бабай белә кызы торып калган икәү, байлык белән асыл итеп гомер иткәннәр инде.

*Яшерган авылында*
*Галләмова Фәния Абдулла кызыннан (1936 елгы),*
*Гобәйдуллина Флүрә Ибәтулла кызыннан (1946 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

**Алтын балык**

Борын-борын заманда, булган икән әби белән бабай. Бабай балыкчы булган. Шулай бервакыт бу алтын балык тотып кайта. Балык: «Мине суга җибәрегез, мин 3 төрле теләкләрегезне чын-

га ашырам», – дигән. Әби сораган инде. Башта зур йорт, аннары патшабикә булырга теләгән, аннары .... беткән, кире элекке хәлгә кайткан. Бабайны таягына таянып күрсә, әби улагы янында бөкерәеп утыра.

– Китте, бабай, бөтен әйбер дә китте, – дип әйтә, ди. Бабай:

– Китәр инде, нәфсең туймагач, – дигән.

*Яшерган авылында*
*Кашапова Гөлфани Сафиулла кызыннан (1937 елгы)*
*Г. Яхшисарова язып алды*

* * *

Борын-борын заманда бер әби белән бабай яшәгән ди. Аларның бер кызы белән бер малайлары булган. Боларның әниләре үлеп киткән дә, әтиләре икенче әни алган. Бик явыз, бик хәтәр кеше булган үги әнкәләре. Бер вакытны әтисенә бу балаларны урманга илтеп адаштырырга кушкан. Моны балалар ишетеп торганнар да, әниләренең көзгесе белән тарагын алып, ерак юлга чыкканнар. Моны күреп торган үги әнкә аларның артыннан куа чыккан. Ул аждаһа кыяфәтенә кергән дә балаларны бастыра башлаган. Балалар бу үги әнкәдән качып ерак юлга киткәннәр. Төрле каршылыкларга очраганнар. Үги әнкә куып кына тотыйм дигәндә, кыз алган да таракны юлга ыргыткан. Аның каршында куе урман барлыкка килгән. Бу үги әнкә куе урманны үтеп чыкканчы, балалар берникадәр юлны үткәннәр. Шуннан урманны кичкәннән соң артларына борылып карасалар, үги әнкәләре куып җитеп килә икән. Хәзер, артларына әйләнгәннәр дә, көзге ыргытканнар. Көзге ыргыткач, зур күл барлыкка килгән. Явыз әнкәләре бер як ярда, балалары икенче як ярда калган. Сорый икән балалардан: «Балалар, сезнең янга ничек итеп йөзеп чыгарга?» – дип. Балалар: «Бугазыңа бау бәйлә дә, очына таш бәйлә, һәм суга төш дигәннәр», – дигәннәр. Балалар әйткәнчә, бу суга төшкән. Һәм шул килеш суга төшеп киткән. Балалар яңадан әтиләренә әйләнеп кайтып, рәхәтләнеп гомер кичергәннәр.

*Тәтер-Арслан авылында*
*Макашева Гүзәлиядән (1960 елгы)*
*Г. Яхшисарова язып алды*

**Мәрьям әби сөйләгән әкият**

Бер бабай урманга барган икән. Урманнан шөшле тапкан да, кайда-кайда кадыйм дип, вич изүен ертып беткән. Кайткач әбисе: «Шөшлене изүгә кадамыйлар аны, билгә кыстыралар». Шуннан, икенче тапкыр энә тапкан. Энәне биленә кыстырган. Ул төшеп калган. Өченче барганда, көчек тапкан икән. Көчекне биленә кыстырган икән бабай. Теге көчек төшеп калмаган, үлгән. Кайткач әбисе: «Иии бабай, көчекне мах-мах дип чакырып алып кайталар», – дигән. Шуннан, бер җирдә пожар чыккан ди. Бабай шундагы кешеләрнең янына барган да: «Мах-мах», – дип чакыра икән. Кайткач, әби бабайны кыйнап җибәргән, әрли ди. «Эээй бабай, анда бит су сибәләр, алай чакырмыйлар», – дигән әби. Шуннан бер сарай яныннан китеп барган. Анда ашлык киптерәләр икән кояшта. Бабай ала да су сибә икән, ала да су сибә икән ашлыкка. Моны күреп, опять кыйнап җибәргәннәр икән. Шуннан кайткач, әби тагын бабайны әрләгән ди. Алай итмиләр аны: «Кипкән микән, кипкән микән, дип ашап карыйлар,» – дигән әби. Базар яныннан китеп барган. Анда алма сатып торалар икән. Хәзер бу ала да ашый икән, ала да ашый икән, кипкән микән дип. Әби тагын әрләгән моны. Шуннан юлда кайтышлый, бер бүре очраган. Бу бабай: «Мах-мах», – дип чакыра икән. Бүре алган да капкан ди бабайны.

*Хәлекәй авылында*
*Хәмзина Фәүзия Хәйретдин кызыннан (1941 елгы)*
*Г. Яхшисарова язып алды*

**Кәҗә белән сарык әкияте**

Әби белән бабай булган. Аларның бер кәҗәләре белән бер сарыклары булган. Әби белән бабай сөйләшкәннәр: «Боларны ашатып ятып булмый, чыгарып җибәрергә кирәк, үзләре табып ашасыннар», – дигәннәр. Шуннан боларны куып чыгарганнар. Кәҗә белән сарык чыгып киткәннәр. Кара урманга барып чыкканнар. Каршыларына бүреләр очраган. 4 бүре тезелешеп ботка пешереп утыралар икән, казан белән. Кәҗә белән сарык туктаганнар да боларга карап торалар икән. Бүреләр: «Әһәә, безнең

боткага ит юк иде, менә үзләре килеп җитте». Уйлашалар икән: «Башта кайсысын, сарыкнымы, кәҗәнеме ашыйбыз», – дигәннәр. Кәҗә башлы булган бит инде. Кәҗә: «Ми-ки-ки, ми-ки-ки, безнең капчыкта бит бүре башы унике, алып кил ботка-га салырга». Сарык бара да, башны бүреләр янына алып килә. Моны күргәч, бүреләрнең күзләре акая: «Зурыракны алып кил, зурыракны», – диләр бүреләр. Сарык бара да шул бер үк башны тагын алып килә. Бүреләрнең берсе: «Ботканың суы бетте бит, барып су алып килим әле», – дип кача. Хәзер бүреләр курыкты инде. Безнең дә башны өзәрләр, дип. Кәҗә: «Әйдә тотыйк та, боларның башларын боткага салыйк», – ди. Шуннан икенче бүре дә, ботканың суы бетте бит инде, теге бүре артыннан барыйм әле, югалмасын, ди. Шулай, бүреләр берәм-берәм качып китеп бетәләр. Кәҗә белән сарык ботканы ашап, рәхәтләнеп ут янында ятып йоклыйлар.

*Тәтер-Арслан авылында*
*Шәрипова Разия Шаһвәли кызыннан (1937 елгы)*
*Г. Яхшисарова язып алды*

## Ташбака белән чаян

Зур су аша теге ярга чыгарга кирәк, чаян ташбакага ялына: «Теге як ярга чыгарып куй», – ди. Ташбака: «Булмый, син чагасың», – ди. Чаян бик нык ялына. Ташбака ризалаша. Теге як ярга алып чыга. Чаян чага.

Ташбака: «Мин сиңа изге эш эшләдем, син чактың», – ди.

Чаян: «Синең эшең – изгелек эшләү, ә минем эшем – чагу», – ди.

Кеше гомере бик аз гына, коллективта, эштә, арабызда чаян кебек чагучы кешеләр бар. Алар – тәрбиясез кешеләр, көнләш, күрә алмаучылык (белән), чаян кебек чагып, үзләренә «рәхәтлек алалар». Юк, бу кешеләр – бәхетсез кешеләр була.

*Бакый авылында*
*Вилданова Ямал Газиз кызыннан (1921 елгы)*
*Г. Яхшисарова язып алды*

## БӘЕТЛӘР

### Сак-Сок бәетләре

Су буйларында диңгез камышы,
Тын урманнарда Сак-Сок тавышы.

Кара бүркемне алып кайтыгыз,
Әңкәйне күргәч, сәлам әйтегез.

Су буйларында бала үрдәкләр,
Әңкәй, елама, яна йөрәкләр.

Мәдрәсәләрдә китап киштәсе,
Сак белән Сокның тавышын ишетәсе.

Мәдрәсәләрдә пыяла ишек,
Сак белән Сокның тавышын ишет.

Күмәч күлмәгем өч тә кимәдем,
Очып чыкканда саубул димәдем.

Газиз әңкәем, бер сүз әйтәем,
Бәхиллек бирсәң, өеңә кайтаем.

Икәү орыштык тимер ук өчен,
Әңкәй каргадың бигрәк юк өчен.

Сарылы күлмәгем бер дә кимәдем,
Очып чыкканда саубул димәдем.

Яңгырлар ява, әңкәй, башыма,
Елап барабыз әңкәй каршына.

*Куганакбаш авылында*
*Ягафарова Рәхилә Низаметдин кызыннан (1936 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Мәдрәсәдә пиала ишек,
Сак белән Сокның бәетен ишет!

Икәү сугыштык тимер ук өчен,
Әнкәй каргады бер дә юк өчен.

Әнкәй каргагач, яралды канат,
Без өйдән очтык, кайтмаска кабат.

Әткәй кайткандыр, безне сорагандыр,
Әнкәй ничекләр җавап биргәндер?

Сак-Сок булдык без, күрешә алмыйбыз.
Якынайсак без, арага биек тау капка
Яисә алсу таң ата.

Дусларым сезгә әйтәм:
Әнкәй каргышын бер дә алмагыз,
«Әнкәй, әткәйнең кадерен белегез,
Һәрвакыт хөрмәт итегез!»

*Бакый авылында*
*Вилданова Ямал Газиз кызыннан (1921 елгы)*
*Г. Яхшисарова язып алды*

**Мәрьямкәй бәете**

Алтынчы утыз минутта
Фабрикадан кайтканда,
Агуланган Мәрьямкәйне
Салдылар больницага.

Салдылар да больницага,
Күрделәр кара гыроп.
Кара гыроп эчләрендә
Мәрьямкәй ята үлеп.

Ач күзеңне, ач күзеңне
Ач күзеңне, Мәрьямкәй.
Син ачмасаң күзләреңне
Ярдәм итәм үземнән.

(Балачакта картәниләрдән ишеттек).

*Айдарәле авылында*
*Галиәкбәрова Сәрия Сәфәргали кызыннан (1952 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

**Әни белән үземнең аерылышу бәете**

Буй җитте диеп шатланды әнкәем,
Ерак очырды язмыш бәпкәен.

Ерак илләргә баласы китте,
Соңгы сулышында баласын көтте.

Бала өзелде әнисен сагынып,
Очардай булды канатын кагып.

Ана өзелде хатларын көтеп,
Укып елады хатларын тотып.

Хатлары килде, үзе килмәде,
Баланың йөзен ана күрмәде.

Бала өзелде әнисе өчен,
Хатлар язды ул һәр җомга кичен.

Язмыш хөкеме каты булды безгә,
Шатлык сөенечләр күренмәде күзгә.

Ире сугышта, улы сугышта
Үлеп калдылар, ятып калдылар.

Дүрт бала белән ятим калды ул,
Йөрәге сыкраудан сулып калды ул.

Ана егылды, авырып аяктан,
Өч бала елады, өчесе өч яктан.

Гомерләргә кәккүк кычкырып китә,
Минем әниемә дәшмичә үтә.

Төшемдә әнкәй читтә утыра,
Өч баласы өрек ашап утыра.

Ризыгы беткән – күренеп тора,
Шуның өчен ул читтә утыра.

Фәритем, диде, Фәрзәнәм, диде,
Үләм бит инде, кайтыгыз, диде.

Кайталмадык шул, әнкәем үлде,
Яшь башыбызга кайгылар килде.

Үксеп еладык, ятып еладык,
Әнкәй янында була алмадык.

Иң әче агу – үлем хәлләре,
Аяктан екты кайгы җилләре.

Кайсы җирләрдә әнкәй кабере?
Соң аңлашылды әнкәй кадере.

Айрылышканда икәү еладык,
Күрешербез әле дип икәү йобандык.

Аякларында ак тула оек,
Әнкәй озатты, күңеле боек.

Әмиргә хәтле әнкәй озатты,
Киткән юлымны әнкәй күзәтте.

Гомер буена истән чыкмыйсың,
Күпме еласак та барыбер кайтмыйсың.

Хуш, балам, диде, хатлар яз, диде,
Хәлеңне белеп торыйк без, диде.

Әнкәй беләсең, теләп китмәдем,
Нурлы йөзеңне кайтып күрмәдем.

Һич көтмәгәндә чыгып киттем мин,
Туганнарымны ташлап киттем мин.

Елы яклардан кошлар китәләр,
Сәлам әйтергә сине тапмыйлар.

Дүрт балакаең калдылар ятим,
Бу язмышларга ни генә әйтим.

Төшемә керде, күңелемә килде,
Якты дөньядан бик иртә китте.

Ашап туймадың, күреп туймадың,
Балаларыңны назлап туймадың.

Тормам, бик авыр җилләр кагыла,
Балаларың әрнеп сине сагына.

Гомер буена истән чыкмассың,
Күпме еласам да, барыбер кайтмассың.

Сез киткән җирләргә без дә китәбез,
Бу дөнья ул фани гына, безне көтегез.

И кәккүк, кәккүк, безнең киртәгә килеп кунасың,
Дәшмичә генә очып китәсең.

Кәккүк, син безгә начар юрадың,
Әниебезне алып китеп югалдың.

Хәзер син безгә килеп кунмыйсың,
Эшем бетте дип, күрәсең, уйлыйсың.

Әти 43 ендә, әни 46 сында
Якты дөньяны ташлап киттеләр.

Алып киттеләр, илтеп куйдылар,
Ике баланы детдомга бирделәр.

Бер балакең өеңдә калды,
Кайгы-хәсрәттән йөрәге янды.

Бу балакаең әрнеп елады,
Хыялланудан Алла саклады.

Җиде кешедән берүзе калды,
Үксеп елаудан күзләре тонды.

Кеше хәлләре кешегә билгесез,
Башыгызга төшсә, шунда белерсез.

Әти киткәндә, тумаган идем,
Әни үлгәндә, урманда идем.

Безнең ризык урманда – балтырган,
Ходай безне шуңа калдырган.

Газизләремнең йөзен күрмәдем,
Ятимлек килде, ашап туймадым.

Ялгызлык авыр, яши алмады,
Бу йортта хәзер ризык калмады.

Капкаң ябылды, утларың сүнде,
Тәрәз төбендә гөлләрең шиңде.

Бу йортта хәзер кошлар сайрмый,
Самавырларда чәйләр кайнамый.

Йортны, бакчаны чүп үлән басты,
Бу йортның хәзер ямнәре качты.

*Стәрлебаш авылында*
*Кәримова Фәрзәнә Гыйльметдин кызыннан (1926 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## МӨНӘҖӘТЛӘР

### Мөнәҗәтләр

Рәхмәтулла, диде Муса,
Миңа җәннәт булыр микән?
Сиңа җәннәт булыр, Муса,
Әрвахларның хәлен белсәң.

Рәхмәтулла, диде Муса,
Миңа җәннәт булыр микән?
Сиңа җәннәт булыр, Муса,
Әрвахларга дога кылсаң.

Рәхмәтулла, диде Муса,
Миңа җәннәт булыр микән?
Сиңа җәннәт булыр, Муса,
Атаң-анаң разый булса.

Рәхмәтулла, диде Муса,
Миңа җәннәт булыр микән?
Сиңа җәннәт булыр, Муса,
Күршеләрең разый булса.

Рәхмәтулла, диде Муса,
Миңа җәннәт булыр микән?
Сиңа җәннәт булыр, Муса,
Гарипләрнең хәлен белсәң.

Рәхмәтулла, диде Муса,
Миңа җәннәт булыр микән?
Сиңа җәннәт булыр, Муса,
Кыз туганың разый булса.

Рәхмәтулла, диде Муса,
Миңа җәннәт булыр микән?
Сиңа җәннәт булыр, Муса,
Фәкыйрьләргә гошер бирсәң.

Рәхмәтулла, диде Муса,
Миңа җәннәт булыр микән?
Сиңа җәннәт булыр, Муса,
Теләкләрең (догаларың) кабул булса.

Кыз туганның дәрәҗәсе зур. Менә үтеп барганда чыбыркы булса да болгап китәргә. Безнең абый гел шулай итәдерие. Чыбыркы болгап китәдерие. Ат belә(н) йөрде инде ул, ат асрады.

И, Мөхәммәд Мостафа,
Атам-анам димәгән,
Балам-чагам димәгән,
Олы өммәтем дигән,
И Мөхәммәд Мостафа,
Салләллаһу галәйкә!

Теләмәде атасын һәм
Шәфкатьле анасын,
Кылды өммәте догасын –

И Мөхәммәд Мостафа,
Салләллаһу галәйкә!

Ачлыкка сабыр иткән,
Нәфескә җәбер иткән,
Өммәт өчен «аһ» иткән,
И, Мөхәммәд Мостафа,
Салләллаһу галәйкә!

Атасын да кичкән,
Анасын да кичкән,
Өммәт өчен «аһ» иткән,
И Мөхәммәд Мостафа,
Салләллаһу галәйкә,
Йа Мөхәммәд Мостафа.

* * *

Лә иләһе иллә Аллаһ –
Гарше көрси баскычы.
(Лә иләһе иллә Аллаһ –
Сигез оҗмаһ ачкычы).

Лә иләһе иллә Аллаһ,
Карамагыз әзенә.
Лә иләһе иллә Аллаһ –
Мәңге бетмәс хәзинә

Лә иләһе иллә Аллаһ,
Күп әйтегез фәләкләр.
Лә иләһе иллә Аллаһсыз
Кабул булмас теләкләр.

*Куганакбаш авылында*
*Ягафарова Рәхилә Низаметдин кызыннан (1936 елгы)*
*язып алынды*

**Мөнәҗәт**

Кеше өчен әүвәле иман дигән,
Ахирәтнең барлыгына инан дигән.

Яткан җирдән Ходай кичерер димә, дигән,
Иман шартын белмәгәнне яман, дигән.
Аннан кала беренчесе – намус, дигән,
Намусыңны сатып итмә табыш, дигән.
Байлык өчен илен-көнен саткан кеше
Ике дөнья өчен дә ул явыз, дигән.
Икенче иң кыйммәтлесе – гакыл, дигән,
Гакылсыз да тәүфыйк ягы такыр, дигән.
Гакылсызда тәүфыйк тә юк, иман да юк,
Ялганга ант биреп барып сатыр, дигән.
Өченче иң кыйммәтлесе – әдәп, дигән,
Әдәпсездә бәхет тә юк, тәүфыйк та юк,
Кеше исмен күтәрүе гаҗәп, дигән.
Дүртенче иң кыйммәтлесе – күңел, дигән,
Күңле бозык кеше – кеше түгел, дигән.
Бозыкларга җир өстеннән асты яхшы,
Яшәмә дә, үлеп җиргә күмел, дигән.
Бишенче иң кыйммәтлесе – сабыр, дигән,
Сабыр кеше зур бәхетләр табыр, дигән.
Юк-бар өчен ачуланып дөнья бозу
Бер кайгыдан икенчегә салыр, дигән.

**Мөнәҗәт**

Шушы дүрт нәрсәне, Раббем,
Сорыймын ялварып синнән.
Бере – җәннәт, бере – хөрмәт,
Бере – рәхмәт, бере – иман.

Сорыйм синнән миңа, Раббем,
Шушы дүрт нәрсәңне күрсәт.
Бере – кавышу, бере вилдан,
Бере – күркәм, бере – гыйлман.

Сорыйм синнән миңа, Раббем,
Шушы дүрт нәрсәне яр ит.
Бере – гыйлем, бере – гамәл,
Бере – саулык, бере – амән.

Итәр шәфкать, кичерер Раббем
Шушы дүрт нәрсәдән ансат.
Бере – сорау, бере – газап,
Бере – үлчәү, бере – сират.

Кыямәттә кубар Раббем
Шушы дүрт белән бергә.
Бере – Ситдыйк, бере – Фарук,
Бере – Хәйдәр, бере – Госман.

Дучар итмә бу дөньяда
Шушы дүрт нәрсәгә, Раббем.
Фәкыйрь булу бурычлану,
Гаепләнү, күрү зиндан.

Үзең сакла зыяныннан
Шушы дүрт әгъзамны, Раббем,
Гөнаһтан саклый күр үзең.
Бере – башым, бере – телем,
Бере – колак, бере – күзем.

Шушы дүртнең явызлыгын
Кагылдырма мине, Раббем.
Бере – динсез, бере – азгын,
Бере – шымчы, бере – шайтан.

Аерма безне, Ходаем,
Шул иде дүрт китабыңнан.
Бере – Инҗил, бере – Тәүрат,
Бере – Зәбур, бере – Коръән.

* * *

Лә илаһи иллә Аллаһу –
Гарше көрси баскычы.
Лә илаһи иллә Аллаһу –
Сигез оҗмах ачкычы.
Лә илаһи иллә Аллаһу,
Карамагыз азына

Лә иләhи илләә Аллаhу –
Мәңге бетмәс хәзинә.
Лә илаhи иллә Аллаhны
Төшермә телеңнән hәр заман.
Лә илаhи иллә Аллаhу,
Аерылган кол бик яман.
Лә илаhи иллә Аллаhу
Күңелләрне юата.
Лә илаhи иллә Аллаhу –
Кайгыларны тарата.
Лә илаhи иллә Аллаhу –
Яңгырлыкта сердәш ул.
Лә илаhи иллә Аллаhу –
Ялгызлыкта юлдаш ул.
Лә илаhи иллә Аллаhу –
Сүзләрнең кирәге ул.
Лә илаhи иллә Аллаhу –
Динебез терәге ул.
Лә илаhи иллә Аллаhу,
Аерылмагыз hичкайчан.
Лә илаhи иллә Аллаhу,
Салмыйк телдән hәр заман.
Лә илаhи иллә Аллаhу
Гаеп маллар таптыра.
Лә илаhи иллә Аллаhу
Һәркемгә ризык арттыра.
Лә илаhи иллә Аллаhны
Әйткән кеше зур булыр,
Лә илаhи иллә Аллаhны
Әйтмәгәннәр хур булыр,
Лә илаhи иллә Аллаhу
Киң кылачак каберне.
Лә илаhи иллә Аллаhны
Әйткән кеше кадерле.
Лә илаhи иллә Аллаhу

Туры юлга күндерер.
Лә илаһи иллә Аллаһу
Тәмуг утын сүндерер.
Лә илаһи иллә Аллаһу
Авыруларны бетерер.
Лә илаһи иллә Аллаһу
Сәламәтлек китерер.
Лә илаһи иллә Аллаһу –
Мөэмин колларга бәхет.
Лә илаһи иллә Аллаһу
Оҗмаһта булыр тәхет.
Лә илаһи иллә Аллаһу
Сираттан җиңел кичерер.
Лә илаһи иллә Аллаһу
Кәүсәр суын эчерер.
Лә илаһи иллә Аллаһу
Дошманнардан саклар ул.
Лә илаһи иллә Аллаһу
Бәлаләрне таптар ул.
Лә илаһи иллә Аллаһу
Күп әйтәдер мәләкләр.
Лә илаһи иллә Аллаһу
Кабул булмас теләкләр.
Лә илаһи иллә Аллаһу
Мөнәҗәтем гыйндә Аллаһ.
Лә илаһи иллә Аллаһу
Бар хаҗәтем – бер Аллаһ.

*Гөлем авылында*
*Сәхибгәрәева Әминә Миңнехан кызыннан (1940 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Газиз Алла берлеген,
Ислам диннең хаклыгын,
Әхмәт пәйгамбәрлеген,
Бердер илаһым бәнем.

Илаһым сүзе – Коръән,
Пәйгамбәремә кимән.
Ул безгә китап булган,
Алла, ди гел Бәдәвам.

Илаһымның белүе,
Күрүе, ишетүе,
Башка эшләр кыйлуы
Бердер илаһым бәнем.

Бу дөньяны куарсыз,
Бик күп маллар җыярсыз.
Барып куеп китәрсез,
Алла, ди гел Бәдәвам.

Газраил янын алыр,
Малын варислар алыр.
Вабалы үзенә калыр,
Алла, ди гел Бәдәвам.

* * *

Әминәдер – үз анасы,
Хәлимәдер – сөт анасы.
Габдулла затның баласы
Туды бу көн ул Мостафа.

*Карагош авылында*
*Табаева Әминә Мөхсин кызыннан (1930 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

* * *

Сабыр итик, сабыр итик,
Сабыр итик, бәндәләр.
Сабыр иткән кешеләр
Иман белән үткәннәр.
Сабыр итик, сабыр итик,
Сабыр итик, адәмнәр.
Сабыр иткән изгеләр
Оҗмах ишеген ачар.

Сабыр итик, сабыр итик,
Сабыр итик, адәмнәр.
Сабыр иткән юмартлар
Оҗмах ишеген ачар.
Бакырган дигән китапны инәй укый иде.
Килер бер көн авыру тияр,
Кызыл йөзең сары көяр.
Тамырларың акрын тибәр,
Шул хәлләргә төшмә көн бар.

* * *

Оҗмах шәрәфен әчәр,
Оҗмахта хурлар качар,
Алла диген Бәдәвам.
Намазсызның түкел каның,
Этләргә бир ел ашын.
Җеназа укымаганга юк,
Кәфен салмаганга юк.
Намаз укыган очар,
Кәүсәр шәрабен эчәр,
Оҗмахта хурлар качар,
Аллаһ диген Бәдәвам

*Өч-Әсән авылында*
*Гафиятуллина Мөбарәк Муллагали кызыннан (1930 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Язам әле, балам, сүзләремне,
Сүзләремне түгел, моңнарымны.
Мин үлгәчтен, балам, укыт Коръән,
Тәрәзәдән килеп тыңнармын.

Зинһар әйтәм укыт, балам, Коръән,
Минем васыятем шул булыр.
Син, балам, Коръән укытсаң,
Кабер эчем нур булыр.

Зинһар әйтәм укыт, балам, Коръән
Син бит минем газиз балакаем.
Атнакичләр булса яным кайтыр
Ак күбәләк булып, бәбекәем.

Тар каберләрдә мин ятырмын,
Сез балалардан дога көтәрмен.
Догалар булса, тыныч ятырмын,
Онытсагыз, ни хәлләр итәрмен

Садакалар бир, балам, минем өчен,
Мине яткызмагыз изү газапта.
Мин бит сездән сорый алмыйм,
Мин бит тоткында, ә сез азапта.

Тагын, балам, шуны әйтәм:
Уздырыгыз минем өчемне.
Килгәннәргә биреп дога кылдыр,
Буш үткәрмә атна кичемне.

Еламагыз, балам, яшь түкмәгез,
Миннән аерылып калганда.
Бер Ходаем тел ачкычы бирсен
Мөнкир-Нөнкир җавап алганда.

* * *

Раббым Алла, диде, Муса,
Миңа җәннәт булыр микән.
Сиңа җәннәт булыр, Муса,
Атаң-анаң риза булса.

Раббым Алла, диде Муса,
Миңа җәннәт булыр микән.
Сиңа җәннәт булыр, Муса,
Күршеләрең риза булса.

*Бузат авылында*
*Гарифулллина Флүрә Мансур кызыннан (1945 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

**Мөнәҗәт**

Әгүзе билләһи …
Килеп кердек өегезгә, нур балкыган йөзегездә,
Әҗре газыйм савап булсын һәрбер баскан эзегезгә.
Иттегез хөрмәтегезне, җыйдык без нигъмәтегезне,
Кыямәт көнендә хурлар каршы алсын үзегезне.
Ходаем әйләсен рәхмәт, йөзегез нур белән тулсын,
Бу мәҗлесне корган өчен, сигез оҗмах насыйп кыйлсын.
Мәхәббәт калебеңә тулсын, сәгадәт әһеленнән кыйлсын,
Бәхетләрегезне биреп, камиллек иясе кыйлсын.
Ходай бирсен сезгә дәүләт, урыныгыз булып җәннәт,
Бүләк кыйлсын сезгә җәннәт, ике җиһан нурга тулсын.
Ихлас күңелдән укыйбыз Коръәнне вә салаватны,
Хәерле дога кыйлабыз Сезгә теләп зур савапны.
Киләчәктә икенче мак сүзем шулдыр:
Рәсүлем юлына күндер, җәннәт сараена иңдер,
Насыйп итсен Тәгалалла киләчәктә очрашканчы.
Саубуллашыйк, кардәшләрем, күрешелмичә аерылышсак,
Бәхил булышыйк, кардәшләрем,
Вәссәләтү вәссәламу варахматуллаһи вә бәрәкәтү.

*Тәтер-Арслан авылында*
*Мөхәммәтшина Әнвәрә Хәмәтһади кызыннан (1941 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

«Лә иләһи иллә Алласыз
Кабул булмас теләкләр», –
дип әйтә торганые әни:
Лә иләһе иллә Аллаһы –
Гарше көрси баскычы.
Лә иләһе иллә Аллаһы –
Сигез оҗмах ачкычы.

Лә иләһе иллә Алланың
Карамагыз азына.
Лә иләһе иллә Аллаһы –
Мәңге бетмәс хәзинә.

* * *

И, Ходаем, миңа җәннәт
Былырмы икән, диде Муса.
Сиңа җәннәт булыр, Муса,
Атаң-анаң разый булса.

И, Ходаем, миңа җәннәт
Былырмы икән, диде Муса.
Сиңа җәннәт булыр, Муса,
Туганнарың разый булса.

И, Ходаем, миңа җәннәт
Былырмы икән, диде Муса.
Сиңа җәннәт булыр, Муса,
Кыз туганың разый булса.

И, Ходаем, миңа җәннәт
Былырмы икән диде Муса.
Сиңа җәннәт булыр, Муса,
Гамәлләрең кабул булса.

И, Ходаем, миңа җәннәт
Былырмы икән диде Муса.
Сиңа җәннәт булыр, Муса,
Күршеләрең риза булса.

* * *

И, Ходаем, ошбу хәлдин,
Аерма бу газиз яндин.
Аерсаң бу газиз яндин,
Аерма бакый имандин.

И, Ходаем, сәңә карыйм,
Сәндин башка кая барыйм
Синең рәхмәтеңә карыйм,
Шәфәгатьчем сән, бер Алла.

И, Ходаем, сәңә карыйм,
Сәндин башка кая барыйм.

Синең рәхмәтеңә карыйм,
Шәфәгать кыйл Рәсулулла.

Әни әйтә иде. Мин Арсланда тудым. Әнием Яшерганныкы, картәни-картәтиләрем.

*Тәтер-Арслан авылында*
*Тәминдарова Фатыйма Бакыйр кызыннан (1931 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Лә иләһе иллә Аллаһы
Мөхәммәдрәсүлүллаһи.
Лә иләһе иллә Аллаһтан
Аерылма һәр заман.
Лә иләһе иллә Аллаһтан
Аерылган кол яман.
Лә иләһе иллә Аллаһны
Күп әйтегез кешеләр.
Лә иләһе иллә Аллаһсыз
Кабул булмас теләкләр.
Лә иләһе иллә Аллаһы –
Гарше көрси баскычы.
Лә иләһе иллә Аллаһы –
Сигез оҗмах ачкычы.
Лә иләһе иллә Аллаһның
Карамагыз азына.
Лә иләһе иллә Аллаһы,
Дөнья-ахирәт – хәзинә.
Лә иләһе иллә Аллаһы,
Авыр килер мизанда.
Лә иләһе иллә Аллаһы,
Җиңел килер инсанда.
Лә иләһе иллә Аллаһы
Дин Исламга күндерер
Лә иләһе иллә Аллаһы
Тәмуг утын сүндерер.
Лә иләһе иллә Аллаһы,
Йөзебездә нурыбыз.

Лә иләһе илләә Аллаһы –
Үлгәндә әйткән сүзебез.
Лә иләһе илләә Аллаһы,
Бер дә салма авыздан.
Лә иләһе илләә Аллаһы
Сине саклар явыздан.
Лә иләһе илләә Аллаһы
Әйткән кеше кадерле.
Лә иләһе илләә Аллаһы
Киң кыйладыр каберне.
Лә иләһе илләә Аллаһы
Булса минем телемдә.
Лә иләһе илләә Аллаһы
Юлдаш булыр гүремдә.

Амин. Бирсен Аллаһы Тәгаләкәем һәммәбезгә иман белән яшәп, иман белән үтәргә.

* * *

Бисмилла диеп башлыймын
Тыңласагыз мөнәҗәтем.
Мөхәммәд өммәте өчен
Яралтты сигез җәннәтем.

Иртә торып тышка чыксам,
Айның үндүртләре җиткән.
Әлхәмдүлилләһи шөкер,
Мөхәммәд өммәте иткән.

Сәхрәләрдә бер агач бар,
«Әлхәм» укый кошлар кунгач.
Әлхәмдүлилләһи шөкер,
Мөхәммәд өммәте булгач.

Җәннәтеңне насыйп әйлә,
Дидарыңны насыйп әйлә.
Рәсүлуллаһ шәфәгатен
Барчамызга насыйп әйлә.

Мәрьям ана туйларыный
Барчамызга насыйп әйлә.
Сигез оҗмах юлларыный
Барчамызга насыйп әйлә.

Тубый агач төпләрени
Барчамызга насыйп әйлә.
Кәүсәр шәраб тәмнәрени
Барчамызга насыйп әйлә.

Рәсүлуллаһ намаз укый,
Башындадыр аның таҗы.
Гасый өммәтләре өчен
Сызыладыр йөрәк мае.

Рәсүлллаһ Коръән укыр,
Сачәкләре атып торыр.
Рәсүлуллаһ Кыямәт көн
Шәфәгатен кыйлып торыр.

Рәсүлуллаһ дога кыйлды,
Догалары кабул булды.
Рәсүлуллаһ догасындин
Ике җиһанга нур тулды.

Күзләрем Сине эзлидер,
Күңелем Сине эстидер.
Телләрем Сине сөйлидер,
Шәфәгать кыйл, Рәсүлуллаһ.

Ачыйк әле күземезне,
Зикер берлән телемезне.
Галимнәрне сөйик әле
Чын ихласлы күңелемездин.

Фәрештәләр килер каршы
Пәйгамбәрләр хөрмәтенә.
Җәннәтеңне насыйп әйлә
Рәсүлуллаһ өммәтенә.

И дусларым, беләсезме,
Күктә Гайсә пәйгамбәр бар,
Үзебез – мөэмин, динебез – Ислам,
Шөкерана кыйлырлык бар.

Әгәр иман берлән үтсәм,
Җәннәтел – Нәгыймгә керсәм,
Үзеңнең дидарың күрсәм,
Иң зур бәхет булыр бирсәң.

Телемнең тәмнәре бетәр,
Тәнемнең куәте китәр,
Иман белән китәр булсак,
Безгә шул рәхмәтең җитәр.

**«Җомга көн» мөнәҗәте**

И, мөселман, кыйл гыйбадәт,
Бу – мөбарәк җомга көн.
Зикер илә кальбең саф кыйл,
Бу – мөбарәк җомга көн.

Бир салават – ул Мөхәммәд
Мостафаның рухыйна.
Ничә йөз Кәгъбә савабы,
Бу – мөбарәк җомга көн.

Ходай хакына гыйбадәт кыйл,
Бу – мөбарәк җомга көн.
Зикре тәсбих ихсан кыйл,
Бу – мөбарәк җомга көн.

Әйт салават Мөхәммәд,
Мостафаның рухыйна.
Вәрсенә мең савап язылыр,
Бу – мөбарәк җомга көн.

Тәһлил әйтеп, Коръән укып,
Изгелек кыйл җомга көн.
Кыйлма заяга гомерең,
Бу – мөбарәк җомга көн.

Кыйл йа Раббе, дусларыңа,
Бу – мөбарәк җомга көн.
Бир садака рухларына,
Бу – мөбарәк җомга көн.

Кальбеңне саф тот һәр кичтә,
Һәр җәһәттән пакь итеп.
Кыйл азат тәнеңне уттан,
Бу – мөбарәк җомга көн.

Сүрәи Фатыйха илә
Сүрәи Ихлас укып.
Шат кыйл әрвахларыңа син,
Бу – мөбарәк җомга көн.

Безнең барча әрвахларны
Көтә дога җомга көн.
Шат кыйлыйк аларның җанын
Бу – мөбарәк җомга көн.
Әмин.

**Мөнәҗәт**

Бисмилләәһир-раәхмаанир-рәхиим.
Бүген таңда хәйран калып,
Табигать илендә йөрдем.
Изге гыйбадәтханәнең
Ишекләрен ачып кердем.

Бар табигать тәкбир әйтеп,
Олугъ Көчкә оеган иде.
Күзләрем могҗизалы вә
Серле тамашаны күрде.

Тәкбир әйтеп, агачлар да
Изге сүрәләр кабатлый.
Кыямга баскан куаклар,
Тәгәүүз, бисмилләһ укый.

Тәкбир әйтеп, чәчәкләр дә,
Рөкуг халәтенә баскан.
Каумә кыйлып сәҗдәдән,
Аллаһ хозурын ашкан.

Аллаһны олуглап кошлар,
Зикер әйтә, тәсбих тарта.
Дөнья аклана, пакьләнә,
Бәрәкәт, изгелек арта.

Бар тереклек шәфкатьле вә
Рәхмәтле көчкә табына.
Мөэмин, мөселман халыкта,
Диңгезләрдәге балык та.
Әмин.

**Зур теләгем**

Бисмилләәһир-рахманир-рәхиим.

Мин сөямен ислам динен,
Ислам белән мин мактанам.
Әле дә мөэминә исемен
Алганмын әле диеп шатланам.

Булмаса да миндә башка
Динне һичбер кимсетү.
Әмма дә мин Ислам кебек
Ул динне һичбер мактамам.

Бу җиһанда дин-иманымнан
Сөекле һичбер нәрсә юк.
Дин-иманымны алсалар,
Мин мең үлемгә буйсынам.

Игътикадым Коръәнем,
Коръән – бөек бер борһаным
Күңелемә бер кер төшсә,
Коръән белән мин пакьләнәм.

Кальбемә сеңгәндер бөек
Тәңренең исеме, кодрәте.
Тәңре берлән мин башкача,
Мохтаҗ булудан сакланам.

Әй газиз Тәңрем, җиһанга
Чәч бөек Коръәннең нурын.
Дин телим дә, шул теләктән
Мин тагын да ләззәт алам.

Барча инсанга сәгадәт,
Юлларын күрсәтче, Ходай.
Рәхмәтең бик зур, Илаһым, – дип
Аңарга мин баш салам.
Әмин.

**Уйлап яшә**

Бу дөньяда син яшисең, гомер үтә.
Сиңа биргән вакыт бетә, вакыт җитә
Башка дөнья алда көтә,
Кеше җирдән шунда китә.
Ә әлегә хәбәр көтә.
Фәрештәләр килер арттан,
Әмер белән, Күктә сине Ходай көтә.

Фәрештәләр озатырлар күккә кадәр.
Ике капка алда булыр.
Тик кайсына сине кертә,
Ике капка алда көтә.

Ике фәрештә ике иңдә язып бара,
Берсе яза синең яхшы эшне
Булса әгәр,
Икенчесе яза икән кара эшне,
Монысы – хәтәр.

Гомер буе байтак кына җыеладыр.
Төрле эшләр.

Вакыт җиткәч, үлчәү белән
Үлчи аны фәрештәләр.
Кайсы ишек ачылыр икән
Синең өчен. Белсәң әгәр!

Син әлегә җирдә булсаң,
Исеңә төшер.
Фани дөнья адәм өчен
Бик тә кыска,
Барасың бар Ходай каршына
Үкенерлек булмасын дип,
Уйлап яшә!
Әмин.

**Күңелдә тот зикерне**

Өч нур диеп шуны әйтәләр, белегез.
Рәсүлуллаһның сөннәтен тотыгыз.
Кичен булса, ятың тәһарәт алып,
Салават әйт, төннәрендә уянып.

Салават әйтсәң, фәрештәләр иңәрләр,
Гөнаһыңның ярлыкавын теләрләр.
Салават әйтеп, күңелләреңне уят,
Салаватлар – оҗмах юлына маяк.

Салават әйтсәң, насыйп булыр оҗмахлар,
Анда үсәр синең өчен игачлар.
Салават әйткел, Рәсүлеңне танырсың,
Зикер әйткел, мәңге оҗмахта калырсың.

Бу зикердән таулар, ташлар туймыйдыр,
Бер зикерсез җанга ләззәт булмыйдыр.
И дусларым! Гафил үткәрмик көннәрне
Күңелдә тот! Даим әйткел зикерне.

Тәнең – саләт, телең зикердән куйма,
Бер зикерсез кыямәт көн хур булма.
Бу зикерләр – даим салихлар эше,
Бер зикерсез мисалы – чуер ташы.

Зикер-тәсбих – кул-аякка көч түгел,
Аңа кирәк телең һәм ихлас күңел
Мәңгелек дип кумагыл дөнья-фани,
Иртә вә кич күңелдә тот Аллаһны.

Ният кыйлсаң гыйбадәтләр үтәргә,
Сәбәп булыр Иман белән күчәргә!
Әмин.

* * *

Дидем: Аллаһ, йәә Аллаһ!
Ятмагызлар, и гафилләр,
Зикер әйтегез Хакка.
Без – җирдә кунак кына,
Тиздән керербез туфракка.

Барча күрше-күләннәр,
Сәхәр вакыты торырлар.
Ата-ана, угыл-кыз
Хакка дога кыйлырлар.

Дидем: «Аллаһ, йәә Аллаһ!
Аллаһ, Аллаһ, йәә Аллаһ!
Гамәлеңне бир, Аллаһ!
Догам кабул кыйл, Аллаһ!

Атам-анам, остазым,
Барча мөэмин дусларым.
Ярлыкагыл, йәә Гани!
Раббым Аллаһ, йәә Аллаһ!
Әмин.

**Ходайны зурлыйк!**

Корьән иңгән безгә вәгазьләнү өчен,
Югалтмый ул беркайчан да үзенең көчен.
Корьән безне дөрес юлга җәлеп итә,
Корьәнчә яшәсәк, хәерле үзебез өчен.

Җир-күккә карап белеп була
Ходайның көчле кодрәтен.
Ходай Тәгаләне без зурласак,
Җәлләми бит ул рәхмәтен.

Ачы язмыш, авырлыклар
Беркемне дә читләп үтмәгән.
Пәйгабәрләр генә яшәп китмәгән.

Ходай хакын хаклый белсәк,
Яхшы якка дөнья үзгәрер.
Ходай Тәгалә юмарт бит ул,
Рәхмәтләрен җибәрер.

Гыйбрәт алыйк җиһан киңлегеннән,
Таулар, сулар, якты дөньядан.
Болар бөтен уңайлыгы белән
Безнең өчен килгән Ходайдан!

Изге догаларны укысак,
Изге юлга җитәкли.
Тормышта да җиңел була,
Кайгы-хәсрәт күрсәтми.

Изгелекне алга куйсак,
Юлдаш була яуда да.
Изгелегең алдан йөри.
Һәр очракта файдага.

**Хак каршында артыр хакыбыз**

Аятел-Көрси – зур аять.
Аны һәркем зурласын.
Аны зурлаган адәмнәр,
Җәннәттән урын алсын.

Аятел-Көрси укыган,
Җәннәткә керми калмас.
Аятел-Көрси белмәгән,
Җәннәткә юл табалмас.

Аятел-Көрсине укың,
«Хифзүһүмә» дигән сүзне.
Кадерле булган иманымнан,
Мәхрүм итмәче, дип безне.

Аятел-Көрси – зур аять,
Намазга кушып укыгыз.
Укысагыз, ХАК каршында
Артыр сезнең хакыгыз.

Укыйк Аятел-Көрсине,
«Хифзүһүмә» дигән сүзне.
Мизаннарда үлчәгәндә,
Кызартмас ул йөзебезне.

Бөтен мөэмин-мөселманга
Аятел-Крси яраткан.
Рәсүлебез ярдәм кылып,
Аятел-Көрси тараткан.

Укы Аятел-Көрсине,
«Хифзүһүмә» дигән сүзне.
Сират күперен кичкәндә,
Җиңеләйтер хәлебезне.

Аятел-Көрси укыйк,
Туганнарым, һәркөн кичен.
Тәһлилен дә без күп әйтик,
Җәннәтләргә керү өчен.

Аятел-Көрси белмәгәннәр,
Тырышсыннар белергә.
Ахирәттә юл ачылыр
Җәннәтләргә керергә.

Балаларга да өйрәтик,
Аятел-Көрсине белсеннәр.
Безгә дә куаныч булыр,
Диндар булып үссеннәр.

## Намаз – диннең терәге

Хәләл малың әз булса да,
Шөкер кыйлсана барына.
Кыйла күргел гамәлләрең,
Уттан сакланыр тәннәрең.

Намаздыр – диннең терәге,
Намаз – ахирәт бүләге.
Гамәл кылган бәндәләрнең
Утта янмастыр сөяге.

Кадерләп малны җыйсаң да,
Китәрсең барын да куеп.
Авызыңнан җаның чыккач,
Алырлар күлмәгең суеп.

Күлмәгең суеп алганда,
Башыңа суны салганда,
Илтеп ләхеткә куйганда,
Ни җавап бирерсең анда.

Әҗәлнең вакыты җитәр,
Йөзеңнән нурлары китәр.
Шул вакытта шайтан мәлгунь
Баш очыңа килеп җитәр.

И Раббыбыз, газиз Аллаһ,
Рәхмәтеңдә булсак иде.
Иртә-кичен биш намазны,
Вакыты белән кыйлсак иде.
Әмин.

## Аллаһның әмере белән иңгән Коръән аятләре

Ак кәгазьнең өсләрендә,
Язамын – бәән калями:
Ләә иләәһе илләаллаһы –
Рәсүлебез сәламе.

Аллаһның әмере белән
Иңгән Коръән аятьләре.
Өммәтләренә калгандыр
Рәсүлебез сөннәтләре.

Аллаһ әмеренчә куелган
Коръәннең тынышлары.
«Аллаһ» дисәң, күккә аша
Бәндәнең сулышлары.

Урыннардан кузгалганда,
«Аллаһ» диеп сулыймын.
«И Ходаем, гөнаһымны,
Гафу ит», – дип елыймын.

Иртә торып, тәһарәт алып,
Укыйм «Әлхәм» сүрәсен.
Кыямәт көне булганда,
Фирак уты булмасын.

Иртә торып, намаздан соң,
Укыекчы без Коръән.
Җан яраткан Аллаһының
Юлында булыйк корбан.

Иртән торып, намаздан соң
Укыек без «Тәбарәк».
Аллаһыны яд иткәндә,
Яшьләр төшсен тәгәрәп.

Ходаем, рәхмәтең берлә
«Кәлям Шәриф» иңдердең.
Рәсүл сөннәтләре аша,
Туры юлга күндердең.
Әмин, Бирсен Аллаһы Тәгаләм.

*Бакый авылында*
*Байтимерова Нажия Шаһиәхмәт кызыннан (1937 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

**Мөнәҗәт**

Бу дөнья бит фани гына,
Бер мизгелгә генә килгәнбез.
Ризыгыбыз бетәр, сулышыбыз туктар.
Алланың мәңгелек йортына китәрбез,
Зур җаваплар шунда тотарбыз.

Фани дөньяданиләр чәчтек,
Әхирәттә шуны урырбыз.
Изге гәмәлләребез күбрәк булса,
Җәннәтләрдән урын алырбыз,
Ахирәттә җәннәт күрербез.

И Раббем, ташламачы безне,
Рәхмәтеңнән безне калдырма.
Дидарыңны күрергә насыйп итче,
Күзләребезне безнең талдырма.

Раббем, сиңа чиксез рәхмәтлемен,
Чиксез нигмәтләрең өчен.
Изге йөрәгем, иманлы кальбем,
Бигрәк сабырлыкларың өчен.

Барасыбыз бар бит әле
Алланың хозурына.
Барасыбыз бар бит әле
Җавапның иң зурысына.

Кушканнарыңны эшләп,
Тыйганнарыңнан тыелып,
Коръән кушканча яшәсәк иде.
Үз хозурыңа тулы иманыбыз белән барып,
Җәннәтләреңнән урыннар алсак иде,
Насыйп ит, Аллаһым!

*Стәрлебаш авылында*
*Кәримова Фәрзәнә Гыйльметдин кызыннан (1926 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

**Җырлар**

Султан, Бакыйр,
Мәрвәрбикә,
Шәмсекамәр, Фидая,
Мөсәвиясе кайда?

Алга мансам, ачар микән
Аклы күлмәккәемне?
Ниләр генә басар икән
Янган йөрәккәемне?

Ал булам синең өчен,
Гөл булам синең өчен.
Аккан дәрьяларга төшеп,
Югалам синең өчен.

Ал булганчы, гөлләр булсам,
Сулар сибәрләр иде.
Сабый чакларымда үлсәм,
Сагынып сөйләрләр иде.

Карамал калкулары,
Аерылырга булган икән
Кашымның тартулары.

Без үзебез Уфаныкы,
Уфада тормасак та.
Үкенечкә калдырмадык,
Япь-яшь кенә булсак та.

Алып алырсың микән,
Гөлен алырсың микән.
Урталарга чыгып сайлап,
Кемне алырсың икән?

Алларын да алырбыз,
Гөлләрен дә алырбыз.
Күңелебезгә кем ошаса,
Шуны сайлап алырбыз.

Каеннарын сайларсың,
Гомер буе күкрәгемдә
Утлар булып янарсың.

Кияле, кияле,
Кияле галушыңны.
Бер кычкырып ерла әле,
Яратам тавышыңны.

Кайгыра белми кайгырдым
Кайгыларым юк чакта.
Инде уралдым кайгыларга
Карый да алмыйм як-якка.

Кара юрга, кара юрга
Менеп бара үрләргә.
Күрәчәкне күрмәенчә
Кереп булмый гүрләргә.

* * *

Әйдә, иркәм, барасыңмы?
Мин барам кар суына.
Кар сулары эчеп торам
Йөрәгем ярсуына.
Ургылып-ургылып агар кар суы,
Ник басылмый йөрәгем ярсуы.

Гармуннарга кушылырга
Минем тыннарым кыса.
Моңаеп сайраган кош та
Сабыр итәргә куша.
Ургылып-ургылып агар кар суы,
Ник басылмый йөрәгем ярсуы.

Бәйлим сүтәм, бәйлим сүтәм,
Җәллим кистерергә.
Бәхет бит ул гөлләр түгел,
Су сибеп үстерергә.

Ургылып-ургылып агар кар суы,
Ник басылмый йөрәгем ярсуы.

*Турмай авылында*
*Курманаев Динияр (Минияр) Биктимер улыннан (1931 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

**Яз җиткәч**

Яз җиткәч, яфрак яра ак каен,
Яз җиткәч, өзелә үзәккәем.
Ничә яз гөлләр чәчкә аттылар,
Ничә яз кошлар кире кайттылар,
Ничә яз сезне сагынып көттеләр,
Ничә яз гөлләр чәчкә аттылар,
Ничә яз кошлар кире кайттылар,
Ничә яз сезне сагынып көттеләр.

Яз җиткәч, өзелә үзәккәем,
Яз җиткәч, көтәм сине көн саен,
Ничә көз кошлар сезне көттеләр,
Ничә көз гөлләр чәчкә койдылар,
Ничә көз кошлар күрми киттеләр,
Ничә көз гөлләр чәчкә койдылар,
Ничә көз кошлар сезне көттеләр,
Ничә көз сезне күрми киттеләр.

*Яңгырчы авылында*
*Тимербакова Мөнирә Миңнегали кызыннан (1944 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Бу дәфтәргә мин халык авыз иҗаты яза башладым. Әнием өйрәткән җырлар.

Ерак бит ул,
Ерак бит ул тайгалар.
Җифәк түгел, җилгә очмый,
Авыр бит ул кайгылар.

Болар бит сугышка киткәч чыгарылган җырлар.

Аэроплан үрләсен дә,
Үрләсен, үргә менсен.
Тормышлар аерым булса да,
Күңелләр бергә булсын.

Уфаның уеллары,
Булмас инде рәхәт көннәр,
Булса да кыеннары.

Сугыштан соң Ишембай шәһәре барлыкка килгән, Салават шәһәрләре.

Ишембайның шәмнәре,
Ишембайның шәмнәре.
Бездән түгел, тормыштан бит
Аеруларның хәлләре.

Әрни йөрәгем тибеп,
Әрни йөрәгем тибеп,
Әллә шуңа әрни микән,
Аерылганнарны сизеп.

Былбыллар кунган киртәгә,
Ашыгалар китәргә.
Былбыл көннәренә калдым,
Белмим нихәл итәргә.

Әйт, сандугач, дускаем,
Дускаем елый, диген.
Бер минут истән чыгармый,
Гел сине уйлый, диген.

Сакмар да каеннарда,
Самар да каеннарда.
Хәзер инде ялгыз башым,
Уйларда-кайгыларда.

Сандугач булалмадым,
Гөлләргә куналмадым.

Дусларым бәхетле булды,
Мин генә булалмадым.

Фатыйма туташ микән?
Латыйфа туташ микән?
Бу кайгылар бетәр микән,
Әҗәлгә тоташ микән?

Бөгелә каен, сыгыла каен,
Әкрен искән җил саен.
Утырамын да җылыймын
Исемә төшкән саен.

Үтте-китте яшьлек чагым,
Килмәс инде яңадан.
Яшьли сөйгән ярларымны,
Күргән саен яңарам.

Җил булмаса да җилферди
Җилфер буе әремнәре.
Сезнең өчен әз булмады
Йөрәгем әрнүләре.

Их, дускаем, без икебез
Аерылмас кебек идек.
Ай янындагы якты
Йолдызлар кебек идек.

Рәкыя дигән түти, безнең күршедә генә яшәде, гел алар урак уралар ие. Төнлә шәл бәйлиләр, көндез – колхоз эшендә, Шул җырларны җырлый иде.

Канәфер куш карага,
Канәфер кушсаң карага,
Дошман керми арага.
Хәнәфер сал балларга,
Хәнәфер салсаң балларга,
Дошман керми арага.

Зәңгәр чәчәкләр яратам,
Зәңгәр чәчәк өзелде.
Чәңгәр чәчәкләр шикелле
Ярата идем тормышны,
Күңелләрем сүрелде.

Алар шулхәтле җырлыйлар иде. Бәетләре, җырлары. Мин инде язып ала идем, мин бит инде укыткач монда.

Иртә торсам, иртә икән,
Намаз вакыты җитә икән.
Чит җирләрдә торулары
Диваналар итә икән.

Иртә торсаң, иртә икән,
Азан тавышы ишетелә икән.
Сөйгәнеңә баралмасаң,
Яр сөйгәнеңне сагынып,
Башкаеңны диваналар итә икән.

Менә бу җырны беренче Герман сугышына катнашкан Әхмәтша бабайдан язып алган идем. Ул бабай менә 1 күлек дәфтәр алып кайткан иде. Кайдадыр кемгәдер бирдем дә китте бит инде.

Үзебез шәлләр бәйләгәндә Сарман, Агыйдел, сандугач турындагы җырларны җырлыйбыз.

* * *

Агыйделдә ак пароход
Килгән икән салларда.
Саллар белән хәсрәтләрем,
Кайгыларым аксала.

Бу безнең бабайлар, әбиләр җырлаган җырлар. Менә Гомәр абый Гомәрәв җыйган җырлар:

Уфа тараклары кирәк
Чәчләреңне тararга.
Кәртечкеләреңне җибәр
Сагынганда карарга.

Агыйделгә басма салдым,
Кошлар йөзә алмагач.
Алдым каләм, яздым сәлам,
Сагынып түзә алмагач.

Сугыш елларында кыска җырларны безнең әби-бабайлар җырламыйча калмаганнар. Безнең халык җырсыз тормаган, бәетсез тормаган.

Бу Бөек Ватан сугышында катнашкан Сәйфетдинов Ягъфәр Хәсән улы (1903–1945) язып алган җырлар:

Гашыйк уты шундый ут ул
Сүнми дә, сүрелми дә...

Җилфер-җилфер җилләр исми,
Әйтәлмим сүзләремне.
Зар-интизар булдым инде
Күрергә йөзләреңне.

Аһ җаныем Җамалым,
Кысма билем – янамын.
Кысма билем – яндырасың,
Ятларга калдырасың.

Уфаларда бер генә бит
Чын гарәбә төзүче.
Ах, җаныем, син генә бит
Эчләремне өзүче.

Алтын йөзек бирсәм иде,
Кигәнен күрсәм иде.
Хәләл җефетләрем булып,
Куеныма керсәң иде.

Урал тавын ташлы, диләр,
Ал, диләр, аның ташын.
Сагындыңмы, дип сорыйлар,
Күрмиләр күзнең яшен.

Агыйделгә басма салдым,
Кошлар йөзә алмагач.
Алдым каләм, яздым сәлам,
Сагынып түзә алмагач.

Беләзегем-йөзегем,
Кулъяулыгым-шәлләрем.
Дошман аерырга йөри,
Юк аерылыр хәлләрем.

Шәм яндырып эзләп алдым
Карурман имәннәрен.
Кайчан ишетермен икән
Кавышыйк дигәннәрең?

Уфа тараклары кирәк
Чәчләремне тарарга.
Кәртәчкеләреңне җибәр,
Сагынганда карарга.

Җилбер-җилбер җилләр исә,
Туздыра чәчләремне.
Исеңдәме, аерылганда
Түккән күз яшьләремне?

Аһ җаныем, без икебез
Савыттагы сөт кебек.
Синең өчен өзеләэчем
Нечкә тегәрҗеп кебек.

Иртә торып тышка чыксам,
Урап киләм су буен.
Әйтмәсәң дә, беләм, җаным,
Ташларга синең уең.

Иртә торып тышка чыксам,
Кар яуган көрәгемә.
Син җанымның гыйшыгыннан
Кан сауган йөрәгемә.

Кара бөдрә чәчләремне
Бөдрәләп үрер идем.
Әгәр мөмкин хәлләр булса,
Бер барып күрер идем.

Алма бакчасына кереп,
Югалттым эзләремне.
Мәхәббәтле яр икәнсең,
Саргайттың йөзләремне.

Базарларга барам, җаным,
Ал (ак) яулык алыр өчен.
Таһир үлгән Зөһрә өчен,
Мин үләрмен синең өчен.

Алларың булмый калсам,
Гөлләрең булмый калсам,
Алсын Ходаем җанымны
Ярларың булмый калсам.

Тәрәзәмне ябар идем,
Сандугачлар кунмаса.
Гомерлек дип сөяр идем,
Бүтән ярың булмаса.

Ак пирчәткә, күк пирчәткә,
Кешеләргә күрсәтмә.
Шушы хатны укып беткәч,
Яр булырга исәплә.

Тәрәзәсе матур икән,
Нурлар сибә гөлләре.
Инде безгә калды микән
Таһир-Зөһрә көннәре?

Алма бизәкләре төшкән,
Ахирәт, шәлләреңә.
Җаныкаем, нишлим икән
Бу гашыйк хәлләремә?

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Мәрфуга.
Йөгереп чыгып айга карыйм
Йөрәкләрем ярсуга.

Чәчемне үргәнем юк,
Үргәнне күргәнем юк.
Ничә айлар, ничә көннәр.
Мин сине күргәнем юк.

Өстемдәге күлмәгемнең
Уңды алсу бизәге.
Дошман сүзләренә карап,
Әллә күңелең бизәме?

Атың иярләдеңме?
Таең йөгәнләдеңме?
Җаныкаем, мин ташлар дип,
Ятка иярмәдеңме?

Көнгә каршы ялтырыйдыр
Җиләнеңнең тәңкәсе.
Ташламам, җаным, ташламам
Син әфлисүн чәчкәсен.

Алтын булавкалар кадыйм
Зәңгәрле күлмәгемә.
Кавышалмасам төшеп үләм
Зөбәрҗәт күлләренә.

Тәрәзәмдәге пәрдәнең
Җиргә төшкән аклыгы.
Беребез анда, беребез монда –
Юк дөньяның шатлыгы.

Гашыйк уты сүнәр микән,
Су буйларын буйласам?
Гашыйк ялкынында янып,
Башларымны җуймасам?

Урамнардан үтсәңче,
Үткәнеңне күрсәмче.
Шулкадәрле гыйшык тотып,
Сине алып үлсәмче.

Җаныкаем, бакчагызда
Кызыл гөлләр үсәме?
Җил артыннан сәлам әйтәм,
Җилләр сезгә исәме?

Аклы яулык – матур яулык,
Яраткан яулыккаем.
Яратмасам, сөймәс идем,
Яратам, җаныкаем.

Каш араларында миң бар,
Исемеңдә миң бармы?
Минем исләремдә син бар,
Синекендә мин бармы?

Уң як битеңдә дә миң бар,
Сул як битеңдә дә миң бар.
Минем күңелемдә син бар,
Синекендә мин бармы?

Өстемдәге күлмәгемне
Әллә куфталыйм микән?
Сагындым, күрәсем килә,
Әллә кош булыйм микән?

Безнең урам төз түгел,
Төзәтүче без түгел.
Җаным, ятларга карама,
Ятлар синң иш түгел.

Сандугачлар өзелеп сайрый
Ярты төннәр авышкач.
Хатка язып сүзләр бетмәс,
Сөйләшербез кавышкач.

Сандугачның балалары
Очып китә камыштан.
Җаным, әгәр кавышалмасак
Үлмәм микән сагыштан?

Аллар бирим мин сиңа,
Гөлләр бирим мин сиңа.
Алың түгел, гөлең түгел,
Ярың булыйм мин сиңа.

Сандугачлар килеп кунса,
Тал башлары бөгелә.
Былбыл хәлен былбыл белә,
Безнең хәлне кем белә?

Агыйделгә киез җәйдем,
Асыл бизәк төшереп.
Җаныкаем, хат яза күр,
Мине исеңә төшереп.

Җаныкаем, күлмәгеңне
Алга мандырасыңмы?
Сөеп-сөеп әллә, җанкай,
Ятка калдрасыңмы?

Алма бакчасына кердем,
Каен булгач кисмәдем.
Калдырма ят кулларда,
Ятлар өчен үсмәдем.

Беләзекләр коя микән
Уфадагы сәгатьче?
Әгәр башымны югалтсам,
Син булырсың сәбәпче.

Беләзекләр коя микән
Уфадагы зәркәнче (ювелир)?
Әгәр башымны югалтсам,
Син булырсың сәбәпче.

Сәгатьләрем төзәтер микән
Уфадагы сәгатьче?
Әгәр башымны югалтсам,
Син булырсың сәбәпче.

Мендем тауга, кистем каен,
Төядем атлар саен.
Сагынмыйм атна саен –
Сагынам атлаган саен.

*Яңгырчы авылында*
*Батталова Галия Миннегәрәй кызыннан (1951 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

* * *

Үтте дә китте яшьлегем,
Үткәнен дә тоймадым.
Йә үтмә дип, йә китмә дип,
Үзем бер дә тыймадым.

* * *

Аһ мин үзем гөлләр булсам,
Ал чәчәк атар идем.
Атлап түгел, яшьлегемә
Йөгереп кайтыр идем.

* * *

Ачарга да өлгермәде,
Чәчкәсен койды гөлем.
Ә шулай да чәчкә ат, ди
Таңнарда искән җилем.

### Уфтанма

Уфтанма гәмерләр яз кебек үтә дип,
Чал чәчең күрсәң дә уфтанма.
Яз килә дә китә, гомер шулай үтә,
Уфтанма, уфтанма, уфтанма.

Уфтанма синең бит ул үткән гомерең
Уйнап-көлеп кенә үтмәгән.
Безгә насыйп булган ак бәхет, зур шатлык,
Якты көннәр әле бетмәгән.

Биш бала үстердек, акыллы, матурлар,
Алар безнең өчен алтыннар.
Бәхетле-тәүфыйклы балалар үстереп,
Дәвамыбез булып калсыннар.

*Гөлем авылында*
*Сәхибгәрәева Әминә Миңнехан кызыннан (1940 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Сагындым сине, туган җирем
Кайтыр юллар әле төшмәгән.
Газиз әнкәемнең учагында
Мин ашыйсы ашлар пешмәгән.

Сагындым сине, туган җирем,
Кайтыр юллар әле төшмәгән.
Кошлар очып җитмәс җирдә
Ризыкларым әле бетмәгән.

*Хәлекәй авылында*
*Шәрипова Гадәния Низаметдин кызыннан (1937 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Мәхәббәтем язгы яшен кебек
Кинәт балкып, кинәт югалды.
Язын яшен суккан имән кебек
Миндә зур ярәхәт, ут калды.

Әллә ул мәхәббәт мәңге шулай
Сүнгән чәчкә кебек калырмы.
Әллә таңда сүнеп, кичен янган
Йолдыз кебек кабат янырмы, –

дигән ер барые.

* * *

Керерсең дип һәрчак өметләнәм,
Керми калсаң тәмам боегам.
Нигә гелән, иркәм, синдә генә икән,
Синдә генә икән күңелем.

* * *

Зәңгәр чәчкәләрне мин өзмәдем,
Алсу-асылларын эзләдем.
Хәтереңне саклап әйтмәсәм дә,
Бер сөярмен әле, түзмәмен.

Зәңгәр чәчкәләрне мин өзмәдем,
Алсуларын аның эзләдем.
Сөям-сөям диеп әйтмәсәң дә,
Сөюең, иркәм, сизәм мин.

*Әмир авылында*
*Мөрәсова Зөбәрҗәт Хөббрахман кызыннан (1934 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

**Төртмә җырлар**

Бәләкәйрәк булсаң:

Көтүдән кайткан тәкә,
Кеше буен үстергәндә
Нишләп яттың, бүтәкә?

Озын буйлы Мәрьям апага ерлыйлар:

Озын булып үскәнсең,
Озын булып үскәнсең дә
Кәкерәеп төшкәнсең.

Телеграм кисмәдем,
Утыр утырган ереңдә,
Синең өчен үсмәдем.

Зөфәр апага ерлыйлар:

Автомобиль гаражы,
Кешедән көлгән буласың,
Ишәк авыз, заразы.

Мин чыксам, миңа ерлыйлар:

Шикалат тараталар,
Такмак әйтергә белмиләр,
Биергә яраталар.

*Әмир авылында*
*Басырова Фәһимә Гаяз кызыннан (1942 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

**Бүләк**

Бүләк итеп чәчкәләр өзмәдем,
Мин сезгә иң матур ер эзләдем.
Ул ерны таптым туган илемнән,
Моңлы көй оттым тургай теленнән.

Кушымта:
Әйдәгез, дусларым, ерлыйк бергә,
Иң матур ерларны сайлап кына[2].
Яшик бу дөньяда сайрап кына.
Әллә лә лә лә лә лә лә лә лә.

Килдем сезгә Идел-диңгез кичеп,
Сезне сагынып, канатланып очып.
Кош канатлары түгел иңемдә,
Җыр канатлары минем күңлемдә.

Кушымта: шул ук.

* * *

Әй рәхәт, әй матур табында,
Тагын да дусларың янында.
Әй, рәхәт, әй кызык табында,
Тагын да сез, дуслар, янында.
Бер ямен күрмим мин табынның,
Әгәр сез булмасагыз янымда.

Саф чишмә суын эчәмен сусаган чагымда,
Чылтырап аккан саф чишмә суын

Эчәмен сусаган чагымда.
Бер тәмен тапмыйм мин суларның,
Әгәр сез булмасагыз янымда,

*Әмир авылында*
*Мөрәсова Зөбәрҗәт Хөббрахман кызыннан (1934 елгы),*
*Мөрәсова Мәрхәбә Гыйззәтулла кызыннан (1937 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Агыйделкәй алкын, суы салкын,
Дәрья суларыннан ким түгел.
Кешеләрдән кеше һич ким түгел,
Тик бәхеткәйләре тиң түгел.

* * *

Уфаларга бару белән
Кермәдем бакчаларга.
Яшь гомерне сатып алып
Булмый бит акчаларга.

* * *

Ник әйтмәскә бу айда?
Кара җир астына кергәч,
Кара җир астына кергәч,
Тапкан маллардан ни файда?

*Әмир авылында*
*Сәйфетдинова Гөлшәһәр Галиулла кызыннан (1936 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Уйна, дустым, гармуныңны,
Син матур уйнатасың.
Уйнатасың, ерлатасың,
Күңелне юатасың.

Гармунчының исемнәре
Гармун каешларында.
Булмасын сөйгән ярларың
Кояш баешларында.

* * *

«Беренче мәхәббәт» җырын җырлый.

* * *

Давыллардан оча алъяулыгым,
Ишкәйләрен кайдан табарга?
Яшьли сөйгән ярым калды ятка,
Әйтегезче, дуслар, нишләргә?

Аның йөрәгендә юксыну бар,
Сызланадыр төсле мәңгегә.
Ара ераклаша, тик тигәдер
Кавышырбыз төсле тоела.

Армиягә киткән чакта
Карадым күзләренә.
Юксыну утын тапмадым
Елмайган йөзләреңдә.

* * *

Кодакаем, сиңа әйтәм,
Болай таба карале.
Авыру башың сихәтләнер,
Шуны эчеп карале.

Эх, кодалар, сезнең белән
Күтәрелә күңелләр.
Күтәренке күңел белән
Үтсен алдагы көннәр.

Килдегез дә утырдыгыз,
Тамыр җәйдегезме әллә?

Ансын туй башланганда.

Килдегез дә утырдыгыз,
Фанер җәйдегезме әллә?
Кузгалмыйсыз да нитмисез,
Тамыр җәйдегезме әллә?

* * *

Йомшак кына җемелдиләр
Йолдызлар айлы кичтә.
Туган якның таң җилләре
Истә, һаман да истә.

Яктыра урман-кырлары
Сандугачлы яз җиткәч.
Туган якның зәңгәр күге
Истә, һаман да истә.
Туган якның яшел болыны
Истә, һаман да истә.

* * *

Айның яраткан йолдызы
Кереп бара болытка.
Гомер дә онытмам, дигән
Сүзләреңне онытма.
Утыр әле яннарыма,
Ял булсын яннарыма.
Син утырсаң яннарыма,
Ял була яннарыма.

*Әмир авылында*
*Нәфыйкова Гөлсем Мулләхмәт кызыннан (1952 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Карлугачкай кара, муены ала,
Ул һаваларга кереп югала.
Ир балалар китсә,
Аталардан яшьли калса,
Күкрәк көче белән мал таба.

Уй күтәрә күңелне,
Уй күтәрә күңелне,
Уй саргайта йөзеңне.
Уйлар күп ул, уйласаң,

Тиз диваналар булырсың,
Уйларыңны куймасаң.

*Әмир авылында*
*Галиева Гайникамал Һидиәтулла кызыннан (1912 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

**Ай-ли, Гөлмәрфуга**

Агыйделгә төшә яздым, төшә яздым,
Тотмадың беләгемнән, Мәрфуга...
Ай-ли Гөлмәрфуга, бар суга!
Гөлмәрфуга, барсаң суга,
Сөйләшербез барсын да.
Салкын чишмә суын эчсәң,
Янган йөрәк басыла.

Тамыр җәйгән гөлләр кебек, гөлләр кебек.
Чыкмыйсың йөрәгемнән, Мәрфуга...
Ай-ли Гөлмәрфуга, бар суга!
Гөлмәрфуга, барсаң суга,
Янган йөрәк басыла.
Салкын чишмә суын эчсәң,
Янган йөрәк басыла.

* * *

Кашкайларың синең бигрәк кара,
Карлыгачкай мае сөрттеңме?
Буй-сыннарың зифа, йөзең күркәм,
Бал-шикәрләр ашап үстеңме?

* * *

Кулыңны кесәмә тыксаң,
Кесәләрем канфитлы.
Кайда барсам, йөзем якты,
Туганнарым тәүфыйклы.

* * *

Укый торган китабымның
Уң ягында тәселе (кагыйдә).
Әмма ирләрнең иң асылы –
Шәриповлар нәселе, –

дип киявенә ерлап бирәйе.

* * *

Ишек алдым яшел чирәм,
Чирәм түгел сарымсак.
Без үзебез грамотный,
Хат язырбыз сагынсак.

* * *

Минем зур абый хатыны оста язайе.

Таш казарма буйларында
Йөри безнең башлыклар.
Бергә ашарга насыйп булсын
Сезнең чәчкән ашлыклар, –

хат саен 1–2 ер язайе.

* * *

Егет алып китә кызны. Шунда киленнең җиңгәләре тегене нитәләр инде – чеңнәү diләр инде:

Кизелкәй шаршау яшел читле,
Кор дисәң дә, корма, әңкәем.
Бер вакытлар җиткәч,
Атлар җиккәч,
Тор дисәң дә, тормам, әңкәем.

Әтисенә дә атап әйтә инде. Мин татар. Минем бабайлар да татар булган.

* * *

Уфа тараклары кирәк
Чәчләремне тарарга.

Безнең кулдан килер микән
Кодагый, сезгә ярарга, –

дип кодагыйга ерлап бирәсең.

*Карагош авылында*
*Табаева Әминә Мөхсин кызыннан (1930 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Ераклардан җәелеп ята
Безнең авыл иген-кырлары.
Шул кырларда тырышып эшли
Безнең якның уңган кызлары.
Зил, зил, җилләр исә, Зиләйлүк,
Зиләйлүкнең биле нәзек, биле нәзек,
Зиләйлүкнең беләгендә беләзек.

Алма бөреле, алма бөреле, җаныем,
Алмалар бөреле була ул.
Җан яраткан, күңелем тарткан
Яр бер генә була ул, җаныем.
Зил, зил, җилләр исә, Зиләйлүк,
Зиләйлүкнең биле нәзек, биле нәзек,
Зиләйлүкнең беләгендә беләзек.

*Карагош авылында*
*Мортазин Наил Гыйбадрахман улыннан (1956 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Колхозлашкан елларда:

Колхозникалар эшкә бара
Бричкага төялеп.
Аерымнар карап кала
Читәненә сөялеп.

Кайсы керә колхозга, кайсы керми. Колхозга кергәннәре белән кермәгәннәре сүз көрәштереп ерлашалар.

Бригадир эшкә әйтә,
Кая чабаталарың?

Кая кашык, кая катык,
Кая катламаларың?

Ә мынсы сугыш чыккач, ирләр китеп бетте, егетләр китеп бетте, самый җәйге кызу эш вакытлары бит инде. Июнь айлары. Печән өсте, апалар, җиңгиләр, егетләре киткән апалар, ирләре сугышка киткән җиңгиләр, без – яшүсмерләр, шуларга ияреп, эшкә йөрибез. Бричкага төялеп кайтып киләбез. Ерлыйлар теге ятим калган апалар, җиңгиләр:

Сандугач талларга куна
Без кая сөяләек?

*Бакча авылында*
*Тимербулатова Миңниса Минневәли кызыннан (1924 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Сандугачым-былбылым,
Кичә кайларда булдың?
Уф, дигән тыннарым белән
Тартып алырдай булдым.

* * *

Үзең гармунчы егетсең,
Кулыңда көмеш йөзек.
Төшсәң дә Байкал күленә,
Төшеп алырмын йөзеп.

* * *

Оча, оча, оча, оча,
Оча ком бураннары.
Без киткәч тә, тынар әле
Бакчаның урамнары.

* * *

Военкомат янса иде
Комиссарлары белән.
Армиягә китсәң иде
Сөйгән ярларың белән.

Без яшь чакта шулай урамда ерлыйдырыек.

Капканы зәңгәрләгәннәр,
Ишекне зәңгәрләгәннәр.
Мәрьямне Ибәткә биргәннәр,
Нигә җәлләмгәннәр?

Безнең Ибәт белән Мәрьям булгандырмы?

Мәрьям исемле кыз кем белә(н) йөргән соң әле ул? Пары белән. Аннан икенче бер егеткә кияүгә биргәннәр. Картинәсендә үскән бер кыз, шуның турында ул ер.

* * *

Гөр-гөр,
Гәрәй кайнага – га-га.
Үзенә өйләр салдырдың,
Миңа дигән өй кая-я-я?

* * *

Дусларның бар төрлесе,
Дусларның бар төрлесе.
Дусларның да бар төрлесе,
Син бит саф күңеллесе.

Их, дускаем, сөям сине,
Сүрелмәс булсаң гына.
Базга төшеп катыкка, майга
Үрелмәс булсаң гына.

* * *

Әңкәң сине тугачтын да
Ак биләүгә биләгән.
Ак биләүләргә биләгән,
Депутат бул димәгән,
Бәхетле бул димәгән,
Министр бул димәгән,
Директор бул димәгән.

* * *

Язгы тамчы тамган чакта
Тамчы буласым килә.
Тамчы булып керфегеңә
Тамып торасым килә.

Язгы җилләр искән чакта
Мин җил буласым килә.
Мин җил булып чәчләреңнән
Сыйпап үтәсем килә.

* * *

Ничек килдегез сез безгә,
Төшмәенчә диңгезгә?
Кадерле кунак сез безгә,
Ни хөрмәт итим сезгә?

*Бакча авылында*
*Рысаева Минзия Мөдәррис кызыннан (1959 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Кара бөдрә чәчләремне
Таратасым килмидер.
Эчем ялкын, тышым салкын,
Белдерәсем килмидер.

Әкрен барчы, әкрен барчы,
Безнең яннан узганчы.
Карап калыйм син дустымны
Ике күзем туйганчы.

* * *

Һавалардан очып килә
Күгәрчен көтүләре.
Әле дә булса күз алдымда
Кул биреп китүләре.

Исеңдәме, киткән чакта
Кулларыңны биргәнең.

Моңсу карап күзләремә
Кит, онытма! дигәнең.

* * *

Зөя сулары бик тирән,
Карап күзләрем тала.
Хатка язып сүзләр бетми,
Сөйләшергә дә кала.

* * *

Яллар итә-итә мендем
Янгантау баскычларын.
Әллә ниләр бирер идем
Сине бер күрер өчен.

Янгантау баскычларыннан
Эзләремне эзләдем.
Син киткән якларга карап,
Талды инде күзләрем.

**Авыл көе**

Бара торгач бер утырдым
Биек тау билләренә.
Без түгел, кошлар талпына
Кайтырга илләренә.

Карагайлы карурманны
Узар көннәр булырмы?
Каршы чыгып, кул бирешеп,
Күрешер көннәр булырмы?

Сахраларга чыктым исә
Ал чәчкәләргә карыйм.
Ал чәчкәләр сезнең кебек,
Алып түшемә кадыйм.

*Бузат авылында*
*Булатов Фәрит Гыйлемҗан улыннан (1955 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Ак пароход агып килә
Агыйдел буйлап кына.
Гомерләр үтә инде
Гел сезне уйлап кына.

Ак дулкыннар очрашалар
Агыйдел ярларында.
Гомерең буе булса идең
Гел генә яннарымда.

*Бузат авылында*
*Гобәйдуллина Миңсылу Нуретдин кызыннан (1934 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

* * *

Чүт, чүт, чүт, чүт
Сайрый сары сандугач.
Җырлау түгел, еларсың да
Бик өзелеп сагынгач.

* * *

Җилән атым кая бардың?
Су тама ялларыңнан.
Бер дә җибәрәселәрем
Килми күз алларымнан.

*Бузат авылында*
*Гарифулллина Флүрә Мансур кызыннан (1945 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

«Наза»лы уйнаганда «Су буйлап»ны, «Уфа»ны ерлыйларые.

Уфа тавы күренеп тора
Сызлып таңнар атканда.
Сөю уты сүрелмәсен
Гашыйк булган җаннарда.

Уфа кайда, Уфа кайда?
Уфа биек тауларда.
Язмыш бәндә балаларын
Йөртә әллә кайларда.

Уфа тавы биек булгач,
Менәлмим алларыннан.
Язмыш җиле аермасын
Парларны ярларыннан.

Җиделе лампа асмалы,
Унлысы басылмалы.
Сезне күреп сөйләшмичә,
Күңелем басылмады.

* * *

Алмагачларым куерды,
Кошлар үтәрлек түгел.
Язып түгел, сөйләшеп тә
Сүзләр бетәрлек түгел.

Алмагачка җимнәр куйдым,
Сандугачлар кунсын дип.
Син дустымны сагынып сөйлим,
Сагынып искә алсын дип.

Алмагачка менмәс идем,
Белмәдем бөгеләсен.
Аралар ераклашалар,
Күңелләр сүрелмәсен.

«Наласа»ны ерлыйларые. Без үскән вакытта «Озата барма», «Сарман», «Раушания»лар(ны).

*Яшерган авылында*
*Мухтаруллин Һидиятулла Ибәтулла улыннан (1942 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Син ант иттең, вәгъдә бирдең
Гомерлеккә яр булырмын дип.
Арыган, талган чакларымда
Йөрәгеңә ял булырмын дип.

Ник соң, иркәм, биргән вәгъдәң
Очып китте искән җил сыман?

Ә мин ялгыз боегып калдым,
Яфракларын койган җил сыман.

* * *

Җиделе лампалы асмалы,
Унлысы басылмалы.
Сезне күреп сөйләшмичә,
Йөрәгем басылмады.

Җидегән йолдыз
Җиде әйләнә
Җиде төн уртасында.
Җидегән йолдыз нурлары
Бар йөзеңнең уртасында.

* * *

Кызыл-кызыл бөрлегән
Юл буена тезелгән.
Булмас инде сезнең кебек
Минем өчен өзелгән.

Уфа юллары – пыяла,
Таш булса – таймас иде.
Минем йөрәкләрем яна,
Сез булсагыз янмас иде.

Су буенда бөдрә чәчең юарсың,
Син юарсың, мин ерлармын,
Күңлең тулса – еларсың.

* * *

Биек тауга менимме,
Агым суга керимме,
Дусларыма сөйлим микән,
Үзем генә белимме?

Таулар текә, су тирән,
Тирән булса да керәм.

Ерак икәнен дә беләм,
Нигәдер якын күрәм.

* * *

Хәмдиянең ак калфагы,
Яңа каралган чагы.
Хәмдиягә сүз әйтмәгез,
Зиһене таралган чагы.

* * *

Килдем сезгә Идел-диңгез кичеп,
Кошлар булып канатланып очып.
Кош канатлары түгел иңемдә,
Җыр канатлары минем күңлемдә.

Әйдәгез, дусларым, җырлыйк бергә,
Иң матур җырларны сайлап кына.
Иң матур җырларны сайлап кына,
Яшик бу дөньяда сайрап кына.

* * *

Һаваларда ак юл сызып
Самолет очса,
Бәхетле елмаеп ана
Баласын кочса,
Дуслар гөрләшеп утырса,
Табын түрендә, –
Тибрәлә җыр дулкыннары
Минем күңлемдә.

Сыерчыклар язын кайтып,
Оясын корса,
Бакчаларда алмагачлар
Шау чәчәк атса,
Кояш көлсә, ай елмайса
Илем күгендә, –
Тибрәлә җыр дулкыннары
Минем күңлемдә.

* * *

Өстәлдәге матур көзге
Күзләрне чагылдыра.
Үтеп киткәч «саубул», дигән
Сүзләре сагындыра
Әй, өй түбәсе дыранча,
Давыл чыкса җил ача.

*Яшерган авылында*
*Гобәйдуллина Флүрә Ибәтулла кызыннан (1946 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

* * *

Ташлап киттең мине җәлләмичә,
Калдырып кайгыларда.
Күкләр биек, юк баскычлар
Сагынганда карарга.

* * *

Ай янында якты йолдыз, –
Минем йолдызым гына.
Таң алдыннан ул да сүнә,
Калам ялгызым гына.

* * *

Уйлап эшләрмен дип
Уйлыйм да, ул
Килер микән минем кулымнан.

* * *

Челтәр күпер тактасын
Җиз дагалы ат таптый.
Сулар булып агар идем,
Су сезнең якка акмый.

* * *

Җиңел генә йомшак мамык шәлне
Җилкеп иңнәреңә саласың.

Сокландыргыч шушы гүзәллекне
(Зөбәрҗәт) әйтче сылу, кайдан аласың?

Табигатьнең бөтен гүзәллеген
Сыйдра алгансың син үзеңә.
Күзләреңдә булса күл серләре,
Ай нурлары балкый йөзеңдә.

Тәтер суның көмеш дулкынында
Озын толымнарың югансың.
Уңганлыгың, сабырлыгың (сылулыгың) белән
Илне бизәр өчен тугансың.

* * *

Җирән атым, кайдан кайттың?
Тир тама ялларыңнан.
Һич тә җибәрәсем килми
Сине күз алларымнан.

* * *

Шиңгән гөлгә күбәләкләр кунмый шул инде,
Үткәннәргә кире кайтып булмый шул инде.
Ник кенә утырдым икән ялгыз җилкәнгә,
Ник очрадың (икән) тормышымның көзе җиткәндә.

* * *

Әрәмәсе аша үтәм,
Шомыртын авыз итәм.
Китүемә күп тә түгел,
Кабат кайтуны көтәм.

Кушымта:
Тәтер буер әрәмәлек,
Анда сайрый сандугач.
Әйләнәм дә шунда кайтам,
Өзелеп-өзелеп сагынгач.

Чишмәсенә йөгереп төшәм,
Учлап суларын эчәм.
Ташларына бераз басып,
Кошлар белән серләшәм.

Кушымта: шул ук.

* * *

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр ал алма.
Абын-сөртен, тор да җөгер,
Сөйгән ярыңнан калма.

* * *

Күгәрченем күгелкәем,
Җиргә төшә җимешем.
Сез кадерле кода безгә,
Без ничек сезнең өчен?

* * *

Җырчысын сагынып каен
Көтеп ала май аен.
Ник булмадык икән без дә
Син сандугач, мин каен?

Алар бездән бәхетлеләр,
Очрашалар таң саен.
Ялгыз җанымны яндырма,
Очрашаек, тап җаен.

* * *

Сандугачлар гына кайда сайрый?
Сарман буйларында тирәктә.
Сиңа булган яшьлек мәхәббәтем
Үреләп чәчәк ата йөрәктә.

Сарман буйларына кайткан чакта
Тыңларсыңмы, җырлар җырласам.
Күзләреңне тутырып карарсыңмы,
Зәңгәр яулык таудан болгасам.

Сарман буйлалары – киң ялан,
Печәннәрен чабарга барам.
Бергә яшәүләре ай күңелле,
Әмма аерылышулар яман.

Сарман буйларында тау битендә
Йөридерләр елкы көтүе.
Йокыларда күргән бер төш сыман
Бу гомеркәйләрнең үтүе.

* * *

Бер дә юкка гына үпкәләп,
Син булмагач янда,
Күңел юксынганда,
Кем юатыр мине иркәләп.

* * *

Сандугачым-былбылым,
Кичен кайларда булдың?
Ямансу, тыннарым белән
Тартып алырдай булдым.

* * *

Кара кәстүмеңне кисәң,
Кысып тора билләрең.
Сине кемнәр сөймәсеннәр,
Юк килмәгән җирләрең.

*Тәтер-Арслан авылында*
*Мөхәммәтшина Әнвәрә Хәмәтһади кызыннан (1941 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Син утырткан муел
Чәчкә атты быел,
Ак яулыгын салып иңенә.
Чәчкәләрен үземә... (өзмимен),
Назлап кына иснимен,
Юк назларга бергә син генә.

Син утырткан муел
Бөреләрен быел
Күтәрәлмәс кебек тоела.
Сагынуларым бик көчле,
Синсез ул сүнәр төсле,
Кайтмый калсаң әгәр быел да.

Син утырткан муел
Җимеш бирер быел,
Кем белән соң авыз итәрмен?
Синнән башка ямь тапмам,
Синнән баш тәм тапмам,
Кайтмый калсаң быел да.
(Гомерем буе сине көтәрмен)

* * *

Ерламый түзеп буламы,
Кулда гармун булганда?
Яшьли сөйгән ярларымны
Калдырмадым ятларга.

* * *

Яшь чагымда аулак өйдә,
Уеннарда баш идем.
Гармун тарта белгән өчен,
Күз өстендә каш идем.

* * *

Җилләр исә, гөлләр үсә,
Иркәләп сулар сипсәң.

Өзелә үзәк, яна йөрәк,
Яшь чаклар искә төшсә.

*Тәтер-Арслан авылында*
*Усманов Миңнебәк Мәҗит улыннан (1948 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

* * *

Сусыз далаларда әгәр очыратсам,
Синең яннарыңа килермен.
Бер йотымлык сулар таба алсам,
Үзем эчмәм, сезгә бирермен.

* * *

Башкортлар базык була,
Татарлар нәзек була.
Башкорт кызын суырып үпсәң,
Бер көннек азык була.

* * *

Зәңгәр һава, зәңгәр болыт
Зәңгәрләтә җир шарын.
Гомерем булса онытмамын
Җир шарында сез барын.

Ала дуга да дуга,
Кола дуга да дуга.
Өстә ничек кием туза,
Яшь гомер шулай уза.

* * *

Ничек килдегез сез безгә
Төшмәенчә диңгезгә?
Кадерле кунак сез безгә,
Ни хөрмәт итик сезгә?

* * *

Җыйдым җиләк, җыйдым җиләк,
Җыйдым да кабалмадым.
Сезгә (сиңа) охшаган алсу чәчәк
Эзләдем – табалмадым.

* * *

Алга баруларым бару,
Җиз еланнар чакса да.
Гөлләр сездән артык түгел,
Ал чәчкәләр атса да.

* * *

Зур йортларга ямнәр керми,
Зәңгәр чаршау кормыйча.
Йөрегәмнең уртасында
Торырсыз онытылмыйча.

* * *

Каз канатларын санадым
Тезелеп кагынганда.
Инде кемнәргә карармын
Өзелеп сагынганда.

* * *

Эх, кодалар, кодалар,
Кодалар-кодачалар.
Сездә ничек, бездә шулай
Ерлап күңел ачалар.

* * *

Утырыйк әле төнозын,
Утырыйк әле көнозын.
Көннәр озын, төннәр озын,
Күреп туялмый күзем.

* * *

Болай димә син миңа,
Алай димә син миңа.
Авыр сүзләр әйтмә миңа,
Мин ятлар түгел сиңа.

* * *

Иркәм, алай дисеңме,
Иркәм, болай дисеңме?
Син дә шулай минем кебек
Уф йөрәгем, дисеңме?

* * *

Матурсың син, чибәрсең син,
Кимә бүтән күлмәгеңне,
Күз тиеп үләрсең син.

*Тәтер-Арслан авылында*
*Садретдинова Миннур Сәбәхетдин кызыннан (1938 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Һайт! дигән чагында,
Тайт! дигән чагында,
Ирең пчеловод булсын
Дөнья көткән чагында.

Җыйдым җиләк
Бөрлегәннәре белән.
Без яшәйбез дус-ишләрнең
Бер дигәннәре белән.

* * *

Нигә бәреләләр икән
Болытларга болытлар?
Нигә тиз үтәләр икән
Бу кадерле минутлар?

Агыйдел буйларын
Буйлыйм да буйламыйм да
Булмас инде сезнең кебек,
Булыр дип уйламыйм да.

Нигә бәреләләр икән
Болытларга болытлар?
Нигә тиз үтәләр икән
Бу кадерле минутлар?

Агыйдел күпере
Чуен белән чылтырый.
Каш астында ике күзең
Энҗе кебек елтырай.

* * *

Алма бакчасына чыгып,
Алмага үрелдеңме әллә?
Матурлык өләшкән чакта
Алдан йөгердеңме әллә?

* * *

Алмагачның алмалары
Тәрәзәләргә туры.
Әллә сезгә биререлгәнме
Бөтен дөньяның нуры?

* * *

Гармуннар уйный beләсең,
Маладис кулларыңа.
Исле гөлләр чәчәк атсын
Йөрегән юлларыңа.

*Тәтер-Арслан авылында*
*Шәрипова Миннур Гыйләҗетдин кызыннан (1933 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Ап-ак карны шыгырдатып
Атлый бәхетле парлар.
Нигә соң бергә булмыйлар, булмыйлар
Өзелеп сөйгән ярлар?

Алтын алкамны югалттым,
Табырмын микән алка?
Булырсың микән үземә, үземә,
Калырсың микән ятка?

Болындагы чәчкәләрне
Таптамам дигән идем.
Өзелеп сөйгән ярымны
Ташламам дигән идем.

Болындагы чәчкәләрне
Таптарга туры килде.
Өзелеп сөйгән ярымны
Ташларга туры килде.

Агыйделнең аръягында
Памидур түтәлләре.
Без бит әле яшь бит әле, бит әле,
Бер-ике ел көт әле.

*Айдарәле авылында*
*Хәбибуллина Гөлшат Гыйбадрахман кызыннан (1962 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Кара урман эчләрендә
Әңкәйемнең кабере.
Ятим калган кыз баланың
Елап тибә бәгыре.

Карурманга килгән идем,
Әңкәй каберен күрергә.
Газиз җаным шунда алына,
Инде кайтмыйм кирегә.

Кара урман эчләрендә
Сандугачлар сайраша.
Әңкәем кабере өстендә
Җиттем соңгы сулышка.

Бу «Әңкәй каберендә» дигән пьеса иде. Районга бардык без аның белән. Бу – пьесадагы ер.

* * *

Алмагачларым куйыра,
Кошлар үтәрлек түгел.
Язып түгел, сөйләшеп тә
Сүзем бетәрлек түгел.

Алмагачка җимнәр куйдым,
Сандугачлар кунсын дип.
Сез дусларга җырлар җырлыйм,
Сагынып искә алсын дип.

Алмагачка менмәс идем,
Белмәдем бөгеләсен.
Аралар ерак булса да,
Күңелләр сүрелмәсен.

* * *

Кар сулары бетте,
Яр сулары үтте,
Ташулар тәгәрәми ташкында.
Минем генә йөрәк
Кавышуны теләп,
Бәйдәге аттай сиңа ашкына.
Арта һаман уйлар,
Төртә сиңа табан,
Кыен миңа ялгыз чакларда.
Сөенечкә дисәм, көенечкә икән,
Күрешүләр сезнең якларда.

## Янар чәчәк

Нинди матур озын юлга чыктым,
Янар чәчәк иде юл башым.
Чәчәк сулган, синең йөрәгеңә
Ниләр булды, яшьлек юлдашым?

Ул чәчәкне өзеп кадар өчен,
Тугайларга эзләп барма син.
Син эзләмә аны, үз йөрәгем
Янар чәчәк булып кабынсын.

Мин югалттым янар чәчәгемне,
Күзләр җиткән, эзлим, табалмыйм;
Ут як минем ярсу йөрәгемә,
Синнән башка сүнәм, яналмыйм.

## Торналар

Күл карап озатты
Торналар китүен.
Сагынып көтә ул
Кабат яз җитүен.

Чылбырдай тезелеп
Кайтыгыз, торналар,
Бу күлдәй камышлы
Гүзәл күл кайда бар?

Йөрмәгез боегып,
Каңгырып чит илдә.
Оялар корырсыз
Яңадан шул күлдә.

Туган як күге киң,
Күңелләр күлдәй киң.
Туган ил тормышы
Шул гүзәл күлгә тиң.

## Пар юкә

Бакча уртасында пар юкә,
Күңелемдә сиңа бар үпкә.
Сүз куештык кичтән,
Син оныттың иртән,
Очрашмадык аннан без бүтән.

Чәчәк исе мәңге бөркелә,
Кыз елмайса, егет биш көлә.
Чәчәгем күрергә, пар юкә төбенә
Ялгызым килдем мин бүген дә.

Пар юкәбез тора гел бергә,
Ник тормадың, егет, сүзеңдә?
Сөйсәң сөй гомергә,
Яр була бер генә,
Сөймә, егет, алай бер көнгә.

## Вәгъдә

Гашыйк булган яшь егеткә
Дөньяда керсез күңел,
Саф мәхәббәт, хис кирәк.

Яшьтән өзелеп сөйгән ярың
Үз вәгъдәсен үзе бозгач,
Газапланып әрни яшь йөрәк.

Вәгъдә биргәч, кирәк иде көтәргә,
Нигә инде хыянәт итәргә?
Зәйтүнгөл чәчкәсе кебек
Яшьтән сөйгән үз ярыңны
Нигә инде ялгыз итәргә?

* * *

Алма бөреле, алма бөреле,
Алма чәчкәсе төрле.
Башкаларга күз салмыймын
Сине күргәннән бирле.

*Кушымта.*

Ай, алмагачлары,
Сайрый сандугачлары.

Алма бакчасына керсәм –
Бадъян түтәлләре.
Ал булса да, гөл булса да,
Кирәкми бүтәннәре.

* * *

Буй-сыннарың бигрәк матур,
Исемнәрең Габделхәй.
Кашың кара, буең зифа,
Күзең йолдыз, йөзең ал.

*Кушымта:*

Бөгеләдер, сыгыладыр beləгең,
Өзеләдер синең өчен үзәгем.
Матурлыгың, чаянлыгың сөйдерә,
Уңганлыгың өчен үзәк өзелә.

Кара костюмыңны кисәң,
Кысып тора билләрең.
Сине кемнәр сөймәсен соң,
Юк килмәгән җирләрең.

*Кушымта.*

**Һаман яратам**

Шик туса кинәт күңлеңдә әгәр,
Я килсә сиңа куркыныч хәбәр
Мин йөргән яктан, ерак-ерактан,
Ышана күрмә, – һаман яратам.
Ашыга күрмә, ялгыштан саклан, –
Һаман яратам, һаман яратам.

Кояшлы аяз күгеңне әгәр
Кара болытлар каплап китсәләр,
Каршы искән җил капланса тынга,
Нык бул, син генә, тик син җанымда!
Бирешә күрмә сагышка, моңга,
Җанымда тик син, тик син янымда.

Сакла сөюне, таптама берүк,
Олы хисләрне ташлама берүк!
Узар гомерләр аккан су кебек,
Яшәү бер генә, сөю мәңгелек
Узар гомерләр искән җил кебек,
Сөю мәңгелек, сөю мәңгелек!

*Айдарәле авылында*
*Юсупова Сәгүрә Зәйнулла кызыннан (1929 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

**«Әрәм буласым килми»**

Түбән очтан яучы килгән,
Мине кияүгә димли.
Синнән башкаларга карап,
Әрәм буласым килми.

*Кушымта:*
Ай иркәм, вай иркәм,
Кайчан кавышырбыз икән?
Алма кебек матур чагым,
Күпме көтәргә тагын?
(Сиңа кем кирәк тагын?)

* * *

Дуслар мине үгетлиләр:
Алам дисә – бар, диләр.
Бөтен Башкортстанда юк
Сезнең кебек пар диләр.

*Кушымта:*
Ай иркәм, вай иркәм,
Кайчан кавышырбыз икән?
Алма кебек матур чагым,
Күпме көтәргә тагын?

**«Агымсу»**

Агымсуның буйларында
Матур кырлар, болыннар.
Шул кырларда тырышып эшли
Безнең дуслар, туганнар.

Акчарлаклар очып уйный
Агымсу өсләрендә.
Иртән истә, кичен төштә,
Чыкмыйсың исләремнән.

Ага сулар, ага сулар,
Ага сулар гел шулай.
Аккан сулар кире кайтмый,
Яшь гомерләр дә шулай.

* * *

Сандугачлар кунып сайрый
Су эчәргә талларга.
Иртән торсам, хат көтәмен
Син дустым тарафынннан.

Аллар үсә, гөлләр үсә
Идел буе – тугайда.
Сагынмас кешеләр булмас,
Сагынсаң да түз әйдә.

Минем иркәм бар иде,
Үзем белән пар иде.
Сөйләшеп тә туймый торган
Чакларыбыз бар иде.

Агыйделнең буйларын
Буйлыйм да, буйламыйм да.
Булмас инде синең кебек,
Булыр дип уйламыйм да.

Ай-ли дусларым,
Ай дус-ишләрем,
Китте иркәм еракларга,
Инде нишләрмен?

Ай-ли, дусларым,
Ай, дус-ишләрем.
Сабыр итмәдем,
Инде нишләрмен?

Итек киюләреңә,
Читек киюләреңә.
Бик исләрем китми әле
Ятны сөюләреңә.

Иртән торып тышка чыксам,
Кошлар сайрый усакта.
Төрле-төрле кошлар сайрый,
Сагындыра шул чакта.

Агыйделнең аръягында
Ай кергән болытларга.
Ай кермәгән болытларга,
Мин кергәнмен утларга.

Дулкынында чайкалып йөзә
Агыйделдә параход.
Мәңге сүнмәс утлар булмас,
Сүнәр әле бервакыт.

Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Җырлыйк әле күп итеп.
Бергә булган вакытларны
Сагынып сөйләрлек итеп.

**Әй гүзәлем**

Әй гүзәлем, камышлы күл –
Шул бит безнең су юлы.
Озата барсам, кеше күрер,
Хуш, исән бул, җанашым.

Әллә нигә бик яратам
Гүзәлем дип җырларга.
Җырлар җырлыйм, уйлар уйлыйм (…)
Төшәмен тирән уйларга.

Әй гүзәлем, камышлы күл –
Шул бит безнең су юлы.
Кара кашым, сандугачым,
Бик сагындым бу юлы.

(…) Агымсуларга карыйм да
Төшәм тирән уйларга.

* * *

Сагынганда ак болытка кара
Ак болытлар булып мин киләм.
Шыбыр-шыбыр яңгыр ява, димә,
Күз яшьләре булып мин тамам.

Сагынганда ак буранга кара,
Ак бураннар булып мин явам.
Ак бураннар адаштыра, димә,
Адаштырам сине мин һаман.

Сагынганда ак диңгезгә кара,
Ак диңгезләр булып мин агам.

Ярларына дулкын кага, димә,
Йөрәгеңә килеп мин кагам.

*Бакый авылында*
*Баһаветдинова Әлфия Зәйни кызыннан (1952 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

* * *

Безнең урам түбән таба,
Таш булса, таймас иде.
Ике күзем күреп туйса,
Йөрәгем янмас иде.

Эх, метро, метро, метро,
Бер утыру ни тора,
Эх, метрополитин,
Сагынам ни хәл итим?
Сагынуларга юк чаралар,
Ерак булгач аралар.

Син дә кара каш идең,
Мин дә кара каш идем.
Син ятларга карамасаң,
Мин дә карамас идем.

Эх, метро, метро, метро
Бер утыру ни тора.
Эх, метрополитин,
Сагынам ни хәл итим.
Эх, татар мынчасы,
Көн дә шулай булсачы.

Кодалар-кодачалар,
Сезгә ничек, бездә шулай
Ерлап күңел ачалар.

Эх, метро, метро, метро
Бер утыру ни тора.
Биш сумыңны түләмәсәң,
Кысып кирәкне бирә.

* * *

Тәрәзәңә килгәнсең,
Өстең-башың алама.
Бар, базардан җеп алып кайт,
Өстең-башың ямарга.

Алам-салам егитләргә ерлыйдырыек.

* * *

Хәтерлә син минем карашымны,
Хәтерлә син ничек тын алам.
Синең серле кара күзләреңне
Бер күзгә дә, бер дә алмашмам.

Аерылабыз дигән шомлы уйлар
Килмәсеннәр синең башыңа.
Син кайтканда алсу чәчәк тотып,
Мин чыгармын синең каршыңа.

* * *

Одеал ябынасыңмы,
Юрган ябынасыңмы,
Одеал асларында
Мине сагынасыңмы.

Одеал да юк монда,
Юрганнар да юк монда.
Шатыр-шотыр пуля ява,
Синең кайгы юк монда.

*Стәрлебаш авылында*
*Шәмсетдинова Зөбәрҗәт Хаҗи кызыннан (1931 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## БАЛАЛАР ФОЛЬКЛОРЫ

Аллаһу-Аллаһу, кәҗәләрне тауга ку,
Аллаһу-Аллаһу, сыерны көтүгә ку.
Әлли-бәлли итәр ул,
Йоклап кына китәр ул,

Зур кыз булып үсәр ул,
Укуларга китәр ул.
Әллүки-бәллүки –
Бәләкәй чактагы көй.
Минем кызым бик матур,
Үскәч зур кеше булыр ул.
Еракларга китә ул,
Ерлап йокыга китәр.
Әллүки-бәллүки –
Бәләкәй чактагы көй, –

дип тирбәтә ием. Әниләрен дә шулай йоклата ием.

*Куганакбаш авылында*
*Ишбулдина Мөзәлифә Корбангали кызыннан (1940 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Чәүкә, чыпчык, син кал, бу чык
Әке-бәке, ышкылаган сәке.

*Куганакбаш авылында*
*Яхина Хәкимә Тимерхан кызыннан (1961 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Минем иремнең әнисенең кызы үлгәч, имә торган 6 айлык баласы калган. Аны да караган. Шуннан 1,5 яшькә җиткәч, кызамык чыгып үлде диде ул бала. Шул баланы юатканда.

Әлли-бәлли бәбкәсе,
Кая киткән әңкәсе?
Таш имчәкле, ком сөтле,
Үлеп киткән әңкәсе,
Елап калган бәбкәсе.

* * *

Балам, алтыным,
Алтыным һәм күз нурым.
Ил каршында ир былып,
Батыр булып үс улым.

* * *

Бишек җыры көенә җырлый.

Минем улым армиядә
Озын-озын атлыйдыр.
Кулларында винтовкасы
Туган илне саклыйдыр.

* * *

Баш бармак,
Имән бармак,
Урта бармак,
Чүрәкәй үрдәк,
Чум да чык.

*Карагош авылында*
*Табаева Әминә Мөхсин кызыннан (1930 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Менә шулай,
Үтте гомерләр,
Янып бетте күмерләр,
Көлләрен чыгарып түгерләр,
Бидрасын алып кергәч,
Рәхмәт, дип кочаклап үберләр.

* * *

Әтәч менгән киртәгә,
Сикереп үтәргә.
Әтәчкә повестка килгән
Армиягә китәргә.
Әтәч әйтә:
– Бармыйм, – ди.
Тавык әйтә:
– Калмыйм, – ди.
Син армиягә китсәң,
Мин бер күкәй дә салмыйм, – ди.

* * *

Иртән торып тышка чыксам,
Каргалар кар көриләр.
Таң алдыннан (Тал артыннан) килеп чыксам,
Гармун уйный бүреләр.

Бер карт сарык гармун уйный,
Сарманай көйләренә.
Бер ат белән кәҗә бии
Картайган көннәрендә.

*Стәрлебаш авылында*
*Дәүләтшшин Альберт Рәхми улыннан (1944 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

* * *

Әлли-бәү, бәлли-бәү,
Йокла, балам, йом күзең.
Син бит минем күз нурым,
Изүендә тәңкәсе, авызында маңкасы,
Әлли бәү-бәү-бәү.

*Стәрлебаш авылында*
*Шәмсетдинова Зөбәрҗәт Хаҗи кызыннан (1931 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## ХАЛЫК СҮЗЛӘРЕ, ПАРЕМИЯЛӘР

Тулган айларга карап теләгез балаларыгызга теләкләрегезне.

*Куганакбаш авылында*
*Ишбулдина Мөзәлифә Корбангали кызыннан (1940 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Ир икмәге irekле, чәйләре дә чирекле.

* * *

Бала кулына калганчы – иргә барганың әйбәт.

*Куганакбаш авылында*
*Ягафарова Рәхилә Низаметдин кызыннан (1936 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды.*

Ирнең хакы нык зур. Ирләрне нык хөрмәт итәргә кирәк.

*Яңгырчы авылында*
*Тимербакова Мөнирә Миңнегали кызыннан (1944 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Олы кешеләр элек әйткән, борынгылар:

«Андызлы җирдә ат үлми» дип. Атлар чирләсә терелми бит, сыерлар терелә.

* * *

Кемгә нәрсә – тимер кашыгыгыз.

* * *

Көрәк белән киткән бер дә кайтмый.

*Өч-Әсән авылында*
*Гафиатуллина Мөбарәк Муллагали кызыннан (1930 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Бер рәхмәт мең бәладән коткара.

* * *

Бодай чәчсәң, бодай урырсың.
Арыш чәчсәң, арыш урырсың.

* * *

Агач башын җил бора,
Кеше башын сүз бора.

* * *

Тиле-тиле дигән саен,
Тигәнәк буе сикерә.

* * *

Туң күрмәгән туң күрсә,
Аны кагып туздыра.

* * *

Алла бирмәсә, чучка ашамый.

*Стәрлебаш авылында*
*Галиева Зәйтүнә Рәхмәтулла кызыннан (1945 елгы)*
*Г. Яхшисарова язып алды*

* * *

Кояш баеганда йоклаган кеше гомер буе чирле, авыру була.

* * *

Кояш чыкканны күрмәгән кеше бәхетле булмый, дияләр иде. Кояш чыкканда син эш өстендә булырга тиеш.

*Айдарале авылында*
*Сәгыйтдинова (Йосыпова) Гөлнур Гарифулла кызыннан (1938 елгы)*
*Г. Яхшисарова язып алды*

* * *

Икенде вакытында китап укырга ярамый, дияләр иде.

*Хәлекәй авылында*
*Хәмзина Фәүзия Хәйретдин кызыннан (1941 елгы)*
*Г. Яхшисарова язып алды*

* * *

Мин эшләмим,
Эшләсәм – тирлим,
Тирләсәм – чирлим.

*Бакый авылында*
*Вилданова Ямал Газиз кызыннан (1921 елгы)*
*Г. Яхшисарова язып алды*

## ТАБЫШМАКЛАР

Нинди ярымутрау үзенең бәләкәйлегенә үпкәләп яши? (Ямал ярымутравы)

* * *

Нинди елганы сыерлар ашыйлар? (Сена елгасы)

* * *

Нинди шәһәр елан исеме белән йөртелә? (Ужгород)

* * *

Нинди каналны балалар башларына киеп йөриләр? (Панама)

* * *

Ике сигез уналты – янә сигез, янә алты, ничә була? (30)

* * *

Сигез сигезең алтмыш дүрт, янә сигез, янә дүрт, ничә була? (76)

*Бакый авылында*
*Вилданова Ямал Газиз кызы (1921 елгы)*
*Г. Яхшисарова язып алды*

* * *

Бәләкәй генә булды,
Миңа карап көлде. (Күзге)

* * *

Бәләкәй әби тау шуый. (Тарак)

*Карагош авылында*
*Туктарова Зөлфә Шәмсетдин кызыннан (1938 елгы)*
*Г. Яхшисарова язып алды*

# СТӘРЛЕБАШ РАЙОНЫ ТАТАРЛАРЫ РИВАЯТЬЛӘРЕНЕҢ ТАРИХИ ҺӘМ МИФОЛОГИК НИГЕЗЛӘРЕ

*Илдус Фазлетдинов*

Стәрлебаш районында яшәүче татарларның фольклорын җыю һәм фәнни рәвештә өйрәнүнең үз тарихы бар. Мондый характердагы беренче үрнәкләр «Октябрьнең 40 еллыгы исемендәге Башкорт дәүләт университеты» составына кергән Тел һәм әдәбият кафедрасы студентларының 1971 елның 1–15 июль көннәрендә үткәрелгән беренче фольклор экспедициясе материаллары эчендә теркәлә. Экспедиция җитәкчесе – филология фәннәре кандидаты Ф.М. Хатипов, машинка белән җыелган китапны төзүче сыйфатында Ф.М. Галиева күрсәтелә[1]. Түбәндә китерелгән мәкаләгә әлеге җыентыктан алынган бер генә язма да кертелмәде, формалашкан 70 нче елларда, ни кызганыч, татар фольклорында әкияти характерда булмаган халык прозасы жанрлары тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгән, классификация һәм дифференциация күзлегеннән анализланмаган була әле.

Әлеге эш 1987 елда «Татар халык иҗаты» күптомлыгы составында дөнья күргән «Риваятьләр һәм легендалар» томында гына

---

[1] Татар халык иҗаты. Стәрлебаш районы / экспедиция җитәкчесе Ф.М. Хатипов; китапны төзүче М.М. Галиева. Уфа, 1971. 179 б. *(кулъязма)*

башланып китеп[1], аны төзүче С.М. Гыйләҗетдинов тарафыннан якланган кандидатлык диссертациясендә генә тиешле гыйльми югарылыкка күтәрелә[2].

Ләкин бу чорда да Стәрлебаш районында яшәүче татарларның риваять һәм легенда мирасын җыю һәм өйрәнү эше башлангыч хәлдә кала. Бу төбәк татарларының риваять һәм легендалары, алардагы мөһим тарихи һәм мифологик үзенчәлекләр бары тик 1990 еллар ахырында гына бу мәкалә авторы тарафыннан җыела һәм анализлана башлый. Алар авторның Башкортстан татарлары риваятьләренә һәм легендаларына багышланган кандидатлык диссертациясенең мөһим өлешен тәшкил итә[3]. Соңыннан әлеге үрнәкләр безнең тарафтан төзелгән «Башкортстан татарлары фольклоры: риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр, сөйләкләр» томында һәм башка гыйльми хезмәтләрдә урын алды[4].

Стәрлебаш районы татарларының риваятьләре тематик төрлелеге белән аерылып тора. Биредә халыкның тормыш корып китү рәвеше дә, Пугачев җитәкчелегендәге крестьян күтәрелеше кебек илкүләм тарихи вакыйгалар да, төрле милләтләр арасындагы җир-тел-дин мөнәсәбәтләре дә, көнкүреш вакыйгалары да

---

[1] Татар халык иҗаты: риваятьләр һәм легендалар / томны төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы С.М. Гыйләҗетдинов; фәнни редакторы Х.Ш. Мәхмүтов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 368 б.

[2] *Гилязутдинов С.М.* Татарские исторические предания и легенды и их художественные особенности: автореф. дис. ... канд. филол. наук / ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Казань, 2000. 32 с.

[3] *Фазлутдинов И.К.* Топонимические предания и легенды татар Башкортостана: исторические основы и идейно-эстетические функции: автореф. дис. ... канд. филол. наук / ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Казань, 2005. 26 с.

[4] Башкортстан татарлары фольклоры. Риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр, сөйләкләр / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни мөхәррире Ә.М. Сөләйманов. Уфа: Китап, 2018. 344 б.; *Фазлетдинов И.К.* Тарих кайтавазы – риваять. XVI–XIX гасырлардагы зур тарихи вакыйгаларның Башкортстан татарлары риваятьләрендә чагылышы: уку кулланмасы / җаваплы мөхәррире Ә.М. Сөләйманов. Уфа: БДУ нәшрияты, 2007. 111 б.

бердәй чагылыш таба. Әлеге язмабызда без 27 риваятькә анализ ясадык. Алар арасында 5 авыл тарихы, 16 топонимик һәм 5 тарихи һәм 1 көнкүреш риваяте бар. Бу үрнәкләр 1997, 1998, 2000, 2011 елларда Башкорт дәүләт университетының филология факультеты татар-рус бүлеге студентлары Флүр Гафиев, Зөлфия Латыйпова, Гөлназ Мөхәррәмова, Айсылу Баһаветдинова, Илира Юнысова тарафыннан районның Стәрлебаш, Бакый, Бузат, Тәтер-Арслан, Хәлекәй авылларында яшәүчеләрдән язып алынган. Риваятьләрнең тулы текстлары һәм паспорты мәкаләнең кушымтасында китерелә.

Әлеге язмалар арасында авыл тарихларын тасвирлаган риваятьләр һәм гыйльми-тарихи, һәм сәнгати әһәмияте ягыннан аерым урын били.

Башкортстанның Стәрлебаш районында урнашкан татар авыллары тарихын тасвирлаган риваятьләрнең һәркайсын композицияләре ягыннан ике өлешкә бүләргә мөмкин. Аларның берсе монда яшәүче халыкның башыннан кичкән тарихи вакыйгалар турында сөйләп, күренекле шәхесләре белән таныштырса, икенчесе, нинди дә булса вакыйгага таянып, турыдан-туры авыл атамасының килеп чыгышына аңлатма бирә. Шулай итеп, атап үтелгән авыл тарихлары мөстәкыйль ике сюжетка корылып киләләр. Риваятьтә алар бертигез хокукка ия булып, үзләре генә дә аерым әсәр сыйфатында халыкның фольклор репертуарында йөри алалар. Шул рәвешле, хәтта кешеләрнең авылда тормыш корып китү рәвеше, аның үсеше турындагы сюжет сызыгы халык хәтереннән җуелса да, авыл атамасын аңлаткан этиологик мотив сакланган очракта, риваять художестволы әсәр буларак яшәүдән туктамый. Бу сыйфат безнең кулыбыздагы Бакый, Бузат, Яшерган, Хәлекәй авыллары тарихын тасвирлаган риваятьләрдә күзәтелә.

Әлеге төр риваятьләрнең тагын бер үзенчәлеге итеп, аларда тарихи фактларның һәм халыкның борынгы мифологик күзаллауларының берегеп, үзенчәлекле синтез хасил итеп килүен атарга кирәк.

Мәсәлән, Стәрлебаш районы Бузат авылы тарихын тасвирлаган үрнәктә «өч Пенза татары»ның яңа урыннарны килеп

караулары, ошатулары, ләкин кайтыр юлга чыккач, аларның бер атлары кинәт авырып» китүе сурәтләнә һәм «юлчылар аны бер чишмә янында калдырып китәргә мәҗбүр» булдылар дип хәбәр ителә. «Бер ел тирәсе вакыт үткәч, 7 гаилә бу якларга күчеп киләләр һәм чишмә янындагы аланга төпләнәләр. Бер көнне суга барган хатын-кызлар чишмә янында бер ат очраталар... Ул үткән килгәндә калдырып киткән чирле ат булып чыга. Бу акбүзат була. Аның савыгуына һәм исән-сау кышлавына куанган халык авылларына Акбүзат дип исем кушарга булалар». Әлеге риваятьтә борынгы бабаларыбызның мифологик карашлары ачык күзаллана.

Ф.А. Нәдершина язуынча, «ак, бүз (күк) атлар төрле халыкларның мифологиясендә кешеләргә бәхет китерүче, изгелекле җан ияләре сыйфатында чагылыш тапкан»[1]. Бу фикерне башка тикшеренүчеләр дә куәтли. Мәсәлән, Г. Гыйльманов акбүзатны Кояш символы итеп карый. «Шуңа күрә, борынгы ышану буенча, акбүз атка атлана алган, аны үзенә буйсындыра алган кеше изге максатына ирешә – җир астына да төшә, утлы таулар аша да чыгып, бер төн эчендә дөньяның читенә дә барып җитә ала»[2]. Шулай итеп, белгеч фикеренчә, «Акбүз атлар яктылыкны, Көнне, Кояшны гәүдәләндергәннәр»[3].

Югарыда телгә алынган риваятьтә, без әлеге илаһи көчкә ия булган мифологик персонаж – Акбүзатның халыкның иҗтимагый аңы үсеше нәтиҗәсендә трансформация кичереп, гадәти җир тормышына якынаюын күрәбез. Биредә аның югарыда санап үтелгән илаһи сыйфатлары чагылыш тапмый. Бу исә риваятьнең борынгы мифлардан, әкиятләрдән соңрак иҗат ителүен дәлилли. Әмма борынгы мифологик карашларның әлеге риваятькә тәэсире дә ачык тоемлана. Пенза татарлары тарафыннан калдырып кителгән чирле атның савыгып, бер елдан үзләрен

---

[1] *Нәҙершина Ф.А.* Халыҡ хәтере: монография / яуаплы редакторы Нур Зарипов. Өфө: Башҡортостан китап нәшриәте, 1986. Б. 85.

[2] Татар мифлары: ияләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, им-томнар, сынамышлар, йолалар. Беренче китап / Галимҗан Гыйльманов хикәяләвендә. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. Б. 55.

[3] Шунда ук. Б. 55.

шушы җирдә каршы алуы ниндидер гайре табигый, сәбәбенә төшенергә гади акыл гына җитмәслек вакыйга итеп карала һәм әлеге «могҗиза» атның, борынгылар карашынча, илаһи көчкә ия акбүзат булуы белән аңлатыла. Акбүзатның кешеләрне яңа урында каршы алуы нигез корасы җирләрнең уңдырышлы, үлән-суга бай, яшәр өчен уңайлы, котлы икәнлеген күрсәтүче илаһи билге сыйфатында да чыгыш ясый. Шуңа да кешеләр авылны Акбүзат дип атап, киләчәктә үзләрен бәла-казадан сакларга, яңа урында үзләренә бәхетле тормыш тәэмин итәргә омтылалар. Риваятьтән күренүенчә, борынгы мифологик карашлар халыкның бүгенге реаль тормыш ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен, ягъни практик максатларга хезмәт итәләр.

Шул ук вакытта әлеге үрнәк авылның борынгылыгы, аның халык аңында мифологик күзаллаулар хакимлек иткән чорларда ук нигезләнүе турында фаразларга мөмкинлек бирә. Рус фольклорчысы Н.А. Криничная билгеләвенчә, атны изгеләштерү кешелек җәмгыятенең иң борынгы чорларында ук барлыкка килеп, ул «явыз көчләрдән саклаучы, мәҗүси тәңреләрнең кодрәтен кешеләргә җиткерүче илаһи зат» буларак, авыл тарихларын тасвирлаучы риваятьләр составына килеп керә[1]. Күренекле галимебез Ф. Урманче Бузат, яки Акбүзатның борынгы төрки-монгол эпосларында «Күктән төшкән илаһи зат, батырның җиңелмәс яклаучысы» сыйфатында сурәтләнүен күрсәтә[2].

Димәк, яңа урында беренче булып очраган ат – инде гади йорт хайваны гына түгел. Борынгы халык аны шушы җирләрнең хуҗасы, иясе итеп карый, тәңреләрнең ихтыярын кешеләргә җиткерүче – арадашчы дип саный һәм, авылга аның исемен биреп, илаһи көчләргә хөрмәт-ихтирамын күрсәтергә тырыша, киләчәктә кешеләргә мәрхәмәтле булуын, зыян китермәвен

---

[1] *Криничная Н.А.* Русская народная историческая проза: вопросы генезиса и структуры / ответ. ред. В.К. Соколова. Л.: Наука, 1987. С. 50.

[2] *Урманчеев Ф.И.* Развитие татарского фольклора в контексте «Запад – Восток // Очерки по истории татарской культуры (в контексте «Запад-Восток») / под. ред. М.З. Закиева, Ф.И. Урманчеева, А.И. Садековой. Казань: Фикер, 2001. С. 309.

үтенә. Шулай итеп, әлеге җанвар үз җирләренә күчеп утырган кешеләрнең киләчәге белән идарә итәргә сәләтле изге җан – тотем дәрәҗәсенә күтәрелә. Югарыда китерелгән риваятьтә нәкъ шушы зооморфик һәм антропоморфик карашлар чагылыш таба.

Димәк, Бузат авылы тарихында ат культы ике яктан ачыла дигән нәтиҗәгә килергә мөмкин. Аның беренчесе татар халкының борынгы мифологик карашларын үзендә чагылдырса, икенчесе милләттәшләребезнең реаль тормыш ихтыяҗларына бәйле рәвештә барлыкка килә. Еллар узу белән, риваятьтәге илаһи акбүзат үзенең күп кенә мифологик атрибутларын җуеп, кешенең аерылгысыз юлдашы, терәге – реаль эчтәлекле җир атына әверелә.

Стәрлебаш төбәге татарларының борынгылыгын раслаучы икенче бер дәлил – аларның фольклор репертуарында, аерым алганда, риваятьләрендә, су культы чагылышы. Ф. Урманче билгеләвенчә, «су дөнья мифологиясенең иң борынгы, популяр, көч-куәте чикләнмәгән универсаль категориясе буларак гәүдәләнә»[1]. Шул ук вакытта ул «үлемсезлек атрибуты булып та килә ала»[2]. Стәрлебаш районы татарлары фольклорында су образы үзендә шушы архаик-мифологик күзаллаулар тәэсирен саклый. Мәсәлән, Хәлекәй авылында язып алынган «Күндерәк елгасы» риваятендә халкын корылыктан (димәк, үлемнән!) коткарырга хыялланган үзәк герой күңелендә илаһи көчнең боерыгын ишетә: «эчке тавыш егеткә ерак түгел урнашкан соры ташка басып, тылсымлы сүзләрне кабатларга куша». Боерыкны үтәү белән «җир астыннан салкын, шифалы су күзе бәреп чыга. Егет озак уйлап тормый, чишмәне үз артыннан ияртеп, авылга таба чаба. Авыл уртасыннан чишмә Ашкадарга барып кушылганчы, алдын-артын карамыйча йөгерә дә йөгерә. Шушы егет хөрмәтенә, ул барлыкка китергән елганы Күндерәк дип атаганнар».

Г. Гыйльманов билгеләвенчә, «борынгы ышанулар буенча, елгаларның башы – Күк йөзендә. Хәтта, һәр елганың Күккә чыгып киткән (яки киресенчә: Җиргә агып төшкән) капкасы бар, дип

---

[1] *Урманче Ф.И.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: 2 т. (Д – С). Казан: Мәгариф, 2009. Б. 338.

[2] Шунда ук. Б. 339.

уйлаганнар. Елгалар, күлләр, дәрьялар Су тәңресе белән шул капка аша элемтәгә керәләр, дип ышанганнар»[1].

Безнең фикеребезчә, әлеге үрнәктә борынгы җәмгыятьтәге су культының сүз культы белән табигый синтезлашуын, берегеп килүен күрергә мөмкин. Югары көчләр тарафыннан егеткә хәбәр ителгән тылсымлы гыйбарә борынгы җәмгыятьтәге табу сүз – сүз тыюы традицияләренә барып тоташырга тиеш. Ф. Урманче билгеләвенчә, «сүзнең тагын бер мөһим үзенчәлеге – аның кеше тормышында хәлиткеч роль уйный торган магик-мифологик тәэсир итү көче, йогынтысы белән нисбәтле»[2]. Мифологик карашлар буенча, аерым гыйбарәләрне бары тик изге йола башкарганда гына сөйләргә яраган, башка шартларда сөйләсәң, бу сүз-хикәятләр илаһи кодрәтен җуярга мөмкин, дип исәпләнелгән[3].

Шулай итеп, егет тылсым көченә ия табу сүзләр аша – Күк катыннан, Тәңреләр дөньясыннан ярдәм сорап, авылдашларын үлемсезлек чыганагы – Су белән тәэмин итә. Ягъни, үзе дә Җир дөньясы белән Күк дөньясы арасындагы арадашчы дәрәҗәсенә күтәрелә. Күндерәкнең исеме елга атамасында мәңгеләштерелү дә шуңа ишарәли.

Стәрлебаш төбәгендә, хәер, анда гына түгел, гомумән, Башкортстан татарлары арасында таралган риваятьләрдә Казан ягында очрамаган бер үзенчәлекле тарихи мотивның шактый зур урын тотын билгеләп үтәргә мөмкин. Бу – җирле халык һәм казакълар арасында барымта-карымта сугышлары. «Тарихтан билгеле булуынча, XVI–XVIII гасырларда, башкорт-казакъ ырулары арасында мөнәсәбәтләр катлаулана. <...> Халык авыз иҗатында үзара үчләшүгә, дошманлашуга китергән феодаль чапкыннар, барымта һәм карымта күренешләре урын ала. <...> Көньяк, көньяк-

---

[1] Татар мифлары: иyaләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, им-томнар, сынамышлар, йолалар. Беренче китап / Галимҗан Гыйльманов хикәяләвендә. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. Б. 126.

[2] *Урманче Ф.И.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: 3 т. (С – Я). Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. Б. 80.

[3] *Урманче Ф.И.* Татар халык иҗаты / фәнни мөхәррире Х.Ш. Мәхмүтов. Казан: Мәгариф, 2005. Б. 36.

көнчыгыш башкортларының авыз-тел иҗатында казакъ белән башкорт барымталары хакында байтак кына риваять һәм легендалар очрый», – дип яза фольклорчы Ф.А. Нәдершина[1].

Моңа кадәр әлеге төр әсәрләр мөстәкыйль тематик төркем буларак бары тик башкорт риваятьләре составында гына аерымлана иде. Соңгы еллардагы тикшеренүләребез карымта-барымта яулары белән бәйле мотивларның башкорт фольклорында гына түгел, Башкортстан татарларының риваятьләрендә дә мөһим урын тотуын ачыклады һәм аларны мөстәкыйль тематик цикл итеп карарга мөмкинлек бирде[2]. Безнең фикеребезчә, биредә татар халкының зур гына өлешенең хәзерге Башкортстан җирләрендә борын-борыннан яшәп, бу сугышларда турыдан-туры катнашуы турында фаразларга да нигез бар[3].

Биредә бер мәсьәләгә ачыклык кертеп үтәргә кирәк. Эш шунда: Башкортстан җирлегендә казакъ халкы элгәре «кыргыз» атамасы астында йөри. Танылган тел галиме Р.Г. Әхмәтьянов билгеләвенчә, бу хәл XX гасырның 30 нчы елларына кадәр дәвам итә[4].

Мәсәлән, Стәрлебаш районы Стәрлебаш авылында теркәлгән «Котып чокыры» риваятендә дә казакълар «кыргыз» атама-

---

[1] Башҡорт халыҡ ижады. Икенсе том: Риүәйәттәр, легендалар / төҙөүсеһе, инеш мәҡәлә һәм аңлатмалар яҙыусы Фәнүзә Нәҙершина; яуаплы редакторы Кирәй Мәргән менән Әхмәт Сөләймәнов. Өфө: Башҡортостан китап нәшриәте, 1997. Б. 18–34.

[2] *Фазлетдинов И.К.* Тарих кайтавазы – риваять. XVI–XIX гасырлардагы зур тарихи вакыйгаларның Башкортстан татарлары риваятьләрендә чагылышы: уку кулланмасы / җаваплы мөхәррире Ә.М. Сөләйманов. Уфа: БДУ нәшрияты, 2007. Б. 8–15; *Фазлутдинов И.К.* Топонимические предания и легенды татар Башкортостана: исторические основы и идейно-эстетические функции: автореф. дис. ... канд. филол. наук / ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Казань, 2005. С. 20.

[3] Башкортстан татарлары фольклоры. Риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр, сөйләкләр / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни мөхәррире Ә.М.Сөләйманов – Уфа: Китап, 2018. Б. 31.

[4] *Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге: ике томда. I т. (А – Л). / ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты; җаваплы редакторы А.Ә. Тимерханов. Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. Б. 519.

сы астында бирелә. Үрнәктә барымта сугышлары сурәтләнгән булырга тиеш. Дөрес, биредә кыргызлар барымтачылар итеп түгел, ә гадәти «мал куучылар» итеп күрсәтелә. Ләкин «Ибракай авылы кешеләренең кыргызлар белән сугышка» чыгуы, һәм баскынчыларның «шушы чокырда Котып исемле егетне ук белән атып» үтерүләре киресен күрсәтә. Бу уңайдан, еллар үтү белән риваятьнең аерым детальләре халык хәтереннән җуелгандыр, дигән фикергә килергә мөмкин. Котыпның исеме дошман юлында табигый киртә булган чокыр атамасында мәңгеләштерелү дә шуны исбатлый. Димәк, халык әлеге батырга хас сыйфатларның шушы чокырга да күчәчәгенә, ягъни аның гомере яңа төстә дәвам итәчәгенә ихлас ышана.

Әлеге үрнәккә таянып, бер кызыклы күзәтү ясарга мөмкин. Илен яклап, батырларча һәлак булган, яисә халкын үлемнән коткарган кешенең җаны ул күмелгән тауда, чокырда, чишмәдә яшәвен дәвам итә, дип исәпләнелгән очракларда, халык бу табигать җисемнәренә әлеге кешенең исемен бирә. Моның ачык мисалын без югарыда анализланган «Күндерәк елгасы» риваятендә дә күрдек. Димәк, кешенең җаны бу табигать объектларына аның исеме аша күчә, дип ышаныла. Шулай итеп, борынгы халык кеше исеменә ниндидер магик сыйфатлар биреп, аны җанның символик гәүдәләнеше итеп карый. Әлеге исемдә батырның тормыштагы барлык сыйфатлары, көче, рухы код рәвешендә яшерелгән дип исәпләнә. Димәк, тикшерелгән риваятьтә без борынгы мифологик карашларның реаль эчтәлекле, тарихи нигезле риваятьләргә берегеп китү очрагын күрәбез.

Шул ук вакытта, биредә җиргә изге корбан китерү мотивының үзенчәлекле чагылышын да сиземләргә мөмкин. Борынгы заманнарда теге яки бу төзелеш эшләренә керешер алдыннан, кешеләр әлеге урынга изге корбан китереп, киләчәктә бинаның корбан булган затка хас сыйфатларын үзләштерүенә, ягъни аның җаны төзелгән әйбергә күчүенә ихлас ышанган[1]. Шулай итеп, әлеге

[1] *Криничная Н.А.* Русская народная историческая проза: вопросы генезиса и структуры / ответ. ред. В.К. Соколова. Л.: Наука, 1987. С. 53–61.

чокыр да батыр исемен йөрткәч, дошман алдына ышанычлы киртә булып килеп басар, дип ышанылган.

Зур тарихи вакыйгаларга бәйләнмәгән шәхси фаҗигаларның топонимик риваятьләрдә тоткан урыны алай ук зур түгел һәм аларның мифологик тамырларын ачыклау да авырлык тудыра. Мәсәлән, буранда адашып һәлак булган кешенең исемен топонимда мәңгеләштерү мотивы Стәрлебаш районы Стәрлебаш авылында язып алынган «Бикмәт тавы» риваятендә үзәк урынны тота. Һәлак булучылар турында информация биредә бик саран, аның юлга чыгу максатыннан гайре бернәрсә дә әйтелми. Бикмәт утынга барганда, буранга очрап, җан бирә.

Күренүенчә, халык бары тик эш өчен янып, изге максатларда йөргән затларның исемнәрен генә топонимнарда мәңгеләштерә, начар гамәлләр башкарганда һәлак булган кешеләрне урын-җир атамасына «якын да китерми». Безнең фикеребезчә, бердән, бу – үзенчәлекле халык фәлсәфәсенең, аның мораль-әхлак кагыйдәләренең гәүдәләнеше булса, икенчедән, биредә борынгы мифологик карашларның, атап әйткәндә «изге корбан» турындагы мәҗүси күзаллауларның чагылышын да күрергә мөмкин. Эш башкарганда фаҗигага очрап һәлак булган авылдашларына халык «изге корбан» сыйфатларын күчерә һәм аның исемен җирсу атамаларында мәңгеләштереп, киләчәктә үзен мондый аяныч хәлләрдән саклап калырга тырыша. Шулай итеп, топонимнарга биредә фаҗигалы үлем белән һәлак булган кешеләрнең исемнәрен бирү мотивына корылган риваятьләрне тамырлары белән борынгы профилактик магиягә тоташа, дип карарга да нигез бар.

Халык хәтеренә фаҗигалы хәлләр белән бергә көнкүрештәге шатлыклы, яисә көтелмәгән вакыйгалар да уелып калган, һәм алар да еш кына урын атамаларына нигез булып киткәннәр. Мәсәлән, Стәрлебаш районы Стәрлебаш авылында язып алынган «Көмеш ташы» риваятендә әлеге ташның ничек итеп бу атаманы алуы тасвирлана. «Борын заман бу таш су төбендә яткан. Тимергали исемле егет үзе кебек унбер кеше белән аны тартып чыгарып, яр башына утыртканнар», – дигән сүзләр аша әсәр ташның ни дәрәҗәдә авыр булганлыгын хәбәр итә, чөнки аны күтәрү

өчен дистәдән артык кеше кирәк була. Атама исә су керергә килгән Көмешбикә исемле хатынның шушы ташка сөялгәч, аның «әйләнеп китеп», Көмешбикәне басуы, шулай да адәм затының фаҗигадан исән-имин котылуы белән аңлатыла. «Шуннан ташын күтәреп алсалар, Көмешбикәнең бер җире дә имгәнмәгән икән. Шул көннән ташны аның исеме белән «Көмешбикә ташы» дип атап, тау башына мендереп утыртканнар», – дип хәбәр итә риваять. Аңлашылганча, атамада үлемнән могҗизалы рәвештә котылган кешенең исеме урын ала.

Борынгы мифология белән бәйлелек Стәрлебаш авылында язып алынган «Бүре бүләге җире» риваятендә дә тоемлана. Беренче карашка, ул да югарыда атап үтелгән кеше һәм ерткыч арасындагы конфликтка бәйләп, урынга исем бирүгә корылган. Күпләп аулау нәтиҗәсендә, бүреләрнең бу урынны ташлап, башка урыннарга качуын тасвирлау әсәрнең төп эчтәлеген тәшкил итә. Ләкин алар әлеге җирләрне ташлап кына калмый, җанварлар аны кешеләргә «бүләк итеп» тапшыралар. Бусы инде – борынгы антропоморфик фикерләү рәвешенең чагылышы. Кеше үзендә булган сыйфатларны җанварларга да күчерә һәм моны атамада мәңгеләштерә. Урын-җирнең тере табигатьтән бүләккә алынуының формаль күрсәткече булып, атамада җанвар атамасының һәм «бүләк» сүзенең бергә килүе хезмәт итә. Шулай итеп, биредә зооморф «тотем баба» белән бәйле мотивның үзенең борынгы төсмерләрен югалта баруын, трансформацияләнеп, чынбарлыкка якынаюын күрергә мөмкин. Н.А. Криничная билгеләвенчә, «тотем баба образы эволюциясе барышында <...> ул, риваятьләрдә үзәк герой булудан туктап, үз урынын «варисы»на бирә»[1]. Күп очракта аның «варисы» булып кеше чыгыш ясый. Югарыда китерелгән «Бүре бүләге җире» риваятендә дә без шушы күренешкә шаһит булабыз.

Стәрлебаш районында килеп чыгышы аждаһа образы белән бәйләнгән топонимнар да бар. Мәсәлән, «Аждаһа ерымы» дип

---

[1] *Криничная Н.А*. Персонажи преданий: становление и эволюция образа / ответ. ред. А.К. Микушев. Л.: Наука, 1988. С. 66.

аталган үрнәктә әлеге урынның барлыкка килүе «җир астыннан» килеп чыккан аждаһаның «үзенең озын койрыгын болгап, артыннан чокырлар, ерымнар калдырган»лыгы белән бәйләнә.

Аждаһа – «һәрвакыт берничә башлы явыз зат һәм кешенең <...> явыз дошманы»[1]. Башкортстан татарларының фольклорында ул – һәрчак кире персонаж. Ләкин кеше аның алдында көчсез түгел. Ул бу затлардан илаһи көчләр ярдәмендә котыла ала. Бу очракта да аны күк үзенә тартып ала, ягъни кешеләрне бу явыз заттан коткару эше илаһи көчләр ярдәмендә тормышка ашырыла. Г. Гыйльманов билгеләвенчә, татарлар һәм башкортлар арасында киң таралган «Аждаһа күтәрелү» дигән әйтем дә тамырлары белән борынгы мифларга барып тоташа[2] һәм «Күк вәкилләре белән Су вәкилләре, Ут (Кояш) белән Су көрәшен» гәүдәләндереп килә»[3]. Югарыда китерелгән риваятьтә дә без шушы миф калдыкларын күрәбез.

Стәрлебаш төбәге татарларының риваятьләрендә Емельян Пугачев җитәкчелегендәге 1773–1775 еллардагы Крестьян сугышы белән бәйле мотивлар аеруча зур урын тота. Ф. Урманче фикеренчә, «алар барысы да тарихка якын торулары белән аерылалар»[4]. Шул ук вакытта Пугачев явы «әлеге хәрәкәт белән бәйле тагын бер төркем – топонимик риваятьләрнең тууына һәм халыкка таралуына сәбәп була»[5]. Стәрлебаш төбәгендә дә күп кенә авыл, җир-су атамаларының барлыкка килүен халык шушы күтәрелештә катнашкан кешеләрнең исемнәренә, төрле сугыш вакыйгаларына бәйли. Мәсәлән, Яшерган авылы тарихын тасвирлаучы риваять атаманың килеп чыгышын «элек монда пугачевчылар яшеренеп яткан», дип аңлата.

---

[1] *Урманче Ф.И.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: 2 т. (Д – С). Казан: Мәгариф, 2009. Б. 339.

[2] Татар мифлары: ияләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, им-томнар, сынамышлар, йолалар. Икенче китап / Галимҗан Гыйльманов хикәяләвендә. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. Б. 89.

[3] Шунда ук. Б. 84.

[4] *Урманче Ф.И.* Татар халык иҗаты / фәнни мөхәррире Х.Ш. Мәхмүтов. Казан: Мәгариф, 2005.Б. 298.

[5] Шунда ук. Б. 300

Фольклорчы-галим Ф.А. Нәдершина 1773–1775 еллардагы крестьян сугышын тасвирлаган риваятьләрдә «интернациональ мотивларның бөреләнүен» ассызыклап үтә[1]. Моның ачык чагылышын Стәрлебаш районы Бакый авылы тарихын тасвирлаган үрнәктән күрергә мөмкин. Биредә халыклар дуслыгы идеясе, аларның кулга-кул тотынышып, колониаль изүгә каршы чыгуларын хуплау аермачык ярылып ята.

«Пугачев восстаниесе вакытында качкын крепостнойлар Кабакуш авылыннан үтеп барышлый, бер чибәр башкорт кызын үзләре белән алып китәләр. Кыз берничә ай качаклар отрядында яши. Аның туганнарын бик сагынуын күреп, пугачевчылар ышанычлы кеше аша кызны кире Кабакуш авылына озаталар. Тик кызның әтисе баласыннан баш тарта. Урыслар арасында яшәгәннән соң, кызын кире өенә кертәсе килми. Ата үз җирләренең читендәге урманнан кызына бәләкәй генә урын бүлә һәм пугачевчылар җибәргән юлдашы белән шунда яшәргә озата. Бу егетнең исеме Бакый була. Ул татар милләтеннән була.

Урман эчендә яшәгәндә, башкорт кызы белән татар егете үзләрендә утызлап качкынны яшерәләр. Эзәрлекләүләр тынгач, аларның кайберләре хатыннары янына кайтып китә, кайберләре, киресенчә, кәләшләрен монда алып килә. Әкренләп биредә йортлар салына башлый. Шулай итеп, Бакый авылы барлыкка килә».

Риваятьтән күренүенчә, татар егете һәм башкорт кызының берләшеп, гаилә хасил итеп яшәве дистәләрчә башкүтәрүченең гомерен саклап кала. Шушы образлар аша халык милләтара дуслык, татулык идеалларын алга сөрә, татар һәм башкорт кулга кул тотынышып, бергә чыгыш ясаганда, һәртөрле каршылыкларны да җиңеп чыгачагын ассызыклап үтә. Бер милләтне – егет, икенчесен кыз белән тиңләп, борынгы бабаларыбыз аларның бары тик бергә булганда гына, иңгә-иң торып дошманнарга каршы чыкканда гына, азатлыкка ирешә алуларын исбатларга омтыла. Биредә халыкларыбызның үзенчәлекле тормыш фәлсәфәсе чагылыш таба.

[1] *Нәҙершина Ф.А.* Халыҡ хәтере: монография / яуаплы редакторы Нур Зарипов. Өфө: Башҡортостан китап нәшриәте, 1986. Б. 78.

1773–1775 еллардагы Крестьян сугышы турындагы риваятьләрдә яу картиналары үзләре әлләни зур чагылыш тапмый. Еш кына аларда сугыш үзе түгел, ә аның белән бәйле бүтән вакыйгалар сурәтләнә. Мәсәлән, Стәрлебаш районы Стәрлебаш авылында язып алынган «Поскын чокыры» риваятендә атаманың барлыкка килүе Пугачев явына бәйләп, ул «бастырылганнан соң, башкүтәрүчеләр шушы чокырда качып-посып яталар. Шуңа да чокыр Поскын дип атала», – дип аңлатыла. Без моны риваятьләргә хас анахронизм күренеше дип тә саный алабыз. Чынлыкта, атаманың, гомумән, тикшерелүче чордан күпкә алда тууы да ихтимал. Ләкин халык үзенең әлеге зур тарихи вакыйгаларда катнашканлыгын раслар өчен, инде булган, кулланылышта йөргән топонимнарның Пугачев явы белән ерак ассоциациясен табып, аларны көчәйтеп, атаманың яңа «аңлатмасын» иҗат итә. Шул рәвешле, «поскын» – пугачевчыларның биредә патша гаскәрләреннән качып-посып ятуыннан килеп чыккан топонимга әверелә. Әлбәттә, бу фараз гына. Хәтта бу шикләребез, чыннан да, дөреслеккә туры килеп, әлеге топонимнарның килеп чыгышы чынбарлыкта Пугачев явы белән берничек бәйләнмәгән очракта да, халык Крестьян сугышы вакыйгаларын урын атамаларының аңлатмаларына алып кереп, күңеле белән үзенең башкүтәрүчеләр арасында булуын, азатлык өчен көрәш утында януын раслый. Фольклор өчен анахронизмның гадәти күренеш булуын бу очракта һич онытырга ярамый.

Стәрлебаш татарларының топонимик риваятьләрендә урын атамасының биредә кайчандыр әйтелгән сүзләр белән аңлатылу мотивы да очрый. Дөрес, бу мотивка нигезләнгән әсәрләр үзләрендә тасвирланган чор, персонажлар ягыннан да, эмоциональ киеренкелек җәһәтеннән дә бер-берсеннән аерылып торалар. Ләкин аларны уртак бер сыйфат берләштерә –сүз кайчан, кем тарафыннан гына әйтелмәсен, мотлак урын атамасының нигезе булып китә.

Әлеге типтагы риваятьләрнең бер өлешендә чит телдә әйтелеп, мәгънәсе татарларга аңлашылмаган сүзнең милләттәшләребез тарафыннан урын атамасы итеп кабул ителү мотивын күрергә

мөмкин. Н.А. Криничная билгеләвенчә, «биредә уйдырма өчен киң мөмкинлекләр ачыла һәм уйлап чыгарылган вакыйгалар топонимик мотивның бөтен эчтәлеген тәшкил итә ала». Әлеге мотивның формалашуын галимә «яңа җирләрне үзләштерүчеләрнең үзләре өчен таныш булмаган һәм чит телләрдән кергән топонимнарны аңлату омтылышы» нәтиҗәсе, дип саный[1]. Аның фикерен раслап, Стәрлебаш районы Стәрлебаш авылында теркәлгән «Сискал тау» риваятен китерергә мөмкин. Биредә ороним «Тәпәнәй исемле чуваш»ның «малайлары белән шушы тау борынында каен тузы кайнатып, елкы мае кушып, арба майлар өчен дегет» ясап, аны Оренбург якларында «игенгә, онга алыштырып» кайткач, «яшәү чыганагы табу шатлыгыннан»: «Хорошее место сыскал!» – дип кычкырып җибәрүе белән аңлатыла. Шулай итеп, Тәпәнәйнең эмоциональ киеренкелек вакытында әйткән сүзләренең тәэсир көче гаять зур булып, халык хәтеренә берегеп, урын атамасында мәңгеләштерелә. Шушы ук авылда язып алынган «Байгара тавы» риваятендә дә әлеге мотив кабатлана.

Күренүенчә, авыл тарихларында, тарихи һәм топонимик риваятьләрдә яңа җирләрне үзләштерүнең күптөрле хасиятләре чагылыш таба. Биредә татарларның элек яшәгән җирләрен ташлап китү сәбәпләрен, яңа урында тормыш корып китү үзенчәлекләрен, җир, дин, тел мәсьәләләренең хәл ителешен, борынгы бабаларыбызның дөнья, җанлы һәм җансыз табигать белән бәйләнешләрен ачык күзалларга була. Мәсәлән, Стәрлебаш районы Бузат авылы тарихында Мамин фамилияле бер генерал-морзаның яхшы хезмәте өчен патша тарафыннан бүләк ителгән җирләрен, өч Пенза татары белән килешү төзеп, алар яшәгән урыннарга алмашуы тасвирлана. Шулай итеп, җиде татар гаиләсе яңа урынга килеп төпләнә. Хәлекәй авылы тарихында исә, аның барлыкка килүе Хәлиулла исемле бабайның «гаиләсенең, балаларының мөселманлыгын саклау өчен», морзалыгыннан, җирләреннән дә баш тартып, элек яшәгән Пенза тарафларын ташлап китүе белән

---

[1] *Криничная Н.А.* Русская народная историческая проза: вопросы генезиса и структуры / ответ. ред. В.К. Соколова. Л.: Наука, 1987. С. 75.

аңлатыла. Шулай итеп, ике риваять тә авылларга нигез салучылар итеп Пенза мишәр-татарларын күрсәтә. Өстәвенә, риваятьләрдә аларның сословиесе һәм дини инанулары турында да мәгълүмат китерелә.

Стәрлебаш районы Бузат авылында язып алынган «Мамин урамы» дип аталган риваять татарлар һәм урыслар арасындагы мөнәсәбәтләр хакында өстәмә мәгълүмат бирә. Монда атаманың килеп чыгышы җир мәсьәләсендә килеп чыккан конфликтларга бәйләп аңлатыла һәм татарлар – үз җирләрен саклаучылар итеп, ә урыслар яулап алучылар сыйфатында тасвирлана. Милләттәшләребез барыбер үз чәчүлекләрен саклап кала һәм әлеге конфликт урын атамаларында мәңгеләштерелә. Стәрлебаш авылындагы «Ясаклылар урамы» топонимының барлыкка килүен риваять «элек монда махсус ясак түләүче татарлар яшәгән» дип аңлата. Шулай итеп, риваятьләр тарихи документ ролен үти алмасалар да, шул тарихның халык аңындагы образлы чагылышы булып торалар.

Авыллар күп һәм төрле булган кебек, аларның тарихлары да, атамаларның барлыкка килүен аңлатучы этиологик мотивның риваятьләрдә тоткан урыны да төрле. Аерым авыл тарихлары тулысынча авыл исеменә аңлатма бирүдән генә торалар. Этиологик мотив аларда сюжет хасил итеп килә. Икенче төркемдәге авыл тарихлары кыскача тарихи белешмә характерында гына булалар. Аларда документальлек өстенлек итә, халык фантазиясенә, аның иҗади мөмкинлекләренә ирек бирелми. Өченче төркемдәге риваятьләр авылның тарихи-этнографик, социаль-икътисади, мәдәни үсеш юлларын мөмкин кадәр тулырак чагылдыру максатын үтиләр. Аларда тарихи хатирәләр җирле халыкның иҗади фантазиясе белән бергә үрелеп, кабатланмас синтез, поэтик күренеш тудыралар һәм катлаулы сюжетка нигезләнгән, авылның үткәнен барлыкка килгән көненнән башлап бүгенгә кадәр сөйләп бирүче, чын мәгънәсендә, художестволы әсәр хасил итәләр. Стәрлебаш төбәгендә язып алынган үрнәкләр нәкъ шушы төркемгә карый.

Риваятьләрдә атаманың барлыкка килүе нинди генә аспекттан яктыртылуга карамастан, аларда сүз конкрет кешеләр яшәгән

конкрет урын турында бара. Шулай булса да, күп кенә очракларда аларның мифологик карашлар йогынтысында аңлатылуын, әсәр тукымасына легендар мотивлар үтеп керүен күрергә мөмкин. Аларда бабаларыбызның борынгы тотемистик һәм анимистик карашлары да, бу җирләрдә яшәүче башка халыклар белән мөнәсәбәтләре дә, төрле табигать күренешләре дә, кайчандыр әйтелгән сүзләр дә, илкүләм тарихи вакыйгалар да, тормыш көтү үзенчәлекләре дә ачык чагыла.

Шуны да әйтик, җир, чокыр, урман һ.б. атамаларына аңлатма бирүче топонимик риваятьләр бер генә хәл-вакыйганы, күренешне үз эченә алсалар, авыл тарихларының вакыт һәм вакыйгалар сыйдырышлыгы киң. Бу төр риваятьләр бер урында төрле вакытта булган хәл-вакыйгаларны бер-берсенә ялгап, даими рәвештә тулылана баралар һәм тәмамланмаган, дәвамы киләчәккә барып тоташучы әсәр хасил итәләр. Чөнки авыл халкы үз тарихын үзе яза. Авыл яши икән, аның тарихы да яши һәм дәвам итә.

КУШЫМТА

## Риваятьләр һәм легендалар

### *1. Бакый авылы*

Пугачев восстаниесе вакытында качкын крепостнойлар Кабакуш авылыннан үтеп барышлый, бер бик чибәр башкорт кызын үзләре белән алып китәләр. Кыз берничә ай качаклар отрядында яши. Аның туганнарын бик сагынуын күреп, пугачевчылар ышанычлы кеше аша кызны кире Кабакуш авылына озаталар. Тик кызның әтисе баласыннан баш тарта. Урыслар арасында яшәгәннән соң, кызын кире өенә кертәсе килми. Ата үз җирләренең читендәге урманнан кызына бәләкәй генә урын бүлә һәм пугачевчылар җибәргән юлдашы белән аны шунда яшәргә озата. Бу егетнең исеме Бакый була. Ул татар милләтеннән була.

Урман эчендә яшәгәндә, башкорт кызы белән татар егете үзләрендә утызлап качкынны яшерәләр. Эзәрлекләүләр тынгач, аларның кайберләре хатыннары янына кайтып китә, кайберләре,

киресенчә, кәләшләрен монда алып килә. Әкренләп яңа йортлар салына башлый. Шулай итеп, Бакый авылы барлыкка килә.

*1997 елда Бакый авылында*
*Флүр Гафиев язып алган. Информанты*
*күрсәтелмәгән. – БДУ ТФҺМК ФФ;*
*1998 елда Стәрлебаш мәктәбе музеенда*
*укытучы М. Мөхәммәтҗанов кульязмаларыннан*
*Зөлфия Латыйпова күчереп алган. –*
*БДУ ТФҺМК ФФ; Фазлетдинов, 2018. – Б. 81*

### *2. Бузат авылы*

XVII гасырда патшага Мамин фамилияле бер генерал-морза хезмәт иткән. Яхшы хезмәте өчен, патша аңа җир бүләк итәргә булган. Аны Башкортстаннан, буш яткан җирләрдән биргән.

Мамин килеп җирен караган, ошаткан, әмма бик төпкелдә булуын гына яратмаган. Озакламастан, Мамин Пенза губернасында яшәгән татарлар белән җирләрен алышырга уйлаган. Өч Пенза татары килеп, бу җирләрне караганнар һәм бик ошатканнар.

Ләкин, кайтыр юлга чыккач, аларның бер атлары кинәт авырып киткән. Юлчылар аны бер чишмә янында калдырып китәргә мәҗбүр булганнар. Кайтып, җирне ошатулары һәм алыштырырга риза булулары турында Маминга әйткәннәр. Бер ел тирәсе вакыт үткәч, 7 гаилә бу якларга күчеп килә һәм чишмә янындагы аланга төпләнә. Әле ул урында Бүзат авылының Актүбә урамы урнашкан.

Бабаларыбызга яшәп китүе бик авыр була, иген үстерү өчен җир эшкәртергә, өр-яңадан дөнья корырга туры килә.

Бер көнне суга барган хатын-кызлар чишмә янында бер ат очраталар. Кайтып, ир-атларга сөйлиләр. Бергә килеп карасалар, ул үткән килгәндә калдырып киткән чирле ат булып чыга. Бу ат – акбүз ат була. Аның савыгуына һәм исән-сау кышлавына куанган халык авылларына Акбүзат дип исем кушарга булалар. Безнең көннәргә хәтле килә-килә, авыл Бүзат дип кенә йөртелә башлый.

*1998 елда Бузат авылында*
*М. Кадыйровтан Гөлназ Мөхәррәмова язып алган. –*
*БДУ ТФҺМК ФФ; Фазлетдинов, 2018. – Б. 82*

### *3. Яшерган авылы*

1773 елга кадәр авыл Нухрат дип атала, ә соңыннан Яшеренгән исемен ала. Чөнки авыл зур булмый һәм урман акланында урнаша. Шуңа да Яшеренгән исемен йөрткән булгандыр, мөгаен. Картлар, монда пугачевчылар да яшеренеп яткан, дип сөйлиләр. Тора-бара авыл исеме әйтергә җиңелләштерелә һәм Яшерган дип атала башлый.

*1998 елда Стәрлебаш мәктәбе музеенда укытучы*
*М. Мөхәммәтҗанов кулъязмаларыннан*
*Зөлфия Латыйпова күчереп алган. –*
*БДУ ТФҺМК ФФ; Фазлетдинов, 2018. – Б. 82*

### *4. Хәлекәй авылы*

Борын заманда Пенза якларыннан җир эзләп йөрүче мишәрләр безнең якларга килеп чыгалар. Алар юлларында биек тау очраталар. Аның башына менеп басып, тирә-якны күзәтә башлагач, үзләренең күңелләренә ошаган бер үзәнлек күрәләр. Бу үзәнлеккә алар зур өметләр баглап, ачлыктан һәм ялангачлыктан котылырга теләп, төшеп китәләр.

Бирегә иң беренче булып Хәлиулла дигән кеше төпләнә. Киң күңелле, кешеләргә игелекле булганы өчен, авыл халкы аны яратып, Хәлекәй бабай дип йөртә. Ул гәүдәгә таза була һәм үзенә йорт төзү өчен бүрәнәләрне, кулбашына салып, Мәчет тавыннан ташый. Ә тау башлары элек куе нарат агачлары белән капланган була. Аның артыннан тагын йортлар төзелә башлый, шул сәбәпле тау ялангачланып кала. (Хәзер инде Мәчет тавы башында яңадан наратлар шаулап утыра.)

Хәлекәй бабай иң матур, иң чибәр кызны үзенә хатын итеп сайлый. Ул Җәмилә исемле була. Менә шулардан Хәлекәй авылында яшәүчеләр саны арта башлый. Табигатьнең иң матур култыгына кереп урнашкан авылны күреп, сокланып, уңдырышлы җирләренә төпләнергә теләүчеләр күбәйгәннән-күбәя. Ләкин аларга зур сынау аша үтәргә туры килә, чөнки

алларында биек тау тора. Күпләр йончып, шушы тау аша үтә алмыйлар; кайберләре үлеп кала, шуның өчен аны Әҗәл тавы дип атыйлар.

*2011 елда Хәлекәй авылында яшәүче*
*Яушева Фатыйма Гыйният кызыннан (1925 елгы)*
*БДУ талибәсе Айсылу Баһаветдинова язып алган*

### *5. Хәлекәй авылы һәм аның җир-су атамалары*
### *(2 вариант)*

Татар-мишәрләр арасында ислам дине киң таралган булган. Ул халыкның мәдәниятен, аң-белемен үстерүгә ярдәм иткән. Татар морзалары күп кенә мөселман илләре белән бәйләнештә торганнар, хаҗга барып кайтулар оештырганнар, чит илләр белән сәүдә иткәннәр. Урыс хөкүмәтенә татар морзаларын кысарга, «тәртәгә кертергә» кирәк булган.

Шуның өчен патша 1713 елда мишәр, татар морзаларын дворян (морза) дәрәҗәсеннән мәхрүм итү турында Указ чыгара. Кысрыкланган морзалар төрле якларга тарала. Мишәр морзалары Пенза якларына юнәлә. Алар төпләнеп, җирләр сатып алып яши башлый.

Ислам диненең көчәюеннән курыккан урыс патшасы мөселман морзаларын тагын да эзәрлекли башлаган. 1743 елда Синод «изге урыс җирен поганый мөселманнан» чистарту турында карар кабул итә. «Чабаталы морза»лар алты ай эчендә христиан динен кабул итәргә тиеш булалар. Байлыкларыннан колак кагарга теләмәгәннәр бу шартка күнеп, тизрәк чукына, әлбәттә. «Баш бирмәгәннәр»нең дәрәҗәләрен (морзалыгын), җирләрен тартып алып, «казна крәстиәне» дип яздыралар. Алар лашман тартырга, ягъни кораблар төзү өчен 150 шәр ел үскән агачларны кисәргә җибәрелә.

Кыерсытылган һәм кимсетелгән мөселман морзалары, үзләренең гомер иткән җирләрен ташлап, Казан,Уфа губерналарына да күчә башлый. Әмма аларга җир бирергә берәү дә ашыкмый. Элегрәк Уфа губернасына килеп урнашкан хәлле генә татарлар, мишәрләр күчеп килүчеләргә ярдәм кулы суза. Урындагы

чиновникларны көйләп-чөйләп, җиргә нәсел буенча хуҗа булган башкортлар белән күп кенә җирләрне берничә елга арендага алу турында килешү төзегәннәр. Күчеп килгәннәр утрак тормышта яши башлаган.

Хәлиулла бабай, әлбәттә, күчеп килгәндә карт булмаган. Пенза ягыннан гаиләсе белән беренче булып әлеге Иске Хәлекәй авылы урнашкан төбәккә 1743 елдан соң, 1750 елга кадәр үк килеп утырган. Милләте мишәр булган, гаиләсенең, балаларының мөселманлыгын саклау өчен, яшәгән урынын ташлап киткән.

Йорт корып, дөнья көтә башлаган. Сайлаган урыны тау астында, йорты калку урында, йорттан ерак түгел инеш агып яткан, мал-туар эчерү өчен якын, җайлы, ә тугайда – зур елга. Инеш язын ярларын җимереп ташканга, суының төсе кып-кызыл булганга, аны Казынды дип атаганнар.

Тора-бара елга кичү биргән, урынын табып, аны күперсез дә чыгып йөри башлаганнар. Шулай итеп, ул буйсынган, күнгән. «Елга күнде әзрәк» дигән сүзләрне бергә кушып, «Күндерәк» дигән сүз ясалган. Елгага да Күндерәк дип исем кушканнар.

Хәлиулла килеп утырганда, тирә-якта беркем дә яшәмәгән, авыллар булмаган. Ул тирә-як белән танышып, шунда яшәргә калган.

Тора-бара Хәлиулла янына кешеләр күпләп килеп яши башлаган, авыл барлыкка килгән. Чишмә сулары бик тәмле булганга, авылны башта «Сок чишмә» дип атаганнар. Җимеш суларын «сок» диләр. Чишмә суын да яратканга, сок дәрәҗәсенә күтәргәннәр. «Сок чишмә» дип әйтү дә җөмлә төзелеше ягыннан гарәпчәгә якын. Татарча булса, «Чишмә согы» булыр иде.

Авыл халкы Хәлекәй бабайны бик яратканга, аны Хәлекәй бабай дип атый башлаган. Беләсең, *-кай*/*-кәй* кушымчалары сөйкемле, ягымлы кешеләрне атау өчен яңа исемнәр ясалганда кулланыла. Аның исемен мәңгеләштерү максатында, авылга Хәлекәй исеме кушылган.

1754 елның 3 маенда мишәрләр белән Юрматы волосте башкортлары арасында төзелгән килешү буенча, юридик яктан Хәлиулла бабай хөрмәтенә Хәлекәй дип аталган яңа авыл барлыкка килгән.

Хәлиулла киң күңелле, белемле, гарәпчә дә белгән кеше булгандыр. Авыл тирәсендәге атамалар да борынгылар, хәтта гарәпчәләре дә бар. Авылдан ерак түгел Хөҗрә дип аталган тау һәм чокыр бар. Хөҗрә – гарәп сүзе, татарчасы – «бәләкәй бүлмә». Гарәпләр монастырьдагы бәләкәй бүлмәне «хөҗрә» дип атаганнар. Бу атама – бүлмәне шулай дип атау пәйгамбәр Мөхәммәд галиәссәлам заманыннан ук килә. Хәлекәй авылы янындагы Хөҗрә чокыры өч яктан таулар белән уратылган, көньяктан ачык, башка чокырлар белән чагыштырганда зур түгел, әйтерсең лә бүлмә.

Өч бүлкәле озын тауны, атлары дулап, арбалары авып, михнәтләр күреп, кешеләр үлгәч, Әҗәл тавы дип атаганнар.

1784 елның 8 июль килешүе буенча Хәлекәй авылына дәүләт крестьяннары катламындагы татарлар, дүрт елдан соң 27 типтәр кушылган. Менә шулай авыл барлыкка килгән.

*2011 елда «Хәлекәйнең чал тарихы» китабы*
*авторы Хәлил Салиховтан БДУ талибәсе*
*Айсылу Баһаветдинова язып алган*

### *6. Күндерәк елгасы*

Хәлекәй бабай белән Җәмилә әбинең бер генә уллары була. Аны Күндерәк дип йөртәләр.

Бервакыт шушы төбәкләрдә корылык була. Тауларда үләннәр калмый, урман эчләре шомлы төс ала, су юклыктан маллар кырыла, кешеләрнең кәефләре булмый. Кечкенә елгалар кибеп бетә, ә гүзәл Агыйдел бик ерак.

Күндерәк кешеләрне бу бәладән коткару турында уйлана башлый. Тик ничек соң? Егет озак уйлап тормый, күзе кайсы якка карый, шул якка таба атлый башлый. Мөхәммәтдин авылына җитәрәк бер тавыш ишетеп, сагаеп кала, ләкин беркем дә күренми. Бу эчке тавыш егеткә ерак түгел урнашкан соры ташка басып, тылсымлы сүзләрне кабатларга куша. Егет, тавышка буйсынып, күңеленә килгән сүзләрне кабатлый башлый. Кинәт җир астыннан салкын, шифалы су күзе бәреп чыга. Егет озак уйлап тормый, чишмәне үз артыннан ияртеп, авылга таба чаба. Авыл уртасыннан чишмә Ашкадарга барып кушылганчы, алдын-артын

карамыйча йөгерә дә йөгерә. Шушы егет хөрмәтенә ул барлыкка китергән елганы Күндерәк дип атаганнар.

*2011 елда Хәлекәй авылында яшәүче*
*Суфия Әхмәровадан БДУ талибәсе*
*Айсылу Баһаветдинова язып алган*

### 7. «Тайсуган» һәм «Этаскан»

Кайчандыр Хәлекәй авылында бер егет яши. Аның чабышкы вакытларында ал бирми торган аты була. Авылдагы бик күп кешеләрнең аңа күзләре төшә. Озакламый бу ат хуҗасына бөдрә койрыклы, нечкә сыйраклы, балык кебек шома тәнле, капкара күзле бер колын бүләк итә. Авыл картлары аңа сокланалар һәм аның әнисеннән дә шәбрәк чабышкы булачагын әйтәләр. Көнчелләр бу колынны юк итәргә була.

Ат, бер хафасыз, колыны белән тугайда үлән уртлап, көмеш кебек сулардан авыз итеп, кояш нурында иркәләнеп, әнисе кырында йөрүен белә. Әнисе дә һич аны-моны сизми. Ләкин байның боерыгы буенча аны тотып суялар. Шул урыннан ерак та китмичә, байның үзенең этен дә каен агачына асып китәләр. Моны бай махсус, начар эшен яшерү өчен, үзенә кара күләгә төшмәсен өчен эшләтә.

«Кырын эш кырык елдан соң да беленә», – дип борынгылар юкка гына әйтмәгән. Әлбәттә, байның кара эше ачыклана, тик инде соң була. Шунлыктан бу җирләрне «Тайсуган» («тай суйган урын») һәм «Этаскан» («эт аскан урын») дип йөртә башлыйлар, бүген без дә шулай дип атыйбыз.

*2011 елда Хәлекәй авылында яшәүче*
*Суфия Әхмәровадан БДУ талибәсе*
*Айсылу Баһаветдинова язып алган*

### 8. Котып чокыры

Ибракай авылы яныннан кайчандыр кыргызлар мал куган. Шул вакытта Ибракай авылы кешеләре кыргызлар белән сугышка чыккан. Сугыш вакытында кыргызлар шушы чокырда Котып

исемле егетне ук белән атып үтергәннәр. «Котып чокыры» атамасы шуннан калган.

*1998 елда Стәрлебаш мәктәбе музеенда*
*укытучы М. Мөхәммәтҗанов кульъязмаларыннан*
*Зөлфия Латыйпова күчереп алган. –*
*БДУ ТФҺМК ФФ; Фазлетдинов, 2018. – Б. 111*

### *9. Поскын чокыры*

Пугачев явы бастырылганнан соң баш күтәрүчеләр шушы чокырда качып-посып яталар. Шуңа да ул «Поскын чокыры» дип атала.

*1998 елда Стәрлебаш мәктәбе музеенда*
*укытучы М. Мөхәммәтҗанов кульъязмаларыннан*
*Зөлфия Латыйпова күчереп алган. –*
*БДУ ТФҺМК ФФ; Фазлетдинов, 2018. – Б. 121*

### *10. Мамин урамы*

Урман эчендә урнашкан бәләкәй генә авылга әйбәтләп көн күрер өчен, төрле һөнәргә ия булган кешеләр кирәккән. Шулай итеп, төрле авыллардан монда тагын берничә гаилә килеп төпләнгән.

Шулай, халык саны артып, авыл зураеп яшәп ятканда, тирәяктагы урыс авылларыннан баскынчылар килеп, малларны куып алып киткәннәр, кешеләрнең бар булган мөлкәтен тартып алганнар. Халыкны төрлечә кыерсытканнар. Моңа түземлеге беткән авыл халкы киңәшләшеп, генерал Маминга прошение белән кеше җибәрәләр. Аңа яңа җирдә кыерсытылуларын сөйләп бирәләр. Мамин берничә гвардеецын авылны сакларга җибәрә. Шулай итеп, бу гвардеецлар үзләре бер урам булып төпләнәләр. Морза Маминга рәхмәт йөзеннән, ул урамны «Мамин урамы» дип атый башлыйлар.

*1998 елда Стәрлебаш мәктәбе музеенда*
*укытучы М. Мөхәммәтҗанов кульъязмаларыннан*
*Зөлфия Латыйпова күчереп алган. –*
*БДУ ТФҺМК ФФ; Фазлетдинов, 2018. – Б. 127)*

### *11. Ясаклылар урамы*

Бу урам Стәрлебашта урнашкан. Элек монда махсус ясак түләүче татарлар яшәгән, диләр. Исеме дә шуннан калган икән.

*1998 елда Стәрлебаш мәктәбе музеенда*
*укытучы М. Мөхәммәтҗанов кульязмаларыннан*
*Зөлфия Латыйпова күчереп алган. –*
*БДУ ТФҺМК ФФ; Фазлетдинов, 2018. – Б. 136*

### *12. Бүре бүләге җире*

Бу җирдә элек бүреләр күпләп яшәгән. Ачлыктан алар кешеләргә һәм малларга һөҗүм иткәннәр. Сунарчылар күмәкләшеп барып, бүре аулаганнар. Вакыт узган саен бүреләр кимегән, башка урманнарга качкан. Алардан калган урынны авылыбызда яшәүче Гатаулла бабай «Бүре бүләге» дип атаган. Шулай итеп, бу атама халык теленә кереп киткән.

*1998 елда Стәрлебаш мәктәбе музеенда*
*укытучы М. Мөхәммәтҗанов кульязмаларыннан*
*Зөлфия Латыйпова күчереп алган. –*
*БДУ ТФҺМК ФФ; Фазлетдинов, 2018. – Б. 182*

### *13. Байгара тавы*

Әүвәл бу җир җәнлекләргә, җиләк-җимешкә бик бай булган. Анда агачтан-агачка сикереп йөрүче күпшы тиен дә, урман хуҗасы аю да, башка җәнлекләр дә яшәгән.

Тау эргәсендә урыс авылы булган. Алар бу урынны урысча «богатая гора» – «бай гора» дип йөрткәннәр. Менә шуннан «Байгара тавы» дигән атама торып калган да инде.

*1998 елда Стәрлебаш мәктәбе музеенда*
*укытучы М. Мөхәммәтҗанов кульязмаларыннан*
*Зөлфия Латыйпова күчереп алган. –*
*БДУ ТФҺМК ФФ; Фазлетдинов, 2018. – Б. 189*

### *14. Сискал тау*

Элек монда Тәпәнәй исемле чуваш яшәгән. Ул малайлары белән шушы тау борынында каен тузыннан сагыз кайнатып, шуңа елкы

мае кушып, арба майлар өчен дегет ясаган һәм Оренбург якларына алып барып, игенгә, онга алыштырып кайта торган булган.

Шундый керемле урын табу шатлыгыннан Тәпәнәй карт: «Хорошее место сыскал!» – дип кычкырып җибәргән, имеш. Шушы сүздән соң бу урын «Сискал тау» исемен ала. Бу тауда чуашларның сагыз кайнаткан мич урыннарын әле дә табып була.

*1998 елда Стәрлебаш мәктәбе музеенда*
*укытучы М. Мөхәммәтҗанов кулъязмаларыннан*
*Зөлфия Латыйпова күчереп алган. –*
*БДУ ТФҺМК ФФ; Фазлетдинов, 2018. – Б. 195–196*

### *15. Бикмәт тавы*

Әүвәл авылда Бикмәт исемле бер карт яшәгән. Берчакны ул урманга утын артыннан киткән. Чыбык-чабыкны бау белән бәйләп, күтәреп алып кайтып килгәндә, юлда буран чыккан, һәм Бикмәт шушы тауда туңып үлгән. Шуңа да ул «Бикмәт тавы» дип атала.

*1998 елда Стәрлебаш мәктәбе музеенда*
*укытучы М. Мөхәммәтҗанов кулъязмаларыннан*
*Зөлфия Латыйпова күчереп алган. –*
*БДУ ТФҺМК ФФ; Фазлетдинов, 2018. – Б. 200*

### *16. Көмеш ташы*

Борын заманда бу таш су төбендә яткан. Тимергали исемле егет үзе кебек унбер батыр белән ташны тартып чыгарып, яр башына утырткannar.

Җәйге печән вакыты булган бу. Төшке ашка туктагач, хатын-кызлар шушы урынга су керергә килгәннәр. Көмешбикә исемле кыз шушы ташка сөялгән. Шулчак таш әйләнеп китеп, тегене баскан да куйган. Кешеләр чакырып, ташны күтәреп карасалар, Көмешбикәнең бер җире дә имгәнмәгән икән.

Шул көннән башлап ташны кызның исеме белән, «Көмешбикә ташы» дип атап, тау башына мендереп утырткannar. Вакыт үтә-үтә, атама кыскарып, «Көмеш ташы» булып кына калган.

*1998 елда Стәрлебаш мәктәбе музеенда*
*укытучы М. Мөхәммәтҗанов кулъязмаларыннан*
*Зөлфия Латыйпова күчереп алган. –*
*БДУ ТФҺМК ФФ; Фазлетдинов, 2018. – Б. 212–213*

### *17. Рәйхан тавы*

Ибраһим авылында революциягә тиклем чибәрлеге белән дан тоткан, мәрхәмәтле, бик уңган Рәйхан исемле кыз үсә. Аның матурлыгына сокланып, күп егетләр гашыйк булалар. Рәйханның ата-анасы бик ярлы яшиләр. Ул гаиләдә бердәнбер бала була. Кыз үзе кебек үк ярлы егетне ярата.

Алар кичен, кеше күрмәгәндә, авыл кырындагы биек тау башында очраша торган булалар, вәгъдәләр куешалар. Ләкин үзенә бишенче хатынлыкка алу уе белән янып, Рәйханны күрше авыл мулласы сагалый башлый. Ул гашыйкларны очрашкан урыннарында көтеп, качып тора. Егет белән кызны күргәч, пычак белән алар өстенә ташлана. Ләкин егетне чәнчим дип, буталып, пычакны кызга казый.

Шушы вакыйгадан соң, кызның әти-әнисе сарыга сабыша. Ә егет сөеклесен үзләре очрашкан тау башында җирләттерә дә читкә чыгып китә. Тау шуннан соң «Рәйхан тавы» дип атап йөртелә башлый.

*1998 елда Стәрлебаш мәктәбе музеенда*
*укытучы М. Мөхәммәтҗанов кулъязмаларыннан*
*Зөлфия Латыйпова күчереп алган. –*
*БДУ ТФҺМК ФФ; Фазлетдинов, 2018. – Б. 224*

### 18. Аждаһа ерымы

Борынгылар сөйләве буенча, бервакыт бу урында җир астыннан аждаһа килеп чыккан. Ул үзенең озын койрыгын болгап, артыннан чокырлар, ерымнар калдырган. Бу урын шуңа күрә «Аждаһа ерымы» дип атала да инде.

*1998 елда Стәрлебаш мәктәбе музеенда*
*укытучы М. Мөхәммәтҗанов кулъязмаларыннан*
*Зөлфия Латыйпова күчереп алган. –*
*БДУ ТФҺМК ФФ; Фазлетдинов, 2018. – Б. 255*

### *19. Сәфәр елгасы*

Авылыбызның бер кешесе күрше 25 чакрым авылга кунакка киткән. Бу авылга беренче тапкыр гына барган була, шуңа юлны

белмәгән. Шулай, бара торгач, моңа бер елга очрый, һәм ул елга буйлап авылга барып җитә.

Кайтканда, югалмас өчен, бу Сәфәр исемле кеше тагын шул юлдан кайта. Шулай итеп, елга буенча күрше авылга сукмак салына. Ә елганы менә шушы кеше исеме белән Сәфәр елгасы дип атый башлыйлар.

*2000 елда Тәтер-Арслан авылында яшәүче*
*Йосыпова Рәшидә Шакир кызыннан (1934 елгы)*
*Илира Юнысова язып алган. – БДУ ТФҺМК ФФ*

### *20. Урыс елгасы*

Бу елга төньяктан безнең Тәтер елгасына ага. Элекке заманнарда бу елга буена ерак җирләрдән урыслар килеп утыра. Һәм безнең авыл халкы елганы Урыс елгасы дип атый.

*2000 елда Тәтер-Арслан авылында яшәүче*
*Йосыпова Рәшидә Шакир кызыннан (1934 елгы)*
*Илира Юнысова язып алган. – БДУ ТФҺМК ФФ*

### *21. Комчокыр елгасы*

Авыл кешеләре бер чокырдан ком чокып алган була. Һәм шулай ком чокыганда, инеш килеп чыга. Бу инешкә башка күп инешләр агып төшеп, елга була. Комчокыр елгасы шуннан китә.

*2000 елда Тәтер-Арслан авылында яшәүче*
*Йосыпова Рәшидә Шакир кызыннан (1934 елгы)*
*Илира Юнысова язып алган. – БДУ ТФҺМК ФФ*

### *22. Ташкүпер инеше*

Элек монда бер мулла яшәгән. Аның йортын күршесе белән бер инеш аерып аккан була. Шушы инеш аркылы сикереп чыгып йөрмәс өчен, мулла таштан зур күпер салдыра. Шулай итеп, инешне Ташкүпер инеше дип атыйлар.

*2000 елда Тәтер-Арслан авылында яшәүче*
*Йосыпова Рәшидә Шакир кызыннан (1934 елгы)*
*Илира Юнысова язып алган. – БДУ ТФҺМК ФФ*

### 23. Җитен елгасы

Бу елга буенда элек-электән күп итеп җитен үскән. Авыл халкы, җитенне җыеп, сүс ясаган һәм аңардан киндер суккан булганнар. Менә шуңа күрә Җитен елгасы дигәннәр.

*2000 елда Тәтер-Арслан авылында яшәүче*
*Йосыпова Рәшидә Шакир кызыннан (1934 елгы)*
*Илира Юнысова язып алган. – БДУ ТФҺМК ФФ*

### 24. Бүреле кое

Бер карчык коега суга барган. Су алам дип, коега иелсә, бүрегә охшаган бер нәрсә күрә. Һәм «Бүре, бүре!» – дип кычкыра-кычкыра өенә таба йөгерә. Шуннан бирле бу коены Бүреле кое дип атыйлар.

*2000 елда Тәтер-Арслан авылында яшәүче*
*Йосыпова Рәшидә Шакир кызыннан (1934 елгы)*
*Илира Юнысова язып алган. – БДУ ТФҺМК ФФ*

### 25. Әпәкәй урманы

Безнең авылга элекке вакытларда ачлык килгән булган. Авыл халкы ачтан үлмәс өчен, тамакларын ничек тә туйдырыр өчен, урманга күчеп киткән. Шунда алар үлән тамырлары, кыргый җимеш ашап көн күргәннәр.

Әниләре балаларын «әпекәй» («ипи» сүзеннән) дип ашата торган булган үләнне. Шул «әпекәй»дән «әпәкәй»сүзе килеп чыккан. Шуңа урманга Әпәкәй урманы дип исем кушканнар.

*2000 елда Тәтер-Арслан авылында яшәүче*
*Йосыпова Рәшидә Шакир кызыннан (1934 елгы)*
*Илира Юнысова язып алган. – БДУ ТФҺМК ФФ*

### 26. Шәйбәк табыры

Озак еллар Шәйбәк исемле бер карт колхоз сыерларын көткән. Аның үзенә генә маллар йөртә торган җире һәм табыры булган. Бу табырны әле дә Шәйбәк табыры дип исемләп йөртәләр.

*2000 елда Тәтер-Арслан авылында яшәүче*
*Йосыпова Рәшидә Шакир кызыннан (1934 елгы)*
*Илира Юнысова язып алган. – БДУ ТФҺМК ФФ*

### *27. Зөһрә кыз*

Таһир белән Зөһрәнең мәхәббәтенә тиң мәхәббәт юктыр. Алар бер-берсен күрмичә тора алмыйлар. Зөһрә кыз шундый чибәр була. Таһир кызның гүзәллегенә таң кала, сөйкемлелегенә соклана.

Берчак җиргә афәт килә. Сугыш башлана. Таһир да туган җирен дошманнардан сакларга китәчәк.

Менә гашыйкларның соңгы кичләре. Алар Мәхәббәт күле янында очрашалар. Куллар кулга, иреннәр иренгә үрелә.

– Тиздән җиңү яулап кайтырмын, – ди Таһир.

– Мин сине көтәм, тиз кайт! – ди Зөһрә.

Зөһрә һәр көнне кич күл буена суга килә, Таһирны искә төшерә, Ходайдан исән кайтуын сорый.

Менә сугыш кырыннан кара кәгазь килә – Таһир һәлак булган.

Кич белән Зөһрә көянтә-бидрәләре белән серле күл буена килә. Күлдә – ай шәүләсе. Зөһрә кыз яшьләрен түгә, бик кайгыра. Ул кинәт кенә елавыннан туктый һәм Таһирына эндәшә: «Сөеклем, мине дә үз яныңа ал!» – ди дә күлгә ташлана.

*2000 елда Тәтер-Арслан авылында яшәүче*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
*Габитова Нажҗия Әюповадан (1952 елгы)*
*Илира Юнысова язып алган. – БДУ ТФҺМК ФФ*

ШАРТЛЫ КЫСКАРТМАЛАР

**БДУ ТФҺМК ФФ –** Башкорт дәүләт университеты татар филологиясе һәм мәдәнияте кафедрасы фольклор фонды;

**Фазлетдинов, 2018 –** Башкортстан татарлары фольклоры. Риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр, сөйләкләр / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни мөхәррире Ә.М. Сөләйманов. Уфа: Китап, 2018. 344 б.

**Авторлар турында кыскача белешмә**

*Миңнуллин Ким Мөгаллим улы* – филология фәннәре докторы, профессор, ТР Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры.

*Булатова Миңнира Рәхим кызы* – филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре.

*Насыйбуллина Нуридә Шәйдулла кызы* – филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре.

*Фазлетдинов Илдус Камил улы* – филология фәннәре кандидаты, доцент; Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе һәм мәдәнияте кафедрасы доценты; ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге фәнни хезмәткәре.

*Ямалтдинов Ильмир Илдар улы* – филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге мөдире.

*Яхин Фәрит Зәкиҗан улы* – филология фәннәре докторы, профессор, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре.

## ЭЧТӘЛЕК


КЕРЕШ = ВВЕДЕНИЕ
5

ТАТАР ТЕЛЕ УРТА ДИАЛЕКТЫНЫҢ
МИНЗӘЛӘ СӨЙЛӘШЕ БӘЛӘБӘЙ УРЫНЧЫЛЫГЫ
*Миңнира Булатова*
26

ТАТАР ТЕЛЕ КӨНБАТЫШ ДИАЛЕКТЫНЫҢ
СТӘРЛЕТАМАК СӨЙЛӘШЕ
*Миңнира Булатова*
87

БАШКОРТСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СТӘРЛЕБАШ РАЙОНЫ ТАТАРЛАРЫНА СӘЯХӘТ
*Фәрит Яхин*
131

О КУЛЬТУРНОМ НАСЛЕДИИ И ИСТОРИИ
СТЕРЛИБАШЕВСКОГО МЕДРЕСЕ
*Нурида Насибуллина*
154

БАШКОРТСТАННЫҢ СТӘРЛЕБАШ РАЙОНЫ
ТАТАРЛАРЫ ЗАМАН ФОЛЬКЛОРЫ
*Ильмир Ямалтдинов*
168

СТӘРЛЕБАШ РАЙОНЫ ТАТАРЛАРЫ РИВАЯТЬЛӘРЕНЕҢ
ТАРИХИ ҺӘМ МИФОЛОГИК НИГЕЗЛӘРЕ
*Илдус Фазлетдинов*
406

Научно-популярное издание
*Серия «Из сокровищницы научных экспедиций»*

**Национально-культурное наследие**

**ТАТАРЫ БАШКОРТОСТАНА. СТЕРЛИБАШ**
**1 часть**

2-е издание

Фәнни-популяр басма
*«Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясе*

**Милли-мәдәни мирасыбыз**

**БАШКОРТСТАН ТАТАРЛАРЫ. СТӘРЛЕБАШ**
**1 нче кисәк**

2 нче басма

Редактор: *Л.Г. Шәрифуллина*
Компьютерда биткә салучы *Н.Т. Абдуллина*

Китапта *Л.М. Шкляева, Н.Ш. Насыйбуллина*
фоторәсемнәре файдаланылды

Басарга кул куелды 20.01.2021.
Форматы 60×84 $^{1}/_{16}$. Офсет кәгазе. Times New Roman гарнитурасы.
Офсет басма. Нәшер-хисап табагы 19,75. Шартлы басма табагы 25,6.
Тиражы 500 д. Заказ

Оригинал-макет
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшләнде
420111, Казан, К. Маркс ур., 12

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты
420111, Казан, Бауман ур., 20

ИСКӘРМӘЛӘР ӨЧЕН